# КАЗАН УТЛАРЫ

12. 1992



## КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Башка күп кенә газета-журналлар кебек, матди ярдәм алу өчен, без дә **Редакция фонды** оештырдык. Татарстанда, Россиядә, БДБ дәүләтләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә мөрәҗәгать итәбез. Безгә ярдәм итәргә теләүчеләр булса, хәл кадәри акчаларын түбәндәге адрес белән күчерә алалар:

**420066, г. Казань, ул. Декабристов, 1. Волжско-Камский акционерный банк РКЦ ГЦБ. Р/счет № 700161998/2345114 МФО 265005. Для Фонда Редакции.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**12**

**(842)**

**1992**

КАЗАН

## *Бу санда*

ДРАМАТУРГИЯ

**И. ЮЗЕЕВ.** Ак калфагым төшердем кулдан... *Халык драмасы* . . . . . . . . . . . . . . . 3

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

**К. ЛАТЫЙП.** Иман кәрваны. *Шигырьләр* . . . . 22
**М. ШАҺИМӘРДӘН.** Кеше күңеле — карурман. *Повесть* . . . . . . . . . . . . . . . 26
**М. ХӨСӘЕН.** Моң канатларында. *Шигырьләр* 129
**Р. ШӘФИ.** Күтәр башыңны, татар! *Шигырьләр* 135
**Җ. МОСТАФИН.** Шәҗәрә. *Хикәя* . . . . . . 138

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

**Ә. ТИМЕР.** Бөек шәхесләребезнең берсе . . . 143

ПУБЛИЦИСТИКА

**Н. БУЛАТОВ.** Туган туфрак җылысы . . . . 161

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Ф. БӘШИР.** Галиҗанап сүз остасы . . . . . . 167
Укучы сүзе . . . . . . . . . . . . . . . 174

СӘНГАТЬ

**Г. БӘШИРОВ.** Күңеле тулы җыр иде . . . . . 178
**Б. КАМАЛОВ.** Сагындыра каләмдәш . . . . . 181
Безнең календарь . . . . . . . . . . . . 184
1992 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге . 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
**Марсель Әхмәтҗанов**

Б е з н е ң  а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Драматургия»: народная драма И. ЮЗЕЕВА.
«Проза и поэзия»: повесть М. ШАГИМАРДАНОВА «Душа человека — дремучий лес», рассказ ДЖ. МУСТАФИНА «Родословная», стихи К. ЛАТЫПОВА, М. ХУСАИНА, Р. ШАФИ.
«Из истории народа»: статья А. ТИМЕР «Один из выдающихся».
«Публицистика»: статья Н. БУЛАТОВА «Тепло родной земли».
«Литературная критика»: статья Ф. БАШИРОВА «Мастер слова» об известном писателе А. Еники.
«Искусство»: статья Г. БАШИРОВА о народном артисте Татарстана Р. Ваганове.
Воспоминание Б. КАМАЛОВА о писателе Г. Мухаметшине.
«Наш календарь».
Дневник общественно-политической жизни.
«На наших обложках»: картина уфимского художника Р. Кираева «Окраина»; известный писатель, лауреат премии Г. Тукая Г. Рахим.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 3.11.92 ел. Басарга кул куелды 7.12.92 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 23961. Заказ В-504. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

**Илдар Юзеев**

# АК КАЛФАГЫМ ТӘШЕРДЕМ КУЛДАН...

ХАЛЫК ДРАМАСЫ

САН-ФРАНЦИСКО — КАЗАН ТЕЛЕВИЗИОН КҮПЕРЕНДӘ КАТНАШАЛАР:

**Сан-Франциско ягыннан:**

Сафия Нурхан — очраштыручы
Тайфур Кормаш — 35 яшьтә.
Жак — 67 яшьтә.
Катрин Люсиль — 57 яшьтә.
Майк Стерн — 67 яшьтә.
Клиффорд Стреттон — 40 яшьтә.
Гөлнур Галәветдин — 35 яшьтә.
Ратмир Зәкиевский
Зөбәйдә Прайс.

**Казан ягыннан:**

Клара Измайлова — очраштыручы
Регина — 35 яшьтә.
Шәмсия Ишмуллина — 85 яшьтә.
Исмай Акчурин — 57 яшьтә.
Иванов Павел Николаевич — 70 яшьтә.

Алар безнен көннәрдә берьюлы Сан-Францискода һәм Казанда очрашалар.

## БЕРЕНЧЕ АКТ

### Беренче күренеш

**Казан телестудиясендә Клара Измайлованың эш бүлмәсе.**

Клара *(телефонда сөйләшә)*. Димәк, сценарийны расладыгыз? Рәхмәт! Бер генә кимчелеге? Әйтегез, шеф! Кадрия ханымны төшереп калдырырга? Кырмыска оясына таяк тыгарга кирәкмәс? Аннан котылу җиңел булмас... Ярый, җаен табарбыз! Ышанычыгызны акларга тырышырбыз!

Акчурин *(керә)*. Мөмкинме?

---

Илдар ЮЗЕЕВ (1933) — *шагыйрь, драматург; татар, башкорт, рус телләрендә дөнья күргән егермедән артык («Мәхәббәт китабы», «Кыр казлары артыннан», «Мәңгелек белән очрашу» һ. б.) китап авторы. Татарстанның Г. Тукай һәм М. Җәлил бүләкләре лауреаты. Казанда яши.*

Клара. Әйдәгез, Исмай Саттарович, узыгыз!

Акчурин. Исәнмесез, Клара Измайловна! Тагын нинди олы мәшәкатьләр көтә безне?

Клара. Сизеп торасыз, бер генә сәяси чара да сездән башка үтә алмый. Сан-Франциско телевидениесе безне очрашуга чакыра.

Акчурин. Американнар белән?

Клара. Татарлар белән!

Акчурин. Юк, юк! Мине катнаштырмагыз, бу юлы миннән башка!..

Клара. Исмай Саттарович, сез бу очрашуның тоткасы...

Акчурин. Гафу үтенәм... Мине сызыгыз! Дөнья — куласа...

Клара. Исмай Саттарович... сез бөтен дөньяга күрсәтеп горурланырлык мәшһүр рәссамыбыз!

Акчурин. Башканы табыгыз! Вакытым юк! Иҗат!

Клара. Сценарий расланган, фамилияләр хәл ителгән!

Акчурин. Шулаен шулай да... авырып торам...

Клара. Борчылмагыз. Сценарийда сүзләрегез язылган. *(Бирә.)*

Акчурин. Анысы ярый. Нигә соң мин, нигә мин?!

Клара. Кыскасы, сезне Майк Стерн әфәнде очрашуга үзе чакыра.

Акчурин. Майк... Стерн?

Клара. Аны Сан-Францискодагы коллегаларыбыз эзләп тапканнар.

Акчурин. Ул... исән?

Клара. Үз күзләрегез белән күргәч, ышанырсыз.

Акчурин. Әйе... сез миңа гаять авыр җаваплы миссия йөклисез. Сез бит татарлар белән генә дигән идегез?

Клара. Милли чикләнүдән коткару өчен, без сезне чакырдык та инде, Исмай Саттарович... Киләсе якшәмбегә, сәгать бишкә көтәбез!

Акчурин. Хуш иттек! *(Чыга.)*

Шәмсия *(керә)*. Рөхсәтме?

Клара. Рәхим итегез! Сез Шәмсия апа Ишмуллинамы?

Шәмсия. Рәхмәт, сенелем, әллә каян танып торасың.

Клара. Утырыгыз, апа!

Шәмсия. Шулкадәр ерактан килгәч, утырмый да булмас. Сиксән биш яшьлек карчыкның кемгә кирәге чыкты, сенелем?

Клара. Без сине бөтен дөньяга күрсәтергә уйлыйбыз, Шәмсия апа.

Шәмсия. Беткәнмени унҗиде яшьлек чибәрләр, дөньяның тоткасы булырлык асыл хатын-кызлар?

Клара. Сез бер дә алардан ким түгел. Бездә татарча да, русча да, инглизчә дә белүчеләр бармак белән генә санарлык.

Шәмсия. Анысы шулайдыр... Минем инглизчә сөйләшүне каян белдегез, кызым?

Клара. Әтиегез Фәтхетдин Ишмуллинның революциягә кадәр үк инде Америкада укуын беләбез.

Шәмсия. Дөрес, атам бик тә мәгълүматлы кеше булган. Әмма аны революциядән соң, чит ил белән бәйләнешләре өчен, атканнар...

Клара. Тапшыруда сез анысын әйтмәссез.

Шәмсия. Нинди тапшыру?

Клара. Без сезне Америка татарлары белән үткәреләчәк телевизион күпердә катнашырга чакырабыз.

Шәмсия. Атам язмышы кабатланмасмы?

Клара. Дөнья үзгәрде, апа, курыкмагыз.

Шәмсия. Нинди телдә сөйләшергә?

Клара. Нигездә, татарча... Кирәге чыкса, инглизчә дә... Менә, сценарийда сүзләрегез язылган. Шушы фикер кысасыннан чыкмагыз.

Шәмсия. Алар... качып киткән татарлармы?

Клара. Төрлесе бар. Анда туганнары да...

Шәмсия. Минем өчен алар... илен сатучы хыянәтчеләр. Кызып китеп, әлләниләр сөйләп ташламасам ярый...

Клара. Шуның өчен сценарий төзелә дә инде. Без сезнең патриотик хисләрегезгә ышанабыз.

Шәмсия. Тормышым-язмышым турында сорасалар?

Клара. Ягъни мәсәлән?

Шәмсия. Сез бәхетлеме, бәхетсезме? дип...

Клара. Ничек җавап бирер идегез?

Шәмсия. Мин бәхетле дә...

Клара. Аргумент?

Шәмсия. Совет илендә яшәвем белән...

Клара. Дөрес!

Шәмсия. Мин бәхетсез дә... үзара әйткәндә...

Клара. Ни өчен?

Шәмсия. Гомеремдә бер тынычлык күрмәдем. Сугыш та ачлык... Ачлык та сугыш... «Атаң революция дошманы» дип, яшьлегемне сүндерделәр. Аннан сугышта ирем, балам ятып калды. Бердәнбер юанычым шул: ил өчен башларын салдылар. Уйлап карасаң, шулмы инде бәхет? Җитмеш ел буе рәхәт, гадәти тормыш күрмә, имеш... Үзара әйткәндә... Гел «давай! давай!» дигән боерыкка буйсынып яшәдек инде...

К л а р а. Син боларын сөйләмәссең инде, апа.

Ш ә м с и я. Сөйлимме соң... Авызың тулы кара кан булса да, дошманың алдында авызыңны ачма, диләр. Үзебезнең абруйны төшерәмме соң? Ни кушсалар, шуны сөйләп өйрәнгән инде без, кызым...

К л а р а. Мин сиңа ышанам, Шәмсия апа.

Ш ә м с и я. Без инде шул, гадәтләнгәнчә, язылганны ятлап килербез.

К л а р а. Киләсе якшәмбегә, сәгать бишкә көтәбез!

Ш ә м с и я. Аңладым, кызым. Хушисән булыйк! *(Чыга.)*

И в а н о в *(керә)*. Чакырган җиргә керергә ярыйдыр?

К л а р а. Керегез!

И в а н о в. Иванов.

К л а р а. Клара Измайлова. Баш редактор. Зәңгәр экранда Сан-Франциско белән Казанны очраштыручы.

И в а н о в. Мине көрәшергә чакыргансыздыр инде? Американнар белән рәхәтләнеп бил алышам. Сөлгене дә алып килдем. Ну, брат!

К л а р а. Физик мәгънәдә түгел, идея көрәше!

И в а н о в. Минем өчен аермасы юк. Безнең бөтен нәселебез — көрәшчеләр. Бөтен тормышыбыз — сугыш та көрәш...

К л а р а. Бу юлы дусларча көрәш. Америка татарлары белән.

И в а н о в. Керәшен абзагызда бөтен дөньяның татарлары белән көрәшерлек көч бар әле. Ну, брат!

К л а р а. Сезгә ничә яшь?

И в а н о в. Җитмеш. Җә?

К л а р а. Җитмеш? Америка татарлары сезнең авыл сабантуена килделәрме?

И в а н о в. Ну?

К л а р а. Былтыргы сабантуебызның батыры кем?

И в а н о в. Иванов!

К л а р а. Кайсысы?

И в а н о в. Минем онытым. Җә?

К л а р а. Сез ялгыш килгәнсез. Американнар яшь батыр белән очрашырга телиләр.

И в а н о в. Ул килми. «Тел тегермәне тартырга вакытым юк», — ди.

К л а р а. Алайса, сезгә кайтып китәргә туры килер.

И в а н о в. Җә инде, илле ел бил бирмәгән Иванов шулкадәр җирдән килгәч, американнар белән сүз көрәштермичә ничек кайтып китсен? Теләсәләр, мин әле җырлый да беләм! *(Керәшенчә җырлап җибәрә.)*

*Авылыбызда бер матур бар,*
*Әйдә салыйк шобага!*

К л а р а. Ярый, калыгыз... Сценарийны бозып булмый инде. Иванов тек Иванов. Батыр тек батыр... Әмма зинһар өчен хәзерге кебек күп сөйләшмәгез. Менә бу тексттан чыкмагыз!

И в а н о в *(ала)*. Авызыма су каптым, җә! Бетте! Тагын берне генә җырлап җибәрим дә! *(Җырлый.)* Җә?

К л а р а. Минем өчен генә ярый... Якшәмбегә, сәгать бишкә!

И в а н о в *(честь бирел)*. Дошман алдында бил бирмәбез, брат, алла бирсә! *(Чыга. Телефон чылтырый.)*

К л а р а *(трубканы ала)*. Регина Хәбиб? Үткәрегез! *(Номер җыя.)* Иптәш Байбулатов! Сценарийдагы Хәбиб турында... Кирәк булыр дип уйлыйсыз? Үлем сәбәпләренә кагылмаска? Яхшы, иптәш Байбулатов! *(Регина керә.)* Регина Хәбиб?

Р е г и н а. Әйе.

К л а р а. Утырыгыз.

Р е г и н а. Рәхмәт.

К л а р а. Регина дип кенә дәшәргә мөмкинме?

Р е г и н а. Мөмкин.

К л а р а. Регина, безне бер сорау кызыксындыра. Тарихта Галимҗан Хәбиб дигән күренекле бер шәхеснең булуы билгеле. Аның сезгә ниндидер бәйләнеше бармы?

Р е г и н а. Мин андый кешене белмим.

К л а р а. Дөрес, ул дин әһеле, эшчәнлеге сезнең өлкәгә — сәнгатькә карамый...

Р е г и н а. Бигрәк тә...

К л а р а. Ә бездә аның сезнең туганыгыз булуы турында дәлилләр бар.

Р е г и н а. Нигә әле сез миннән сорау аласыз? Әйтик, ул минем туганым, ди?

К л а р а. Тонны дөрес алмавым өчен гафу итегез... Сез бер дә курыкмагыз. Ул безне тарихи шәхес буларак кызыксындыра.

Р е г и н а. Бөтен мирасны юк иткәннәр. Бер генә документ та сакланмаган.

К л а р а. Ул инде акланган...

Р е г и н а. Атып үтерелеп, алтмыш ел узгач...

К л а р а. Ни өчен гаепләнгәнен беләсезме?

Р е г и н а. Америкага барганы өчен... «Шпион!»

К л а р а. Ул анда ни өчен барганын беләсезме?

Р е г и н а. Юк.

К л а р а. Казан мәчетенең мулласы Галимҗан Хәбиб, Идел буендагы халык ачлыктан кырыла башлагач, 1921 елны делегация составында Америкага бара. Аннан ашлык алып кайталар...

Регина. Сез моны каян белдегез?

Клара. Америкадагы коллегаларыбыз эзләп тапканнар.

Регина. Һәм... күпме халыкның тамагын туйдырып үлемнән коткарып калган каһарман үзе сөргендә ачтан үлә. Хәзер кабере дә юк. Пермь өлкәсендәге зират өстендә завод корганнар.

Клара. Сез инде тапшыруда анысын әйтеп тормассыз...

Регина. Төшенмим.

Клара. Сезне Сан-Франциско телевизион компаниясеннән милләттәшләребез чакыра. Галимҗан Хәбибнең берәр туганын табуны сорадылар. Менә сезнең сөйлисе текстыгыз... *(Бирә.)*

Регина. Текст? Мин шуны укырга тиешме?

Клара. Нәкъ шуны түгел инде... Нигездә...

Регина. Бу сезнең шартыгызмы?

Клара. Шарт дип... Сез андагы фикерләрне үз сүзләрегез белән әйтә аласыз. Сез бит — фәннәр кандидаты...

Регина. Минем ни әйтеремне сез каян беләсез?

Клара. Дошманнарча провокацион сораулар бирелә калса, сак булыгыз, дип кенә әйтүем... Димәк, килештек, киләсез?

Регина. Киләм. Әмма үземнең башым белән!

Клара. Якшәмбе көнне сәгать бишкә көтәбез! Хушыгыз! *(Регина чыга. Телефон чылтырый.)* Кадрия Мөбәрәкова килгән? Юк, хәзер безнең вакытыбыз юк! Үткәрмәгез! Сөйләшүне таләп итә? Клара Измайлова тыңлый. Хөрмәтле Кадрия ханым, бу юлы без сине тапшыруда катнаштыра алмыйбыз. Ни өчен дигәндә, тапшыруга Сан-Франциско үзе чакырган иптәшләр генә киләчәк. Гафу үтенәбез. Хушыгыз! Башка беркемне дә минем янга кертмәгез! Сценарий расланган, бер сүзен дә үзгәртү мөмкин түгел!

## Икенче күренеш

**Телевизор экранында башта Казан, аннары Сан-Франциско ягыннан катнашучылар күренә.**

София Нурхан. Әссәләмәгаләйкем, Советлар берлегендә яшәп ятучы газиз милләттәшләребез, туташлар, ханымнар, әфәнделәр! Без, җиһанның төрле ягына чәчелеп, бүгенгесе көндә бер сөйләшүгә зар-интизар булып гомер кичерүчеләр, сезне кайнар сәламлибез! Америкаи татар җәмгыятенең дә сәламен кабул итеп алыгыз! Таныш булыйк: мин — София Нурхан, япон телевидениесенең комментаторы. Бүгенге күрешүне алып бару өчен мине Сан-Франциско телевидениесе махсус чакырды, чөнки әлегә аларның саф татар телендә чыгарлык дикторлары юк. Сүзне кадерле спонсорларыбыз фин татарларының Тукай җәмгыятенә вә Нью-Йорктагы американ татар җәмгыятенә рәхмәт әйтүдән башлыйк!

Клара. Исәнмесез, София ханым, хәерле кич!

София. О, Клара ханым Измайлова, бездә көн булса да, хәерле кич! Казанда чакта сездә үткәргән кадерле көннәрне вә кичләрне һич онытасым юк. Бабаларыбызның туган җиренә, теленә, җырына, гореф-гадәтләренә берничә көнгә генә кайту да җан яраларын дәвалады сыман.

Клара. Хәтерегездәме, без сезне Казан артындагы ике авылга сабантуйга алып бардык.

София. Сокландыргыч күренешләр!

Клара. Ул вакытта безнең операторыбыз шуннан бер күренеш төшереп алган. Рәхим итеп карагыз!

**Телевизион кадр**

**Кызлар, сулы чиләк күтәреп, йөгерешәләр. София Нурхан да алар белән бергә. Кызлар артыннан җитә алмыйча, ул артта кала, егыла. Чиләктәге сулары түгелә.**

Клара. София ханым, кулыгызны бирегез!

София. Адәм көлкесенә калдым... бөтен халык алдында...

Клара. Борчылмагыз, сезгә барыбер бүләк биреләчәк!

София. Юк, юк... Нигә кунак булган өчен генә... Кирәкми... *(Аңа чиккән ак сөлге бирәләр).* Юк, юк, алмыйм!

Клара. Алмыйча ярамый. Бу — халкыбызның гореф-гадәте. Чабышта иң арттан килгән атның муенына да сөлге салалар.

София. Кичерегез... аңладым... *(Кадр өзелә).*

Сафия. Кабат хатирәләрне яңартуыгыз өчен рәхмәт, Клара ханым. Яшермим, сабантуйда алган иң зур тәэсирем дә шул...

Клара. Комментарий бирә алмыйсызмы?

Сафия. Артта калган, читкә кагылган, кимсетелгән, үзен рәнҗетелгән дип хис иткән бичарага илтифат күрсәтү — милләтебезнең асыл сыйфаты.

Клара. Килешәм. Сез үзегезне дә читкә кагылганнар рәтенә кертми торгансыздыр бит?

Сафия. Чынында, без барыбыз да — без дә, ә бәлки сез дә, читкә кагылганнар, рәнҗетелгәннәр. Халкыбызның күпчелек өлеше үз туфрагында яшәми. Алар сабантуйдагы чабыштан, хәлсезләнеп, егылып калган атлар кебек. Әгәр халкыбыз артта калган атларның муенына ак сөлге бәйләү хисен югалтса, милләт буларак яшәүдән туктаячак.

Клара. Дөресен әйткәндә, бу хакта мин үзем дә борчылам... Исегездәме, күрше авылдагы сабантуйда колгага... әйтергә дә оят инде...

Сафия. Колгага ак сөлге урынына хәмер бәйләгәннәр иде...

Иванов. Бездә — әтәч!

Сафия. Авылның исемен әйтеп, дөнья алдында хурлыкка калдырмыйк инде. Шунда ук батырга бүләккә тәкә урынына дуңгыз бирделәр.

Шәмсия. Булуы мөмкин түгел! Чит ил матбугаты, бигрәк тә буржуаз газеталар безнең тормышны бозып күрсәтергә бик оста.

Клара. Менә сез ни әйтерсез... иптәш... үзегез белән таныштырсагыз иде?..

Иванов. Иванов Павел Николаевич. Керәшен. Сабантуйдагы дуңгыз мәсьәләсенә мин бик аек карыйм. Монда бернинди дә провокация күрмим. Бик табигый хәл. Элиләр батырга бүләк бирергә тәкә, ә фермада — юк! Гореф-гадәтне югалтырга ярамый, салалар батырның җилкәсенә мыркылдап торган дуңгызны, батыр да тук, дуңгыз да юк!

Клара *(микрофонны тартып ала)*. Иптәш Иванов арттырып җибәрде. Без күргән әкәмәт сирәк очрый торган очраклылык кына...

Сафия. Батырның фамилиясе дә истә калган. Иванов. Без аны чакырган да идек...

Иванов. Мин — Иванов! Ягъни мәсәлән, шул батыр егетнең бабасы, бывший батыр Иванов! Ну, братлар, дөресен әйтеп сөйләшик, доньяда булган хәлмени, жә? Татар сабантуеннан җилкәсенә дуңгыз салып кайткан... Керәшендә дә мондый хәлнең булганы юк! Күтәрдем дә киттем председательләренә. Салдым дуңгызларын өстәлләренә!

Клара. Колхоз рәисе кунаклардан гафу үтенә...

Иванов. Ә бездән... халыктан?

Сафия. Без моны бер көлке итеп кенә кабул иттек, Иванов әфәнде. Баксаң, үз телегезне дә онытмагансыз икән... Фамилиягезгә карап бездә шик бар иде...

Иванов. Онытабызмы соң! Телебез булмаса, безне карга күтәреп китә бит!

Сафия *(телефон трубкасын алып)*. Тыңлыйбыз! Нью-Йорктан Газиз Сафалының Иванов әфәндегә соравы бар. Татар керәшененең асылы нидә?

Иванов. Татар керәшененең асылы? Динен югалтса да, денен, телен югалтмый саклауда.

Клара. Иванов иптәш, сорауны дөрес аңладыгызмы? Сүз керәшен турында түгел, кәрәш турында бара.

Иванов. Аңладым. Татар керәшененең асылымы? *(Җырлап бирә)*.

*Башымда картуз булса да,*
*Сатып алдым чалмалык.*
*Безгә аяк чалсалар да,*
*Без үзебез чалмадык.*

Клара. Павел Николаевичка өстәүчеләр бармы?

Арадан берәү. Минемчә, халкыбыз зәгыйфьләнүнең бер сәбәбе — көрәштә кулланган шул хасиятен югалта башлауда.

Сафия *(телефонда)*. Иванов әфәндегә тагын бер сорау бирәләр. Ни өчен сезнең исемегез урысча?

Иванов. Без — милләтнең көчләп чукындырылган өлеше. Җисемебезне саклап калсак та, исемебезне саклап кала алмадык. Безне керәшен диләр. Татар да бит Болгар дигән исемен саклап кала алмаган.

Сафия. Иванов әфәнде, әйтегез әле, нигә сез шаян сүзләрне дә кайгылы көйгә салып җырлыйсыз?

Иванов. Җырыбызга борынгы хәлебезне сагыну сеңгән. Шаян сүз әйтергә генә торганда, адәмнең башына кайгы килеп төшә дә жан сөенергә өлгерми кала.

Клара. Чыннан да, ни өчен соң халкыбызның җырлары үзәк өзгеч кайгылы, сагышлы?

Сафия. Аерылышу, озату, сагыну, бәхилләшү, бәхет эзләү...

Клара. Бәлки халкыбызның бөтен язмышы, тарихы шулдыр... Арабызда хөрмәтле Шәмсия апа утыра. Сез ничек уйлыйсыз?

Ш ә м с и я. Үз илләрен ташлап, бәхет эзләп читкә китүчеләрдән мин сорар идем: нигә киттегез? Бәхетне читтә түгел, үз жирендә эзләү, табу мөмкин ич. Китүчеләр үзләре гаепле! Читтә солтан булганчы, үз илеңдә олтан булу мең артык!

С а ф и я *(телефонда)*. Калифорния штатыннан Сәйфетдин Иманлы сезгә каршы төшә: «Үз илеңдә олтан булып яшәү егетлек түгел!» Аңа хәләл жефете Зөләйха ханым кушыла: «Без үз жиребездән үз ихтыярыбыз белән китмәдек, ачлык куды...»

Ш ә м с и я. Читтә тук булганчы, үз илеңдә ач яшәү өстенрәк! Үз тамагыңны гына кайгыртып, илдәшләреңне авыр хәлдә ташлап читкә качу — жинаять!

К л а р а. Шуны да әйтеп китик, Шәмсия апаның атасы Фәтхетдин Ишмуллин революциягә кадәр Кембридж университетында белем алган.

Ш ә м с и я. Бай яшәү мөмкинлекләреннән баш тартып, үз иленә кайтып халкына хезмәт иткән.

К л а р а. Гыйбрәтле бер фактны исегезгә төшерәсем килә, аны эзләп табулары өчен, Сан-Францискодагы коллегаларыбызга зур рәхмәт.1921 елгы ачлык чорында Казаннан Галимҗан Хәбиб Америкага барып, Идел буена ашлык төяп кайткан.

С а н - Ф р а н ц и с к о  я г ы н н а н  б е р ә ү: Галимҗан әфәнде Хәбибне, үз иленә кайткач, шпионажда гаепләп, юк иттеләр. Америкада калса, ул исән калыр иде...

Ш ә м с и я. Үз иленә кайтып жан бирүне артыграк күргән! Горурланам шундый затлар белән!

К л а р а. Тапшыруда Галимҗан Хәбибнең кыз туганы Регина Хәбиб катнаша. Регина иптәш, бәлки, сез дә берәр сүз әйтерсез?

Р е г и н а. Мин бер сүз дә әйтә алмыйм... Моннан артык ни әйтәсең... Бабамны онытмавыгыз өчен зур рәхмәт...

К л а р а. Регина — бүгенге көндә бабасының матур дәвамы...

А к ч у р и н. Талантлы яшь галимебез. Сәнгать фәннәре кандидаты.

К л а р а. Хәзер сезне халкыбызның мәшһүр рәссамы белән таныштырырга рөхсәт итегез. Хөрмәтлебез Исмай Саттарович Акчурин!

М а й к  С т е р н. Сафия, микрофонны бирегезче! *(Микрофонга)*. Исмай! Акчурин!

А к ч у р и н. Гафу итегез!..

М а й к. Ә мин сине, яшьтәш, озак еллар үтсә дә, фамилияне әйтү белән таныдым. Татарлар белән очрашырга дигәч, сөенеп ризалык бирдем.

А к ч у р и н. Әле һаман истә...

М а й к. Их, яшьтәш... Ул чактагы очрашуны, истәлеккә дип, егетләр киного төшергәннәр иде. Мин аны хөрмәтле алып баручыга тапшырдым. Мисс Сафия?

С а ф и я *(микрофонга)*. Беренче санлы язманы күрсәтүегезне үтенәм.

**Экранда документаль кино, кадрдан өзек.**

**26 апрель 1945 ел. Майк Стерн — Америка, Исмай Акчурин — совет солдаты формасында. Алар кочаклашалар.**

И с м а й. Сәлам, Америка!

М а й к. Ура! Жиңү!

И с м а й. Мин — Исмай...

М а й к. О, Исмай... Герой! Рус!..

И с м а й. Мин Россиядән, но...

М а й к. Но?

И с м а й. Татар.

М а й к. О, татар! Беренче тапкыр күрәм. Татарлар ярты дөньяны яулап алганнар. Чингиз хан?

И с м а й. Юк... юк... Чыңгыз хан түгел. Казан татары.

М а й к. Чыңгыз хан — үз чорының бөек полководецы. Аннан баш тартасың?

И с м а й. Бу юлы без дөньяны фашист явыннан коткарырга килдек.

М а й к. Гитлер капут! Ура! *(Виски йотып)*. Союзниклар исәнлегенә! *(Исмайга бирә.)* Исмай исәнлегенә!

И с м а й *(йотып)*. Союзниклар өчен! Исемегезне әйтмәдегез...

М а й к. Син — Исмай, мин — Майк Стерн. Майк... Исмайк!.. Ха-ха-ха!

И с м а й. Исмайк — дуслык! Махорка?

М а й к. Сигара? *(Бер-берсен сыйлыйлар. Исмай махорка төреп бирә, үзе сигара кабыза. Икесе дә чәчиләр, көләләр.)* О, көчле!

И с м а й. О, каты!

М а й к. Безнең дуслык та шулай булсын! Сугыштан соң нишләргә уйлыйсың?

И с м а й. Өйләнергә, балалар бәхетен күрергә...

М а й к. Алла бирсә, мин дә өйләнәм. Бәхетле балалар тудырыйк, Исмай. Алар да дус яшәсеннәр, сугышмасыннар иде!

И с м а й. Без шундый киләчәкне үзебез сугышып алдык, Майк!

М а й к. Амин! Әйдә, балаларыбыз өчен тост күтәрик!

И с м а й. Ура, Майк!

**Кадр өзелә.**

И с м а й. Майк! Стерн! 1945 елның 26 апреле! Эльба!

М а й к. Күпме еллар узган... Картайдык, яшьтәш... Шулай да таныдың.

И с м а й. Картайдык, яшьтәш.

М а й к. Яшьләр картайта. Менә без балаларыбызның бәхете өчен дип сугышып йөрдек, хыялыңа ирештеңме, Исмай?

И с м а й. Ничек дип әйтергә... синең балаларың бармы?

М а й к. Хатын белән икебезгә бер малай үстердек. Дөнья артыннан куып, ычкындырдык. Наркоманга әйләнеп харап булды... Синең балалар ничек, Исмай?

И с м а й. Сорама...

К л а р а. Хөрмәтле Майк әфәнде һәм Акчурин иптәш, без сезнең очрашуга бик шатбыз. Сезгә әле тагын вакыт бирербез. Диалогны дәвам итәбез. Исмай Саттарович, минем сезгә бер соравым бар. Үзегез яшәгән сәнгать өлкәсендә сезне ниләр борчый?

А к ч у р и н. Без, өлкәннәр, әкренләп бу дөньядан китеп барабыз. Яшьләрдән кемнәр алыштырыр да безне, кемнәр дәвам итәр. Мин әллә ни өмет күрмим. Әкчечелек, җинаятьчелек канат җәя...

С а ф и я. Хөрмәтле Исмай ага, артык куертмыйсызмы? Сез әйткән ямьсезлекләр әлегә татар яшьләре арасына ул кадәре үк үтеп кермәгән.

Ш ә м с и я. Исмай иптәш белән килешмим! Безнең яшьләребез андый түгел. Сафия ханым, ул мәсьәләдә сездә ничек?

С а ф и я. Безнең якта эшләр ничегрәк дип уйлыйсыз? Жак әфәнде, микрофонны сезгә бирәм.

Т а й ф у р *(арттагы рәтләрдән)*. Бозыклыкка килгәндә, ике як та бер-берсеннән калышмый. Аллага шөкер, анда да, монда да мисаллар җитәрлек...

С а ф и я. Үзебезнең татарлар турында сүз алып барабыз. Дилбегәне ычкындырмыйк.

Т а й ф у р. Татарлар дөнья күләмендә дилбегәне кулдан ычкындырдылар. Елмаеп үләләр татарлар, башлары өстендә гильотина, ә алар берни булмагандай, гамьсез елмаялар...

Ж а к *(көтмәгәндә сикереп тора)*. Нәрсә белдесең соң син?!

С а ф и я. Кичерегез, газиз тамашачылар. Безнең бәхәсне тыңлап арыгансыздыр инде. Бераз ял итеп алыгыз. Игътибарыгызга Хельсинки татарларының «Тургай» исемле хор ансамблен тәкъдим итәбез.

Х О Р. *Ай, әле бик еракта идек без,*
*Җитмеш чакрым җирдән килдек без.*
*Ак калфакның табылган чагы,*
*Туганнарның сагынган чагы.*

С а ф и я. Гөлнур туташ, бу җырны каян өйрәндегез?

Г ө л н у р. Казаннан алып кайттык.

С а ф и я. Казан яшьләре сезгә ошадымы?

Г ө л н у р. Ошады. Әмма без, туган телебезне онытмаган туристлар, гаҗәпкә калдык. Милли башкалабызның күпчелек яшьләре үз телләрен онытканнар.

С а ф и я. Ак калфак сезгә бик килешә, Гөлнур туташ. Казаннар ак калфак кияләрме?

Г ө л н у р. Ансамбль артистлары гына кия. Җырда гына калган.

Т а й ф у р. *Ак калфакның каралган чагы,*
*Туганнарның таралган чагы...*

Г ө л н у р. Без, Фин илендә адашып калганнар, туган телебез башкаласыннан еракта яшәсәк тә, телебезне, динебезне, гореф-гадәт вә йолаларыбызны онытмыйбыз. Киләчәктә без үз балаларыбызны татар итеп үстерергә телибез.

Т а й ф у р. Бәхетсез татар балаларының санын күпме генә арттырырга тырышсак та, халкыбызның сыйфаты үзгәргән шул инде... Сез генә саклап кала алмассыз...

А р а д а н б е р ә ү. Протест белдерәм! Кайчандыр бөтен җиһанны калтыратып торган милләтебезгә яла ягу!

Т а й ф у р. Элекке даныбыз белән мактана-мактана, телсез калдык инде. Хәзер ул «милләтче» дип әйтмәгәйләре дип калтырап тора.

Г ө л н у р. Мин сезнең белән килешмим!

Т а в ы ш л а р. Килешмибез!

Т а й ф у р. *Тарих юлларында үз урыны.*
*Әле түбән, әле биектә.*
*Бер карасаң, ул бик кечкенә дә.*
*Бер карасаң, ул — бик бөек тә!*

Хәзер татарның яртысыннан артыгы үз телен белми. Җир шарының теләсә кайсы ягына чыксаң да аңлашып була торган үндүрт телнең берсе дип танылган бүгенге татар теле белән кая барырга мөмкин? Римгәме? Вашингтонгамы? Парижгамы? Әйтегез әле, Ратмир әфәнде, дөньяның атаклы биючесе булып танылырга сезгә безнең милләтебезнең теле кирәктеме?

С а ф и я. Безнең диалогта мөшһүр биючебез, Сан-Францискога гастрольгә килгән бөек артистыбыз, дөнья балетының йолдызы Ратмир әфәнде Закиевский катнаша.

Р а т м и р. Туташлар, ханымнар, әфәнделәр, хәерле кич! Мин бер генә минутка, тамаша башланыр алдыннан гына күренеп китәргә кердем. Сәлам, ватандашлар! Татар теленең тоткан

урынына килгәндә, әфәнделәр, шәхсән, үз мисалымда... мине татар теленә өйрәтүне Рәсәйдә кирәк дип тапмаганнар, күрәсең. Һәм, дөресен әйтим, ул телне белмәвем белән, мин бернинди дә кыенлык кичермәдем. Кыскасы, мин милләтче түгел, ә бәлки космополит!

Т а й ф у р. Кызганыч, ләкин факт!

Р а т м и р. Шунысы кызык: минем бабам 1812 елгы сугышта Парижны ат менеп, корал белән яулаган. Мин башка юл белән киттем, корал белән түгел, Парижны, җиһанны биюем белән яуладым.

Т а й ф у р. Фамилиягез генә безнеке булса да, горурланырлык кеше сез! Тик шуны да онытмасагыз иде, Ратмир әфәнде, сез яулаган тамашачыларның күбесен сезнең чыгышыгыз, нәселегез тарта.

Р а т м и р. Ихтимал, әмма бу минем өчен әһәмиятле түгел.

Г ө л н у р. Туктагыз, сез — безнекеме соң? Нишләп без сезне белмибез? Нишләп сез татарча бер генә бию дә башкармыйсыз?

Р а т м и р. Кадерлем, кызганычка каршы, татарыбызның югары сәнгатьне аңлау дәрәҗәсе әлегә чикле. Мин гаепле түгел. Ихтирам белән... Рәхим итеп концертыма килегез. Кыска вакытлы визитым өчен түбәнчелек белән гафу үтенәм. Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Хушыгыз! *(Чыга.)*

Г ө л н у р. Ни өчен соң бездә мондый даһи биючеләр юк? Ни өчен талантлы кешеләребез дөнья сәхнәсенә күтәрелә алмыйлар?

Т а й ф у р. Ә нигә, кемгә кирәк ул күтәрелү? Талантың күренеп, әз генә аерылдыңмы,— көт тә тор, булдыксызлар, көнчеләр, сәләтсезләр аяк чалалар, үзләре түбәнлеккә төшсәләр төшәләр, менгән биеклектән тартып төшерү өчен барысын да эшлиләр.

А к ч у р и н. Сез яшьләр, гел инкарь итүне генә беләсез, ә безнең иң даһи татарыбыз Тукай бар бит әле!

Т а й ф у р. Иң гыйбрәтле мисал — Тукай. Аны үз милләте биеклеккә күтәрде, үз милләте үк егерме жиде яшендә үтерде. Бүгенгесе көндә без Тукайларны тудырырлык хәлдә түгел. Чөнки үз телебезне югалту алдында торабыз. Туса да, алар әнә үз кендегеннән өзелгән Ратмир әфәнде хәлендә...

А к ч у р и н. Нигә мескенләнәсең син, егет?

Т а й ф у р. Безнең мондый хәлгә төшүебезгә сез дә гаепле, Исмай Саттарович!

А к ч у р и н. Менә бу җөмләгезне әйтү белән, мин сезне таныдым, иптәш...

Т а й ф у р. Әфәнде!

А к ч у р и н. Тайфур Сәлимович...

Т а й ф у р. Тайфур әфәнде!

А к ч у р и н. Ярый, сезненчә булсын...

Т а й ф у р. Сез һәрвакыт үзегезчә булыр дип көттегез шул...

А к ч у р и н. Без әле бу фикердән кире кайтырга уйламыйбыз.

С а ф и я. Мин сезне буләргә батырчылык итәм. Сез танышлармыни?

К л а р а. Бу — минем өчен дә көтелмәгән хәл, Исмай Саттарович. Сез аны беләсезмени?

А к ч у р и н. Әйе, без танышлар.

К л а р а. Ягъни мәсәлән?

А к ч у р и н. Ул — яшь рәссам. Мин аны Казанда сәнгать училищесында укыттым.

К л а р а. Тайфур әфәнде, сез аны үзегезнең остазыгыз итеп хәтерлисезме?

Т а й ф у р. Хәтерлим.

К л а р а. Һәм... таныйсызмы?

Т а й ф у р. Таный идем.

К л а р а. Ә хәзер?

Т а й ф у р. Хәзер танымыйм.

К л а р а. Нигә? — дип сорамаска рөхсәт итегез...

Т а й ф у р. Сорамасагыз да әйтәм. Без — ике кыйбла кешеләре булып аерылыштык.

А к ч у р и н. Тайфур, хәлең ничек?

Т а й ф у р. Соңга калып булса да минем хәлем белән кызыксынуыгыз өчен рәхмәт. Монда минем хәлем әйбәт! Тамак тук, өс — бөтен, реклама агентствосында эшлим, шәп түлиләр, фатирым, машинам бар. Байлыгым Акчуриннар нәселен көнләштерерлек түгел-түгелен. Исмай Саттарович, мин монда, сәяхәттә йөргәндә, затлы токымыгызның бер вәкилен очраттым. Фамилиягезгә тап төшермәгән, горур, зыялы, акыллы, талантлы...

А к ч у р и н. Ялгышасыз, чит илләрдә минем туганнарым юк. Мин алардан баш тарттым. Алар — минем идея дошманнарым.

Т а й ф у р. Нигәдер алар бер дә дошманга охшамаганнар.

А к ч у р и н. Фабрикант, морза, акгвардияче Акчуриннарның иске династиясе җимерелде. Мин яңа чор Акчурины. Минем чит илләрдәге эмигрантлар белән бернинди дә бәйләнешем юк!

Т а й ф у р. Яшь вакытта, укырга керү өчен, сезне үз атагыздан баш тарткан, дип сөйлиләр иде. Ул чакта ышанмаган идем. Хәзер ышандым.

А к ч у р и н. Бик табигый хәл ул дәвер өчен... Сыйнфый көрәш. Кулакларны төбе-тамыры белән юк итү кампаниясе... Әлбәттә, бүгенге көннән чыгып караганда, яшьләргә сәер тоеладыр...

Ш ә м с и я. Туктатыгыз бу йомшаклыкны, иптәш Акчурин! Нигә әле сез шушы тәти егетләрнең тамагы тук булсын өчен сыйнфый дошманнар белән көрәшкән, фашистларга каршы сугышкан мәшһүр рәссам — иманын арзанлы чит ил чүпрәгенә алыштырган элемент алдында әдәп саклап торасыз?

Р е г и н а *(арттагы рәтләрдән)*. Тайфур!

Т а й ф у р. Регина?..

Р е г и н а. Тайфур!.. Очрашырбыз дип кем уйлаган...

Т а й ф у р. Кызганыч, безнең очрашу бөтен дөнья алдында...

С а ф и я. Тайфур әфәнде, һич тә уңайсызланмагыз, таныштыгыз белән сөйләшегез. Без сезгә берничә минут вакыт бирәбез. Клара ханым, сез ризамы?

К л а р а. Рәхим итегез... сценарийда каралмаса да:.. әңгәмәгез ике якка да кызык булыр дисеп уйлыйбыз...

Р е г и н а. Нигә син киттең, Тайфур, барысын да ташлап?

Т а й ф у р. Китәсем килеп китмәдем, туган илдән кем туйган? Анда минем беркемем дә юк иде: әтием дә, әнием дә... Минем анда синнән дә якын кешем булмаган икән... Кил якынрак... Үзеңә генә әйтәсе сүзләрем бар.

Р е г и н а. Син үзеңнең кайда икәнеңне оныттың, ахры?

Т а й ф у р. Бүген минем барысын да онытасым, дөньяның икегә бүленгәнен истән чыгарып, синең белән генә каласым килә. Әле дә ярый, Регина, син килгәнсең. Миллион чакрымнар аркылы мин синең килүеңне тойдым. Шуңа да мин бу очрашуга ышандым, Регина. Хәтереңдәме, тал-тирәкләр янында, тыныч күл буенда, айлы төндә күзгә-күз карашып торган мизгелләр? Мин ул манзараны рәсемгә дә төшердем.

Р е г и н а. Хәтердә.

Т а й ф у р. Хәтерлә...

### Хәтерләү

Т а й ф у р. Бәхил бул, Регина. Мин хәл иттем, китеп югалам.

Р е г и н а. Кая югаласың?

Т а й ф у р. Дөньяның билгесез ягына.

Р е г и н а. Китмәскә мөмкин түгелмени, Тайфур?

Т а й ф у р. Мөмкин.

Р е г и н а. Шулай булгач?..

Т а й ф у р. Әгәр дә мин үз карашларымнан баш тартып, гаебемне таныcам, мине гафу итәчәкләр...

Р е г и н а. Тайфур, зинһар өчен, баш тарт, тәүбә ит!

Т а й ф у р. Минем берниндн дә гаебем юк. Ике төрле була алмыйм.

Р е г и н а. Алар сиңа нәрсә тәкъдим иттеләр?

Т а й ф у р. Минем алда ике юл бар: үзебезнең тиләләр йортына яки төрмәгә керү... Мин чит илгә сөргенгә китүне, мөһаҗир булуны сайладым.

Р е г и н а. Әле соң түгел, Тайфур, үзеңне харап итмә! Минем бабамны да чит илгә барган өчен атканнар...

Т а й ф у р. *Моңайма, кош, моңайма, кош,*

*Моңайсаң да аталар.*
*Безгә моңайсак та ярый,*
*Чит илгә озаталар.*

Курыкма, Регина, сиңа берни дә булмас, безнең аралар мәңгегә өзелә...

Р е г и н а. Тайфур, китмә, җаным... Кичә минем янга Акчурин килде. «Әйт, талантын кызгансын, ди, чит илгә китмәсен»,— ди.

Т а й ф у р. Ә нигә ул мине яклап бер генә сүз әйтми? Минем хаклы икәнне белә бит. Юк, мин Акчурин кебек бүген бер, башка көнне икенче төрле була алмыйм.

Р е г и н а. Ул дөрес әйтә: бу... бу... хыянәт...

Т а й ф у р. Мин үземә, талантыма тугры калам. Кайчан булса да бер аклардар. Илне ташлап китми чара юк.

Р е г и н а. Сорыйм, үтенәм, ялварам... Тайфур!

Т а й ф у р. Исәр җилләр, чыгар кояш, бездән сәлам шул булыр...

Р е г и н а. Шушы зәңгәр күлне, безне очраштырган тал-тирәкләрне сагынмам дисеңме әллә?

Т а й ф у р. Минем йөрәгем сагынуның ни икәнен әлегә аңларлык хәлдә түгел. Ул суынды, ташка әйләнде.

Р е г и н а. Юк, ышанмыйм! Синең йөрәгең андый түгел.

Т а й ф у р. Мин ул салкын йөрәгемә салып бер генә нәрсә дә — сине дә, күлне дә, тал-тирәкләрне дә алып китмим. Калыгыз туган илегездә, дулкынланып, таң җилләренә назланып, рәхәтләнеп...

С а ф и я. Сезнең тагын бер минут вакытыгыз калды!

К л а р а. Сафия ханым, регламент!

Р е г и н а. Тайфур, зинһар, тагын бер генә сүз әйт, югалма!

Т а й ф у р. Кил, якынрак кил, Регина!

Р е г и н а. Онытылма, Тайфур, бик теләсәм дә, мин сиңа якыная алмыйм. Без — шәүләләр... Арабызда күпер дә юк. Сират күпере булса да, хәзер мин курыкмыйча сиңа китәр идем, Тайфур!

Т а й ф у р. Регина, ачуланма, «мәңгегә сагынмам» дип, мин үз-үземне алдаганмын...

Р е г и н а. Нигәләр алай дип әйттең соң?

Т а й ф у р. Минем өчен син газап чигәргә тиеш түгел идең...

Р е г и н а. Түзәр идем барысына да. Нигә дип синең белән китмәдем, үкенәм. Мин синең уңышларың өчен бик шат, Тайфур. Максатыңа ирештең, димәк?

Т а й ф у р. Матди яктан минем хәлләр ярыйсы...

Р е г и н а. Ирекләме соң син хәзер?

Т а й ф у р. Мин ирекле. Ни телим — шуны эшлим. Әмма иң кадерле нәрсәне югалту бәрабәренә алынган ирек мине бәхетле итмәде. Басып торган үз туфрагым, җирем, суым, шунда тамырланган тал-тирәкләрем, телем-моңым җитми миңа. Һәрбер көнем-төнем иксез-чиксез газапка әйләнде. Мин моны сиңа әйтмәс тә идем. Бәлки, соңгы тапкыр күрүемдер...

Р е г и н а. Юлларын өйрәт, мин сиңа барам!

Т а й ф у р. Мин килгән бай илдә Тайфурның аяныч язмышы да бик житкән. Нигә сине дә бәхетсез итәргә?

Р е г и н а. Синнән башка мин монда, үз илемдә бәхетсез...

К л а р а. Регина иптәш!..

Р е г и н а. Тайфур, әйтеп кал!

Т а й ф у р. Бәхил бул, Регинам, минем өчен иң кадерле җан. Сине газапларга тартуым өчен гафу ит. Мин хәзер синең мәхәббәтеңә лаек түгел. Мин инде бозылдым, гөнаһларга баттым. Хәтта син кичерсәң дә, мин үз-үземне гафу итә алмыйм. Минем алда хәзер бер генә юл...

К л а р а. Сафия ханым, без сценарийдан ычкындык!

С а ф и я. Мин сезне аңладым, Клара ханым. Хәзер, түземле тамашачыларыбыз, игътибарыгызга «Менә шулай, Майкл...» дигән Америка җырын тәкъдим итәбез. Башкара яшь җырчыларыбыздан Зөбәйдә Прайс! *(Башта җырны Шәмсия татар телендә укый, аннан соң ул инглизчә башкарыла).*

*Менә шулай, Майкл, менә шулай:*
*Дөнья безне куа, без — дөньяны...*
*Куып җитсәм, койрыгыннан*
*Тотар идем аны.*
*Менә шулай, Майкл, менә шулай,*
*Әйтче, әллә этме соң без бәйдә?*
*Бәйдә булсак, тик беразга гына*
*Онытылыйк, әйдә!*

Р е г и н а. Туктагыз! *(Үз ягында кул чабып, биеп торучыларга карап.)*. Сез берни дә аңламадыгызмени?! Тайфур! Тайфур! Мине ишетәсеңме?! *(Аңа игътибар итмиләр, бию, җыр, рок-музыка дәвам итә.).* Ул юк! Ул — юк, ул киткән... Туктатыгыз аны! Сафия ханым, әле соң түгел, әйтегез, аның артыннан барсыннар! Коткарыгыз аны!

С а ф и я. Кичерегез туташ, сезнең шәхси мөнәсәбәтләрегез безнең очрашуда каралмаган.

Р е г и н а. Арагызда бер генә дә рәхимле җан юкмени соң? Ичмасам, киңәш бирегез: нишләргә? Ничек аны коткарырга? Бәлки, сез ярдәм итәрсез... Исмай Саттарович? *(Акчурин, мин нишли алам, дигәнне аңлатып, кулларын җәя.).*

К л а р а. Без сценарийдан бөтенләй читкә киттек. Иптәшләр, тынычландырыгыз туташны!

Р е г и н а. Дөньяда бер генә шәфкатьле кеше дә юкмыни соң?! *(Аны ике ягыннан тотып алып чыгалар).* Тайфур! Тайфур!

**Музыкаль антракт**

## ИКЕНЧЕ АКТ

## Өченче күренеш

К л а р а *(телефонисткалар өстәле янында).* Тыңлыйм, шеф! Расланган сценарийдан тайпылган өчен җавап бирерсең, дисезме? Мин берни дә эшли алмыйм! Дөньяның агышын туктата алмыйм! Теләсә нишләтегез! *(Трубканы куя. Үз өстәле янына утыра. Экранда — шулар ук.).* Музыкаль антракт тәмам. Сафия ханым, сез дәвам итәргә әзерме?

С а ф и я. Әзербез, башлагыз!

К л а р а *(Акчуринның күтәрелгән кулын күреп).* Исмай Саттарович, сез Майк Стерн әфәнде белән әңгәмәгезне дәвам итәргә телисез, ахры?

А к ч у р и н. Әйе, әйе... Майк, мине ишетәсеңме?

М а й к. Ишетәм, Исмай.

А к ч у р и н. Менә шулай, Майк...

М а й к. Мин сине аңлыйм, яшьтәш. Яшьләр безне, без яшьләрне аңламыйбыз. Алар бәхетле булырга тиешләр иде бит...

Акчурин. Әллә алар үзләре гаепләме?

Майк. Әллә безме?

Акчурин. Яшь чакта безнең идеалыбыз бар иде: фашист дигән дошманны юк итү өчен сугыштык.

Майк. Югыйсә, безнең балаларның дошманнары да юк шикелле инде.

Акчурин. Булмаса, дошманны үзебез уйлап табабыз, Майк.

Майк. Синең балаларың бармы?

Акчурин. Бер малай.

Майк. Ул ни хәлдә?

Акчурин. Сорама, Майк...

Майк. Теләмәсәң, әйтмә...

Акчурин. Хәзер яшермәсәк тә ярый. Әфганстаннан сугышып кайтты. Танымадым: йомшак күңелле бер бала иде...

Майк. Адәмнәр, бер-берсен үтереп, ерткычка әйләнәләр, Исмай. Теге сугышта, фашистларны үтергәндә башта мин үз-үземнән жирәнә идем, соңыннан кеше үтерү гадәти хәлгә әйләнде. *(Зөбәйдә Прайсның жыры аларның диалогын бүлә. Түгәрәк өстәл янында Сафия Нурхан, Зөбәйдә Прайс.)*.

Сафия. Зөбәйдә ханым, сезнең белән нинди телдә сөйләшергә?

Зөбәйдә. Бары тик инглиз телендә.

Сафия. Клара ханым, сезнең якта татарчага тәржемә кылучы тылмачлар бармы?

Клара. Әлбәттә. Шәмсия апа, сезнең ярдәмгә мохтажбыз.

Шәмсия. И заманалар, татарга да тылмач кирәк хәзер... Тәржемәләп карыйк... *(Башта диалог инглиз һәм татар телләрендә бара.)*.

Сафия. *(Зөбәйдәгә)*. Татар телен оныттыгызмени?

Зөбәйдә. Татар? Юк! Юк!

Сафия. Милләтегез?

Зөбәйдә. Американка.

Сафия. Әниегез кем?

Зөбәйдә. Әни? Татарка.

Сафия. Әтиегез?

Зөбәйдә. Рейнольд Прайс. Йөз процент американ.

Сафия. Әниегез каян?

Зөбәйдә. Россиядән.

Сафия. Америкага ул ниге килгән?

Зөбәйдә. Язмыш.

Сафия. Төгәлрәк әйткәндә?

Зөбәйдә. Сугыш вакытында аны немецлар Донбасстан, кол итеп, Германиягә алып киткәннәр. Мин моны хәтта әйтергә дә оялам. Әмма үземнең язмышыма рәхмәт кенә әйтә алам. Мин азат ил — Америкада тудым. Кайчандыр кол булган татардан... *(Шәмсия тәржемә итә.)*.

Сафия. Шәмсия ханым, дөрес тәржемә кылуыгызны үтенәм...

Шәмсия. Ә мин милләтебезгә яла якмауларын таләп итәм!

Клара. Шәмсия апа, тылмач икәнегезне онытмасагыз иде...

Сафия. Әгәр Россиядә туган булсагыз?

Зөбәйдә. Кол хәлендә калыр идем. Әнинең жырлаганын тыңлаганым бар. Сары кайгы, өзелгән өмет... яки менә мондый... *(Көйли.)*.

*Яшьләремне түгеп еласам да,*
*Һичбер кеше миңа карамый*
*Әйләнеп.*
*Чит илләрдә калдым бәйләнеп.*
*Кайта алмыйм, туган илем, сиңа,*
*Дөнья өзгән безнең араны.*
*Беткән юл.*
*Туган-үскән илем, исән бул...*

Шәмсия. Кыланчык! Татарча беләсең ич!

Зөбәйдә. Мин жырлый гына беләм...

Сафия. Зөбәйдә ханым, сез әниегезнең, әби-бабаларыгызның жирен сагынасызмы?

Зөбәйдә. Сагыну? Нәрсә ул сагыну? Ни өчен әле мин әниемә бәхетсезлек китергән жирне сагынырга тиеш? Миңа беркем дә андый ят хисне көчләп тага алмый. Мин азат илдә яшим.

Шәмсия. Мин артык тәржемә итә алмыйм. Баш тартам!

Сафия. Борчылмагыз, Шәмсия ханым, үзем тәржемә кылырмын. *(Зөбәйдәгә.)*. Туган жир тойгысы бармы сездә?

Зөбәйдә. Туган жирем минем — Америка, шуңа күрә ул минем өчен барысыннан да өстен! Безгә, гомумән, Сафия ханым, эмоция, хис дигән нәрсәләр ят. Без, бизнес кешеләре, шуңа күрә дә без прогресс, цивилизация юлыннан киттек.

Сафия. Мин сезне бүләм, татар халкы да ялкаулардан түгел, ул да үзләре өзелгәнче эшләгән. Тукаебыз язган:

*«Без сугышта юлбарыстан көчлебез,*
*Без тынычта аттан артык эшлибез...»*

Зөбәйдә. Дөрес әйткән Тукаегыз: гомер буе сугышкан халык, тынычта үзләре өзелгәнче эшләсә дә, алга китә алмый, ул йә юлбарыс, йә ат хәлендә генә кала, цивилизациягә ирешә алмый.

Сафия. Киләчәгебезне юрап карагыз?

Зөбәйдә. Кешеләр кыргый, вәхши сыйфатларын онытып, аллаһе тәга-

лә җан биреп индергән Адәм тормышы белән яши башламасалар, бер-берсен бетерәчәкләр. Юлбарыслар — атларны, акулалар ваграк балыкларны йотачаклар.

Сафия. Үз уйларыгызны ихлас әйтүегез өчен рәхмәт, Зөбәйдә ханым Прайс! Казан, Клара ханым, дилбегәнең очын сезгә бирәм...

Клара. Без сезне игътибар белән тыңлыйбыз, Сафия ханым... Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә «Ватан» җәмгыятенең игъланын җиткерәбез.

«Егерменче елларда Казанга Америкадан бер татар кешесе килеп, бик арзан бәягә Фатих Халидиләр нәселенең бай китапханәсен төяп киткән. Анда тарихи әһәмияткә ия булган бик күп документлар, әйтик, Алтын Урда ханнарының ярлыклары саклануы билгеле. Шул хәзинәне табып кире кайтаруда ярдәм итүегезне сорыйбыз».

Сафия. Кулдан килгән кадәр ярдәм итәрбез, Клара ханым. *(Өстәлгә язу куялар.)*. Игътибар! Әле генә бизнесмен Таминдар әфәнде шалтыраткан. Ул балачагы узган Каенлык авылындагы җимерек мәчетне яңарту өчен үз өлешен кертергә уйлаган. Әмма авыл советы баш тарткан, киңәш сорый.

Клара. «Ватан» җәмгыяте аша аның белән бәйләнешкә кереп, уңай хәл итәрбез дип уйлыйм.

Акчурин. Клара ханым...

Клара. Микрофонны сезгә бирәм, Исмай Саттарович...

Акчурин. Майк, мине тыңла әле...

Майк. Тыңлыйм, Исмай.

Акчурин. Синең белән төне буе серләшеп үткән бер төн искә төште. Миңа хәзер дә кем беләндер ачылып сөйләшәсе килә. Дөресен әйтим, үз өемдә, үз илемдә йөрәкне бушатырлык фикердәшләрем юк икәнне белү — үзе бер фаҗига.

Майк. Ни борчый сине, Исмай?

Акчурин. Яшь чакта үз авылымдагы мәчетне мин дә җимерүдә катнаштым. Әйе... әйе... Моны әйтү бик авыр... Шулай да... дөньядан китеп барганчы... ялгышларны төзәтергә вакыт бар әле. Мәчетнең аен мин алып ташладым, мин — куярга тиеш!

Майк. Яшьлектәге хаталар минем җанны да телгәли, Исмай...

Акчурин. Әйдә, алтмышынчы елны Казандагы очрашуны да искә төшерик...

Майк. Бик рәхәтләнеп!

Акчурин. Миндә дә җавап сюрпризы. Клара ханым, мин биргән тасманы күрсәтсәгез иде?

Клара. Исмай Саттарович язмасын сорыйм!

**КИНОКАДР:**

**Казанда Татар ашлары йорты. Өстәл артында Акчурин һәм Майк.**

Акчурин. Майк, әйдә минем күргәзмәне карап килик.

Майк. Кызганыч, мин Мәскәүдән сине күрергә дип, бер генә сәгатькә килдем.

Акчурин. Әйдә алайса, вакытны әрәм итмик, монда гына сөйләшеп утырыйк... *(Бокалларга шәрап сала.)*. Хәлләрең ничек, Майк?

Майк. Менә балалар хирургларының симпозиумына килдем. Тукта, татар ресторанында нигә чит музыка гына? Ә нигә бармен татарча белми? Официантлар да? Сәер, бик сәер, Исмай?..

Акчурин. Без инде моңа күнеккән, исебез дә китми.

Майк. Син мине татарча өйрәтергә маташкан идең, һаман онытмадым: әни, әти, балам...

Акчурин. Әйдә, Майк, башка нәрсәләр турында сөйләшик... *(Кадр өзелә.)*.

Майк. Гаҗәп! Кем төшерде безне ул вакытта?

Акчурин. Хәзер яшермәсәк тә ярый. Һәркемгә «шпион», «дошман» дип шикләнеп караган иптәшләр төшергән. Хәзер алар үзгәрделәр шикелле. Миңа истәлеккә үземә бүләк иттеләр.

Майк. Үпкәләмәсәң, бер соравым бар, Исмай?

Акчурин. Үпкәләмим.

Майк. Казандагы шул очрашуда мин синең тарафтан элеккеге ихласлык, җылылык тоймадым сыман. Син Эльбада очрашкан Исмай түгел идең...

Акчурин. Ул чакта синнән генә түгел, миннән дә шикләнделәр. Янәсе, без милләтчеләр.

Майк. Мин... татар милләтчесе? *(Көлә.)*. Мин бик шатмын! Менә ни өчен безнең аралар салкынайган икән... Аннан соң бер-беребезне оныттырдылар, арабызга кара пәрдә кордылар. Эльбада салынган күпер сүтелде...

Акчурин. Менә шулай, Майк.

Клара. Сан-Франциско, дәвам итегез!

Сафия. Хәзер реклама вә чит илләрдә яшәп ятучы милләттәшләребез тормышыннан бер манзара-видеотасма карагыз!

Катрин тавышы. Әгәр дә сез адәмчә бер рәхәтләнеп ял итәргә, теле-

гезне йотарлык тәмле француз һәм татар ризыкларыннан авыз итәргә теләсәгез, «Ак калфак» барына, аның сөйкемле хуҗалары Жак әфәнде һәм Катрин Люсиль ханымга рәхим итегез! Кайгы-хәсрәтләрдән, аерылышуның моңсу хатирәләреннән, сары сагыш зәхмәтләреннән, үзәк өзгеч сагыну хисләреннән онытылып тору — бары бездә генә!

**Татар һәм француз музыкасы яңгырый. Барда, прилавка артында, Катрин.**

Сафия *(оператор һәм яктыртучы белән бергә керә)*. Хәерле кич, мисс Катрин!

Катрин. Хәерле кич! Түргә узыгыз, кадерле кунаклар!

Сафия. Телевидение комментаторы Сафия Нурхан. Сан-Франциско һәм Казан телевидениесе экранда очрашу турында килешү төзеделәр. Мин әле генә сезнең иргегез Жак әфәнде белән сөйләштем. Без әнә шул максаттан чыгып, татарлар тормышыннан бер күренеш төшерергә уйладык һәм объект итеп сезнең барны сайладык. Жак әфәнде фатихасын бирде. Сез каршы түгелме, мисс Катрин?

Катрин. Жакның сүзе житкән, рәхим итегез...

Сафия. Сез бик ягымлысыз. Хәзер иргегез дә кайтып житәр. Егетләр, төшерә башлагыз! *(Микрофонга.)* Сез биредә Дебюсси, Равель музыкасы белән бергә, Сәйдәш, Яруллин көйләрен дә ишетерсез. Нәкъ татарча милли ризыклар белән сыйланырсыз.

Катрин *(тәрәзәгә карап)*. Кичерегез, безгә кунак килә.

Сафия. Безгә игътибар итмәгез.

Тайфур *(керә)*. Хуҗалар өйдәме?

Катрин. Рәхим итегез, әфәндем! Җаныгыз ни тели?

Тайфур. Минем җаным сез рекламада вәгъдә иткән моңсу тынычлык тели.

Катрин. Сез аны алырсыз, әфәндем.

Тайфур. Болар кемнәр?

Катрин. Телевидение. Казан өчен. Ризасызмы?

Тайфур. Миңа барыбер. Сез татармы әллә?

Катрин. Юк, француз.

Тайфур. Мине әллә кайлардан татар музыкасы тартты.

Катрин. Минем ирем татар.

Тайфур. Күңелем дөрес тойган.

Катрин. Виски, лимон?

Тайфур. Нәрсә булса да ярый.

Катрин. Пәрәмәч?

Тайфур. Кызык, биш ел авыз иткән юк.

Катрин *(китерә)*. Бары бездә генә! Жак үзе пешерә. Әнисеннән өйрәнгән.

Тайфур. Үзе кайда?

Катрин. Америкаи татар җәмгыятенә китте.

Тайфур. Миңа аны ничек тә күрергә кирәк.

Катрин. Борчылмагыз, әфәндем. Төнгә юлга чыгарга уйламасагыз, һотель дә үзебездә.

Тайфур. Юл кешесенең юлда булуы хәерле. Берни дә булмас.

Катрин. Алла бирсә...

Тайфур. Сез татарча да беләсез?

Катрин. Әз-мәз.

Тайфур. Хуҗа белән язмыш ничек очраштырды?

Катрин. Сез эчегез, ашагыз.

Тайфур. Сезнең исәнлеккә... кем...

Катрин. Катрин Люсиль.

Тайфур. Тайфур.

Катрин. Сез татар?

Тайфур. Казан татары.

Катрин. Жак сөенер инде. Ак калфагын күрсәтер.

Тайфур. Ак калфак? Нәрсә ул?

Катрин. Талисман. Ул аны сугышта үлемнән саклаган.

Тайфур. Катрин ханым, ак калфак хөрмәтенә...

Катрин. Миңа ярамый, ирем көнләшер...

Тайфур. Танышу хөрмәтенә!

Катрин. Шулай дисәгез генә инде. *(Эчәләр.)* Сезгә минем Жак белән танышу кызыкмы? Без кара урманда очраштык. Мин — татар киленс. Кайнанамны күрү бәхетенә генә ирешмәдем. Кайнаналарны бик усал диләр, дөресме, Тайфур әфәнде?

Тайфур. Татар кайнаналарымы? Башкалар белән чагыштырганда — алар фәрештә!

Катрин. Арттырасыз, кайнана кайда да кайнана инде ул...

Тайфур. Каен ана... Каен кебек ак күңелле ана...

Катрин. Их, күрәсе иде шундый ананы! Жакны әйткән дә юк. Хыялында гел әнисе белән яши, өчпочмак пешергәндә, аның белән сөйләшә, киңәшә...

Тайфур. Әнисе кайда?

Катрин. Татар илендә, һаман исән, ди. Ул Жакны үлгән дип саный.

Тайфур. Жак нигә хәбәр бирми?

Катрин. Мин дә шулай дим. «Әйдә, бергәләп кайтыйк, мәйтәм, күрик әнине» Юк! Үзе «Әни!» — дип өзгәләнә, тилмерә, үзе исәнлеген белдерергә теләми.

Т а й ф у р. Кара урман кебек серле... Шундый кешеләр хөрмәтенә!

К а т р и н *(бокал күтәреп).* Сез бәйрәм алып килдегез, әфәндем. Аңа да, миңа да! Юллардан күзләрен алмый көтә инде үз татарын. Мин аның өчен сөенәм. Бәйрәмдә биилләр түгелме соң сездә дә? *(Җырлап-биеп китә.)*

*Бас, кызым Әпипә,*
*Син басмасаң — мин басам.*
*Кече кызымның туенда*
*Биеп калыйм ичмасам!*

Т а й ф у р. Браво! Катрин! Кече кызыгыз бармы соң, чыннан да?

К а т р и н. Ах, булсачы бер кыз... Тотар идем дә сиңа кияүгә бирер идем. Жак сөенер иде татар дип. Аллаһе тәгалә балалардан мәхрүм итте. Шулай да бәхетсез түгел мин Жак белән. Ул үзе сабый кебек... Көнләшә дә, үпкәли дә, шундук оныта да... *(Тәрәзәгә карап.)*. Әнә, үзе дә кайтып килә кадерлем! Жак, бездә кунаклар бар! Татар!

Ж а к *(керә).* Хәерле кич, Сафия ханым!

С а ф и я. Игътибар итмәгез! Сөйләшкәнчә...

К а т р и н. Тагын бер кунак, Жак!

Т а й ф у р. Исәнмесез, Жак әфәнде! *(Кулын бирә.).* Тайфур Кормаш. Үз иленнән сөрелгән, бүгенге көндә дөнья юлларында адашып йөрүче мөһаҗир, ирекле рәссам.

Ж а к. Саумысыз?.. Без барыбыз да адашканнар, энекәш...

Т а й ф у р. Әфәнде диегез. Шулай дәшсәләр, мин үземне шәхес итеп тоям.

Ж а к. Нинди җилләр ташлады бу якларга, Тайфур энем?

Т а й ф у р. Нинди җилләрме? Милләтебезнең асыл затларын, Гаяз Исхаки кебекләрне үз иленнән сөргән сәмум җилләре.

Ж а к. Утыр әле, энем, сайрашыйк әле бер үзебезчә, жаннар рәхәтләнгәнче. Катрин!

К а т р и н *(йөгереп килә, бокалларга шәрап сала).* Эч, жаным!

Ж а к. Кара аны, «жаным» дип, сөйгән ярга гына әйтәләр! Ярый, жаным, эшеңдә бул! Тукта! Мин эзләгәнне таптым. Сафия ханымнан язып алдым. Мәле, куеп җибәр! *(Катрин китә. Магнитофоннан Илһам Шакиров башкаруында «Бик еракта идек» җыры яңгырый. Жак сейфтан саклык белән генә ак калфакны ала, аны күкрәгенә кыса.)*

Җ ы р: *Ак калфагым төшердем кулдан,*
*Безнең дус-иш белән ил туган...*

**Жак калфакны урынына кире куя.**

Т а й ф у р. Әйе, ак калфакны төшердек кулдан... Бердәмлек юк бездә... Әнә яһүдләр һәм әрмәннәр ничек дөньяда бер-берсенә тотынып, үзләрен югалтмый саклыйлар. Болай да кискәләнгән, бүлгәләнгән милләт җирнең төрле якларына чәчелгән, алар арасындагы күперләр яндырылган. Кем генә җимермәгән ул күперне... Иван Грозныйдан алып Сталинга кадәр... Күпме татар дәүләтләре, үзара сугышып, берберсенең көчен бетергәннәр. Аннан соң урыслар белән... Әнә шулай яшәвен дәвам итсә, бетә татар...

Ж а к. Мин, бетмәбез дип уйлыйм, Тайфур энем.

Т а й ф у р. Үз талантларына мөнәсәбәттә милләтнең бер сыйфаты чагыла.

*Тәгәрәп уйнап,*
*Буй үскән*
*Туган илем, исән бул!*
*Чәч түзгытып,*
*Җай искән*
*Таңгы җилем, исән бул!*
*Йөгереп-йөгереп туктаган...*
*Яулык болгап сыктаган*
*Нәзкәй билем, исән бул!»*

— дип, аерылышу, саубуллашу турында җан шигыре язган Дәрдемәнд, Рәсәйне алтынга күмгән миллионер Дәрдемәнд, революциядән соң ачтан үлә. Әле «Азатлык» радиосыннан ишеттем: Дәрдемәнднең рухи алтыны — бәләкәй генә китабы Казан кибетләрендә тузан эчендә, сатылмыйча ята икән. Әйдә, эчик әле, Жак әфәнде, кол хәлендә яшәүче, мескен халкыбыз өчен әрнеп, гажиз булып...

Ж а к. Мин, энекәш, бу сүзләрең өчен тост күтәрмәс идем. Татарның мокытлары, салам-торханнары жиде миллион арасында күптер, әмма халык мескен түгел, түгел!

Т а й ф у р. Аның иң бөек чагы — 1905 нче елда, шул чорда ул Тукаен тудырды. Кызганыч! Факт! Милләтебез хәзер милләт дигән горур исемен, асылын югалтты. Үз хәле турында сөйләшүдән куркып яши.

Ж а к. Син мине дә шулар рәтенә кертәсеңме? Үзеңне дә?

Т а й ф у р. Әйе, Жак әфәнде.

Ж а к *(сикереп тора).* Минме куркак! Минме мескен!

К а т р и н *(йөгереп килә).* Жак, тынычлан, утыр...

Ж а к. Син кит моннан, Катрин!

К а т р и н. Тайфур әфәнде, авырткан жиренә кагылмагыз...

Ж а к. Фашист лагерьларында тиреслектә казынганда да баш имәгән, офицерның битенә төкергәне өчен аяклырыннан асып куелган — минме куркак?!

Т а й ф у р. Кичерегез, Жак әфәнде!..

Катрин *(«Ак калфак»ны кочаӧйтә).* Тынла, Жак... *(Кочаклап аны утырта.)*

Тайфур. Жак абый, нигә син сугыштан соң илгә кайтмадың?

Жак. Әсирләрне, бигрәк тә безне — татар легионында хезмәт итүчеләрне илебез дошман, хыянәтче итеп игълан итте. Менә монысында син хаклыдыр, мин курыктым — илемә кайтсам, хөкем итәрләр дип курыктым. Һәм дөрес эшләгәнмен — дошманда мең газап чигеп кайткан әсирләрнең күбесен, кайтып, керү белән, Себергә озаттылар. Әле дә ярый, халкыбыз бәхетеннән Муса Җәлил илгә исән кайтып кермәде...

Тайфур. Их, татар, татар... һәрбер талантың — үзе бер фаҗига... *(Кинәт.)* Сагынасызмы?

Жак. *Сагынасыңмы дип сорыйлар.*
*Сагынмаган кая ул...*

Тайфур. Туган илгә кайта алмаганга үкенмисезме?

Жак. *Кычкыра торган кәккүкне*
*Очырмас идем күрсәм дә.*
*Туган-үскән җирне бер күрсәм,*
*Үкенмәс идем үлсәм дә...*

Минем анда, туган җиремдә, өмет багълап, бишек тирбәткән әнкәем калмаган дисеңме әллә, минем анда, тар басмада кер чайкаучы нечкә билем калмаган дисеңме әллә, чит җирнең озын төннәрендә җанны әрнетеп, төшкә кереп үз урманымның кошлары сайрамыйлар дисеңме әллә?

Тайфур. Ник кайтмыйсың, Жак абзый?

Жак. Мин — алар өчен һаман да дошман. Менә син яңа заман кешесе, япь-яшь кеше, син нигә илеңне ташладың?

Тайфур. Алар мине дә дошман ясадылар. Үзләре кебек уйламауларым өчен, алар кушканча иҗат итмәвем өчен...

Жак. Рәсемнәреңне күрәсе иде бер...

Тайфур. Кайберләре — үзем белән. Бер минут! Хәзер, Жак әфәнде! *(Чыга.)*

Катрин *(килә, Жакның алдына утырып, кочаклап).* Сак бул, Жак, шпион булып чыкмасын...

Жак. Юк, моның күзләрендә иман нуры бар.

Катрин. Нәрсә ул иман нуры?

Жак. Ул шундый нур, кадерлем... аны бер телгә дә тәрҗемә итеп булмый.

Тайфур *(берничә картинасын алып керә, элеп куя).* Карагыз, Казанда боларны кабул итмәделәр. Сезгә ошар дип уйлыйм. Катрин ханым, сез дә бәяләгез.

Катрин *(күңеле булсын өчен генә).* Грандиоз! Искиткеч! Браво!

Тайфур. Жак әфәнде, мина дөрес сүз кыйммәт...

Жак. Бу нәрсә соң? Ә монысы? Гаҗәп... Ә нигә болай? Юк, мин сезнең картиналарыгызны аңламыйм, Тайфур энем... Дөресен әйтәм, аңлашылмый...

Катрин. Жак... Кунакның хәтерен калдырырсың...

Тайфур *(рәсемнәрне кискен хәрәкәтләр белән җыеп ала).* Сез, гомумән, сәнгатьнең ни икәнен беләсезме соң?

Жак. Мин белгеч түгел, минем үз фикерем.

Тайфур *(бер читкә китеп).* Соңгы өметем дә сүнде. *(Күзләрен бер ноктага текәп).* Бер аңларлар, ләкин мин булмам...

Жак. Ни дидең?

Тайфур. Мин... китәм!

Жак. Кайларга таба юл тотасың, кайнар егет?

Тайфур. Белмим. Мин генә мени карурманда адашканнар?

Жак. Безгә кайчан да булса бер керерсеңме?

Тайфур. Белмим.

Жак. Якшәмбе көнне Сан-Франциско Казанны очрашуга чакыра. Бәлки, катнашырсың?

Тайфур. Белмим... Рәхмәт бу йортка... *(Акча калдыра).*

Жак *(акчаны Тайфурның кесәсенә кире салып).* Син безнең кунак.

Тайфур. *Күңелемәгез, күп тормабыз,*
*Без җирдә кунак кына...*
БӘХИЛ БУЛЫГЫЗ!

Жак. Сау бул, энекәш...

Катрин. Гаепләп китмәгез.

**Җыр көчәя.**

Тайфур. Шулай да мин рәсемнәремне сездә калдырам. Бәлки, кем булса да ошатып, сатып алыр...

Жак. Калдыр... Тукта, бер сүзем калган.

Тайфур. Әйтеп калыгыз.

Жак. Халыкка ункәләмә, энем. Елап йөреп халыкны бөек ясап булмый... Онытма, карурман серле, чиксез... күпме генә кырсалар да... *(Көйли).*

*Әй тал үсә, тал үсә,*
*Башын киссәң, тагы да үсә!*

*(Чыгалар. Җыр бер көчәя, бер тына.)*

**Кадрда телевизион күперда катнашучылар.**

Сафия. Мөхтәрәм тамашачыларыбыз, сез чит илләрдәге милләттәш-

ләребез тормышыннан бер сәхифә карадыгыз. *(Өстәлгә кәгазь куялар.)*. Америка сенсациясез яши алмый. Гадәттән тыш хәбәр әйтү өчен, студиябезгә полиция вәкиле Клиффорд Стреттон әфәнде килеп кергән. Рәхим итегез, Клиффорд әфәнде! Безне нинди яңалык белән куркыта аласыз?

Клиффорд. Бездә сөенерлек хәбәрләр булмый инде, Сафия Нурхан.

Сафия. Шулай да?

Клиффорд. Моннан нәкъ унбиш минут элек, телестудиядән ерак та түгел кварталда туктап калган машинага игътибар иттек. Шикләнүебез юкка түгел икән — ишеген ачып карасак — хәрәкәтсез гәүдә!

Сафия. Ул безгә таныш кешеме?

Клиффорд. Безне дә әнә шул сорау кызыксындыра. Аны әле генә сезнең тапшыруда күргәннәр. Документларына караганда, ул — Америка гражданины Тайфур Кормаш!

Сафия. Юк! Булуы мөмкин түгел! Сез моны дәлилләп, өздереп әйтәсезме?

Клиффорд. Һич юк! Бу әле тикшерүне таләп итә. Шулай да бездә бер версия бар.

Сафия. Версиягезне тыңлыйбыз.

Клиффорд. Тайфур Кормаш үзүзен үтергән булырга охшый.

Сафия. Фактларыгыз бармы?

Клиффорд. Машинасында язу калдырган.

Сафия. Укып бирсәгез иде.

Клиффорд. Аңа кадәр миндә бер сорау бар. Арагызда мәрхүм Тайфур Кормашны белүчеләр бармы?

**Тынлык.**

Сафия. Казан, безне ишетәсезме?

Клара. Ишетәбез, Сафия ханым. Америка гражданины яшь рәссам Тайфур Кормашның вакытсыз үлеме мөнәсәбәтеннән кайгыбызны белдерәбез.

Шәмсия. Клара иптәш, нигә әле сез барыбыз исеменнән дә сөйлисез? Мин, мәсәлән, бу фикергә кушылмыйм. Менә хөрмәтле Исмай Саттаровичтан да сорагыз!

Клара. Исмай Саттарович?

Акчурин. Минем фикеремме?.. Мин... шулайрак уйлыйм... Бу — минем өчен бөтенләй көтелмәгән хәл. Мин... бераз уйларга тиеш. Дөнья — куласа...

Клара. Ярый, Исмай Саттарович, уйлагыз.

Акчурин. Мин инде уйладым... Мин кайгы белдерүгә кушылам. Ләкин... мәрхүмнең дөньяга карашы белән килешмәгән хәлдә...

Сафия. Клара ханым, мәрхүмне якыннан белүчеләр бармы, дигән рәсми сорауга сезнекеләр җавап бирмәделәр?

Клара. Якыннан белүчеләр бармы, иптәшләр?

Шәмсия. Минем аны күргәнем дә юк. Күрергә дә теләмәс идем! Менә Исмай Саттаровичтан сорагыз!

Клара. Исмай Саттарович, мистер Клиффордка җавап бирерсез, бәлки. Сез Тайфур Кормашны якыннан белә идегезме?

Акчурин. Мин аны укыттым.

Шәмсия. Сезнең тәрбия?

Акчурин. Минем аның белән мөнәсәбәтләр фикер каршылыкларыннан гыйбарәт. Юк, мин аны якыннан белмим. Регинадан башка, гомумән, аны якын күрүчеләр юк иде. Ул да, ялгышмасам, акылына килеп, аңардан суынды. Дөнья — гел үзгәреп тора...

Сафия. Мәгълүматларыгыз өчен рәхмәт, Казан! Мистер Клиффорд, сезне тагын нәрсә кызыксындыра?

Клиффорд. Хәзер мин сезгә мәрхүмнең васыятен укыйм. Рөхсәтме?

Сафия. Безнең сценарийда бу аяныч вакыйга булмаса да, без ризаларга мәҗбүрбез. Рәхим итегез!

Клиффорд. Тыңлагыз!

Тайфур тавышы.

1. Мин бу шәфкатьсез дөньядан үз теләгем белән китәм. Минем үлемемдә беркемне дә гаепләмәгез.

2. Жак әфәнде, әгәр дә минем иҗатым белән кызыксынып, картиналарымны сатып алсалар *(монысына мин өметне өзмим)*, алардан килгән табышны чит илләрдә газап чигеп үлгән бөек әдибебез Гаяз Исхакыйның исемен мәңгеләштерү өчен тапшыруыгызны үтенәм.

Клиффорд. Имзам: Тайфур Кормаш. Конвертның тышына Жак әфәндененең адресы язылган. Мин белергә тиеш, сезнең арагызда васыятьтә күрсәтелгән шәхес, ягъни Жак әфәнде, бармы?

Жак *(алга чыгып)*. Мин — Жак. Америка гражданины!

Клиффорд. Мистер Жак, сез Тайфур Кормаш белән кайчан таныштыгыз?

Жак. Күптән түгел.

Клиффорд. Мин төгәл җавап көтәм.

Катрин. Бер атна элек.

Клиффорд. Сез кем?

Жак. Ул минем хатыным. Катрин Люсиль. «Ак калфак» барының хуҗалары.

Клиффорд. О кей! Элек сез Тайфурны белми идегезме?

Катрин. Юк! Юк! Алла сакласын!

Жак. Белми идек.

Клиффорд. Мистер Жак, мисс Катрин, әйтегезче, Тайфур Кормаш сезнең белән очрашуда үзен ничек тотты?

Жак. Ничек дияргә?.. Аның шундый адымга барасын кем белсен...

Клиффорд. Мәрхүм үзенең дошманнары барлыгына ишарә ясамадымы?

Жак. Минем бик аз белүемчә, аның дошманнары юк иде.

Клиффорд. Сәер.

Жак. Аны дошман итеп күрергә теләүчеләр бар иде.

Клиффорд. Кемнәр алар? Фамилияләре?

Жак *(югалып кала)*. Атап әйтү мөмкин түгел... Ул конкрет әйтмәде.

Клиффорд. Тайфур үзенең васыятендә сездә картиналарын калдыруы турында да яза. Бу факт дөресме?

Жак. Дөрес. Мин аларны алып калдым.

Клиффорд. Ни өчен ул картиналарын сездә калдырды?

Жак. Ул газаплана иде. Иҗади кризис дигән сүзләре хәтердә. Монда күчеп килгәч, бер генә картина да ясый алмаган. Ул үзе, исән булса, дөресрәк аңлатыр иде. Башта ул үзенең илендә әсәрләренең кире кагылуын әйтте. Аннан соң безгә дә күрсәтте. Рәсемнәрне, дөресен әйтим, мин дә аңламадым. Шуннан соң ул... китте...

Клиффорд. Ул ялгызы гына чыгып киттеме?

Жак. Ялгызы. Машинасында.

Клиффорд. Аннан картиналарны нишләттегез?

Жак. Керүчеләр күрсен дип, барга элеп куйдык.

Клиффорд. Алар хәзер кайда?

Жак. Ядкарь өчен генә булса да берсе дә калмады. Узучылар, туристлар «ах»та «вах!» килеп сокланып карадылар. «Гениально!» дип мактадылар, сатып алдылар. Бер атна эчендә! Мин аптырап калдым. Сәнгатькә карата мондый кызыксынуны күргәнем юк иде. Мәрхүмнең васыятен, әлбәттә, җиренә җиткереп үтәрбез.

Клиффорд. Минем әлеге сорауларым тәмам. Лэди һәм джентльменнар, туташлар һәм әфәнделәр, тапшыруыгызга көтмәгәндә бәреп кергән өчен, гафу итмәссез дип уйлыйм! Нишлисең, эшем шундый... Ә сезнең белән, мистер Жак, мисс Катрин, саубуллашмыйм. Кайбер ачыкланып бетмәгән, томанлы мәсьәләләр турында сөйләшәсе бар. Тапшыру тәмамлануга, сезне минекеләр каршы алырлар. Тикшерү дәвам итә... Тагын бер мәсьәлә! Мәрхүмне күмәргә аның туган иленнән килүчеләр булачакмы? Хәбәр итәрсез! О кей! *(Чыга.)*

Сафия. Мистер Стерн, күреп торам, сезнең әйтәсе сүзләрегез калган?..

Майк. Рәхмәт, Исмай, шундый да талантлы шәхесегезнен һәлакәте мөнәсәбәте белән... кайгыгызны... кайгыбызны уртаклашам.

Акчурин. Бу минем өчен бигрәк тә авыр, Майк... Кызганыч. Без аны аңларга тырышмаганбыз. Бәлки, әле аны коткару да мөмкин булгандыр... Дөнья үзгәрмәсә...

Майк. Юк, Исмай, мөмкин түгел. Доктор буларак әйтәм, ул инде бу адымга барасын килгәнче үк хәл иткән. Ә мин, Исмай, аның бер картинасын сатып алдым бит. «Ах калфак» кафесында. «Айда очрашыр күзебез». Гаҗәеп!

**Сафия өстәленә телефонистка кәгазь куя.**

Сафия. Минем өстәлемә игълан китереп куйдылар. Сезне дә таныштырырга рөхсәт итегез.

**«Американ татар җәмгыяте хәбәр итә:**

**Милләтебезнең күренекле бизнесмены Зәйни Акчура Сан-Франциско каласында вафат булды. Мәрхүмнең бай мирасын беркетү өчен, нәсел-ыруын, кардәшләрен эзлибез. Ул калдырган васыятьтә Исмай Саттар улы Акчурин да бар».**

**Исмай әфәнде, мәрхүмнең якыннары хәзер үк сездән ачык җавап көтәләр... Исмай әфәнде?**

Клара. Сез бу унай белән кайгы белдерәсездер бит?

Шәмсия. Шулай инде, миллионер үлү — безнең өчен бик зур кайгы... Йә, нигә дәшмисез?

Акчурин. Мин... мин... кинәт кенә җавап бирә алмыйм...

Шәмсия. Димәк, сез...

Акчурин. Безнең мөнәсәбәтләр өзелгән иде...

Шәмсия *(усал)*. Соң... яңартыгыз мөнәсәбәтегезне...

Акчурин. Юк... юк... булмый... Дөнья үзгәреп тора.

Клара. Исмай Саттарович, нәрсә булмый?

Акчурин. Мин... ул мирастан... баш тартам...

Клара. Сафия ханым, ишеткәнсездер? *(Телефонистка аның өстәленә язу китереп куя.)* Исмай Саттарович, рәхим итеп телефонга барыгыз!

Акчурин *(телефонга барып трубканы ала)*. Тыңлыйм!

Акчурин хатыны. Акылын бармы синең, юкмы?! Көтмәгәндә ишелеп төшкән байлыктан баш тартасың. Хәзер үк ризалыгыңны бир!

Акчурин. Ярамый... үзең дә беләсең... Дөнья... үз...

Акчурин хатыны. Доллар үзгәрми! Ул синең туганың, бетте-китте! Ишетәсеңме?

Акчурин. Туктале, алай ярамый бит... мин...

Хатыны. Имзаңны гына куй, акчасын безгә бирерсең. Әфган сугышыннан авырып кайткан малаеңны дәваларга чит илгә җибәрермен. Менә үзе,

трубканы йолкый...

Малае. Папа, немедленно оформляй! Юкса, хәзер үзем барам! Мин дә — Акчурин! *(Акчурин, трубканы куеп, үз урынына килә.)*

Сафия. Исмай әфәнде ни дип җавап бирә?

Клара. Исмай Саттарович?

Акчурин. Мин әле... хәл итеп бетермәдем... Бераз уйлангач...

Сафия. Ару белмәс тамашачыларыбызга, көн саен, минут саен ишелеп торган авыр хәлләрдән арыну өчен, Истамбулдагы төрек татарлары башкаруында җыр тәкъдим итәбез.

Җыр: *Ике кеше ике ярда*
*торып кала,*
*Сөйләшергә, аңлашырга*
*күпер юкмы?*
*Беркем җавап тапмый торган*
*авыр сорау:*
*Кем гаепле?*
*Кем гаепле?*
*Кем гаепле?*
*Кемдер йөзеп чыгып җитәр*
*теге ярга,*
*Кем кабызыр өмет дигән*
*сүнмәс утны?*
*Нигә безнең араларда*
*күперләр юк?*
*Кем гаепле?*
*Кем гаепле?*
*Кем гаепле?*

Катрин. Юк! Жак гаепле түгел!

Жак. Тынычлан, Катрин...

Катрин. Полиция сиңа шик белдерде. Сине гаепләүләре ихтимал.

Жак. Без аны соңгы тапкыр күрүчеләр. Бу эшкә шаһитләр сыйфатында катнашабыз.

Катрин. Ә гаепләсәләр? Сине моннан чыгуга көтеп торачаклар.

Сафия. Мин барыгызны да тынычланырга чакырам. Тайфур әфәнденең үлемендә гаепле адәм юк.

Катрин. Юк! Юк!

Сафия. Сез ничек уйлыйсыз, әфәнделәр, ханымнар? Гөлнур туташ?

Гөлнур. Нинди дә кыйммәтле адәмебезне югалтканбыз. Туганнарының хәсрәтен уртаклашабыз. Соңгы юлга озатырга килүчеләр булса, юл чыгымнарын үзебез түлибез.

Сафия. Без дә Тайфур әфәнде туганнарының кайгысын уртаклашырга телибез. Бәлки, аны соңгы юлга озатырга килүчеләр табылыр?

Клара. Ничек уйлыйсыз, иптәшләр? Мәрхүмнең туганнары бармы? Аны соңгы юлга озатырга кем килер?

**Рәтләрдә «Юк!», «Юк!» дигән тавышлар.**

Регина *(атылып керә).* Бар! Бар! Бар!

Клара *(каушап).* Регина иптәш... утырыгыз... ярамый...

Регина. Сценарийда каралмаган, димәкче буласызмы? Җитте! Без болай да, сценарийда расланганча гына, куркып яшәдек. Әти-әнисе булмаса да, Тайфурның Казанда туганнары бар. Әмма Тайфур «дошман»га әйләнгәч, алар, куркып, аның белән араны өзделәр. Тайфурның бердәнбер якын кешесе мин идем! Әмма мин аның мәхәббәтенә лаек булалмадым. Һәм мин аның үлеменә дә гаеплемен! *(Шау-шу.)* Ни өченме? Куркак мин! Куркак! Ни генә булса да миңа аның белән китәргә кирәк булган. Соңгы тапкыр аның сүнгән күзләренә карап: «Кичер, Тайфур!» — дип әйтергә, аны чит ил туфрагына тапшырырга ярдәм итегез... ярдәм итегез... Ишетегез, мин Тайфурны яратам!..

Шәмсия. Нигә сез аны туктатмыйсыз? Ул ни сөйләгәнен дә белми.

Жак. Ни өчен аны туктатырга? Сез аның сүзләре белән килешмисезмени?

Шәмсия. Килешмим!

Жак. Ни өчен?

Шәмсия. Тайфур Кормашны күмәргә бару рәсми төс алачак. Ни өчен әле без үз илен ташлап киткән, үз халкына яла яккан, иҗатын халык аңламаган, безгә чит элементны хөрмәтләп соңгы юлга озатырга тиешбез?

Жак. Нигә сез шулкадәр кистереп әйтәсез... кем...

Клара. Шәмсия әби.

Жак. Шәмсия әби... Күз алдына китерегез, сезнең балагыз шундый фаҗигале хәлдә калды ди...

Шәмсия. Горурланып әйтә алам: минем ирем дә, балам да Ватан сугышында батырларча һәлак булдылар. Мәңгелек дан аларга! Үзләренең кадерле илләрен сатмадылар...

Жак. Димәк, мин сатлык җан?

Катрин. Жак, кузгалма, утыр... Мисс Шәмсия, аңа андый сүзләр әйтү ярамый...

Шәмсия. Әгәр инде адәм, иленнән ваз кичеп, теге якка чыккан икән, аның исеме дә, җисеме дә — дошман!

Жак. Моңа кадәр минем тәнемне фашистлар телгәләделәр, йолдыз яндырып, күкрәгемә бастылар, автомат, итекләр белән изделәр! *(Күлмәген аерып төшерә.)* Менә аларның автографлары!

Иванов *(сикереп тора).* Габделхак! *(Жак сискәнеп китә, әмма дәшми, исемен ишетеп, урынына бөгелеп төшә.)* Габделхак Ишмуллин! *(Шәмсия дә куркып башын күтәрә.)* Мин сине таныдым! Нихәл, маки? Син исәнмени? Мине таныйсыңмы? Керәшен Иванов! Кил, кочаклыйм үзеңне, җә!

Жак. Сез ялгышасыз. Мин — Жак.

Иванов. Юк, син Жак түгел, син — Габделхак! Тән яраларыннан та-

ныдым. Хәтерендәме татар легионы? Җырчылар ансамбле? Сабантуй ясадык. Синен белән көрәштем дә әле...

*Яфрак ла төшә җирләргә*
*Көзге дә каты җилләрдә.*
*Сагынамын да, әнкәй, саргаямын,*
*Ябыгамын ят ук илләрдә.*

Син минем җырлаганны тыңларга ярата идең. Ә аннан сон — француз партизаннары отрядында. «Маки Лимузин». Ну, хәтереңне эшләт, җә?! Роан шәһәрен азат итеп, үзебезнең кулда тоттык, ә? Җә? Монысын кара урманда, разведкага барганда, әкрен генә җырладым:

*Су буйларында эләмәлек,*
*Эләмәлектә йөрмәдек.*
*Туган илдә рәхәт икән,*
*Кадерләрен белмәдек...*

Их! Мин исән калдым. Легионда булган өчен утырдым утыруын. Себер урманнарында агач аудардым. Ходай кушкандыр, баш исән калды. Габделхак, әле һаман керәшенне танымыйсың, ә? Туктале, син алай нитмә әле, картайсам да, минем хәтерем ничава. Ну, исеңә төшерим тагын теге тимер юл күперен шартлаткан чакны... Өчәү бардык. Керәшен, татар, хохол дип көлештек. Соңыннан кочаклашып, үкереп еладык. Без шартлаткан эшелонның бер вагонында үзебезнекеләр икәнне белдек. Их, брат, ну үкендек! Син бигрәк тә нык кичердең... Ну, төштеме исеңә? Габделхак!

Ш ә м с и я. Юк! Юк! Ул Габделхак түгел!..

Ж а к. Жак!!! Кем белән бутыйсың мине? Әмма шуны әйтәм: без... сез... һаман да... аңлапмы, ялгышыпмы... үз кешеләребезне юк итүне дәвам итәсез!

И в а н о в. Габделхак! Нигә яшерәсең? Син гаепле түгел бит, брат!

Ш ә м с и я. Провокация! Аның Габделхак Ишмуллин булуы мөмкин түгел!

Ж а к *(катып калган хәлдә Шәмсиягә текәләп карап тора. «Ак калфак» җыры ишетелеп куя.)* Әйе... Мин Габделхак Ишмуллин... түгел... Кичерегез... Катрин, мин сине анда котәрмен... *(Чыга.)*

И в а н о в. Габделхак! Ишмуллин! Тукта! Китмә! *(Катринга карап.)* Миңа бит исән партизаннардан имза кирәк. Минем француз партизаннарында сугышып йөргәнгә ышанмыйлар. Зинһар өчен расла! Габделхак! Китте... Нишләгән ул? Үзгәргән. Шундый саф күңелле егет...

Ш ә м с и я. Димәк, үзегез дә икеләнәсез?

И в а н о в. Шундый саф күңелле егет... Әнисенең ак калфагын иң авыр чакларда югалтмый саклаган җан...

Ш ә м с и я. Ак калфак? *(Хәлсезләнеп утыра.)* Габделхак... Улым...

А к ч у р и н. Шәмсия апа, ни булды сезгә?

К л а р а. Тотыгыз аны... ярдәм итегез... *(Шәмсияне ике ягыннан тотып алалар.)*

Ш ә м с и я. Балам... Габделхак...

И в а н о в *(аның янына килеп)*. Әйттем бит, Габделхак дип...

Ш ә м с и я. Кем уйлаган... Күпме еллар көттем. Үлем хәбәрен алгач та өметне өзмәдем. Кире китерегез аны! Күреп калыйм... Чәчләреннән сыйпыйм, күзләренә карап калыйм. Чакырыгыз Габделхагымны...

С а ф и я *(телефонга барып номер җыя)*. Мистер Клиффорд! Жак әфәндене, ягъни Габделхак Ишмуллинны әнисе Шәмсия Ишмуллина чакыра. Ә? Ничек? Мин бернинди Габделхакны да белмим, ди?

К а т р и н. Әни... Кайнана... Бу мин... сезнең киленегез Катрин Люсиль...

Ш ә м с и я. Минем киленем бармыни?

К а т р и н. Исәнмесез, әни? Мин сезне күрергә күптән хыялландым. Жак риза булмады. Ул үзе гел сезнең хакта сөйли, төшләрендә күрә.

Ш ә м с и я. Ә нигә... әнисен күрергә теләми?

К а т р и н. Ул әйтә: «Әгәр анда минем исәнлекне белсәләр, әнигә дә, нәсел-нәсәпкә дә көн күрсәтмәсләр», — ди. Шунлыктан үзенең исемен дә, фамилиясен дә алыштырды. «Габделхак Ишмуллин дөньяда юк, сугыш кырында ятып калды», — ди. Кемнәрдер өчен бар, кемнәрдер өчен — юк...

Ш ә м с и я. Нигә соң без шулкадәр шәфкатьсезләр?! Улым... балам... Габделхагым...

К л а р а. Докторның килүен сорыйбыз!

**Ашыгып доктор һәм шәфкать туташы керәләр.**

Д о к т о р. Соң инде...

**Казан ягы җыр башлый. Сан-Франциско күтәреп ала.**

*Казаннардан мамык шәл алдым,*
*Алтын тәңкә бирдем җәлләми.*
*Ак калфагым төшердем кулдан,*
*Безнең дус-иш белән ил туган,*
*Безнең дус-иш белән ил туган.*
*Алтын тәңкә бик зур мал түгел,*
*Бер дә кирешүләр әлә ни.*
*Ак калфагым төшердем кулдан...*
*Ак калфагым төшердем кулдан...*

ПӘРДӘ

*1990.*

# ШИГЪРИЯТ

## Кави Латыйп

### Иман кәрваны

*Гаяз Исхакыйга*

**1**

Диңгездә мин кәрван күрдем,
барыр юлы туры иде:
бисмиллалы, җырлы иде,
кояшлы һәм нурлы иде.

Кәрван юлы шундый иде:
биш кораб та иман белән тулы иде.
Флагманы — илаһи зат,
бер мөселман улы иде.

Диңгездә ул бик тә иркен сулый иде,
игелеклелек кылуны ул уйлый иде.
Шуңа диңгезләрне буйлый иде:
вөҗданлылыкта,
иманлылыкта,
юлдашларын сыный иде...

Диңгездә мин кәрван күрдем,
аның юлы туры иде.
Кораблары иман белән тулы иде.
Флагманы — илаһи зат,
бер мөселман улы иде.
Диңгездә ул
Җир язмышын уйлый иде.

**2**

Имансыз кораблар да
Шулай йөзә,
Шулай гизә диңгезләрдә.
Югалсалар,
кемнәр чыгар
андыйларны эзләргә?..

---

Кави ЛАТЫЙП (1927) — *шагыйрь, прозаик; татар, урыс, чуваш телләрендә басылган китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

3

Сәфәрләрдә
иман — җилкән.
Иманлылар
җиде диңгез артына ук барып җиткән.
«Көфер почмаклар»ын
исән-имин үткән.
Үләргә теләмәсәң,
инан икән:
коткаручың,
әҗәлдән алып калучың —
иман икән.
Шуңа инан икән!

4

Иманлылар
кораб-кораб
яхшылык йөрткән.
Җавапка тик
суда батмас,
утта янмас
рәхмәт көткән...

5

Диңгездә мин кәрван күрдем,
барыр юлы туры иде.
Бисмиллалы, җырлы иде,
кояшлы һәм нурлы иде.
Биш кораб та
иман белән тулы иде.
Флагманы — илаһи зат! —
бер мөселман —
татар улы иде...

* * *

Уңга да мин сугылам,
сулга да мин сугылам.
Ләкин иң зур кыйблам:
туган җиргә,
туган илгә сыенам.
Идел-йортка
кирәк булып тоелам...
Кирәк икән —
корыч булып коелам!

* * *

Август уртасы.
Җәйнең шундый ноктасы:
алмагачта алма пешә,

поезд узган саен,
җир селкенүдән,
өзелеп төшә.

Алма җыям.
Берәмләп кәрзингә куям.
Бакчада үземне
хуҗа итеп тоям.

Идел-йорт бакчаларында
алма пешүдән,
җиргә өзелеп төшүдән
кемнәргә зыян?..

* * *

Төштә күрдем әниемне:
син дә чал чәчле булгансың, дип әйтте.
Минем белән озак түгел,
бер-ике мизгел генә сөйләште.
Аннары югалды.
Оҗмахкамы юл алды?
Күз алдында тере сурәте калды.

Инде әнием белән
өндә сөйләшәм,
көн дә сөйләшәм...

Әнием дә яшәр кебек,
мин яшәсәм,
мин үлмәсәм...

* * *

Яшәү өчен кырыс булу кирәк,
корыч булу кирәк.
Кырыслана-кырыслана җан,
корычлана-корычлана тән,
ярылмасмы йөрәк?

Әҗәл бушлай килә,
яшәгәнгә — түлә...

* * *

Минем күңел яралanучан,
гомеремдә санаусыз яра алдым
дошманнан, дустан.
Әллә шуның өчен
аларның кулларын кысам?..

Куллар кыскан саен,
яралар тирәнәя...
Дус-дошман була шул — тирәдә.

* * *

Кайда хакыйкать юлы?..
Бүгенге пәйгамбәрләр,
күрсәтә аласызмы?

Әллә муеннарга элмәк кенә
саласызмы?
Без — колларны юк итеп,
үзегез генә каласызмы?

Бездән соң
яңа коллар табарсызмы?..

* * *

Гөнаһлы бәндә!..
Гел ялгышам исемен әйткәндә.

Дине, дене белән кяфер,
сөйләшә безнең телдә ул...
Чыга калса җил-давыл,
сиңа, миңа каршы чыгачак.

Бабаларыбызны гүргә керткән
Явыз Иван белән булачак.

Татар халкы —
гөнаһ шомлыгы, дип,
аягүрә бәддога кылачак...

* * *

Яхшылык эшлим дип,
кайчак күрәсең зыян.
Шаһит — тере җиһан.

Яхшылык кылып йокла,
Игелек теләп уян.
Гел сызлан,
гел ян,
җан-аҗаган!

* * *

Ялгыз торна һаман ялгыз
көзен — кичен һәм иртән.
Ялгыз торна, оч, әйдә, оч
биектән, гел биектән.

Яшермим, зәңгәр күктән
мәрхәмәтлелек көтәм —
Усаллар урыны түбән...

Күңелдә яра тирән.

Ялгыз торна, ялгыз булма,
мине дә син алып кит
еракка үзең белән.
Үз хәлемне үзем беләм:
җәй үлмәдем, көзен үләм...
Саргайган әнә үлән.

## Мансур Шаһимәрдән

# Кеше күңеле — карурман

ПОВЕСТЬ

Көннәрнең берендә, һич көтмәгәндә, Габделбәр өчен дөньяның чите кителде. Төлке Маһиры армиядән кайтып, Зөбәйдә тирәсендә бөтерелергә кереште. Төлке дигәннән... Маһирның атасы, сугышта, «тел» алырга барган җирдә, нидер сизенеп, үлгәнгә сабышып яткан да, янына килеп чыккан немец солдатын кинәт әсир итеп, частька алып кайткан һәм аңа төлке кушаматын әнә шул чакта, яратып, разведотряд командиры кушкан, имеш. Бу мәшһүр кушамат Маһирга бишектән үк чат ябышты. Кем малае? Төлке Гыйльми малае — бетте-китте... Төлке Маһир турында: «Авызы белән кош тота ул»,— дип сөйләүчеләр дә булды. Алдамаганнар икән. Бер кичне Габделбәр шаккатты: куштирәк төбендә кыз белән чөкердәшепме чөкердәшә болар! И егетне күрсәгез сез — йөзе әнис алмасы, күзе утлы күмер. Габделбәр гөберле бака тотып тегеләрнең өсләренә атты... Соңы ни белән беткәндер, артыннан Зөбәйдәнең куркынып кычкырганы ишетелде дә, «чер-р-р» итеп чикерткәләр генә сайрашып калды.

Иртәгесен фермага килгәч, егетнең сәламен алмады Зөбәйдә. Ул аңа хәтта күтәрелеп тә карамады. Горур да соң! Аңа калса, Габделбәрдә дә горурлык юк түгел. Кызлар да җитәрлек. Әнә Әргән Вафа кызы Разыя аның кочагына атылырга тора лабаса!

Әргән дигәннән... Вафаның уң кулы бертуктаусыз селкенеп, әллә нинди хәрәкәтләр ясап тора: кем әйткәндәй, әргән уйный!

Габделбәр шуны уйлап кына бетергән иде, Разыя наян сиздермәстән генә егетне төртеп җибәрде; көлә-көлә йөгереп китеп барганда, ул ферманың икенче ишегеннән чыгып каршысына баскан Габделбәрнең кочагына искәрмәстән генә килеп керде... Ә кич Әргән Вафа, Габделбәрләр өендә пәйда булып, төсле музыка уйнатты:

— Ай, разбуйник! Кызны бырачка аппарып тикшертәм, ул-бу булса, катор җибәртәм...

Сизә егет: картның юри генә ачулана, ә үзенең күперенке кесәсе нәрсәдер вәгъдә итеп маташа. Әмма башка тай типмәгән: Әргәннәр белән туган булганчы, юлга ятып тузан булсаңчы, дип әнисенең әйткәннәрен яхшы хәтерли. Шунлыктан һавалы гына әйтеп куйды егет:

— Вафатдин абзый, чынлап та ник килдең син монда?

Карт ык-мык итте, кызарынды-бүртенде, җавап тапты:

— Бабай буласы кешене шулай каршылыйлармы? Оятсыз... Бар, җәтрәк, закускалар хәстәрлә!

---

Мансур ШАҺИМӘРДӘН (1951) — *яшь язучы. «Казан утлары»нда күләмле проза әсәре белән беренче тапкыр катнаша. Казанда яши.*

Ә сәгать ярымнан соң инде кичке тын һавада Әргәннең исерек тавышы яңгырый:

— Кияү-ү-ү! — һәм аны очкылык тотып куя.

— Әкрен, Вафатдин абзый, шаулама,— дип карый Габделбәр әселесуыклы булып, як-ягына каранып. Әмма Вафа аның саен катырак кычкыра. Аптырагач, Габделбәр картны житәкләп, аулак урамнар, караңгы тыкрыклар буйлап өенә илтә китте.

Басманы чыкканда берәм-сәрәм генә бакалар бакылдашып калды. Элек чүп-чар, тирес оясы булган һәм як-ягында әрсез алабута һәм кычыткан үскән таудан Вафаны жилкәгә күтәреп менәргә туры килде.

Атасын каршыларга Разыя чыкты. Ул арада күктә көмеш ай калыкты, тирә-юнь яп-якты булып китте.

Вафаны келәткә кертеп яткырганда, Габделбәрнең кулы ялгышып кына Разыяның түшенә орынды да, егет, кызмачалыгы белән дөньясын онытып, кызны кочагына алды. Аннан соң алар ай яктысына, капка буена чыгып утырдылар. Ләкин Габделбәрнең һич кенә дә тик утырасы килми, аның һаман Разыяга үреләсе, шулай итеп, Зөбәйдәдән туйганчы үч алырга күңеле кыжрый иде...

Бе ра ул Разыяның чәчләреннән энҗе чәчәге исе аңкуын, ә муенында зур г ына коңгырт миңе барлыгын шәйләде. Аннары ул үзен басмадан чыгып бара итеп күрде. Әмма бу юлы нигәдер бакалар аваз бирмәде. Күрәсең, бюрократ житәкчеләрнең күп еллардан бирле: «Теге ярамый, бу ярамый»,— дип тыеп килүеннән бакалар да курка башлаган инде...

Иңкүлеккә төшкәндә чык салкыны тәнен калтыратып жибәрде. Ә үр меңгәндә йомшак жил кырлар ягыннан сусыл, татлы исләр алып килде. Бу исләр әллә ниләрне хәтерләтә, әллә нинди хатирәләрне искә төшерә, юата да, ямансылата да иде.

Габделбәр Зөбәйдәне уйламаска тырышып кайтты. Авыл тын иде. Тын иде, чөнки элекке кебек капка төпләрендә гармун уйнап жырлашып утырулар олылыр хәтерендә генә саклана иде инде.

Габделбәрнең юлында кеше-фәлән очрамады. Һәм егет тыныч күңел белән йокларга ятты. Ләкин дөнья дигән мыштым бабайның күрсәтәселәре алда булган икән әле.

Иртәгесен авыл шау итте:

— Габделбәр — Вафа кияве!

— Габделбәр Разыяга өйләнә икән...

Егет, ачуыннан, күзенә ак-кара күренмичә, арлы-бирле йөренә-йөренә, әйтеп куйды:

— Төкерәм мин Вафа Разыясына! Миңа Зөбәйдә кадерле. Аннан башка миңа берәү дә кирәкми...

Һәм ул, кызны Маһир кулыннан йолкып алу өчен, жиң сызганып көрәш мәйданына чыгарга булды. Элек утырып хат язды ул Зөбәйдәгә.

«Сандугачым!» — дип башлаган иде дә, уйлап куйгач, сандугачка орынмаска итте, сокланырлык башка чагыштыру табарга ниятләде. Аннары гади итеп — «Зөбәйдә! — дип башлады ул.— Әгәр мин Рембрандт яки Рафаэль булсам, иң элек синең күзләреңне ясар идем. Гафу ит, Зөбәйдә, иҗат итәр идем. Ай, ул синең күзләрең! Мин менә, ак биткә кара белән хәреф төшергәндә дә, синең күзләреңнең миңа карап торуларын сизәм һәм, буш, кирәксез сүз яздым, ахры, дип, оялып куям. Син мине һәр төштә күзәтәсең, һәр жирдә ялгышларымны искәреп торасың кебек. Менә шул буладыр инде ул — мәхәббәт!»

Кызып киткәч, ургып чыккан хисләрен туктата алмады. Хәер, аларны нигә дип тыярга? Гашыйк кешенең хисләрен борынгы римлеләр дә чишмә сафлыгына тиңләп жырлаганнар бит!

Хатны күптән түгел генә медучилищеда укып чыккан Зөбәйдәнең ак халат кесәсенә илтеп салды.

Шуннан соң Габделбәр атна буе жавап көтеп йөрде. Икенчесе дә үтте атнаның, өченчесе дә үтә, дигәндә, бер көнне, газиттә хатны укып, авыл

китә язды егет. «Мәхәббәткә мәдхия» дип, парча итеп чыгарганнар бит, әй... Кайсы «оста»ның кулы бу? Маһирныкымы, әллә Зөбәйдәнекеме? Хәер, кемнеке булса да, эш узган инде. Ташка басылганны кырып кара, бар!

Габделбәр, читтән торып, авыл хуҗалыгы техникумында укый. Ул фермада зоотехник булып эшли иде. Шулай булмәсендә кайгырып, һәм бераздан, иртәгә сыерларга ашатылырга тиешле азыкны мөмкин чаклы туклыклырак итәргә тырышып, алдындагы кәгазьгә төрле-төрле саннар язып утырганда, Зөбәйдә күренде. Кызның йөзе-е... Мунчадан чыкканмыни... Ул күкрәкләре — ярышта катнашканмыни! Кулында — гәзит.

— Габделбәрем... Сандугачым... — ди бу еш-еш сулап.

— Нинди сандугач булыйм... Ул — сары, ә мин...

— Гафу ит, карлыгачым!

— Карлыгач та түгелмен. Канатым бөтен...

— Язучы... Язучы син!

Бусын көтмәгән иде Зөбәйдәдән.

— Син бастырдыңмы ул хатны?

— М-м-м-и-ин!

— Моннан ары Маһирга утырып йөрмисеңме?

— Һи-и-и... — дип көлемсерәде Зөбәйдә.

Егет аңлады. Дәлилләүнең кирәге юк иде. Һәм ул Маһирны акылга утыртырга булды.

Рәхәт, җылы кич. Түбәннән генә выж да выж май коңгызлары очып үтә. Май коңгызлары дигәннән... Үзгәртеп кору җилләре исә башлагач, кырларга очкычлардан агу сиптерүне туктаттылар. Шуңа менә май коңгызларының үрчүенә гаҗәпләнмәгез!..

Әнә, капка төпләренә печән таратып салганнар. Кыяк үләне катыш урман печәне исе һавага таралган. Кайдандыр җир мае исе килә кебек. Шул ук урман печәненнәндер, ахры.

Ә өйләрдә утлар, утлар... Авыл кешеләренең көндезге мәшәкатьләрдән арынып, тәмләп чәй эчкән чаклары булыр бу...

Әйе, илдә үзгәртеп кору башланды. Ләкин авыл кешеләре һаман элеккечә шимбә, якшәмбеләрдә ял итүнең ни икәнен дә белмичә «бил бөгә» бирәләр. Хәер, җәйге чиллдә кая инде ул авыл кешесенә ял итү...

Габделбәрләрнең борынына сасы тәмәке исе килеп бәрелде.

Эскәмиядә ир-ат халкы гәпләшеп утыра икән. Иртәгесе көн турында сөйләшәләр, хәзер кереп ятарга кирәк, урак вакыты җитте бит, диләр. Габделбәрнең сәламен дә алмадылар, ахры, әллә ишетмәделәрме?

Әнә бакчадагы көнбагышлар егеткә текәлеп баш чайкап куйдылар. Хәзерге заманга каян килеп чыккан Дон Кихот бу, диделәр бугай.

...«Зөбәйдәне төлке кулыннан йолып алсаммы? — дип уйлый Габделбәр. — Чынлап та булдыклы егет икән бу диярсез әле».

Тукта, чү! Капкаларыннан Маһир чыгып килә түгелме? Шул ич. Кырынган, төзәтенгән. Яшел плащ, ак күлмәк кигән. Яшькелт төймәдәй күзе кара эшләпә астыннан гына көндәшенә төбәлде.

— Һм-м... Ялгыш күрәмме, чынмы? — дигән була.

— Йолдызлар күрсәтимме? — ди Габделбәр.

— Һи-и... Куштирәк төбеннән күреп тә туйган инде аларны!

— Анысы шулайдыр... Вәләкин мин әйткән йолдызларны күрмәгән әле син.

— Йә, күрсәт алайса!

— Мә, күр...

Бераздан, Маһир, торып, плащындагы тузаннарын кагарга керешә. Мәгәр каршылык күрсәтмәде. Ул кичне Маһир кыз янына килмәде. Ә Зөбәйдә тәмам төлкеләшеп беткән икән. Куштирәк төбендә тора да тора көтеп...

Габделбәр түзмәде, поскан урыныннан чыгып, янына килде.

Бизәнгән-ясанган кыз. Кара җирлеккә канәфер чәчәкләре төшерелгән күлмәк, шоколад сыман кофта кигән. Чәчләрен дә кистергән икән. Барыбер чибәрлеге кимемәгән. Менә кара кашлары астыннан гына елмаеп, сөрмә керфекле ике күз егеткә төбәлде.

— Кемне көтәсең? — диде Габделбәр.

— Си-и-и-не-е... — дип җавап кайтарды кыз, егеткә төбәлеп, күзен зур ачып.

— Ялгышасың... Минем урын түгел бу — төлкенеке.

— Ш-шу-лай-мы-ни-и?!

— Шаярма, — диде Габделбәр, — уйнама ут белән, ахырда үзенә янып-көяргә туры килмәгәе...

Зөбәйдә авыр сулап куйды, тамак кырды һәм тавышына үкенүле тон чыгарып әйтте:

— Нишлим соң, Габделбәр? Барлык кызлар йөргәндә, мин генә өйдә ятыйммыни?..

— Йөр син... Түлке төлке белән түгел...

— И-и-и, Габделбәр, үзең беләсең ич, безнең авыл кызлары солдаттан кайткан егетләрне аеруча яраталар.

Бәгырьне телеп ташлагандай итте аның бу сүзләре. Менә сиңа, мә! Илдә демократиягә юллар ачылгач, ни әйтсәң дә бата, дип уйлыйммы әллә бу кызый актыгы... Ярый алайса, көт төлкеңне! Һәм Габделбәр кырт кына борылды да су буйлап кайтырга юнәлде.

— Габделбәр... Габделбәр... Тукта-ле, аңламадың син мине...

— Мин үземә тиешлесен аңладым инде, калганын төлкеңә аңлат...

...Моңсу көз. Селтеле, кислоталы ашлама-фәлән эрегән сулар агып төшеп, зифа талларны корытып юк иткән вә җикән камышларны Кызыл китапка кертеп калдырырлык дәрәҗәгә китереп җиткергән хәвефле елларның чишмәсез һәм сусыз елгаларына карап төшкәч, нигәдер, кычкырып елыйсы килә башлый... Их, елар иден дә бер бушаныр идең. Ләкин шунысы бар, елап кына файда юк шул. Авыр, бик авыр...

Әнә, элекке түрәләр тарафыннан киселеп бетми калган урманнар да инде шәрә... Тиле җил бакчадагы агачларның соңгы яфракларын өзгәләп очыртты. Хәзер менә, күкнең төбе тишелгәндәй, атналап яңгыр коя. Ләкин җирдә барган тормышны күктән таш яуса да туктата алмас инде, юк, туктата алмас! Мәгәр, батырлар янында өркәкләр бар дигәндәй, яшәү янәшәсендә дә һәрчак үлем сагалап йөри. Әмма шулай да яшәү үлемнән йөз-мең мәртәбә көчлерәк булырга тиеш! Шулай булмаганда исә җирдә яшәүнең мәгънәсе калмаячак!..

Район хәрби комиссариаты ишегалдында армиягә китүчеләрне автобуска төяү бара иде. Дистәләгән төркем, бергә укмашып, автобусны чолгап алган. Һәр төштә саубуллашканда тиешле сүзләр әйтелә, киңәшләр ишетелә, вәгъдәләр бирелә. Инде яңгырга игътибар итүче дә юк. Лычма юеш булган кешеләр туганнарын, дус-ишләрен, якыннарын, сөйгәннәрен, соңгы мәртәбә күреп, карап калырга ашыгалар.

Тәрәзәдән такыр башларын чыгарган егетләрнең берсе, төркем өстенә күз атып, моңлы итеп җырлап җибәрде:

> Китәм инде — каласыз...
> Кала җәйгән урыннарым,
> Сагынсагыз карарсыз.

Җырлаучы — Габделбәр иде. Ул күзләре белән озатучылар арасыннан Зөбәйдәне эзләде.

Әнә ул, ике күзен мөлдерәтеп, Габделбәргә карап тора. Бу — аларның яңадан табышулары, сүзсез генә булса да, аңлашулары иде.

... Көннәр үтә торды. Габделбәрнең солдатта хезмәт итә башлаганына бер ел тулып узды. Бу вакыт эчендә Габделбәргә Зөбәйдәдән сәлам

хатлар килеп торды. Ләкин хат — хат инде ул. Аларның берсе дә Зөбәйдәнең үзен алыштыра алмый.

Инде менә егет кыска вакытлы ялга, туган авылына кайтып килә. Зөбәйдәсен күрергә.

... Кояш офык читенә якынлашкан.

Авылга ике яктан бормаланып-сырмаланып тузан болыты кереп бара. Күп тә үтми, авыл эчен мөгерәшкән, бәәлдәшкән, «бәрәш-бәрәш», «маһ-маһ» дип чакырган авазлар күмеп китә. Һәммә кешегә эш чыга.

Чиләкләр шылтырый башлый. Моңа чаж-чож итеп сыер сауган тавышлар кушыла.

Арканнар әзерләнә, казыклар юныла.

Бала-чага мал-туарны җәйләүгә куып алып китә. Алар анда, чырчуга күмелеп уйнап йөргәндә, автобустан Габделбәр абыйлары килеп төште.

Үскән, тазарган. Җилкәсе куна тактасыдай киң. Йөзендә — нур, күзендә — сагыну, соклану һәм сәерсенү галәмәте... Дөньяда, илдә күпме үзгәрешләр бар инде, ә туган авыл әле һаман элеккечә яши бирә кебек.

Солдат егет кибет янында басып торучы һәм элеккечә, авылча киенгән абыйлар, элеккечә көтүдән кайтмый калган бәрәннәрен эзләргә чыгучы апайлар белән исәнләшә-исәнләшә үз өенә таба атлады. Өйләрдә ут ала башлаганнар иде инде. Габделбәрләрнең дә почмак ягында нәкъ элеккечә яп-якты булып ут балкый иде. Ә әтисе белән әнисе ишегалдында нәрсәдер эшләп йөриләр иде.

Капкадан кергән яшел гимнастеркалы солдатны беравык танымыйча тордылар. Ә танып алгач, икесе дә, элеккечә сөенә-сөенә сөекле улларына ташландылар.

— Исән сау гына кайттыңмы, улым!

— Так точно! Әйбәт, бик әйбәт,— дип горур гына җавап кайтарды егет.

Ниһаять, өйгә керделәр. Өй эчендә үзгәрешләр байтак иде: гөлләр арткан, Габделбәрнең солдат рәсеме зурайтылып диварга куелган, ак якка затлы чаршау эленгән, төсле телевизор пәйда булган.

— Болар хәзер бер җирдә дә сатылмый бит, каян алдыгыз?— дип сорау бирде Габделбәр, башы белән телевизор тарафына ишарәләп.

— Колхозга алып кайталар. Аннары шобага салалар. Бу юлы шобага миңа чыкты да, телевизорны мин сатып алдым,— диде Гасыйм абзый көлемсерәп.

Китаплар да күбәйгән. Язу-сызу өстәлендә кочагы белән гәзит-журнал ята. Сүз иң элеккеге авыл тормышы, колхоз хәлләре турында барды, аңа дөньядагы вакыйгалар килеп ялганды. Аннары, илдә барган үзгәртеп коруларга үзләренчә бәя бирә-бирә, ата белән ана балачакларына әйләнеп кайттылар.

— Минем әти бик тырыш иде. Ике ат җигә, өч сыер асрый иде. Колхозлашу чыккач, атларны да, сыерларны да суеп, боз базына тутырды... Ит ашалып беткәч, ачыга башладык... Колхозга керүчеләр дә мантымады, алар да ачыкты...

Хатынының сүзләрен ияк кага-кага гына тыңлады Гасыйм-Зарифулла абзый. Элекке чак булса, ул хатынын: «Синең атаң кулак, контр, ә син — кулак калдыгы, ишетәсем дә килми, сөйләмә»,— дип кенә бетерер иде дә бит... Хәзер әнә бу «спектакль»нең киресе күзәтелә. Кызганыч, бик кызганыч, әлбәттә. Чөнки, Зарифулла — сугыш чорында партия сафларына кергән, «Туган ил өчен, Сталин өчен алга!» дип атакага башлап күтәрелгән кеше. Берлинны алып кайтканнан соң ул, югары партия мәктәбен тәмамлап, төрле авылларда партоешма секретаре булып эшли. Халык арасында дингә каршы аяусыз көрәш алып бара... Ә хәзер динне янә халыкка кайтаралар, элек ябылган мәчетләрне ачалар, яңа мәчетләр салалар, мулла булырга телисең икән, укыталар... Шуңа күрә Зарифулла абзыйның хатынына каршы әйтер сүзе юк.

Зарифулла дигәннән... Аның мулла кушкан исеме — Гасыйм. Ләкин авыл советында метрикә кенәгәсе тутырганда сәркатип бик белдекләнеп әйтеп куймасынмы: «Гасыйм — русчага тәрҗемә иткәндә — Гасим, погасим, ягъни, сүндерү була... нигә инде баланың якты хыялларын вакытыннан элек карангылатырга! Давай, без аны Зарифулла дип, язып куйыйк. Болай, русчага тәрҗемә иткәндә дә матур һәм мәгънәле чыга. Подумайка... Зари... За-р-и-и, ягъни, таңнар туа, димәк, киләчәге бар баланың! Яздыкмы?»

Әмма, туу таныклыгында Зарифулла исеме чекерәеп торса да, малайның икенче исеме — Гасыйм да онытылып калмый. Шуннан бирле озак еллар үтә, бик күп сулар ага, ә абзыйны әле һаман да кемнәрдер Гасыйм дип, икенчеләре исә Зарифулла дип йөртә бирә.

Фирдания түти, ире белән бәхәстә өстен чыгуына куанып булса кирәк, зур коңгырт күзләрен тутырып елмайды да Габделбәргә эндәште:

— Миңнисалар бүген яшьләр жыя. Сиңа да әйттеләр, улым!

— Әнисе алдый иде. Чөнки Миңниса Габделбәрнең бүген армиядән кайтып төшәчәген белми иде. Шуңа күрә ул аны яшьләр янына берничек тә чакыра алмый иде. Әмма медальнең икенче ягы да бар бит: чакырылмаган җиргә, яшьләр янына солдат егет килеп керсә, аны кем куып чыгарыр икән?

Менә Габделбәр Миңнисаларда Зөбәйдә белән күзгә-күз карашып утыра. Әргән Вафа Разыясы да солдат егеттән күзен ала алмый. Ләкин Габделбәр шундый сагынган Зөбәйдәне, караган саен карыйсы гына килеп тора!

Менә берзаман көлешә-көлешә Маһир белән китапханәче кыз килеп кермәсеннәрме... Сөйләшеп, киңәшеп куйганнар, ахры. Габделбәрнең кайтканын белгәннәрдер инде. Маһир Зөбәйдәгә таба атлады, китапханәче кыз — Зөбәйдәнең икенче ягына, ә Разыя Габделбәр янәшәсенә күчеп утырды. Утырды да, кершән-хушбуй исләре аралаш балкып, пышылдап куйды:

— Кайттыңмыни, бәгърем? — һәм ул җавап биргәнне дә көтмәстән чибәрлеге, затлылыгы белән масаеп, барлык кызлардан үзен өстен санап, һаваланып, Зөбәйдә ягына ишарәләде:

— Кара, кара, теге кыланчыкны, кәпәренеп утырган була...

Зөбәйдә Маһир яныннан күчеп утырган иде. Габделбәрнең дә түземе төкәнде. Ул торды. Ишеккә күрсәтеп Зөбәйдәгә ым какты.

— Габделбә-әр?! — диде Разыя инәлеп.

Егет аны ишетмәмешкә сабышты. Зөбәйдәгә ияреп чыкты... Өйалдында караңгы иде. Кызның кайнар сулышы егетнең муенын көйдереп алгандай булды. Кыз да үз йөзендә егетнең утлы сулышын тоеп, кымшанырга да диярлек куркып басып торды. Бу вакытта йөрәкләр генә серләшә, сүзләрнең хаҗәте юк иде.

... Алар урамда озак кына йөрделәр. Сер тулы күккә бактылар. Йолдызларның атылуын күзәттеләр. Су буена төшеп, куштирәк төбенә утырдылар.

— Менә мин дә солдат булдым, — диде Габделбәр. — Син бит, кызлар солдатта булган егетләрне генә яраталар, дигән идең...

— Хезмәтеңне бетереп кайтасың бар әле, җаным!

— Аннары — вәгъдәме?

— Вәгъдә!

Габделбәр көчле бер омтылыш белән Зөбәйдәне кысып кочаклап алды һәм үзенең йөзен кызның йөзенә якын ук китерде. Шулвакыт әллә каян гына килеп чыккан катлы-катлы болытлар арасыннан Ай үрелеп, җиргә карады. Егет белән кыз, дөньяларын онытып, үбешәләр иде инде. Һәм шуннан соң Габделбәр белән Зөбәйдә таң атканчы, күктә, йолдызлар югалганчы, бер-берсеннән аерылыша алмадылар.

Ниһаять, ул көн сизелмичә үтеп тә китте. Габделбәрне янә хезмәт урынына озатып җибәрделәр... Тагын шул ук яшел поезд, борынгы

станциялəр, күңелсез разъездлар, шул ук сирəк-мирəк урманнар, «майлы», болганчык сулы күллəр, өстəн кушу буенча сукалатып бетергəннəн соң берни дə үсми торган файдасыз кара «болыннар», шул ук аксыл болытлы офыклар... Ə алда — килəчəк, Зөбəйдəнең вəгъдəсе бар!

Табигать барыбер үзенекен итə.

Менə тагын декабрь керде. Кичə генə ат арбасының көпчəклəре туң җир өстендə дыңгырдый-дыңгырдый тəгəри иде. Бүген инде күктəн болытлар төшеп яткан диярсең, гүя, бөтен дөнья ап-ак карга төрелгəн. Болайга киткəч, ат чаналарына түземлек бирсен! Башланды туйлар авылда...

Кыңгыраулар чыңларга тотынды, тальяннар моңланды, курай үкседе...

Элекке елларда туй-фəлəннəргə кода-кодагыйларны автобусларда, «Жигули»ларда, «Волга»ларда ташып ду килгəн авыл кинəттəн генə үткəндəге уңай күренешлəргə йөз белəн борылды. Хəзер туйларга кода-кодагыйларны атларда ташыйлар: шулай кирəк авыл өчен, шулай əйбəтрəк!

Ənə шундый вакыйгаларга бай, күп бизəкле, шаулы көннəрнең берендə, юлда маhабəт гəүдəле солдат күренде. Ул шинель изүлəрен чишеп җибəргəн, ашыкмыйча гына, уйланып кына атлый.

Аның күңеленə бала вакытындагы чирəмле авыл урамнары кереп тула. Əйе, кайчандыр авыл урамнары ямь-яшел чирəмле булган бит. həм тагын чирəмле булыр əле! Килəчəк көннəр турында шундый күңелле итеп уйлагач, Габделбəр шушы кышның, яшəүнең, тормышның гел уңай якка гына үзгəрəчəген тагын да ачыграк, тагын да тирəнрəк тойгандай була. Ул тирə-юньгə əсəрлəнеп карый. Юллар чатында элек «җенле карама» басып торган урын да, сукалап юк ителгəн борынгы зират та, аның янəшəсендəге (Болгар бəге утырткан) меңьяшəр өч нарат та Габделбəрнең хəтерендə саклана əле. Лəкин алар турында килəчəк буыннар берни дə белмəс инде... Менə ничек халыкның үткəненə балта чапканнар, аны тəмам хəтерсез итəргə телəгəннəр həм шундый юл белəн урыс булмаган миллəтлəрне тулысынча юкка чыгарырга уйлаганнар икəн, həм шулай итеп, илдə тоташы белəн рəхимсез сəяхəт үткəреп, дөньяда беренче булып төзелгəн социалистик дəүлəтне эчтəн черетеп ятканнар лабаса. Лəкин нишлисең? Буласы булган... Инде, бу ялгышларны hичбер вакытта да кабатламыйча, алга таба барасы да барасы иде...

Габделбəр авылга керде. Иң башлап, күзенə Зөбəйдəлəр өе чалынды. Ənə шул елга аръягындагы өйнең тəрəзəсеннəн аны сөйгəн яры күзəтеп торадыр сыман тоелды. Егетнең тиз, бик тиз күрəсе килде кызны. Лəкин...

— Маhир урларга йөри əле кызыңны, — дилəр аңа. — Эңгер төшүгə сыйланып чыгалар да Зөбəйдəне сагаларга керешəлəр.

Габделбəр кайтуның икенче көнендə Вафа Разыясы да солдат хөрмəтенə зур итеп аулак өй үткəрергə, Габделбəрне «Ламбада»га биетергə уйлаган, имеш. Күңеле каршы торды, бармады егет. Соң инде, Зөбəйдə белəн сүз куелган, вəгъдə бирелгəн, нигə, кеше теленə кергəнче, сузып торырга...

Габделбəр, турыдан ярып, Зөбəйдəлəргə таба китте. Кар ява иде. Буага җитəрəк көчле буран купты. Габделбəр җилдəн, бураннан перчаткасы белəн йөзен каплап барды.

* * *

Бу вакытта Маhир иптəшлəре белəн капка төбендə Габделбəрне сагалап тора иде. Ə күңелендə — Габделбəргə дə, Зөбəйдəгə дə кагылышы булмаган уйлар.

... Аны əнисе урак өстендə, Мəскəү тавы кашлагында, карт шомырт төбендə тулгаклап тапкан... Мəскəү тавы дигəннəн... Əби патша полков-

нигы әнә шул тауны Пугачев кулыннан сугышып алганга күрә, халык ул тауга шундый сәер исемне кушкан. Һәм бу тарихи исемне халык күнелеңнән бер генә түрә дә йолкып чыгара алмаган. Чөнки тау зур, аны сукалап бетереп тә, иштереп тә юк итеп булмый.

Әйе... Маһир, әнисенең сөйләвенә караганда, карап торырга ярыйсы гына күренсә дә, холыксыз нәрсә булып чыккан. Көнозын йоклый-йоклый да төнозын акыра-бакыра елый икән. Ә ата кеше тешен кысып ята-ята да, түзем савыты мөлдерәп тулгач: «Һай тамаша, кешенеке түгелдер, җен баласыдыр бу»,— дип, мендәрен алып печәнлеккә юл тота икән...

Алты яше тулгач, Маһир әтисенә ияреп эшкә йөри башлады. Алар таң сызылып килгәндә китәләр һәм күктә йолдызлар балкып янганда гына кайталар иде. Маһир шулай, әтрәднең чуар халкы арасында кайнашып, каешланып бетте. Аны яхшы ук сүгенергә дә өйрәттеләр. Эчкечеләр бер-берсен сыйлаганны карап торганда яннарына чакырып, сыра чөмерергә һәм: «Ничава, братцы, без моның кебек чакта ат жигеп сука сукалый идек»,— дип каты градуслыны да йоткаларга өйрәттеләр. Аннары тәмәке суырырга да хирысланды Маһир. Уналты яше тулганда Маһирның, атаман, башкисәр, жулик шикелле кушаматлары бар иде инде.

Алга таба ул ничек яшәр иде икән? Бәхетенәдер, шул җәйне каладан күрше Нәгыйм абзыйларга бер кунак кызы килде. Зөбәйдә исемле иде ул. Маһир бер күрүдә үк аңа баш-аягы белән гашыйк булды. Һәм шуннан соң җәйнең җәй буенча малай кая басканын да белмәде, тиле хыял канатларында, дөньяны кочып сөярлек булып йөрде. Яшәүнең асылын, җирнең матурлыгын моңарчы күрә белмәвенә гаҗәпләнде. Әйтерсең лә җилләр аның өчен генә исәләр, чәчәкләр-гөлләр аның өчен генә хуш исләр тараталар, кошлар аның өчен генә сайрыйлар, чишмәләр аның өчен генә челтерәп яталар, җиләкләр аның өчен генә пешә, Зөбәйдә дә аның өчен генә яши... Мона, әлбәттә, Зөбәйдәнең Маһир сеңелесе Роза белән дуслашуы да ярдәм иткәндер... Аннары, Маһирның кызыл матае бар иде. Дөресрәге, әтисенеке. Ләкин ул аны әтисе өйдә юк чагында кая тели шунда алып китә ала иде. Ә Маһир, матайны кулга төшерү белән үк, «выж» ындыр артына! Анда аны Роза белән Зөбәйдә көтеп тора...

Маһир кызларны артка утырта да, иркен һавадагы тургай сыман, җырлый-җырлый кыр юлы белән элдерә генә... Шул елны комбайнда эшкә керешкәч, Зөбәйдә белән Роза Маһир янына комбайнга утырып йөрергә дә килә башладылар. Алар, хәйләкәр, турыдан-туры утырып йөрергә дип түгел, ә ашарга алып киләләр. Килгәч, билгеле инде: рәхим ит комбайнга!

Зөбәйдә ялындырып тормый, сөрмә керфекле зур кара күзен тутырып бер карый да: «Ну, джентельмен, монда — җирдә ничава күренәсең дә, тегендә, һавада ничегрәк икән»,— дигән булып, сумаладай кара чәчләрен ялык-йолык иттереп комбайнга менеп китә.

Шулай берничә ел вакыт үтте. Зөбәйдә каникулларның һәммәсенә кайтып йөрде. Ул, үзе тумышы белән шәһәрнеке булса да, авылны ярата иде. Күрәсең, аны авылга ата-бабалары каны тарткандыр. Һәм, ниһаять, Маһир армиягә китәсе елны, Зөбәйдә әнисе белән авылга бөтенләй үк торырга кайтты. Алар түбән урамда, су буендагы йортны сатып алдылар.

Зөбәйдә артыннан Габделбәр йөри башлаган ел иде бу. Әмма аларның бу «мавыгу»лары бала-чага уенын гына хәтерләтә иде кебек. Чөнки Маһир: «Зөбәйдә минеке генә...» — дип уйларга күнеккән иде. Армиягә дә шундый татлы уйлар белән китеп барды. Аннан өйләнеп кайтканда, Зөбәйдә тәмам өлгергән, медпунктта «врач» булып эшкә керешкән иде. Ә Габделбәр фермада «кашевар» икән. Маһирны кайтуы белән котлап күрешкәндә үк эсселәтеп җибәрде. Аю көче бар иде егеттә. Шунысы бигрәк тә сагайтты: Габделбәр кыз артыннан чаба бирә икән. Ошамады

бу Маһирга. Ул җәтрәк, тимерне кызуында сугарга ниятләп, фермага эшкә керде. Армиядә укып, шоферлыкка таныклык алган иде, ярап куйды. Мичкәле машина белән комбинатка сөт ташый, Зөбәйдәне дә күздән ычкындырмый, җай табып (кыз райүзәккә барганда, йә кайтканда) утыртып та китә башлады.

Кыз Маһирныкы... Ул аны үлсә дә кулдан ычкындырмаячак. Булдырыр абзагыз!

Әмма бер кичне Габделбәр, өйләре буена килеп, искәрмәстән генә Маһирны тәпәләп китте. Ай-һай, шәп сабак булды бу. Егет хәзер планнарына яңа алым, тактикага кыю үзгәрешләр кертелергә тиеш дип саный... Бәхеткәдер, шул көннәрдә Габделбәр армиягә китеп барды. Ләкин Габделбәр армиягә китү белән генә эш үзгәрмәде шул. Зөбәйдә коточкыч үҗәтлек белән егетнең тәкъдимнәрен кире кага торды.

Маһирның кыз туганы Разыя бар ич әле. Разыяның: «Габделбәр...»— дип утларда януын белә иде. Ниһаять, кирәге чыгып куйды. Бер җай табып, ул кызга аңлатты:

— Габделбәрне яратасың икән, сөюең үзеңдә генә торып калмасын, егетеңә дә күчсен, аның да йөрәген телгәләрлек булсын...

— Аңладым, абый! — диде Разыя тәэсирләнеп. — Мин моны син әйрәткәнчә эшләрмен...

Бу сөйләшүдән соң ярты ел үтте. Габделбәр ялга кайтты. Кайткан көнне үк Миңнисаларда яшьләрнең күз алдында Зөбәйдәне үзе белән алып чыгып китте. Разыя янындагы урын бушап калды. Шулай итеп, бу икәүнең бар тырышканнары җилгә очты. Әмма моның белән килешергә теләмәделәр, максатларына ирешү өчен башка чара кулланып карарга булдылар. Бит кичләрен Зөбәйдәне ялгызын гына очратып булмый, инде аның янына Габделбәрне җибәрмәскә, ничек тә булса тоткарларга тырышырга, һәм аннары, җаен-чарасын табып, Зөбәйдәне Маһирга урларга кирәк...

Аллага тапшырдык!

* * *

Кинәт дөнья бозылгандай булды. Буран өермәсе купты. Пәри туе ясап җил чыелдады. Берничә минут элек кенә Габделбәргә барысы да ал да гөл сыман иде, хәзер бер нәрсәнең кызыгы калмады. Тәне җелеккә үтәрлек салкыннан оепката башлады. Ул зәһәр җилдән, әче бураннан йөзен томалап та маташмады, йөгерде дә йөгерде. Тизрәк Зөбәйдәләргә барып җитәргә кирәк! Күңелендә — Зөбәйдә генә иде...

Зөбәйдәләргә килеп җитәрәк, ул Фәрхетдиннәр капкасы төбендә дүрт-бишләп егетнең басып торганын күреп алды. Маһирлар икән. Нишлиләр алар монда?!

Габделбәрнең эченнән ялкын бөркелде сыман. Ул җылынып киткәндәй булды. Ялан куллары кызышып чәнчергә керештеләр. Бармаклары сулык-сулык авыртты. Ул нәфрәтләнеп йодрыкларын кысты, эре адымнар белән Маһирлар турысыннан үтә башлады. Аны күреп алдылар, үзләре янына чакырдылар.

Габделбәр ишетмәгәндәй юлын дәвам итте.

Төркем һай-һаулап аны урап алды.

— Җә... — диде Габделбәр, тешләрен кысып. — Күрдегезме? Таныдыгызмы?

— Һи-и-и... — диде сипкел Кәрим алгарак чыгып. — Мин сине... — Ул сүзен дә әйтеп бетерә алмый калды, көлтәдәй киселеп карга мәтәлде.

— Әһ, әле син шулаймы?! — Егетләр өерләре белән Габделбәргә ябырылдылар.

Бер мизгелгә барысы да буталды. Кем кемгә тондырганны да, кем кемнең өстенә егылганын да белерлек түгел иде. Кемдер авызын тотты,

кайсыдыр борынын учлады. Берсе ерткычларча үкереп килде дә диварга бәрелгән түп кебек янә артка очты... Берничә минуттан аяк өстендә Габделбәр белән Маһир гына торып калды.

— Ә сиңа ни өлеш бирим? — дип киң күнелләләнеп сорады Габделбәр.

Маһир куркуыннан агарынып килде, үзе дә сизмәстән, җиң эчендә яшереп торган тимер белән Габделбәргә кизәнде...

Бу хәлләр күз ачып йомган арада булды. Маһир хәтта ни эшләгәнен төшенми дә калды шикелле. Аның «дәһшәтле» кулы зиһененнән елгыррак булып чыкты. Габделбәрнең яралы маңгаеннан сиптереп кан бәргәч һәм егетнең гәүдәсе киселгән агачтай кар өстенә аугач кына исенә килде ул. «Үтердем бит!» — дип коты очып уйлады.

— Егетләр... Кәрим... Сәлим... үлде Габделбәр!

Егетләр ах-вах иттеләр.

— Бетте баш!

Маһир кулындагы тимерен җан ачысы белән көрткә томырды. Кабаланудан тирләп-пешеп пәлтәсен салып атты, майкасын аерып алды. Бу минутта ул эченнән генә дуслары, туганнары һәм Зөбәйдә белән хушлашырга да өлгерде.

— Егетләр, башын күтәрегез инде, башын!

Кәрим белән Сәлим әле һаман куркуларыннан айный алмыйча, дер-дер калтырана-калтырана Габделбәргә иелделәр. Бу ыгы-зыгыда ике яшь егет: «Без берни күрмәдек, безне берәү дә күрмәде», — дип өйләренә җилдерделәр.

Менә ат килде. Габделбәрнең гәүдәсен печән арасына салып, тун белән төрделәр.

— Үлмәсә генә ярар иде, — диде Кәрим авыр сулап.

— Шыңшыма әле, — дип кычкырды аңа Сәлим ачу белән.

— Җебедең инде... Бир әле монда! — дип, Маһир дилбегәне Харисның кулыннан тартып алды. — Фь-фь-юу-уо! — дип яңгыратып сызгырды ул. Яшь айгыр сискәнеп колакларын шәмрәйтте. Маһир аягүрә басты, ләкин шикләнеп тезләренә чүкте, дилбегәне бушайтып чак кына кагып куйды. Сәгатьләр буе ажгырган буранда тик торып боеккан айгыр, көч-дәртен кая куярга белмичә, алагаем алып та китте.

* * *

Телевизорда «Татар хатыны ниләр күрми» спектакле бара. Халыкның ябырылып шуны караган чагы. Барлык өйләрдә балкып утлар яна. Тик авыл уртасына, тау башына салынган фин йортының тәрәзәләре генә караңгы һәм серле төстә дөньяга карап торалар. Шулай да, җентекләбрәк күзәткәч, урта тәрәзәдә тоныклык ак яктылыкның шәйләнүен сизми һич мөмкин түгел. «Күрсәтү тартмасы»ннан таралган яктының шәүләсе бу. Сания әби сызлаулы аякларын юрган астына яшергән дә, ялгызы түрле уйларга бирелеп, спектакль карап утыра. Гөлбануның бәхетсез язмышы, явыз кайнана белән аның улы Закирның җәбер-золымы күңелен тетрәндерә, изә.

Бер дә хаксызга: «Кәнтәй», — дип җикерде кайнанасы, уклауны алып килененә бәрде. Гөлбану иелде, котыла алмады. Анасы ягыннан Закир төште...

Тышта әче җил сызгыра... Карчыкның күзләре яшьле...

Менә Закир, тешен кысып, ачулы дуңгыз күзе белән батырып карап килде дә хатынының җилкәсенә уратып-уратып сукты. Ул Гөлбануга суккан саен, Сания әби сискәнеп-сискәнеп куя иде. Закир гүя, Гөлбануга түгел, аның үзенә суга... И ходаем! Мондый хәлләр Саниянең үз тормышында да булды бит! Фәләхетдин яшь чагында шактый ук кызу канлы, җинел холыклы ир иде. Бары тик кырыкка җиткәндә генә кызуы сүрелә төште, сабырланды, дөньяга аек күз белән карый башлады...

Шул мизгелдә болдыр ишеген кагарга тотындылар.

Сания тетрәнеп куйды, яулык почмагы белән күзендәге яшьләрен сөртте; рматизлы аякларын юрган эченнән чыгарып, идәнгә басты, үрелә төшеп, мич авызыннан пималарын алып киде. Тышта һаман буран җулый иде.

Карчык чыгарга кузгалды, ишек ягында караңгы булгач, дивардагы кабызгычны капшанып табарга туры килде. Һәм менә ул, нык сеңерле, сөякчел бармакларын бер тирәгә җыеп, «кабызгыч нәмәрсә»гә басты. Мизгел эчендә караңгылыкны тәрәзәләргә таба куып, ут кабынды, кинәт чагылудан әби күзләрен йомды, бер мәлгә аның күз аллары кан төсен хәтерләтеп торды. Ниһаять, ул күзләрен ачты һәм чит, ошамаган әйбергә баккандай, сәерсенеп өй эченә күз текәде. Ул бит Гөлбану түгел, яшәгән, авырлыкларны җиңә-җиңә җиде бала үстергән... Шулай да, гомер азагына якынлашып килгәндә, ире Фәләхетдин вафат булгач, ул көтмәгәндә генә ялгыз торып калды. Үз өендә дә түгел әле... Әйе, Саниянең үз йорты белән күршесендәге медпункт бинасы җәйге пожар вакытында дөрлидөрли янып көл булган иде. Бу фаҗигадән соң фин йортының яртысын медпункт, икенче өлешен, читтән килгән фельдшер кыз белән карчык өчен фатир иттеләр.

Сания, гомере буе авылдан чыкмыйча яшәү сәбәпле, бу юлы да үз-үзенә тугры булып калды. Читтәге малайларыннан гайре, тик бердәнбер кызы гына аның янына кайткалап йөрде, ә ул аның янына бармады. «Мине анда кем белә, кемгә кирәк мин»,— дип кенә җибәрә иде сораганда ахирәт карчыкларына. Ләкин сәбәп аннан гына түгел, Сания читтә көтмәгәндә генә үлеп калудан курка иде.

«Монда тудым, монда гүргә керәчәкмен»,— дип уйлады. Ялгышмады. Авылдашларының кешелеклелеге өе янып, бер нәрсәсез калгач ук беленде. Саниягә хәтта «күрсәтә торган әрҗә» дә китереп бирделәр. Иске искесен... Ләкин карарга була әле!

Мәгәр шунысы үзәкне өзә: җиде бала арасыннан авылда яшәп калган бердәнбер малай — Хисаметдиннең ярдәме тимәде карчыкка. Хәер, әбекәй кибетче булып эшләүче бу малаеннан берни дә өмет итми инде. Чөнки Хисаметдин яшь хатынының кубызына биепме бии, ә тегесе дәҗҗалның да дәҗҗалы... Аһ! Аның белән каберең якын булмасын... Ә менә Хисаметдиннең беренче хатыны, Зөбәйдәнең әнисе, алтын иде. Хәзер дә ярдәменнән ташламый әле. Рәхмәт аңа! Әнә, күрше бүлмәдә йоклый ул бала. Кайгы-хәсрәтсез, яшь, чибәр кыз — Зөбәйдә йоклый. Ул бүген районга, конференциягә барды. Юлның яртысын җәяүләп кайткан, шулай булса да ул әбисенең хәлен белеп чыгарга уйлаган... Җәяү кайту арыткан булса кирәк үзен. Чак кына ятып торыйм дип, мендәргә башын төрткән иде, йоклап та киткән, рәхмәт төшкере. Спектакль башланганчы уят, дигән иде кебек. Ничек уятмак кирәк,— бигрәк тәмле итеп йоклый шул.

Янә каты-каты итеп болдыр ишеген дөбердәттеләр. Менә тамаша! Кем булыр бу? Тамара янына килүчеләр дисәң, ул кыз авылына кайтып китте ич. Бәлки, Зөбәйдәне эзләп килүчеләрдер. Маһирлардыр. Шул Маһир бит инде Зөбәйдәне урларга йөрүче... Ә бәлки...

Сания карчык яманга юрамаска тырышып, эченнән укынып, ишекне ачып җибәрде. Шундук усал җил салкын сулышын өрде, буран комы сибәләде, битләрне чеметтереп-чеметтереп алды. Тагын ишек тукылдаттылар. Әмма әби бусын ачарга ашыкмады, сораштырырга тотынды:

— Кем ул шакый? Нишләп йөрисез?

Тыштан, буран шавы аралаш, өзек-өзек җаваплар ишетелде.

— Менә... егет... килдек, хәле авыр...

— Ул-лә-ә-ә!..

— Ти-з-рә-әк ач...

— Хәзер ачам.

Карчык урелә төшеп, ишекнең keләсен ычкындырды, гүя, тилертә торганны ашаган һәм шуңарга котырган шашкын, ярсулы җил бар куәтенә каерып, ишекне ачып ташлады. Сания бер мәлгә авыз ачып сүз әйтү түгел, сулыш та ала алмыйча торды. Ачык ишектән ургылып кергән тыгыз җил карчыкның тын юлларын кисте һәм ул, башын янлый борып, кулы белән йөзен томаларга мәҗбүр булды. Күз-керфекләренә кар сыланды. Болдыр каршында басып торган, ап-ак кар сарган өч-дүрт егетне, ап-ак атны, чанада, печән өстендә яткан тунны көчкә шәйләп өлгерде. Ә тун астында, аңсыз булып, кемдер ята, ахры. Әби, эчке сизенү белән эшнең хикмәтенә төшенеп, оныгын уятырга ашыкты. Аннары, кирәк булыр дип, бүлмә саен ут кабызып чыкты. Ул арада өйгә салкын иңләп кергән егетләр, Габделбәрне идәнгә салып, чишендереп азапланалар иде. Габделбәрнең киемнәре тиз генә салынмый... Маһир хәтта җилкә чокыры буйлап тир агуын сизде. Әнә Кәрим дә җиңе белән маңгаендагы тирләрне сыпырып алды. Һәм Сәлимнең дә борын очыннан әллә тир, әллә эрегән кар суы идәнгә тып-тып тама иде.

Ниһаять, Зөбәйдәнең йомры тезләре, ак халаты һәм килешле генә биек маңгае күренде. Аның ай тик йөзе элеккечә горур, ә күзләре утлы күмер кебек өтеп ала иде.

— Бирегә кертеп яткырыгыз,— диде ул, каршындагы бүлмәнең ишеген ачып. Боерык бирелүгә үк каударланып бүлмәгә ташланган егетләрнең борыннарына эфир һәм йод исе килеп бәрелде. Зөбәйдә Габделбәргә таба иелде, пульсын капшап карады. Кемнеңдер кулына спиртлы шешә тоттырды, каты итеп эндәште: «Тиз... тәннәрен уыгыз!» Ә үзе маңгайдагы канланып каткан җәрәхәтне сөртергә керешге. Сания әби йөзен чытты. «И җанашым, и бәгърем»,— дип куйды һәм эченнән генә дога укырга тотынды... Җәрәхәт тирән һәм куркыныч иде. Икенче караш ташлаганда ул гади булып, күптәнге кызыл чүпрәкне хәтерләтә иде. Егетләр, безнең эш бетте дип, шыпырт кына чыгып китмәкче булдылар, әмма әбинең егетләрне тиз генә чыгарып җибәрәсе килми иде. Ул бу хәлнең сәбәбен төпченергә, сорашырга тотынды. Ә Зөбәйдә, яшь аралаш нәфрәтләнеп, егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә төбәлде, җавап көтте.

— Белмибез...— диештеләр егетләр каушап.

— Белмибез...

— Белерсез әле, бәлдерерләр!

Ләкин карчыкка җавап бирүче булмады.

* * *

Зөбәйдәнең әнисе, Зәлия ханым, булачак киявен көтте. Билгеләнгән сәгать күптән үтте инде, тавык шулпасы да, пешергән пәрәмәчләр, өчпочмаклар да суынып бетте, самавырны да ике тапкыр яңартып алды, ә Габделбәр юк та юк. Җитмәсә, Зөбәйдә дә күренми. Кайда йөри икән ул? Ни булды икән аларга?

Зәлия ханым чын-чынлап хафага калды, чыгып капка буйларыннан әйләнде. Әмма урамга ук аяк басарга җөрьәт итмәде. Җил-бураннан шүрләүдән түгел, юк. Дөресрәге Маһирдан курка ул. Маһир иптәшләре белән кичләрен өй каршыннан җырлап узгалый башлаганнан бирле курка. Маһир болай дип җырлый иде:

... ай ли Зөбәйдә,
Зәлия апа, Зөбәйдәне
Миңа кияүгә бир әйдә!

Зәлия ханым Маһирга һаман бер төрле итеп әйтә торган иде: «Йөрмә болай, энем, килешми, үзеңә тиң кыз тап! Зөбәйдәнең сөйгән егете бар бит!» Маһир исә кызып китә, кычкыра башлый иде: «Мин

барыбер Зөбәйдәне үземнеке итәм!» «Әгәр ул... теләмәсә?» «Урлыйм мин аны... атка салам да урлап китәм, элекке заманда кыз урлаган кебек итеп... Мин кемнән ким?!»

Менә сөйләш син аның белән, бәхәсләш. Син аңа бер нәрсә турында әйтәсең, ә ул һаман үзенекен тукый. И Маһир, мәктәптә укыган чакта ук шундый кире бала булган идең син. Яхшы да укымый идең, артка да калмый идең. Тәмәкене пошкыртыпмы пошкыра идең, сүгенә дә идең әле... Дөресен генә әйткәндә, күрмәгәнне күрсәттең инде син безгә!.. Аннары, мәктәпне бетереп чыккач, синнән котылдык, дип уйлаган идек... Озакламый тагын менә минем башка бәла булып куйдың...

Шулай уйланган Зәлия ханым урамга чыкмаган иде. Чыкса, каршына Маһир килеп басар да, кызыңны миңа кияүгә бир инде дип, өзми-куймый аптырата башлар сыман иде.

Зәлия ханым кызы уйнаганнан соң урындыкта онытып калдырган мандолинаны сак тотып футлярга салды, илтеп урынына элде, аннары, укучыларының дәфтәрләрен сумкасыннан алып өстәлгә куйды да тикшерергә кереште. Ул — татар теле укытучысы. Казанда сиксәненче мәктәптә татар теле укытты. Гомумән, туган теленә, туган халкына мәхәббәте көчле аның. Һәм ул бу мәхәббәтне, тамчылап-тамчылап булса да, үзенең укучыларына да өләшә иде, өләшә ала иде. Һәм ул шуңарга сөенә, шатлана, һәм шуның белән горурлана иде. Ә инде, көннәрнең берендә, интернационалист татар түрәләре үзләрен милләтчелектә гаепләрләр дип шыр җибәреп, сиксәненче номерлы татар мәктәбен дә урыс мәктәбе итеп куйгач, Зәлия ханымга татар иленең башкаласында рәт калмады. Һәм ул, газиз татар милләте өстенә ажгырып, үкереп килгән шовинистлар поезды астында калып тапталырга, изелергә, юкка чыгарга теләмичә һәм бу бәладән кызын да саклап калырга исәп итеп, әти-әнисенең туган авылына (ул үзе Казанда туып үсте) кайтты. Бу вакытта Зәлия ханымның икенче ире — Зөбәйдәнең атасы — Хисаметдин өченче яшь хатыны белән (аның икенче хатыны авырып үлгән иде) нәкъ шушы авылда яшәп ята иде. Хисаметдин, яшь хатыны белән бергә, кибеттә сатучы булып эшли иде. Зәлия ханымның, капылт кубып, авылга эшләргә кайтуы турында кешеләр дөньяга ниләр генә чыгармадылар да, ил-йорт буйлап ниләр генә чәчмәделәр. Мәгәр Зәлия ханым бернигә дә карамыйча, авыл мәктәбендә, үзенең җаны сөйгән татар телен укыта бирде: татар авылында, татар балаларына, татар теленә, татар әдәбиятына бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт тәрбияли бирде. Зәлия ханым аңлый иде: бары тик телен яхшы белгән, аны җаны-тәне белән яраткан кешеләр генә башка халыкларны да үз итә алалар. Ә инде үз теленә җирәнеп, төкереп караган адәм имгәкләреннән нинди ватанпәрвәр чыксын ди, җә? Чын мәгънәсендә — манкорт ич алар! Әйе, манкорт! Һәм менә шул рухи гариләр тора-бара үз милләтенең теленә булган һөҗүмне гаять киң җәелдереп җибәрделәр. Дөрес, алар бу корткычлыкларын аклау өчен: «Өстән кушалар, Мәскәү шулай куша!» — дигән сылтау уйлап таптылар. Ихтимал, анысы да бардыр. Хәлбуки, болай эшләгәндә җиңелрәк бит: иелгән башны кылыч кисми, янәсе. Ә үзәккә татарны телсез калдырып өнсез итү нигә кирәк булган соң? Билгеле, бу халыкны тәмам кол итәргә, һәм татар илен йөз процент кабалага төшерү өчен кирәк болай эшләү. Дөрес, алар бу планнарны, коммунизм дигән хыялый теория белән купшыландырып һәм уракчүкечле кызыл байрак артына яшереп, «Дөньяны капиталистлардан арындырабыз һәм андагы барлык халыкларга да ирек, азатлык яулап бирәбез!» — дигән үтә кызыл лозунглар язып куя-куя, тормышка ашырырга керештеләр. Әмма... нәтиҗәсе аяныч!

Зәлия ханым менә шундый уйлар уйлый-уйлый дәфтәрләрнең соңгысына җитте. Бәй! Бусына: «Серебристая Река мәктәбенең... нче класс укучысы...» дип язылган лабаса! Татар теле дәфтәренең тышына, татар авылында яшәүче татар баласының уң кулы белән сырлап-бизәкләп, «Серебристая Река», дип язылган. Бу — мөселман Хәбибнең үз теләге

белән христиан диненә кочүе белән бер бит инде, мөэмин мөселманның чукынуы белән бер. Дөрес, бирәдә татар баласын гаепләп тә булмый. Гаеп, Көмеш Елга дигән зур татар авылының исемен урысчага әйләндереп язып куелган булуда. Ә аны башлап кем шулай язган соң? Әлбәттә, өстән кушу буенча манкорт түрәләр язган. Һәм шул ук манкорт түрәләр, көннәрнең берендә, шул ук татар авылындагы татар мәктәбен, халыктан рөхсәт сорап-нитеп тормыйча, урыс мәктәбе иткәннәр дә куйганнар. Хәзер инде Зәлия ханым, татар авылындагы, татар балалары укый торган урыс мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты дәресләре алып бара. Мәктәпнең директоры Зәлия ханымга адым саен аяк чала, укытучыга дәресләрне үзе теләгәнчә алып барырга ирек бирми иде.

Укучылар үзара урысча гына сөйләшеп йөри башладылар. Моңа татар авылындагы балалар бакчасында тәрбиячеләрнең маржа булулары нык ярдәм итә иде. Ә, шул ук вакытта, үзебезнең татар милләтеннән булган тәрбиячеләребез урыс авылларында эшләп ятмышлар. Әлбәттә, алар урыс балаларында татар теленә карата мәхәббәт тәрбияли алмыйлар. Һәм аларның моңа мөмкинлекләре дә юк, кыюлыклары да, кем әйткәндәй, тездән түбән генә.

«Әйе, юк!» — дип пышылдады Зәлия ханым, йодрыкларын төйнәп, тешләрен кысып. Әгәр ул хокук дигәнең чынлап та булса, авыл кешеләре узган ел, Татарстан җөмһүриятенә депутатлыкка кандидатлар күрсәткәндә, тавышның күбрәген, районга килеп бер ай да эшләп карамаган чит башлыкка түгел, ә халыкның сөекле җырчысы Әсәдуллинга биргән булырлар иде. Монда да халык гаепле түгел инде. Чөнки халыкка тагын өстән, депутат итеп Әсәдуллинны түгел, ә яңа башлыкны сайларга куштылар. Әгәр дә мәгәр аны сайласагыз, сезнең бар теләгегез дә үтәлер, сез бик бай, мул тормышта яшәрсез, диделәр.

Нишләргә соң? Нишләргә? Хәер, мондый чакта укытучы кешегә икеләнеп торырга урын юк! Укытучы кешенең вазифасы — халыкның милли хисләрен кузгатып җибәрү, балалар һәм ата-аналар арасында сәяси агарту эшләре алып бару. Аннары, Маһир тирәсендәге егетләрнең дә энергиясен милләт мәнфәгатьләренә таба юнәлдерергә кирәк! Моның өчен алар белән уртак тел табу фарыз...

Зәлия күңелендә туган әлеге сорауларга җавап эзләп, аптырап утырганда, кемдер капкага каты-каты гына тибеп куйды.

Ханым урыныннан сикереп торды. Әмма иртә сөенгән икән. Шакучы Габделбәр дә, Зөбәйдә дә түгел, ә бәлки күрше хатын иде. Ул үз күзләре белән күргән икән: Маһирлар Габделбәргә һөҗүм иттеләр, Габделбәр егылды, ди, аннары аны ат чанасына салып каядыр алып киттеләр, ди, медпунктка түгелме икән, ди...

Әлеге куркыныч хәбәрдән мөгаллимәнең тез буыннары хәлсезләнде, ул чак кына егылып китмәде. Каерылып тәрәзәгә карады, аннары, артык дулкынланудан сүзен дә әйтә алмыйча, күрше хатынга төбәлде. Зөбәйдә турында да берәр нәрсә ишетеп булмасмы икән, дип көтте. Мәгәр күрше хатын бүтән сүз әйтмәде, тизрәк чыгып китү ягын карады.

* * *

Сатучы Хисаметдин диванга кырын ятып ял итә иде. Ул күзләрен йомган, әмма йокламый, уйлана, борчыла, газаплана. Үтә усал яшь хатын, әллә ничәнче мәртәбә инде идәнгә каты-каты басып, Хисаметдингә текәлеп карап үтте. Хисаметдин «карт» чынлап йоклыймы, әллә уйланып кына ятамы? Йокласа ярый, арыгандыр, тик уйланып ятса, әлбәттә, көндез кибеттә күзе төшеп калган чәчбиләр турында уйланып ята инде... И ярата да соң Хисаметдин хатын-кыз затын, хатын-кыз дигәндә үлепләр китә инде менә! Хәер, хатыннар да хөрмәт итми түгел үзен, хәтта яраталар да! Яратырлар да шул: буй дисәң буй, тәс дисәң тәс,

тел дисәң тел — барысы да бар үзендә! Эшкә дә кулы ятып тора, нәрсә тотса, шуны булдыра ала! Менә шундый ирне кайсы хатынның инде кулдан ычкындырасы килсен!

Хисаметдин, хатыны йоклый икәнлегенә ышансын өчен, гырылдап җибәрде, авызын чапылдатып куйды. Юкса хатыны анең йокламыйча уйланып ятуын сизсә шундук эш куша. Ә өйдә эшнең ир-ат өчен дә, хатын-кыз өчен дә бетәсе юк!

Ниһаять, яшь хатын иренең йоклый икәнлегенә тәмам ышанды һәм, галанка миче артындагы җылы, йомшак урынга барып ятты. Хисаметдин күзен ачты. Кухня якта электр лампасы якты нурын чәчепме чәчә иде. Бу — эчкечеләргә кирәк. Бу — аларга маяк ролен үти ләбаса. «Кибетчеләрдә ут бармы? Әһә, бар! Димәк, капканы ачтырып керергә була...» Ләкин Хисаметдин эчкече бәндәләргә аракыны талонга сатып җибәрә иде. Аракы бит талонга кайтарыла. Мәгәр Хисаметдин аракыны көндез кибеттә сатмый һәм ул анда аракы тотмый да диярлек. Болай иткәндә, ягъни аракыны кичләрен өйдән сатканда, бермә-бер файда эшләп була. Алалар әлкәшләр аракыны талонга булса да, ике бәя түләп алалар! Алмаслар иде, кесәләрендә акча сикерә. Ә акчаны, кем әйткәндәй, чәйнәп тә, йотып та булмый аны! Аннары, яңа тәртипләр тамыр җәя башлаган заман бит, шома кешеләргә, киң булып, капкалар ачылган вакыт. Нигә әле ходай биргән бу мөмкинлектән файдаланып калмаска!

Кемнәрдер капка дөбердәтә башлаган тавыш Хисаметдиннең уйларын бүлде. «Әһә, килделәр!» Хисаметдин хатынының: «Бар инде тизрәк!» — дип эндәшкәләгәнче торып, узышлый гына сырмасын эләктерде дә парадныйга чыкты. Йөзенә, буасы ишелгән су агымы кебек, салкын һава килеп бәрелде, муенын, күкрәкләрен рәхәт кытыклатып эчкә таба төшеп китте.

Тышта «ыж-ж-ж, ыж-ж-ж» килеп, чинап, үкереп җил дулый иде. Ул йә парадный ишеген тилереп йолыккалый, йә капканы этеп ачмак була... Хисаметдиннең чыгуын казлар да ишетте, ахры, үзләренчә: «Ка-ка-ка!» — дип сөйләшеп куйдылар. Аларга карлыккан тавышлы бер бәрән дә кушылды. Хисаметдин, җил-буран жулавы аралаш, сарайда яткан буаз сыерның авыр мышнавын да ишеткәндәй булды.

«Шулай да кемнәр булыр икән бу?!»

Янә әдәп белән генә ишек дөбердәттеләр.

«Авыл советы рәисе түгелме икән бу?!»

Хисаметдин караңгыга кулларын сузды. Кармаланып, кыска юан бармаклары белән лампаны эзләп тапты да ут кабызды. Парадныйга иске җиһаз тутырылган, җепсәгә ит түшкәләре асып куелган, аралык тар. Хисаметдин алпан-тилпән атлап, ишеккә таба китте.

— Кем бар анда? — дип сорады ул карлыккан тавышы белән.

— Без әле бу, Хисаметдин абый, үз кешеләр.

Парадный алдында, ышыкта, бүрекләренә, кашларына, якаларына кар сарган эреле-ваклы дүрт егет, «үз кешеләр» ул чыкканны көтеп, түземсезләнеп, зур өметләр белән ишеккә төбәлеп торалар иде.

* * *

Егетләр сәгатьтән артык утыралар иде инде... Өстәл астында «утлы су»дан бушаган шешәләр ишәя бара. Хисаметдин сәяси темаларга гәп куертырга ярата иде. Шуны аңлаган егетләр көтмәгәндә генә мөстәкыйльлек тирәсендә бөтерелә башладылар. Сәлим, безнең әңгәмәбез турында хуҗа ни уйлый икән дигәндәй, Хисаметдингә карап куйды. Юк, мөстәкыйльлек турындагы әңгәмә дә кызыксындырмый иде ахры хуҗаны. Аның шома, кызыл йөзе әле һаман уйчан иде. Соры күзләре мич авызындагы утыннарга төбәлгән... Ул — утыра, тәмәке тарта. Гәүдәсе астында — кайчандыр үзе ясаган, еллар үтү белән искергән, әмма әле дә ныклыгын җуймаган агач урындык.

— Юк, юк, үзгәртеп кору дигәнең болай дәвам итсә, берни дә кыра алмаячакбыз... Системаны сүтәргә кирәк, системаны! — диде Маһир, кемнәндер ишеткән сүзләрне кабатлап.

Кәрим исә, чиядәй кызарган борынының очын кашый-кашый, хуҗага төбәлде. Әмма Хисаметдин аларның майлы карашын күрмәмешкә һәм үзләре өр-яна дип уйлаган хәбәрләрне ишетмәмешкә сабышты. Ул бит, болар кебек, аракы эчеп вакытны бушка сарыф итми! Ул бит кирәкле, бик кирәкле эш белән мәшгуль!

— Мин дә шулай уйлыйм: системаны җимереп ташлау фагыз! — Харис «р» урынына «г» әйтеп сөйләшә иде.

Егетләр тагын салып эчтеләр, «аһ-ваһ» килделәр, шатыр-шотыр кыяр чәйни башладылар.

— Нинди шәп тормышта яши башладык бит, ә?! — диде Сәлим мыскыллы елмаеп. Аның кулында йомарланып беткән бер талон кисәге бар иде. Иптәшләренә ул шуны күрсәтеп азаплана иде.

— Системаны пыран-заран китерергә кирәк дим мин сезгә! — һәм Маһир тозлап-борычлап сүгенде, аннары бар көченә өстәлгә китереп сукты.

Хисаметдин, кинәт күзләрен кыса төшеп, инде исерүе тәмам җиткән Маһирга төбәлде. Маһир исә үзалдына текәлгән көе кызыл йөзен җыерып, авызын килбәтсез кыегайтып мыгырдады:

— Юмартландың син, Хисаметдин абый, үзгәртеп корулар башлангач. Валлаһи менә... синнән дә яхшы бай юк хәзер кибетчеләр арасында. Кара бу өстәлне! Алмалар дисеңме, кыярлар, помидорлар... Кипкән, тозлы, маринадлы гөмбәләр дисеңме... Чахун балык! — һәм Маһир бөгелә-сыгыла кыярга үрелде, пальто җиңе помидор суына буялып чыкты...

Түшәмдә ике чебен йөри. Икесе дә симез — Хисаметдин белән яшь хатыны шикелле! Ике тәрәзә арасында күзгә чүпләм сөлге асылган. Бу сөлге — Хисаметдиннең горурлыгы, кайчандыр сабантуйда, Зәлиягә өйләнер алдыннан, көрәшеп алган бүләк иде. Ак якка үтә торган ишек ябык. Эчтә яшел пәрдә корулы.

Сәлим күзлеген төзәтеп, кыбырсып читкә карап куйды. Кәримнең килде-китте сүзләре туйдырган иде аны. Кәрим шуны сизгәндәй сүзне икенчегә борып җибәрде. Хариска таба борылып, кыйссасын дәвам итте.

— Ш-шулай-теп, парин, куып җиттем мин моны. — Һәм ул тешләрен шыгырдатып алды. — Куып җиттем дә каратэ алымы белән җиде-сигез метрга шалт тегене...

— Кемне-е? — диде Маһир, йокымсырап утырган җиреннән.

— Эчик әле башта! — диде Харис. Һәм үзе ялт кына эчеп тә куйды.

— Лаеш бакасын инде, күрше авыл дуңгызын... аларга шул кирәк... йөрмәсеннәр безнең авыл кызлары янына килеп!

Харис көтмәгәндә генә җыр сузып җибәрде:

*Без бит ыгыйбный ыгаюны-ы-ы...*

Ишектә хуҗа хатынның үтә кырыс йөзе һәм ачулы авазы ишетелде, шуның артыннан ук түзем савыты мөлдерәп тулган Хисаметдиннеке яңгырады:

— Әйдәгез, егетләр!

Кәрим шешәне бөкеләп кесәсенә салды, кибетчегә кулын сузды:

— Ярый, абый, пока!

Хисаметдин тамчы да эчмәгән иде бүген, аек иде. Кәримнең кулын теләр-теләмәс кенә кысты. Уйчан соры күзләрен зур ачып, гаҗәпләнеп Хариска төбәлде. Әйтәм ул кулын сузып саубуллашмый, аның кулларында өстәлдән «сугып» алган закускалар икән!

— Кыярларны куй, сакау тәре, йә акча түлә, бушка килгәнмени алар безгә?! — дип кычкырды хуҗа хатын Хариска.

Хисаметдин, сабыр булырга тырышып, Хариска әйтте:

— Энем, Фазыйлә апаң дөрес әйтә. Сораусыз алган әйбер урлауга керә, ә урлаган өчен нишләткәннәрен беләсеңдер...

— Бу кыяглагда минем дәхелем баг! — дип тартышты Харис. — Мин сиңа, юаң тәге, көн саен күпме «выгучка» кегтәм, беләсеңме, ә?

Кинәт Харисны бер читкә этеп җибәреп, Хисаметдин каршына Кәрим килеп басты.

— Мә, абый, ал! — диде ул, кибетчегә кукиш күрсәтеп. — Тагын өч мәртәбә берәрне өсти алабыз! Ризамы?

— Нәрсә? Нәрсә дисең?! — Хисаметдин Кәримгә якын ук килеп басты.

Егетләр тып-тын булып калдылар. Кәрим дә шыр җибәрде ахры, эндәшмәде... Сипкел баскан озынча йөз, болганчык зәңгәр күзләр, кызгылт чәчләр, Маһирның кызарып бүртенгән йөзе, Харисның җәлпәк борыны, Сәлимнең җан өшеткеч салкын карашы — һәммәсе бергә буталып, Хисаметдиннең күңелендә ярсулы дулкын кузгатты.

Ишек-амбразурадан хуҗа хатынның ләгънәтле сүзләре торган саен көчлерәк сибелә барганлыктан егетләргә чыгып китүдән башка чара калмаган иде.

* * *

Аш бүлмәсеннән сүрән генә яктылык килә. Эңгер-меңгергә иялəнгәч кенә Маһир үзен идәндә ята итеп күрде. Янәшә диванда урын буш иде, ул шуннан егылып төшкән булса кирәк.

Маһир торып су эчәргә бармакчы, аннары янә килеп ятмакчы булды. Әмма башын калкытуга, ул үзен чит өйдә күреп гаҗәпләнеп куйды һәм янә кулларына башын салды. Шулай байтак кына уйланып ятты. Уйлары да уенчык самолет сыман бер тирәли әйләнгәләп йөрде. «Мин кайда? Кемнәрдә? Һәм ни сәбәпле?» Шулай уйланып ята торгач, аның хәтерендә кичәге вакыйгалар җанланды... Ул бит җинаять кылды, кыз урламак булды әле, аннары Харисларга кайтып лыкынганчы бал чөмерде, сүгенде, елады... Аннары... аннары... белми! Аннары тагын ниләр кыланып бетерде икән ул, ходаем?

Кинәт Маһирның күңелен коточкыч курку биләп алды.

Ниһаять, ул «беткән баш» икәнлегенә ышангач, авылдан гомерлеккә китеп, юкка чыгарга дигән катгый карар кабул итте. Әмма икенче уй аңа каршы төште:

— Бу авылдан китеп, син кая барасың?

— Мин үткәнемнән һәм бүгенгемнән качып, киләчәгемә таба барачакмын.

— Аһ, ялгышасың, бик ялгышасың...

— Ни өчен? Ни өчен?

— Син киләчәгеңә балта чабачаксың, беләсеңме шуны?

— Ник? Аңлат!

— Качып китмә...

— Алайса, нишләргә миңа? Нишләргә?

— Эшләгән эш өчен җавап тотарга, кылган җинаятьнең җәзасын алырга... Шунсыз син кеше түгел!

— У-у-у, бу бик авыр... Бик авыр...

Кадактан костюмын, пальтосын алып киде Маһир. Аягына итекләрен, башына бүреген батырып, кинәт дөньясына кул селтәп, ишеккә таба кузгалды.

Кичтәнге җил-буранның әсәре дә калмаган. Аның каравы салкынайткан — битләрне куырып ала, колакларны чеметә, сулышка каба иде. Шул мизгел кар шыгырдаганы ишетелде. Арттан кемнәрдер килә бугай. Тиз киләләр. Сөйләшүләренә караганда, Маһирны куып җитәргә ниятлиләр. Тәмәкеме, шырпымы кирәк аларга.

Маһир урыныннан кузгалды һәм, бу көтелмәгән кунаклар белән очрашмаска исәп итеп (кем икәнлекне танытмаска кирәк бит!), адым-

нарын ешлатты. Тегеләр дә тизлекләрен арттырды. Маһир шикләнеп йөгерә үк башлады, һәм кинәт ике өй арасында сарылы-кызыллы утлар җемелдәп алды. Озак та үтмәде, борылышта автобус пәйда булды.

Маһирның башыннан җылы өй дә, арттан килүчеләр дә очты. «Әһә-һә-һәй-й-й!» — дип кычкырды ул, кул болгап, шоферга туктарга ишарәләп. Автобус тизлеген акрынайтып, ишекләрен ачты һәм Маһир йөгереп менеп утыргач, елаган аваз чыгарып, китеп барды.

«Уф-ф-ф!» — дип авыр сулый-сулый автобусның урта өлешенә үтте Маһир. Алдагы рәттә йокымсырап баручы ир-ат бар иде... Маһир да йомшак утыргычка чумып, йокымсырагандай, күзләрен йомды. Ләкин кая ул... Шул мизгел аны теге кешеләр, кем икәнен белеп, артыннан куа чыкканнардыр да, менә-менә тотып алырлар кебек тоелды. Маһир хәтта куучыларның йөз кыяфәтләрен, авыр-авыр йодырыкларын да күргәндәй булды. Моның берсе, арада иң дәһшәтлесе, әлбәттә, Зарифулла-Гасыйм абзый иде. Ул җинаятьчене качып китеп барган җиреннән тоту гына түгел, малаеның каны өчен ерткычларча үч тә алыр кебек иде.

Маһир хәтта Заруфулла-Гасыйм абзыйның котырган, шашкан йөзен, коточкыч булып акайган юлбарыс күзләрен шәйләп, үзенә шап-шоп сугуын, теш казнасы җимерелүен, авызыннан-борыныннан шаулап кан ага итеп тә сизде сыман... Теге чакта аклы-сарылы песи баласы да үзен шулай итеп сиздеме икән?..

Маһирга җиде яшь кенә иде әле ул чакта... Күлмәген бөрмәләндереп болдыр баскычын юып яткан әбисе аны үзенә чакырып китерде дә:

— Анауы мәче баласын үтер әле... Бигрәк мәнсез нәрсә, һаман баскычны, болдырны кәкәйли, һаман аяк астына «өеп» куя... Үзе алдына салганны ашамый да, һаман урлау ягын каера. Тычкан да тотмый бу, моның файдасы юк, зыяны гына бар... Үтер әле син аны, улым... бер тәңкә акча бирермен аннары, ямә! — диде. Маһирның урыныннан кузгалмавын күреп, янә өстисе итте әби кеше:

— Ярый алайса, акчаны хәзер үк бирәм, мә, ал! Син кечкенә әле, сиңа бер җан иясенең дә каргыш-рәнҗеше төшмәячәк. Син гөнаһсыз, улым... Үтер син аны, аннары тагын бер тәңкә бирермен, ямә!

Маһир җинелде. Акчаны бик ярата иде шул. Дөрес, ул мәче баласын да ярата иде, ләкин акча яратуы өстенрәк булып чыкты.

Маһир беркатлы мәче малаен «пес-пес» дип үзенә чакырып китерде дә, эләктереп, урамга алып чыгып китте. Ә урамда, тыкырык каршында телеграмм баганасы бар. Багана янында ике ир-ат колачларлык өянке төпсәсе.

Маһирның бер кулында акча, икенче кулында аклы-сарылы мәче баласы... Аның күңелендә кызганунын әсәре дә юк. Хәер, кызгана торган, шәфкатьле малай булса, әбисе аңа бу хәтәр йомышны кушмас та иде.

Маһир мәче баласын баш өстенә күтәреп, бар көченә өянкегә тондырды. Песи малае чарыйлап кычкырды, аның авыз-борыныннан кан китте, ул берничә тапкыр тыпырчынды да, тынып калды...

Маһир, акча алырга дип, әбисе янына керде, ләкин әбисе өйдә юк, ишекне бикләп каядыр киткән иде.

...Автобуста Маһир бер янды, бер туңды һәм авыр-авыр сулап, маңгаен тәрәзәгә терәде. Бераздан боз салкыны баш сөяген өшетеп җибәргән кебек булды. Ми туңса, кеше үлә, ди бит. Әллә... Юк, юк... Маһир сискәнеп башын күтәрде. Мәгънәсез үлем бу. Бу адымга беркайчан да барачак түгел ул...

Автобус олы юлдан, Идел буеннан бара башлаган иде инде. Көн яктырган. Күк йөзендә серле зәңгәрлек. Түбәндә генә тотен кебек ак болытлар асылынып тора. Як-якта түбәнлекләр һәм калкулыклар, җимерек чиркәүле авыллар... Кая бакма — кар да кар. Гүя бөтен дөньяны кар дәрьясы чолгап алган, авыллар шул дәрьядагы утраулар сыман.

Көн болай ярыйсы кебек иде. Әмма Маһирга ул караңгы чырайлы кеше сыман шыксыз һәм ямьсез булып тоелды. Кая гына күз салмасын, карашы нәрсәгә генә төшмәсен, күңелендә матурлык тойгысы кузгалмады. Һәм бу очракта моның булуы да мөмкин түгел иде.

Әнә, еракта гөмбәзләрен ялтыратып, мәһабәт булып калкып торучы силос башнялары! Берәү булса аларга карап сокланыр, тел шартлатыр иде. Әмма Маһирның аларга исе китмәде. Әнә, кыр ягыннан бирегә таба бер трактор килә. Ни өчен килә? Ни калган аңа монда? Маһир хыялы белән ул тракторны кире якка борып куйды. Ул гына да түгел, чөйкәлтеп үк җибәрде... Шул кирәк аңа, йөрмәсен!

Аннары ул хыялы белән юлдагы машиналарны да аударып бетерде. Соңыннан: «Безнең автобус ауса, мин нишләр идем икән?» — дип уйлап куйды, һәм аңа куркыныч булып китте. Шуңа күрә ул үзен бик тиз кулга алды: бая хыялында ауган машиналарны да торгызып, үз юлларына җибәрде...

Автобус кинәт туктады, Маһир алга сөрлегеп куйды. Шофер тәрәзәсен ачып кемнәндер:

— Кая барасың? — дип сорады.

— Казанга! — Бу тавыш Маһирга таныш сыман ишетелде.

— Утыр әйдә,— дип, шофер автобусның алгы ишекләрен ачты.

Анда башына йөнтәс бүрек, өстенә кара тукыма белән тышланган кыска тунлы берәү күренде.

— Әй-яй, салкын бүген! Тәмам өтеп ала...— дип сөйләнде ул. Һәм аннары кая куйыйм икән дигәндәй, як-ягына каранды да, кулындагы авыр сумкасы белән туп-туры Маһир янәшәсенә килеп утырды, сумкасын идәнгә куйды. Маһир бу ирне шундук таныды. Әлеге кеше Сания әбинең өченче баласы — Илһам иде. Илһам да Маһирны тиз таныды һәм: «У-у, кода, син түгелме соң бу?» — дип, канәгать төстә елмаеп күрешергә кулын сузды... Шунысын да әйтик, күптән инде Маһирның олы абыйсы Илһамның апасына өйләнгән иде... Маһир Илһам кодасының кулын теләр-теләмәс кенә кысты. Бу очрашуга әзер түгел иде ул. Шуны сизгәндәй, Илһам кода шартлатып әйтеп куйды:

— Син дә авылдан качып китеп барасыңмы әллә?

Маһир дерт итеп сискәнде, ләкин сер бирмәскә булды.

— Юк, качмыйм мин авылдан! Аннары, мин дә качсам авылдан, сезне икмәк белән кем туйдырыр?

Илһам Маһирга таба чак кына авыша төште:

— Шул-шул менә, туйдыра алмыйсыз. Икмәкне без чит илләрдән валютага сатып алабыз ич.

— Моңарчы шулай иде... Ә менә мөстәкыйльлеккә ия булгач, үзебез үстергән икмәк үзебезгә җитәргә тиеш,— диде Маһир.— Тик бер шарт белән: сез, шәһәрдә яшәүчеләр, без үстергән икмәкне футбол тубы урынына тибеп йөртмәсәгез генә...

— Ә сез үзегез үстергән икмәкне кала кибетләреннән алып кайтып хайваннарыгызга ашатмасагыз, җитәргә тиеш, әлбәттә,— диде Илһам, бер дә югалып калмыйча.

Маһир көтмәгәндә генә:

— Син кайда эшлисең, Илһам абый? — дип сорап куйды.— Әле һаман урам тазартасыңмы? Әллә...

— РКБда мин хәзер! — диде Илһам.

— Анда кем булып?

— Лифтта эшлим мин, энем. Беренче каттан — тугызынчыга, тугызынчыдан беренчегә врачлар, медперсоналлар, авырулар һәм алар янына килүче олы кешеләрне ташыйм... Син килсәң, менә сине дә тугызынчы катка алып менеп куя алам!

— Анда көн саен эшлисеңме, кода абый?

— Юк, бер тәүлек эшлим дә өч көн ял итәм! Ял итәм дип... эш бетми инде ул! Шулай да митингларга йөрергә вакыт кала әле! Сөембикә

манарасына ай менгереп куйганнарын үз күзләрем белән карап тордым мин! Шөкер, уяна башлады безнең халык...

Автобус Лаеш юлын биш былтыр ук үтеп киткән иде инде. Мишә күперен дә бая ук узды. Ә хәзер Казанга якынлашып килә...

Уң тарафта, постта, автомат тоткан бер солдат басып калды. Сул тарафта яшел танклар төркеме каядыр китеп бара иде. Ә танклардан ары, карга яткан солдатлар, «та-та-та-та» килеп, мишеньнәргә атып ята иде.

Маһир, солдатта чакларын хәтереннән кичереп, шундагы бер кайгысыз яшьлеген сагынып куйды. Аннары Илһамга таба борылып:

— Кодагый әби сиңа күп итеп сәлам юллап җибәрде,— диде.

«Кодагый әби»не ишеткәч, Илһамның төсе үзгәреп, агарып китте, яңак мускуллары тартышып куйды. Һәм ул урыныннан торып:

— Бу четерекле мәсьәлә турында башка вакытта сөйләшербез... Менә мин армиядә бергә хезмәт иткән иптәшем авылына кайткан идем. Алардан яңа суйган бозау ите сатып алдым. Хәзер РКБ янында төшеп калам, бүген минем эш көнем!— диде. Бераз сүзсез торгач, өстәп куйды:

— Безгә дә килеп чык! Адресны беләсеңме?

— Беләм...— дип алдады Маһир. Хәер, Илһамның өй адресын табып алу кыенмыни?! Ул бит озакламый Илһамның апасы белән күзгә-күз карап сөйләшәчәк!

Автобус бара да бара. Маһир торып, үзенең «П» тукталышында төшәчәге турында хәбәр иткән иде шоферга. «П» тукталышында басып торган милиция капитанын күреп, егетнең аркасы буйлап бер көтү кырмыска узгандай булды. Маңгаена борчак-борчак тир бәреп чыкты. Инде хәзер, монда туктама, мин монда төшмим, дип әйтергә дә соң иде, автобус капитан турысына туктарга өлгергән иде.

Маһир автобустан арты белән чыкты. Пальто якасын күтәрде. Автобус артыннан шоферга сәлам биреп калган булды. Аннары, перчаткасы белән озынча йөзен томалап, тротуар буйлап китте. «Борылышка җиткәнче капмасам, котылам!»— дип уйлады ул. Ләкин борылышка җиткәндә аңа янә өч милиционер очрады. Аларның өчесе дә карага каккан тун кигәннәр иде. «Гаишниклар гына бит болар»,— дип уйлады Маһир сөенеп. Һәм ул туктап папирос кабызды. Комсызланып төтен суырды һәм маңгае астыннан гына капитан басып торган якка карады. Капитан анда юк иде инде.

— Тфү,— дип төкереп куйды Маһир.— Курыкканга бәрән дә бүре булып күренгән, ди. Болай һәр очраган милиционердан куркып яши башласаң, аягыңны бик тиз сузарсың. Курыкмаска... Батыррак, кыюрак булырга!— дип үз-үзен дәртләндерде Маһир һәм болай да зур гәүдәсен тагын да озынайтып, үрә катырып «С» урамына таба юл тотты. Каршында бакча иде. Кар кызы, кар бабай һәм аю сүрәте төшерелгән кубиклар, шугалаклар, таганнар иде. Һәм шунда мәш килеп, кайнашып балалар уйнап йөри иде.

Маһир хәтта бер кызны Зөбәйдәгә охшатып, дерт итеп сискәнеп куйды. Кыз да аңа көлемсерәп карады һәм, нидер көткән сыман адымнарын акырынайтып, үтеп китте. «Кемгәдер ошатты булса кирәк, әнә ничек карап узды». Маһир янә артына борылып карады. Шул мизгел кыз да аңа әйләнеп карады.

«Аһ, ялгышасың кызый. Син көткән егет түгел мин. Юкка чыккан, беткән кеше мин хәзер!» — һәм Маһир авыр сулап көрсенде. Аннары, ике катлы агач йортның яшел капкасын ачып, ишегалдына үтте. Каршында, гасыр башында салынган бер катлы гына кирпеч өй тора иде. Менә шушы куышта кызы белән икесе генә яшәп ята иде инде Илһамның апасы, ягъни Маһирның абыйсының хатыны. Ә Маһирның абыйсы Себердәге нефте эшеннән елына ике мәртәбә унар көнгә кайтып та өйдә, гаиләсе янында ике генә көн куныт китә торган иде шул.

Маһир галәт буенча кыңгырауга басмады, ә чибәр апасы йоклый торган тәрәз буена килеп, пыялага чиртте. Чибәр апасы, тәрәзәгә коргай

пәрдәнең читен ачып, кем икән бу, дип карарга тиеш иде. Ләкин бу юлы пәрдәнең кылы да селкенмәде. Аның урынына аш бүлмәсендә ут кабынды һәм озак та үтмәде, өйалдында: «Кем ул»? — дигән борчулы аваз ишетелде.

«Нишләп болай итте соң әле бу? — дип уйлады Маһир әчке борчылу белән, нindидер ярамаган нәрсә барлыгын сизенеп. — Нишләп пәрдә почмагыннан карамады, ә тизрәк кухняга чыгып ут кабызды икән?»

Чибәр апасы янә:

— Кем ул? — дип сорады.

— Мин, — дип, — бу юлы чынлап та чибәр апасыннан шикләнеп аваз бирде Маһир. — «Ул бит мине күрә, ә ачарга ашыкмый», — дигән уй аның күңеленнән һаман китми иде.

— Ә-ә, синмени әле? — дип чибәр апасы, ниһаять, ишекне ачып, каенесен эчкә үткәреп җибәрде. Ишекне эчтән бикләп үзе дә керде. Бай җиһазлы чибәр хатынның өй һавасы да баллы, татлы исләргә бик мул иде. Үзенә килгәндә исә аның авызы тулы алтын теш, колакларында ахак кашлы алтын алкалар, алты бармагында алты төрле йөзек. Шунысы сәер, ул аларны йоклаганда да салмаган бугай, хәтта күлмәген дә салып-нитеп тормыйча йоклаган... Ә мич янында торган өр-яңа кара унты гүя: «Салисә ялгызы гына түгел...» — дип әйтеп тора иде.

Маһирның унтыларга текәлеп каравыннан уңайсызланып, кызарып чыккан Салисә, аклану йөзеннәндер инде, су сиптергәндәй тиз-тиз генә әйтеп ташлады:

— И шуларны урамга чыгарып атармын, ачуым да килмәгәе.

— Ыргыта күрмә... Иясе ялан тәпи йөрер дә салкын тидереп үләр җә, — дигән булды Маһир, мәсхәрәле елмаеп.

Салисәнең ялт-йолт килеп торган яшькелт-соры күзләре коточкыч булып акайды:

— Нәрсә-ә! Син әллә... Җизнинекеләр иде бу, абыең кия аларны... Себердән кайтты да, боларны калдырып, көньякка китеп барды әле, дөмеккере!

«Әһә, иргә җирсегән бу! Моныякларга кирәк! Шунсыз моннан акча алып булмаячак!» — дип уйлады Маһир. Һәм, бүреген салып чөйгә элде дә, урындыкка утырып, йодрыкларын уйната-уйната, төкерекләрен чәчә-чәчә абыйсын әрләргә кереште:

— Дурак ул, шундый акыллы, матур хатынының кадерен белмичә, әллә кайларда каңгырып, ят почмакларда аунап йөри. Ахмак, дуңгыз... Ярар, бер кайтыр әле ул, очратырмын мин аны... менә шунда сөйләшеп карармын әле мин, ничегрәк сайрар икән ул?!

Салисә йомшарды. Бер дә кирәксә-кирәкмәсә дә туктаусыз тамак кырырга һәм кашынырга кереште. Шулай да ул, элекке вакыттагы кебек, зәңгәр ягулыкны дөрләтеп, плитәгә чәйнек куеп җибәрергә ашыкмады. Сизелеп тора: аның тизрәк сәбәп табып Маһирны өйдән чыгарып җибәрәсе килә. Ә Салисәдә дипломатлык, төлкелек һәм мәкерлек поты белән иде.

Хәер, Маһир да төшеп калганнардан түгел, әгәр теләсә, максатына ирешмичә калмый. Менә ул, эшне кыскарак тотарга чамалап, турыдан суктырырга булды: Салисәнең ялт-йолт килеп торган мут яшькелт-соры күзләренә туры карап әйтте:

— Чибәр апа, син миңа бераз акча биреп тор инде! Ашыгам мин, соңаруым бар!

Салисә кинәт дерт итеп куйды, аннары, егылып китүдән сакланырга теләгәндәй, кулларын җәеп җибәрде:

— Әстәгъфирул-ла-а! Ни булды сиңа, — диде ул курыкканга сабышып. — Нәрсәгә сиңа акча?

— Кирәк булгач, кирәк инде, — диде Маһир яшькелт күзләрен челт-челт йомгалап.

— Пәлтәндә нинди кан таплары соң ул?— дип үзе һөҗүмгә күчте хәйләкәр Салисә. Бу алым белән ул Маһирны акча сораудан ваз кичтерергә тели иде. Һе, кара син аны, акча кирәк булган аңа... Бетмәс монда теләнүчеләр!

Маһир ялт кына пәлтәсенә карап куйды һәм үзен кулга алырга тырышып:

— Ә-ә-ә... мал суйганда чәчрәгән иде бу,— диде.

«Үзләре мал чалганнар, ә күчтәнәч биреп җибәрә белмәгәннәр, кы-зы-к... Өстәвенә әле Маһир килеп миннән акча сорый. Оятсыз!» Ә Салисәнең авызыннан башка сүзләр чыкты:

— Синең, энем, өйдән килүеңме соң бу?

Маһир кыяр урлап тотылган малайдай каушап:

— Э-э-э? Юк, мин... ни...— диде, калтыранып, дереллдәп кесәсенә тыгылды, папирос чыгарып кабызды. Ләкин бу хәлдән соң да башына юньле фикер килмәде. Һәм шуннан соң ул соңгы көчен, батырлыгын туплап әйтте:— Җинаять кылдым мин, чибәр апа.

Салисәнең симез йөзе агарып китте. Күзләре зур булып ачылды. Шул ук вакытта ул эченнән генә тантана да итә иде кебек.

— Нинди җинаять?

— Габдел-бәр-нең башын... ярдым...

— Ah-h-h!

Салисә, хәле беткәндәй, урындыкка чүкте.

— Их, энем... Барыбер утырталар бит сине.

Маһир йөзен чытып, маңгаен учлап әйтте:

— Авылдан чыгып качтым мин, чибәр апа.

Салисә озак кына дәшмичә уйланып утырды. Ниһаять, җанланып куйды.

— Әти-әниең белдеме соң әле?

— Ишеттергәннәрдер инде.

Салисә тәрәзә буена барып басты. Тышта нәкъ аңар карап бер овчарка басып тора иде.

— Инде нишләргә уйлыйсың?

Шул мизгел көл юллыгында торган бер күмер кисәге ялкынланып янып китте.

— Анда күз күрер әле,— диде Маһир, чак кына батырая төшеп.

— Болай вакыт үткәргәнче, бәлки, милициягә...

— Юк, чибәр апа, булмый,— диде Маһир кырт кисеп.— Ул явызлар кулына үземне тәк-сибәгә генә илтеп тапшыра алмыйм, бигайбә.— Һәм егетнең күзләре мич каршында яткан зур балтага төште.— Син миңа, чибәр апа, йөз тәңкә биреп тор да, мин китим!

Салисә балтаны алып мич арасына кыстырып куйды.

— Илле тәңкә дә бик җиткән, энем! Мә, илле тәңкә бирәм, шуннан бер көмеш тә арттыра алмыйм! Үзең дә беләсең булыр, хәзерге кыйммәтчелек заманында акча табулары, ай-һай, авыр!

Шулвакыт ак якта нәрсәдер шап итеп идәнгә төште, нәрсәдер чылтырап ватылды. Маһир шул тарафка керергә итеп урыннан талпынып куйды. Ләкин Салисә шундук аның юлын бүлеп өлгерде.

— Юк, берни дә юк, кермә анда!— диде ул.— Мә, йөз тәңкә бирәм, бар, чыгып кит!— һәм ул, тәрткәләп диярлек, Маһирны ишеккә чаклы озатты. Маһир, йөз тәңкәне кесәсенә шудырды да, кулын селтәп, чыгып китте.

* * *

Разыя уянганда Асылбикә түти почмак якта кыштыр-кыштыр эшләп йөри иде инде. Ул, күрәсең, мичкә ягып җибәргән дә, хәзер утлы күмерләрне тартып азаплана. Аннан соң ул казанга су салыр, утлы күмерләр-

нең бер өлешен чуенга тутырып һәм мичкә табалы пирог-миргогларны пешәргә куяр да, олы җиз самавырны кулга алгач кына эндәшер:

— Разыя, кызым...

— Хәзер торам, әни,— дип җавап кайтарыр Разыя.

Аннары ул башына шәлен алып бәйләр, өстенә кара жакетын, аякларына итекләрен кияр дә чиләк-көянтәсен алып, чишмәгә йөгерер.

Чишмә өйдән ерак түгел, елганың каршы як ярында гына, төптән бәреп әллә ниткән борынгы көйләр көйли-көйли агып ята. Күптән инде, егерме еллар элек, кайсыдыр, рәхмәт төшкере, аңа тимер торба куйган, шуннан бирле иеләсе дә юк, чиләкләреңне көянтәдә килеш кенә тутырасың да, җеп сузгандай туры сукмак буйлап янә авылга элдерәсең.

Асылбикә түти Разыяның кайтуын зарыгып көтә инде.

— И-и-и... Бигрәкләр мөлдерәмә иткәнсең, кызым,— дип мактап куя ул, Разыя чиләкләрен түкми-чәчми өйгә килеп кергәч.

Аннары самавырга шаулатып су салалар, морҗасына күмер төшереп җибәрәләр дә торба башын учакка каратып куялар.

Озак та үтми, самавыр, кайный башлавын хәбәр итеп, шыңлыйшыңлый көйләргә тотына. Ә Разыя шкафтан тегесен-бусын алып чыгып өстәлгә куя.

Аналы-кызлы шулай эш белән әвәрә килеп йөри торгач, өй эченә тәмле бөккән исе тарала. Самавырның да ачылмалы тишегеннән пар бәреп чыга, чалмага куйган таш чәйнекнең дә капкачы фырылдап сикерергә тотына.

Менә җитә күңелле вакыт. Мичтән бер-бер артлы пәрәмәчләр чыга башлый. Кызарып, кетердәп пешкән паштетлар өлешләргә бүленеп тәлинкәгә салына һәм табынның патшасы самавыр янына менеп кунаклый. Өй эчендә бөркү. Асылбикә түти белән Разыяның ике бит алмасы алсуланып чыккан. Аларга рәхәт. Алар үзләрен күкнең җиденче катында итеп хис кылалар. Әгәр сорасалар, алар һич икеләнмичә:

— Дөньяның иң күңелле, иң ямьле чагы менә шушындый кышкы иртәдә, авыл өендә тирләп-пешеп чәй эчеп утырганда,— дип әйтерләр иде.

Әйе, ярата иде, бик ярата иде шул Асылбикә түти иртәнге якта яңа алып кайткан чишмә суыннан кайнатып чәй эчүләрне.

Янә читтән күчеп кайткач та ул:

— Үзебезнең авыл чишмә суын эчеп кенә сихәтләнәчәкмен,— дип әйткән, имеш.

Шул сүздән чыгыпмы, әллә бүтән сәбәбе табылыпмы, авылдашлары Асылбикә түтине «Чишмәбаш Асылбикәсе» дип кенә йөртәләр.

Разыя шулай уйланып ята торгач, гадәттәге урыннан киемнәрен алып киде һәм артъякка чыкты. Кайдадыр, сузып-сузып мәче мияулый иде. Асылбикә түти кызына күзләрен генә төшереп алды да, самавырын кире өстәлгә утыртып, идән сайгакларын ачарга керешге.

— Бибифатыймау-у-у... Чык, әйдә, йөрмә анда интегеп.

Бибифатыйма үпкәләгән сыман, «миях-у-у», дип аваз биреп куйды, сикереп идәнгә менде.

Ап-ак мыеклы, бөтен җирен кырау суккан гаять олы мәче иде бу. Әнә ул төссез кара нокта күзләрен тутырып Разыяга караган булды, барыбер танымады. Аннан соң күптән түгел генә эссе чуенга тиеп кутырлаган борынын сузып, өстәл астына таба титаклады. Менә без дә шулай картаясы инде, дигәндәй, Асылбикә түти мәчене күзләре белән озатты да, тирән сулап, уфтанып куйды. Аннары янә самавырын кулына алды.

— Мин, әни, суга барып кайтыймчы,— диде Разыя, өйдә булмаган юанычны чишмә юлында табар күк тоеп. Чөнки ул кичтән күп итеп яшьләр җыйды. Габделбәргә дә әйткән иде яшьләр янына. Ләкин Габделбәр ни өчендер килмәде, күренмәде. Ни өчен килмәде? Ни өчен күренмәде икән ул? Әллә...

— Бар, кызым, бар! — диде Асылбикә түти сөенеп.— Әле үзем дә шуны исенә төшермәкче идем.

Вафа абзый, ишегалды белән абзар-кураны килә-сара, мал-туарга печән салып, су эчертеп мәш килә иде. Разыяның өйдән чыгуын сизми калды, ахры. Сыергамы, сарыккамы: «Хә-с инде, паразит!» — дип, бик яман тавыш белән җикерде, аннары шап итеп тибеп җибәрде һәм тозлап-борычлап сүгенә башлады.

Разыя җәлт кенә капкага таба китте.

Кыз, ашкынып урамга чыккач, бер мәл күзләрен ачалмыйча торды. Башта ул моның нилектән икәнлегенә төшенеп җитмәде. Бары тик билдән карга кереп чумгач кына хәл ачыкланды. Төнге давыллы буран бер якка да сукмак калдырмаган, барлык юлларны күмгән, барча чокыр-чакырны шомартып, тигезләп киткән икән. Яңа яуган кар шундый да ак, аңа карагач, күз аллары әлҗе-мөлҗе килергә тотына.

Әйе, бүген халыкка эш чыккан. Кая карама, кар көриләр. Разыяның да үзләренең капка төбен ялт иттереп куярга хәленнән килә, әлбәттә. Әмма бүген эшне алай кызу тотарга аның дәрте дә, теләге дә юк шул. Нидидер хис аны һаман-һаман чишмәгә барырга ашыктырыпмы ашыктыра. Разыя килеп җиткәндә чишмә буен хатын-кыз халкы сырып алган булып чыкты.

Яшелчә урамыннан мичче Харисның әнисе өрәк Сатирә дә килгән хәтта. Чәтер-чәтер бер тавыш яңгырый — шуныкы! Ул Разыяның үзләренә таба якынаюын, сүз белән мавыгып булса кирәк, күрмәде, шәйләмәде.

— Кич йокларга яттымыс гына, шул заман ук тәрәзәгә чирттеләр. Торып тәрәзәгә килдем. «Кем бар?» — дип сорыйм. «Бу мин әле, Асылбикә», — ди. Карасам, әргән Вафа икән теге...

Шулвакыт хатыннарның кайсыдыр Разыяның килүен әйтеп өлгерде, ахры, өрәк Сатирә тынды, күзләрен челт-челт йомып, як-ягына каранды һәм Разыяны күргәч, кып-кызыл булды.

— Әкиятең күңелле иде, Сатирә, иң кызык җирендә генә өздең, җә, дәвам ит инде, шуннан ни булып бетте? — дип үртәп алды бер шук телле хатын Сатирәне.

— Калганын иртәгә тыңлап бетерерсез инде, — дигән булды Сатирә.

— Вафатдин абзый көн дә, көн дә килеп йөрмәс шул ул синең өй артына, — дип төрттерде баягы хатын.

Бу сүзләргә Разыяның бик тә ачуы килде. Ул:

— Нәрсә булган минем әтигә? Ник чәйнисез аны? — дип дәрләп кабынды.— Ботыгызга ак төкләр чыккан башыгыз белән мәчет карты турында гайбәт сөйләмәсәгез, чәйнәр әйбер беткәндер шул сезгә, оятсызлар!

— Әй, гайбәт капчыклары, китегез юлдан!

Хатыннар, бердәм рәвештә сискәнеп, тавыш ягына карадылар. Яннарына гына чал мыеклы, кызыл чырайлы, әзмәвер гәүдәле «чукрак» Нәгыйм ат белән килеп туктаган иде.

— Каягыз әле, хатыннар... Атка су эчертә торыйм ичмасам!

— Чиратсыз кертмәгез, кертмә. Әнә, фермасына барып, кое суы эчерсен.

Нәгыйм, шунда карашы төшеп, Разыяны искәреп алды:

— Син дә монда икән, сеңелем? Ишетмәдеңме әллә яман хәбәрне?

— Юк, Нәгыйм абый... Ә нәрсә булган?

Нәгыйм Разыяның күзләрендә курку иңүен, йөзе көл булып агаруын шәйләп, ничек тә тынычрак итеп әйтмәкче иде, булдыра алмады.

— Габделбәрнең башын ярып ташлаганнар бит кичә, — диде.

— Кайда? Кемнәр?

— Маһирлар инде... Маһир тимер белән суккан, аннары атка салып, медпунктка китергәннәр. Ул шунда ята!

Нәгыйм абзыйның тавышында гүя Разыяны гаепләү чалымы да сизелә. Разыя бит Мәһирнең ерак туганы! Аннары Нәгыйм абзый Разыяның Габделбәргә үлеп гашыйк булып йөрүен дә белми түгелдер. Шуңа күрә, бу сөйләшүне тын калып ишетеп торган хатыннар да, бу юлы сүны Разыяга чиратсыз гына биреп җибәрделәр...

Бетте!.. Бар да бетте, барысы да җимерелде. Хыял-өметләр дә, киләчәккә корган планнар да... Разыя күрше бабай ачкан сукмак буйлап өенә кайтып бара. Димәк, кызның кичәгедән бик яман борчыла башлавы, төнозын ярым саташып чыгуы, иртәгесен җанына тынычлык таба алмавы тикмәгә генә булмаган... Хикмәт менә нәрсәдә икән — Габделбәрнең башын ярганнар!

Их, тормыш, тормыш! Әле башланмас борын ук нигә син миңа шундый мәрхәмәтсез булдың икән? Ничәмә-ничә еллар янып-көеп, өзгәләнеп, көтеп алган бәхетемне күпсендең икән? Разыя шундый уйлар эчендә өйгә кайтып керде. Кызу мич тирәсендә кайнашып йөргән Асылбикә түти шундук кызының янына килеп басты:

— Чү! Балакаем, ни булды сиңа? Бер генә дә төсләрең калмаган ич,— диде ул гаҗәпләнеп.

— И-и-и, әни бәгърем... Габделбәрнең башын ярып ташлаганнар ди бит әле.

— Кит инде... Кайчан? Кайда? Кемнәр?

— Кичә кич, безнең турыда... Мәһирлар...

— Әй, аллам! Сизенүләрең дөрес булган икән, балакаем. Хәле ничек ди соң? Хәле...

— Авыр, бик аяныч ди аның хәле! Булмаса, мин, әни, эшкә барышлый (кыз колхозда хисапчы иде) медпунктка кагылыйм әле. Бәлки...

— Бар, кызым, хәзер үк бар! Кара инде, һич уйламаганда, һич көтмәгәндә...

— Зарифулла-Гасыйм абый (авылда яшьләр Габделбәрнең әтисен шулай атап йөртәләр иде) каладан самолет та чакырткан инде... Медпункт каршындагы яланны кардан Габделбәрнең абыйсы тракторы белән чистарта икән! Аннары анда зур итеп учак ягып куячаклар икән, самолет турылап төшсен өчен!

Разыя кинәт кенә башын күтәреп, яшь белән мөлдерәмә, карлыгандай елтыр кара күзләрен әнисенә төбәде.

Асылбикә түти кызының бу карашыннан: «Минем абыем да очучы булган бит»,— дигән сүзләрне укыды, һәм ун ел элек, океан өстеннән очканда һәлакәткә очрап юкка чыккан улының шулай бервакыт ерак авыллардагы авыруларны шәһәргә илтеп йөрүләрен хәтерендә яңартты. «Ул чакта мин дә бардым,— дип уйлады Асылбикә түти.— Рифнурның гәүдәсен җиде көн эзләгәннәр, таба алмаганнар. Һәм ни үкенеч: шуннан бирле мин океан-диңгезгә генә түгел, кояшлы Идел-Кама өстендәге дулкыннарга да тыныч күз белән карый алмыйм. Шуларга төбәлдемме, колагыма акчарлакларның гүя сулкылдап елаган тавышлары килеп керә дә җаннарым актарыла, бәгырьләрем өзелә».

Асылбикә, авыр хисләреннән айнып, кызының иңнәренә орынды:

— Ярый, балам, бар, бар! — диде.

— Рәхмәт, әни!

...Карның җете аклыгыннан күзләр чагыла. Юл беленми дә диярлек. Көчле бураннан соң тирә-юньне искиткеч тынлык баскан. Тынлык иңнәргә кагыла, гәүдәне баса сыман. Шул мәлне йомшак ак карга ятып ауныйсы, үксеп-үксеп елыйсы килә. Әмма ярамый, бирешмәскә, нык булырга, иң мөһиме алга, фәкать алга гына барырга һәм курыкмыйча хәрәкәт итәргә кирәк.

Разыя, күпергә кермичә, елга аша турыдан гына суктырырга исәпләп куйды. Болай якын якынын да, ләкин тау күтәрелүе авыр. Бу

тирәдә тау биек һәм текә. Хәер, яшь кеше өчен мондый тау күтәрелү файдага гына ул!

Боз һәм кар каплаган елганың яртысына житәрәк, Разыяны һич көтмәгәндә сабакташы — Нәкыя куып житте. Аяклары камыт, бүе кечкенә булса да, тавышы, сөбханалла, көр иде үзенең. Һәм ул тәскә-биткә дә ярыйсы гына чибәр иде. Габделбәр кайчандыр шул кызга гашыйк иде бугай. Әйе, камыт аяклы ул кыз, гәүдәгә бәләкәй булса да, шактый ук чая, житмәсә, яхшы укый, жыр-биюгә дә бик һәвәс, эш рәтен дә бик белә иде. Кыска гына итеп әйткәндә, ут та ут, ул да ут иде инде.

Унны бетергәч, калага китеп, сәүдә училищесында укып чыккан да, ниндидер кибеттә сатучы булып эшли башлаган. Аннары, читтән торып техникум, соңыннан институт тәмамлаган. Хәзер ул зур бер кибетнең директоры ди бугай.

Менә шул директор ханым, ягъни Разыяның элекке сабакташы, куып житте дә, калын, көр тавыш белән, әллә кай вакыттагыча күңелле генә итеп:

— Исәнме, малай! Кая, медпунктка юл тотасыңмы? — дип сорады.

Разыяның: «Юк... эшкә...» — дип әйтәсе килгән иде. Ләкин колхоз идарәсенең бу тарафта түгел икәнлеген исенә төшереп, тыелып калды. Аннары:

— Әйе, медпунктка барам... Грипп эләктердем, ахры, авырыйм, миңа яраклы дару-фәлән булмасмы икән анда, — дип жавап кайтарды.

Дөресен генә әйткәндә, Разыя камыт аякны өнәми иде.

— Медпунктта «главный» кем анда хәзер? Зөбәйдәме? — дип төпченде Нәкыя.

— Кем булса да сиңа барыбер түгелмени!

— Мине күбрәк Зөбәйдә кызыксындыра шул! Бит ул йә әтисе шикелле сәүдә юлын, йә әнисе сыман укытучылыкны сайларга тиеш иде кебек... Ә ул менә тотты да медучилище тәмамлады, хәзер әнә мединститутта укый икән. Афәрин! Молодец! Габделбәр юкка гына: «Зөбәйдә! Зөбәйдә!» — дип, утка пешкәндәй, чабып йөрми икән аның артыннан, ай-һай, сәләтле кыз булып чыкты ул!

— Харап инде... бик кыра-а... — диде Разыя көнчелегеннән иреннәрен турсайтып. — Укол кадаса — кан чыгара, жәрәхәтне сүтеп, майлап, бәйли башласа, кешеләрне кычкыртып елата. Шул да булдымы сәләт?!

— Әйе, сәләтле-е, бик сәләтле-е, — дип үз сүзен итте камыт аяк. — Ул районыбызда, бәлки, районыбызда гына да түгелдер... беренче врач булачак әле!

— Ә-ә... белдем! Син, күрәсең, база директоры белән типтереп корсак тутыргансың да, авылга кайтып, Зөбәйдә янына аборт ясатырга баргансың! Күпме түләдең соң? Әллә бушка гына ясадымы?

— Син ул... син... колхоз рәисе белән типтереп, колхозны бөлдереп, талап ятасың... Мин кияүдәге кеше... балам бар!.. Син менә үзең...

Директор ханымның сүзен бүлеп, Разыя янә кычкырып жибәрде:

— Ә-ә... валюта белән түләденмени-и! Түләрсең дә шул: кала халкына дигән импорт товарны, кибет складыннан сатуга чыгармыйча, итәк астыннан гына кыйммәт бәягә уңлы-сулы шудырып яткач!

— Күрдеңме-е? Тоттыңмы-ы? Ах-мак!

Разыя үзен-үзе белештермичә сабакташына ташланды.

— Кем ахмак? Күрсәтермен мин сиңа...

Шулвакыт алар каршына каяндыр әзмәвер бәдәнле Нәгыйм килеп чыкты.

— Әй-й... туктагыз! — дип, тамак ертып кычкырып жибәрде ул. — Укымышлы гына кыз балалар үзегез, ә надан авыл хатыннары шикелле тукмашып ятасыз, понимаете... — һәм ул сабакташлар янына ук килеп басты. Нәгыймнең йөзе чөгендердәй кызарып чыккан, ә авызыннан бөркелеп колмак балы исе килә иде. — Анда әнә Габделбәрне алып китәргә самолет төшкән иде. — Нәгыйм исән кулы белән медпункт

ягына таба ишарәләп күрсәтте. — Озатып калырга күп кеше килгән... Ә сез монда...

...Медпункт тирәсен сырып алган халык, икегә аерылып, Разыяга юл бирде. Ни әйтсәң дә Разыя аппарат хезмәткәре бит, халыкчан итеп әйткәндә, үзенә күрә урындагы кеше.

Менә, пөхтәләп көрәлгән сукмак буйлап, кыз ишегалдына керде. Сөрмә тарткан озын керфекле күзләренә Габделбәрнең төрле кыяфәттә басып торган туган-тумачалары чалынып калды. Кыз соңгы көчен туплап эчкәре узды. Монда да кеше күп иде: Сания әби, Тамара, Габделбәрнең әти-әнисе, сеңлесе, карчык-корчыклар...

Разыя Сания әби белән баш кагып кына исәнләшкәндәй итте. Карчык та кызның сәламен алган сыман җинелчә генә ияк кагып куйды.

Әнә, каршы бүлмәдән носилка күтәреп чыгучы ак халат кигән кешеләр күренде. Носилкада күзләре йомык Габделбәр ята. Ә носилка янәшәсендә, кайгысыннан бик ватылган һәм таушалган кыяфәт белән, Зөбәйдә атлый. Ул Разыя-кендәшен күрмичә дә үтеп китте.

Разыя ниндидер яшерен өмет белән төркем артыннан юнәлде. Иң алдан киң җилкәсенә ак халат элгән врач ир бара иде.

Урамга чыккач, төркем ишәйде, зурайды, тулы бер агымга әверелде. Тирә-якта акырын гына сөйләшкән, пышылдашкан тавышлар ишетелгәләп куйды.

— Исән калыр микән, мескенем?

— Врач нәрсә дип әйтте икән соң?

— Хәзер калага алып китәләр микәнни?

— Күрәсең ич...

Вертолет янында кемнәрнеңдер басып торганы шәйләнде. Разыя өлгерә алмый калды, борыны төбендә генә тимер ишек шапылдап ябылды.

— Әй! Ник яптыгыз? Ачыгыз! Мин дә барам бит...—диде кыз боерган сыман итеп. Һәм ике-өч тапкыр ишеккә төртеп алды. Ләкин,.аңа җавап урынына, төркем арасыннан берәү:

— Калага барасың килсә, юлга җәяү чык... Элек безнең әби-бабайлар салган эздән, кәҗә сукмаклары буйлап!—диде.

Бу, һичшиксез, баягы камыт аяклы сабакташының тавышы иде.

* * *

Кызыл билле вертолет күкне дер селкетеп килде-килде дә, РКБ каршындагы урман турысына җитәрәк, ак түшен ялтыратып түбәнәя башлады. Аннары тизлеген киметеп, төшеп утырды.

Нәкъ шулвакыт Казан юлы өстендә туктап калган яшел танк янында басып торучы, каракүл папаха кигән бер полковник һәм өч-дүрт офицер яныннан сирена улатып, уктай атылып кызыл билле машина үтеп китте һәм... вертолетка җитәрәк туктап калды.

Бер үк вакытта диярлек машинаның да, вертолетның да ишеге ачылып китте һәм алардан ак халатлы кешеләр коелды. Вертолеттан чыккан кешеләрнең кулларында носилка бар иде. Носилкада, башы ак бинт белән бәйләнгән, гимнастерка кигән бер егет ята иде... Солдатны машина янына китергәндә, вертолеттан бер кулына төенчек, икенче кулына бәләкәйрәк чемодан күтәргән кыз чыкты. Аның башында төлке бүрек, өстендә чия төсендәге пальто, пальтода төлке яка, аякларында шундый ук чия төсендәге сапожкилар иде.

Кызның кара кыска чәчләре күпереп, бөдрәләнеп тора. Киң ак маңгай, кыйгач кашлар, акыллы, уйчан, сабыр караш. Килешле генә нәфис борын, табигый алсу иреннәр—кыскасы, һәркемнең игътибарын җәлеп итәрдәй, һәркемнең күңелендә җылы хисләр уятырдай күркәм кыз иде бу.

Кыз вертолеттан төшеп баскач, күзләренә мизгел арасында тирә-юньдәге табигать күренешләре чалынып узды.

Иң элек аксыл күктә балкыган якты, ләкин салкын кояш. Аннары түбәндә генә йөзгән кәфендәй ак болытлар. Шул тарафка китеп күк белән тоташкан сыман тоелган иксез-чиксез кар чүле. Уңъякта — шәрә кара урман. Ә сул тарафта — күпкатлы яшел-ак йортлар — РКБ бинаилары, аларга каршы якта, авыл өйләрен хәтерләтеп тезелешкән агач йортлар, моржалардан бормаланып чыгучы аксыл төтен һәм... аннары кызның карашы носилкада яткан ап-ак йөзле солдат егеткә төште. Кыз солдатка текәлеп-текәлеп карады. Әмма ул күпме генә карамасын, егетнең сулавын сизмәде. Кызның иреннәре калтыранып китте.

Озын буйлы, күзлекле яшь врач носилканы каршы алды. Аннары доктор кушуы буенча, сумкасыннан нәрсәләрдер чыгарды, ниндидер приборлар белән мәтәште, ниһаять, интәшенең ярдәме белән егеткә укол ясарга керешт. Бу эшне ул беркемгә дә илтифат итмичә, үзалдына гына текәлеп, игътибар белән башкарды. Эшен төгәлләгәч, приборларын җыештырды, сумкасын бер читкә алып куйды. Ләкин солдатта һаман да җан әсәре сизелмәде.

«Бәлки ул исәндер, аның йөрәге тибәдер. Бу укол аңа шулай хәрәкәтсез ятсын өчен, авыртуны сизмәсен өчен бирелгәндер...»

Доктор кызны уйларыннан бүлдерде, аңа машинага утырырга кушты. Кыз кереп, күзлекле яшь врач янына утыруга ук машина җәһәт кенә кузгалып та китте.

Ниһаять, машина тугыз катлы һәм галәмәт озын яшел бинаның «Ашыгыч ярдәм» дип эре кызыл хәрефләр белән язылып куелган турыда, ишек каршында туктады.

«Тизрәк... тизрәк...» — дип эчтән генә ашыктырып типте кызның йөрәге. Доктор машина ишеген ачты. Аның авыр гәүдәсеннән кабина чак кына янтаеп куйды һәм доктор, яшьләргә хас житезлек белән, җәһәт-җәһәт атлап, бина эченә кереп югалды. Тиздән ул ак халатлы юантык хатын белән әйләнеп тә чыкты.

— Кая урнаштырыйм? Коридорда да урын юк ичмаса,— диде хатын, докторга инәлеп.

— Милый мой-й-й... Саимә Абдуловна-а...— диде Рәхим Фәһимович.— Һәм ханымга, үзенең хаклы булуы турында әйтеп, кызып-кызып дәлилләр китерә башлады.

Ләкин Саимә Абдуловнаның үз туксаны туксан иде. Өстәвенә, бүген үзәк хастаханәнең авырулар кабул итү көне дә түгел икән. Ә Рәхим Фәһимович таләпчән төстә «һөҗүм» итүен белде. «Солдат егетнең хәле авыр, аны ничек тә коткарып калырга кирәк»,— диде.

— Урын юк бит, бүтән больницага алып китегез,— диде Саимә Абдуловна һаман үҗәтләнә бирел. Күренеп тора: аның Рәхим Фәһимовичка каны каткан, алар арасында кайчандыр кара мәче йөгереп үткән булса кирәк. Ләкин бу мизгелдә, яшь кеше гомере кыл өстендә генә асылынып торганда, шәхси үчкә урын булырга тиешме инде?

— Ну-у сине-е...— диде Рәхим Фәһимович кулын селтәп. Аннары яшь врачларга:— Артур, Роберт... Операционныйга живо! Живо! — дип боерды.

Кызның күзләренә тансык яшьләр бәреп чыкты. Артур белән Роберт авыр яралы егетне ишектән алып кереп киттеләр. Алар артыннан кыз да, авырулар кабул итү бүлмәсендә кизү торучы врач ханым да керде.

Керү белән үк кызның борынына әллә нинтән дару исләре килеп бәрелде. Шул мизгел мәрмәр плитә җәелгән тигез, шома иденле коридор буйлап, докторның бирегә таба ашыгып килүе шәйләнде. Егеткә операцияне, тәвәккәлләп, ул үзе ясый икән... Менә доктор кызны юатып, аркасыннан кага-кага, аның врач һөнәрен сайлавын да исенә төшереп, ныклы торырга кушып, олы гына ханым каршына утыртты да тиз-тиз генә

күздән югалды. Анда аны хирургиянең шәфкать туташлары яңадан киендереп, операциягә әзерләргә тиешләр инде.

Кыз уйчан, сагышлы йөзле шәфкать туташына кайдан килүен, кем булуын, яралы егеткә нинди мөнәсәбәте барлыгын һәм егетнең ни сәбәпле яралануын, дулкынлануы аркасында өзек-өзек итеп кенә сөйләп бирде. Ханым кызны бүлдермичә генә, ихлас рәвештә тыңлады, кирәклеләрен теркәп куйгач, никель кысалы күзлеген салып:

— Шәһәрдә туганнарыгыз бармы соң, акыллым? — диде.

— Мөмкин булса, мин биредә генә калып торыр идем, апа!

— Белмим, йокларга урын табып булмас, акыллым! Авырулар күп бит хәзер, ай-һай, күп! Элек болай түгел иде...

— Ә мин йокламыйм, апа. Мин аны саклармын.

Шәфкать иясе чынлапмы, дигәндәй, кызга теләктәшлек иткән кебек текәлеп карап куйды да, теге башта идән юып яткан түтигә эндәште:

— Хәбирә апа-а!

Түти киндер мунчала таягын диварга сөяп куйды, чаларган маңгай чәчләрен яулыгы эченә кертеп, бирегә таба килә башлады.

— Менә бу кызны урнаштырыгызчы?

Түти шып туктап, халат кесәсенә тыгылды һәм аннан тимер йөзеккә кертеп урнаштырылган ачкычлар алып кызга ым какты:

— Әйдәгез!

Хастаханә хезмәткәрләре телендә «подвал» дип аталган, лампалар белән яктыртылган галәмәт озын — уң якка да, сул тарафка да китеп барган һәм монда беренче мәртәбә эләккән кеше аның кая илтеп чыгарасын белә алмый торган серле коридор иде бу. Коридор диварына «бомбоубежище» дип язылган. Аннары кайсы блок кирәк булса, шул блокның чишенү-киенү бүлмәсенә, болай таба барыгыз дигәндәй, кызыл уклар төшерелгән.

Монда азык-төлек, яшелчә, кием-салым, җиһазлар, дарулар склады да, аш-су әзерләү бүлмәләре дә, лифт хезмәте инженерлары механиклары өчен, электротехниклар, сантехниклар, слесарьлар, балта осталары өчен дә бүлмәләр дә бар иде.

Зөбәйдә, адашмагаем тагын дигән сыман, Хәбирә түти белән гел янәшә атлап барды. Хәбирә түти сөйләшми, авыз эченнән генә моңлы бер җырны көйли дә көйли:

. . . . . . . . . . . . алдылар
... үтереп суга салдылар,
Кабан күле гел кан иде!

Зөбәйдәнең кычкырып елыйсы килде. Ул йодрыкларын кысты һәм иреннәрен тешләде...

— Эй! Дарога-а?

— Тет Хабира! Не слышишь что-ли?

Икесе дә гайре-табигый хәлләренә кайтты һәм, читкә авышып, иртәнге ашны алып китеп баручы хатыннарны үткәреп җибәрде.

Чит телдә яңгыраган боеру авазларыннан соң, Хәбирә түти җыр көйләвен һәм моңлануын онытты, ничектер кечерәеп калды сыман... Зөбәйдә Хәбирә түтине кызганып куйды. Ләкин үз хәле дә шундый булуын уйлап, эчтән тынды...

Шулвакыт кемдер аңа йомшак тавыш белән эндәште:

— Нихәл, Зөбәйдә! Практика үтәргә җибәрделәрме әллә?

Кыз борылып караса, каршысында Сания әбинең малае Илһам басып тора. Өстендә кардай ак халат, аякларында тапочка. Чәчләре җитүле, кырынмаган. Зәңгәр күзләре кысыла төшкән һәм кызарып тора. Күз төпләренә яшькелт капчыклар асылынган. Ә үзе, гаепле кеше сыман, кыяр-кыймас кына елмаеп маташкан була.

— Чү! Илһам абый? Күземә күренәме әллә дип торам... Каян килеп чыктың син монда?

Илһам тыенкы гына көлеп куйды.

— Дөнья булгач... чыгасың икән аны...

— И-и-и... авырып ятасыңмы дисәм, өстеңдә ак халат, эшлисең дисәм...

— Ие, эшлим,— диде Илһам.

— Кем булып? Врач булыпмы әллә?

— Һә... врач булып эшләү өчен укырга кирәк бит! Ә мин белемем буенча сәүдә кешесе. Лифт йөртәм мин.

— Ә-й... кһы... Сине, Илһам абый, ялгышмасам, кайдадыр инженер булып эшли дигәннәр иде шикелле...

Илһамның йөзенә куе кызыллык җәелде, ул дәшмәде. Шул мизгел аңа кычкыра башладылар:

— Ильгам, милый, ну, давай, быстрее...

— Эй! Что ты там... уснул что ли?

— Не видишь что-ли? В любви объясняется!

— Ильгам? Скажу жене!

— Час... иду-у! — дип кычкырды Илһам. Аннары Зөбәйдәгә таба борылып, гаепле төстә, кулларын җәеп җибәрде: — Бернишләп тә булмый. Ашыктыралар! Син китмисеңдер ич әле?

— Юу-ук!

— Алайса, ундүрт-ике йөз сиксән дүртенче номерлы лифтка кил, мин шунда булырмын.

— Ярар...— дип баш кагып куйды Зөбәйдә, теләр-теләмәс кенә.

Илһам абыйсы «выход» дигән аралыкка кереп күздән гаип булгач, Хәбирә түти:

— Кемең ул синең? Танышыңмы әллә? — дип сорады.

— Авылдашым! — диде Зөбәйдә.

— Һәй...— дип кулын селтәде Хәбирә.— Аю хәтле гәүдәсе белән лифтта эшләп йөрмәсә, ни эше, ни акчасы дигәндәй...

Зөбәйдәгә авылдашы өчен уңайсыз булып китте. Ярый әле бу түти Илһамның әнисе янына да кайтып йөрмәвен, бертуган абыйсы, апасы, энеләре белән дә аралашмавын белми... Белсәме әгәр?!

«Гардеробная» дип язылган зәңгәр ишекне ачкач, түти Зөбәйдәгә:

— Кер, сеңелем,— диде.

— Кыз, чишенү бүлмәсеннән чыккач, баскычтан беренче катка күтәрелде, уңга борылды һәм мәрмәр плитәле коридор буйлап бара-бара икенче блокның «Травматология» бүлегендәге беренче палатаны эзләргә кереште.

Бередә, күзлекле ханым әйткәнчә, коридорда яткан бер генә авыруны да очратмады Зөбәйдә.

Һәммә урын тыныч, пөхтә һәм чиста иде.

Беренче палатаны ул тиз тапты. Шакып баккан иде, җавап бирмәделәр. Шуннан соң кыз ишекне үзе ачып керде.

Монда — сынып имгәнүчеләр ята икән. Кайсының — аягы, кайсының кулы — гипста! Кыз кычкырып исәнләште, ләкин аңар такыр башлы бер үсмердән гайре эндәшүче булмады. Әйе шул: барчасының да үз кайгысы кайгы, үз хәсрәте хәсрәт!

— Сезгә кем кирәк?

Кыз йомышын әйтеп бирде. Үсмер, такыр башы белән уң як дивар ягына ымлап күрсәтте. Зөбәйдә шундагы буш койкага карап атлады. Ашамлыкларны тумбочкага бушатты. Аннары койканың мендәрен кабартты, ак җәймәнең чит-читләрен әйбәтләп матрац астына кыстырды һәм, ничек тиз кергән булса, шулай тиз чыкты да... Анар хәзер операция бүлмәсенә барып, Габделбәрнең хәлен белергә кирәк иде.

Ул барып җитә алмый калды, аны арбага салып, тартып киләләр иде инде.

Зөбәйдә, салкын суга кергәндәй, сулышы буылып, чак кына кычкырып җибәрмәде, исен җыеп авызын каплады. Аннары, ишек төбенә

чыгып баскан Рәхим Фәһимовичның тыныч күз карашыннан куркырлык нәрсә юк икәнлеген аңлап өлгерде.

Габделбәр кулларын күкрәгенә кушырып ята. Күзләре эчкә баткан, сулыш алуы беленмиме дә диярлек. Борынындагы тир тамчылары гына аның исән икәнлеген белдерәләр иде.

Берсе сары, икенчесе кара чәчле яшь шәфкать туташлары, күндәм эш атлары сыман бернигә исләре китмичә, 14284 нче номерлы лифт янынннан үтеп, арбаны теге тарафка таба алып бара башладылар. «Димәк, икенче блоктагы лифт белән менәргә туры киләчәк икән! — дип уйлады Зөбәйдә.— Чынлап та, «травматология» бүлеге икенче блокка урнашкан шул! Ә Илһам абыйны кайчан күрәм соң мин? Аның белән кайчан сөйләшәм? Сания әбинең сәламнәрен кайчан тапшырам?! Хәер, вакыт булыр әле, очратырмын...»

Авыруны баягы шәфкать туташлары койкага сак кына яткырып, палатадан чыгып киткәч, егетнең хәлен белер өчен Рәхим Фәһимович үзе керде. Кыз «миһербанлы» хирургның кул хәрәкәтләрен, йөзендәге һәр сызыкны, күзләрендәге һәр үзгәрешне тын да алмыйча күзәтте.

— Су эчермәгез,— диде врач җитди итеп.— Операциядән соң ук су эчерергә ярамый. Монысын инде син үзең дә беләсең, сеңелем. Дымлы марля белән иреннәрен генә чылатып торырга мөмкин.

...Зөбәйдә Габделбәргә таба иелде. Ул янә аның күкрәгенә кушырган кулларына, балавыз төсе йоккандай сары йөзенә, эчкә батып торган күзләренә, маңгаендагы канлы бәйләвечкә озак кына текәлеп карап торды. Баягы такыр башлы үсмер исә, колагына бәләкәй аппарат куеп, транзистор тыңлап яткан килеш, күз кырые белән генә әлеге чибәр кызга илтифат итте. Йөзенең киеренке төстә булуы аның эчке кичерешләре каршылыклы вә буталчык икәнлеге турында сөйли иде сыман. Чынлап та ул бу минутта Зөбәйдә турында болай дип уйлый иде: «Бу сөйкемле, мәртәбәле кыз бәхетсезлеккә тарган ошбу солдатның сөйгән кызы, яисә хатыны, яки сеңлеседер... Юк, сөйгән кызы түгелдер. Хәзерге заманның «түземсез» кызлары хастаханәгә килеп, бәхетсезлеккә очраган солдатның баш очында фәрештәдәй саклап утырмаслар! Бу, мөгаен, бу ир-егетнең сөяркәседер!»

Зөбәйдәнең исә бу минутта үз хәле хәл иде. Ул сөенергәме-сөенмәскәме, еларгамы-еламаскамы икәнлеген тәгаен генә белми иде.

Елар иде — Габделбәр исән, сөенер иде — Габделбәр әле аңында түгел. Шулай да бер нәрсә ачык: Габделбәр менә биредә ята, аңа катлаулы операция булды, ул сулый, ул озакламый тереләчәк!

Шуларны уйлагач, Зөбәйдә чак кына тынычланып китте. Аннары, иртән авылда Разыяның вертолетка утырырга маташуын искә төшереп, елмаеп җибәрде.

...Зөбәйдә төнозын Габделбәрнең баш очында утырып, саклап чыкты.

Кичке якта ашханәгә чакырдылар, анда да бармады. «Авырулар өлешенә кермим әле»,— диде.

— Нишләп авырулар өлешенә керәсең ди... Үз өлешеңне ашыйсың ич син анда! — диде «травматология» бүлегенең кизү торучы шәфкать туташы.— Менә без барыбыз да үз бүлекләребезнең ашханәсендә тамак ялгап алабыз ләбаса. Җитә. Әле артып та кала. Авырулардан артып калган азыкны аш сосучы хатыннар, икешәр-өчәр чиләк итеп, йорт хайваннарына алып китәләр. Бар, бар, ашап кил!

— Юк! — диде Зөбәйдә, катгый баш тартып.

— Шәфкать туташы да бүтәнчә кыстамады. Бары тик:

«Уколны үзең кадамыйсыңмы соң?» — дип сорады. Ул, күрәсең, Зөбәйдәнең авылда шәфкать туташы булып эшләвен кемнәндер ишетеп белгән иде.

— Ярый инде үзегез кадагыз,— диде Зөбәйдә.
— Мәйлең алайса.

Сестра укол кадаганнан соң, Габделбәрнең беләгендәге кан тамырына олы гына шприц энәсе кертте дә, шул энәгә «система» шлангасын тоташтырды. Егетнең канына әкрен-әкрен генә витаминлы дару агып керә башлады. Озакламый Габделбәр телен ялагандай итте, ыңгырашып куйды. Зөбәйдәнең эченә жылы йөгерде.

Шулвакыт санитар түти, палатага кереп, тумбочка өстенә кечкә аш китереп куйды. Син ашамасаң, ул (ягъни, Габделбәр) ашар, дигән мәгънә белгертә иде кебек түтинең карашы.

Кич иде инде. Барысы да йоклыйлар. Тик кемдер, йокы аралаш, сызланып, ыңгырашып куя. Кемдер саташып сүгенә. Ә кайсысыдыр, янына килергә чакырып, иркә сүзләр белән якынына эндәшә.

Ә Зөбәйдә, тагын бер мәртәбә тикшереп, сөйгәненең йоклый икәнлегенә ышангач, палатадан чыкты һәм коридорга таба юнәлде. Аңа хәрәкәтләнергә, аякларын язып алырга кирәк иде. Шәфкать туташы аның артыннан:

— Озак йөрмә! Сәгать унда ишекләрне биклибез,— дип калды. Зөбәйдә ишеткән иде инде: кайвакыт больницага җинаять группасы әгъзалары үтеп керә икән. Ә бер көнне балта күтәргән исерек ир төнозын баскычтан баскычка киләп-сарып йөргән. Юлына очраучыларга: «Хатынымны эзлим! Кайда ул?» — дигән. Шулай итеп, шул имансыз исерек ир шәфкать туташларын, врач хатыннарны куркытып бетергән. Хәзер дә шикләнәләр әле, кичләрен берәү дә баскычтан төшеп-менеп йөрми, барысы да ашыгыч ярдәм бүлегендәге лифтка бара икән.

...Ундүрт тә ике йөз сиксән дүртенче номерлы лифтның килеп житкәнен озак көтәргә туры килмәде кызга. Менә, ниһаять, лифтның ишеге ачылып китте. Ишектә Илһамның зур башы күренде.

— Чү! Зөбәйдә? — диде Илһам гаҗәпләнеп.
— Ие, мин! — диде кыз елмаеп.
— Әйдә, уз, утыр...
— Ярар, монда гына сөйләшеп торсак та... Мин озакка түгел!

Илһам нидер сизгән сыман, башын гаепле төстә түбән иеп, әйтеп куйды:

— Әнине син карыйсың икән, син тәрбия кыласың... Рәхмәт! Ләкин кешеләр авылда мине яманлап сөйләмәсеннәр. Мин гаепле түгел...

Зөбәйдә, Илһам абыйсының кая таба салулап китүен, нәрсәгә ишарәләвен шундук аңлап алды. Үзенчә, авылга кайтып йөрмәгәне һәм әнисен карамаганы өчен акланып маташуы инде бу аның. Ләкин хикмәт тә шунда шул: һичничек аклап һәм аңлап булмый Илһамның бу миһербансызлыгын. Хәер, бер Илһамныкын гынамы икән әле!

— Сине минем белән сөйләшергә әни җибәргәндер инде,— дип дәвам итте Илһам сүзен.— Әнинең хәлен аңлыйм мин. Әмма аның миннән тыш алты баласы бар икәнлеген дә истән чыгармаска кирәк...

— Салисә ападан кала, берәү дә кайтып йөрми шул әби янына,— диде Зөбәйдә, Илһамның нилектәндер кызарган күзләренә туры карап.

— Менә, менә! — дип, Илһам бармагы белән Зөбәйдәнең ике каш уртасына таба төртеп күрсәтте.— Җавабын үзең әйтеп күрсәттең инде, сеңелем. Хәзер мин дә сиңа кайбер нәрсәләрне аңлатып бирим әле... Әти үлгәннән соң, әни бөтен байлыкны Салисә апа кулына тапшырды. Бу булдымы — бер. Икенчесе. Мин кунакка түгел, үземнең туган йортыма, әни янына, әнигә булышырга кайткач, Салисә апаның унбиш яшьлек кызы әйтеп салмасынмы: «Син монда кайтып хозяйничать итеп йөрмә әле... Бу домга без хуҗа, син түгел!» Егылып китә яздым, Зөбәйдә сеңелем. Хурлыгымнан утырып еладым хәтта. Мин бит аңлыйм, башсыз малай түгел: бу сүзләрне апаның унбиш яшьлек кызы әйтмәде, аны котыртканнар шулай әйтергә, аны йә әни, йә апа котырткан, икесенең берсе... Ни өчен мин мондый кискен карарга килдем? Шуның өчен, чөнки,

ул вакытта мин апаның кызын эт итеп әрләп маташканда, әни миңа бик авыр сүзләр әйтте, апаның кызын яклап... Өченчесе. Мин әни алдында, кем әйтмешли, чәчем белән идән себерсәм дә, аңа ярый алмыйсымны аңладым. Ул барыбер миннән читләшәчәк һәм бары тик апаны гына кайгыртып, апаны гына баетып яшәячәк. Монысына минем иманым камил! Менә шуннан соң, сеңелем, матди тәэмин ителешкә тукталыйк.— Апаның авызы тулы алтын теш, бармагы саен алтын йөзек, колакларында ахак кашлы алтын алка... Шкафлары да чит илләрдә эшләнгән кием-салым белән шыплап тулган, суыткычы да тәм-томнардан сыгылып тора! Каян алган ул аларны? Һәм аларны сатып алырга ул тамаша акчаны каян алган? Мин беләм, аңа... әни биргән!

— Салисә апа бит ашханә буфетында эшли! — диде Зөбәйдә тыныч кына итеп.— Баерга теләгән кеше өчен менә дигән төшемле эш инде ул!

— Эш-ли-и...— диде Илһам ачуыннан буылыр дәрәҗәгә җитеп.— Күпме эшли соң ул анда? Күп булса... өч... дүрт ел... Ә бит ул ун ел буе ипи сату идарәсендә бухгалтер булып, йөз тәңкәлек хезмәт хакына көн күреп яшәгән кеше. Һәм ничек итеп ул тиз арада гына шундый хәзинәгә ирешсен, ди?! Ә менә мин егерме ел буе тир түгәм, көн-төн тырышам, тырышам... юк, байый алмыйм... Менә, өстемдәге күлмәк, чалбар, ботинка — һәммәсе дә әтинеке. Ләкин әти үзе дә, мәрхүм, район хастаханәсендә үлгәннән соң гына калдырды миңа бу нәрсәләрне.

— Ник син, Илһам абый, һаман ата-ана малына гына өметләнеп яшисең, малны үзең тапмыйсың? Син бит ир кеше... Сиңа күп акчалы эшкә, заводка кереп эшләргә кирәк!

— И сеңелем, эшләмәгән кая, заводында да эшләдем, кибетендә дә, базасында да, төзәтү-көйләү остаханәсендә тәэминат инженеры булып та, урам себерүче булып та... Ләкин мин алдаша һәм урлаша белмим шул. Минем менә... монда кереп эшли башлавыма, врачларның дөньяда иң гуманлы һөнәр әһелләре булуы сәбәптер, ахры. Аннары мин дөньяда, илебездә һәм республикабызда барган кискен вакыйгаларны, четерекле хәлләрне вә капма-каршы төркемнәрнең «портфель» өчен гадел вә гаделсез көрәштә ни өчен җиңү яки җиңелүләренең сәбәпләрен, менә шушыннан, РКБдан торып, аңларга һәм анализларга теләдем... Мин майлы буяулар белән киндергә рәсемнәр төшерәм. Мин һәвәскәр рәссам бит! Әнә... Травматология бүлегенең диварларындагы картиналарны карап чыга аласың...

Зөбәйдә соклануыннан һәм сөенеченнән, кайда басып торуын да онытып, кычкырып җибәрде:

— И Илһам абый-й! Син ясадыңмыни аларны? Чынлап та гаҗәеп бит алар! Искиткеч!

Илһам ялт итеп Зөбәйдәгә карап куйды.

— Сиңа, сеңелем, берәрсе әйттеме ул картиналар турында? Әллә үзең очраклы рәвештә генә барып эләктеңме ул травматология бүлегенә?

Зөбәйдә Габделбәр белән булган фаҗигале хәлләрне кыскача сөйләп биргәч, Илһам шаккатты. Башын тотты. Аһ-ваһ килде. Аннары, ниһаять, үзен кулга алып әйтте:

— Иртә белән автобуста очраткан идем бит мин ул дуңгызны! Очраткан идем!

— Автобуста очраткан идем дисеңме, Илһам абый-й?!

— Әйе, очраткан идем! Әле мин аны өйгә, безгә килергә дә чакырдым, баш тартмады, киләм! — диде. Болай булгач килмәсен, кирәге юк!

— Ярый, китим инде мин...— диде Зөбәйдә, күңелсезләнеп.— Сәгать ун тулып килә... Ишекне бикләп куярлар җә... Палатага керә алмыйча интегеп йөрермен!

— Юк! Интекмәссең...— диде Илһам үз-үзенә нык ышанган кыяфәт белән.— Икенче блок лифтының ачкычы минем кулда! Гомумән, кич белән бөтен лифтларның да ачкычлары минем кулда була. Син барып

житкәнче ишекне бикләп куярга өлгерсәләр, аптырап торма, туп-туры минем янга кил, өченче катка момент менгереп куярмын.

— Рәхмәт,— диде Зөбәйдә,— ишек бикле булса, килермен! — Аннары кыз Илһамга текәлеп карады: — Син нигә сакал-мыегыңны кырмыйча йөрисең, абый, болай килешми бит үзеңә.

Илһам кулы белән яңагын учлады һәм бармакларын йөзе буйлап шуыштыра-шуыштыра сакал-мыегын капшарга кереште.

— Вакыт ягы бик кысан шул... Йә, ярый, анысы вак мәсьәлә... Син, Зөбәйдә, безгә дә килгәлә. Бөтенләй үк чит кеше түгел ич без сиңа!

— Рәхмәт, рәхмәт...— диде кыз һәм сулъяк коридорга китеп югалды.

«Абыйның беренче хатынының кызы, шәп кыз! — дип уйлады Илһам Зөбәйдә турында.— Чынлап та ул безгә бөтенләй үк ят түгел ич. Килсен фатирга! Килгәләп йөрсен... Кем белә, бәлки, ул мәрхәмәтле кыз аша без җиде бертуган арасына күпер салыныр... Кем белә?»

Зөбәйдә палатага әйләнеп кайткач, Габделбәрнең шабыр тиргә батып ятуын күрде. Егет вакыт-вакыт ыңгырашып та куя иде. Ләкин шунысы яман: уянмый, нилектәндер һаман уяна алмый иде ул.

Зөбәйдә йокымсырап китте. Аның күз алдына авыл фермасы, ак халатлы шаян кызлар килеп басты. Гүя әлеге тәрәзәләрдә, боз челтәрләре арасыннан, кызлар үзләре дә елмаешып-көлешеп карап торалар иде... Зөбәйдә Габделбәргә карады һәм аптырап китте.

Габделбәр күзләрен ачкан да, үзенең кайдалыгын һәм янәшәсендә утыручының кем икәнлеген белергә теләгәндәй, тын гына, мыштым гына кызга карап ята... Менә ул маңгаендагы кан таплары беленеп торган бәйләвеч астыннан, шатлыклы төстә елмаеп куйды. Күзләрендәге җете зәңгәрлек, нинди дер сыекча тиюдән сыек зәңгәр төскә кергәндәй булды. Һәм ул шунда тормак булып, ике кулын да алга таба сузды.

— Зөбәйдә-ә! — диде ул, күзләрендәге яшь элпәсен ялтыратып һәм ялваргандай итеп.

Зөбәйдәнең гүя сөенечennән башы әйләнде һәм ул күкрәгеннән чыгардай булып типкән йөрәгә тавышына колак салды, еш-еш сулап, егетнең кипшенгән иреннәрен эзләргә тотынды.

— Габделбәр... Габделбәрем! — дип кайнарланып пышылдады кыз. Һәм шунда егет дөньядагы иң якын кешесенең чын күңелдән, чын йөрәктән, яратып, сөеп әйткән тавышын танып, моңарчы хис итә дә, тоя да алмаган рәхәтне татыгандай булып, бәхетле төстә изрәп тә китте, берничә минуттан янә күзләрен ачты.

Зөбәйдәгә таныш түгел икенче бер шәфкать туташы керәп:

— Обход вакыты җитте. Болай... егетне бимазалап утырганыгыз өчен, баш врач сезне ачулана... Ул инде барысын да белә... Аның күзенә чалынмыйчарак торыгыз, берүк! — диде.

Зөбәйдә бурлаттай кызарып килде, кайтарып ни әйтергә дә белмәде. Менә бит ул ничек: син кемгәдер яхшылык кылырга, аны бәладән йолып алырга уйлыйсың, ә кайсыдыр синең бу изгелегеңне бимазалау дип кабул итә. Әйе, берничшли алмыйсың, хастаханәнең үз кануннары шул аның... Зөбәйдә тагын бер кат Габделбәргә күтәрелеп карады да, шыпырт кына чыгып китте. Әмма ак төркем алдыннан кем беләндер гапләшеп килүче зур гәүдәле баш врачның күзенә чалынмый мөмкин булмады. Чалынды... Инде берничшләп булмый. Хәзер теләсән, теләмәсәң дә карлы тәрәзә аша урамга караш ташлаштыргалап табибларның палатадан чыкканын һәм баш табибның каты хөкемен көтәргә кала.

Баш врач нинди фикергә килер бит әле. Анысы менә билгесез. Шул билгесезлек дигән нәрсә җәфалый инде кешене. Тора-бара ул шикка әверелә, аннары корт булып җанны ук кимерә башлый... Ә вакыты җиткәч баксаң, ул билгесезлекнең кара пәрдәсе астында томан гына булган икән...

Зөбәйдә тәрәзә аша урамга карады. Урамның каршы ягындагы йортлардан өстә, түбәндә генә, таш мәчеткә охшаш бер болыт кисәге

асылынып тора иде. Әнә манарасы да бар. Яңалык бу! Чөнки элек, үзгәртүләр башланганчы, болытлар һичкайчан да мәчет сурәтен хәтерләтмиләр иде.

Палата ягыннан аяк тавышлары ишетелде. Ак төркем ишектән чыгып, бире таба килә иде. Аяк астына төбәлеп барган баш табиб, Зөбәйдә турысына җиткәч, туктап, тыныч, соры күзләрен кызга төбәде. Һәм симез учы белән йомшак кына, тоелыр-тоелмас кына итеп кызның иңенә кагылды:

— Менә нәрсә, сеңелем! — диде ул ашыкмыйча гына, уйланып кына. — Сезгә моннан чыгып китәргә туры киләчәк бит... Башкача һич мөмкин түгел. Аның хәле гаять авыр, үзең үк белеп торасың... — Баш врач «сез» дип башлады да кинәт «син»гә күчеп дәвам итте: — Син... аны тынычта калдырырга тиешле. Әйе... Әйе...

...Габделбәр Зөбәйдәне юксына башлады. Килми дә килми. Ник килми инде ул? Нишләгән? Ник озак тора? Әллә баш врачның сүзләре дөрес булып чыктымы? Зөбәйдәне чыгарып ук җибәрделәрме?

Шулайдыр... Чыгарып җибәргәннәрдер...

Габделбәр авыр сулап күзләрен йомды. Аннары тагын ачты. Кемнәрдер аңа таба иелделәр. «Ай-һай, ут яна бу!» «Белмим, исән калырмы икән?» — диештеләр. Шуннан соң аны күтәреп алдылар да, арбага салып, кая табадыр тартып алып киттеләр. Габделбәр, бала вакытындагы шикелле хыялга бирелде. Ул үзен ат арбасында бара итеп хис кылды. Әнә... күк! Тик ул нигәдер ак. Һәм анда берьюлы әллә ничә кояш балкый иде.

Кояшмы? Юк, электр утлары бит болар. Алайса, нигә аларны кояш дип, Габделбәрне алдыйлар!

Тукта... Чү! Янәшәдә генә нәрсәдер шартлап ярылды. Бомбамы әллә? Ярчыгы күкрәккә батып керде ахры, ә бер кыйпылчыгы йөрәккә кадалды булса кирәк... Аһ!.. Габделбәр шуннан соң берни дә хәтерли алмады. Аның карашы томанлы һәм битараф иде. Һәм лифттан чыгып барганда ул бөтенләй үк аңын җуйды.

* * *

Илһам да төнне керфек какмыйча үткәрде... Тугызынчы каттагы бәләкәй бүлмәнең зур тәрәзәсеннән тышкы дөньяны күзәтте. Калага җитәрәк икегә аерылып китә торган юлның теге ягындагы кара урманга текәлеп, ярты сәгать элек кенә шунда кереп югалган зәңгәр «Жигули»ның чикканын көтте. «Ник кереп китте икән бу «Жигули» анда? Ни эзли икән ул кышкы төндә, кара урманда? Ни югалтты икән? Кем белә, бәлки, ул анда берни дә югалтмагандыр һәм берни дә эзләмидер, киресенчә, үзенең кара эшләрен, канлы җинаятьләрен югалтырга йөридер...»

Кинәт, лифтчының түземлеме-юкмы икәнлеген сынарга теләгәндәй, һич өзми-куймый кыңгырау чырылдый башлады... Илһам, бүлмәсен бикләде дә, ашыга-ашыга лифтка керде. Авыру-мазар китергәннәрдер, бәлки?

Илһам сигнал лампаларына карады. Бер турысындагы лампа кабынган иде. Димәк, чынлап та аны беренче катка чакырдылар.

Тиз төшеп җитте. Шаулатып ишекләрне ачты. Һәм ни күрсен: каршында, кәефле елмаеп, каравылчы Николай басып тора. Йөзе кып-кызыл. Ике кулы кесәсендә. Ә аның артында — күзләре хәтәр елтырашкан төнге өч кунак...

— Илһам абый! — диде Николай. — Борчыганым өчен гафу ит: бер шешә аракы кирәк иде. Менә акча бар...

— Юк! — дип кырт кисте Илһам. — Мин андый эшләр белән шөгыльләнмим...

«Менә бит?!» дигәндәй, Николай, көрсенеп тегеләргә карап куйды. Тегеләр исә үз чиратында, өметләре киселгәнгәдер инде, гаҗиз булып, бер-берсенә караштылар.

— Юк бит менә...— дип акланды Николай төнге кунаклар алдында унайсызлануын яшермичә.— Кичә килгән булсагыз, йә иртәгә күренсәгез, табар идем дә... Андый көннәрдә бирелә Федосия Павловна дежур тора. Ә бүген... юк!

Николайның Федосия Павловна дигәне, ашыгыч ярдәм бүлегендә эшләүче урта яшьтәге шәфкать туташы иде. Ул хатынның ире юк, үзе эчми — ярамый. Шуңа күрә ул, талонга сатып алган ике «ак чалма»ны бирегә алып килеп саткалый иде. Әлбәттә, хакын арттырып!

— Илһам абый! Тартырга юкмы соң? — диде Николай.

— Юк! — дип янә кырт кисте Илһам.— Ун ел була инде ташлаганыма. Исен дә яратмыйм хәтта!

— Ярый алайса, тыныч йокы,— диде Николай сүрән генә итеп.

— Сиңа да шулай ук...— диде Илһам, йөзендәге житдилеген тамчы да киметмичә.

Төнге кунаклар, Илһамның төс-битен хәтерләп калырга теләгәндәй, аңа текәлеп-текәлеп карадылар.

Илһам йөз килолы гәүдәсе белән дөпелдәп лифтка керде һәм, исем китә минем сез курачларга дигәндәй, шапылдатып ишекне япты. Аннары тугызынчы катка менеп китте.

«Йөриләр шунда...— дип куйды ул.— Николаен да әйтер идем. Хәер, Николайның үзенә дә ышанып бетеп булмый, биш ел төрмәдә утырган бәндә бит ул... Хастаханәдәге кайбер пычрак эшләрнең «архитектор»ы да ул түгелме икән әле, кем белә?! Милиционерлары да әллә кем түгел... Кобура тагып, автоматлар асып, этләр ияртеп килгән булалар, пычагымны да кыра алмыйлар! Әлегә тикле бер генә җинаятьнең дә эзенә төшкәннәре юк... Ә баксаң, киноларда ниләр генә күрсәтмиләр, китапларга ниләр генә язмыйлар... Чынлыкта исә: тьфү!»

Илһам бүлмәсен ачып керде. Карыны ачкан иде. Термостан чокырга кайнар чәй агызды. Көндез буфеттан, банкыга салып, пылау алып килеп куйган иде, шуны ашарга кереште.

«Хатыным, җанкисәгем йоклыйдыр инде, кызым белән улым да...— дип уйлады ул.— Хәзер мин өйдә булсам, аш бүлмәсендә майлы буяулар белән теге картинамның кайбер урыннарын өр-яңадан эшли башлар идем. Картинамдагы төп каһарман кызны Зөбәйләгә охшатыр идем. Ә йомшак холыклы кызны — Руфинага!» — Шулвакыт, юлга ике ут көлтәсе таратып, баягы «Жигули» урманнан килеп чыкты. Бусында, ай-һай, озак тоткарланып торды ул. Их, белсәң иде, нишләде икән ул анда?!

Илһам пылавын ашады, чәен дә эчеп бетерде. «Жигули» инде киң асфальт юлга чыгып, бар куәтенә калага таба җилдерергә керешкән иде.

«Их, Руфина, Руфина-а! — диде Илһам көрсенеп.— Нишләдең син? Ни булды бу дөньяга? Их-х...»

Илһам башын тотты, җиту чәчләрен туздырып ташлады, сакалмыегын чеметкәләде. Нинди шәп кыз иде бит, бөтен бәхете, матурлыгы үзе белән иде. Ә болай-й... хәзе-е-ер... кемгә кирәк ул? Кемгә хаҗәт?..

Илһам, лифт алдындагы мәрмәр идәнле мәйданчыкка чыгып, кулларын биленә куеп, ишекле-түрле киләп-сарып йөрергә башлады... Ординатор бүлмәсеннән тамак авырулары врачы килеп чыккач кына ул лифтка таба атлады. Врач туташ исә, ике лифтның да кабинасында яктылык күреп, Илһамга:

— Рөхсәт итсәгез, лифтларның берсе белән мин үзем генә төшеп китәр идем,— диде.

— Авыру китергәннәрме әллә?

— Әйе, бер авыруны китергәннәр.

Илһам уңъяктагы лифтның ишеген ачты һәм:

— Рәхим итегез! — диде.

«Йөзенә, күзләренә караганда, ул үзен бәхетле итеп сизә сыман,— дип уйлады Илһам врач туташ турында.— Бу сүзләр Зөбәйдәгә дә карый. Ә менә Руфина турында алай дип әйтеп булмый. Ялгышкан ул. Юк, ялгышкан гына да түгел, адашкан!»

Уйлар, уйлар...

Шифаханә. Көндезге икеләр тирәсе...

Руфинаның йөзе кар сыман ак. Йөзе моңсу һәм сагышлы иде. Башта ул абыйсына ни әйтергә дә белмәде, югалып калды. Илһам лифтта эшли, аны ашыктыралар иде. Шуннан соң ул сеңлесенә: «Әйдә, кер монда, уңайлы вакыт табылгач сөйләшербез»,— диде. Ләкин уңайлы вакытның табылырга исәбе дә юк, кеше дигәнең Кышкы сарайны «штурм»лаган шикелле, лифт эченә ябырылырга гына тора иде. Җитмәсә әле кайбер усалрак санитаркалар Руфинага очып-очып куна башлады: «Утырып йөрергә килдеңмени монда, әйдә, чык, бу сиңа тамаша тәгәрмәче түгел!» — диләр. Руфина тәмам бетте, кашлары җимерелде, иреннәре бөреште, йөзе әче алма капкандай сытылды, ул менә-менә елап җибәрер сыман иде. Һәм кызның ялварып караган коңгырт кара күзләренә төбәлеп, ныклы бер карарга килде Илһам. «Юк, бу миңа туйга әйтергә килмәгән һәм минем хәлне белергә дә килмәгән... Бу — миннән ярдәм өмет итеп килгән!»

Илһам ниндидер бер куркыныч нәрсә барлыгын тоеп, имәнеп киткәндәй булды, салкын суга кергәндәй, калтыранып куйды һәм аның сулъяк тезе дер-дер килә башлады. Ул тиз генә лифтны тугызынчы катка алып менде дә, кысан бүлмәдә оекбаш бәйләп утырган лифтчы Фәимә түтине үз урынында калдырып, Руфинаны бүлмәгә алып кереп, төпченеп сораштыра башлады.

Руфина авылга кайткан икән, авылда барысы да, аллага шөкер, исән-сау яшәп яталар, ди. Сания әби елый да елый, ди, балаларымны сагындым, кайтып хәлемне белмиләр, үлсәм үкенечкә кала, дип әйтеп әйтә, ди... Руфина артыннан чук-чук сәламнәр җибәргән. Бигрәк тә ул сәламнәрнең иң күбесен, иң кайнарын Илһам улына атап юллаган икән...

Боларын Илһам белә, болары әле аңа кирәк түгел, шуңа күрә ул боларын хиссез-нисез генә колагы төбеннән үткәреп җибәрде. Ә инде сүз Маһирның Руфинаны урларга маташуы турысына килеп җиткәч, Илһам түзеп кала алмады, нәфрәтләнеп, йодырыгын төйнәп:

— Аһ, бандит! — диде.— Тимер белән сугып Габделбәрне имгәтеп ташлавы гына аз булган аңа, инде алмадай сеңелемне урлап, аның чәчәктәй яшь гомерен харап итмәкче булган бит...

— Габделбәр фаҗигасе турында каян беләсең, кем әйтте? — дип гаҗәпләнде Руфина.

— Зөбәйдә апаңны очраттым... Апамы әле ул сиңа? Ә, ие, бер яшькә генә кече бит син аннан... Зөбәйдә генә бит ул сиңа!.. Менә шул: Зөбәйдә Габделбәрне бирегә алып килгән, вертолет белән. Дөрес, мин ул вакытта бу турыда аның үзеннән сораша алмыйча калдым, эшем тыгыз бит, сөйләшеп-нитеп торырга ирек бирмиләр, барысы да, утка пешкәндәй, ашыга, кабалана... Шулай да миңа бу турыда, ашыгыч ярдәм бүлегендә кизү торучы врач ханым, лифтка кергәч, әйтте. Безнең район кешесе икән ул, минем әтине дә белә... Сезнең авылдан, ди, Габделбәр исемле авыр яралы бер солдат егетне китерделәр, ди, Маһир дигән егет аның башына тимер белән суккан, ди...

— Маһир үзе генә түгел иде анда,— диде Руфина.— Күзлек Сәлим бар иде, зимагур Фәткул малайлары...

— Харис белән Кәримме?

— Әйе!

— Җә, шуннан алар сине Маһирга урлап китәргә булдылар, иеме?

Руфина бу турыда абыйсына һәммәсен дә бер җепкә тезгәндәй, түкми-чәчми диярлек, кайбер урыннарда хәтта ләззәтләнеп, күзләрен йома-йома, илһамланып, кабына-кабына сөйләп бирде. Маһирның: «Кө-

мәнле ич син... дип шаккатканын да.— Кай арада тутырдың моны?!» — дип мыскыллавын да төшереп калдырмаска тырышты.

Илһам: «Менә хикмәт нәрсәдә икән?» — дип уйлады. Һәм, сеңлесенең корсагына сизелер-сизелмәс кенә итеп, карап куйды. Әйе, беленә шул, күперәп тора!

— Алдандым мин...— диде Руфина һәм баядан бирле көчкә-көчкә генә тыеп торган яшьләрен коя-коя елый башлады.

— Туктале, тукта! — диде Илһам.— Юньләбрәк аңлат: кемнән алдандың? Безнең авылныкымы? Кем малае? Исеме ничек ул сволочьның?

Руфина башын чайкады, иңбашларын сикертте һәм елавын дәвам итте.

«Мин нишлим соң хәзер, нинди кинәш бирим бу җәфага?» — дип ачынып уйлады Илһам һәм шулай да сеңлесенең мөшкел хәленә битараф түгел икәнен күрсәтергә теләп, сораштыруын дәвам итте:

— Ничек булды соң бу эш? Өйләнәм дип юмаладымы соң ул сине? Әллә...

Руфина кып-кызыл булды. Кыска чәчле башын түбән иде: «Үзем дә белмим, абый...» — диде. Бераз тын торгач, аннары, ниһаять, бәтәсе баш бәткән дигәндәй, ашыкмыйча гына сөйләп китте:

— Иптәш кызымның туган көне иде. Анда, теге, миңа күз салып йөргән чая егет тә бар иде. Ул шигырьләр сөйләде, җырлады, гитара чиртте, көлде, биеде. Соныннан минем янга килеп утырды, шәраб эчәргә кыстый башлады. Шундагылар барысы да, эч инде, эч дип, аның ягыннан торып мине кыстарга керешкәч, мин түзмәдем... Аннары, берничә минуттан соң, башымның җиңелчә генә әйләнеп китүен сиздем, яңакларымның, ут капкандай, яна-кызыша башлавын тойдым... Шуннан бер заманны карасам, бүлмәдә ут сүнгән, без... икәү генә... Ул мине көчләгәндер дип уйламыйм. Әмма... мин үз теләгем белән түгел. Юк!

Руфина сөйләп бетерде һәм авыр йөктән котылгандай җиңел сулап куйды. Аннары җавап көтеп абыйсына төбәлде.

— Шуннан уздыңмы?..— дип сорады Илһам.

— Ие! — диде Руфина башын түбән иеп. Һәм колакларына тикле кызарып чыкты. Күренеп тора, ул алдый иде. Алар әле тагын очрашканнардыр. Һәм бер генә дә, ике генә мәртәбә дә түгелдер...

— Бу турыда ул беләме соң? Аңа әйттеңме?

— Белә...

— Белгәч, әйбәтләп аңлашыгыз... Миңа өйлән, диген, бала икебезнеке дә, аны ятим итмик диген!

— Әйт-те-ем.

— Нәрсә ди?

— Башта төшерт, аннары күз күрер әле, ди.

— Аһ, кабахәт, җаваплылыктан ничек җиңел котыла! Шомарган таш икән, сволочь!.. Шуннан соң нинди карарга килдең инде, сеңелем? Нишләмәкче буласың?

— Аборт ясатырга ниятләдем инде, күпләр шулай эшли бит... Син миңа ярдәм ит инде, абый... Монда гинекология бүлеге бар ич... Шундагы берәр врач белән сөйләшеп карасаң... Акчадан баш тартмас әле.

Илһам, әйдә дигән мәгънәне белгертеп, сеңлесенә ым какты да, алтынчы катка, гинекология бүлегенә таба юнәлде.

...Руфинаны байтак вакыттан соң гына алып чыктылар. Аның йөзе кәфендәй агарган, кара күзләре ачык, ләкин алар кешене танымый иде әле.

— Ай-һай, чыдам, таза булып чыкты синең сеңелкәш! — диештеләр Руфинаны арбага салып китеп баручы сестралар.— Хирург та шаккатты хәтта. Мөдир үнҗиле атналык дигәнне, ә бу егерме атнадан да ким түгел, ди.

Илһамның эченә җылы кереп китте. Исән-сау котылгач, булган инде, хәзер терелеп аякка басасы гына кала. Шулай да Руфинаны күпме яткырырлар икән: ике атнамы, өчме?..

Авырыннан колак каккан аңсыз кызны, ниһаять, икенче блоктагы унбишенче бүлмәгә, баягы хатын янәшәсендәге койкага салып чыктылар.

— Курыкмагыз, бер сәгатьтән соң айныша әле ул,— диде шәфкать туташларының берсе Илһамга.— Аннан соң да өч сәгать ятасы була әле.

«Димәк, төп-төгәл дүрт сәгатьтән соң Руфинаны бүтән палатага күчерәләр...»— дип уйлады ир. Һәм эшенә барганчы, палатага кереп, Руфинага берәр сүз әйтеп китәргә ниятләде.

Ул кергәндә кибәндәй хатын чайрап йоклый, ә Руфина ыңгыраша, аңлаешсыз төстә нидер мыгырдана иде.

— Гена! — диде Руфина, ниһаять, ап-ачык итеп. Һәм иреннәрен сузып, ялап куйды.— Гена! — Шуннан соң ул бүтән сүз дәшмәде, башын диварга таба борды да тынып калды. Израп йоклап китте шикелле. Мәгәр аның саташып сөйләнүе, Гена дип, якын итеп, кемгәдер эндәшүе Илһамның җан тынычлыгын алды.

Ул лифтка керде. Шул мизгел берле турысында лампа кабынды, өзми-куймый кыңгырау чыңларга тотынды: лифтны түбәнге катка чакыралар иде. Илһам төшеп китте. Төшеп җитеп, ишекләрне ачып җибәрде... Шәфкать туташы янәшесендә Илһамның авылдашы — Кәрим, муенын тотып, басып тора иде. Аны ашыгыч рәвештә санавиация белән китергәннәр икән. Хәле мөшкел! Чөнки аның кө̆тчкыч булып, бугазы шешкән, үпкәләренә һава бик аз керә, шул сәбәпле гомере кыл өстендә генә тора икән.

Илһам Кәримгә таба башын борып:

— Ни булды, нишләдең син, егет? — дип гаҗәпләнеп сорады.

Кәрим авылдашының көтелмәгән бу соравыннан, көзге өрәңге яфрагы кебек, куырылып килде, гүя уңайсызланды, оялды һәм күзләрен кая яшерергә белмичә әле тегендә, әле монда төбәлде. Шулай да аңа авылдашының соравына җавап бирергә кирәк иде. Һәм ул бугазын кысып ютәлли-ютәлли, гыжылдый-гыжылдый зур кыенлык белән әйтте:

— Маһ-һ-һир... бозлы арра-кы эчерде-е...

— Ишеттем! — диде Илһам.

— Реанимациягә! — диде врач туташ.— Тиз, бик тиз!

* * *

Маһир Райбашкарма комитеты янәшәсендә... сыра эчәргә тезелгән галәмәт озын чиратның бер өлешендә басып тора иде. Мичкә кыяфәтенә кертеп, ярыйсы гына чибәр итеп, ишек һәм тәрәзәләр уеп ясалган әлеге нәрсәкәй чынлап та сыра мичкәсенең зурайтып ясалган күчермәсен хәтерләтә иде. Һәм «күбек» эчеп кәефләнергә яратучылар аны, гади генә итеп, «сыра мичкәсе» дип атый. Ул мичкә, икенче төрле әйткәндә, матрешканы да хәтерләтә, мичкә эчендә тагын мичкәләр: аларында — сыра!

Маңгаена зур хәрефләр белән «Пиво» дип язылган әлеге мичкә эчендә мөләем йөзле, ярыйсы гына чибәр ханым, колакларындагы энҗе күзле алтын алкаларын һәм бармакларындагы фирәзә кашлы алтын йөзекләрен ялт-йолт уйнатып, пыяла тустаганнарга чыжылдатып сыра тутыра һәм аларны: «Миңа! Миңа!» — дип сузылган калтырча кулларга бер-бер артлы тоттыра; шул ук вакытта акча алырга да, кайтарырга да өлгерә иде. Бу ханым, кайчандыр, химфакны тәмамлаган булып, ул чынлап та сыраны «химияләштерү»нең бөтен нечкәлекләрен дә диярлек белә һәм шул юл белән табылган чумара аның кесәсенә, кем әйткәндәй, чишмә кебек агылып керә иде. Әгәр сөйләүләре дөрес булса, мичкә эчендә сыра-күбек белән сату итүче әлеге елгыр ханым, янәшәдәге райбашкарма комитеты бинасында эшләүче зур бер түрәнең яшерен сөяр-

кәсе, имеш. Әйе, монда ышанырга мөмкин! Чөнки, кемлегенә карамыйча, кимчелекләрне күзгә туры карап әйтергә ярый торган безнең бу заманда, сер капчыгын җиде кат йозак астында саклап тотып буламы соң!

Ярый, теге зур түрә өченче каттагы бүлмәсенең зур тәрәзәсе аша, сыра мичкәсе янындагы «спектакль»не бушлай карап, күнел ача торсын, без исә шул тирәгә якын килеп, төрле-төрле тавышларга, сөйләшүләргә колак салып карыйк.

— Сыра бетәме әллә, егетләр?

— Бетәргә дә мөмкин... кайчаннан бирле бер урында таптанып торабыз ич!

— Һаман чиратсыз керәләр дә керәләр... Көчленеке замана!

— Без алардан кимме әллә?

— Шулай, шулай... Азынып беткәннәр, авызлыкларга кирәк!

— Әйдәгез... бердәм булып!

— Эй, не толкайте!

— Куда лезешь? Морда!

— Дай ему в рот!

— Егетләр... минем арттан!

— Чего они хотят?

Шулай итеп, үз телләрен оныткан татарлар белән үз телләрендә иркен сөйләшүче татарлар чак-чак кына сугышмыйча калдылар. Әйе, уттай кайнар ташларга су сибеп кыздырган мунчаның эссесен ишек ачып куып чыгаралар, ә биредә сыра өстенә сыра өстәп кызган кешеләр йөрәкләрендәге кайнарлыкны (юкса, янып үләргә мөмкиннәр) үзара чәкәләшеп чыгаралар: эчтәге бөтен нәфрәтләре һәм әшәкелекләре белән...

Маһир этешү-төрткәләшү һәм үзара кыска гына вакыт эчендә кемлекне күрсәтеп, аңлашып алганда дуслашып өлгергән алты-җиде кеше белән «чын күңелдән» сөйләшеп тора башлаган иде инде. Сыра алырга чиратсыз керүләр дә беткән, чират үз җаена, бу юлы, әлбәттә, тоткарлыксыз бара иде.

— Син... къай раюннан әле? — дип сорады, зәңгәр күзле, сары чәчле Чүпрәле кешесе Маһирдан.

— Балык Бистәсеннән.

— Къайсы авылдан анда?

— Көмеш Елга! — диде Маһир горурланып.

— Ишеткән бар... Үзең Къазанда торасыңмы?

— Әйе. Син дә Казанда торасыңмы, абый?

— Монда кызык нәмәләр булгалай, имә! — диде кара чәчле, кара күзле Актаныш егете.

— Юк! Бернинди кыдык әйбер юк монда! Халкын әйтер идем... бодау тек бодау инде, — диде озын буйлы Минзәлә егете.

— Әтәй-әнәйең бармы авылда? Катькалап йөрисеңме алар янына? — дип, сораулар бирүен дәвам итте Чүпрәле кешесе Маһирга.

— Кайтмаган кая... атна саен кайтам, — дип ялганлады Маһир һәм шул ук вакытта, таныш-фәләннәр очрамагае дигәндәй шүрләп, як-ягына карангалап куйды.

— Хазыр йәшьләр әтәй-әнәйне къадерламыйлар ведь.

— Дөрес әйтәсең, абый! — диде Маһир дәртләнеп. — Минә безнең авылда Сания исемле әбинең җиде баласы бар: бер кыз, алты малай. Һәм шуларның, кыздан кала, ник берсе кайтсын әниләре янына!

— Каңаннан бирле катьмыйлар инде алар?

— Күп инде... Әтиләре вафат булганнан бирле...

— Әтәйләре-е?! — Чүпрәле кешесе, зәңгәр күзләрен зур ачып, Маһирга төбәлде. — Ә аңарьцы, әтәйләре ульганцы катьалар идеме суң алар?

— Кайталар иде! Гел кайтып йөриләр иде!

— Алайса, ул әтәй кешенең күп малы къалган, ә ул мал малайлар къулына барып керьмаган, къыз кулына гъына барып керыган...

— Вәйт, дөрес тә әйттегез, абый кеше! Ну, дөрес тә итеп әйттегез инде, амауый... Моның өчен, амач, бер тустаган пиво эчертәм әле мин сиңа... Һәй-яй-йәй... нәкъ сыер кебек итеп, эзенә генә бастыгыз бит, амауыай, ә!

Ләкин Чүпрәле кешесе бу мактауларга әллә ни эреп китмәде, Маһирның кулын иңбашыннан сүзсез генә этеп төшерде дә, күршесенә таба борылып, җитди генә итеп:

— Иван Гурич! Аракыны хазыр ыщабызмы, соңъыннанмы? — дип сорады.

— Казер эчәрбез,— диде керәшен егете Иван Гурич һәм Маһирга күз кысып куйды.

«Юк, безнең районадагы керәшеннәр болай сөйләшми,— дип уйлады Маһир Иван Гурич турында.— Бу — чувашлар белән аралашып үскән булса кирәк, тел төбеннән шул сизелә».— Һәм Маһир бәләкәй чагында авылга сөлге, эскәтер ише әйберләр сата килгән җор телле чуваш хатынынннан отып калган берничә сүзне исенә төшерде.

Шулвакыт янәшәдәге төркем эченнән сүгенеп кычкырган тавыш ишетелде:

— Татарлармы? Юк аларга бернинди мөстәкыйльлек! Юк! Бирмибез! Аяк терәп каршы торачакбыз!

— Баш күтәрсәләр нишләрсең? — дип, чинап кычкырды аңа каршы икенче берәү, шулай ук русчалатып.

— Менә, күрсеннәр! — диде шунда бер исерек кыз күлмәк итәген күтәрергә азапланып.— Ирек кирәк, имеш, аларга! Элеккечә биш хатын белән яшәү кирәк. Тотсыннар!

— Тарих сабакларын онытмаска кирәк, иптәшләр! — диде беренче тавыш.— Татарларның кемнәр икәнлекләрен, русларны ничек итеп изгәнлекләрен беләбез ич...

«Чү! Бу бит Руфина? — дип уйлады Маһир исерек кызны танып.— Ә татарларны сүгүче ир — Илһамның энесе Фердинанд! Тик шунысы аңлашылмый: алар үзләре татар, ә үзләре татарларны күралмыйлар. Ни өчен? Сәбәп нидә, нәрсәдә?»

— О-о... Господи! — диде Фердинанд.— Защищай нас от злоумышленников. Помилуй нас грешных...— Һәм ул, еракта, ике катлы йортлардан шактый ук мәһабәт булып калкып торган чиркәүнең алтын тәреләренә исерек карашын юнәлтте.

— Рәхмәт сезгә, мине яклаучы татарларым! — диде райбашкарма комитеты бинасының өченче катыннан бу хәлләрне күзәтеп һәм яшертен микрофон аша андагы сөйләшүләрне тыңлап, ишетеп торган манкорт түрә.— Әйе, татарларның берләшүләренә каршы сәясәтне тагын да ныграк дәвам итәргә кирәк. Берләшмәсеннәр алар! Татарлар таркау яшәсә, безгә — түрәләргә искиткеч тыныч һәм рәхәт булачак!

— Долорес! — дип селектор аша эндәште манкорт түрә сыра сатучы ханымга.

— Тыңлыйм, Мадрид Марсельевич! — диде сыра сатучы ханым ялагай тавыш белән.

— Мичкәңне биклә дә, тиз генә минем янга күтәрел әле!

— Хәзер, хәзер, Мадрид Марсельевич! — һәм Долорес ханым мичкәсеннән чыгып, тустаганнарны җыеп алып кереп китте дә, тәрәзәгә «Пиво нет» дигән игълан элеп куйгач, арт ишектән чыгып, райбашкарма комитеты бинасына таба юнәлде.

— Фу, идрит-кудрит, тагын аракъы эцәргә къалды...— дип зарлана башлады Чүпрәле кешесе. Иван Гурич сеткасыннан аракы һәм стакан тартып чыгарды. Керәшен агайның кулында чын аракы күреп алгач, Минзәлә егетенең күзләре аракы бөкеседәй елтырады.

Исерек Руфина, Актаныш егете турысына җиткәч туктады һәм ашыгып-ашыгып, озын пальтосының төймәләрен чишәргә тотынды. Чишеп бетерде дә, ялт кына әллә ниткән бер хәрәкәт ясап алды. Һәм шул

мизгелдә, кара кашлы Актаныш егетенең чем кара күзләренә, исерек кызның ап-ак шәрә күкрәге чалынып калды. Егет көтелмәгән бу хәлгә нинди бәя бирергә дә белмичә аптырап торган арада, кыз аңа эндәште:

— Гони пятерку!

— Ни өчен?

— Ты меня видела?! Видела?!

— Юк, күрмәдем... Син мине тамчы да кызыксындырмыйсың һәм синең миңа кирәгең дә юк!

— Ах! Так...

Кыз Актаныш егетенең яңагына чабып җибәрде.

Егет кешелектән чыккан Руфинаны этеп җибәрмәкче иде, ул арада кызга ярдәмгә кызыл сакал (сөяркәсе булса кирәк) белән Фердинанд килеп өлгерде. Актаныш егете, бу бәладән, биш тәңкә түләп котылырга мәҗбүр булды. Ә манкортлар өере Минзәлә егетенә бәйләнде.

— Гони пятерку!

— Мәгед, тамагыгыдка сөяк булып тыгылсын! — дип, Минзәлә егете кесәсеннән биш тәңкә чыгарып, кызыл сакалга сузды. Кызыл сакал, тәмәкесен тәмләп суыра-суыра, акчаны ялтыравык бумажнигына салды һәм эчке кесәсенә шудырды. Үз эшен оста башкаручы Руфина бу хәлгә канәгать калып, кызыл сакалга елмайды — акчаны бергә тотачаклар бит! Аннары кыз Буа егете каршына килде һәм, пальто эчендәге анадан тума гәүдәсен ялт кына күрсәтеп алды. Кызның ярыйсы гына йомры имчәкләре егеткә тәэсир итми калмады түгел, билгеле.

— Байлыгыңа салкын тидерәсең ич син болай! — дигән булды Буа егете, теленә салынып.

— Не твое дело! — диде кыз кырт кисеп. Һәм акчаны егетнең кулыннан тартып диярлек алып, кызыл сакалга сузды. — На, милый...

Кызыл сакал, ни өчендер, Буа егетенә ачулы карап куйды. Кыз, акчаны учына йомарлап тоткан көе, Чүпрәле кешесе янына барып, пальтосы эчендәге шәрә тәнен ялт кына күрсәтеп алды.

— Гони пятерку!

— Күрмәдем әле, башта күрсәт, аннары бирермен акча! — дип, Чүпрәле кешесе авызын бәлшәйтеп көлде.

— Ну! Дашь или нет?

— Мә инде, чукынган кыз... Имчәгеңне дә тоттырсаң, тагын биш тәңкә бирәм әле.

— Ну! Ну! Давай...

Чүпрәле кешесе каударлана-каударлана кулын кызның пальтосы эченә тыкты һәм җылы, йомшак имчәкне эләктереп уч төбенә кысты, әвәләде. Аның күзләре ут яна иде.

— Ну! Довольно? Хватит...

— Икенче имчәгеңне дә тоттырсаң, тагын биш тәңкә өстим!

— Давай! Только быстрее...

Чүпрәле кешесе икенче кулын да, кызның пальтосы эченә тыкты һәм җылы, йомшак имчәкне эләктереп уч төбенә кысты, әвәләде, тарткалады, аннары әкрен-әкрен генә түбән таба төшә башлады. Шул ук вакытта ул, кояш баеганда, тын су өстендә көймәдә тирбәлеп баргандай рәхәт бер хис кичереп, нәрсә турындадыр хыяллана да иде бугай. Менә ул, кызга таба шактый ук авыша төшеп, пышылдады:

— Әйдә... әнә теге йортка кереп... чыгабыз... Егерме биш тәңкә бирәм!

— Нет уж, этого я не позволю! — Кызыл сакал, күк күкрәгән тавыш чыгарып, кычкырып җибәрде һәм Руфинаны култыклап алды. Аннары Чүпрәле кешесенә таба борылып:

— Гони пятерку! — диде.

Чүпрәле кешесе ике кулын да пальто кесәсенә тыккан усал йөзле Фердинандка карап куйды, нәрсәдәндер шикләнә булса кирәк, шундук кесәсеннән бишлек алып кызыл сакалга тоттырды. Ә кызыл сакал әле

генә Руфина «эшләп алган» акчаларның барысын да Иван Гуричка тәкъдим итеп:

— Дай, три бутылка зеленого! — диде.

— Җәмгысе өч шешә генә бит, егетем!

— Дашь или нет?!

— Бирәм! Бирәм! — Иван Гурич сеткасыннан өч шешә ак чалма алып кызыл сакалга тоттырды. Ә кызыл сакал шешәнең берсен кесәсенә салды, икесен Фердинандка бирде. Һәм алар койма янында көтеп торучы шешәдәшләренә таба атлап киттеләр.

Маһир тиз аңышты. Аһ, әйбәт ич! Аңа тимәделәр! Аның акчасын алмадылар! Хәер, бу шайкада, кызыл сакалдан кала, Руфина да, Фердинанд та Маһирның авылдашлары ич: аңа ник тисеннәр, аның акчасын ник алсыннар?! Шулай да берьялгызың аксөяк булып читтә матди зыян күрмичә һәм түбәнсетелмичә басып калу килешми иде. Маһир яңа табылган дусларыннан аерылып китеп барды. Чукынсын сырасы! Эчмәгән агу түгел! Кирәк икән тагын эчәр әле, хәзергә башның исән булуы кадерлерәк!

Шулай итеп, аңа сүз әйтүче, аны туктатырга теләүче табылмады. Маһир китте. Кая? Үзе дә белми әле.

* * *

— Магирка-а, Магирка-а-а...

Юк, уянмый Маһир. Ул төш күрә иде.

Малай чагы, имеш, мәчет тавыннан чаңгы шуып кайтып килә. Күккә ай калыкмаган әле, йолдызлар да күренми. Әмма Маһир күзләре чаңгы юлын гына шәйләрлек әле. Чаңгы юлы нәкъ менә караңгы бакчалар аша үтә иде.

Маһир бүгенге көннең каһарманы буларак, үзен отряд алдында баручы командир кебегрәк хис итә. Артына борыла да, башы белән алга ымлый: йөгерәбез хәзер, минем арттан калмагыз, янәсе.

Шулай ди дә, бар көченә алга омтылып, таяклары белән селтәнеп җибәрә, аннары чүгә төшә. Һәм калтыр-колтыр шуып китә. Маһирның колагында җил сызгыра, бит очларын суык энәләре чәнчи, ләкин ул боларга игътибар итми, ул бары тик, минем арттан куып киләләр, мин аларга уздырмаячакмын, дип кенә уйлый. Соң, шулай булмыйни?.. Мәчет тавының иң биегеннән башлап кем төште? Маһир! Дүрт сикертмәне кичеп тә егылмый калган малай кем? Әлбәттә, Маһир! Шуңа күрә бүгенге көннең каһарманы да инде ул.

Маһир кызу-кызу гына барганда, мунча каршында кинәт туктап кала. Кайчандыр, кем тарафыннандыр әйтелгән сүзләр исенә төшә аның. «Җен-пәриләр кеше сурәтендә, бигрәк тә хатын-кыз кыяфәтендә, кояш баегач, җир өстен караңгы саргач ук мунча керәләр икән. Шуңарчы алар туфраксада яткан булалар, имеш». Маһир көлеп куя. Шыр әкият инде бу! Алай да тәрәзәсеннән карап китим әле, күнелдә калмасын, дип, ул мунчага юнәлә.

Бакча шундый тын, тирә-юньдә ялгышып кына да эт тә күренми ичмасам. Маһирның йөрәге кага, күңеленә шик төшә һәм ул җеннең сурәтен хыялында тудырып карамак була. Әмма күзләрен фосфордай ялтыраткан мәче кыяфәтеннән гайре нәрсәне тоемлый алмый. Маһир ул-бу булмасынга таякларын әзер тотып, мунча алдына чыга һәм күрә: тәрәзәдә тонык кына ут шәүләсе. Маһир акрын-акрын гына тәрәзәгә елыша. Әһә, бу яктылык сәке тактасына куелган фонарьдан төшә икән.

Маһир карана торгач, ниһаять, тәрәзәгә капланып бетүен дә тоймый калды. Ләхәүлә! Ләхәүлә, бүрәнәдәй юан ак ботларын салындырып, шулай өстенә көлтәсе белән сибеп ташлаган шомырт кара чәчләрен тарап пәри үзе утыра. Маһир инде кире йөгереп китәргә дә уйлаган иде,

әмма теге «пәри» чәчләрен ике кулы белән артка таба ташлагач, аның йөзе ачылып китте һәм Маһир шундук аны танып алды. Бу — шәһәрдән ялга кайткан укытучы Зәлия апа лабаса! Кайчандыр данлыклы көрәшче Хисаметдин абыйның үлеп яраткан хатыны булган ич ул. Хәзер дә кызларга биргесез чибәр әле Зәлия апа, бик чибәр!

Шулай да аның аз гына калкыбрак торган матур борыны, караган саен карап туеп булмаслык йомры-йомры ак беләкләреннән гайре әгъзалары күренми иде әле... Шул мәлне янәшәдә генә диярлек калын тавыш белән эт өреп җибәрде. Маһир сискәнеп китеп, үзе дә сизмәстән терсәге белән рамга орынды. Каты орынды, ахры. Зәлия апа ялт кына ләүкәдән сикереп төште дә, тәрәзәгә капланды.

— Кем ул анда?

Маһир сөрлегеп китте, карга егылды. Торды. Чаңгыларын эләктереп күкрәгенә кысты. Таләпчән тавыш тагын да катырак һәм дәһшәтлерәк булып өйалдында ишетелә иде инде хәзер.

— Ке-ем у-у-ул-л?!

«Минә ишек ачылып китәр дә, чәчләре тезләренә җиткән һәм Зәлия апага охшаган пәри хатыны Маһирны тотып...» Малайның шулай уйлавы булды, кемдер каты-каты гына аның җилкәсенә тертте. Маһир дерт итеп уянды.

Тәрәзәнең бозланып катмаган өлешеннән, югарыда балкып ай күренә. Мәгәр аның яктысы бирегә үк төшеп җитми, монда караңгылык патшалыгы иде. Мунча белән Зәлия апа образы төшкә генә керсә дә, булган хәлләр иде алар.

Ләкин Маһир хәзерге вакытта үзенең кайда һәм нинди бүлмәдә ятуын белергә теләде. Әйе, ул бит кичә кабат Фердинандны очратты. Янында Руфина да бар, ә кызыл сакал күренми иде.

Сеңлесе Руфинаны ияртеп Фердинанд бик якын иптәшенең туган көненә барырга чыккан икән. Алар үзләре белән Маһирны да барырга күндерделәр.

— Кызыл сакал кайда соң? — дип сорады Маһир алардан.

Фердинанд кулын гына селтәп куйды.

— Тигез урында егылып аягын сындырды да, РКБга озаттык!

— Әйбәт кеше ул,— диде Руфина.

Юл уңаеннан алар кибеткә дә кагылып чыктылар. Туган көнгә коры кул белән барып булмый бит. Ниһаять, Маһир күпкатлы тулай торакның бер бүлмәсендә гомердә күрмәгән егетләр-кызлар арасында утыра. Ә Фердинанд монда үз кеше. Үз кеше генә дә түгел, мәҗелеснең хуҗасы кебек иде. Аңа Федя дип кенә дәшәләр иде.

Маһир баштарак эчемлекне иреннәренә тидереп-тидереп кенә утырды. Мәҗелестә купкан бернинди бәхәскә дә катышмады, беркем белән дә сөйләшмәде диярлек. Шул мәлне аңарга, әллә күңеленә охшап, әллә бүтән сәбәп белән бәйләнде генә бит күз-кашларын чабарткачы буянган, озын гына итеп тырнаклар үстергән марҗа кызы. Рюмкасын күтәреп килә дә чәкештерә, күтәреп килә дә чәкештерә.

— Әй, әй, болай булмый бу! — ди.— Төбенә чак-лы-ы,— ди.— Минә мин-н-н...— ди.— Кыска сары чәчләрен артка чөеп, рюмканы җәлт кенә авызына коеп җибәрә.

Тәнәфестә Маһир районлашын очратты. Һәм аның белән тәмәке пыскыта-пыскыта озак кына сөйләшеп торды. Күңеле чак кына күтәрелгәндәй булды һәм ул, кереп утыргач, үзе башлап бер-бер артлы өч рюмканы авызына озатты.

Бая үпкәләгән марҗа кызы:

— Вот дает, вот молодец! — дип, шундук егет янына килеп басты. Маһир берзаман исереп китте һәм кызны биленнән кочып үбәргә итенә башлады.

Кыз карыштымы, юкмы Маһир аңысын хәтерләп бетерми. Ул кызны тагын күтәрмәк булып азапланганда, егылып та китте бугай. Аннары

маржаны почмакка бастырып, аңа юатып-юмалапниләрдер әйтте шикелле. Кыз аның яңагына салып җибәрде булса кирәк. Маһир яңагын тотып йөрде-йөрде дә коридорга чыгып ауды һәм шуннан тормады, ахры. «Мине монда кайчан һәм кем кертеп салды икән, гомумән, мин кайда ятам икән?»— дип уйлады Маһир. Күзләрен зур ачып кабат тәрәзәгә карады. Ләкин тәрәзәдә күктә йөзгән ялгыз айдан гайре нәрсә шәүләләнми иде.

Шул мизгел янә Маһирның аркасына төрттеләр. Маһир артына әйләнеп карады һәм янында басып торучы Фердинандны күрде. Фердинанд җиренә җиткереп кырынган, чистарынган иде. Яңа гына ышкыланган тактадай шома йөзен хушбуйлап та өлгергән.

— Мин эшкә китәм,— диде Фердинанд авылдашының махмырдан шешенгән йөзенә, кысылып бетә язган күзләренә төбәлеп.

— Ашыкмый тор әле, мине көт! — диде Маһир. Һәм теләр-теләмәс кенә торып киенергә кереште.

Ишектән алар бергә чыктылар.

— Менә нәрсә...— диде Фердинанд һәм сигарет кабызды. Маһирга да тәкъдим итте. Сигареты хуш исле иде, чит илдә эшләп чыгарылган булса кирәк.— Базага барып алам, шуңа кытлык кичермим! — диде Фердинанд, Маһирның күңелендәге уйларын укыгандай, тыныч кына итеп.— Анда минем ахир эшли... Мин бит беренче разрядлы самбочы! Минем кебек егәрле спортчылар оҗмахта яши хәзер. Ничекме? Кичә күрдең ич сыра мичкәсе янындагы хәлне... Менә шулай егет! Ягъни, кыска гына итеп әйткәндә, көчленеке замана!

— Шулай да кайда эшлисең соң син, Фердинанд абый? Кем булып?

— Минме? Мин җәмгыятькә хезмәт итәм! Аңлашылмыймы? Алайса аңлатам: менә мин бизнесменга да, кооператорларга да, мафиягә дә, милиция органнары өчен дә бик кирәкле һөнәр иясе бүгенге көндә! Әгәр дә алар ярдәм сорасалар, мин шуларның һәммәсенә дә рәхәтләнеп булышам! Әлбәттә, элекке вакыттагы шикелле, коры рәхмәткә түгел — акчага!

— Аңладым кебек...— диде Маһир. Һәм, перчатка кигән кулы белән, изүендәге тәмәке көлен кагып төшерде.— Чынлап та син бәхетле бугай, Фердинанд абый! Мин синең шундый көчле, куркусыз булуыңа сокланам! Синең киләчәгең алда әле... Ә менә минем язмышым бүгенге көндә кыл өстендә генә тора, мин беткән кеше инде хәзер. Мин бит...

Фердинанд кулы белән, сөйләмә, кирәкми дигәндәй, бер хәрәкәт ясап куйды.

— Аңлыйм мин синең хәлне, брат! Монда синең гаебең юк диярлек. Чөнки син эш өчен «батырлык» кылгансың. Эш өчен! Элекке заман булса бу «эш» өчен дворян яшьләре үзара дуэльгә чыгарлар иде. Һәм шунда аларның берәрсе үтерелер иде... Ә бит син Габделбәрне үтермәгәнсең! Габделбәр исән.

— Анысы шулай инде,— диде Маһир күңелсез генә итеп.— Ләкин мин үземнең бу эштә хаклы булуым турында кемне ышандыра алам соң хәзер? Берәүне дә...

— Күңелсезлеккә бирелмә, Маһир! Син минем Фоат абыйны беләсеңме, бу районда «паспорт өстәле»нең начальнигы урынбасары булып эшли, капитан?!

— Беләм! — диде Маһир.

— Менә аның өй адресы... Бар син аның янына, сөйләш... Әйбәт кеше ул! Бәлагә юлыккан кодасына ярдәм кулы сузмый калмас... Аннары ул хәзер элекке «кызыл» карашларының күпчелегеннән баш тартты бугай, партбилетын да райкомга илтеп тапшырды шикелле...

— Рәхмәт,— диде Маһир күңеле үсеп.— Барырмын, әлбәттә, сөйләшермен!

— Юлың уңа калса, минем янга килерсең... Мин сине бередә берәр кооперативка тыгып куярмын...

Фердинанд борылды да, дингезче кебек, аякларын як-якка аерып атлый-атлый, тимер юл станциясе ягына таба китеп барды. Ул Маһир ягына бүтән бер генә мәртәбә дә борылып карамады.

«— Әй! Фердинанд абый... Авылга кайтып әниеннең хәлен белеп кил инде син!» — дип кычкырырга теләде Маһир аңа. Ләкин Фердинанд бу вакытта ярыйсы ук ерак китеп өлгергән иде. Маһир аңа дәшә алмады. Әй эндәшсә ярыйсы икән! Чөнки Маһир Фердинандны бүтән беркайчан да очратмаячак, хәтта жир өстендә каберен дә таба алмаячак икәнлеген бу минутта башына да китерә алмый иде әле.

Маһир, барсам ярый, бармасам ярый дигәндәй, эленке-салынкы гына атлап китте. Каршына берсеннән-берсе чибәр студент кызлар очрады. Зөбәйдә дә студентка бит! Кайда икән ул хәзер? Нишли икән?

* * *

Зөбәйдә иртәдән үк кәефсез иде. Кызның күңелен төшергән сәбәпләр күп, бик күп инде монда. Әнә, адым саен диярлек төрле-төрле белдерүләр очрый — һәммәсе дә урысча язылган! Адым саен урысча сөйләшкән авазлар ишетелә... Әллә соң бу Казанда туган телдә сөйләшүче бөтенләй дә беткәнме?

Зөбәйдә иреннәрен тешләде, кашларын җыерды һәм: — Хурлык, хурлык! — дип ачынып уйлады.— Бөек Тукай теле, бөтен дөньяга курку белмәс батыр шәхес булып танылган каһарман шагыйрь Муса Җәлил теле, дип лаф орабыз да лаф орабыз, ә үзебез тиешле урында шул телне төрле һөҗүмнәрдән күкрәк куеп саклый алмыйбыз һәм үзебез бу кыюсызлыгыбызны аклау өчен, татар исеменнән дә колак кагарга әзер торабыз: теләсә нинди исем булсын, тик татар дигән исем генә булмасын, янәсе... Бит бу — бүрек ыргытып бүредән качып котылырга азаплану белән бер!

Ирек мәйданына, киң елга булып агылган халык, дингез сыман кайный да кайный иде.

Зөбәйдә халык агымына таба якыная төште. Инде хәзер кычкырып сөйләүчеләрнең тавышлары да ачыграк ишетелә иде. Кешеләрнең һәммәсенең йөзе борчулы, җитди һәм аларда кыюлык, тәвәккәллек чалымнары да сизелеп тора.

Әнә, баш өстендә — югарыда, ярым ай һәм йолдыз сурәте төшерелгән яшел төстәге милли байраклар җилферди башлады... «Мөстәкыйльлегебез куркыныч астында!» — дигән язулар пәйда булды. Баксаң, Югары Совет сессиясендә, мөстәкыйльлегебезгә каршы килә торган карар кабул ителгән булган икән дә, хәзер халык шул карарны юкка чыгаруны катгый төстә таләп итә икән.

Кемдер уң кулын югары күтәреп, һаваны кисеп: «Азатлык!» — дип оран сала. Меңләгән күкрәктән чыккан көчле һәм дәһшәтле авазлар, Югары Совет сессиясе барган бинаның диварларына килеп бәрелә, тәрәзәләрен зыңлата, залга үтеп керә:

— Азатлык!

— Азатлык!

— Мәгънәсез карарны юкка чыгарырга! Бер казанга ике тәкә башы сыймый!

— Таләп итәбез!

— Таләп итәбез! — дип кычкырды Зөбәйдә дә. Аның күзләре очкынланган, битләре, суыктан, ут капкандай кызарып чыккан иде. Ул бергә килүенә үкенми, киресенчә, әнә теге зур бина эчендә татар язмышы хәл ителеп яткан минутларда монда булуы белән горурлана иде.

* * *

Маһир бу көнне, Фердинандның киңәшен истә тотып, Фоат янына килде. Ишекне аңа милиция капитанының сары чәчле хатыны ачты.

— Вам ко-во-о?! — диде ул тәкәбберлеген тавышына ук кучереп.

«Ай-һай күркә кебек кабарынган бу! — дип уйлады Маһир Фоатның хатыны турында. Әйтерсең аның каршында кеше түгел, ә бер эт басып тора! Хәер, горур кыяфәтле мондый хатыннар ирләрне үз кубызларына биетергә генә торалар. Һәм бии ир кисәге. Ничек кенә бии әле! Ышанмыйсызмы? Алайса... Фоат абыйның берәр баласы татар телен беләме? Юк! Ә кайсы татар кызы урыс егетенә кияүгә чыккач, урыс ирен үз кубызына биетә алганы бар? Юк! Аннары аңардан туган бала үз телен беләме? Юк! Белми һәм белергә дә теләми!»

Әнә бит Руфина белән Фердинанд кичә «мичкә» янында ниләр кыландылар. Татарга хас гадәтме бу?! Юк, чит халык гадәтен кучереп алган бит алар. Әнә шулай итеп үз җиребездә, бөек милләткә ярыйбыз дип, аларча гына сөйләргә, аларча кыланырга тырышабыз шул. Болай барса, кайберәүләр чиркәүләргә кереп чукынырга да күп алмаслар...

— Ва-ам ко-во-о? — дип кабатлап сорады сары чәчле хатын.

Маһир сискәнеп китте:

— Мне нужен Фоат абый! — диде ул тиз-тиз генә, сары марҗа ишекне ябып куяр дип шикләнеп.

Хатын бер сүз дә әйтмәде, ишекне акрын гына япты, эчтән бикләде. Аннары аның ишек буеннан китеп барган аяк тавышлары ишетелде. Кем белә, бәлки чынлап та, Фердинанд әйткәнчә, изге күңелле кешедер ул, Маһирга бик теләп булышыр, аны алда көткән куркыныч бәлаләрдән коткарып калыр, аңа янә тулы канлы тормышка әйләнеп кайтырга ярдәм итәр...

Менә, ниһаять, эчтә ишек йозагы чылтырап куйды, һәм яртылаш кына ачылган ишектә кибетче Хисаметдингә охшаш, матур, сөйкемле карашлы, таза ирнең бөдрә чәчле башы күренде. Ул Маһирны күрде, таныды һәм битараф төстә:

— Сезгә нәрсә кирәк?! — дип сорады. Аннары, мосафирның җавап биргәнен дә көтмәстән: — Мин бит хәзер паспорт өстәлендә эшләмим... Эшләмим! Аңлыйсызмы? — диде.

Маһир ык-мык итте, ни әйтергә дә белмәде. Ул арада милиция капитаны киемендәге Фоат ишекне ябып өлгерде.

«Менә сиңа туган тиешле кеше! Менә сиңа кода! — дип гарьләнеп уйлады Маһир. — Марҗага денен саткан да, әллә кем булган, стерва! Ярар, ачык йөз күрсәтмәсәң ни, фатирына кертмәсәң ни... Бер килеп безнең урамда да бәйрәм булыр әле, булмый калмас!»

Маһир башын түбән иеп, теләр-теләмәс кенә баскычтан төшә башлады. Аяклары атласа атлады, атламаса — юк. Аның Фоатка хәтере калган иде. Йә, ни була инде шунда фатирына кертеп, аш бүлмәсенә чакырып, кодасы белән чын күңелдән сөйләшеп утырса?! Һич югы, кода итеп кенә булса да! Юк, бит, чакырмады һәм чакырырга уйламады да... Ә Фердинанд бит аның турында мине канатландырып җибәрерлек сүзләр әйткән иде. Ул хәзер әйбәтләнде, партиядән чыкты, билетын райкомга илтеп тапшырды, гади кешеләрне дә үз итә, кыерсытылганнарны яклый һәм ялгышып җинаять кылганнарның да хәленә керергә тырыша, дигән иде.

Маһир тәмәке кабызды һәм шырпысын өскә таба чирттереп җибәрде. Аңа каршы баскычтан бер әби менеп килә иде. Маһир бу бәләкәй гәүдәле әбинең йөзенә багып, татар карчыгы икәнлеген чамалады.

— Нихәл апа... Исән-сау гына яшәп ятасызмы? — диде Маһир.

— Манем хәлдә синең ни эшең бар! — диде әби кинәт коры гына итеп һәм, Маһир ягына таба төкереп җибәрде: — Әйдә, не стуй здич, уматвуй атсуды...

— Ник куасың мине, апа? Татар бит мин, үз кеше! — диде Мәһир.

— Һе... Татар, имеш! — Әбинең тавышы калтырап китте. — Беләм мин сезнең хәйләне... Башта, нихәл апа, аннары, мин синең туганың, аннары, аракы дай, ашайт дай... Беләм мин сезнең хәйләне!

Мәһир шунда гына аяныч язмышка дучар булган әбигә туры килүен аңлады. Дөньясы түгәрәк булган әби, әлбәттә, болай усал итеп сөйләшмәс, аның теле татлы, сүзе мамыклы булыр иде! Хәер, дөньясы түгәрәк әбиләр бармы икән соң ул безнең бу каһәрләнгән заманда?..

Мәһир көлемсерәде.

— Алайса син миңа, апа, шуны гына әйт: Фоат абыйны беләсеңме син?

— Бернинди Фуат-муатны белмим мин... Әйдә, уматвуй атсуды! — һәм әби, артына карана-карана, баскычтан менеп китте.

Шушы уңышсызлыктан соң икенчесе, өченчесе, дүртенчесе башланды. Мәһир белән бер генә кешенең дә сөйләшәсе, аңлашасы килми иде. Һәммәсе дә каядыр ашыктылар, кабаландылар.

«Ярар, дөмегеп китегез шунда!..» — дип, дөньясына кулын селтәп, Мәһир подъездан чыгып барганда, кинәт урам ягындагы ишектән, тугыз яшьләр чамасында булыр, сөйкемле генә бер кыз килеп керде. Кыз нәрсәгәдер бик әсәренгән, дулкынланган иде. Ул, чак кына читкә авышып, Мәһирны урап үтеп китмәкче иде, ләкин Мәһир аны, сорау биреп, туктарга мәҗбүр итте:

— Исәнме, сеңелем! Син бу подъезда яшисеңме?

— Әйе, абый... — диде кыз, — ә сиңа кем кирәк соң?

— Фоат абыеңны беләсеңме?

— Беләм. Ул — милиционер!

— Аның хатыны марҗа! Иеме?

— Түгел. Татарка! Ләкин ул татарча белми.

— Исеме ничек соң аның?

— Жанна.

— Ә-ә... Жанна Д.Арк, димәк ки... Аңла-шыл-ды-ы...

— Ә синең, абый, исемең ничек?

— Тимур, — дип алдады Мәһир.

— Син, абый, Гайдар китабындагы Тимурмы әллә?!

— Әйе. Ә синең исемең ничек?

— Ин-дира-а! — диде кыз горурланып.

— Ә әниеңнең исеме ничек?

— Ул — Долорес, «мичкә»дә сыра сата!

— Әтиең?

— Минем әтием юк! Безгә исполкомнан бер абый килеп йөри. Корсагы — менә мон-ды-ы-ый!

Кече күңелле, беркатлырак булып тоелган әлеге кызчыкка сораулар бирүне шул төштә туктатырга да мөмкин иде. Һәм кызчык үз юлы белән китеп барган булыр иде. Ләкин шул чакны Мәһирнең күңелендә җылы бер хис уянды. Һәм ул кызчыкның коләч күзләренә туры карап:

— Индира, син эт яратасыңмы? — дип сорады.

— Ярата-м! — диде кызчык.

— Минем этем бар бит...

— Кайда ул, абый?!

— Урамдадыр... Әйдә, чыгабыз!

— Әйдә-ә!

Шушы көннәрдә генә Мәһиргә хуҗасыз бер эт ияләшкән иде. Мәһир кая барса, ул шунда бара, яңа хуҗасыннан һич аерыласы килми. Әгәр дә егет берәр төшкә кереп китсә, аның чыгуын иренмичә көтеп утыра башлаган иде. Әнә, бу юлы да...

Мәһир этне кочаклап алды. Башыннан, колакларыннан сыйпады. Аннары, кызчыкны күрсәтеп:

— Бу — синең апаң. Индира булыр, таныш! — диде.

Әмма эт ни өчендер, кызчыкка барырга теләмәде, аңа күзләрен алартып карады һәм ямьсез итеп, ырылдап-ырылдап куйгалады.

— Бобик, кил инде, кил!— диде Индира. Һәм этнең башын сыйпарга дип, ахры, кулын сузды. Сузуы булды, эт көтелмәгән бер җитезлек белән кызга ташланды һәм аның беләгеннән каптырып, тешләп тә алды. Индира чырылдап кычкырып, елап җибәрде.

Маһир үзен-үзе белештермичә: «Пошел во-он!»— дип эткә җикереп кычкырды. Эт, ниһаять, ярамаган нәрсә кылуына төшенде булса кирәк, чиный-чиный качып китте. Шуннан соң егет кызчыкны тынычландырырга теләде. Ләкин кая ул, кызчык аның саен катырак илерә, елый иде.

Шул тирәдән үтеп баручы бер бабай Маһирга:

— Нәрсә карап торасың инде... күтәреп ал да, ятьрәк больниска илт, больниска!— диде.

— Больнис моннан еракмы соң, бабай?

— Юк, юк, әнә генә... күрәсеңме, балалар бакчасына охшаш ике катлы бинаны?

Маһир хастаханәдә Индираны калдырып чыкканда җир өстенә караңгылык җәелгән иде инде. Бәхеткәдер, врачлар Маһирдан шикләнмәделәр, аңа ышандылар. Шулай да егет ашыкты. Бу тирәдән тизрәк китәргә, эзне югалтырга кирәк иде. Һәм ул, ниндидер көйгә сызгыра-сызгыра, каршыдагы күпкатлы ак йортлар арасына кереп югалды.

Күпмедер вакыттан соң ул «мичкә» янында басып тора иде. Ләкин Долорес ханым Маһирга сыра салып бирергә ашыкмады. Ул эчтә кем беләндер сөйләшеп тора иде.

— Димәк, синең... малаең бар.

— Әйе, бар шул,— диде калын гына тавышлы ир.

— Минем дә кызым бар бит!

— У-у... алайса кода белән кодагый булып йөриселәребез алда икән...

— Ха-ха-ха-ха-а-а...

«И сөенәләр, и хыялланалар болар. Ләкин юкка сөенәләр. Әмма алар үзләренең юкка сөенгәннәрен белмиләр. Чөнки теге хәл мәгълүм түгелдер әле аларга. Әгәр белсәләрме хәзер, ул эшне Маһир кылганлыгын сизсәләрме?!»— Егет, сыра салдырып алырга дип сузган кулына карады. Кул, акчасы белән бергә, дер-дер килеп калтырый иде.

Долорес, көлүеннән кинәт тукталып, Маһирга таба борылды:

— Сезгә нәрсә кирәк?

— Сыра!— диде Маһир үз тавышын үзе танымыйча.

— Сыра бетте шул инде, егетем!

— Ә?

— Бетте дим... сыра юк... ту-ту...

Шулвакыт Маһир янәшәсенә теге усал әби килеп басты. Һәм ул, Маһирга тамчы да игътибар итмичә, тәрәзәгә таба үрелеп:

— Долорес!— дип эндәште.

— Нәрсә, әни?

— Индира юкка чыкты бит! Индира!

— Аһ! Син ни сөйлисең, әни?

Маһир, ана белән кызның сөйләшкәннәрен тыңлап бетермичә, бу тирәдән тиз-тиз генә китеп барды. Кая барганын да, кая таба барырга кирәклеген дә белмәде ул һәм бу турыда уйларга да теләмәде. Бары тик ниндидер озынча тимер күпергә барып кергәч кенә һәм күпернең теге башында үсмерләр төркеме шәйләнгәч кенә исенә килде Маһир. Һәм ул борылып, килгән юлы буенча кире китеп бармакчы иде, ләкин күпернең бу башында да үсмерләр төркеме тора булып чыкты.

Әйе, алар күп! Алар әнә ничаклы! Әмма алар күпергә, Маһирны кыйнау өчен түгел, ә үзара сугышу өчен килгән булырга тиеш. Ярар, шушы урында торыйк әле, көтик... Нишләрләр икән?..

Үсмерләр төркеме озак көттермәде, ике яклап, әкерен-әкерен генә Маһирга таба якынлашты.

«Әйе, мин, күрәсең, бу ерткычларның чираттагы корбаны... Бетерә бит болар мине...»— дип коты очып уйлады Маһир. Һәм шуннан соң ул озакка сузып тормады, тотты да күпердән түбән табан сикерде... Аңына килгәндә, башында бүреге, кулында сәгате һәм перчаткалары, кесәсендә акчалары юк иде. Әлбәттә, бу теге кабахәтләр эше инде, кемнеке булсын!

Егет торды да, туңудан калтырана-калтырана өскә, югарыга, урамга менеп басарга азапланa башлады. Ләкин аның сул аягы бераз чатанлый, уң кулы беләк турысыннан үтереп сызлый һәм кабыргалары да, күз-кашлары да, битләре дә сулкылдап-сулкылдап авырта иде.

«Әйе... шәп эләккән миңа...— дип уйлады егет.— Инде бу килеш кая барырга? Бүрексез, сәгатьсез, акчасыз килеш нишләмәк кирәк хәзер? Ай-вай...»

Маһир тырыша-тырыша дигәндәй, яр өстенә менә башлады. Менеп җитте. Инде кая барырга дигән сыман бераз уйланып торды да, ниһаять, төпле карарга килеп, трамвай юлына таба атлап китте.

Тартасы бик килә иде. Ләкин кесәләрендә тәмәкесе юк! Нишләргә? Әһә... әнә бер мужик тәмәке кабызып тора.

— Исәнмесез! Миңа да бер көйрәтерлек бирмәссезме?

Ир кеше Маһирга күтәрелеп карады һәм, тәмәкесен эчкә суырып, авызыннан-борыныннан төтен чыгара-чыгара, кесәсенә тыгылды.

— Рәхмәт!— диде Маһир, тәмәкене алып, ир кешенең тәмәкесеннән ут элдерде дә, ютәлли-ютәлли:— Ну, бирделәр дә соң кирәкне,— диде.— Бүрекне дә салдырдылар, сәгатьне дә, акчаларны да!

Маһирның уйлавы буенча, ир кеше аны хәзер кызганырга, аңа жылы сүзләр әйтергә һәм аның күңелен күтәреп җибәрергә тиеш иде. Ләкин, көтмәгәннән киресе килеп чыкты. Ир кеше Маһирны гаҗәпкә калдырып, тупас рәвештә:

— Төкер син аларга!— диде. Һәм карлыккан тавыш белән өстәп куйды.— Башың исәнме? Күрәм, исән! Бүтән берәүгә дә зарланма инде син... Тора-бара һәммәсе дә булыр!— Һәм ир кеше тротуар буйлап ашыкмый гына китеп барды.

«Әйе шул,— дип сөенеп уйлады Маһир,— дөрес әйттең, абый кеше! Иң мөһиме, баш исәнлеге... калганы — булыр!»— Һәм Маһир трамвайга утырды.

Бер сәгатьтән соң инде ул Марат абыйсының өе янында басып тора иде. Тәрәзәләр дөм караңгы. Аш бүлмәсендә дә ут шәйләнми. Марат абый, әлбәттә, Себерендә булыр. Ә Салисә апа кайда? Авылга, әнисе — Сания әби янына кайтып китмәдеме икән? Шулайдыр әле, авылга кайтып киткәндер...

Маһир сак кына тирә-юньне күзәтеп чыкты. Ишегалдында тыныч, эт тә юк. Күрше-күләннең тәрәзәләреннән дә аңа карап тормыйлар иде. Маһир, аш бүлмәсендәге форточканың эчке ягын капшарга кереште, бармаклары җепкә тиеп китте. Аһ, нинди әйбәт... ачкыч һаман үз урынында эленеп тора икән әле!

Маһир ачкычны алып, өйалды ишеген ачты. Һәм аннары, палас астындагы ачкычны табып, өй ишеген ачты. Керде, ләкин, саклык йөзеннән, электр утын кабызмады. Ул яхшы белә иде: дивардагы калакта, бил каешына беркетелгән күн кыны эчендә, хәнҗәр эленеп тора...

Маһир хәнҗәрне тиз тапты һәм аны шундук биленә тагып куйды. Аннары ул, тумба өстәленең икенче тартмасы эченнән, кесә фонаре тартып чыгарды. Фонарь яңа һәм өй өчен әйбәт яктырта иде. Маһир ашыкмыйча-кабаланмыйча гына акча эзләргә, бүрек эзләргә, сәгать эзләргә, перчаткалар эзләргә тотынды. Эзләгән нәрсәләрне тиз тапты. Аннары аның кулына ике саклык кенәгәсе килеп керде. Кенәгәләр икесе дә Салисә исеменә язылган һәм аларның берсендә мең ике йөз, икенчесендә мең өч тәңкә акча теркәлгән иде. «И-и... әкәмәт!— дип уйлады Ма-

һир.— Авылда, шәмәй Фәләхенең бөтен малы кызына калган, дип, шаугәр килеп сөйләгәннәр иде, ә монда әллә ни артык мал күренми! Алай булгач, кайда соң ул шәмәй Фәләхенең дөнья чаклы малы? Бәлки, бүтән төштәдер... тапмаганмын әле мин аны...»

Эзләнә торгач, Маһир һич көтмәгәндә ике шешә аракыга тап булды. Аракының берсен шундук ачып, шешә авызыннан гына голт-голт эчә башлады. Тиздән авызына соңгы тамчы агып төште. Эзләнүеннән туктальп, ишекләрне бикләп, ачкычларны үз урыннарына куйды да урамга чыкты.

Аның хәзер үзен кыерсыткан шалапайларны очратасы, алардан үч аласы килә иде. Һәм Маһир, шул ният белән «Б» урамында буталып йөргәндә, кемдер аңа бәрелеп китте. Бәрелүче кешенең култык астындагы китабы шапылдап тротуарга төште.

— Әй, күзең чыккыры!— дип кычкырды Маһир бәрелүче кешегә. Теге кеше, куркып булса кирәк, Маһирга бәйләнеп тормады, тиз-тиз генә китеп барды.

Маһир да үз юлы белән китте. Кая? «К» урамындагы биш катлы йортның подвалына! Моңарчы ул «К» урамындагы шул йортның подвалында кунгалап йөрде. Бүген дә кунар, боерса! Һәм кунды Маһир. Иртәгесен торып утырды да, шешәдә калган аракыны эчеп башын төзәткәч, хәнҗәренең үткенлеген тикшерә башлады. Әйе, үткен иде дә соң хәнҗәр, йөзенә китергән чәч бөртекләрен кыеп кына төшерә иде.

— Булды бу!— диде Маһир. Һәм ясканып урыныннан торды.— Инде хәзер Зөбәйдәне эзләп табарга кирәк. Эзләп табарга да, ультиматум куярга... Сайласын: йә — мин, йә — кабер!

* * *

Зөбәйдә уянып күзләрен ачты. Бүлмәгә кичә кич кенә кереп урнашкан ике хатынның урыннары буш иде. Казан белән танышып йөрүләре. Ашыкканнардыр.

Буфетта бер стакан кофе һәм ике пирожный белән тамак ялгагач, кайберәүләр сыман интегә-интегә лифт көтеп тормады, баскычтан җәяү генә менеп китте.

Менә инде ул үз бүлмәсендә... Сулъяк дивар буенда ярыйсы гына чибәр трюмо көзгесе бар иде. Шуның каршына басып бизәнергә керешге. Иң элек шомырт кара чәчләрен дулкын-дулкын итеп ике як иңенә тартып җибәрде. Карлыгачтай кыйгач кашларына орынмады. Күз-керфекләренә беленер-беленмәс кенә итеп, ике төрле сөрмә тартты. Аннары шоп-шома булып алсуланып янып торган ике бит алмасының табигый нәфислеген җуярга базмыйча, Париж һәм Хельсинкидагы фирма мөһерләре сугылган кремнәрен кире сумкасына төшереп җибәрде. Шулай да, ахырда, янар кызыл төстәге помадасын иреннәренә тидереп алмыйча, йөрәгенә тынычлык тапмады. Бу эшләрен дә төгәлләгәч, көзгегә зур кара күзләрен тутырып бер карады да, үз карашының сихеренә үзе бирелеп китә язып, тиз генә тәрәзә буена барып басты.

Тышта ишелеп-ишелеп кар ява иде. Ул ак, ап-ак булып түгел, ә ниндидер кара тәрткеләрдәй төшә-төшә дә, кинәт, исәпсез-хисапсыз ак күбәләкләргә әверелеп әкрен генә, мыштым гына итеп җиргә куна. Берәү... Икәү... Өчәү... Юк, аларны һич тә санап бетерергә мөмкин түгел... Зөбәйдә карашын бер урыннан икенче төшкә күчерде, бер нәрсәдән икенчесенә һәм өченчесенә... Шундый карарга килде: «Авылга, әнигә хат язып салырга кирәк!..»

Тәрәзәдән тышка янә бер мәртәбә карап алды да, чемоданыннан кирәкле нәрсәләрне барлап, хат язарга утырды.

«Исәнме, сөекле әнием!!!— дип башлады ул.— Минем беренче хатымны алып укырга өлгермәгәнсеңдер әле, бәлки. Мин инде менә икенчесен

язам. Тышта кар ява. Авылда да шулай матур булып, күбәләк кебек бөтерелә-бөтерелә явадыр ул, иеме? Һәм шунадыр, ахры, мин авылдагы өебезне, өебезнең почмак тәрәзәсеннән, яуган карларга багып сагышланып, уйларга батып утыручы сине, әнием, күз алдыма китереп, үзем дә сагышланып, офтанып куям.

И бик сагындым мин Сине, әнием, бәгырем! Белмисең генә... Син дә мине шулай сагынасыңмы?! Сагынасыңдыр, әлбәттә!

Инде, әни, минем хәлләргә килгәндә, мин әлегә шөкер, исән-сау. Ә Габделбәр турында теге хатымда тәфсилләп язган идем инде, бусына шунысын хәбәр итәм: аның үпкәсенә бик нык салкын тигән, пульманология бүлегенә күчерделәр үзен. Мин хәзер кунакханәдә торам. Габделбәр янына көн аралаш барып йөрим. Әлегә, инфекция көчле дип, аны миңа күрсәтмиләр, хәлен сорап һәм тегесен-бусын язып кына калдырам...

Мин тулысынча диярлек ялгыз монда. Ялгызлыгым төрле уйлар белән аралашып мине газапламасын өчен, кибетләрдән кибетләргә йөрим, тегесен караган булам, бусын күзәткән булам, ә үзем бер әйбер дә алмыйм диярлек. Ә кичләрне кунакханә бүлмәсендә сынауга әзерләнеп үткәрәм...»

Ул әнисенә ходайдан озын гомер, җан тынычлыгы теләп, хатын тәмамлаганнан соң, киенеп урамга чыкты... Хастаханәгә, Габделбәр янына юнәлде.

Бер озын буйлы егет тимер капка буенда Зөбәйдәне көтә иде. Бу — Маһир, әлбәттә. Маһир бирегә нәкъ менә шушы хастаханәне эзләп килгән иде. Ул берничә сәгать элек кенә телефон аша Үзәк хастаханәнең травматология бүлегеннән Габделбәрне сорашып белгән иде. Маһирның бирегә Габделбәрне түгел, ә бәлки Зөбәйдәне очратмаммы, читтән генә булса да сөйгән кызымның нурлы йөзенә күз салып кала алмаммы, дип килеше иде. Ләкин ул Зөбәйдә белән соңыннан гына — Зөбәйдә Габделбәр яныннан чыккач кына очрашырга ниятли иде. Шулай, бимазаланып, уйланып торганда, Маһирның күзләренә күкнең бер почмагында пәйда булган кара болыт кисәге чалынып узды. Егетнең йөрәге жу итеп китте...

Габделбәр бүген дә Зөбәйдә янына төшеп сөйләшә алмады. Ул әле палатадан да көчкә-көчкә генә чыкты. Тәрәзә каршына барып басты. Монда, дүртенче каттан, бөтен нәрсә уч төбендәгедәй күренә иде. Шунысы сәер: кояшлы көн уртасында, кала өстендә тулы түгәрәк ай калкып тора...

Габделбәр эченнән генә көлемсерәп куйды. Күңеле күтәрелеп китте һәм ул карашын түбәнгә юнәлтте. Әнә аның сөеклесе Зөбәйдә дә хастаханәнең пөхтәләп җыештырылган ишегалдыннан җилле генә атлап чыгып бара.

Их, ничек сагынган Габделбәр, ничек сагынган! Йөрешләрен дә, тавышын да, кулларының җылысын да, чәчләренең хуш исен дә, серле карашларын да, елмаюын да — барысын да, барысын да сагынган... Әгәр мөмкин булса да, ул кош шикелле очып, сөйгәненең иңнәренә барып кунар иде дә... Габделбәр күзләрен йомды һәм татлы хыялга бирелде.

... Зөбәйдә, урамга аяк басуга ук, ни өчендер коймага таба борылып карады. Карады һәм озын буйлы кешенең җилдә аз гына чайкалып торуын күреп алды. «Маһир түгелме соң бу?» — дигән коточкыч уй башын чыңлатып җибәрде. Аны бит авылдан качкан, дип сөйләгәннәр иде. Әллә тагын берәр явызлык кылырга йөриме икән бу? Аның кесәсендә, бәлки...

Зөбәйдә шундый сизенүе белән үз-үзенә: «Киттек!» — дип эндәште. Әмма Маһир югалып калмады, озын күләгә булып, Зөбәйдә артыннан тагылды.

«Азык буласы килгән балык кармак белән шаяра, — дигән уй Зөбәйдәнең йөрәгенә батырлык, кыюлык өстәсә, икенче уй, киресенчә, аның җан тынычлыгын алды. — И-и-и... Син аны әле, чынлап та белеп житкермисең, ахры. Ул шундый явыз, хәйләкәр...»

Уң тарафта бакча бетеп, киртәсез нарат полосасы ямь-яшел булып түбәнгә таба төшеп китә иде. Бу полосаны үткәч, кара урман буйлап шактый юл титаклыйсы бар әле.

Зөбәйдә түзмәде, кыпылт кына артына борылып карады да туктал-ды. Маһир да йөрешен акрынайтты һәм туктап тәмәке кабызырга керешге. Һәм шул мизгел борылышта милиция машинасы күренде. Егет, эшнең асылына төшенеп, урамның икенче ягында туктап торган таксига таба чапты.

— Ах, кача!— диде Зөбәйдә ачынып. Һәм кулларын бутый-бутый шунда таба йөгерде.— Тукта! Туктатыгыз!

Әмма такси кузгалып китәргә өлгергән иде инде. Такси урынына, Зөбәйдә каршына тормозларын шыгырдатып, милиция машинасы тук-тады.

— Яшәүдән туйдыгызмы әллә, кызый?— диде шофер янәшәсендә утырган милиционер.

— Гафу итегез, абый. Таксига утырып бирсдән әле генә бер җина-ятьче качты...

* * *

Маһир борылып тәрәзәдән карады. Зәңгәр билле машина портфель-ле адәмгә орынып ук туктаган иде. Аңлашалар булса кирәк. Әнә ян-нарына Зөбәйдә дә барып басты. Эшләр хәтәрләнә...

Маһир шофер егеткә таба иелә төште:

— Мөмкин булса, кызулатыгыз әле! Бик ашыгам мин!

Таксист, Маһирга күзләренең чите белән генә карап алды, ләкин ашыкмады.

— Сезгә кай тирәгә кирәк соң?— дип сорады ул.

— Проспектка җитәрәк сулга борылыгыз, аннан күп калмый.

— Һо-о! Анда керергә ярамый...

— Ни-чек ярамый?!

— Анда «кирпеч» тора.

— Үҗәтләнмә инде, брат... Алайса син лутчы менә монда борыл! Менә шушы урамга!

— Бу бит зират урамы!

— Миңа зират кирәк тә инде.

— Ник аны шулай дип әйтмисез?

— Әйтеп торам бит, туганымны күмәләр, соңга калам дип!

— Әйтергә уйлагансыз гына... Ләкин алай дип әйтмәдегез!

— Ярый, алайса, гафу итегез!

Зират буенда, чынлап та, бер автобус, бортлы ике машина һәм берничә автомобиль тезелеп тора иде. Кемнедер күмәләр иде, ахры.

Такси артка чигә-чигә борылды да, җитез болан кебек, кинәт куз-галып китте. Маһир, таш коймалы зиратның биек тимер капкасыннан кергәч, үзен яңа дөньяга килеп эләккәндәй хис итте, күңеленә әкренләп тынычлык иңде. Каршыда киң генә асфальт юл булып, юлның һәр ике ягында тимер рәшәткәле, мәрмәр плитәле каберләр һәм юкә, каен агач-лары тезелеп тора иде. Аннары ул шунысын да чамалап алды: монда каберләр бик тыгыз, бер-берсенә якын һәм янәшә торалар иде ки, араларына барып керсәң, чыгар юл тапмыйча аптырап бетүең дә мөм-кин.

Аның карауы юл әйбәт. Үзе киң, үзе шома, такыр. Әйтерсең, бу юл кешеләрне каберлекләргә түгел, ә ниндидер серле йортка алып бара!

Маһир, карана торгач, туйды. Каберләр өстендәге күңелгә шом салып торучы өнсез матурлыклар аны кызыксындырмыйлар иде инде. Ул бер йөрәге белән тышкы дөньяга омтылды, уйлары белән чынбарлык-ка әйләнеп кайтырга мәҗбүр булды.

... «Мин биредә йөрим. Габделбәр больницада ята, ә Зөбәйдә анда...»

Маһирның күзләренә яшь тыгылды, йодрыклары йомарланды.

... «Юк, монда түзеп булмый, түзәргә мөмкин түгел,— диде ул нәфрәтләнеп.— Акылга утыртырга кирәк аны. Безне тилегә санап йөрмәсен. Кикриген шиңдерергә кирәк!» Һәм аның күз алдыннан иренең уңмаганлыгы турында әйтеп зарланучы Салисә, исерек Руфина берәм-берәм үтеп киттеләр.

«Зөбәйдәне дә шулар рәтендә күрәсе килә!»

Маһир мыскыллы елмаеп, йөзен чытты.

«Һәм аннары йөзенә төкерергә. Юк, төкерү генә аз, суда бүрткән камчы белән...»

Маһирны чаж-чож иткән, кычкырган, ыңгырашкан авазлар исенә килергә мәҗбүр итте.

«Юк, минем Зөбәйдәне алар рәтендә күрәсем килми. Әгәр мин Зөбәйдәне алар рәтендә күрсәм, тормышта яшәүнең бер генә мәгънәсе дә калмас иде. Зөбәйдә андый түгел... Андый булмаячак та... Зөбәйдә — дөньяда иң әйбәт кыз. Иң инсафлы. Иң тәртипле. Иң акыллы. Мин аны яратам... Яратам... Яратам һәм яратачакмын». Маһирның каһкаһәләп көләсе килде. Ни өчен? Нәрсәдән? Ул моны үзе дә белми иде. Бәлки Зөбәйдә дигән йолдызга үзенең буе җитмәү гарьлегеннән, аптыраганнандыр. Бәлки, шулайдыр...

Шул мәлне кай тарафтадыр әче итеп сирена улаганы ишетелде. Маһир авызын йомарга да онытып, яшькелт күзләрен шар ачып, баскан урынында катты да калды. «Милиция машинасы бу!.. Монда таба килүедер!.. Менә аны, менә аны хәзер тотып алачаклар! Аннары... Юк, тотмый торсыннар әле!»

Маһир яшен тизлегендә карлы сукмакка ташланды һәм, кайда сөртенеп, кайда мәтәлеп китеп, тез башларын сыдырып, кулларын канатып шашкан кешедәй чапты да чапты. Куркуыннан ул үзенең дөп-дөп иткән аяк тавышларын һәм чыбык-чабык сынып калган авазларны аермыйча, минем арттан куып киләләр, дип уйлады. Менә алда таш койма күренде. Ләкин аны сикереп чыгу мөмкин эш түгел, койма ифрат биек иде. Маһир койма буйлап китте. Маһир, ни булса шул булыр, дип, мәче житезлегендә, койма янәшәсендәге агачка үрмәләп менеп китте. Һәм агачның юан ботагы буйлап барды-барды да тышкы якка сикерде. Бәхетенә, көрткә туры килде. Сикереп торды һәм дамбага таба чаба башлады.

«Өлгерергә, ничек тә өлгерергә!»

Ул арада милиционерлар да койма аша төшеп беттеләр шикелле тоелды аңа.

«Хәзер менә ата башласалар?.. Тизрә-ә-әк, өлге-рер-гә, өлге-рер-гә-ә...»

Маһир хәзер чапмый, дамбага дүрт аяклап үрмәли иде.

Менә ул соңгы көчен туплап аякларына калыкты һәм бар куәтенә алга омтылды. Инде дамбаны менеп җитәргә дә күп калмады. Биш адым... өч, ике... Менеп җиттем дигәндә генә ул, кинәт хәле китеп, җилкәсе белән артка таба егылды. Шулчакта, гүя, мөгезле бер алып, дамбаның икенче ягыннан күтәрелде дә, аягы белән егетнең күкрәгенә басты.

— Әни-и-и!

Маһир чытырдатып күзләрен йомды.

Бераздан ул кабат күзләрен ачты. Күк йөзендә хәрәкәтсез торып калган алсу-ак болытлар тирәсендәге кечерәк кенә бер кара болыт кисәге аның игътибарын үзенә җәлеп итте. Ул аңа бер мәл шикләнеп карап ятты. Һәм шунда бала вакытында әбисенең әйткән сүзләре исенә төште. «Гомереңдә юлыңа кара мәче очрамасын, ә кыш көне күзләреңә кара болыт чалынмасын. Моның берсе — бәхетсезлек, икенчесе — бәхетсезлекнең фаҗигага сукмак салуы булыр!..»

Маһир, тетрәнеп, урыныннан сикереп торды. Кая барганын да белештермәстән, дамба буйлап атлап китте. Анда кояш балкый. Әмма кышкы кояшның нурлары дөньяны җылытмый һәм җылытырга уйламый да иде.

* * *

Маһирның көтмәгәндә генә өйгә кереп, Марат абыйсының кыйммәтле бүреген, электрон сәгатен, мех эчле перчаткаларын, бүләк хәнҗәрен һәм аннары чумара акчаларын, ике шешә аракысын да урлап алып чыгып китүе Салисәне авыр уйга салды, катлаулы кичерешләргә дучар итте. Шайтан алгыры, ул аны кабат килер дип, кичләрен, барасы җирләренә бармыйча, юкка гына көтте. Ләкин Маһир бүтәнчә күзгә-башка чалынмады, суга төшкәндәй юкка чыкты.

— Их, хәсрәт капчыгы...— дип сүкте Салисә Маһир кайнешен.— Әниләрен утка салуы гына җитмәгән, монда килеп, аннары кем беләндер өемне чистартып чыгып, минем дә тәмам җан тынычлыгымны алды бит, хайван! Ни булган иде инде шунда теге чакны милициягә үзе барып хәбәр итсә... Болай качып йөреп, аннары җинаять өстенә җинаять кылып җиңеллек килми ич инде аңа.

Салисә шулай үз-үзе белән каршылыкка кереп, тузынып йөрде-йөрде дә, тора-бара бу хәлгә күнекте. Маһирның җинаятьләре аңа хәзер күптән күргән ямьсез төш сыман булып кына тоела иде. Шулай да ул, әниемне һәм кайнанам белән кайнатамны күреп сөйләшмичә булмас, дип уйлады, һәм бер шимбәне тотты да авылга кайтып китте.

Ләкин Сания әби авылда юк иде. Аны, салкын тиеп бик каты авырып киткәч, район хастаханәсенә илтеп салганнар икән. Салисә, бу хәбәрне әйтүне өрәк Сатирәгә хөрмәт йөзеннән (әнисен кызганып түгел), пышын-пышын гына елап алган булды. Һәм аннары сәгатенә карады. Соң шул инде! Һәм ул, хастаханәгә әнисе янына иртәгә иртүк барырга булып, Маһирларга юнәлде.

Салисәне кайнанасы урын өстендә яткан көйгә каршы алды. Ул бик бетерешкән, ябыккан. Күзләре моңсу һәм боек карыйлар иде.

— Туңам,— диде кайнана калтыранып.— Гел генә дә җылы керми эчкә... Атаң, мич башына ятып кара, дигәч, анда да ятып караган идем, файдасы тимәде...

Салисә кайнанасының зарын тыңлый-тыңлый өй эчен тәртипкә китерергә тотынды. Гадәттә, хуҗабикә авырып китсә, өйнең яме бетә торган була. Гүя өйнең кояшы сүнә. Һәм менә берничә сәгать үтүгә, өй эченә янә кояш чыккандай булды. Юылган идән дә, тузаны сөртелгән өй җиһазларында — һәммә җирдә көләч нурлар уйный башлады.

Мәйсәрә түти дә чак кына тернәкләнеп китте. «Берәр чынаяк чәй эчәм дә»...— дип утырган иде, дүртенчесен эчә инде. Ләкин бу шатлык-куанычлар озак дәвам итмәде, өйгә дөм исерек Гыйльметдин агай кайтып керде. Ул әллә җырлый, әллә көйли — белмәссең. Сыер мөгерәгән тавышлар чыгарып, урындыкка утырды да шуннан бөгәрләнеп төшеп, дөбердәп идәнгә ауды.

Нихәл, килен — юк, исәнме, карчык — юк, гырлап йокыга да китте. Йокысы... Диңгез пиратымыни: хр-р-р да хр-р-р!

— Ай-һай, эчкән әти!— диде Салисә бернихәтле тын торганнан соң.

— И киленкәй... Көн дә шушы хәл, көн дә шушы тамаша инде,— дип җавап кайтарды Мәйсәрә түти.

— Тукталганы бармы соң аның бу эчүеннән?

— И киленкәй, туктаган кая. Картайган саен азына гына бара. Инде кешегә күренерлегемне калдырмады. Таң тудымы, өй борынча эчәргә теләнеп йөри башлый. Кергәч, борып чыгармыйлар тагы, эчертәләр.

Кеше бит ул сине түгел, күбрәк үзен кайгырта. Бу — заправщик, миңа кирәк кеше, йомышым төшәр, дип уйлый.

— Әйе, күнелле хәл түгел бу.

— Юк инде, юк.

Салисә чәен эчеп куйганнан соң янә сүз башлады.

— Маһирны да әти генә бозып бетергән бугай инде аны.

— И киленкәй... Җиде яшьтән өйрәтте ул аны эчәргә. Икәүләшеп җырлап кайталарые ярты төн уртасында. Мин ишек ачарга чыгам, һай, имансыз, тагын эчеп кайткансың икән, дип, Гыйльметдинне тиргим, ә Маһир әтисен якларга тотына. Баксаң, алар икесе тиң исерек икән. Әнкәң әрләгәндә мине якларсың, яме, улым, дип эчертә икән Гыйльметдин Маһирга. Менә шул...

— Кем ул-л?— дип кычкырып җибәрде Гыйльметдин агай кинәт. Һәм тормакчы булып терсәкләренә таянды, тузгыган ярым чал башын күтәрде, исереклектән тонган яшькелт күзләрен өстәл ягына таба текәде.

— Салисәмени ул? Салисә килен кайтканмыни?

Мәйсәрә түти белән Салисә бер-берсенә мәгънәле генә төбәлеп, тынып калдылар.

— Килен, бәгырем!— диде Гыйльметдин агай һәм торып күрешергә боздай салкын кулын сузды.

* * *

— Менә шулай-й,— дип сузып кабатлады Гыйльметдин агай.— Күзкашларыңны сөрт, тырнакларыңны кис... Андый хатын-кызларга ышанмыйм мин, ышаныч аз аларда.

— Үзеңне бел, әти,— диде Салисә кимсенеп. Аннары, кинәт хатын-кыз горурлыгы кубып, чаяланып өстәде:— Әнә, Маһирыңны өйрәттең инде...

Бу сүзләр Гыйльметдин агайның иң авырткан төшенә барып тиде булса кирәк. Ул ачы суган капкандай йөзен чыңып куйды һәм кырт борылып, алъякка кереп китте. Күп тә үтмәде, ак өйдә гармун да, телевизор да, магнитофон да телгә килде.

— Һаман шул гадәте икән әле.

— И киленкәй! Миемне черетеп бетерде инде, чыкмаган җаным гына калды.

— Син аны, әни, куркытып кара, ташлыйм да Мәскәүдәге кызым янына торырга китәм, диген.

— Әйтмәгән кая инде.

— Нәрсә ди соң?

— Бар, кит, ди. Аналы-кызлы ятарсыз шунда... ди. Ичмасам Маратыбыз да юньле булып чыкмады...

— Юньсез дә түгел инде ул, әни. Тик менә чыгып китеп йөрүләре генә...

— Шуны әйтәм ич инде мин дә!

Шулвакыт Гыйльметдин агай ишекне ачып кычкырды:

— Янында тора торган кияү кирәкмени?.. Иң элек күз-кашларыңны сөрт, тырнакларыңны кис. Аннары сульфат кислотасы белән телеңне юу! Телең бик озын.

— Синең белән сөйләшмим әле мин, яп ишекне!

— Ә шулаймы? Син минем киленем түгел болай булгач, кит, чыгып кит минем өемнән!

— Шулаймы,— диде Салисә кайнатасын үчекләп һәм кайнанасына кайгырмаска, үз-үзен бетермәскә кушып, ишеккә юнәлде.

— Кайтып керәсе булма!— дип кычкырып калды Гыйльметдин агай килене артыннан.

* * *

Клубта кино бара иде. Салисә урта рәттәге бер урынга барып утырды. Утыруы булды, янәшәдәге егет аңа иелеп һәм текәлеп-текәлеп карарга тотынды. Кино беткәч тә әлеге әрсез егет Салисә артыннан тагылды.

— Кая барасың кызларыңны калдырып?..— диде Салисә, ни уйларга да белмәгәч.

— Сине озата барам,— диде егет турыдан ярып.

— Мин кем соң?— дип авызын ерды Салисә.

— Һе, белмәскә... Син — Салисә!

— Апа диген.

— Телем әйләнми.

— Ни өчен?

— Мин сине яратам!

Салисәгә гаҗәп тә кызык булып китте. Бу егет — ни акыллы, ни тиле Гаделша иде.

— Нәрсәгә яратасың мине, ә, Гаделша?— дип «уйнарга» керешге Салисә.

— Билгеле инде, нигә аны сөйләп торырга, ошаганга яратам,— диде Гаделша һәм кулын хатынның иненә салды.

— Кара! Мин кияүдә бит инде.

— Кайда киявең?

— Еракта ул.

Гаделша батырая төште һәм кулын Салисәнең иңеннән алып биленә куйды.

— Узган ел да еракта, быел да еракта...

Салисәнең кинәт ачуы купты. Шушы тиле аның тормыш хәлләрен белеп торсын инде... Шулай да ул ачуын тышка чыгармады: кызып китеп, әллә ниләр әйтеп, Гаделшаны куркытып җибәрүдән сак булырга тырышты. Ә Гаделша аңа кирәк, бик кирәк ләбаса бу кичне!

— Әйт әле, Гаделша җаным, тыкрыкта кар күпме?

— Кайсы тыкрыкта?

— Менә бу тыкрыкта.

— Күп дип... Юл бар ич анда!

— Алып бар алайса мине шул юлдан.

— Кая?

— Бара-бара әйтермен, яме!

Киттеләр кереп тыкрыкка. Төньяктан галәмәт салкын җил исә. Кашкерфекләр һәм шәл читеннән чыгып торган чәч чуклары шундук бәсәрә дә бозланып ката. Салисәнең аяклары астында кар шыгырдый. Ә Гаделшаның фабрикада әвәләнгән зур кара каты итекләре астында кар яман да каты итеп тавыш чыгара.

Тыкрык бетте. Салисә Гаделшага:

— Менә бу урамга борыл,— диде.

— Бу — сезнең урам ич!

— Ие, Гаделша, безнең урам бу, безнең урам!

Бераздан алар, кар эченнән рәшәткә баганалары һәм мәһабәт булып капка баганалары басып торган янган өй урынына килеп туктадылар.

— Сания әбинең өе янганын мин күрми калдым,— диде Гаделша.

— Нәр-сә?

— Кемдер ут төрткән, диләр.

— Фердинанд! Миңа булмагач, бүтәннәргә дә булмасын дигәндер.

Салисә уртадагы капка баганасыннан, карга бата-чума, туп-туры эчкә таба кереп китте. «Биш, алты... ун... унбиш...» дип санады ул. Аннары сулга таба җиде адым атлады да Гаделшага:

— Бар әле, үскәнем, миңа кирәк белән лом алып килеп бир,— диде.

— Хәзер... Аннары бер үптерәсеңме соң?

— Бар инде, бар! Соныннан сөйләшербез, соныннан!

Тиле китте. Өйләре ерак түгел иде, озак тормады: иненә лом салып, кулына очлы көрәк тотып, авызын ерып килеп тә житте.

— Үптерәсенме?

— Аннары... Казы менә бу төшне!

Гаделша казый башлады. Кар калын һәм каты иде. Тиз-тиз көрәгәнгә күрә, егет тирләп үк чыкты, ахры. Һәм ул ара-тирә Салисәгә таба борылып карарга керешге.

— Казы, казы!— диде Салисә егетне дәртләндереп.— Аз казыдың ич әле! Тагын казы инде бераз!

Гаделша казыды да казыды. Кар көрәлеп беткәч, бозлы жирне көрәгенең очы белән чокчырга тотынды.

«Монда бәдрәф урыны булырга тиеш!»— дип уйлады Салисә. Һәм ломын, бар көченә каерылып Гаделша көрәк белән эзләгән урынга батырды. Лом, туңның каршылыгын сындырып, кинәт ниндидер бушлыкка төшеп китте. Борыннарына яман ис бәреп керде.

— Фу-у-у...— диде Гаделша кашын-йөзен жимереп.— Бәдрәф урыны ич бу!

— Түгел! Түгел!— диде Салисә һәм ломы белән кабалана-кабалана бушлыкка төртә бирде. Шулай итеп, ломы каты әйбергә, ягъни бакыр әржәгә тимәсме дип жан-фәрман тырышты.

«Монда түгел, ахры,— дип уйлады Салисә.— Әти аны иске бәдрәф урынына күмеп калдырмадымы икән? Әгәр чынлап та шулай булса, бу тирәгә җәй кайтып казынырга туры килер! Ә хәзергә...»

— Фәләхетдин абзый хәзинә күмеп калдырганмы әллә монда?— дип сорады беркатлы Гаделша, кызыксынып.

— И-и, нинди хәзинә күмсеннәр монда, тизәк ич, күрмисеңмени!— диде Салисә, тавышын күтәреп.

— Тизәк шул!— диде Гаделша.

— Ломыгызны буядым инде, амауый.

— Кайгырма, Салисә карчык! Мунчага алып барып юам мин аны.

— Нинди мунчага?

— Ни инде, Вафатдин абзыйлар мунчасына! Алар якканнар ие бүген кич. Үзләре кергәннән соң да жылысы, сулары мулдыр әле.

— Һәй, алай булгач, әйдә, алып бар мине, Гаделша жаным, шул мунчага, юыныйм әле әйбәтләп... Юкса, миннән тизәк исе килергә мөмкин, ие бит?!

Киттеләр. Вафатдин абзыйлар мунчасы буа каршлагы өстендәге бакча читендә икән. Сүз дә юк, гыйш-гыйшрәт өчен аулак урын. Ләкин Салисәнең күңеле бүген бүтәндә иде. Ул бит әтисе яшереп калдырган хәзинәне тапмаммы дип кайткан иде. Ә хәзинә «анда» юк. Бәлки аны берәрсе күптән табып алып киткәндер инде. Ә бәлки Хисаметдин абый табып алгандыр. Кем белә... Ә бәлки шунда, бәдрәф төбендә, табып алганны көтеп ятадыр ул. Их, ул хәзинәне таба алсамы?! Белер иде ничек яшәргә кирәклекне...

Салисәнең исәбе юыну түгел, ә бу мунчада төн кунарга калу иде. Аннары иртүк торып чыгар да, автобуска утырып, районга әнисе янына хастаханәгә китеп барыр. Ә теге бакыр сейф турында әни нәрсә дә булса белә торгандыр шәт, белми булмас!

* * *

Казанга әйләнеп кайтканда Салисәнең күңеле күтәренке, кәефе шәп иде. Дөрес, бер карганда аңа сөенергә сәбәп тә юк кебек. Чөнки Сания әби, түшеннән алып аңа саклык кенәгәсе тоттырганда, әйтте:

— Монда акча, кызым. Үнбер мең тәнкә! Без аны атаң белән гомер буе жыйдык. Акча минем исемгә салынган... Авылдагы саклык кассасын-

да васыятем бар... Әлегә кенәгә синдә торып торсын, кызым, дөнья хәлен белеп булмый, үлеп китәрмен җә...

— Үлмәссең, әни, терелерсең, алла боерса! — диде Салисә елмаеп.— Ә кенәгәң чынлап та миндә торып торсын: җә югалып куяр, ие бит!

— Ие шул, кызым!

— Әни! Минем синнән бернәрсә сорыйсым барые әле...

— Әйт, кызым.

— Кайчандыр әти бәдрәфкә алтын-көмеш күмгән, ди. Шул сүз дөресме, әни?

— Кит әле, кызым, юкны сөйләмә! Каян алсын ул алтын-көмешне?

— Ә нәрсә күмде соң?

— Белмим, кызым. Мин каян белим инде.

— Әти бит... Илһамга әйткән булган... йөз сиксән мең тәңкәлек хәзинә күмүе турында...

— И-и-и... шаярып әйткәндер инде алайса. Атаң гомере буе шундый әкәмәт кеше булды инде.

Бусында әнисенә ышанды Салисә. Димәк, әтисенең йөз сиксән меңлек хәзинәсе бар дигән сүз ялган булган! Ярый, аның каравы, Салисәнең кулына унбер мең сум акча килеп керде. Дөрес, ул акча әле әнисенеке булып хисаплана. «Әни үлгәч, алар һәммәсе дә минеке булачак! Мин аларны, әни васыять иткәнчә, абыйга һәм энеләремә тигез бүлеп бирмәячәкмен. Мин аларга бер тиен дә бирмәячәкмен. Тотсыннар! Алар ир кавемнәре. Үзләренә кирәк хәтле акчаны гына табарлар, тапмый калмаслар!»

Салисә шундый өметләр белән канатланып эшенә китте. Эшендә дә аны шатланышып каршы алдылар һәм буфет белән базарга чыгардылар. Студентлар кышкы ялда булганлыктан, ул үз буфетын бикләп, башка берәү урынында эшләп торган иде. Буфетчы хатын «больничный»дан килгәч, аны йөземдер, алмадыр ише җимешләр сатарга җибәргәләделәр. Бүген инде менә ул үз буфеты белән чыкты. Башына ап-ак калфак, өстенә март карыдай җете ак халат киеп, ул әнә кофе кайната. Ә аның «кайный» торганы икәү, шул сәбәпле ул кулларын бер генә минут та тик тотмый. Берсе белән кофе агызса, икенчесе белән тәм-томга үрелә һәм шунда кемнәр беләндер шаярып сөйләшергә, кемнәр беләндер күз кысышып, танышып алырга да өлгерә иде.

Өйләгә чаклы шулай матур гына, күңелле генә сату итте Салисә. Ул хәтта үзен гармун уйнасалар, кушылып җырлап җибәрерлек дәрәҗәдә хис кылды. Чөнки аның белән бүген кич фәлән-фәлән төштә очрашырга атлыгып торучы кавалерлар да бар иде. Салисә бүген менә шуңа да сөенә, аның күңеле менә шуңа да күтәренке иде. Аннан соң, көлсәң көл, еласаң ела, аккошлар янындагы чәүкә шикелле, мәһабәт кавалерлар арасында кавказлы бер «донжуан карт»та бар иде. Ул карт иртәдән үк бөтерелә иде инде Салисә тирәсендә. Әле кофе эчкән була, әле чәкчәк ала һәм аны «тәмле» дип үтереп мактаган була. Аннары тотына Салисәне мактарга... Ә Салисәгә бу — кызык! Ул кавказлы бабайның сорауларына да шаян җаваплар кайтара, туктаусыз елмая һәм шырык-шырык көлә иде. Ә бабай тегендә-монда киткәләп салып та килгәли иде бугай, ул ярыйсы гына кызмача да иде. Ниһаять, алар арасында менә мондыйрак сөйләшү булды:

— Үз гомеремдә унҗиде мәртәбә өйләндем мин,— диде теге җитди генә итеп.

— О-о-о,— диде Салисә, башын-күзен уйнатып һәм бик гаҗәпләнгән булып.

— Э-э-э, менә, унҗиде мәртәбә,— диде бабай кабатлап. Шул сүзләрне әйткәндә аның бөркетнекедәй күз карашына уйчан бер төс иңде.

— Ник ул тамаша өйләндең соң, бабай?

— Үлделәр шул бичаракайлар, бер-бер артлы дөнья куеп бардылар.— Бабай, борынын тартып, авыр сулап куйды.

— Әй, кыйнап үтергәнсең лә син аларны, бабай?

— Анламыйм...— диде бабай, очлы күзләрен кыюсыз гына Салисәгә төбәп.

— Ну,— диде Салисә, шаркылдый-шаркылдый, суккан сыман ишарә ясап.— Кнутик белән ләбаса менә монда... Салисә шап-шоп китереп үзенең арт санына сугып та күрсәтте.

— Да, да...— диде бабай дәррәү җанланып сүзне икенчегә борып.— Миндә акча кү-ү-үп, мин бай, мин әйбәт. Бабай чак кына артына чигеп үзен сыпырып күрсәтте:— Таныш булыйк!

— Һи, карт шул инде син, бабай... соңга калгансың!

— Әйе, карт, карт,— диде бабай, ләкин әле һаман да Салисәнең үтергеч тәнкыйте белән килешмичә, сүз көрәштерә биреп:— Мин ялгыз, понимаешь! Минем Кавказда өй әйбәт, бакча әйбәт. Миңа иптәш кирәк. Сиңа яхшы тормыш кирәкмимени? Ә мин бай!

— Уй, үләм инде,— диде Салисә үзалдына пырхылдап.— Әллә бу миңа чынлап та тәкъдим ясамакчы була?

— Әйе, син... әнә нинди таза,— диде бабай үткен карашы белән Салисәне баштан-аяк капшап.— Син... шундый-шундый матур! Во син! Менә мондый... Югары сортлы виноград шәрабы кебек!

Салисә бу «үтереп» мактауга, салкыннан җылы өйгә кертеп куйган бозлы сөт сыман, эреп ага язды. Аның шунда яшь кызлар шикелле чытлыкланасы, сикерәсе, биисе, туйганчы иркәләнәсе, назланасы һәм һич туктаусыз сөеләсе килде. .

— Шулай да син карт шул инде, бабай!— диде Салисә шаяртуын дәвам итеп.— Минем шул синең акчаңа, өеңә һәм бакчаңа гына канәгать булып яшисем килмәс, берзаман күңел ачасым да килеп куяр, шулчакны нишләрсең син, бабай, ә?!

Кавказлы бабай кинәт үзгәреп китеп:

— Ә шулаймы... Ярый алайса...— диде.— Минем бирелә бер егет бар! Дөрес, ул яшь әле. Аның үз йорты да, бакчасы да, күп акчасы да, малы да, фәләне дә юк! Таныштырыйммы?..

— Нинди егет ул, бабай? Әллә үз малаеңмы?

— Минем күрше ул. Әнә теге почмакта әфлисун сата. Чакырыйм-мы?

Уеннан уймак чыга, диләр. Салисә хатасын төзәтергә ашыкты.

— Юк, кирәкми бабай, нигә мәшәкатьләнеп торырга! Минем ирем бар бит.

— Юк, сезнең ирегез юк!

— Каян беләсең, бабай? Маңгаема язылганмы әллә?!

— Унҗиде хатын алган кеше мин, барысын да үтәли күрәм.

— Ничек күрәсең инде аны?

— Күзеңә карап! Күзләр алдамыйлар...

— Алайса, син, бабай, хатыннарың белән сөйләшеп тә тормагансың, аларның теләкләрен күзләренә карап кына белгәнсең?

— Киресенчә, кызым! Менә мин синең белән нәрсәдән башладым бу сөйләшүне!

— Унҗиде хатынга өйләнүеңнән... бабай җаным!— дип хихылдады Салисә.

— Менә шул, шул. Әгәр дә синең ирең булган булса, тормыш ягың көйле булса, син ул хатыннарның язмышлары белән тирәнтен кызыксыныр идең. Унҗиде хатынның унҗиде язмышы бит югыйсә, кавказ картының легендага тиң гомере. О-о-о! Алар... Алар... Ә син? Эх-эх-х!..— Бабай, карчыганыкыдай борын яфракларын калтыратып, Салисәгә йотылды. Бу юлы аның бөркетнекедәй очлы күз карашында тимер салкынлыгы бар иде бугай. Һәрхәлдә, ул Салисәгә шулай тоелды. Аннары янә Салисәгә текәлде. Бу юлы инде картның күзләрендә нәфрәт уты гүли иде.— Кыйнап үтергәнсең, имеш... Кнутик белән менә мон-да-а-а... Тфү!

Салисә көлеп торган кояшны кинәт болыт каплагандай булып, сүрәнләнеп, кызарынып-бүртенеп, күкле-яшелле тавыш белән бабайга берәдән эзен суытырга кушып кычкырды.

— Һә-ә-ә! Шулаймы?.. Синең кофең да натуральный түгел бит...— диде бабай.

Салисә каушады, нервыланып калтыранырга тотынды. Аның йөзенә генә түгел, ап-ак муенына да, сөттәй ак беләкләренә дә тимгел-тимгел кызыл таплар бәреп чыкты. Ул берничә мәртәбә пирожныен, берничә тапкыр стаканын төшереп җибәрде. Аннары кигәвен кугандай як-якка кулларын селтәп:

— Сатмыйм, сатмыйм... Барыгыз әле, китегез...— диде.

Ләкин сатып алучылар китмәделәр һәм китәргә уйлап та карамадылар. Күзләрен тозландырып, нәрсәдер көтеп басып тора бирделәр. Шуннан соң Салисә, яшь баладай үпкәләп, халыкка арты белән борылды да, үзен кызгандырырга теләп, ахры, пышын-пышын гына еларга керешге. Ә теге баштан баягы карт белән дежур милиционерның килгәне шәйләнә иде.

Салисә сүзсез-нисез генә лавкаларның тартмаларын ачып күрсәтте. Ә милиционер башка тартмаларны да ачып, тикшереп карады. Ләкин «кофейный напиток» юк иде. Һәм бу вакытта кавказлы бабайдан да җилләр искән иде. Салисә сөенеченнән күз яшьләре аша елмаеп, көлемсерәп куйды.

— Гафу итегез, служба!— диде лейтенант, кулын чигәсенә тидереп һәм аннары мәгънәле генә итеп елмайды. Аның күзләре гүя: «Миндә тамчы да гаеп юк, кадерлем. Мин шулай ук ир кеше бит. Әгәр кичкә... чакырсаң, мин — әзер!»— ди иде.

— Юк!— дип, кырт кисеп җавап бирде Салисәнең күзләре.

Милиционер исә: «Уйла-уйла, мин һәрвакыт кирәкле кеше»,— дигән сыман, ашыкмый гына атлап китеп барды...

* * *

Шифаханә. Барысы да йоклый кебек. Кизү торучы шәфкать туташы да йоклый булыр. Йокласын! Йокының иң татлы чагы... Ә түбәндә, беренче катта, бала табу бүлегендә ниндидер хатынның:

— Ай-вай... Әни, үләм!— дип илереп-илереп кычкырганы ишетелә. Бусы биредә гадәти хәл. Һәм андагы кычкырган авазларга бүтән бүлекләрдәге уяу авырулар тамчы да игътибар итми. Күнегелгән, күрәсең.

Шулай да Габделбәр йокламый. Ул төш күрә. Авылда чагы, имеш. Бала вакыты. Әнә ул сәкедә «чиртеш» уйнап утыра. Әтисе эшкә киткән, ә әнисе идән юа. Менә ул мунчаласын чиләктәге суга тыгып әйләндерә-әйләндерә сыгып алгандагы тавыш әллә кайдагы диңгез дулкыннарының комлы, ташлы ярга бәрелеп артка чиккәндәге сыман көйле авазлар чыгара һәм шул охшаш авазлар Габделбәрнең колагын туктаусыз иркәли, күңелендәге нечкә кылларны рәхәт зеңләтеп, аның бөтен дөньясын сафландырып җибәрә төсле. Габделбәр башын күтәреп, әнисенә карый. Ә анасы улының бу күз карашларын сизми дә, җаны-тәне белән эшкә бирелгән. Габделбәр әнисенең игътибарын үзенә җәлеп итәргә һәм аның йомшак, ягымлы тавышы белән назлап эндәшүен ишетергә тели. Шул нияттә дөпелдәп идәнгә сикереп төшә. Әмма көткәне урынына әнисенең:

— Идән кибеп җитмәгән бит әле, менеп кит хәзер үк!— дигән таләпчән һәм катгый тавышы яңгырый.

Габделбәр иреннәрен турсайта да борынын лыштырдата-лыштырдата сәкегә менеп китә һәм эченнән генә әнисенә әлләниләр тели башлый.

«Суы түгелсен иде хәзер... Шәп булыр иде...»

Габделбәр күзләрен тозландырып утыра торгач, әнисенең күрсәткән игелекләрен берәм-берәм хәтеренә төшереп, әнисен кызганып елап ук җибәрә. Әни кеше дә баласын кызгана. Менә ул тураеп баса да, кулларын сөртеп, почмак якка чыгып китә. Озак та үтми, кулына нәрсәдер тотып әйләнеп тә керә:

— Мә, улым! Ашап җибәр әле шушыны!..— ди. Яратып кына улының арык аркасыннан сыйпап, кагып куя.

Ул исе дә исе! Габделбәрнең авыз сулары килә. Ул, ике кулы белән дә йомарлап тотып, дәп-дәү алманың хуш исләр белән тулы алсу тәненә ак тешләрен батыра.

И-и, Габделбәрдән дә бәхетлерәк бала бармы икән бу җиһанда?! Әнә бит, янәшәсендә генә киң күңелле, юмарт әнисе басып тора. Шул ук вакытта чип-чиста тәрәзәләр аша кояш балкып караган да, сап-сары итеп юылган идәннең сафлыгына, пакьлыгына исе киткәндәй, диварларны, түшәмне, бөтен өй эчен нурландырып ташлаган. Кая бакма — нурлар балкышы, нурлар тирбәнеше... Бу сихри яктылык Габделбәрнең алмасына да төшә. Ул гүя, алма белән бергә, кояшны да тешләп, авыз итеп карый!..

Габделбәр шул мәлне уянып китте. Колагы төбендә чынлап та дулкыннарның ярга бәрелеп артка чиккән һәм янә бәрелгәндәге сыман тавыш иде. Габделбәр борылып карады һәм Нюра түтәйнен идән юуын күреп алды. Менә кем чыгара икән ул диңгез дулкыннары тавышын! Тик палата эчендә сап-сары итеп юылган паркет идән булса да, төштәге, яп-якты кояш нурлары юк иде. Көн әле яктырып җитмәгән, тәрәзәләр караңгы иде. Шулчак төштәге алма исенә төшеп, Габделбәрнең алма ашыйсы килеп куйды һәм ул тумбочкага үрелде.

Дикторның әкренрәк тавыш белән халыкара хәлләр турында сөйләгәне ишетелә иде:

— Палестина качакларына каршы Израил солдатлары рәхимсез ут ачты. Дүрт кеше үтерелде, унсигезе яраланды... Пекинда баш күтәргән кытай студентларына каршы танклар җибәрелде... Балтыйк буе республикаларында забастовкалар. Россия парламентында әле һаман элекке автономияле республикаларның мөстәкыйльлеген танымыйлар...

Габделбәр радионы чак кына ачарак төште һәм, алманы ашыйашый, тыңлавын дәвам итте.

Аның шулай итеп, бертуктаусыз күңелен борчып, васвасәләп, йөрәген бимазалап, шикләндереп, яндырып-көйдереп бетергән җил-аяк уйлардан качасы, онытыласы, дөнья борчулары белән борчылып, дөнья кайгысы белән кайгырып, дөньяның бетмәс-төкәнмәс агышы белән җенләнеп яшисе килде. Аның уенча, кеше бары тик дөнья уйлары, дөнья кайгылары белән уйланып, кайгырып яшәгәндә генә тулы хаклы тормыш кичерә алачак.

Аның карашы тумбочка өстендәге гәзитләргә төште. Аларны Габделбәргә кичә Зөбәйдә калдырып киткән иде.

Габделбәр иң өстә яткан гәзитне кулына алды. «Шәһри Казан» иде бу. Тәк, тәк. Әһә... «Милиция көндәлеге». Укып карыйк соң! У-у-у, караклар күбәйгән икән Казанда... Наркоманнар да, токсикоманнар да юк түгел икән... Стоп! Неужели спид?! Әйе шул: Казанда — спид! Куркыныч, һай, куркыныч заманда яшибез болай булгач... Арырак китик. Әл-лә-лә-лә... Самбо буенча беренче разрядлы спортчы сеңлесе белән икәүләп, зур гына кибетләрнең ярыйсы ук дәрәҗәлесендә директор булып эшләүче ханымнан утыз меӊ бирүне таләп итәләр. Монда инде ике юлның берсен генә сайлыйсы калган: йә — мал, йә — баш!

Болай да череп баеп беткән директор ханым өчен, әлбәттә инде, баш кадерле, һәм ул, һич икеләнүсез, утыз меңне килешенгән урынга илтеп куя.

Абыйлы-сеңелле талаучылар акчаны алырга дип... керүгә үк ишек шартлап ябыла. Һәм озак та үтми... янә башлый. Директор ханым

яклылар (мафиячеләр) ут төрткән була аңа. Һәм, әлбәттә инде, ничек кенә тырышсалар да, талаучылар тышкы яктан бикләнеп өлгергән ишекне ачып чыга алмыйлар, янып үләләр. Соңыннан аларның көлләрен генә табалар...

«У-у-у, коточкыч! — дип уйлады Габделбәр.— Ә бит бу эшләр әллә кайда Парижда түгел, нәкъ менә биредә, Казанда эшләнгән...»

Габделбәр газитне ишләре янына ташлады да палатадан чыкты. Аның йөзе борчулы, күзләре сагышлы, ә куллары сизелер-сизелмәс кенә калтырыйлар иде. Чөнки ул үзе дә кечкенә генә җинаятьчел бер төркемнең корбаны була язган кеше ләбаса...

Габделбәр, ике кулын артка куеп, коридор буйлап уйланып бара торгач, урология бүлегенә килеп чыкты. Эчкә үтеп тормады, уңга борылды. Бу тарафта кечкенә генә мәйданчык, ә каршысында — лифтның тимердән ясалган һәм яшелгә буялган шахта ишеге иде. Ишектә бәләкәй генә түгәрәк тәрәзә дә бар. Габделбәр килеп әнә шул тәрәзәдән эчкә карап алмыйча түзә алмады. Килде, карады һәм... эчтә лифт булып, анда ялгызы гына моңаеп Илһам утырмасынмы!

Габделбәр ишекне ачып җибәрде. Һәм Илһам кайгылы күзләре белән аңа карады. Илһамның кулларында Габделбәргә таныш «Шәһри Казан» ята иде.

— Мә, укы әле! — дип, Илһам газитне Габделбәргә сузды.

— Укыдым инде мин аны,— диде егет.

— «Милиция көндәлеге»н?

— Укыды-ым!

— Икесен дә үтергәннәр бит...— диде Илһам һәм авыр гына көрсенеп куйды.

— Ә-ә?..— диде Габделбәр һәм, җавап көтеп, Илһамның йөзенә текәлде. Илһамның ни әйтергә теләгәнлеген аңламаган иде әле ул.

Шул мәлне лифтка, култык таякларын тук-тук китереп, кызыл сакаллы бер ир килеп керде. Аның уң аягы гипска катырылган иде, ахры. Кызыл сакал, син монда нишләп йөрисең дигәндәй, Габделбәргә күзләрен акайтып карады да, ниһаять, куркырлык нәрсә юк икәнлегенә төшенеп булса кирәк, Илһамга таба башын борды. Дорфа гына итеп:

— Айда, гони на восьмой этаж, быстро! — диде.

Илһам сикереп торды. Таза гәүдәсенең авырлыгыннан лифт дер селкенеп куйды. Ишекләрне япты һәм сигезенче кара төймәгә басты. Ярты минут та үтмәгәндер, лифт инде сигезенче катта тора иде.

Кызыл сакал, култык таякларын шак-шок китереп, телефон янына барып басты. Илһам лифтны тугызынчы катка менгерде.

— Кызыл сакал тыңлап тормаска куша,— диде ул. Аннары үз-үзе белән генә сөйләшкәндәй, акрын гына итеп:— Кабахәт! Бу бәндә төнозын борчып чыкты мине,— дип, читкә төкереп куйды.

Ә түбәндә, сигезенче катта кызыл сакалның телефоннан кемгәдер җикеренеп кычкырганы ишетелә иде.

— Убью, падла! На этот раз от меня далеко не уйдешь, все равно найду, и за смерть Фердинанда и Руфины отомщу...

Габделбәр шунда гына «Милиция көндәлеге»ндәге хәлнең һәм Илһамның, икесен дә үтергәннәр бит, дигән сүзләренең хикмәтенә төшенеп, дерт итеп сискәнеп китте.

Астан кинәт кызыл сакалның:

— Лифтер, гони лифт сюда-а! — дип җикереп кычкырган авазы ишетелде. Кызыл сакал, күрәсең, Илһамның Фердинандка абый тиешле икәнлеген белми иде. Белсә, ихтимал, алай җикереп кычкырмас иде аңа. Хәер, белмәве яхшырактыр да әле.

Габделбәр Илһамга сүз әйтмичә генә лифттан чыкты. Кызыл сакал белән бүтән очрашасы килми иде аның. Чөнки кызыл сакал бик кызу канлы, нервылары бик какшаган адәм кебек сизелә. Аннары Габделбәрдә

дә нервылар корыч түгел. Габделбәр дә дорфалыкны, авыр сүзләрне күтәрә алмый. Йә юктан гына бәйләнешеп китәрләр...

Илһам сигезенче катка төшеп китте.

— Ник озак тордың? — дип кычкырды аңа кызыл сакал.

Илһам ни дип җавап биргәндер, тавышы ишетелмәде. Әллә бөтенләй үк җавап бирмәдеме? Габделбәр күз авырулары бүлегенә таба китеп барды. Шул яктагы баскычтан әйләнеп кайтырга иде аның исәбе. «Әйе... Илһам булып Илһам да курка икән кызыл сакалдан, — дип уйлады Габделбәр. — Ник курка? Ни өчен? Шуның өчен, мөгаен, чөнки ялгыз ул! Ә кызыл сакал ише сволочьлардан курыкмас өчен нишләргә? Әлбәттә, берләшергә! Ә берләшүне бер ата-анадан туган балалар арасыннан башламыйча кайдан башлыйсың инде? Хисаметдин абый, Салисә апа, Илһам абый, Фоат абый, Йосыф абый — берләшегез! Берләшегез! Әйе, менә озакламый мин дә Зөбәйдәгә өйләнеп җибәргәч, иптәш Шәймуллин-Фәйзуллиннар сезнең белән берләшәчәкмен! Без аннары аерылмабыз — аю ашамас, бүленмәбез — бүре ашамас! Һәм без аннары кызыл сакал ише пычрак җаннарга басымчаклык итәргә юл куймабыз...» — Менә шундый уйлардан Габделбәрнең кәефе күтәрелеп китте. Бераздан аның күңеленә янә тәшвишле уйлар килде. «Ә бит кызыл сакал ише сөлекләр барыбер үз ирекләре белән генә синең таза тәнеңдәге сәламәт канны суырудан туктамаячаклар. Дөрестән дә шулай ич? Әйе, шулай! Алайса нишләргә соң безгә?..»

* * *

— Берләшергә кирәк, — диде калада яшәүче татар.

— Берләшергә кирәк, — диде иртән авылдан чыгып китеп, кич өенә кайтып кергән татар.

— Берләшергә кирәк, — диде татар, колхозчыларның гомуми җыелышында берничә урыс аңа үз телендә чыгыш ясарга мөмкинлек бирмәгәннән соң.

Бу сүзләрне татарлар тегендә дә, монда да әйтә башладылар. Ниһаять, татар дөньясы уяна. Ниһаять, татар дөньясы күгенә кояш чыгарга чамалый. Бирсен ходай!

...Тау башында айлы, манаралы мәчет басып торган зур гына татар авылында, тыштан караганда барысы да ал да гөл сыман күренә бугай. Монда йортлар шәп. Мәктәбе, клубы, кибетләре заманча итеп салынган. «Монда халыкка яхшы яшәү өчен бөтен уңайлыклар да тудырылган, бөтен мөмкинлекләр дә булдырылган», — ди колхоз рәисе. Анысы шулай: ашказаны һәм тән өчен барысы да бардыр. Әмма җан өчен барысы да бармы соң биредә?

Тән өчен ит, сөт, май кирәк булган кебек, җан өчен дә азык кирәк ләбаса, иптәш председатель! Җан бушлыгын, ни генә әйтсәң дә, ит, сөт, май белән тутырып булмый. Алайса нишләргә соң? Бу мөһим мәсьәләне кайдан, ничек итеп чишә башларга?

— Кхм-м-м... Бу мәсьәләне, минемчә, менә болай чишәргә кирәк түгелме икән, иптәшләр, — ди элекке мәдәният министры сүз сорап.

— Ничек итеп? — дип сорау бирә аңа яшь министр куен кесәсеннән блокнот белән карандаш чыгарып, язарга әзерләнеп.

— Мин бу мәсьәләдә бик күп уйландым инде, бик күп баш ваттым, — дип сүзен дәвам итә «бывший» министр маңгай пеләшендә елтырый башлаган салкын тирләрне йомшак учы белән сыпырып. — Минемчә, иптәшләр, безгә җаннан баш тартырга кирәк...

— Үлепме?! — дип сорау бирә заллан кемдер.

— Әйе, әйе... Үлеп! Тик физик яктан түгел, ә рухи яктан.

— Аннары тәмам хайваннарга әверелергәме? Без болай да ярты-лаш хайван инде, иптәш «бывший». Юк, без моңа риза түгел, иптәш «быв-

ший». Без бит мәдәният аркасында хайваннан кеше булган идек, инде хәзер кешедән хайван ясамагыз безне!

— Дөрес! — дип кычкырды яшь министр.— Сезнең сүзләрдән... торгынлык заманы исе килә... Хәзерге үзгәртеп кору чорында җәмгыятебезгә бөтенләй бүтән җыр кирәк ләбаса!

— Нинди җыр? — дип сорау бирде залдан баягы тынгысыз иптәш.

— «Интернационал!» — һәм яшь мәдәният министры куркынып якягына каранып куйды. Ләкин аңа берәүнең дә ачуланып карамавын, киресенчә, «бывший»дан кала, һәммәсенең дә күзләрендә кызыксыну чаткылары балкып-балкып киткәнен күреп, яшь министр батырая төште:— Бигрәк тә «Интернационал»ның менә бу юллары безгә — татарларга карата төбәп әйтелгән төсле... Тыңлагыз! — Һәм егет дулкынланып җырлап җибәрде. Ә зал аны шул минуттан ук аңлап бердәм күтәреп алды:

Алла да, патша да, батыр да —
Азат итмәс беркем безне.
Яулап тик без көрәш сафында
Алырбыз үз иркебезне.
Җимерик дисәң коллык, җәберне,
Яулыйк дисәң син барын да,
Дөрләт утны, тизрәк тимерне
Сугып кал кызу чагында!

Төшемнең шул урынында мин уянып киттем. Як-ягыма каранып куйдым. Кунакханәдә, үз урынымда ятам икән ләбаса! Аннары мин төшемнең мәгънәсе турында уйлана башладым. Кичә Ирек мәйданында, митингта катнашкан идем. Берзаман күрәм, меңләгән татар арасына килеп кысылган бер урыс тамак ертып кычкыра:

— Әй, анда чыгыш ясаучылар! Һаман татарча гына сөйләмәгез әле, югыйсә, мин берни аңламый калам бит!.

Шуннан ни булды дисезме? Шуннан шул булды: бер өер татар тотындылар, мин сиңа әйтим, трибунага кычкырырга:

— Урыс иптәш дөрес әйтә, аның хәлен аңларга кирәк. Урысча сөйләгез!..

Сүз дә юк, әйбәтләр болар, киң күңелле татарлар! Һәм шулар ук әле, адым саен диярлек: «Милләт!» — дип, «Берләшергә кирәк!» — дип лаф орган булалар... Һи, берләшерсең, болай дәвам итсә, бар, яшәрсең бербөтен милләт булып! Әнә безнең чыкылдаган татар авылын гына ал: гомер-гомердән түбән оч дип йөртелгән урам хәзер — «ул. Чкалова!» Ә югары оч — «ул. Матросова!» Чишмә урамы — «ул. Зоя Космодемьянская!» Һәм югары оч белән түбән оч малае чишмә урамында очрашкач, болай сөйләшәләр икән: «Син кайсы урамнан?» «Улица Матросовадан!» «Ә мин — улица Чкаловадан!» Дөрес, без инде үтә наивный халык: әллә кайда Әмрикә шәһәрендә татар хәрчәүнәсе барлыгын белсәк — бетте, тотынабыз мактанышырга, тотынабыз шапырынырга: «Ул бит безнең милләтнең бер кыйпылчыгы, ул бит әнә нинди үткен, дөньяның читендә ят халыклар арасында эреп, югалып калмаган — татарлыгын татар итеп һаман яши бирә ләбаса! Ә үзебездәге хәлләрнең асылына килгәндә — яман бит, әфәнделәр! Телебез сандыгына бер көтү көя төшкән! Әллә мин әйтәм Әмрикә каласында хәрчәүнә тотучы саф татарга телеграмм сугып карыйкмы? Ул, хәлебезне аңлап, Ак йорт аша БМОга гариза язып, телебез сандыгында мыжгыган хәшәрәтләргә каршы уңышлы көрәшү өчен берәр төрле дару сорап ала алмасмы икән?!

«Шәһри Казан»ны өстәлгә куйды да, Разыя кеткелдәп көлеп җибәрде. Зәлия апа язса яза инде, чукынган... И оста да инде! Әмрикә президенты белән бәхәсләшерлек баш бар үзендә.

Шулай шул, үз кирәгеңне генә кайгыртып яшәмәскә, үз теләгеңне генә канәгатьләндермәскә һәм шул максатларда чит-ятларга тәлинкә

тотмаска! Аннары нәрсә? Павел Корчагинныкы кебек эт тормышымы?! Юк, бусы булмас инде. Чөнки һәммә кеше дә «кирәкле кишер яфраклары»на уңлы-суллы тәлинкә тотып, тәмле ашап, әйбәт киенеп рәхәт чигеп яшәгәндә, нишләп әле Разыя дигән чибәр кыз гына, дулкын өстендәге йомычка шикелле, бер ярдан икенче ярга ташланып, кагылып-сугылып яшәсен, ди...

Һәм Разыя икенче юлны — тук, бәхетле тормышны сайларга булды. Әнә... Фәләхетдин абзый үлгәндә яшереп калдырган бакыр сейфны кемдер табып алган ди бит әле. Ә аның эчендә йөз сиксән мен тәңкәлек алтын-көмеш бар!.. Чынлап та белсәң иде: кем табып алды икән ул бакыр сейфны? Берәүләр әйтә: ул бакыр сейфны төнлә яшертен генә каладан Фердинанд кайтып тапкан да, жинаять эзен яшерер өчен, әйгә ут төртеп юкка чыккан, ди. Аннары ул бөтен байлыгы белән мафия кулына эләккән дә, сеңлесе белән бергә үтерелгән, ди. Аларны харап итүдә Разыяның сабакташы, хәзер кибет директоры булып эшләүче кәкре аяклы ханым зур роль уйнаган, ди, имеш. Булыр, булыр, бусына ышанырга мөмкин. Халык белми сөйләмәс. Димәк, сейф кәкре аяклы жинаятьче ханым кулында! Тик әлегә бу имеш-мимешләргә генә ышанып директор ханымны кулга алырга ярамый икән, дип әйтеп әйтә ди Фоат абый һәм, бу жаваплы эшкә мин үзем керешәм, сейфны табам, андагы байлыкны туганнарым арасында тигезләп бүләм, ә Руфина өлешен Разыяга бирермен...

Бирер, бирер, ник бирмәсен. Фоат абый ялган сөйләшә торган кеше түгел: ул бит милиция капитаны! Димәк, йөз сиксән меңне тугыз кешегә тигезләп бүлгәч, егермешәр мең тия! У-у-у-у!... Болай булгач яшәргә мөмкин, мөмкин яшәргә бу нурлы дөньяда: и-һи һи-һи-һи-и-и...

Аннары... гаилә ягын гына көйлисе кала!

Уйларының шул төшендә Разыя ачуыннан шартлар дәрәжәгә житте. Ниндидер бер килмешәк кыз аның сөйгәнен тартып алды бит. Тартып алды да, Разыяның якты өметләрен, матур төзегән хыялларын жимерде, киләчәккә корган планнарын туздырып ташлады.

Тора тора да, тагын бер мәртәбә гажәпләнеп куя Разыя: кай төшенә кызыкты икән Габделбәр шуның? Миннән артык жире дә юк бит инде. Өстенә кигәне дә шул бер күлмәк тә бер чүәк дигәндәй. Аннан килеп, кызган мунча ташына янә бер чүмеч су өстәп жибәрә Разыя:

— Житте, булды... Күп түздем, чыдар чамам калмады. Тотам да шәһәргә китәм, Габделбәрнең үзен күреп сөйләшәм. Балыкны жим белән каптыралар, егетне дә тәмле тел белән генә сыйлап булмас, күчтәнәчфәлән дә алып барасы булыр. — Һәм Разыя бармак бөгеп санап китә: — Кала кибетләрендә ни юк? Каклаган каз — юк! Маринатлы гөмбә? Юк! Тозлы алма, балан бәлеше? Миләш кагы? Чия хәлвәсе? Төрледән-төрле кипкән жиләкләр бәйләме? Юк, берсе дә юк аларның шәһәр кибетләрендә. Ә Разыяларда бар. Разыяларда жаның ни тели, шул бар.

Һәм кыз иртәгесен шәһәргә китәргә уйлады.

* * *

Зөбәйдәнең көндәлек дәфтәреннән.

«Яши-яши кеше нишли? Берәүләрнең бу сорауга: «Картая!» — дип жавап бирүләре мөмкин. Ә минемчә, тәжрибә туплый. Эшли-эшли остара! Укый-укый гыйлем өсти! Күрдегезме, аңладыгызмы инде: берәү дә ана карынынннан ук даһи булып тумый. Һәм шулай да чын мәгънәсендә даһи булу өчен, югарыда әйтелгән өч нәрсә генә житми: сиземләү, тою, хис итү; башкалар фикеренә колак сала белү, кәпәренмәү, тәкәбберләнмәү; кирәкләре бик мөһим булган карарларны кабул иткәндә — ашыкмау, кабаланмау һәм шул ук вакытта — соңармау да фарыз. Боларга ялгап тагын бик күп, бик күп нәрсәләр өстәргә булыр иде әле, ярый инде,

санап киткәннәр дә житеп торыр. Минем максатым, әйтергә теләгәннәрем бөтән бит!

Бер көнне шулай Ирек мәйданына таба бара идем, күрәм, каршыма Салисә апа килә. Бик зәһәр килә. Таптыйм, бәреп егам, дигәндәй итеп килә. Мин аңа: «Әйдә, митингка!» — дим. Ә ул: «Нәрсә калган анда миңа! Алтын өләшәләрме, көмеш тараталармы анда? — ди. — Митингтан башка да үз хәсрәтем үземә житкән!» — ди. Кашларын әкәмәт жыерып, күзләрен галәмәт акайтып әйтә, валлаһи. Шул хәлдән соң, мин чынлап торып уйга калдым. Әйе, хәлебез яхшы түгел бит безнең, таркау бит без, кем-кемгә туган икәнлекне дә белмибез, хәтта белергә дә теләмибез... Уңга-сулга карамыйча дан артыннан куабыз, шанлы булырга омтылабыз... Ләкин, күпме генә тырышмыйк, көч түкмик, безне бөрәү дә бөек дип, гали зат дип атамаячак. Чөнки без иң кирәкле нәрсәне — кече күңелле була белүне санга сукмый башладык. Әйе, әйе... Бөек кешеләр ни өчен бөек булганнар? Чөнки алар кирәк чакта гади дә, кече күңелле дә була белгәннәр. Һәм шулай ук башкалар бәхете хакына үз рәхәтлекләреннән баш тартырга да батырчылык иткәннәр. Ә без?!.»

* * *

Кызык бу дөнья! Яшәгән саен алда яңа киңлекләр ачыла бара, көтелмәгән борылышлар пәйда була. Тормыш сине матурлыгы һәм мәкерлелеге белән алдап-йолдап төрлечә сыный, талкый, изә... Түзәсең яки бирешәсең. Көрәшәсең яки дәшмисең. Жиңәсең яки жиңеләсең. Бары шулай гына.

Зөбәйдә үзен беренчеләр, көрәшчеләр рәтенә куеп карый. Мондый кешеләр яшьтән үк алларына билгеле бер максат куялар һәм өлешләренә чыккан бәхетләрен, рәхәтлекләрен кызганмыйча, гомерләре буе шул максатка омтылып яшиләр. Зөбәйдәнең дә андый максаты юк түгел. Ул врач булырга хыяллана. Галим-врач! Зөбәйдәнең фикеренчә, галимнәр алар шул ук көрәшчеләр төркеменә керәләр. Чөнки иҗат итү ул — яңалык тудыру дигән сүз. Ә яңалык беркайчан да, беркемгә дә жиңел генә бирелми. Институтта хәлиткеч имтиханны тапшырып чыкканнан соң, Зөбәйдә хастаханәгә — Габделбәре янына бара-бара әнә шулай уйланды.

Көн жилсез. Болытлы. Күктән тын гына кар төшә. Урамнарда машина ташкыны, кешеләр, кешеләр...

Уңайсыз һава шартларына карамастан, шәһәрнең үзәгендә дә, читендә дә төзелешләр бара. Кала көннән-көн яңара, үсә, зурая һәм яшәрә.

Яңарсын әйдә, яңарсын! Үссен әйдә, үссен! Яшәрсен әйдә, яшәрсен!..

Зөбәйдә шундый ашкынулы хисләр дулкыны эчендә хастаханәгә килеп житте. Ашыгыч ярдәм бүлегенең ишеге эчтән бикле түгел иде. Бүген Республика хастаханәсенең кизү көне булса кирәк. Кыз, ишектән кереп уңга борылгач, Илһам абыйсы эшли торган лифтны чакырырга дип кенә торганда, кинәт шахтаның яшел тимер ишекләре үзләре шаулап ачылып китмәсеннәрме! Эчтә, лифтта ак халатлы, сары чәчле, сипкелле урыс егете һәм, Зөбәйдәнең авылдашлары: Кәрим, Сәлим, Харис күренде. Барысының да авызында папирос иде.

«Димәк, бүген Илһам абый эшләми, ял итә икән», — дип уйлады Зөбәйдә. Һәм борылып китмәкче иде, сары чәчле лифтчы егет кыз каршына килеп басты да кулын күкрәгенә куйды һәм башына чак кына түбән иеп:

— Здравствуйте, пани! — диде. — Проходите, пожалуйста. Глядите, только ногу не сломайте и от этих зверей морду берегите... И куда ж Вас отвезти? Не в подвальное помещение ли, где находится под восьми замками медный сейф-ф!..— Һәм сипкелле егет, йөзен-кашын мәзәк кыяфәткә кертеп, Зөбәйдәнең авылдашларына күз кысты. Тегеләр исә ат кешнәгән тавышлар чыгарып, хихылдашып көлешә башладылар. Димәк,

Фәләхетдин бабайның «бакыр сейф» тарихы боларга да барып ирешкән инде! Зөбәйдә кырт кына борылды да коридор буйлап бүтән блоклар ягына таба китеп барды. Аннары баскычтан дүртенче катка күтәрелде һәм, бер авыру ирне пульманология бүлегенә җибәреп, Габделбәрне чакыртып китертте. Зөбәйдәсе янына егет кояштай балкып килеп чыкты.

— И-и, кемне күрәм мин, күрмәгән чакта күеп үләм мин,— дип теленә салынган була әле үзе. Габделбәрнең бармагындагы ак җептә ниндидер ачкыч бар иде. Егет туп-туры лифтка таба китте һәм шахта ишеге янәшәсендәге ак ишекнең йозагын ачарга кереште.

— Зөбәйдә, әйдә! — диде ул кызга ым кагып.

Тар гына, озынча бүлмә иде бу. Тәрәзәсе зур. Ә тәрәзәдән кышкы урман һәм арырак икенче Горки микрорайоннарындагы ак һәм кызыл кирпечтән салынган биек-биек йортлар күренеп тора иде. Зөбәйдә шунда, керүеннән элек чыгуынны кайгырт дигәндәй, нәрсәгәдер шикләнеп якягына каранып куйды.

— Курыкма, Зөбәйдә, монда врачлар керми, керсәләр дә күп очракта шәфкать туташлары гына керәләр,— дип, Габделбәр Зөбәйдәгә сарылды.

«У-һу... ай буе күрмичә торганмыни!» — дип уйлады кыз. Һәм ул, беренче карашка, Габделбәрнең кинәт билләреннән кочып алуына унайсызлану кичерсә дә, икенче карашта инде моңа күнгән һәм үзе дә кайнарланып, сөйгәненең кочагына кереп сыенган иде.

Алар бераз вакыт әнә шулай тын гына, моң гына назланышып басып тордылар. Бу бәхетле очрашудан туган рәхәт тынлыкны беренче булып Зөбәйдә бозды. Аның күзләре тумбочка өстендә торган бәләкәй көзге һәм кершән-помада ише нәрсәләрне күреп алган иде.

— Син... — диде ул,— болай яшертен очрашу урыннарына бик йөреп, тагын өзлегеп куйма инде!

Зөбәйдәсенең ни әйтергә теләгәнен аңлады Габделбәр, аңламады түгел. Мәгәр аның үз хәле хәл иде әле. Һәм ул үтә җитди итеп:

— Тизрәк кенә терелеп чыгарга язсын инде, Зөбәйдә,— диде.— Юкса, шундый туйдым бу аунап ятулардан, шундый туйдым... Их, дим, эчемнән генә, җырлап эшләгән чакларны искә төшереп. Таш киссәм кисәр идем, әмма бирегә ятарга беркайчан да риза булмас идем.

— Моңа син гаепле түгел бит, Габделбәр!

— Түгел түгелен дә...

— Нәрсәгә борчыласың соң?

— Их, Зөбәйдә, Зөбәйдә! — диде Габделбәр офтанып.— Хәзерге чуар бу заманда кайгы-хәсрәтләрсез, борчылуларсыз гына ничек яшәмәк кирәк! Әнә бит Руфина белән Фердинанд абый... Ишеткәнсеңдер инде.

— Ишеттем! — диде Зөбәйдә. Һәм аның күзләренә яшь килде.

— Ярый, житеп торыр әлегә,— диде Зөбәйдә, кинәт Габделбәрнең кулыннан гәзитләрне тартып алып.— Сиңа, бәгырем, артык дулкынланырга ярамый әле...

— Ярый алайса, синеңчә булсын! — диде егет Зөбәйдәсе белән килешеп. Ә Зөбәйдә турыдан-туры Габделбәрнең хастаханә тормышындагы хәлләренә күчеп:

— Йә, Габделбәр, нинди яңалыклар бар соң,— дип, янә элеккечә балкып, елмаеп сорады.

— Яңалыклар дип, мондагы яңалыклар шул инде: укол кадыйлар да дару йоттыралар, дару йоттыралар да укол кадыйлар...

— Авылдан килүчеләр бардыр ич? Кемнәр килә?

Габделбәрнең ачык зәңгәр күзләрендә сәер чаткылар пәйда булды, маңгаендагы җәрәхәт җөе сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп куйды.

— Кемнәр килә дип... Килә инде шунда. Кичә әти килгән иде, бүген сеңелкәш белән энекәш. Аннары...— Габделбәр чак-чак кына. Разыя, дип әйтеп ташламады, аңы житеп, тыелып калды.

Әйе, Разыя да килгән иде шул аның янына. Габделбәр баштарак Разыя белән очрашмаска уйлаган иде. Аннары, авылдаш итеп кызганып бардым, ә ул мине кешегә санап янымa да чыкмады, әллә кем булган, дип, уңлы-сулы гайбәт чәчеп йөрүеннән шикләнеп. Габделбәр Разыя белән дә шушы аулак бүлмәдә сөйләшеп торган иде.

Разыя соңгы мода белән шәпләп киенгән иде. Чем-кара күзләре ялт-йолт итеп уйнап тора. Салкын тәэсирендә алсуланган йөзеннән яшьлек дәрте, яшьлек гүзәллеге бөркелә. Аяклар төз, нәфис, гәүдә сылу... Мәгәр Габделбәр Разыяның мондый купшылыгы каршында бик әллә ни сыгылып төшмәде. Ул аның белән әдәп саклап кына исәнләште, сүзен үлчәп кенә сөйләште. Күбрәген Разыя сөйләде бугай. Һәм ул Сания әбине район хастаханәсендә калдырып кайтуларын, карчыкның урыныннан тора алмыйча ятуын да «тәмләп» әйтеп үтте. Аннары Сания әбинең җиде баласы турында җитмеш тарафка җитмеш төрле гайбәт чәчүләрен дә «борычлап» искә алды. Соңыннан хиссез-нисез генә саубуллаштылар. Бөтен хикмәт менә шул иде. Бу турыда әйтергәме Зөбәйдәгә, әйтмәскәме? Әйтсә, көнләшмәсме, Габделбәр берьюлы ике куян артыннан куа дип уйламасмы? Шулай да егет бу турыда әйтергә үзендә кыюлык тапты.

— Ә-ә-ә...— диде Зөбәйдә, ни өчендер көмеш чылбырлы сәгатенә карап куйды, җиңелчә генә тамак кырды һәм сумкасыннан ак тышлы өр-яңа басылып чыккан калын гына китап алып, егетенә сузды:

— Укырсың!

— У-у-у... Яңа китап!— диде Габделбәр, сөенеченнән хәтта куллары уып.— Әлбәттә, укырмын! Уку тансык безгә, бигрәк тә мондый шәп китап кулга кергәндә...— һәм егет китапны алып урта бер төшен ачты да, күзләренә «Зөфаф төне турында хикәят» чалынып, көлемсерәп куйды һәм Зөбәйдәгә карап:

— Укыйммы?— диде.

Кыз, укы! дигән мәгънәне аңлатып, ым какты.

«Бер патшаның Зөф исемле кызы курайда гаҗәеп оста уйный белә торган Аф исемле яшь егеткә гашыйк була. Ә Аф, шул мәмләкәт кешесе булса да, кардәш милләт вәкиле, имеш. Мәгәр аларның телләрендә әллә ни аерма сизелми. Кайчандыр бу милләт арасында, байлык бүлешкәндә тавыш күтәрелгән, ызгыш чыккан, эш хәтта бер-берсенә каршы корал күтәрүгә үк барып җиткән. Менә шул хәтәр дә, хәсрәтле дә вакыйгалардан соң, бу кардәш ике милләт бер-берсен яратмый һәм бер-берсеннән кыз алып, кыз биреп яшәми икән. Бу канунны бозганнарның башларын чабып өзгәннәр. Менә шундый кыргый канунnar хөкем сөргән заман булган бу. Мәгәр йөрәк дигәнең үзенекен итә биргән: яшьләр яшертен генә бер-берсен сөешкәннәр, янганнар, көйгәннәр, кайбер батырраклары әлеге тыю чиген үтеп, кавыша да торган булганнар. Һәм мондый азаматларның башлары, билгеле инде, мәйданда, меңләгән күз алдында аяк астына тәгәрәгән...

Әйе, безнең Афыбыз көтүен көн дә иртән утлауга җибәрә дә, тау итәгенә утырып, курай тартып моңлана башлый икән. Бу моңнар бер дә бер көнне кардәш милләттән булган патша кызы Зөфнең күңеленә дә барып ирешә. Һәм кыз түзми, якыннанрак танышу нияте белән, Аф янына — тауларга китә.

Менә бервакыт көтүче егет уйнавыннан туктап, аяк язып алу теләге белән урыныннан тора һәм шунда, сылу ат өстенә нурлар чәчеп утырган искиткеч гүзәл патша кызын күреп ала һәм кинәт куркып китә. Беренчедән, бу — патша кызы; икенчедән, дошман милләттән булган патшаныкы; өченчедән, егет бары тик көтүче генә. Шулай булгач, аңа әлеге кыз белән сөйләшергә ярыймы? Юк, әлбәттә!

— Курыкма, егет! — ди патша кызы шунда.— Мин синең белән танышырга телим. Мин — Зөф булам. Ә синең исемең ничек, егет?

— М-мин — А-а-ф булам! — ди егет тотлыга-тотлыга һәм саклык өчен генә булса да, як-ягына каранып ала.

— Мин барда бернәрсәдән шикләнмә! — ди патша кызы чаяланып. — Син курайда таң калдыргыч моңлы уйнавың белән күңелемне тәмам сихерләдең, мин синең белән дуслашырга телим... Әгәр каршы булмасаң, синең янга көн дә шулай килеп-китеп йөрер идем.

Шул көннән алар, беркемнән дә курыкмыйча, очраша башлыйлар. Бу хәл кара көзгә чаклы дәвам итә. Ә бер дә бер көнне, кыш якынлашуын хәбәр итеп, беренче кар төшә. Беренче кар — кышлавыч җәйләүгә күчеп китәргә вакыт җиткәнен дә белгертә. Егет бу турыда кызга хәбәр итмичә кала алмый, әлбәттә. Ә кыз инде моны үзе дә сизенеп белә икән. Ул элек егетне тыңлый, аннан болай ди:

— Кемнәрдер өчен мин, бәлки, буй җитмәстәй кызмын, әмма мин, Аф, синең талантыңның зурлыгы алдында кеп-кечкенә булып калам төсле. Синең ул гаҗәеп музыкаң минем патша кызы булуымның дәрәҗәсе белән һич кенә дә исәпләшергә теләми. Минем шунда, гүя ки, җил булып, шаярҗ-шаяра исәсем килә башлый, минем шунда агым суга әверелеп, шаулап-кайнап агасым килә башлый. Минем шунда ак болытларга ашып, иксез-чиксез зәңгәр күкне иңләп йөзәсем килә башлый. Көй уйналып беткәч тә, әле музыка минем җаныма, каныма кушылып дәвам итә кебек...

— Ышанам, Зөф! Әмма...

— Бүлдермә, Аф, мин сөйләп бетерим! Хәтерлисеңме, беренче очрашканда китәр алдыннан мин сиңа, әйдә дус булыйк, дидем. Әйе, дус булдык без. Һәм мин дуслыкның мәхәббәткә әверелүен сизми дә калдым... Миңа сулышларымны тирәнәйтеп, күкрәкләремне иркенәйтеп җибәрә торган һава кирәк иде. Мин ул һаваны эзләдем. Эзләдем, мәгәр бер кайда да тапмадым. Минем сулышым тарайганнан-тарайды, күкрәкләрем кысылганнан-кысыла барды. Миңа яшәве көннән-көн читенләшә иде. Бер көн килеп, гомерем кыл өстендә генә торып калды. Табипларымның йөзләренә чыккан борчулары буенча мин бу фани дөньядан китәргә тиеш идем инде. Әмма алай бик тиз генә, күрәшсез-нисез генә бирешәсем, эзсез-нисез генә бетәсем, юкка чыгасым килми иде әле. Мин яшәргә тели идем. Минем йөрәгем түрендә ни могҗиза беләндер сүнми, сүрелми калган бер чаткы бар иде. Һәм ул чаткы миңа кардәш халыкның бөек улы тарафыннан тудырылган могҗизалы музыка тәэсирендә очкынланып, янып китте. Үземне яңадан тугандай хис иттем, кабат тормышка кайттым. Рәхмәт сиңа! Мең-мең рәхмәт сиңа, Аф!

— Үзеңә рәхмәт, Зөф! Мин, шушы яшькә җитеп, берәүдән дә мондый җылы сүзләр ишетмәдем әле. Дөрес, асыл ир-егетләрнең күбесе сыман, бәхет эзләп илләр гизә чыкмадым. Андый илләр минем хыялымда гына яши бит. Чөнки мин Тау-Анамның күкрәк сөтен имеп, Тау-Анамның бишек җырын, көен, чын мәгънәсендә җанын тыңлап үскән бала, таулардан, менә шулардан гайре чит-ят җирләргә, илләргә китеп яши алыр идемме икән? Белмим, белмим, бәлки, яшәр идем дә. Әмма мин бер хакыйкатьне исемнән чыгармый идем: тау чәчәкләре тик тауларда гына нәфис була. Шуның шикелле, минем музыкам да халкым йөрәгенә барып ирешкәндә генә мин үлемсезлеккә лаек кеше булып саналыр идем.

Менә шул уйлар, менә шул тойгылар минем йөрәгемә һич тынгылык бирмәде, һаман-һаман борчып, бимазалап торды. Һәм бер көнне килеп, таулар, елгалар, күлләр — боларның барысы да халыкның кайгысы, шатлыгы, аның киләчәккә булган якты өметләре бергә кушылып, бербөтен булып, музыкага әверелеп, җанымнан сызылып-сызылып чыга башлады. Һәм мин бу илаһи музыканы, үзем өчен генә булып калмасын, үз халкыма яңадан әйләнеп кайтсын дип, курайда уйнарга тотындым.

Минем бу музыкама иң беренче бәяне менә син бирдең, Зөф. Шуның өчен рәхмәт сиңа, Зөф!

— Мине түгел, ә халкыңа рәхмәт, Аф! Халкың сине тудырган һәм бу сихри музыкаң белән син халкыңа хезмәт итәргә тиешсең дә...

Ике яшь йөрәк төн утырып, таңны бергә каршылыйлар. Төн карасы аша серле күккә багалар, йолдызларга сокланалар. Ә йолдызлар бу ике гашыйкка сәлам тапшырыр өчен, араларыннан илче сайлап, җиргә җибәрәләр. Мәгәр илче йолдыз галәм кочагына атылуга ук, өндәү билгесенә охшаш якты сызык калдырып, мизгел эчендә янып көл була.

Бу өндәү билгесенә охшаш якты сызыкның сере шунда, имеш, ул менә нәрсә дигәнне аңлата икән: «Кешеләр! Мин йолдыз түгел, мин гади бер күк җисеме генә идем... Йолдызлар беркайчан да атылмыйлар һәм янып көл булмыйлар. Сезнең дә мәхәббәтегез күккә ашып йолдыз кебек балкып, нурлар чәчеп торырлык булсын, минем шикелле, мәгънәсезгә янып көл булмасын!»

Күп тә үтми, Зөф белән Афның да мәхәббәте күккә ашып, йолдыз булып янарга керешә.

— Әйдә, без аңа «Зөфаф» йолдызы дип исем бирик, ә бу бергә үткәргән балдай татлы төнгә, «Зөфаф» төне дип исем кушыйк.

— Әйдә!

Ә иртәгесен ике гашыйк аерылышырга тиеш. Аларны алда ни көтә? Билгеле инде — үлем! Мәгәр кыз белән егетнең әле бик-бик озак яшиселәре килә һәм аларның шушы минуттан башлап бер-берсеннән аерылып, юкка чыгасылары килми. «Мине дә үзең белән ал»,— ди кыз егеткә. Һәм егет үзе белән сөеклесен дә тауларга алып китә.

— Әкият кенә булса да, дөрес кебек үзе, иеме?..— диде Габделбәр китапны ябып.

— Ә син дөреслекне ничек аңлыйсың соң? — дип көтмәгәндә генә сорап куйды Зөбәйдә.

— Дөреслекнеме...— Габделбәр ачык зәңгәр күзләрен әллә кая, билгесез тарафка юнәлтте.— Менә әйтик, кораблар сайга утырмасын өчен дәрьяда юл күрсәтүче маяклар куялар. Һәм кешеләргә дә, тормыш лабиринтларында адашып калмас өчен, маяклар кирәк. Гыйбрәтле язмышлы сәнгать әсәрләре — әнә шундый маяклар инде алар.

— И-и, син әллә ниләр беләсең, Габделбәр җаным,— диде кыз, егетнең күзләренә яратып карады.

* * *

Ә бу вакытта Разыя да Габделбәр турында уйлана-уйлана кала урамы буйлап бара иде. Теге көнне аерылышканда Разыя Габделбәр яныннан аз гына булса да күңеле үсеп чыкты. Габделбәр аның кулын ничек озаклап, каты итеп кысты ич. Бәс шулай икән, егет аңа битараф түгел. Разыя тагын килер әле Габделбәр янына, күчтәнәчләрнең дә иң шәпләрен, иң кәттәләрен генә алып килер... Кем белә, бәлки, алар авылга икәүләшеп «подручком» кайтып төшәрләр. Аһ, шулай булсачы! Разыя һич кызганып тормас иде, хәер итеп, бабасына йөз тәңкә бирер иде.

Разыя дәртле күңелендә туган уйларының үткенлегенә, кискенлегенә канәгатьләнеп елмаеп куйды: шулай, мин дигәнчә булыр, алла боерса, булмый калмас! Әнә, узган ел исәп-хисап җыелышында колхоз рәисе өлкән бухгалтер урынына мине куюларына каршы чыккан иде. (Имеш, бер аулакта мин аның куенына кермәгәнмен. Керде ди ул капкорсакның куенына, керми-ни...). Быел җәй өлкән бухгалтер вафат булгач, рәис барыбер миңа килеп егылды. Менә шулай ул дөнья дигәнең...

Разыя кинәт сискәнеп китте. Урам буйлап, ярым ай һәм йолдыз сурәте төшерелгән яшел төстәге байраклар күтәргән, халык төркеме агыла иде. Югары Совет бинасы янына барадыр инде болар, мөстәкыйльлек-фәлән теләнүләредер... Һи, һи-и... бирделәр ди сез бушбугазларга мөстәкыйльлек, бирми-ни!. Болай йөреп урысларның ачуларын китерсәгез, күрмәгәнегезне күрсәтерләр әле!

Разыя, кардәшләрен күрмәмешкә сабышып, кире борылып китте.

...Менә инде Разыя тирән уйларга чумып Балык Бистәсе ягына кайтып бара. Аяклары очында — сумка. Сумкада Сания әбигә күчтәнәч итеп алынган ике савыт бал белән дүрт лимон да бар. Шоферның «Спидола»сы татарча сөйли башлаган иде, шофер: «Ну, к черту вас!» — дип, Мәскәүне тоташтырды. Анда җырлыйлар иде:

...Русская бере-за-а-а...

Чынлап та, чит-читләренә боз каткан автобус тәрәзәсеннән шәрә каеннар, су өстендәге дулкыннарны хәтерләткән карлы басулар, өстә, тигезлектә, аста, иңкүлектә утырган ярым җимерелгән чиркәүле урыс авыллары күзгә чалынып кала. Бу тирәләрдә татар авыллары юк. Чөнки, Явыз Иван татарларны Казаннан җитмеш чакырымнан ары сөргән...

Разыяның уйлары янә Габделбәргә әйләнеп кайтты. Савыгып килә инде. Маңгаендагы җәрәхәте дә төзәлеп бара. Тик аның миңа карата мөгамәләсе бигүк әйбәт түгел әле. Килүемә дә сөенмәде бугай. Әллә ничек шунда... Салкын каршылады. Теләр-теләмәс кенә сөйләште, сорауларыма да кәефсез генә җавап бирде. Ни булды икән аңа? Элек бит ул минем белән һичкемгә алыштырмаслык эчкерсез дус иде...

Автобустан төшкәч тә Разыя хастаханәнең белешмә бүлегенә керде. Сания әбинең кайда ятуын сорашты. Әйттеләр. Разыя өстен чишенеп, ак халат һәм башмаклар киеп, икенче катка күтәрелде.

— Сез Шәймуллина янынамы? — дип каршы алды аны ябык йөзле, озын буйлы ир врач.

— Әйе.

— Сез аның кеме буласыз?

— Туганы.

— Ул әбинең җиде баласы бар, дөресме?

— Дөрес! Ләкин аның бер малаен күптән түгел генә үтергәннәр...

— Ишетте-ем! — диде врач. — Ярый, бу турыда әбинең үзенә әйтмәскә кирәк... Ә калган балалары ник кайтмый? Әбинең күп булса ун-унбиш көнлек гомере калгандыр. Үләр. Үкенерләр балалары, мәгәр соң булыр?...

— Күптән түгел генә кызы кайтып китте бугай аның, — диде Разыя, сөрмәле күзләрен врачның яңагындагы зур җөйгә төбәп.

— Кайткан кайтуын да озак тормаган, киткән һәм ул киткәннән соң әби үзен элеккедән дә начаррак хис итә, — диде врач канәгатьсез тавыш белән.

Разыя кергәндә Сания әби йоклый иде бугай. Палатадагы дүрт марҗа бергә җыелып, сөйләшеп утыра иде. Разыя алар белән кычкырып исәнләште.

— Здрасьте?

— Здрастуй, здрастуй... — диештеләр марҗалар теләр-теләмәс кенә.

Разыя әкрен генә килеп, Сания әбинең янәшәсенә утырды... Әбинең күзләре куркыныч булып эчкә баткан, борыны зураеп калган, йөзе тәмам суырылган, агарган һәм битенә ниндидер кара тимгелләр чыккан иде. Мондый очракта, авыруның йөзенә үлем шәүләсе төшкән, диләр бугай. Сания әби кинәт кулларын кыймылдатып куйды, иреннәрен ялаштыргалады һәм йөзен Разыяга таба борды да авырлык белән генә күзләрен ачты.

— Син кем? — диде хәлсез генә.

— Разыя мин, кодагый әби, Разыя.

Карчык башын чайкады, телен чапылдатты, — аңламады булса кирәк. Бухгалтер кыз тагын кабатлады.

— Синең туганың мин, Сания апа, Разыя... Марат абыйның, синең киявең Маратның двоюрдный туганы!

«Двоюрдный» сүзен ишеткәч, марҗалар башларын Разыя ягына таба бордылар һәм:

— Нет, она по-русски не понимает... Она с нами по-русски абсолютно ничего не разговаривает! — диештеләр.

— Беләм! — диде Сания әби кинәт. — Алар җеннәр! Алар мине сихерләргә килгәннәр! — Һәм аннары Разыяга төбәлеп: — Син Салисәме? — дип сорады. Марат дигән таныш исем бая аның колагына чалынып калган иде, күрәсең, шуннан алып әйтүедер... Кыз аңы алышына башлаган әбигә бер мәл кызганып карап торды да: «Ашын ашаган, яшисен яшәгән инде бу! Моңа хәзер Салисә булды ни дә, Разыя булды ни!» — дип уйлап, үзен Салисә итеп күрсәтергә ниятләде. Болай иткәндә бакыр сейфны кулга төшерү мөмкинлеге дә бермә-бер арта ич!

— Әйе, мин Салисә! — диде Разыя.

— И балам! И бәгырем! — дип әби Разыяның кулларын тотып алды. — Зөһрә кошчыгым исән-саумы соң? — «Зөһрә кошчыгым» дип әби оныгы — Зояны әйтә инде.

— Исән-исән, әби, тфү, әни! — диде Разыя. — Зояга, тфү, Зөһрәгә ни булсын соң анда?!

— Теге... кенәжкәне нишләттең? Кая куйдың?

Разыяның тәне эсселе-суыклы булып китте. «Имәндә икән чикләвек!» — дип уйлады ул. Әмма бирешергә ярамый инде хәзер, керешкәнкерешкән, спектакльне азаккача уйнап бетерергә туры киләчәк...

— Сервант тартмасына салып куйдым, әни, — диде Разыя күзләрен уйнатып.

— Сервант алдыгызмыни, кызым? Кенәжкәдәге акчагамы?

Разыя тирләп чыкты. Шулай да сынатырга ярамый иде. Үзен кулга алып, елмаеп әйтте:

— Кенәжкәдәге акчага түгел, әни, зарплат акчасына-а!

— Әлимент акчасына дисеңме-е?!

Разыя телен тешләде. Кара син бу Салисә апаны, Марат абыйдан астыртын гына алимент та каерып ята икән әле! Әмма Разыя нәфрәтен карчыкка сиздермәде, киресенчә, кашларын сикертә-сикертә юхаланып өстәде:

— Әйе, әйе, әни... Әлимент акчасына алдым!

— Ай, яхшы булган! Ай... — Карчыкның тыны кысылды, гырылдый башлады. Разыя аны мендәр өстенәрәк күтәреп салды, баш астына икенче бер мендәрне куйды. Карчык тынычланып китте, сулыш алуы да тигезләнә төште. — Шулай да, кызым, — дип сүзен дәвам итте ул, — кенәжкәдәге акчага тими тор инде син, мин үлгәч... кхм... мин... — Карчык сүзеннән бүленде, тынып калды, гәүдәсе исә сулкылдап, тартылып куйды. Ул елый иде, ахры, ләкин аның күзләреннән чыртлап та яшь чыкмый иде инде.

Разыяның бик beләсе килә: кенәгәдә күпме акча бар икән? Үлгән Фердинанд яки Руфинаның өлешеннән аңар да бераз әҗер тимәсме икән? Ләкин карчык бу турыда берни дә әйтми әле һәм әйтергә уйламый да шикелле. Аннары карчыктан бу турыда сорарга яхшы түгел, чөнки Сания әби Разыядан шикләнә башлар, аңар теге бакыр сейфның кайда икәнлеген хәбәр итүдән баш тартыр кебек иде. Ә бакыр сейфның «интегеп» яткан урынын сорамыйча, белмичә калырга ярамый! Сорарга кирәк: хәзер үк һәм икеләнмәстән...

Разыя сумкасыннан бал, лимоннар алып, тумбочка өстенә куйды. Хуш исле лимон исе борынына кергәч, Сания әби чак кына тернәкләнә төшкәндәй булды.

— Әни, — диде Разыя. — Миңа бакыр сейфның кайда икәнлеген әйтә алмассыңмы икән...

— Ә-ә-ә... Теге хәзинә салынган тимер әрҗәне әйтәсеңме?

— Ие, әни... ие, ие...

— Аны атаң бәдрәфкә ташлады бугай.

— Чынмы, әни? Чынмы?

— Чын инде, чын!

Разыя, Сания әби белән саубуллашырга да онытып, күзләренә аккара күренмичә, палатадан атылып чыкты. Коридорда баягы врач ирнечак кына бәреп екмады, һәм, гафу үтенергә дә онытып, тиз-тиз генә баскычтан төшеп китте.

Разыя авылга караңгы төшкәч кенә кайтып төште. Иң элек өйләренә түгел, ә Сания әбинең янган йорты урынына таба юл тотты ул. «Бәлки шул тирәдә Гаделшаны очратырмын, ул миңа... ярдәм итәр, итми калмас»,— дип тә уйлады.

Чынлап та, тиле егет тыкырыкта чаңгы шуып йөри иде. Үзе жырлый:

Бир кулыңны, гүзәлем...

— Гаделша-а! — дип дәште Разыя.

Егет туктады, жырлавыннан да бүленде һәм Разыяны күреп алды.

— Әллә кемнәргә ялынма, Гаделша матурым... Мә, мин бирәм сиңа кулымны, ал! — диде Разыя аңа.

— Һә...— дип куйды егет кискен генә итеп.— Нәрсәгә миңа синең кулың! Кәбестә тозлыйммы мин аның белән, әллә куян атарга чыгыйммы...

— Ник, жырлыйсың ич әле: бир кулыңны, гүзәлем дип... Ә минем кулым жырдагы ул гүзәлнекеннән киммени?!

— Бөгештермә! — диде тиле.

— Нишләп инде, Гаделша матурым... Нигә миңа андый ямьсез сүз әйтәсең...

— И-и, төлкеләнеп маташма инде... Сиңа нәрсә кирәген беләм ич мин...

— Беләсең шул, Гаделша уңганым, беләсең... Ярдәм ит инде!

— Лом белән көрәк алып килимме?

— Ие инде, ие-е...

— Тик... әжере алдан!

— Күпме сорыйсың, матурым-м...

— Бер үптерәсең инде.

«Уф, ходаем, бар икән күрәселәр...» Разыя нервыланып як-ягына каранып куйды. Әмма тирә-юньдә берәү дә күренми, этләр дә йөрми — авыл эче тын иде.

— Ни... Гаделша жаным... аннары инде, яме! — диде Разыя тиле егетне ничек булса да төп башына утыртырга чамалап. Ләкин Гаделшаның бу мәсьәләдә авызы пешкән иде ич инде. Шулай булгач, ул икенче мәртәбә тагын авызын пешереп торырмы! Бигрәк инде сез кызлар: Гаделшаны тиле дигәч тә... Ул чаклы ук шыр тиле түгел әле ул!

— Менә анысы булмас инде,— дип кырт кисте Гаделша.— Мин үз сүземне әйттем... Пардон!

«И ходаем, китә бит инде, китә... Аннан башка бакыр сейфны ничек эзлим мин, ничек табып алыйм...»

— Гаделша-а! — дип дәште Разыя икеләнеп, борчылып.— Мин-н рри-за... Кил, әйдә-ә...

Тиле туктады һәм чаңгыларын карга батырып кадап куйды да, башын түбән игән килеш Разыяга таба якынлашты. Килеп житәр алдыннан кеткелдәп көлде, аннары кулларыннан карлы бияләйләрен салып, кесәләренә тыкты. Һәм, ниһаять, шаяргандай итеп Разыяны эләктереп алды. Разыя үзе дә сизмәстән күзләрен йомды. Ә Гаделша, каударланакаударлана, кызны муеныннан кочты, иреннәренә үбәргә үрелде. Ай-һай, каты суырып үпте ул! Разыяның хәтта алдагы ике теше селкенеп куйгандай булды. Болай аны әле берәүнең дә үпкәне юк иде. Менә сиңа тиле!

Разыя янган йорт урынына килде, капка баганасына сөялде. Гаделшаның әйләнеп килгәнен көтәргә кереште. «Килгәч, эшләтеп желегенә үтәм әле мин синең»,— дип тә уйлап куйды ул. Әмма, үч иткәндәй, Гаделша күренмәде дә күренмәде. Кызның аягына салкын үтте, аягыннан

биленә менде, биленнән эченә үтеп, калтыратырга тотынды. Һәм ул шунда гына тиле тарафыннан алдануына төшенде. Инде бирелә ялгызы гына берни дә майтара алмасына инангач, Разыя кайтыр якка таба юнәлде.

* * *

Зөбәйдә хастаханәдән чыкты. Рәхәтләнеп, кинәнеп, күкрәк тутырып саф һава сулады. Чөнки бирегә, елның кайсы гына фасылы булмасын, завод-фабрик төтеннәре килеп җитә алмый иде. Биредә зур бакча иде, тыныч иде. Кышкы урманда ничек шәп булса, биредә дә шундый ук талгын хозурлык иде.

Зөбәйдә, рәт-рәт итеп утыртылган мәңге яшь, төп-төз наратларга, кызлар сыман ачык йөзле сылу каеннарга, киң ябалдашлы мәгърүр имәннәргә, гүзәллекләрен эчкәре яшергән тыйнак юкәләргә, алма, туйра, тупыл, карама һәм алмагач, шомырт, миләш, балан агачларына сокланып карый-карый атлады. Аның садә күңелендә шундый уйлар килде: «Дөньяда бер генә агач та файдасызга үсми. Нинди генә агач утыртма, ул сиңа рәхмәтеннән калмый. Әйтик: каен суының һәм юкә балының файдасы санап бетергесез, миләш кайнатмасы, балан кагы, алма согы, шомырт экстраты да адәм баласына шифалы. Күн ясауда имән кайрысыннан файдаланганнар, элмәдән чана табаннары ясаганнар, өрәңгедән — балта сабы, караманы пешекләп бөккәннәр. Тирәкне бигрәк тә кошлар ярата, ә һаваны өзлексез сафландырып торуда тупылның файдасы күп. Өй артына, бакча буена, юл читенә — кая телисең шунда, нинди агач кирәк дип саныйсың, шундый агачны утыртып куй. Еллар үтәр, ул агачлар үсәр һәм алар сиңа бурычлы булып калмаслар...»

Зөбәйдә уйланып килә торгач, капкага җитүен дә тоймый калган икән. Һәм менә ул урамга чыгып китәр алдыннан соң мәртәбә хастаханә ягына борылып, тәрәзәләргә карамакчы иде, шул мизгелдә кемнеңдер көчле куллары аны иңнәреннән эләктереп, сул яктагы ташландык будкага таба сөйрәделәр. Кыз тыпырчынды, чәбәләнде, билгесез кешенең көчле кулларын иңнәреннән йолкып ташламакчы булды, анда таба ничек кенә булса да бармаска итеп, аякларын тери-тери җан-фәрман карышты. Әмма билгесез адәм Зөбәйдәгә караганда күпкә көчлерәк, гайрәтлерәк һәм үҗәтрәк булып чыкты. Ул Зөбәйдәне, ишектән кергәндә аяк терәп карышмасын өчен, арты белән борылып алып керде. Һәм будканың урта бер төшендә идәнгә бастырып, иңнәреннән кулларын ычкындырды. Зөбәйдә бары тик шул чакта гына әлеге бәндәнең кем икәнлеген белү өчен әйләнеп карый алды һәм корт чаккандай дерт итеп, сискәнеп китте. Бу — Маһир иде.

Зөбәйдә кинәт уңга каерылды һәм Маһирның кулларыннан яшендәй тизлек белән ычкынып, ишеккә ташланды. Әмма чыгып качарга өлгермичә калды, Маһир корбанына ташланган ерткыч сыман җәһәт кенә сузылып, Зөбәйдәнең пальто чабуыннан каптырырга җитеште. Ул, шул мизгелдә үк сикереп торды һәм Зөбәйдәне түргә таба селтәп тә җибәрде. Мәгәр кыз егылмады, куллары белән кочаклагандай итеп, будканың сулъяк диварына барып бәрелде. Шул рәвешчә торып та калды.

Маһир Зөбәйдәнең елавын, тилереп-тилереп, тырмашып-тырмашып, күңелгә авыр әшәке сүзләр әйтә-әйтә тиргәшеп елавын көтте. Әмма Зөбәйдә ләм-мим эндәшмәде. Бая ничек торып калган булса, һаман шул сурәттә басып тора бирде. Бу сүзсезлек Маһирны өркетә. Аның күңеленә билгесез шом сала, газапка дучар итә иде. Ниһаять, Маһир түзмәде, үзе сүз башлады:

— Гафу ит мине, Зөбәйдә!

Кыз дәшмәде.

Маһир башын күтәрде. Беренче мәртәбә күргәндәй Зөбәйдәнең чия төсле сапожкиларына, таза балтырларына, чия төсле пальтосына, нәзек биленә, көмеш төлке якасына, күпереп торган чем кара чәчләренә, көмеш төлке бүркенә игътибарлы карашын юнәлтте.

Ләкин бу күргән нәрсәләр егетнең аңына бөтен тулылыгы, матурлыгы белән барып ирешмәде, кайдадыр бушлыкта югалып калгандай булдылар. Маһирның аның Зөбәйдәнең бөтен матурлыгы, тулылыгы белән күреп, тоеп бетереп булмый торган «илаһи җаны» биләп алган иде. Гүя Зөбәйдәнең шул «илаһи җаны»ннан көй агыла, моң агыла. Маһирны искиткеч дәрәҗәдә әсәрендерә, аның бөтен-бөтен дөньясын шул көйнең, шул моңның тылсымлы агышына буйсындыра, сихерли төсле иде. Маһир шунда, беренче һәм соңгы мәртәбә үзенең Зөбәйдәгә карата берничек тә явызлык кыла алмаячагын аңлады. Һәм ул шунда, ятып калганчы, атып калырга, дигән әйтемнән чыгып эш итәргә, ягъни кыз алдында актык козырен ачып салырга булды.

— Гафу ит, Зөбәйдә! — дип кабатлады ул. Кыз эндәшмәгәч, тирән сулап өстәп куйды: — Кояшлы көн шикелле гүзәл булып башланган безнең мәхәббәтебез, шушындый ямьсез финал белән тәмамланыр дип, кайчан да булса уйлаган идеммени мин? Һәм мин үләпләр гашыйк булган сөйгән кызым, минем аңар булган олы мәхәббәтемә тап төшерер, минем аңар булган хисләремне агулар һәм минем түземлегемне соң чиккә китереп җиткерер, мине ирексездән ирексез җинаятъ юлына этәрер дип, уйлаган идеммени?!

Зөбәйдә кинәт тураеп басты, бөтен гәүдәсе белән Маһирга таба борылды.

— К-ки-ит юл-да-ан! — диде ул ишеккә таба бара башлап.

Гүя аның кара күзләреннән сибелгән утлы очкыннар Маһирның җанын көйдереп алды. Егет тетрәнеп бер адым артка чигеп куйды.

— Зөбәйдә-ә... — диде.

— Кит... торма юлда-а! — диде кыз, ниндидер хәшәрәт күргән сыман җирәнеп һәм нәфрәтләнеп.

— Бәлки... аңлашырбыз?!

— Хулиган белән нәрсә аңлашыйм мин!

Маһирның эчендә нәрсәдер өзелеп төшкәндәй булды. Башы чыңлап, күз аллары караңгыланып китте, һәм ул хәлсезләнеп диварга сөялде. Шул минуттан файдаланып, Зөбәйдә ишеккә таба атлады...

Бераздан егет аңына килде. Фикерләрен бер ноктага туплап уйлана торгач, ашыктым, дип йодрыгы белән диварга сугып куйды. «Ашыктым, җебеп калдым, — дип кабатлады ул янә шашарга житә язып. — Мина Зөбәйдәне җибәрмәскә булган, җибәрмәскә...» — Һәм озынча урындыкка утырып папирос кабызды. Чак кына иеләрәк төште. Аннары төтенгә карап тора башлады. Аннары бусының төпчеген ташлап, икенчесен кабызды. Тәмәке төтене тиз һәм зәңгәрсу челтәр корганлай үтәкүренмәле булып тарала. Маһирга ул җәйге көндә, ерактагы урман авызында тирбәлүче рәшәне хәтерләтте. Аннары аның күзләре сап-сары бодай басуы өстенә төшкәндәй булды. Гүя анда комбайн урып йөри. Штурвалда Маһир утыра, янына Зөбәйдә баскан. Аннары кич... буйлары... Куштирәк буенда сөйләшеп торулар...

Шул мизгел Маһирның борынына искиткеч хуш ис килеп бәрелгән шикелле булды. Мондый татлы ис тик Зөбәйдәнең чәчләреннән генә аңкырга мөмкин...

Маһир өченчесен кабызды.

«Зөбәйдә белән мавыктым мавыгуын, — дип уйлады ул. — Шулай да, «сөйдем — йөрдем, үптем — кочтым, үкенечкә калмады», дип әйтерлек түгел шул. Иреннәренә якын да китерми иде. Ә менә Габделбәргә карата алай түгел иде Зөбәйдә. Ул спектакльгә әзерләнгәндә гашыйк егет ролен Габделбәргә үзе сорап алды. Бу рольдә Маһир уйнамакчы иде, әмма Зөбәйдә аңар ачыктан-ачык, мин Габделбәр белән уйныйм,

диде. Шуннан соң Маһир спектакльдә катнашмады, тамашачы булып кына утырды.

Гашыйк ролен уйнаучы Габделбәр үзенең сөйгәненә әллә никадәр сагыну-сөю сүзләре сөйләде. Сәхнәдә спектакль түгел, тормыш үзе иде. Ахырда Габделбәр Зөбәйдәне бөтен тамашачы алдында кысып кочаклады, суырып-суырып үпте.

Маһир чытырдатып күзләрен йомды. Тынычланырга теләп учы белән маңгаен тотып торды. Аннары кабалана-кабалана папирос алып кабызырга кереште.

«Үбештеләр бит, үбештеләр... Бар халык күзе алдында, сәхнәдә, Маһир каршында... Их... Мин да йөргәнмен икән егет булып. Кара төндә, куштирәк төбендә дә кочып үбә алмадым бит Зөбәйдәне. Ни өчен? Кыз үзе каршы торгангамы, әллә Габделбәрнең кувалда йодрыкларыннан шүрләгәнгәме? Юк, түгел! Зөбәйдәне фәрештәгә тиңләүдән килеп чыкты бу. Имеш, тупас көч кулланып, мин аның изге рухын пычратам, пакь күңеленә тап төшерәм, имеш һәм ул мине «әдәпле» булуым өчен ныграк яратырга тиеш. Бит болай бер генә «тупас» егетнең дә әле мәхәббәттә уңыш казанганы юк. Сөйгәненә карата гадел һәм игътибарлы булу, аның йомшак якларын «явыз» максатлар өчен файдаланмау, киресенчә «мондый чакларда» күңеленә кереп утырган шайтан коткысын сабыр куып чыгару — менә мәхәббәткә чәчәк атар өчен кирәкле шартның беренчесе шушы дип аңлау кая китереп җиткерде инде. «Нәтиҗәдә, мин бүген Зөбәйдә өчен хулиган булып чыктым лабаса. Кешелеген җуйган әшәке, бозык, түбән җанлы бер зат булып. Юк, ялгышасың, Зөбәйдә. Син бу сүзне тик ачудан гына әйттең...»

Маһир урыныннан калыкты. Пәлтәсен чишеп, билендәге кынысыдан хәнҗәрен суырып чыгарды. Хәнҗәрнең сабы фил сөяге беркетеп төрле-төрле бизәкләр төшереп ясалган, ә йөзе, көмеш пычак шикелле, ялт-йолт итеп тора иде.

Маһир хәнҗәрен үткенлеген тикшерә-тикшерә, бүген нинди көн соң әле, дип уйланды. Һәм аннары, иртәгә шимбә булуын исенә төшерде. Ниһаять, үз-үзенә нык ышанып:

— Менә, Зөбәйдә, синең күңелең хәзинәсендә урам сүзләре бар икән, миндә дә бар ул тупаслык. Берсекөнгә нәкъ шушы урында очрашырбыз. Шунда карап карарбыз... Ничегрәк сайрарсың икән ул вакытта, шунда белербез, тәти кыз! — диде.

* * *

Бүген Ирек мәйданындагы халык башка көннәргә караганда да күбрәк иде. Илһам Зөбәйдәне күреп алды, янына килде.

— Нихәл, сеңелем!

— Әйбәт әле, Илһам абый...

— Шулай итеп, даулыйбызмы ирекне, ә, Зөбәйдә?!

— Без дә дауламасак, ул ирекне халыкка кем бирер соң, Илһам абый?!

— Беркем дә бирми, сеңелем, беркем дә...

Шул мизгел, халык арасында, кемдер «Туган тел»не җырлап җибәрде. Аны, тирә-юньдәгеләр күтәреп алды:

Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы...

Бер урыс икенче бер урыстан булса кирәк:

— Монда нишлиләр соң болар? Ник җыелганнар? — дип сорый иде.

— Россиядән аерылып чыкмакчы булалар бугай! — дип җавап кайтарды мыеклысы.

— Ә? Россиядән! — Мыек, чәчрәп, Илһам каршына килеп басты.— Россиядән аерылып чыкмакчы буласызмы? Ачлыктан кырылып бетәсегез киләме?! — ди-ди, кулларын бутарга, тирәкләрен чәчәргә керешге.

— Юк, без Россиядән аерылмыйбыз,— диештеләр Илһам янәшәсендә басып торган кәләпүш кигән егетләр.— Без Россия дәүләте белән берлектә тигез хокуклы булып яшәргә телибез!

— Сез ул хокукны бездән сорап аласызмы? Әллә үз белдегегез белән тотындыгызмы бу эшкә?!

— Үз ихтыярыбыз белән...

— Алай булмый ул, була алмый... хокукны сез бездән сорарга тиешле... ә без ул хокукны сезгә бирәбезме әле, юкмы! — диде әлеге ямаулы чалбар кигән урыс.

— Ә Иван Грозный, мин сезнең дәүләтегезне юк итимме, юкмы? дип, безнең бабайлардан сорап тормаган бит, сорамаган!

Урыс, теше сызлагандай, чыраен сытып куйды һәм иптәше янына китте.

— Ну, как... убедили?! — дип каршы алды аны салмыш иптәше.

— Убедили!!! — диде мыеклы урыс, күзләрен тасрайтып.

Бу вакытта мәйданда «Туган тел» җыры тагын да дәртлерәк, тагын да көчлерәк булып яңгырый иде инде:

... Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем...

* * *

Разыя Габделбәр янына тагын бер мәртәбә килергә уйлады. Һәм килде. Әмма Габделбәрне очрата алмады. Габделбәр хастаханәдән чыгып киткән иде. Кая киткән? Монысын берәү дә белмәде. Ә Разыяның Габделбәр янына килүенең максаты шул иде: ничек кенә булса да егетне сөйгәненнән биздерү һәм үз ягына авыштыру. Моның өчен аның төннәр буе корып яткан планы да бар, ул план менә нәрсәдән гыйбарәт иде. Зөбәйдә намуслы кыз түгел. Дәлил кирәкме? Менә дәлил...— һәм шунда Разыя редикюленнән чыгарып, бер хат сузар.

Нинди хат дисеңме? Сөйгәнеңнең чын йөзен ача торган тылсымлы хат булыр бу! Рәхим итеп укып бак, авторы — студент. Урта буйлы, коңгырт бөдрә чәчле, коңгырт кара күзле бик хисчән егет. Сүзгә дә кесәгә керми, җырга да оста. Гитарада әйбәт уйный. Исеме Гомәр. Фамилиясе... Фамилиясе гаҗәп кызык аның — Вулканов!

Менә шул Вулканов безнең фермада пәйда булган көнне үк Зөбәйдәгә күз салды. Ягъни гашыйк булды.

Маһир кайда идеме ул вакытта? Маһирны ул чакта берничә көнгә Алабуга төзелешенә җибәреп торганнар иде. Менә шулай... күз-колак булмаудан файдаланып, Зөбәйдә Шәймуллина дигән чая кыз әлеге дә баягы ут егет Гомәр Вулканов белән... Тфү, тфү, алласам яшен суксын үземне. Миңа аларны берничә мәртәбә кичке эңгердә икәүдән-икәү генә парлашып урман буенда йөрүләрен дә күрергә туры килде. Урман якын булгач йөргәннәрдер инде диярсең син, бәлки. Мокыт булма, Габделбәр. Үз күзем белән күрдем. Ай белән, кояш белән, туган туфрагым белән ант итеп әйтәм. Ул эш булды. Зөбәйдә синең изге мәхәббәтеңә хыянәт итте. Ул синең ярату хисләреңә төкерде. Төкерде, вәссалам! Ышанмасаң, менә бу хатны укып бак.

Габделбәр икеләнүле авыр тойгылар эчендә хатны алып укый башлар. Укыган саен аның йөзе караңгыланыр, күзләрендәге зәһәр ут чаткылары сүнә барыр, сүнә барыр һәм көчсезлек, җиңелү билгесе булган ачы һәм хәсрәтле яшьләр белән алышыныр, ә хатның соңгы җөмләсен

укып бетергәндә инде Габделбәрнең башы әйләнә башлар, күз аллары караңгыланып китәр һәм ул аяк буыннары хәлсезләнеп, минем кочагыма авар.

— Гафу ит, Разыя. Мин белмәдем. Зөбәйдәгә мең нәләт. Син чын кеше икәнсең. Миңа синең кебек юлдаш кирәк,— дияр.

Әмма Разыя иртәрәк сөенеп ташлаган икән. Аңа бу «алдакчы» хисләрне беркайчан да кичерергә язмаган булып чыкты.

Габделбәр, Разыяның үзен күтәп торуын күреп алып, ул сузган хатның беренче юлларын уку белән кире үзенә бирде.— Бу турыда Зөбәйдә сөйләгән иде миңа. Син соңгаргансың бераз,— диде ул һәм үз бүлмәсенә кереп китте.

— Габделбәр, Габделбәр...— дип чарасыз калып эндәште Разыя. Әмма егет әйләнеп тә карамады.

* * *

Маһирны бүлеккә китерделәр һәм капитан (кода абыйсы) каршына утырттылар. Шунда басып торган яшь кенә сылу гәүдәле ефрейтор аның кесәләрен тентергә керешге.

— Нәрсәләрең бар, барысын да чыгарып сал! —дип боерды ул.

— Бер нәрсәм дә юк минем, хәтта шырпым да юк,— дип ант итте Маһир.

— Көттермә, тиз бул! — диде ефрейтор.

«Вот, салага, бәйләнде бит чистый. Мә инде, алай бик кирәк булгач!» Маһир чалбар кесәләрен әйләндереп чыгарды. Идәнгә берничә бакыр тиен һәм тәмәке тузаны коелды.

— Мин сиңа кесә әйләндерергә куштыммыни?.. Яхшылык белән әйткәнне аңламыйсың.

Тырыша торгач, Маһирның кесәләреннән алынган әйберләр шул булды: яньчелгән биш папирос, өч шөреп, бер тарак, егерме сигез тиен бакыр һәм керле кульяулык.

— Бу нәрсә? — диде ефрейтор бармагы белән төртеп.

Маһир дерт итеп китте. Кульяулыкта кан таплары аермачык булып беленеп тора иде. Димәк, ефрейтор нәрсәдәндер шикләнә яки аның нәрсәнедер беләсе килә. Мәгәр Маһир эндәшмәде һәм бәхетенәдер, ефрейтор әлеге әйберләрне сейфка бикләде дә, Маһирны тар һәм озын коридор буйлап алып китте.

Менә алар сулга борылдылар. Ефрейтор бер тимер ишекне чылтыратып ачты, Маһирны эчкә үткәреп җибәрде һәм янә чылтыратып япты да бикләп куйды.

Маһир килеп кергән бүлмәнең буе дүрт, иңе биш метрлар чамасы булып, ул ир-ат кавеме белән белән шыплап тутырылган иде. Мунчаныкыдай кара түшәмдә егерме бишле лампочка асылынып тора. Бүлмә һавасы искиткеч тынчу һәм бөркү. Монда нинди генә әшәке исләр юк: тән исе, аяк тире исе, аракы, ширбәт, сыра, суган, сарымсак, тройной һәм тагын әллә ниткән көек исе, тәмәке исе.

Маһир укшып җибәрүдән чак-чак кына тыелып, таныш булмаган чит-ят адәмнәрнең йөзләренә карапып торган арада, аның янына кавказлы бабай белән Урта Азия егете килеп басты

— Подпольный тәмәкең юкмы?

— Минем аристовать иткәндә үк юк иде андый нәрсә.

— Алкаш, димәк ки!

— Сезнең кебегүк пролетар баласы мин...

Күпчелеге чытык йөзле, миләре спирт пары белән томаланып торганлыктан, көлү сәләтләрен югалта башлаган кешеләр дә елмаеп куйдылар. Һәм алардан берничәсе Маһирга табарак елыша төште. Ә кавказлы бабай белән Урта Азия егете, аңа кул селтәп, үз урыннарына күчтеләр.

Маһир да аптырап-йөдәп тормады, цемент идәнгә бәкшәеп ятучыларга басмыйм дип, сак кына атлый-атлый, ничек кирәк алай, сулъяк почмакта гәпләшеп утыручылар арасына барып кысылды.

— Кто такой? А, ну-у-у!..— диде берсе этелеп кысылуга артык түзә алмыйча.

— Борчылмагыз, үз кеше! — диде Маһир.

— Берәрсен чәнчелдерденме әллә? — диде кемдер.

— Әйдә безнең янга! — диде Урта Азия егете.— Анда сиңа җайлы урын бар.

Урта Азия егетенең җайлы урын дигәне чүп-чар тулы тузанлы идән булып чыкты.

... Кайсы вакыт булгандыр, Маһир уянып күзләрен ачты. Кемдер аның җилкәсенә кулын салып, аңа таба авызын куеп яткан. Ул кешенең авызыннан җен исләре килә. Караса, Урта Азия егете икән! Маһир махмырдан авырайган башын көчкә күтәреп әйтте:

— Слуши, авызыңны читкәрәк ал әле! Мин бит сиңа воздухочиститель түгел.

— Һам-һам...— дип тәмле итеп авызын чапылдатып куйды Урта Азия егете.

— Слуши!

— Нәрсә-ә-ә? — дип, ниһаять, ярым уянып әйтте бу.

— Вахитов комбинаты торбасыннан чыккан исләр килә аннан! Авызыңны читкәрәк ал дим...

— Ошамаса, борылып ят! — дип арага керде кавказлы бабай ачуланып.— Шуның өчен йокыдан уятып ята бит...

Маһир борылмакчы иде, кымшана да алмады. Аның аякларына, биленә байтак ир баш төртеп яткан иде. Боларны, күрәсең, Маһир йоклаган арада тутырганнар иде. Ә теге яман ис килә дә килә. Аптырагач, йөдәгәч, Маһир, ниһаять, җаен тапты. Малахаен салып, Урта Азия егетенең ягына таба каратып куйды. Ис килүдән туктады. Әмма Маһир тынычланып җитә алмады. — «Сәгать ничә?» — дип уйлады ул, дөм караңгы бүлмә эченә ярыклардан үтеп кергән яктылыкны күрмәк булып. Ләкин бүлмәдә бернинди ярык та, яктылык та юк иде. Бүлмә эче тирән базга төшкәндәй салкын һәм дөм караңгы иде.

«Ичмасам, сәгатьне генә булса да калдырмадылар бит,— дип уйлады Маһир һәм кинәт эсселе-суыклы булып аягына ябышты. Бәхетенәдер, акчалары оек балтырына кыстырылган килеш исән-сау торалар иде.— Ә хәнҗәр? Хәнҗәр «Б» урамындагы кәрт эчендә... Иртәгә аннан алып, ул аны биленә тагып куячак әле!

Маһир сөенеченнән хәтта онытылып китеп, сикереп тормакчы да булган иде. Мәгәр лавка тактасына башы бәрелеп, күзләреннән көлтә-көлтә утлар очты. Аннары, хәлсез генә көрсенеп, башын беләгенә төшерде. Күзләрен йомды.

...— Низамутдинов? Чыгарга! — дигән тавышка уянып китте ул. Бүлмә эчендә тоныкк кына булып, егерме биш-ле лампочка яна. Гырлап ятучылар юк инде, барысы да уянып беткәннәр. Ярым ачык ишектә мыеклы сержантның табак битле, фуражкалы башы шәйләнә.

Әле генә кергән ирне, «допрос»ка чират көтеп торучылар сорау белән күмеп каршыладылар.

— Ну, ничек?

— Судка калдырдылар.— Аның тавышында язмышыннан курку һәм үкенү дә сиземләнә кебек иде.

— Нишләтерләр икән?

— Кем белгән инде аны! Узган ел ун тәүлек чәпәгәннәр иде...

Маһир шунда гына кемнәр арасына эләгүен аңлап алды. Ул, айныткычта түгел икән. Аны хулиганнар, тәртип бозучылар янына кертеп япканнар икән. «Ярый, ахыры хәерле булсын,» — дип Маһир авырсынып кына урыныннан кузгалды.

...Бу юлы капитан кода абыйсының урынында лейтенант утыра иде.

— Ни өчен тәртип боздың? — дип сорады ул.

Маһирның кәефе юк иде. Аның үзен-үзе дә күрәсе килми иде бу минутта. Ул йокымсырагандай итеп башын түбән иде.

— Как так җавап бирмисең... А ну-ка... Басале! Ссс-миррр-но-о!..

Маһирга буйсынудан башка чара калмады.

— Ни өчен тәртип боздың? Кабатлап сорыйм.

«Фоат абый әйбәт иде», — дип уйлады Маһир.

— Син нәрсә, ишетмисеңме әллә?

— Сезгә мин нәрсә әйтим? Бүлмәдә ничек йоклаганнымы? Мин бар булганны кичә капитанга әйттем инде.

Лейтенант үтә җиңел сөякле, кырыс холыклы кеше иде, ахры. Ул бер дә тик кенә тора алмый: әле тегендә үреләә, әле монда сузыла, һаман хәрәкәттә.

— Бирегә килеп утыр! — диде ул, шкаф янындагы өстәлне күрсәтеп. Өстәл өстендә кәгазьләр һәм җеп белән арканлап куелган агач ручка ята.

— Аңлатма яз! — диде лейтенант. — Ни өчен тәртип боздың, аңлатып яз!

Маһир өчен аңлатма язудан да рәхәт һәм мавыктыргычрак эш бармы икән бу дөньяда! Мин фәлән-фәлән дип башлыйсың да китәсең үзеңне кызгандырып, китәсең...

Биш-алты минут та үтмәде, Маһир аңлатмасын язып та бетерде. Лейтенант таракан йөргән сыман чуар кәгазьне баскан уңайга гына укып чыкты һәм папка эченә кыстырып куйды, ә аннары ниндидер кәгазь алып Маһирга сузды.

— Сиңа штраф. Бүген үк түләргә!.. Түләмәсәң, эшеңә хәбәр итәчәкбез!

— Ярый, — диде Маһир штраф кәгазен лейтенанттан алып. — Мин моны түләрмен... — Һәм борылып, салмак адымнар белән бүлектән чыгып китте.

* * *

— Депутатлар килә...

— Һә-һә-ә-ә-әй-й... депутатлар килә-ә!

Халык диңгезе, бик көчле җил исеп киткәндәй, чайкалып куйды. Ярымай һәм йолдыз сурәте төшерелгән яшел төстәге байраклар тагын да югарырак күтәрелде, йөзләр җитдиләнде, күзләр очкынланды...

— Депутатларны үткәрмәгез! — дип кычкырды берәү тавыш көчәйткеч аша. — Югары Совет бинасы буйлап таралышыгыз... арт ишектән кереп китмәсеннәр! Без шуны таләп итәбез: алар мөстәкыйльлегебезгә куркыныч яный торган карарны юкка чыгарсыннар! Без шуны таләп итәбез... курыкмагыз, мөхтәрәм җәмәгать депутатлар үзебезнеке, аларны без сайлап куйдык һәм алардан азатлык сорарга тулы хаккыбыз бар. Ә азатлык бит безгә генә түгел, аларга да кирәк! Аннары, бәлки, иң мөһимедер дә... азчылык халыкка азатлык бирми торып, күпчелек халык үзе дә азат булмаячак — шуны аңласын урыс иптәшләр!

— Дөре-е-с!

— Аңлатырга кирәк...

— Азатлык!!!

— Иптәшләр! Илле елга якын Татарстан нифтен Мәскәү суырып, бал-майда йөзеп ятты, ә без һаман хәерче... Болай дәвам итсә, озакламый, чабатага калачакбыз! Ә коллыкның иң түбән баскычы шул инде — чабата киеп йөрү! Безгә чабатаны Мәскәү кигермәкче була: үзебез сайлаган депутатлар һәм үзебезнең татар җитәкчеләре аша! Мәскәү әле һаман безне сарык көтүе дип уйлый, алар белән ни эшләсәң дә, ни кылсаң да мөмкин, дип фараз кыла. Юк, җитәр! Күп алдадылар! Бүтән алдат-

мыйк! Акыллы булыйк! Мөстәкыйльлегебезгә куркыныч яный торган карарны юкка чыгартыйк. Һәм шуны эшләтсәк, тарихи дөреслек торгызылыр — без ирекле булып яшәрбез, ә эшләтмәсәк — ярык тагарак янында утырып калырбыз. Иптәшләр... Җитмеш елдан артык капитализмны сүктек, социализмны мактадык... социализм безгә нәрсә бирде һәм бирә вә бирәчәк? Аңладык — тоташ хәерчелек, рухи торгынлык, таркаулык, бөлү, милләтләрнең юкка чыгуы. Ә капитализм нәрсә бирә? Капитализмның нәрсә биргәнен без бәләкәй генә Күвәйт иле мисалында күрә алабыз! Безнең Татарстан Күвәйттән киммени, җәмәгать, ә?!

— Ким түгел, әлбәттә, артык та әле!

— Афәрин! Бик дөрес әйттең!

— Яшәсен азатлык!

— Азатлыкны безгә, тик торганда гына, бәрәү дә тәлинкәгә салып бирмәячәк, мөхтәрәм җәмәгать! Без аны үзебез даулап алырга тиешбез, тик даулап кына!

— Башка чара калмады инде... йә кол булмыйча яшәү, йә — үлем: икенең берсе!

«Минем кебек уйлыйлар икән болар да,— дип куйды Зөбәйдә эченнән генә.— Бу турыда әнигә дә язып салырга кирәк әле».

Ә депутатларның күпчелеге, сессия залына кереп китәр алдыннан, халык каршына басып, мөстәкыйльлеккә куркыныч яный торган карарны юкка чыгартачакларына ышандырдылар.

* * *

Бүген ял көне.

Зәлия ханым ирекле темага язган сочинениеләрне тикшерә. Тикшереп бетерә инде. Аның кулында Габделбәр сеңлесенең дәфтәре генә калды. Менә ниләр язып куйган Гамбәрия:

«Мин мәктәпне тәмамлагач, университетның физмат факультетына укырга керәчәкмен...»

Керер, керер... башлы кыз. Укуга бик һәвәс. Җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Сәбәпсез дәрес калдырганы юк!

Зәлия ханым дәфтәрне ябып, ишләре янына куйды.

Тышта җил, буран.

Гүя өй почмакларында кемдер әче итеп сызгыра, моржада сузыпсузып улый. Ул да түгел, тәрәзә шакыган һәм капка дөберләткән кебек тавышлар ишетелеп куя.

Төнлә булса бер хәер. Көпә-көндез әллә нинди шикләр килә күңелгә. Ялгызлык. Барысына да ялгызлык гаепле. Кара-каршы утырып сөйләшер кешең булмагач, кыенга туры килә шул, һәммәсен дә йөрәккә җыеп барасың инде. Дөрес, Зөһрәбану әби аякка баскан кебек булды булуын. Ләкин ул юньләп күрми дә, ишетми дә хәзер. Шуңлыктан карчыкның өйдәлеге сизелми дә шикелле.

Кайчакларда йөрәккә җыелган авыр йөктән котыласы, түгәнчы елап бушанасы килә. Мәгәр ялгыз башың елап та булмый икән ич. Күз яшьләрен күрсәтер өчен дә сине аңлаучы, синең хәләңә кереп белүче кеше кирәк икән!

Аннары ялгыз кешегә ялгызлыктан котылып тору өчен ныклы бер шөгыль дә кирәк әле. Хәер, ул һәммә адәм баласы өчен дә кирәк. Әмма олыгаеп барганнар өчен бигрәк тә!

Зәлиянең әнисе кайчандыр тирә-юньгә бер дигән оста тегүче иде. Һәм ул бу һөнәргә кызын да бик яшьли өйрәткән иде. Әгәр дә ялгызлыктан бик эче пошып китә башласа, Зәлия ханым хәзер дә әнә тегү машинасы янына барып утыра. Бу һөнәргә Зөбәйдә дә өйрәнмәде түгел. Һәм Зөбәйдә дә, әнисе шикелле үк, тегүчелеккә генә канәгать булмады. Аның да укыйсы, күп беләсе килде. Әмма ул бөтенләй үзгә

юлдан, медицина юлыннан китте. Ярый инде, башы-азагы хәерле булсын, амин!

Авылда кешеләрнең күпчелеге Зөбәйдәнә әтисе Хисаметдингә охшаталар. Төс-бите белән генә түгел, холык-фигыле белән дә... Кыз бала атага охшаса, бәхетле була, диләр.

Зөбәйдә дә бәхетле булыр кебек.

Менә озакламый Габделбәр терелеп хастаханәдән чыгар. Бергәләп авылга кайтырлар. Туй итеп җибәрербез... Һәм Зәлия ханым кызыннан килгән хатны сыйпый-сыйпый озаклап, зәһәр җилгә колак салып, тышта котырган буранга караган көе утырды да утырды.

Аннары ул торып киенә башлады. Урамга чыкты. Җил-буранга каршы бөгелә төшеп, бер кулы белән йөзен каплап, Фирданияләргә таба юл алды.

— И Зәлия, Зәлия... Шушындый күз ачкысыз буранда, шуннан хәтле килеп йөрүләрең өчен рәхмәт инде,— дип каршы алды аны Фирдания, оек бәйләп утырган төшеннән кузгалып.

— И Фирдания, ялгыз башка ял көнендә өйдә утырулары бик читен бит.

— Анысы шулай инде. Серләшер өчен күзле, колаклы кешең булмагач теге... Киемнәреңне менә монда эл, Зәлия. Әйе, менә шулай.

— Итекләремне дә салыйм инде беррәттән... Булды бу. Инде дога кылып алыйк.

«Әгүзе биллаһи... хәвеф-хәтәрләрне күрсәтмәсен, аяк-кулларны сызлаусыз итсен, илгә тынычлык-иминлек, өйгә бәрәкәт китерсен. Амин.»

— Гасыйм күренми, өйдә юк, ахры?

— Эшкә китте, фермасына. Өйләдән соң бармаса да ярар иде дә... Мин дә бармасам, башкалар да өйдә утырса, кала кешеләрен сөт-май, ит белән кем тәэмин итәр, ди...

— Шулай инде шулай... Гасыйм үз эшенең тәртибен белә инде ул!

Зәлия ханым, уч төбе белән ияген сыпырып куйгач, урындыгын түргә табарак күчереп утырды. Ул бирегә ялгызлыктан, эч пошканнан гына килмәгән иде. Күңелен борчып, бимазалап торган уйлары, фикерләре бар иде аның. Ул шуларны булачак кодагые белән уртага салып сөйләшергә, кыска гына итеп әйткәндә, киңәш-табыш итәргә килгән иде.

Ханымның кесәсендә Зөбәйдә язган җитди бер хат бар. Анда кыз әнисенә артык киң җәелмичә генә яшь йөрәген ачкан, күңеле бакчасында чәчәк атып утырган хисләрен җыр итеп юллаган.

«Мин,— дигән ул,— Габделбәрне өзелеп сөям. Габделбәр дә мине ярата...

Татлы ширбәт исе белән тулган кичләрдә сандугачлар да кавыша. Безгә дә ник кавышмаска?

Шулай, әни, без озакламый кавышырга уйлыйбыз. Бер җан, бер тән булып яшисебез килә. Тик моның өчен иң элек язылышырга кирәк. Язылышырга, анысы бездән генә торып калмас. Әмма туйны ничек үткәрербез? Бу авылда туганнарыбыз юк бит безнең. Туганнарыбыз юк, дип үзең әйтә идең ич, әни. Ләкин мин ышанмыйм туганнарыбызның юклыгына. Шундый зур авылда бер бөртек туган-тумачаң булмасын, имеш. Тикшерә китсәң, ярты авыл безгә тугандыр әле. Кияүгә чыккач тагын да күбәер әле ул туганнар. (Шул урында Зөбәйдә көлеп өстәгән). Ә хәзергә туй өчен генә дә «туганнар» табып куярга кирәк.

Саулык-сәламәтлек теләп, Зөбәйдә.»

Зәлия ханым хатны алып күрсәтсә дә, тоташтан укырга җөрьәт итмәде, кыскача гына сөйләп бирде. Үзеннән дә чәчәкләп-чуклап өстәп җибәргәләде. Тегүче кызы сүзгә оста булмыймы инде.

Фирдания түти аны бик бирелеп тыңлады. Эченнән генә малае өчен сөенә иде бугай ул.

Ә инде өенә кайтып барганда, тыкрык чатында, Зәлия ханымны Мәйсәрә түти туктатты. Аның күзләре яшьле иде.

— И Зәлия ханым... аптыраган үрдәк суга арты белән чума, ди. Сине күреп алгач, йөгереп чыктым әле менә... Ни бит... Гыйльметдинемне авыр хәлдә бүлниска озатып җибәрдем баярак кына...

— Гыйльметдин абыйга ни булды соң?

— Бавыр инде аның... ул эчүләр кая китсен соң! Белмим, исән калырмы, юкмы?

Бу урында Зәлия ханым Мәйсәрә түтигә ни әйтергә дә белмәде. Шулай да ни дә булса әйтергә кирәк иде.

— Терелер, боерса... терелер.

— Бавыры тураклангачтамы?... Терелми! Юк, терелми!.. Күңелем сизә: нинди дер яман хәлләр булачак... Ай, булачак яман хәлләр... И ходаем! И аллам!

Зәлия ханым, Мәйсәрә түтинең башыннан чишелеп шуып төшә башлаган шәлен янадан ябып бәйләп куйды.

— Рәхмәт, Зәлия! — диде Мәйсәрә түти. Һәм кинәт башын Зәлия ханымның күкрәгенә куеп, үксеп елап җибәрде. Бераз елап юангач, башын күтәрде, тураеп басты; шәл чите белән күзендәге яшьләрне сөртеп алды. Аннары укытучы ханымга эндәште:

— Ни... безгә керик әле, Зәлия: чәем дә кайнар, бөккәннәрем дә суынмагандыр! Бер иркенләп сөйләшеп утырыйкчы, ә?!

— Менә әле баярак кына чәйләп чыктым, Мәйсәрә апа, рәхмәт! Башка вакытта, ямме... Өемдә эшләрем күп, ашыгам! — диде Зәлия ханым.

— Шулайдыр инде шулайдыр... — диде Мәйсәрә түти кинәт күңелсезләнеп. Аннары тавышын акырынайтып әйтте:

— Зәлия... сенелем... ни бит... Маһирны тәмам батырмаска иде дим. Ни генә әйтсәң дә, бала бит ул минем өчен. Яклыйсы иде бит аны...

— Мәйсәрә апа! Маһир тотылмаган ич әле! — диде Зәлия ханым аптыраудан гаҗиз калып.

— Тотылмаган шул менә, тотыла калса дим... Дөрес, мин аның гаепләре юк дип санамыйм... Шулай да, ул синең укучың да бит әле, Зәлия!

— Элекке укучым! — дип төзәтте Зәлия ханым.— Ярар алайса, мин бу турыда уйлап карармын, Мәйсәрә апа... — Һәм Зәлия ханым тыкрыкка кереп күздән югалды.

* * *

Зөбәйдә Габделбәр яныннан чыкты. Көн кичкә авышып бара. Өскә төшәм-төшәм дигән төсле куркыныч булып, тау-тау болытлар асылынып торган тәбәнәк күк йолдызларсыз һәм айсыз кич булачагын хәбәр итә. Һаваның каннарны оетырлык дәрәҗәдә тын булуыннан төнлә белән буран кубу мөмкин икәнлеген дә чамаларга була. Бит, диңгездә дә давыл алдыннан шомлы тынлык булып ала, диләр.

Зөбәйдә капка буена җитте. Урамга аяк басам дигәндә генә кинәт аның каршында, җир астыннан калкып чыккандай, Маһир пәйда булды.

Егет ябыккан. Йөзе шиңгән кәбестәне хәтерләтә. Яңак сөякләре очлаеп чыккан. Карашы да, усал мәче күзләреләй, очкынлы түгел, тоньк һәм куркулы. Киемнәре дә йомарланып беткән. Тик сакал-мыегы гына пөхтәләп кырылган иде.

Зөбәйдә Маһирны читләтеп үтеп китәргә уйлады. Мәгәр егет аның юлын бүлде. Бу эш берничә тапкыр шулай кабатланды. Ахырда кыз түзмәде, тавышын күтәреп сорады:

— Нишләтмәкче буласың син?

— Синең белән аңлашырга телим, Зөбәйдә!

Кыз дәшмәде. Тамак кырып куйды. Аннары хастаханә ягына таба бара башлады.

— Анда түгел, Зөбәйдә...

Маһир кызны кулыннан эләктереп будкага таба әйдәде.

— Җибәр... Юкса кычкырам! — диде кыз.

— Кычкырмыйсың... кычкырмыйсың...

— Каравыл! — дип аваз салды Зөбәйдә.

— Тилермә! — диде Маһир, тиз-тиз генә кызның авызын томаламакчы булып.

— Кит, бандит, пычрак кулларың белән орынма миңа!

Маһир яңагына суккандай, чайкалып куйды. Аннары исен җыеп, икеләтә куәт белән Зөбәйдәне будкага сөйрәп алып керде.

— Каравыл! — дип кычкырды Зөбәйдә. — Каравыл!

— Кычкыр, тагын да катырак кычкыр, — дип кинәт кызып китте Маһир. — Мин беркемнән дә курыкмыйм хәзер. Куркудан узган инде мин. Әйдә, кычкыра бир.

— Их...оятсыз! Сиңа карарга да уңайсыз, наждакламаганнар да бит сине.

— Әйт... теләсә нәрсә әйт, Зөбәйдә... аяк астына салып таптап... туфрак ит, әмма аңа карап кына мин сине яратудан туктамаячакмын...— Һәм Маһир лып итеп идәнгә чүкте, Зөбәйдәнең аякларын кочты, үкси-үкси еларга керешге.

Зөбәйдә нәфрәтләнеп йөзен читкә борды. Бу минутта Маһир аңа аяк астына тапталып сытылган кабакны хәтерләтте. Әйтерсең лә матайда сәяхәт итүләр, комбайнда утырып йөрүләр, машинада барулар, куштирәк төбендә чөкердәшеп торулар булмаган да. Хәер, аларның булуыннан файда юк инде. Маһир тормышның ул якты сәхифәләрен мәңгелеккә караллты бит.

Зөбәйдә чак кына иелеп Маһирның кулларын этеп җибәрде. Будка почмагына барып басты.

— Зөбәйдә! — диде Маһир кызга таба омтылышлы бер хәрәкәт ясап. — Әйт әле, кайчан да булса яраттыңмы син мине?

— Юк... — диде Зөбәйдә кискен итеп. — Уйлаганым да булмады хәтта.

Маһир торып басты.

— Яраттың бит! Ник яшерәсең, Зөбәйдә? Яраттың... яраттың син мине...

— Юк!

— Яраттың ич инде...

— Юк!

Маһир кинәт башын артка ташлап, күзләрен зур ачып шигырь сөйләп җибәрде:

Син булдың да... йөрәгемне әсир иттең,
Үз артыңнан ияртгең дә алып киттең,
Як-ягыма карамадым,
Чит ярларга багалмадым.
И, Зөбәйдә, нигә мине болай иттең?
Син булмасаң... башка берәү булыр иде,
Яннарымда гел елмаеп торыр иде.
Син — Зөбәйдә... Мине...
Менә кара!

Кыз борылып карады. Тетрәнеп куйды. Маһирның кулында хәнҗәр ялтырый иде. Егет хәнҗәрен капылт кына югары күтәрде. «Бетүем шушында икән!» — дип уйлады кыз. Ләкин куркуын йөзенә чыгармаска, сиздермәскә булды ул. Елмайды. Шундый итеп елмайды ки, Маһирның, гүя, кызның йөзендәге нурларыннан күзләре чагылды. Менә бит... аның сөеклесе, мәхәббәте каршында басып тора, елмаеп басып тора, ә ул, һәчтрүш, аңа хәнҗәр күрсәтә, яный, куркыта... Йә, шуннан... Зөбәйдә курыктымы? Юк, нишләп курыксын ди, белә ич, Маһирның аңа тия алмаячагын! Маһир кинәт ачыргаланып, хәнҗәре белән үзенең беләгенә чапты. Аннары тагын, тагын...

Ниһаять, егет аһылдап куйды. Беләгенә батып кергән хәнҗәргә икенче кулы белән тотынды. Чайкалып китте. Йөзе ап-ак булды, иреннәре күгәрде һәм ул егылмас өчен диварга сөялде. Идәнгә җинен юешләтеп, беләгеннән шыбыр-шыбыр кан агарга кереште.

Зөбәйдә коты очып: «А-а-а-а!» — дип кычкырып җибәрде һәм үзенүзе белештермичә ишеккә ташланды.

Тышта буран улый иде. Ачык калган ишектән иң элек будка эченә җил бәреп керде. Ач юлбасар кебек почмакларны капшанып чыкканнан соң, бу нәрсә тагын дигәндәй, диварга сөялеп утырган Маһирны сыпырып узды. Кан өстенә ярма сипкәндәй булып, кар тузаны коела башлады.

...Зөбәйдә егерме минуттан соң ашыгыч ярдәм машинасы белән әйләнеп килде.

Тәмам хәле киткән Маһирны носилкага салып машинага керттеләр. Егет авырлык белән генә күзләрен ачты. Ул Зөбәйдәне танып алды, җәрәхәтләнеп беткән беләген кысып тотучы кулының җәдәч бармагын чак-чак кына кыймылдатып, кызны үзенә чакырды. Зөбәйдә килеп Маһирга иелде.

— Мин... сине... барыбер яратам, Зөбәйдә! — диде Маһир.

* * *

Зәлия ханым, ишле гаиләләрдәге эш кешеләре белән бервакытта диярлек торып, миченә ут кабызып җибәрде. Кичтән алып кереп эссе мичкә куеп калдырганлыктан, утыннар шытырдап кипкән иде. Шундук күңелле генә гөрелдәп, ялкынланып яна да башладылар. Электр уты яктысы почмак тәрәзәсенә төшми иде, менә хәзер аларда мичтәге ялкынның эссе телләре, җилдә җилфердәгән бер сылуның кызыл күлмәге сыман булып, чагылып уйнарга кереште. Зәлия ханымның сөякләреме, әллә өй эчеме кинәт җылынып киткәндәй булды. Әй, нинди генә хикмәте, нинди генә сере юк бу утның.

Ут — тереклеккә көч, утсыз дөнья чүтсыз, утка төкермә, авызың кутырлар, ут белән шаярырга ярамый.

Яхшы кеше кулында ут изгелек белән яныр; явыз кеше кулында ут яманлык кылыр...

Зәлия ханым ут турында кечкенәдән үк олылар авызыннан ишетеп үскән сүзләрнең төп мәгънәләре хакында уйлый-уйлый чишмәгә суга барырга чыкты. Һәм менә каршында пәйда булган буйчан кызны күреп туктап калды.

Кыз өстенә мутон якалы пальто кигән, башына мамык шәл япкан. Аның аякларында баскан итекләр, ә кулларында чигешләп бәйләгән йон бияләйләр иде. Ул нәзек кара кашлары астындагы коңгырт күзләре белән һичнинди хәйләсез карап килә-килә кычкырып эндәште:

— Исәнмесез, апа! Суга барырга чыктыгызмы? Кая үзем алып кайтып бирим әле. — Һәм ханым җавап биргәнен дә көтмәстән, җәһәт кенә көянтәгә үрелде.

Зәлия карышмакчы иде, булдыра алмады. Әллә нидән генә кулаяклары кадаклангандай булып калдылар. Җитмәсә теле дә көрмәкләнеп китте, әйтер сүзләрен дә әйтә алмас хәлгә килеп, аңкы-миңкеләнеп торган арада, Гамбәрия инде көянтә башларындагы чиләкләрне уйнатауйната, җил-җил атлап чишмәгә таба юл алган иде.

...Кыз чишмәгә җитәрәк күрде: Разыя чиләкләрен мөлдерәмә тутырган да, үз алдына уйланып, ашыкмыйча гына, җай гына болай таба атлый. Гамбәрия аның килеп җиткәнен көтмәде, сукмактан чыкты да үтеп киткәнен көтеп тора башлады. Разыя якынайганнан-якынайды һәм, карашы төшеп, кызны танып алды. Ләкин туктамады, чак кына елмаеп, исәнләшкән сыман башын кагып үтеп китте.

Гамбәрия сукмактан чыкты, нилектәндер арт ягына борылып карыйсы итте. Чишмәгә җиткәч, ул янә әйләнеп карады, менә гаҗәп, урамга кереп бара торган Разыя да аның ягына борылып карады.

Гамбәрия өченчегә чишмәгә килгәндә Разыя да икенчегә су алып тора иде. Күрәсең, аның Гамбәриягә нәрсәдер белгертәсе һәм үзенең дә нәрсәләрдер сорашып беләсе килә иде. Менә ул икенче чиләген дә тутырып бетерде. Һәм ялт кына үрелеп, кызның көянтә башыннан чиләген алып торбага элеп куйды. Күңелле генә елмаеп сораша башлады:

— Йә, матурым, сөйләп җиффәр, башкалабызда ниләр күрдең соң?

«Атаң башын күрдем»,— дип чак кына әйтеп ташламады Гамбәрия, исен җыеп, вакытында тыелып калды. Ярый әле әйтмәде. Әйткән булсамы? И-и-и, әйткән булса-а-а!..

— Ник дәшмисең, сеңелем!

Гамбәрия кызарып аяк очларына текәлде.

— Ник дәшмисең, ә?

Гамбәрия җавап урынына, мөлдерәп тулган чиләген торба башыннан алып, икенчесен куйды.

— И, үзең бухгалтер булам дип йөрисең... Бухгалтер булырга тел кирәк бит аңа, батырлык кирәк...

— Булмыйм мин бухгалтер!

— Кем буласың соң?

— Врач!

— Ә влач-ч...— дип, бу сүзне бозып, мыскыллы елмайды Разыя.— Прапорщик Зәлиясе янында (Зәлия ханымның беренче ире прапорщик булган) күп йөрсәң, ул сине влач кына түгел, академик та итәр, телсез академик! Ха-ха-ха...

Гамбәрия елардай булып хурланып, өйләренә кайтып китте. Ә Разыя, Габделбәрнең сеңлесен теле белән усал итеп чеметеп алуына кәефе булып, чишмә юлында күренгән хатынның килеп җиткәнен көтәргә кереште.

...— Иһей-й, Сатирә апа, килененңне тәпәнгә салып тозларга куймагансыңдыр ич?

— Юк Разыя, юк, иртә әле аны тозларга, иртә.

— Кем әйткәндәй, тәме бозылыр дип куркасыңдыр инде?

— ???

— Ниме соң, Сатирә апа...

— Ниме?

— Тату торалармы диюем.

— Һи юләр, әйтеп торасың тагын, аглый белән таглый инде. Ялашып кына торалар.

— Шулай укмыни, Сатирә апа? Бул-мас-ла-а!

— Һи-и, тиле... бер дә галәмәт инде менә.

— Һәй... урланган мал хәрәм мал, эчкә килешми дип, әйтәләр тагын, килешкән бит болай булгач!

— Урласа да, кем, Разыя сеңелем, кешенекен түгел, үзенекен алып кайтты.

— Бе-ел-ми-и-м, бе-ел-ми-и-м, Сатирә апа!

— Белмәсең, белерсең әле, дөнья бу!

Разыя Сатирә түти артыннан симәнкә чирттереп, көлеп карап калды. Аның тагын шулай кемнедер көтәсе, кем беләндер (елан чагар өчен яратылган инде ул) әрепләшеп аласы килде. Ләкин, сиңа кирәктә шулай бит ул, чишмә юлында бүтән кеше-фәлән күзгә чалынмады, Разыя тулар-тулмас чиләкләрен күтәреп кайтырга чыкты.

Буага җитәрәк бәләкәй чана тартып барган Хисаметдин очрады. Ап-акка әверелгән чәчләрен кара эч бүрке астына яшереп, авызы эченнән генә ниндидер җыр да көйләп бара иде Хисаметдин. Чанага ике кочак чамасы утын бәйләп салган. Күрәсең, Хисаметдин аларны кибетен ягып җылытырга алып барадыр.

— Алла куәт бирсен, Хисаметдин абый! — дип аваз салды Разыя әз-мәз генә куштанланып. Кибетче бит! Күз өстендәге каш кебек кирәкле кеше.

Хисаметдин Шәймуллин кызларның, бигрәк тә «начальник» кызларның аңа шулай әз-мәз генә куштанланып дәшүләрен үлепләр дә ярата инде. Һәм үзенең дә аларга ачылып, елмаеп, каш сикертеп куштанланып җавап бирәсе килеп китә иде.

— Исән бул, Разыя, сәламәт бул,— уенын-чынын бергә кушып.— Су апкайтып барасыңмыни, җанаш? — дип өстәде аннары үзе дә әз-мәз генә салам кыстырып.

Бер атна элек кенә алар (тәэминатчы-аралашчыны да кертеп) ялган документ әзерләп, ярыйсы гына әйбәт акчаны кесәләренә салып куйганнар иде.

— Ә син, Хисаметдин абый, кая илтәсең бу утыннарны?

— Кибеткә ягарга ла инде, җанаш. Менә синең кебек кәттә кызлар автобус көткәндә өшеп тормасыннар, керәп җылынсыннар өчен...— һәм Хисаметдин үз алдына күңелле генә елмаеп, чанасын тартып китеп барды.

Тыкрыкка кергәндә Разыяга Миңсылу очрады. Хат ташучы яшь хатынның йөзе караңгы, иреннәре кысылган иде. Ул, ашыгып, кемгәдер житди хәбәр илтә бара иде булса кирәк. Разыя турысында да туктамады, әйтеп кенә узды:

— Маһир үз-үзенә кул салган, ди!..

Разыя, өстенә бер чиләк бозлы су койгандай, катты да калды.

Бу дәһшәтле хәбәр тиз арада авыздан авызга күчеп, берничә сәгать эчендә бөтен авылга таралып өлгерде.

* * *

Маһирның үз-үзенә кул салуын Зөбәйдәдән ишетте Габделбәр. Ишетте дә бер мәл тын торгач:

— Эт котырса, шулай була ул,— диде. Аннары өстәп куйды: — Менә тагын бер әкәмәт, Зөбәйдә...— һәм ул кесәсеннән кәгазь алып кызга сузды.

— Укып бак әле.

Язуы Разыяныкы иде.

«Габделбәр! — диген.— Әгәр дә Зөбәйдәгә өйләнәсең икән, миннән рәхим-шәфкать көтмә. Мине ал дип әйтмим, дөньяда кыз бетмәгән, ләкин Зөбәйдәгә нәфесеңне сузма. Ул кала шпанасы Маһирның да башына җитте... Үкенерсең, соң булыр, өйләнмә аңа!»

Зөбәйдәнең йөзе кызарып пешкән алма кебек булды, борын очында вак кына тир тамчылары елтырашты.

— Кем бирде моны? — дип сорады ул бераздан, йөрәгендәге нәфрәт уты сүрелә төшкәч.

— Разыя үзе килде монда. Мине синнән ваз кичәргә үгетләде. Сүзләре тәэсир итмәгәч, әллә нинди бер фальшивый хат укытты. Ул хат миндә саклана, менә ул!

Зөбәйдә сискәнеп китте.

— Гомәр Вулканов! Ул язганмы моны? Булмас! — һәм Зөбәйдә ашыга-ашыга хатны укырга кереште.

Коточкыч төчеләнү, ясалмалык һәм әшәкелек аңкый иде бу хаттан. Зөбәйдә хәтта, пычрагы йокмадымы икән дип, бармакларына карап куярга да мәҗбүр булды.

— Ах! Кара җан... Гомәр Вулканов дип тамгалаткан бит әле. Хәтерлисеңме, Габделбәр. Мин сиңа бер мәзәк егет турында сөйләгән идем... Ләкин ул егет монда язылган кебек кабахәтлеккә беркайчан да барачак түгел. Аның калада сөйгән кызы калган иде. Шул ук елны мин аларның туйлары булуын ишеттем.

— Аңлыйм, Зөбәйдә. Бу турыда бер сөйләгән идең бит инде. Әйдә булмаса без бу ялган язуларын ертып чүплеккә ташлыйк.

— Әйдә...

— Ә хәзер мин, Разыя, подвалга төшеп, киемнәремне алып меним... Чыгаралар бит! Авылга кайтабыз бүген.

Зөбәйдә гаҗәпләнеп һәм елмаеп карап тора иде. Габделбәр түзмәде, сорап куйды:

— Нигә алай карап торасың, ышанмыйсыңмы?

— Анысына ышанам да! Тик миңа Разыя дип дәшүеңә исем китеп карап торам әле менә.

— Сиңа шулай дип әйттемме мин? Гафу ит! Ләкин... ләкин үзеңнең дә кайчандыр Маһир дип эндәшүеңне онытма!

Зөбәйдә яратып кына Габделбәргә төртеп алды.

— И синең гел шул булыр инде... Киттек әйдә, Илһам абый белән саубуллашыйк!

— Әйдә суң...

...Лифт тиз килеп җитте. Менә шахтаның яшелгә буялган тимер ишекләре шаулап ачылып китте. Илһамның көләч йөзе шәйләнде.

— Кемнәр дисәм, сеңелем белән киявебез икән ләбаса.

Исәнләшеп күрештеләр.

— Мине хәзер бальнистан чыгаралар,— диде Габделбәр.

— У-у... Исән-сау савыгып чыгуың белән тагын бер мәртәбә котлыйм,— диде Илһам.

* * *

Туйны, ике якның да килешүе буенча, шимбә көнгә билгеләделәр. Быел кыш иртә килде. Атналап-атналап буран котырды. Кар күп. Әнә тагын ябалак-ябалак кар ява.

Гасыйм абзый кырау төшкән чәчләрен артка сыпыра-сыпыра чукрак Нәгыймнең (кодасының) җыерчыксыз алсу шома йөзенә, килешле генә кара мыегына, түгәрәк кара сакалына, яшьлектәге төсен җуймаган карасу коңгырт күзенә төбәлеп сорады:

— Ат беләнме? Машина беләнме?

— Ничек?

— Ат беләнме? Машина беләнме дим?..

— Яшьләр үзләре ни ди соң?

Гасыйм-Зарифулла абзый мәгънәле генә итеп авызын колакларына таба ерып җибәрә.

— Ни дисеннәр, такси давай диләр!

Нәгыйм муенын кыса башлаган галстугын чак кына бушатып куйды. Иртәнчәк аңар хатыны: «Галстук тагып җибәр, зур кешеләр дә була икән анда»,— дигән иде.

— Бер таксига күпме түләргә кирәк инде?—дип, әллә кем булгандай, сорап куйды Нәгыйм.

— Йөз сум!

— Һай-һу! Һай-һу!

— Ник... синдә акча күп ич, кода! Юкка гына сыер орлыкландыручы булып эшлисеңмени? Йөз тәңкәңне нигә кызганасың? Сиңа малмыни ул!

— Ә?—Шулай сукыр Нәгыймнең зур колаклары салмаганда (үзе әйтмешли, әз генә төчкертмәгәндә, йөрәккә көч кертмәгәндә) ишетеп житкерми.

Гасыйм-Зарифулла абзый сүзләрен кабатлап әйтте.

— Һе...—дип хәйләкәр генә көлемсерәде Нәгыйм.— Бездә акча юк түгел анысы... Тавык та чүпләп бетермәле түгел. Хәлбуки, бусы — үзенең укымышлылыгын күрсәтергә теләп әйтүе инде, төптәнрәк уйлап караган-

да, кода, ул такси йөртүче йөз тәңкәгә генә разый булырмы икән? Хезмәте өчен натуралата, ягъни тана боты сорамасмы икән ул, ә?!

— Әйе, әйе, сорарга мужыт,— диде Гасыйм-Зарифулла абзый кинәт житдиләнеп.— Акчаның дәрәжәсе төшкән безнең бу заманда барысы да булырга мужыт.

— Алайса атлар белән, иеме! — диде чукрак Нәгыйм галстугын рәтләштергән булып.

— Ярый, синенчә булсын, кода! — диде Гасыйм-Зарифулла абзый.

Иртәгесен инде дугага сөлгеләр аскан, кыңгыраулар таккан ярсу атлар капка буена килеп туктаганнар иде.

Иртүк торып, абзар-кураны, ишегалдын һәм капка тирәләрен җыештырып маташкан Зарифулла абзый ат тоткан егетләрне өйгә әйдәде. Өйдә, пар өстәлгән мунча кебек гаять бөркү иде. Тәм-том, аш-су исе иде.

Егетләр, бокалларга салып китерелгән татлы, әмма соңыннан кирәгенне бирә торган эчемлекне йотып кына куйдылар. Күптән түгел генә хастаханәдән кайткан һәм кайтуга ук өйләнеп ташлаган Харис:

— Куллар рульдә, эчәргә ярамый, нельзя,— диде.— Шул мәлне ак өй ишеге ачылып китте. Аннан озын ак күлмәк кигән Зөбәйдә, ак күлмәк, кара костюм кигән, кара галстук таккан Габделбәр һәм башка яшьләр чыга. Аларның йөзләре кояш кебек. Аларга багып, син эчтән генә көнләшүгә охшаш бер хис кичереп куясың:

— Менә, ичмасам, болар бәхетле,— дисең.

Яшьләр, иртәнге якта дөньяга җанлы сулыш өреп сайраучы кошлар сыман чарык-чорык килеп өйдән чыгып та киттеләр.

Ат йөртүчеләр дә кузгалды.

— Нишләп ашамыйсыз инде, егетләр?

— Булды, апа, рәхмәт! — диде Сәлим.

— Тагын бер-икене тотыгыз инде, хет!

— Булды инде бу, абый,— диде Кәрим.— Әле без эш күрсәтмәгән, кодаларны, кодагыйларны алып килеп куймаган...

— Ярый алайса, егетләр, үзегезгә карагыз! — диде Гасыйм абзый, тәрәзә аша, капкага таба якынлашучы мулланы күреп алып.

— Киләләр, киләләр...— Шатлыклы чәңгелдәп эт өрә башлады, аяк астында балалар буталышты, кемнәрдер өйдән бирегә йөгереп чыкты, кемнәрдер чатыр чабып өйгә кереп китте.

Качырып кына, аз-мазлап кына кәккәләп йөргән мутрак кодаларның шаркылдап көлгән авазлары, кодачаларның шаян тавышлары белән аралашып кызык тамаша тудырдылар.

— Сез кем?

— О! Извиняюсь, мадам. Я с другой планеты.

— Һе, нинди кызыксыз кеше.

— Йосыф абый ич ул!

— Шулаймыни-и...

— Әнә тегесе Муса абый!

— И танымый да торам икән... Кайда яшиләр соң алар хәзер? Кайда эшлиләр?

— Галәмчеләр каласында яшиләр, галәмне өйрәнү лабораториясендә эшлиләр!

— Ууу! Шулай укмыни... Исәнмесез, Муса абый! Исәнмесез, Йосыф абый!..

— Ә теге тазасы кем?

— Анысы Илһам абый.

— Ул кайда яши? Кайда эшли?

— Казанда яши, РКБда лифтчы булып эшли.

— Һи... Ярар инде аның белән күрешмәсәм дә...

— Художник ул!

— Шулаймыни! Алайса, барыйм әле янына, күрешим аның белән дә...

— Исәнмесез, Илһам абый, сау-сәламәт кенә яшәп ятасызмы?!
— Карале, әнә теге биеге, баганадай төз гәүдәлесе кем була?
— Анысы Фоат абый, милиция капитаны.
— Әһә! Уһу! Тс-фс! Барыйм әле мин аның янына, барыйм...
— Исәнмесез, товарищ капитан!..
Укучы сизәдер инде: Гаделша иде бу!

...Авылның төрле ягында, төрле урамнарда чыңлаган кыңгыраулар тавышы урта урамда бергә кушылды һәм озак та үтмәде, Габделбәрләргә таба бер-бер артлы тезелеп чабып килгән юртак атлар күренде.

Атлар килеп җитеп, бер-берсенен янәшәсенә дә басарга өлгермәделәр, түземсен җуйган халык, умарта күчедәй гөжләп, чаналарны сарып алды. Төп кодага, кәләшнең абзасына әз-мәз капкалап йөргән мут кодалардан да мутрак кода туры килде. Буе-сыны сөбханалла булса да, тавышы нәзек икән үзенең.

— Туктап тор инде, кода бабай, чанадан төшкәнче элек менә бу зәмзәм суыннан авыз итеп ал,— диде ул.

— Хәзер, зәмзәм суымыни ул?! — дип, тавышын бөереннән чыгарып сораган булды Нәгыйм.

— Юк ла инде, болай гына әйтәм... Фасонга китерергә кирәк ич.

— Кая-а бир инде, алайса!

— Чү, карт! Нишлисен? Тилерденме әллә? — дип, ниһаять, телгә килде чукрак Нәгыймнең янәшәсендә утырган шүре тикле генә бәләкәй хатын.

— Иренне тидердем... Чынлап та зәмзәм суы икән бу, амакай!

Мут кода нәзек тавыш белән хихылдап көлеп җибәрде.

— Син гел фасонга китерә беләсең, ә, кода бабай?!

Сукыр Нәгыйм (аның бер күзенә ак төшкән) авызы белән мут коданың колагына керердәй булып, якын килеп:

— Ә кәк же! — диде.

Чанадан иң соңгы булып төшкән Зәлия ханым, үзләрен күнелле генә каршы алган кибетче Хисаметдингә (элекке иренә, кызының атасына) бөтен эче-тышы белән балкып елмайды һәм, түгәрәк алсу йөзендә шул елмаюын саклаган килеш, керүгә таба юнәлде.

...Гасыйм-Зарифулла абзый мулла никах укый башлагач та, мулла укып бетереп китеп баргач та урыныннан кузгалмады. Ул инде баядан бирле веранда тәрәзәсе каршында утырып туктаусыз тәмәке пыскыта, туктаусыз уйлана иде. Моның сәбәбе болай иде. Баярак кына Гасыйм абзыйның бик яман биле кузгалып, үтереп, җанның бәгырьнең әллә кай тешләренә үтәрлек итеп, әрнеп сызлый башлады. Аңа күптән түгел генә врачлар хастаханәгә кереп дәваланырга киңәш иткәннәр иде. Ләкин Зарифулла абзый риза булмады ул чакта. «Малаемның туен үткәреп җибәрим инде, аннары күз күрер»,— диде. Менә хәзер күрә инде күрмәгәнен...

Кемнәр генә кермәде дә, кемнәр генә чыкмады өйдән... Нинди генә сөйләшүләр, эндәшүләр, пышылдаулар һәм ялварулар булмады. Монда тагын Салисәне дә эт итеп сүктеләр, Фоатны да яманлап ташладылар, Муса белән Йосыфны да мәми авызлыкта гаепләделәр, Илһамны да чүп итеп себерделәр, Хисаметдинне дә, күсе итеп, арт ягына типкәләделәр, ни өчендер Фердинандка гына кагылмадылар...

— Йә, нигә җыйган инде ул йөз сиксән мең тәңкәлек алтын-көмешне, берәүгә дә эләкмәсен дип, күмеп калдырырлык булгач... Балаларына тигезләп бүлмәгәч, йә, нинди ата инде ул?

— Ул алтын-көмешнең кая яшерелгәнлеген Сания әби беләдер инде, белмичә булмас.

— Белә кәнишне... белмәс! Ул алтын-көмешне кызына — Салисәгә биргән, вәт шул!

Шул вакыт ишектә Салисәнең җикеренеп кычкырган авазы ишетелә:

— Биргән ат кәлҗемәсен... Ул хәзинәне әни Фердинандка биреп җибәргән булган, белмәсәгез белегез!..Ләкин Гасыйм-Зарифулла абзый боларның берсенә дә игътибар итмәде. Аның һаман шулай веранда тәрәзәсе аша кышкы дөньяга карап торасы, туктаусыз тәмәке пыскытасы һәм уйланасы килде. Юк, аның үткән заманнарны искә төшереп, йөрәгендәге яраларга кагыласы килмәде. Аның хәзерге халәтенә бәя биреп, гәрчә чәчләрен кырау сукса да, үзенең биленнән кала һәммә әгъзалары таза һәм сәламәт булуына сөенеп, тормышның ямьлелеге, яшәүнең матурлыгы турында уйлыйсы да уйлыйсы килде. Аның бүген, тик менә бүген уйлыйсы килде бу уйларны. Чөнки аның өендә бүген бәйрәм, туй. Аның малае, зур өметләр баглап үстергән улының туе, бәйрәме бүген!

Шул вакыт Зарифулла абзый «Әче! Әче!» — дигән тавышка сискәнеп, урыныннан кузгалды.

...Туй иң югары ноктасына җиткәндә генә кинәт өй ишеге ачылып китте дә аннан бер көлтә салкын ияртеп, уен ясап әллә кемнәр килеп керде.

Китте бию, купты шау-шу, башланды тамаша!

Уен ясап керүчеләрнең берсе, бабай булып киенгәне, куллары белән ишарәләп, Зөбәйдәне дә биергә чакырды. Зөбәйдә күңелле генә елмайды һәм урыныннан купты, биючеләр янына чыкты.

«Бабай» чын егетләрчә, ашкынып-кабаланып Зөбәйдә каршында бөтерелә дә башлады. Шул мизгел Зөбәйдәгә әллә ни булды — аның ап-ак туй күлмәге күкрәге турысыннан шәмәхә төскә кермәсенме!

Габделбәр аңлады: Зөбәйдәнең өстенә язу карасы сиптеләр. Ләкин кем?.. Әнә теге, бабай булып киенгән — тиз генә ишеккә таба китеп баручы адәм актыгы түгелме?!

Габделбәр ул кешене тотарга, фаш итәргә теләп, ишеккә ташланды. Салкын урамга чыктылар. Тыкрыктагы кар тавына менеп киттеләр. Төштеләр. Тагын менеп киттеләр. Ай-һай, житез нәрсә булып чыкты бу...Габделбәр тирләде, пеште, шулай да үзенекен итте, әлеге тупас кешене эләктереп алды.

— Кит... Күралмыйм мин сине, күралмыйм...— дип илереп кычкырды Разыя һәм, каты кар өстенә авып, ямьсез тавыш чыгарып еларга керешге.

...Туй икенче көнне дә шау-шулы дәвам итте. Мәҗлес халкы тыштан караганда гади, эчкерсез, саф күңелле иде шикелле. Салисә белән аның ир туганнары арасындагы эчке каршылыкны санамаганда, әлбәттә... Монда халыкның күпчелеге шапырынып, борын күтәреп яки төнтекләнеп, чырай сытып, һәрнәрсәдән гаеп табып утыручыларны өнәми.

Авылда кызык икән: егетләр-кызлар кара-каршы әйтеп җыру җырлыйлар. Җырны иң элек егетләр башлый, аннары кызлар кушыла... Шулай мәҗлес күңелле үтте. Яшьләр таң атканда гына таралыштылар... Казаннар да, юл кешесенең юлда булуы хәерле дип, китәргә кузгалдылар. Габделбәр белән Зөбәйдә аларны озатырга чыкты. Урамнар караңгы иде әле... Бераздан көнчыгыш тарафта офык аллана башлады. Ул торган саен киңәя, биегәя һәм сыекланып-яктырып бөтен күк йөзенә тарала бара иде.

Ниһаять, түбәннән күтәрелеп, зур булып, кызарып, яңа тормыш коручыларның «беренче Кояшы» Көмеш Елга өстенә котлау сәламнәре җибәрде.

— Хәерле сәгатьтә...— диде Габделбәр, кунакларга кул болгап.

— Хәерле сәгатьтә...— дип кабатлады Зөбәйдә.

Автобус китте. Ул үзе белән Сания әбинең биш баласын да алып китте. Һәм менә автобус туктап торган урынга, сулышы кабып, хат ташучы тәбәнәк юан Миңсылу килеп басты.

— Сания апа вафат! Әле генә район хастаханәсеннән хәбәр иттеләр...

* * *

Шушы урында бу әсәрне тәмам итәргә дә булыр иде. Ләкин, берничә ел үткәч, бакыр сейфның кинәт табылу вакыйгасы каһарманнарның язмышларын ачыклап китәргә мәҗбүр итте.

Менә Габделбәр белән Зөбәйдә. Аларның инде ике яшьлек кызы үсеп килә. Зөбәйдә Көмеш Елгада яңа ачылган зур, таш шифаханәдә эшли башлады. Ә Габделбәр — автопаркта механик. Маһир — төрмәдә, хатлар яза. Зөбәйдәгә дә бер хаты килде әле: «Оныта алмыйм!» — дигән.

Разыя бер әрмән егетенә кияүгә чыгып, Ереванга китеп барды. Чукрак Нәгыйм вафат инде, эчә иде бит! Гыйльметдин абзый да гүр иясе... Мәйсәрә түти килене — Салисә янына китеп яши башлады. Марат та читтә йөрүен ташлап, Казанга кайтып урнашты. Аларның хәзер ике яшьлек кызлары бар.

Зәлия ханымны Көмеш Елгада мәктәп директоры итеп билгеләделәр. Хисаметдин кибетне ташлады. Ул хәзер — фермер!

Гасыйм-Зарифулла абзый вафат. Фирдания түти оныгы — Миләүшә белән мәшгуль әлегә. Гамбәрия исә университетның физмат факультетында белем ала.

Инде чират бакыр сейфка килеп җитте бугай. Чынлап та булганмы соң ул сейф? Бармы?.. Әйе, булган ул сейф! Бар! Моның шулай икәнлеген Салисәгә килгән хат исбатлый ала.

Ял көне иде. Салисә кер юарга хәзерләнеп йөри иде. Ишектә кыңгырау чылтырый башлады. Җиз кыңгырау! Аны ишеккә Марат беркетеп куйган иде. Марат үзе әнисен — Мәйсәрә түтине машинасына утыртып, Әми тавында агач йортта яшәүче өшкерүче карчыкка күрсәтергә алып киткән иде.

Салисә барып ишекне ачты. Милиционер? Хатын әллә нишләп китте.

— Не бойтесь! — диде, погонында өч сызык булган милиционер. — Я из отдела охраны... Вот вам извещение... Завтра к девяти... — Һәм сержант честь бирде дә, борылып китеп барды.

Салисә катты да калды, ни уйларга да белмәде. Чөнки чакыру кәгазенә дә нәкъ сержант әйткән сүзләр генә теркәлгән иде, бүтән артык сүз юк иде. Шулай да ни өчен чакырдылар икән? Нигә кирәгем булды икән минем аларга? — Әллә теге Фердинанд алып киткән сейфны табып алганнармы? Алай дисәң, бу очракта сейф җинаять эзләү бүлегендә булырга тиеш бит, мөлкәт саклау бүлегендә түгел... Әллә, әни биреп калдырган саклык кенәгәсенең эзенә төшкәннәрме? Шул кенәгәдәге акчаны туганнарым арасында тигезләп бүләргә кушмакчылармы?.. Юк-юк, бу эштән бөтенләй бүтән нәрсә исе килә шикелле.

Салисә гаҗиз булып, бернинди дә төпле карарга килә алмыйча, икенче көнне милициянең мөлкәт саклау бүлегенә китте. Чакыру кәгазен кизү милиционерга бирде. Кизү милиционер, үз чиратында, хатынны начальник бүлмәсенә кертеп җибәрде.

— Исәнмесез!

— Исенмесез... әйдә, үтегез, утырыгыз! Ни йомыш? Тыңлыйм!

Салисә катты да калды: аның каршында майор — Фоат энесе утыра.

— Мин... менә...— дип телгә килде, ниһаять, Салисә. — Шушы кәгазь буенча инде...

— Кая... бир! — дип, майор кулын сузды һәм кәгазьне алып аңа карап та тормыйча алдына куйды. — Сине беләсеңме нигә чакырдык?..

— Нигә чакырдыгыз соң, энем? Әйт!

— Ну, ну! — диде Фоат йөзен чытып. — Мин монда җаваплы эштә эшлим... Бернинди дә энем-фәләннәргә урын булмасын, эш турында гына сөйләшик!

— Йә, сөйләшик соң алайса! — диде Салисә. — Ник чакырдыгыз?

— Шуның өчен... — Майор урыныннан купты. Шкаф тартмасыннан ниндидер кәгазьләр алды һәм янә урынына утырды. — Менә монда Фәлә-

хетдин Шәймуллинның мирас кәгазе саклана. Моның бер данәсе дәүләт архивындадыр инде хәзер...

Салисә урыныннан сикереп үк торды.

— Нинди мирас?! Син нәрсә сөйлисең, энем?!

— Иптәш Низаметдинова,— диде майор апасын ирә фамилиясе белән атап,— кисәтеп әйтәм, мин монда җаваплы урында эшлим!..

— Ярый... бетте... эш турында гына сөйләшик...

Майор кулындагы кәгазьләрне селкеп:

— Дикъкать белән укып чыгыгыз, иптәш Низаметдинова! — диде.— Шулай, без әйткәнчә, мәрхүм Фәләхетдин Фәйзуллин мирас итеп калдырган бакыр сейф саклана бирәдә!

Салисә янә сикереп торды һәм еламсыраган нәзек тавыш белән кычкырып җибәрде.

— Газаплама инде, энем: кайда ул бакыр сейф? Күрсәт! Аны әти кемгә мирас итеп калдырган?

— Иптәш Низаметдинова... соңгы мәртәбә кисәтеп әйтәм, мин сиңа, мин...

Салисә үксеп елап җибәрде.

— Их, энем, тәмам бюрократлашып беткәнсең икән... Шулай итеп бер дә кешелегең калмадымыни соң, һә-һә-һә?!

Майор Шәймуллин чак кына уйланып торды да, күнеле йомшарып, ахры, апасына кәгазьне бирде.

— Укы! — диде. Һәм үзе кулларын биленә куйган килеш кабинет буйлап кыләп-сара йөренергә тотынды.

Салисә кульяулыгы белән күзендәге яшьне сыпырып алды, борынын сөртеп куйды. Һәм аннары, ихтыяр көчен туплап, мирас кәгазен укырга кереште.

*«Мин Фәләхетдин Фәйзуллин (шулай ук Шәймуллин) Сәләх улы Бөек Ватан сугышы ветераны һәм Бөек Ватан сугышының икенче гр. инвалиды, һәм дә килеп, хезмәт ветераны — түбәндәгеләрне белдерәм:*

*1. Хәзер халык арасында малга табыну, байлыкка кызыгу шше яман чир барлыкка килде. Мал, байлык дигәндә ана — улны, ата — кызны белми башлады. Бу хәл мине дә бик борчый, газаплый, әлбәттә. Чөнки мин кырык ел колхозда амбарчы булып эшләдем һәм минем җиде балам бар. Мин үлгәндә аларга мирас итеп нәрсәдер калдырырга тиеш ич инде!*

*2. Менә минем бакыр сейфым бар. Моның эчендәге байлык бәһаләп бетермәле түгел. Мин балаларыма мирас итеп шуларны калдырырга булдым.*

*3. Бүгенге көндә минем хәлем мөшкел, гомерем кыл очында гына тора диярлек... Шуңа күрә мин милициянең каравыл бүлеге белән биш елга килешү төзеп куярга карар иттем.*

*Килешү нигезендә:*

*а) Бакыр сейфны саклаган өчен биш елга алдан акча түләп куячакмын;*

*б) Бакыр сейфның эчендәге серне алдан мирас ияләренә хәбәр итмәскә;*

*в) Саклану вакыты бетәргә ике көн кала мирас ияләренең берсенә хәбәр итәргә. Килешүдә аларның барысының да тору урыны күрсәтелгән булыр;*

*г) Шушы шартлар үтәлгәч, бакыр сейфны алып китәргә тиешле балаларымның (әйтик, кызымның) кулына әманәт хатын тапшырыгыз һәм ул аны бирәдә ачып укысын да, аннары аңа сейфны биреп җибәрегез!*

*Барчагызга да саулык-сәламәтлек теләп калам. Амин!*

*Фәләхетдин Фәйзуллин (Шәймуллин) Сәләх улы.*

*198... ел, 27 октябрь.»*

Хәзер 199... ел, 26 октябрь»,— дип уйлады Салисә һәм энесенә карады.

— Менә... бусы хат...— диде Фоат.— Ач та укы...

Салисә конвертны алды һәм ачып, эченнән урталай бөкләнгән кәгазь чыгарды. Укый башлады.

*«Сез җәмгысе җиде туган... Минем әманәтем шул: сейф пломбаланган һәм син аны ялгызың гына ачарга тиеш түгел. Калган алты туганыңа кичекмәстән хәбәр ит — кайтсыннар авылга. Сейфны, бергә җыелып, минем каберем янында ачсагыз, яхшырак булмасмы?! Үйла һәм үз сүзеңне төгәл әйтеп, милициянең каравыл бүлегендәге тиешле кәгазьгә кулыңны куй.*

*Атагыз: Ф. Ф. С.»*

— Булдымы, укыдыңмы?! — диде майор.
— Укыдым!
— Инде менә бу «тиешле» кәгазьләргә кулыңны куй, апа!
«Апа-а?!» — Салисә энесенә гаҗәпләнеп карап куйды.
— Әйе, әйе, апа... кулыңны куй!
Салисә әллә каушаудан, әллә энесенә ышанганга күрә, кәгазьләрдәге язуларны укып та тормыйча кулын куеп җибәрде.
— Инде нишләргә миңа? — дип сорады ул аннары.
— Сейфны алып китәсең инде... ул хәзер синеке!
Салисәнең кинәт йөзе караңгыланып, кашлары җыерылды һәм ул ачуланып кычкырып әйтте:
— Туктале, энем... син нигә миңа бәйләнәсең әле, нигә минем башымны юк белән катырасың... Нигә соң алайса сейфны бүтәннәргә бирмәдең яки үзең алмадың, ә?!
Фоат, кресло аркасына ята төшеп, тыныч кына итеп әйтте:
— Шуның өчен, апа, чөнки синдә әниеңнең акча кенәгәсе саклана...
Салисә, энесенең шул сүзеннән соң, көтмәгәндә генә шиңгән куык кебек булды да куйды.
— Ярый алайса, — диде ул авыр сулап. — Әтинең әманәтен үтәрмен мин... үтәрмен! — һәм ул, башын түбән иеп, ишеккә таба борылды.
— Ә сейф?
— Сейф калып торсын әле, энем... Башта Муса белән Йосыфка телеграмм сугыйм, ә Илһамга открытка җибәрим һәм алардан төгәл җавап алыйм... Аннары!
— Сейфны мин авылга үзем алып кайтырмын, — диде Фоат.
— Әһе...
Шулай килештеләр.

* * *

2 ноябрь.
14.00. Көмеш Елга авылы зираты. Зират буена кешеләр җыелган. Эчтә, Фәләхетдин абзый кабере янәшәсендә — алты кеше — Фәләхетдин абзыйның балалары. Аларның алларында җирдә бакыр сейф кукыраеп тора. Бу сейфның эче алтын-көмеш белән шыплап тулган, ди бугай. «Балалар» үзара шул кыйммәтле мирасны бүлешергә тиешләр икән.
Зиратка, тау башындагы мәчет тарафыннан, көндезге азан тавышы ишетелә. Азанны Вафатдин абзый әйтә, ахры. Мәкаме, ай-һай, моңлы икән үзенең!
Зират каршында зәңгәр билле милиция машинасы һәм куе яшел хәрби машина һәм шул тирәдә кораллы өч солдат белән бер офицер, милиционер басып тора.
Зират эченнән килеп чыккан Гаделша иң элек солдатлар белән авылча ике куллап күреште, аннары төксе чырайлы офицерга честь биреп:
— Здрасьте, тауарищ капитан! — диде.

Капитан исә һич көтмәгәндә мөселманчалатып:

— Әссәламәгәлейкем! — дип җавап кайтарды. Шунда җыелган кешеләрнең һәммәсенә дә бик күңелле булып китте.

Төн җир өстен юка кар каплаган иде. Көн салкынча иде. Күк йөзендә авыр кара болытлар йөзә. Тирә-юньдә каберләр... каберләр... Күзләр ирексездән-ирексез: Юрий Вәлиуллин Заһит улы; Дмитрий Хәликов Габделхәй улы, дигән язулы ташларга төшә иде.

Фәләхетдин абзый кабере тирәли чүгеп утырышкан кешеләр, дога кылып бетергәннән соң, урыннарыннан торып, сейф янына җыелдылар. Илһам туганнарының әле берсенә, әле икенчесенә төбәлеп:

— Йә, бу тимер сандыкны кайсыгыз ача?! — дип сорады.

— Әнә... Хисаметдин абый ачсын... Ул арабызда иң олысы, — диде Салисә.

Йосыф апасына каршы төште:

— Юк! Юк! Әнә, Фоат абый ачсын... Ул арабызда иң дәрәҗәле кеше.

— Мин сабыр итәм әле, туганнар, — дип, Фоат баш тартты. Сейфны Муса ачарга тиеш. Ул — галим кеше!

Биш кешенең карашы Мусага төбәлде. Галим «ә» димәде, «җә» димәде, сейфка якынрак килде дә, чүгә төшеп, пломбаны тартып өзде һәм ачкычны йозак тишегенә кертеп борды. Сейф ишеге ачылып китте. Һәммәсе дә бергә укмашып, кызыксынып, сейф эченә төбәлделәр.

Муса Шәймуллин сейф эченнән кызыл бәрхеткә төрелгән ниндидер әйбер тартып чыгарды һәм аны югары күтәреп тотты. Фоат Шәймуллин исә шундук бәрхетне чишеп җибәрде. Зират эчендәгеләр дә, зират тышындагылар да — һәммәсе дә «аһ» иттеләр. Зират эче кояш чыккан сыман яктырып киткәндәй булды. Яшь галимнең кулында яртысы көмеш, яртысы алтын ярым ай иде!

Хисаметдин белән Салисәнең күзләре ут булып янарга кереште. Чынлап та бу «мирас» йөз сиксән мең тәңкәлек тора булыр. Менә алар хәзер бу хәзинәне алты өлешкә тигезләп бүләрләр дә...

Шул мәлне янәшәдәге кабер эченнән гүя әниләренең тавышы ишетелде:

— Балаларым, бәгырьләрем, тыңлагыз... Бу ярым ай түбән оч мәхәлләсе мәчетенеке... 1940 елның җәй азагында ул мәчетнең манарасын явыз бәндәләр җиргә кадалтып төшергәч, бу ай читкә очып китә. Һәм аны шунда сезнең булачак әтиегез Фәләхетдин эләктереп, өенә йөгерә. Алып кайта да яшереп куя. Ул аны мәрхүм, гомере буе күз карасыдай яшереп саклады. Ә инде 1979 елны кемнеңдер ялган шикаяте буенча өйгә тентү керәсен белеп алгач, әтиегез түбән оч мәхәлләсе мәчетенең газиз ярым ае салынган бакыр сейфны бәдрәф янына күмде. Һәм шулай аны котырган адәмнәр кулына кабат төшүдән саклап калды...

Балаларым, кадерлеләрем минем, тыңлагыз... Түбән оч мәхәлләсе мәчетенең ае «юк ителгән» көннән башлап, авылыбыз кешеләре яртылаш иманнарын җуйдылар инде. Кызганыч, әмма нишләмәк кирәк, алар төркеменә сез дә керәсез, балакайларым. Сез дә...

Инде мине тыңлагыз — бирелеп, дикъкать белән тыңлагыз, күз нурларым! Әле генә бакыр сейфны ачып алган яртысы көмеш, яртысы алтын ярым айны кайтарыгыз кире түбән оч мәхәлләсе мәчетенә! Аннары Салисә кызымда минем саклык кассасындагы акчаларымның кенәгәсе бар. Ул акчалар балаларым хәзер сезнеке — һәммәгезнеке! Һәм сез ул акчаларга, бәгырькәйләрем, түбән оч мәхәлләсе мәчетенә куяр өчен әйбәт манара эшләтегез... Һәм аннары, ярдәмчесез калган ялгыз карткарчыкларга, ятимнәр вә ятимәләргә хәлегездән килгәнчә булышыгыз... Шул эшләрне җиренә җиткереп үтәгәч, балакайларым, мин сезне... кичерермен һәм, Хак-тәгаләдән гонаһларыгызны ярлыкауны үтенеп сорармын. Амин...»

* * *

Мәскәү-Казан поезды йөрешен әкренәйтә-әкренәйтә Көнбатыш платформага җитеп туктады. Яшел вагон ишекләре бердәм рәвештә ачылып китте дә алардан сумкадыр, капчыктыр, чемодандыр, биштәрдер ише нәрсәләр күтәргән һәм төрлесе-төрлечә киенгән олыдыр йә яшьтер, озындыр йә кыскадыр, юандыр йә нәзектер кешеләр төшә башлады. Уртадагы вагоннан иң соңгысы булып, озын буйлы ир-ат чыкты. Өстендә спортчылар кия торган ак сызыклы зәңгәр костом, аякларында «Адидас» кроссовкалары, кулында кара дипломат.

Ул, перронда йөренеп торган милиция полковнигын күреп, туктады. Кесәсеннән сигарет алып кабызды. Сәгатенә карап куйды. Аннары янә полковник ягына таба карады. Шул мизгел полковник та аның ягына борылды. Озын буйлы кеше кинәт:

— О-о... Исәнмесез, Фоат абый! — дип кычкырып җибәрде.

Үз исемен ишеткәч полковник та елмайды һәм озын буйлы кешене танып алып, авызын колакларына таба ерып җибәреп, аңар каршы ашыга-ашыга килә башлады.

— Чү? Кем бу? Маһир димме... Әйе шул, Маһир кода!

Алар кул сузып күрештеләр һәм, якын итеп, бер-берсенең җилкәсенә шап-шоп суккаладылар.

Фоат үзгәргән, юанайган һәм аның җилкәсе ындыр табагы шикелле киң, итләч иде.

— Менә мин дә иреккә чыктым,— дип куйды Маһир, ниһаять. Туган якка кайтып килешем...— Әйбәт, бик әйбәт! — диде Фоат. Аннары: — Ә мин малайны көтеп йөри идем,— дип өстәде.— Хәрби академиягә сынауларны тапшырып бетереп кайтырга тиеш иде. Нишләптер күренми әле.

— Бәлкем, бүтән поезд белән кайтырга уйлагандыр...

— Кем белә инде...

Маһир, кода абыйсы белән саубуллашып, китеп барды. Бераздан аның күңелен үкенү тойгысы биләп алды. Нигәме? Фоат абыйсы белән озаклап сөйләшеп тормаганы өчен. Тегә-бу турыда кызыксынып сораштырырга мөмкинлек бар иде бит. «И ярар инде, дип куйды ул үз-үзенә ачуы килеп.— Эш үткәч, үкенүдән файда юк»,— диләрме әле.

Маһир вокзал каршында бер таксины туктатып, шоферга:

— Авылга илтеп ташлачы мине, брат, зинһар...— диде.

— Авылга... Еракмы соң ул авыл?

— Сиксән чакырым...

— Һм-м...— Шофер егет уйга калды.

— Йә, нәрсә... илтәсеңме?

— Юл хакын икеләтә түләсәң генә инде... Урыс әйтмешли: туда и обратно!

— Булды, килештек! — Маһир кабинага, шофер янәшәсенә кереп утырды. Кузгалдылар. Ак Волга шәп җилдерә. Яңа да шул. Көпчәкләре тигән җиргә тия тимәгән җиргә юк... Маһир як-ягына карана, күзәтә һәм уйлана: «Үзгәргән, бик нык үзгәргән бу кала... Хәзер һәр урында рәхәтләнеп авыз тутырып татарча сөйләшәләр, күп урында татар язулары!

Шофер егет, пассажирының уйларын сизгәндәй, радиоалгычны кабызып җибәрде. Эфирда Казан радиосы концерт бирә иде. Хатын-кыз диктор: «Хәзер сез ишетәчәк «Сагыну» җырын Татарстанның атказанган артисткасы Зәйтүнә Фәйзуллина башкара»,—диде.

«Уһу! — дип, исе китеп уйлады Маһир.— Ничек шул дәрәҗәгә ирешеп өлгергән әле ул Кече Көмеш Елга кызы?»

Һәм менә Зәйтүнәнең җырлый башлаганы ишетелде. Әйе, тавышы күпкә шомарган да, матурайган да икән...

Гөл-өл чә-чәк-лә-ре ө-өзәм мин,
Юл-ла-ары-на-а тез-зә-әм мин,
Бик с-са-гын-ды-ым, ир-ркәм,
Бик с-саг-ынд-дым, бәг-гыр-ем,
Әл-е-лә-н ни-че-ек түз-зәм ми-ин.

— Аһ! — дип куйды шофер егет төсе үзгәреп китеп. — Икенче-өченче юлдагы сүзләрне алыштырып җырлый бит артистка, хакы юк ич аның болай эшләргә, Муса Җәлил язган лабаса ул җырның текстын!..Маһир шофер егеткә җавап бирергә дә өлгермәде, уңъякта, агачлыклар турысында ике хулиган егетнең бер кызны каядыр сөйрәп маташуларын күреп алды һәм, такси йөртүчегә:

— Биредә туктат әле, туктат! — дип эндәште.

— Ни булды?

— Әнә... бер кызны кызыл Җигулига утыртып алып китмәкче булалар!

Шофер тормозга басты. Волга туктады. Маһир кызга ярдәмгә ташланды.

— Аааа!.. Коткарыгыззззз!.. — дип кычкырды кыз. — Котка...

Егетләрнең берсе кызның авызын томалады, икенчесе исә Маһирның йөгереп килгәнен күреп, кызны җан-фәрман машинага таба сөйрәүдән туктады, кесәсеннән финка чыгарды һәм ерткыч кебек тешләрен ыржайтып, Маһирның килеп җиткәнен көтә башлады.

Ни өчендер, үлем дигән куркыныч нәрсә шүрләтмәде Маһирны, ул бу турыда хәтта уйлап та карамады. Аның бөтен тойгысын, бөтен игътибарын ярдәмчесез калган кыз гына биләп алган иде, ул ничек кенә булса да бандитлар кулыннан шул кызны йолып калырга тиеш иде. Һәм ул әлеге зур эшне башкарып чыгачагына чын күңелдән ышана иде.

Маһир йөгерүеннән туктады, күзләрен кыса төшеп кояшка карап куйды. Һәм аннары тәвәккәләп пычакка каршы китте.

Гәрчә дошман, коралды булса да, куркак иде, ахры. Менә ул әкренәкрен генә артка чигә башлады... Маһир алдавыч бер хәрәкәт ясап алды да, шап итеп, дошманның кулына типте — финка әллә кая атылып китте! Маһир шундый ук кызулык белән икенче бандитның да биленә «куңдырды». Шуннан соң ул кызның кулыннан эләктереп, үзе утырып килгән машинага таба йөгерергә керешге.

Килеп җиттеләр. Арткы урындыкка кереп чүмәштеләр. Шофер ишекләрне япты. Машина җәһәт кенә урыныннан кузгалды.

— Рәхмәт сезгә! — диде кыз сулкылдавыннан туктап, Маһирның күзләренә төбәлеп карап.

— Шеф! Кая барабыз? — дип сорады шофер Маһирдан.

— Чынлап та! — дип куйды Маһир. — Кая барырбыз икән?

— Мин — культура институтына! — диде кыз. — Дәүләт имтиханы тапшырырга...

— Һи... без нәкъ шул тирәдән үтеп китәбез дә инде, — диде Маһир җитди генә.

* * *

Үзгәргән Маһир, олыгайган. Эшкә баручы, элекке «өч дошманы» юлына очрагач, күңеле тулды егетнең, ул аларны берәм-берәм кысып кочаклады, үпкәндәй итте, елап та алды. Ул хәтта үзенә өрүче этләргә дә, үз йомышлары белән каядыр ашыгучы мәчеләргә дә сәлам биреп үтте. Ә инде капка төбенә «арка кыздырырга» чыгып утырган картлар, карчыклар белән ул аеруча үз итеп, авылча ике куллап күрешеп узды.

Маһирның кайтуы сәгате-минуты белән диярлек авылга таралып өлгерде.

Берәүләр сагаеп тынып калды, икенчеләре исә: өйләнер инде, тормыш корып җибәрер, тик... кемне алыр икән, дип гөман кыла башлады.

Маһир кайтып кергәндә бабасы (йөз дә өч яшендә) үлем белән якалашып ята, телдән үк язган иде. Һәм ул төнлә үлде.

Икенче көнне аны җирләделәр.

Бер атна үткәч, Маһир Зәлияләргә юнәлде.

— Исәнмесез, апа!

— Чү, Маһир димме?!

— Шул инде, үзе...

Зәлия ханым ишек ачылып киткәч, каршысында басып торган чит озын ир кешене күреп аптырап калган иде, тегесе тамак кырып куйгач, таныды тагын.

— Әйдә, әйдә, үт,— дип, кырыйга авышып, егеткә юл бирде ханым.

Маһир, олы ботинкаларын бусаганың тышкы ягында салып калдырды да, кечерәк-кечерәк ике бүлмәле өй эченә керде.

Маһирның бу йортта соңгы мәртәбә булуына байтак еллар үткән иде инде. Шулай да өй эчендә берни дә үзгәрмәгән кебек, барысы да элеккечә... Бәлки үзгәрешләр бардыр, Маһир сиземләп кенә бетермидер... Әйе, бар икән шул: Зәлия ханым картаеп киткән, йөзендә җыерчыклар күбәйгән, кара тәрткеле батист яулыгыннан күренеп торган купшы чәчләре яртылаш ап-ак булган, йөреше-хәрәкәтләре кискенләшкән. Бу инде ялгызлык галәмәтеннән, нервлар киеренкелегеннән киләдер... Ханымның чем кара күзләре генә үзгәрешсез калган да, тавышы...

Маһир утыргач урындык шыгырдап куйды: ай, билем... дигән сыман. Урындык та тузган инде. Бу дөньяда мәңгелек нәрсә бармы икән ул! Әнә нинди юан матча да сыгылган, димәк, язмышка баш ия!

Өй эчен күзәтә торгач, Маһир тагын бер яңалык ачты: Зөбәйдәнең кыз чакта кигән киемнәре һәм кара дерматин тышлы футляр әле дә булса үз урыннарында эленеп тора... Гүя менә хәзер Зөбәйдә медпункттан кайтып керер дә эш киемнәрен салып, иң матур дигән күлмәкләренең берсен алып кияр һәм елык-елык кара чәчләрен туздырып, чем кара күзләрен елтыратып, сыгылмалы билләрен серле генә уйнатып көзге алдында бөтерелеп куяр да кара дерматин тышлы футлярдан алып, мондолинаның кылларын чиртә башлар.

> Һаваларда очкан кошлар кебек
> Ярсый-ярсый канат кагынып:
> Туган җирем! Кайттым мин зарыгып,
> Күз нурларым сезне сагынып!..

Маһирның чигәләре сулкылдады, сулуы ешайды һәм ул яшькелт күзләренә бәреп чыккан яшьләрен күрсәтмәс өчен карашын читкә таба юнәлтте. Юнәлтте һәм ул тарафта — кечерәк кенә пыяла шкаф эчендә торган фотоны күреп алды. Фотодан Зөбәйдә белән Габделбәр бербереенә таба башларын чак кына авыштырып, елмаеп карап торалар иде. Карашлары шулчаклы саф, самими иде ки, хәтта Габделбәрнең зәңгәр күзләренә тикле ап-ачык шәйләнә иде.

Маһирның яңак сөякләре бүлтәйде, тешләре ирексездән шыкырдап куйды. Бу — аларның туйдан соң төшкән фоторәсемнәре. Маһир ул чакта... еракта, бик еракта иде шул.

Егет маңгаен учлады. Сульякта... чәнчи... йөрәк!

Ә колакта эт өргән авазлар.

Күз алдында — автомат аскан сакчылар... Тимер рәшәткәле машинада эшкә барулар.

Һәр адымың, һәр хәрәкәтең исәптә.

Син читкә карыйсың да, мең төрле мәшәкать белән кайнап торган тормышны, иксез-чиксез яшеллек диңгезен, очсыз-кырыйсыз зәңгәр күкне күреп офтанасың.

Үләннәр арасында, яфракларда бөҗәкләр... Агачларда кошлар сайрый. Бөҗәкләр дә, кошлар да — һәммәсе дә иректә. Тик син генә... Син анда жаның-тәнең белән иреккә омтыла идең, ирекне сагына идең, хәтта ирекне генә дә түгел, барыннан да битәр, Туган жиреңне, Туган авылыңны сагынып төшләреңдә дә саташып бетә идең. Син моңарчы уйлап та карамаган, игътибар да итмәгән кешеләрне, урамнарны, тыкрыкларны сагынып ямансулый идең...

Ниһаять, син иректә!

Сиңа һәр жиргә дә юл ачык иде. Мәгәр син тик бер генә жирне — туган жиреңне генә сайладың, шуннан гайре мәртәт уйларны башыңа да китереп карамадың: әлек кайтыйм әле, аннары күз күрер тагын, дидең. Һәм син кайттың. Һәм менә син, ни өчен икәнен үзең дә юньләп белмичә, яшьлектә сөйгән кызыңның өендә, аның әнисе каршында моңаеп утырасың.

Моңаеп! Тфү, шайтан! Моңаеп йөрер өчен кайттымыни Маһир туган авылына?..

— Ни.. апа, менә бу нәрсәне алып куегыз әле.

Зәлия ханым самавыр кайнатырга куеп, өстәлгә тегесен-монысын утыртып, кунак-фәләнгә дип саклап тота торган озын муенлы шешәне күтәреп килә иде, Маһирның сузылган кулына карап чак кына уйланып алгач, кәгазь төргәкне әләктерде, рәхмәт әйтте, ләкин ачып карамады. Моның сәбәбе дә юк түгел иде: кем белсен, ахырга чаклы кунак үзен ничек тотар бит әле?!

• Ханымның тыйнаклыгы Маһирның күңеленә хуш килде. Төргәктә шәп яулык иде. Егетнең уенча, әгәр укытучы апа төргәкне ачып караса сокланырга тиеш һәм әкрен генә, башын чайкый-чайкый бүләкне иясенә кире кайтаруы да ихтимал иде. Шулай була калганда, Маһирның бирегә килүенең мәгънәсе югалачак иде. Бәхеткәдәр, бусы булмый калды, икенче мәгънәсезлекне дә булдырмаска мөмкин.

— Ни... апа, мин хәзер бу шайтан суы белән дус түгел бит, — диде Маһир озын муенлы шешәгә ишарәләп.

— Шулаймы! Һай, рәхмәт төшкере, кинәнепләр яшисең болай булгач... Ул: «Атаң мәрхүм генә эчүе аркасында вакытсыз гүргә керде шул»,— дип әйтмәкче иде. Тыелып калды.

— Мәйсәрәне әйтәм, бик бетерешкән, ябыккан... Беркөн автобустан төшкәч күреп исем китте — әлеп киптергән кебек булган мескен.

— Авылны ташлый алмый бит, шулай ук калага да кендеген беркетә алмый, һаман ике арада буталып йөри бирә, шул сәбәпледер инде тамагына да юньләп капмый. Әни дим, ни ашыйсың килә, ни жаның тели — барысын да табып алып кайтам... Ә ул моңсуланып башын гына селки: юк, ашыйсым килми, улым...— ди.

— Минемчә, хәсрәтләр бетерде аны. Күпне күрде, бик күпне кичерде бит... Әйдә, энем, якынгарак килеп утыр, самавыр кайнады, хәзер чәй ясыйм.

— Чәй? Менә монысын рәхәтләнеп эчәм инде мин. — Һәм Маһир артсыз урындыкка килеп утырды. Аякларын аска таба сузып жибәрде.

...Өченче чокырны каплап куйганда Маһирның маңгаена борчак-борчак тир бәреп чыкты. Һәм ул маңгаен, озынча борынын сөрткәләп торганда, яшькелт күзләрен тәрәзәдән алмады. Бер чите урамга, икенче чите елгага барып тоташкан һәм елганың бормалы-бормалы сөзәк, яшел яры буйлап куш тирәккә таба сузылган бакча Маһирның күңелендә, онытам дип тә онытылмаган һәм мәңге онытылмаячак яшьлек хатирәләрен кузгатты.

...Кич иде. Куш тирәк өстендә, югарыда яшь кызлардай елмаеп-балкып торган тулы түгәрәк айдан көмеш нурлар коела иде. Бу ак яктылыкта, елганың икенче ярында, биек тау башындагы мәчетнең ай урагы да ап-ачык шәйләнә иде.

Каршы якта, сихри күзгедәй, ап-ак булып ялтырап яткан су өстендә, биек-биек таллар, ферма каралтылары, яр читенә таен ияртеп килеп баскан тышаулы ат — һәммәсе дә баштүбән торгандай күренәләр иде, хәтта болытлар да.

— Китер, энем, чокырыңны, ясыйм...— Маһир сүзсез генә чокырын ханымга таба этте.

Әйе... кече, кече искиткеч иде ул чагында, мәгәр кызы... кызы тагын да шәбрәк иде, шайтан алгыры.

— Булды бу, энем, мә...Зөбәйдәнең өстендә,— Маһир ут карашын өй эчендә ялт кына уйнатып алды,— әнә теге күлмәк иде. Аякларында...— Син, энем, авылда торырга кайттыңмы әллә?..

— Әйе, апа, бөтенләйгә кайттым инде мин...

— Яхшы, энем, әйбәт!

Зәлия ханым да бакча ягына карап-карап ала. Юк, аның карашы бакчага түгел, арырак төбәлгән. Чынлап та ул тарафта яңалыклар байтак иде: елга аша киң таш күпер салып куйганнар, ферма да зурайтылган, яңадан-яңа биналар калкып чыккан, әллә кайдан балкып силос башнялары ялтырап күренә... тагын әллә нинди цехлар, киптерү-җилгәрү башнялары, үлән оны заводы...

Зәлия ханым канәгатьләнеп, елмаеп куйды:

— Комплекс диләр моны, сигез йөз баш сыерга исәпләнгән.

Кайберәүләр: бу — шәһәр сыман авылыбызга ямь биреп тора, диләр. Хикмәт аның кирәклегендә, минемчә. Югыйсә, кирәге булмаган нәрсәләр дә төзетеп, ни тамаша халык байлыгын җилгә очыралар кай вакытларда. Хәер, безнең бу председатель ул якка коры кеше, авыл халкы белән киңәш-табыш итмичә кыл да кыймылдатмый. Беләсеңме ул кешенең кем икәнлеген?!

Маһир кызарып чыкты һәм, беләм, дигәндәй, ым кагып куйды. Ә күңеленә: «Өрәк Сатирә малае... минем элекке дус!» — дигән уй килде.

— Менә шул председатель Габделбәр киявемне автопаркка инженер итеп куйдыртты инде. Баштарак, киявем теләмәгән иде. Ул агрономлыкка укыды бит. Сатирә Харисы: «Син әлегә монда кирәгрәк»,— дигән.

— Алай икән...

— Укыйлар шул хәзер авыл яшьләре, читән торып укуларын дәвам итәләр. Молодцы! Аннары теге кара кешеләр бар бит әле. Кавказлар! Шуларның берсе Разыяны алып китте, Бакуга.

— Ишеттем... Ике баласы бар ди инде Разыяның!

— Зөбәйдә кызымның да икәү!..

Аннары сүз түбән оч мәхәлләсе мәчетенең манарасына күчте. Ул мәчеттә имам хатип булып Мизхәт тора икән! Ә аның хатыны Земфира абыстай, ди, теләге булган кызларга дин сабагын да өйрәтә, ди.

Маһир кесәсеннән кульяулык чыгарып кулларын сөртте, аннары урыныннан кузгалырга итә башлады.

— Чәең-сыең өчен (әйе, шулай дип, берлек санда гына әйтте бу юлы) зур рәхмәт, Зәлия апа...

— Ярый, сихәте белән булсын, энем.

Маһир кара дерматин тышлы футляр ягына таба карап куйды:

— Килүем дә шуның өчен иде бит, Зөбәйдәне оныта алмыйм бит, гел төшләремә кереп йөдәтә бит, Зәлия апа...

— Кит, юләр булма, кызлар бетмәгән, өйлән, өйләнгәч онытыла барысы да.

— Үзем дә шулай дип караган идем дә, булмый икән шул... Иртә белән Зөбәйдәне очраткач...

— Ир хатыны бит инде ул, Маһир, ике баласы бар...

— Беләм, Зәлия апа... өч баласы булсын, дүрт... мин аңа кагылмыйм... мин сиңа үз хәлемне генә аңлатам. Аңлагансыңдыр инде... Ярый киттем мин.

Зәлия ханым нидер әйтергә теләп тә әйтә алмады, гаҗәпләнеп як-якка кулларын гына җәеп җибәрде. Һәм шул мәлне аз гына ачык калган ишектән бер шөпшә кереп, өзми-куймый выжылдарга кереште...

* * *

Зәңгәр тракторлар берсе арты берсе тезелеп тауга күтәрелә башладылар.

Тау гаҗәеп текә, биек иде. Астан караганда шулай әле ул. Өстә торып түбәнгә бөркеттәй үткен караш ташласаңмы? Каманың бөтен тирә-юнен очкычтан күргән сыман буласың!

Маһир муфта педаленә басты, мәгәр кузгалырга ашыкмады, тракторларның үзеннән ерагаюларын көтте. Тәмәке кабызды.

Зәңгәрсу-аксыл күктә кояш балкып тора. Елганың борылган төшендә ап-ак кыя, кыя өстендә, биектә мамык болытлар, ә кыя астында, түбәндә исәпсез-хисапсыз ак ташлар. Дүртенче көн инде Маһирлар бередән ак таш ташый: колхозга, яңа салыначак гаражның нигезенә...

Маһир тәмәкесен комсызланып суырды. Бушаган шырпы кабын ишектән ыргытып бәрде. Борынына төче су исе килеп кагылды. Дулкын шавы. Акчарлаклар... Офыкта — күмелеп барган теплоход торбасыннан чыккан төтен. Болытлар...

Сал агып бара.

Чуер ташлы, комлы су чите. Көпчәккә дулкыннар бәрелә: бар инде, кит, торма, дигән шикелле.

Маһир муфта педаленнән аягын әкрен-әкрен генә ала башлады, трактор көчәнеп куйды да туктады, тизлекне арттыра төшкәч, калтырана-калтырана тагын кузгалды. Ике көпчәкле арба да өч тонналы йөктән шиннарын сыгылдыра-сыгылдыра трактор артыннан юнәлде.

Алдан киткән ике трактор гаять биек тауны исән-аман гына менеп җитте. Яңа шул алар. Хәер, Кәримнең кабинасыз кызыл тракторы, ашын ашаган, яшен яшәгән булса да, үҗәт нәрсә, тешен-тырнагын батырып дигәндәй, үрмәләпме үрмәли. Тау өстендә торучылар Кәримне дәртләндерәләр, ура кычкыралар...

Маһир Чулман белән Идел тарафына карап куйды. Ике елганың кушылган урыны бит инде бу. Менә ничәмә ничә гасырлар буе Идел белән Чулман кочаклашкан көе шушы төштә ага да ага. Һәм шушы төбәктә Маһир туган: моның белән горурланмый түзеп буламы соң! Иеһ...

Әнә сул тарафта, тау белән су арасындагы бушлыкта уктай атылып карчыга очып бара.

Маһир тәмәкесен тагын бер суырды да, төпчеген атып бәрде. Кесәсеннән Зөбәйдәнең яшь чагындагы фотосурәтен алып, аңа озак кына карап торды һәм: «Мин дә читтән торып институтка укырга керәчәкмен, Зөбәйдә»,— дип уйлады. Аннары тракторын Габделбәр артыннан тауга таба алып менеп китте.

Габделбәрнең тракторы бөтен көченә үкерә, торбасыннан бөркелепбөркелеп кара төтен чыга. Тауның яртысын узып иң текә урынга җиткәч, тракторның гөелдәү ритмы бозылды, нәрсәләрдер шытырдый башлады һәм кинәт мотор шып сүнеп тә китте... Габделбәр тормоз рычагына-педаленә баса да, тотына да алмый калды...

Маһир алдагы тракторның арты белән җан-фәрман үзенә таба төшеп килүен күргәч, бермәл аптырап калды. Әмма шундук бер карарга килеп, тракторын юлга аркылы куйды һәм... чытырдатып күзләрен йомды. Күзләрен йомды һәм таш төягән арбаның үз тракторына чыкылдап килеп бәрелүен ишетте. Шуннан соң ул яшен тизлегендә, караңгы упкынга очкандай булды.

Төштәге кебек кенә итеп арбалар ауды, тракторлар ауды, як-якка ташлар чәчрәп очты. Габделбәр аңына килгәндә, Маһирны тракторы астыннан суырып алганнар, аның авыз-борыныннан, колакларыннан шаулап кан ага иде.

Тау өстендәгеләр бирегә төшеп беткәннәр, ә тау башына әле һаман халык җыела тора иде. Шомлы хәбәр бик тиз таралды:

— Кашан тавында тракторлар ауган...

— Таш төягән тракторлар икән.

— Кайсы авылныкылар?

— Көмеш Елганыкылар ди бугай...

Зөбәйдә дә, бу шомлы хәбәрне ишетеп, Тау Кичү мәктәбенә лекция укырга барган җиреннән, йөгерә-йөгерә килеп җиткән иде.

Габделбәр әле һаман аңышып җитә алмый: «Ни булды соң?! Нишләдек без,— ди ул үз-үзенә.— Бу тракторлар нигә аунап яталар, мин ник аксыйм, Маһир ник анда кан эчендә?» — ди... Сораулы карашы белән ялт кына Идел өстенә төбәлә, тау өстенә борылып карый һәм Зөбәйдәне күрә...

Зөбәйдәнең яшел косынкасы муенына шуып төшкән, кара бөдрә чәчләре тузган, зур кара күзләре тагын да зураеп киткән.

— Габделбәр! Син исән, бәгырем? — ди ул үрсәләнеп.

Шул мизгел:

— Маһир үлә... Маһир абый үлә...— дип кычкырдылар.

Габделбәрнең йөзе ап-ак булды. Зөбәйдә Маһирга ташланды. Хатыны артыннан — Габделбәр...Маһир, гаҗәпләнгәндәй итеп, күзләрен ачты. Балкып торган кояшны күрде. Күзләре яшь белән мөлдерәмә иде.

— Зөбәйдә! — диде ул. Авызыннан гөрләп кан чыкты.

Зөбәйдә Маһир алдына тезләнде.

Габделбәр кырыйга борылды, гүя болытлар, тау-ташлар актарылды.

— Зөбәйдә! Үләм...— диде Маһир.

— Үлмә, үлмә, Маһир...

Маһир, сулкылдаган кебек, өзек-өзек итеп сулыш алды. Аннары йөзен Чулманга таба борып, тын гына күзләрен йомды.

Шулчак ябык гәүдәле бер апа ачыргаланып кычкырып җибәрде:

— Улым... улым... Шулай үләр өчен кайттыңмыни син монда?!

Апаны, хәлсезләнеп егыла башлаган җиреннән, агара башлаган мыеклы бер ир тотып калды.

— Зөбәйдә?! — Габделбәр хатыны янына чүкте. Яңа гына йокыга талган кебек булып ятучы Маһирга төбәлеп, нидер әйтергә теләде, тавышы чыкмады.

Зөбәйдә әйтте:

— Гафу ит мине... Маһир...— диде.

Бу сүзләрне гүя болытлар да кабатлый, таулар да пышылдый, акчарлаклар да үзләренчә кабатлый-кабатлый Идел белән Чулманның икенче ягына ишеттерер өчен ашыга-ашыга очып баралар иде.

# Мәхмүт Хөсәен

## МОҢ КАНАТЛАРЫНДА

*Татар әдәбиятында инде ярты гасыр хезмәт итәм мин. Шуның шактый өлеше, шагыйрь буларак, җырлар язып үтте. Гомерем буе С. Сәйдәшев, Җ. Фәйзи, Р. Яхин, А. Ключарев, З. Хәбибуллин кебек композиторлар белән иҗади дуслыкта булдым. Җырларымны башкаручы Гөлсем Сөләйманова, Галия Кайбицкая, Зифа Басыйрова кебек атаклы җырчыларыбыз белән фикер алышып, мандолинда маһирәнә уйнаучы Исмәгыйль Һилалов кебек мәшһүр музыкантлар белән аралашып үтте көннәрем. Шуңа, күрәсең, композиторларыбызның, җырчыларның рухи дөньялары, аларның фидакарь хезмәтләренә бәйле уйлануларым иҗатымда да күпмедер дәрәҗәдә чагылыш тапты. Моң темасын яктырткан шигырьләремнең кайберләрен журналга тәкъдим итәм.*

*АВТОР.*

### Салих Сәйдәшевкә

Солдат булып зур походлар үттек,
Европаның уздык яртысын.
Алга илттек кайнар йөрәкләрдә
«Зәңгәр шәл»не — туган як төсен.

Эфир аша йотылып тыңлый идек
Окопларда синең моңнарны,
«Марш»ың белән кердек Берлиннарга,
Җиңеп үттек авыр юлларны.

Сугыш бетте.
Без Казанга кайттык.
Ә бер көнне очрап урамда,
Озак кулың кыстык,
Көйләреңнән
Гомере шулай озын булганга.

Татарларның Чайковские син,
Тукае син көйле дөньяның.

---

Мәхмүт ХӨСӘЕН (1923) — *шагыйрь, татар, урыс һәм казакъ телләрендә күпсанлы шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Рәхмәт сиңа рухландырган өчен
Моң сөюче милләт улларын.

Мәңге үлмәс җырлар иҗат иттең
Арабызда бергә сайрашып,
Халык мәхәббәте лауреаты
Сөеклебез Салих Сәйдәшев.

*Декабрь, 1954.*

## Моңда — фидакарьлек

*Альпларны күреп: «Ah!» — диләр.*
*Алар да ком-таштан калыккан...*
*Тукай кебек титан даһилар*
*Күтәрелгән гади халыктан.*

Син тугачтын йөзенче кат атты
Пәрәнҗәсен төннең ярып таң...
Таш астыннан бәреп чыккан гөлдәй,
Күтәрелдең гади халыктан.

Туишевлар, Солтан Габәшиләр
Сәхнәдәшең булды, моңдашың,
Үссен өчен милли сәнгатебез,
Киң җәелде иҗат колачың.

Моңнарыңны тыңлап сокландылар
Чишмәләре туган җиреңнең.
Җимеше мул булды картлыгыңда
Яшьли түккән маңгай тиреңнең.

Олы яшьтә күрсәм дә мин сине,
Моң агышың таныш бишектән...
Җанга рәхәт маршың авазларын
Төшләремдә хәтта ишетәм.

«Тукай маршы» — халык горурлыгы,
Сәйдәш маршыдай ул үлемсез.
Ә Сәйдәшев синең шәкертең ич...
Безнең өчен һаман тере сез.

Сездән башка күңел китек безнең,
Сездән башка ятим җаныбыз.
Сез — милләткә сүнмәс моң иңдергән
Үткәнебез, җырлы таңыбыз.

Халык өчен яндың гомер буе,
Илһам бирде яшьлек юлдашың.
Абынсаң йә тайсаң тормышыңда,
Ике улың булды кулбашың.

«Шүрәле»се Фәрит Яруллинның
Узды урап бөтен җир шарын...
Онытмас ил — аның илһамчысы
Заһидулла дигән ир барын.

Мирсәетҗан Яруллинның җыры
Иңли бүген газиз ватанны...
Онытмас ил — аны рухландырган
Заһидулла дигән атаны.

«Без — варисың»,— диеп, ике улың
Дәвам итә олы юлыңны.
Син — Сәйдәшнең рухи атасы дип,
Рәхмәт әйттек, кысып кулыңны.

Тууыңа гасыр тулып үтте...
Ә син һаман татар дөньясын
Дәртләндереп мәшһүр маршың белән,
Күңелләргә канат куясың.

Фидакарьлек моңда — шулдыр ул,
«Тукай маршы» — үлмәс моңдыр ул!

*1989*

## Моң музее

*Композитор Сара Садыйкова иҗаты —*
*үлемсез моң дәрьясы.*

Апас — җанга газиз җирең,
Шәһри Казан — туган өең.
Ә беләмсең, Сара апа,
Кемнәр ачты моң музеен?

Тутай халкы,
Кергән чакны
Моң музееның эченә,
Сихри моң бүләк итәсең
Син килгән һәрбер кешегә.

Өй эченнән тышка аккан
Тылсым тулы синең моңнар
Миллионлаган милләттәшнең
Күңеленә яра юллар.

...Күрәм алда сәхнә күлмәгеннең
Бала итәклесен, ап-агын...
Пианино...
Нота дәфтәрләре...
Энҗе белән чиккән калфагың...

Тынып калам аңа күзем төбәп,
Дулкынланып, телгә килә йөрәк:
«Син — сандугач тиңе.
Аерма шул:
Син калфаклы,
Ә ул канатлы.
Күктән төшми талант.
Ходай үзе
Тигез биргән сезгә талантны.

Илһамланып, янып сайрыйсың син,
Дәртең тәңгәл язгы ташкынга.
Тумыштан моң сөйгән, җыр яраткан
Милләтең гел сиңа тартыла.

Мәңге тынмас,
Кат-кат тыңлап туймас,
Үз төсмерен җуймас көеңә
Мөстәкыйльлек алган дәүләтемнең
Һәр татары ихлас сөенә!..

Рухландыра безне,
Сокландыра
Йөрәгеңнең дәртле тибеше...
Безнең өчен син гел Сара апа —
Халык хөрмәтенә тиң кеше.

Сине зурлап яңа таңнар ата,
Сине тыңлап тормышта ямь арта,
Без нахакка кимсетелгән чакта
Арадашчыбыз син, Сара апа.»

Без Саралы булу белән бөек —
Тукай җаны кебек.
Без Саралы булу белән көчле —
Сәйдәш маршы төсле.

Тукайның да, Сәйдәшнең дә музее бар.
Без, татарлар,
Сәйдәшлеләр, димәк, Тукайлылар.
Сараның да туды үз музее —
Рәхмәт сезгә.
Олы җанлы тутайлылар!

*1992*

## Мандолиның тулы моң...

*Исмәгыйль ага Һилалов истәлегенә*

*И, сихерле, серле, илһамлы,*
*гаҗәеп мандолин.*

Ш. БАБИЧ

Дүдәк сынлы,
Үрдәк муенлы,
Сигез кыллы, моңлы мандолин...
Илһам иңдерүче илаһ сыман,
Йөрттең аны һаман янда син.

Давылларда дәрман өстәдең син
Курку белмәс янар җаннарга.
Дан җырладың шомлы төнне куып,
Таң яулаган каһарманнарга.

Нахак бәла, хаксыз рәнҗешләрне
Күп татыдың юлда, күп күрдең...

Моннарыңны тыңлап юанды ил,
Бергә кичте сират күперен.

Интеккәндә халкың,
Аның белән
Уртаклаштың кайгы-зарларны...
Осталыгың белән сокландырып,
Яңгыраттың күпме залларны!..

Сине тыңлап Тукай әсәрләнгән
Троицкида булган чагында.
Сине тыңлап Шәехзадә Бабич
Ләззәт тапкан шигъри җанына.

Моңын саклыйм һаман җанда мин...
Татар барда тынмас мандолин!..

*1992*

## Моңыбыз йөзек кашы

Рөстәм Яхин дисәм,
Искә төшә
Дәрья булып аккан якты моң...
Сәйдәш биеклеген кыйбла иткән
Җырчысы ул татар халкының.

Көйләр язып көн күрүче затлар
Булса да бихисап дөньяда,
Бик сирәге аның чатыр кора
Моң баш төрткән зәңгәр кыяда.

Андыйларның, моңга мохтаҗлыктан,
Тумас борын үлә җырлары...
Яхин моңы
Кояш белән тулы,
Яхин җыры
Хәтерләтә язгы урманны!..

Дәрәҗәле диплом алып та,
Дәрдмәндләрне көйгә салып та,
Моңсыз булса җырың,
Берничек ул
Хуплау таба алмый халыкта.

Тәэсиратен җырның чын моң белән
Үлчи халык, сәнгать дөньясы.
Чын моң чыга ташып чын йөрәктән,
Йөрәк аның илһам оясы.

Милли романслар чәчәк аткан
Моң бакчабыз үсә, ямьләнә.
Бакчага ямь индерүче Яхин
Үзе классикка әйләнә!..

Әйләнмәсен берүк аның башы,
Ихтирамлап, зурлап атаудан.
Ван Клиберн кебек пианист дип,
Музыкада тиңе юк артист дип,
Милләттәшләр ихлас мактаудан.

Рөстәм Яхин, әйе, олы шәхес,
Ерак йөри аннан хилаф ат...
«Син — йолдыз!» дип күккә чөйсәләр дә,
Тыныч калыр...
Ул — бик тыйнак зат.

Яхин яшьли татар рухын тойган,
Тойган аның күңел җылысын.
Үз йөрәге аша уздырган ул
Давылларын чорның, сулышын...

Әхлак тажы — газиз әнкәсенең
Байрак итеп хәер-догасын,
Моңыбызның йөзек кашы Яхин,
Кыю җәеп иҗат колачын,
Киң актырта татар дөньясын!..

*1991*

## Риза Шәфи

### Күтәр башыңны, татар!

«Борын белән җирне сөреп»
Йөри тик йөк атлары.
Аяк астын гына күреп,
Гел йөк тартты татарым.

Үз кояшын югалтты ул,
Үз аен да тапмады...
Гасырлардан гасырларга
Богау сөйрәп атлады.

Килде мизгел: инде безнең
Гамь-гамәлгә кыюлык:
Милләтеңә игелек кыл! —
Инде золым — тыю юк!

Милли күктә урак аең,
Таң кояшың нурлана...
Күтәр башың! Имә тагын! —
Данын, татар, хурлама!

Якты айлы манарадан
Изге дога юл табар
Зиһен, күңлең, мохитенә —
Синең өнең ул, татар!

Күктән иңгән нурны, моңны
Багарга вә отарга —
Башны текә тоту кирәк
Дауга купкан татарга!

### Иң-иң кирәк

Типсә әгәр күкрәгеңдә Тукай йөрәге, —
Әйткән сүзең, кылган догаң — халкың кирәге.

Исхакыйча фикерләсәң илең язмышын —
Шыңшу түгел, күкрәү булыр сөрән тавышың.

Гали́мҗаннар, Туфаннарча кылсаң гамәлең —
Күтәрдең илең түрендә ыруг әләмен.

Солтан-Гали, Мулланурга тәңгәл кыюлык:
Халыкка хөрлек яулыйсың — башка юлың юк!

Нәфрәтеңне тиңли алсаң Муса гаменә, —
Кайнар эзең — утлы сүзең кирәк әле дә.

---

Риза ШӘФИ (1917) — *Ижевскида яшәүче шагыйребез, берничә китап авторы; сугыш һәм хезмәт ветераны.*

Яуга купкан өммәт өчен иң-иң кирәге —
Манкорт түгел, чын татарның кайнар йөрәге!

## Милләтчеләр вә мөлкәтчеләр

Кемнәр яклап үз милләтен мәйданнарга килгәннәр,—
Шуларны гел «милләтче» дип, канлы дарга элгәннәр.

Туганыннан алып, жаны вә керсез вөждан белән
Кемнәр милләт тәрәккыен алга сөргән — шул «бөлгән».

Зиндан базына япканнар, подвалларда атканнар,
Тагын да куркыныч җәза алар өчен тапканнар.

«Өлкән туган» түрәләре курыккан-өреккәннәр:
«Һәр гамьдә безне уздыра бу сәләтле мөртәтләр!»

«Кече милләт»тә дә холуй вә әнчекләр табылган:
Хужа сузган калҗаларга, янчыкларга табынган.

Үз туганын, тәрәккыен шулар башлап сатканнар,
Шул вөҗдансызлык хакына мал да, дан да тапканнар.

Чукынып бетсен — юкка чыксын үз милләте! Ә алар
Күрсенмәгән — хафа да юк — табылган шундый татар.

Милләт елый, милләт сыкрый, ә алар сафа кора.
Вәгазендә: фида ул — «Халкым!» дип, лафлар ора.

Милләт корый, кими, бетә, ә аңа бумы хафа? —
Милләт өчен ник уфтансын — нигә аңа бу «җәфа»!

Телен җуя кардәшем дип, ник аңа борчылырга? —
Түрә иткән түрәгә ул тугры ла, бурычлы ла!

Аларга кирәкми халкың һәм аның киләчәге:
Милләттәшләр вә кардәшләр аңа тик дөнья чүбе.

Юкмы соң алар бүген дә? — бар! алар адым саен:
Милләт данын сатар өчен табалар көен, җаен.

Мөлкәтчеләрне сөрергә — күр! — милләтчеләр килә.
Ни өчен алар килгәнне вөҗданы сафлар белә:

Бер үк хозур, бер үк хокук, бер үк ил, бер үк Кояш! —
Менә шундый милләтчегә — шундыйларга без юлдаш.

## Ил каршында йөзебез ак

Яшермибез йөзебезне —
Үзебезнең татарлыкны: —
Белгәнгәдер ил гамендә
Безнең мул өлеш барлыкны.

Яшерергә маташсалар:
Узганнарны — эзебезне,
Тарих үзе эзли безне —
Илгә дога сүзебезне.

Эз яшерү, битлек кию
Хас йола тик хаиннарга.
Татар килеш кирәбез без
Утка-суга — кыеннарга.

Яшермибез татарлыкны!
Көтмәсеннәр: «ТАТАР ЮК!»ны!
Мәкерләр дә, дәверләр дә
Ега алмый тамыр ныкны!

* * *

Булгандыр каумем башы — ак бүреләр,
Киләдер нәселем шушы ырудан:
Юкса, өрерләр идеме ырлап барча этләр?!
Юк! туктамам, тынмам — кире борылмам!

## Илгә кайта кыр казлары

— Кыйгак! Кыйгак! —
Бу як, бу як
Безгә таныш! — дияме? —
Әллә кыр казлары да
Татар телен беләме?

— Кыйгак! Кыйгак! —
Бу як, бу як
Безнен илләр! — дияме? —
Илдән киткән татарлар
Илгә кайтып киләме?

— Кыйгак! Кыйгак! — куанамы
Күлләрдә кыр казлары...
Кайтканнарга мең дәва
Туган якның назлары.

— Кыйгак! Кыйгак! —
Бу як, бу як
Тагын кала! — диясез.
И татарым! И казларым! —
Бүген нигә китәсез?

## Җәмил Мостафин

# ШӘҖӘРӘ

ХИКӘЯ

*Мы поехали за город,*
*А за городом дожди,*
*А за городом заборы,*
*За заборами — ВОЖДИ.*

Александр ГАЛИЧ

Узган җәй Мәскәүдә эссе, чамасыз коры булды. Шәһәрдә калганнар таң туса иза чикте, бала-чага эсседән чирләп бетте, карт-коры урын өстеннән тормады. Ә хәллерәкләр, байлар һәм урындагылар җәйнең җәй буе дачаларда, туган-тумачалы авылларда, җиләстә рәхәтләнде, киңәнеп дөньясына мең шөкрана кылды. Тагы да хәллерәкләр диңгез ягаларына китеп котылды, чит илләргә сәфәр чыкты, кыскасы, Мәскәү каласында җыен әтрәк-әләм, салам сыйрак, җеп коерык торып калды. Безнең дә дачага чыккан еллар булгалый иде, былтыр колагыбызны шаңкайтеп шәһәр-җәһәннәмдә калдык, сумала казанында кайнадык. Кич саен хатыным колак итемне ашады, таң саен сыртымны игәүләде. Янәсе, фәләннәр дачаны төгән җирдән алганнар, бәясе дә юнь ди, хуҗалар әүлияләр, имеш, җәй буе корсаклары кап булганчы кыяр-кишер ашаганнар, алма-чияне туганнарына шәһәргә дә ташыганнар. Бушлай! Янәсе, әллә кемнәрнең чирләшкә балалары туп булып тазарып, бите алланып кайткан, имеш, көзгә кыраулар төшкәнче Истра елгасы буенда, алпавыт утарыдай дачада җыйнаулашып рәхәт чиккәннәр.

Җитәр! Хатын выжлавыннан гарык, язны көтә-көтә саташып беттем, көннәр җылына башлауга аякны киенеп алдым, белеш-танышлардан сораштырып арыбире юргаларга тотындым. Хатынны, малай белән нәзберек кызны Олы көн узуча дачага илтеп ташларга исәбем! Комарланып, ярсып, хатын искә төшкән саен иреннәремне чәйнәп эзлим, малай! Әзерләп куйганнар ди сиңа, тот капчыгыңны! Кая барып тотынма — кыйбат! Минем хатынга кыз да булсын, буаз да булсын! Арзанлысы кирәк аңа, әмма шәбе: урман, сулы, тимер юлга якыны кирәк аңа... Күр, мин тирләп-пешеп чапкан арада Олы көн дә үтеп киткән, Май бәйрәме дә артта калган, ашыга-ашыга җәйгә кереп барабыз, ә мин һаман хатынның туп атуларын тыңлап газап чигәм. Нишләргә? Дачалар бар, гел очрап тора, андыйларны эләктерү өчен йә бик бай, йә мул чумаралы урында эшләү кирәк. Ә минем... кашым да күзем, чалгы телле хатыным да үзем. Язмыш! Үзебездән бигрәк бичара этем Радж өчен эзлим дачаны. Былтыргы эсселәрдә әз җәфа чикмәде бит ул...

Йөрим, йөрим, инде чын җәй башланды, һава көннән-көн эсселәнә, хатынымның температурасы да өзлексез күтәрелә, теле белән турый мине! Турый да учлап-учлап тоз сибә.

Чираттагы дача хуҗасына барып кердем. Арган, талган, күз тонган, колак ишетми... «Әнә, кара. Күр! Дачаның бер дигәне!» Куас мичкәсе юанлыгы, мыеклы хатын каядыр төртеп күрсәтә. Карыйм, дача дигәннәре ташка үлчим, аннанмоннан әтмәлләгән, чергән әрҗә такталарыннан каккалаган бер мескен алачык-

ны күрәм. Бер почмагы янтайган, икенчесе кыйшайган, тома сукыр арт стенаны аннан-моннан чәпәләп кызыл балчык белән сылаганнар. Рамнары чалшайган, тәрәзә яңаклары калҗайган йорт алдыннан арлы-бирле ярым шәрә бичәкәйләр үтеп йөриләр. Мәскәү елгасы шушы тирәдә генә икән. Мин монысын нигәдер мыеккa чорнап куйдым. Тыштан бәләкәй күренгән алачык, эчкә кергәч, тагын да тараеп калды. Шушы әҗәл тагарагын калын такталар белән икегә бүлгәннәр, олырак якта хуҗалар яшәп ята икән, икенче баштагы чоланны дачникларга бирмәкчеләр... Чоланга кергәч, борынымны җыердым да, әдәп өчен генә: «Шушы табут өчен күпме мәһәр сорыйсыз?» — дип сорадым. Куас мичкәсенең җавабы әзер иде: «Ике айга алты йөз тәңкә!» — диде ул күземә туры карап. «Аз да түгел, күп дә түгел!» Аның тәбикмәктәй йөзенә, почык борынына карап телсез калдым. «Алты йөз?! Безгә батмый бу!» Хуҗа хатын шуны гына көткәндәй күкерт кебек кабынды. «Моннан арзанракка эт оясы гына табарсың! Без үзебез монда тормыйбыз да диярлек. Әнә тегендә, урман авызында яңа йорт җиткереп ятабыз. Әгәр юньле кешеләр икәнсез, тора-бара бүлмәнең тегесе дә сезгә булыр. Балаларыгыз икәү дисеңме, йокларга шунда керерләр. Елга якын, урман өстенә аварга тора, кеше аз. Үтеп йөргәннәр дә юньле адәмнәр. Монда әтрәк-әләмнәрне якын да җибәрмиләр. Килгәндә биек-биек коймаларны абайладыңмы? Анда, койма артында кем ял иткәнен кычкырып әйтергә дә ярамый. Безгә җир танышлык аркасында гына эләкте. Биш киявебез бар, арадан берсе... ярый, анысы калсын. Яхшы, әйтсәм-әйтим, киявебез, Мәскәү мишәре, шул хөкүмәт дачаларын саклый. Яңа өйне уртакка салабыз.»

Хатын тәтелдәпме-тәтелди, дачасын, урынын, кияүләрен, койма артындагы адәмнәрнең шәплеген, һаваның сафлыгын, суының чисталыгын кычкырыпмы-кычкырып мактый. Мәкәрҗә ярминкәсендә шомарган маклер диярсең! Хатын сизгер, җәй башланган, алачык бик кәй, яңа өйгә акча чыгымнары кирәк, электричка туктый торган станцага ике чакрым тәпилисе бар, Мәскәү халкы асылда урнашып беткән. Дача-алачыкны кичекмәстән кемгәдер бәдәргә кирәк! Кемнең ике айга алты йөзне чыгарып саласы килсен! Шулар өстенә куас мичкәсе минем ару кеше булуымны күреп тора. Дача хуҗалары кибетчеләргә иш, алар менә дигән психологлар!

Өзеп әйтмәдем, «уйлашырбыз!» дидем дә ике чакрым тәпиләдем. Монда килгәндә, биек-биек коймалар артында берәр яшерен хуҗалык мәйданнары, дип фараз кылган идем, ялгышканмын. Койма артында «хуҗалар»ның эреләре икән...

Яман уфылдап, кара тиргә батып кайтып кердем. Хатын чыраема бакты да дәшмәде, теш арасыннан сыкранып чәйнеккә барып тотынды. Шактый вакыт иреннәребезне биктә тоттык, ике-өч чынаяк уттай чәйне әйләндереп каплагач кына игә килдем. Тамагымны кырып, сүзгә керештем. Юлның ераклыгын, дачаның кыйбатлыгын, йортның әтрәк-әләм булуын, хуҗа хатынның шапшаклыгын телләренә шайтан төкергән язучылардан бер дә калышмастан өзми-куймый тезеп чыктым. Уф! Әле хатынымның ни теләгәнен, сүземнән һәм сәяхәтемнән нинди нәтиҗә чыгарганын һич аңларлык түгел иде. Ул дәшмәгәч, мин тагын сүз йомгагымны сүтә башладым. Шул чакта тыелган булсам кана!

— Хөкүмәт башлыклары, политбюро членнары шунда ял итә икән. Дачаларын әйләндереп алган коймаларның биеклеген күрсәң, исең китәр! Кош та очып керерлек түгел.

Хатыным биш минут дәшмәде, ун минут, ярты сәгать дәшми чыдагач, авызын ачты да сүз буасы ерылды. Ул, гадәтенчә, минс әрләргә, пешекләргә керешге. «Синең нинди йортта, нәрсә ашап ял итүеңне этем беләмени? Ни теләсәң шуны шыттырырга була! «Хөкүмәт башлыклары, политбюро әгъзалары белән янәшә ял иттек», — дип былтыр кичергән газапларны онытып, ярты Мәскәүнең авызын томалар идек. Хәсрәт чүлмәге, шундый затлы, данлы дачаны килешеп тә кайта алмагансың. Андый затлы урынга ия табылмас дисеңме, хөрәсән! Кышның кыш буе бездән көлгән таныш-белешләрдән берьюлы үч аласы икәнмен».

Кич буе тынмады хатыным, төнлә йокламады, тәрәзә пыяласына сарган явыз черкиләр белән бергә бызлады.

Кыскасы, иртәгесен, шәһәр транспорты кузгалган мәлдә, йокысызлыктан кызарган күзләремне уып, мин кичәге сукмакларга төштем. Өч көн дигәндә, мең мәшәкать чигеп, җәфаланып, шактый акча түгеп, малай-кызны, кирәк яракларны төяп без күченеп тә куйдык. Балалар чиксез шатланды. Радж куанды, ә хатын, озата чыккан күршеләргә: «Затлы урынга, политбюро әгъзалары белән янәшә дачага, ике айга чыгабыз!» — дип кабатлады...

Ничек-ничек баруыбызны, биек коймалар яныннан үткәндә хатынымның күзе ут булып януын, Радж үткәнне сизеп койма артындагы көр тавышлы

овчаркаларның яман ырылдауларын, кызымның һәр чәчәккә иелеп сәлам бирүләрен, малайның җиргә аяк басуга яңгыр суалчаннары эзли башлавын тәфсилләп язып торсам озакка китә, ике сүздә әйткәндә эш болай: бардык, урнаштык, кыеш почмаклы алачыкны күргәч, хатыным мырлар дип курка-курка баруым гел юкка булды, мырламады, куас мичкәсе Матрена Петровнаны кочаклап алды, алар гомергә авызлары авыздан китмәгән әшнәләр кебек чәлдер-чөлдер сөйләшергә тотындылар. Әйбер-караларны кайсын кая таратып урнаштыргач, Матрена Петровна белән урын-җирләр, түшәк-мендәрләр турында килешенгәч, җиңеләеп киттем. Матрена Петровна Радждан гына шикләнде. «Ай-һай, бер эләктереп алса, җаныңны ала инде бу явыз!» — диде. Сизәм, эт аркасында дачаның бәһасын арттырырга чамалый бу явыз! Сынатмадым, этне якларга, аның тәртип-холкын мактарга тотындым. «Тугыз буыннан килгән нәсел кәгазе бар аның, шәҗәрәсе!» — дигәнне хуҗа хатын колагына элде микән, белмим, мәгәр: «Бергә ашый ул, бергә ятып йоклый, тыныч, сабыр!» — дип хатыным да кат-кат сайрагач, куас чиләге әз-мәз сабырланды.

Кичкә кырын биш киявен ияртеп хуҗа үзе да кайтып керде: янәсе, дачниклар, кадерле кунаклар белән танышырга теләгән. Кияүләренең икесе урыс, берсе татар, кышын Казан вокзалында арбачы булып эшләүче Фазыл атлы кеше икән, дүртенче кияү башкорт, бишенчесе арага адашып кереп кысылган гөрҗи-грузин иде. Гөрс-мәрс килеп торган кызмача кияүләргә Радж бик шигәеп кенә карап торды да алачык почмагына күләгәгә барып ятты. Кайчы колакларының ялт-йолт уйнавыннан гына мин Раджның кияүләрне ошатып бетермәвен аңладым. Грузин кияү эткә таба башын кагып: «Без дә эт асрыйбыз. Юньсезе туры килдеме, йортка иялэшә алмадымы, әллә нәрсә шунда, өрмә дисәң — өрә, өр дисәң, авызын да ачмый», — дип сүз кыстырды. Кече кызга өйләнгән бу иркә кияү минем үземә дә ошап бетмәде. Күмер кара күзләре чәчрәп тора, маңгае тар, тар маңгай өстенә бөдрә чәчләр ишелеп төшкән, колак эче дә, танау тишекләре дә кара төк кенә. Кияүнең фикерен төзәтергә ашыктым: «Эт — тәрбия ярата. Торабара хуҗасына ошый инде», — дип куйдым.

Без хуҗаны да, кияүләрне дә сирәк күрә идек. Аларның үз мәшәкате, караңгылы-яктылыда балта чабалар, дөп-дөп нидер кагалар, һаваны ертып нидер каералар. Раджның холкын яхшы белгәнгә, мин алар тирәсенә бармаска тырышам. Ә хатыным... Тәмам йомшады! Ошатты бит шушы алачыкны! Алачыктан бигрәк Матрена Петровнаны яратты! Икәү бергә туры килделәрме, тотыналар сайрашырга! Сөйләшмәгән сүзләре юк! Хатынымны бигрәк тә койма артында яшәүчеләр яшәеше кызыксындыра. Башта әллә ни теш агартмаган куас мичкәсе хатынымның төчелеге, тәмле теле алдында озак ныгый алмады, башта әзләпәзләп кенә, соңра мулрак итеп ишеткән-белгәннәрен сиптерә башлады. Аларның шулай килешенеп китүе миңа үтә дә мач килде, хатын өйдә кала, мин балаларны ияртеп елга ярына төшәм, рәхәтләнеп кызынам, бот күтәреп ваемсыз зәңгәр күккә карап ятам, түйганчы су керәм. Кармак салып мәшәләнгән идем, балык капмагач, ул һөнәрдән баш тарттым. Без еш кына Радж белән икәү калабыз, балалар үз ишләрен табып, танышып өлгерде, андый сәгатьләрдә мин аерата бәхетле, аерата шат була идем. Раджны иярләм дә, тугры этем белән аны-моны сөйләшкәләп елганың аулак ярларын, ерак болыннарны, урман сукмакларын урап кайтам. Лыгырдавык хатын, чыр-чулы бала-чагага караганда Радж миңа иң кулай юлдаш! Хөкүмәт дачаларына якын барырга ярамый, Радж белән мине ике-өч тапкыр туктатып кисәттеләр инде. Һич уйламаганда куак арасыннан гөрс-мәрс ирләр килә дә чыга! «Кая барасыз? Кайда яшисез? Кемнәр сез?» Фәлән-фәсмәтән. Хәзер тикшерүчеләр сирәгәйде, безнең кемлекне белеп бетерделәр, ахрысы. Койма артындагы сакчы этләр генә Раджның исен сизеп тынычсызланалар, койма тактасын тырнап яман ырлыйлар. Без дә коймадан читтәрәк юлларны сайлый башладык, тынычландык.

Раджның үтә сизгер, чиста-пөхтә, сак һәм акыллы эт икәнен әйтеп өлгермәдем шикелле. Кыска тотам, Радж хакында сөйли башласам, телчән хатынымны да узып китәм мин, ншлисең, мин аны үземнән мең акыллырак дип саныйм. Валлаһигазыйм, әгәр Радж сизгерлеге миндә булса... мондый бәла-казаларга элэгә торган адәм идеммә соң мин? Тукта, бу хакта бераз соңрак. Әлегә этем турында.

Зирәклегенә бер дәлил. Анда-монда барганда шәһәрдә дә иярткәлим мин Раджны, ә монда көннең-көн буена аерылган юк, һаман бергә. Аулак сукмакларда гына йөрибез дисәң дә юлда төрле кеше очрый, җәй, һәркем кояш иркәләвеннән, саф һавадан, хәрәкәттән көч җыеп калырга тырыша. Очраган бик күп кешеләргә Радж игътибар итеп тә тормый, ялт кына миңа күз сала да үз юлыннан

бара бирә. Ә сирәк-сорак аңа карап гаҗәпләнеп куясың: кеше үзе күренми әле, искән җил белән аның исе килеп кенә җитәдер, ә тугры этем тынычсызлана башлый. Сукмакның әле бер, әле икенче ягына ташлана, сырт йоннары кабара, коерыгын төп-төз тотып алга ыргылырга әзерләнә. Мин аны тынычландырырга теләп сыртыннан сөям, иркә сүзләр әйтәм, еш кына муен каешыннан тотып та алгалыйм. Дөнья бит, белмәссең... Менә аның тынычлыгын бозган бәндә үзе күренә. Моңарчы беркемгә өрмәгән этем ырылдап тешләрен ыржайта һәм абалап өрә башлый. Кулдан ычкындырсаң, теге бәндәне өзгәләп ташлаячак. Беренче вакытларда белеп бетерми идем, хәзер ышанып әйтә алам, акыллы эт адәмнәрнең кемлеген шулкадәр дөрес аера ки, хәйран каласың! Ул ырылдап каршылаган, өреп озаткан кешеләр минем үземә дә ошамыйлар. Яман авыр карашлы алар, йә исерекләр, йә кием-салымнары шакшы, йә кулларында авыр таяклар, килә-килә алар ян-яктагы яшь агачларның очын кыеп киләләр... Күзләрендә усал ут янган андый бәндәләрне мин дә өнәмим, Раджның үткенлегенә һәрдаим сокланам.

Көннәрдән бер көнне ерак юлларны урап арып-талып, кибегеп дачага кайтып киләм. Хуҗаның йорт төзелеше турына килеп җиткәч, Радж мине шунда тарта башлады. «Өйгә! Өйгә!» — дип әйтеп карыйм, этем тыңламый, күзләрен мөлдерәтеп миңа карап ала да унга каерыла. Этем ихтыярына буйсынып мин дә шул тарафка борылдым. Барып җитсәк, кияүләр юан бүрәнә өстенә тезелеп утырганнар, шәрә тәннәре тиргә манчылган, дымга йомычка, пычкы чүбе ябышып, балта осталары мәзәк бер кыяфәткә кергәннәр иде. Күрәм, Радж баҗаларга борылып та карамый, мине һаман алга йолыккалый. Почмакта, күләгәдә бер эт ята икән, Радж токымыннан, овчарка, ләкин үтә арык, җобанган мескен эт. Каеш муенчагын беләгенә урап тотып эт янына хуҗасы гөрҗи кияү баскан, ул исерек тавыш белән ниндидер боерыклар бирә. Раджның кайчы колаклары уйнаклый башлады, икебез дә гөрҗигә карап тукталдык. Бичара эт хуҗасын тыңламый, аңа буйсынмый, бүтәннәр шуны мәзәк итеп туктаусыз шаркылдыйлар, эт адресына да, хуҗа исеменә дә йомры-йомры сүзләр тәгәрәтәләр. Гөрҗи аның саен кыза, усаллана бара иде. Мин Раджны күзәтәм, ул да, акыллы эт, ни булыр алда дигән сыман ыргылыр-ыргылмас арык кардәшен күзәтә иде. Гөрҗи кияү иелеп үткер кырлы такта кисәге табып алды да, без аны-моны әйтергә өлгергәнче, җирдән калкынырга теләмәгән этнең арык сыртына берне китереп тә орды. Эт ялварып чинап җибәрде. Ә дигәнче Радж алга тартылды, муен каешы кулымнан шуып чыкты, мин җиргә тәкмәрләндем, яңагым сыдырылды һәм күзлегем әллә кая очты. Баҗалар куркып кычкырып бүрәнәдән сикерешеп тордылар, читкә сибелделәр. Мин кармаланып күзлегемне эзләп алып тезләнгән арада алар коралланып өлгергәннәр, кайсы кадак суыргыч тимер тотып, кайсы күсәк белән кизәнеп Раджга яныйлар иде. Ә аның янауларга һич исе китмәгән, ул шыңшып-җылап җирдә яткан бичара кардәшенең муенына борынын төртеп аны тынычландырырга тырыша иде. Гөрҗи кияүгә Раджның кыланышлары бер дә ошамады булса кирәк, ул үткер кырлы такта кисәге белән этенә тагын берне кундырды. Бу юлы Радж чыдамады, яшендәй ыргылып төпчек кияүнең беләгеннән каптырып алды. Инде гөрҗи чинап җибәрде, баҗалар кайсы каян этне һәм мине каһәрләргә тотындылар. Яралы беләген учы белән кысып торган гөрҗине танырлык түгел, аның чырае бозылган, күзен кан баскан, мыек чылгыйлары сикерешә, тешләре ыржайган иде.

— Мин сине, күзлек!.. Җаныңны җәһәннәмгә җибәрмәсәм!

— Радж акыллы эт, ул үз кардәшләрен җәберләргә ирек бирмәс. Гафу итегез, ачуланмагыз инде!

Мин этемнең муен каешын ике куллап тотып аны үземә якынрак китердем. Ул өрми, төрле яктан күкрәгән ачулы сүзләргә борыла-борыла сырт йонын уйната.

— Башын бетерергә кирәк ул этнең!

— Эт түгел, шайтандыр ул. Убырдыр!

Баҗалар аның саен кызды һәм мин бер нәрсәне аңладым: балта осталары эткә түгел, миңа ачулы икән! Алар кара тирләрен коеп шушы эсседә таңнан төнгәчә балта чабалар, юналар, чүкиләр, ялгыйлар, өяләр, ә мин авыз ерып көне буе эт ияртеп йөрим! Бәлки әле аларның ачулары миңа да, эткә дә чыкмагандыр, янәшәдәге биек-биек коймалар, койма артына поскан серле җәннәтләр аларның канын кыздырадыр?! Хуҗаның бер дә җәнҗал чыгарасы килми иде, ул ара-тирә сүз кыстыргалап куйса да, аны тыңлаучы булмады. Берзаман тавышлар басыла төшкәч, аның сүзе дә ишетелде.

— Бар Матрена Петровна янына, йод сөртеп җәрәхәтеңне бәйләр,— диде хуҗа. Аның яхшылык теләп әйткән сүзе өстәмә давылга сәбәп булды.

— Монда иода белән генә котылмак юк. Бәлки ул эт котыргандыр?— диде арадан берәү. Бу сүз утка сипкән май булды. Бҗалар Радж белән мине чолгап алдылар.

Кызган утлы боҗра эчендә калгач, Раджны тыеп тору һаман кыелаша барды. Мин аның муенын кочып җиргә чүгәләдем. Әгәр боҗра уртасына хуҗа кереп калмаса, белмим, давыл тиз генә тынар идеме икән?! Мин мөмкин кадәр сабыр, ягымлы булырга тырышып аңлатып бирдем.

— Радж бик затлы токым эте. Без аны ел саен докторларга күрсәтеп, тикшертеп торабыз. Аның затлы токым эте икәнен раслый торган дәлилле документлар — шәҗәрә бар. Шул шәҗәрәгә карап аның тугыз бабасына кадәр барып житеп була. Аның кан кардәшләре арасында үтә атаклы этләр бар. Шотландиядә, Америкада, Австралиядә аның туганнары. Радж андый-мондый гына эт түгел. Бүген тыела алмады шул, нишлисең... Монда төп гаеп миндә! Кулымнан ычкындырдым бит, сүксәгез мине сүгегез!

Бҗалар минем бер сүземә дә ышанмадылар, аларның берчакта да нәсел, токым, варислар турында ишеткәннәре булмаган, ахрысы, этнең җиде бабасын, минем бабайларны, гүр такталарын, аллаларны русның бик популяр каты сүзләре белән күмеп ташладылар...

Нихәл итәсең, иртә таңнан эсседән, вагоннардагы тыгызлыктан, юлдашларның зарыннан туеп, кысылып Мәскәүгә кайтып килергә туры килде. Бҗаларны җыеп Раджның шәҗәрәсен, аның хакындагы күп санлы документларны таратып ташлагач, тегеләрнең исе китте. Документларны, бигрәк тә шәҗәрәне кулданкулга йөртеп, кат-кат укыдылар, тирле куллары, пычрак бармаклары белән кәгазьләрне пычратып бетерделәр. Хәзер кич житеп эшләрен йомгаклыйлар да, бөялеп, без торган алачыкка килеп җитәләр. Авызларында гел бер сүз: «шәҗәрә дә шәҗәрә». Хәзер шунысы ачыкланды: биш кияү, икесе урыс, берсе татар, берсе башкорт һәм грузин үз нәсел-нәсәпләрен бөтенләй белмиләр икән, онытканнар.

Хәзер кичләр үтә җанлы уза! Бҗалар салган баштан гел бер уңайга әйләнеп кайталар: бабалар кем булган да ничек яшәгәннәр. Нигә акыллы башлар этләрнең шәҗәрәләрен тезеп, аны пичәтләр белән раслап беркетеп калдырганнар?

Гөрҗи кияүнең кулы төзәлде, тамагы тыгылсын, дип, мин аңа ике ярты куйдым. Бҗаларны җыеп ике ярты бөкләгәч, үзләреннән дә әзрәк өстәгәч, сүз тагын шәҗәрәләргә, үткәндәге нәсел җепләренә кайтып калды. Нигә совет заманында шәҗәрәләр язылмаган да, нигә онытканнар аларны?

Хуҗа кеше дә ара-тирә сүзгә катнашкалый иде, бүген дә ул кызып китте:

— Бар, язып кара! Җиде бабаң арасында бер-бер чатаклы бәндә булмас дисеңме? «Бабам урта хәлле булган» дип язсаң да коерыгыңны урап алалар иде! Бөтен Рәчәй пырлитарга әйләнде. Ата-аналар ярлы крестьян булды... Әйтик, әнә теге биек койма артында посып ятучыларның кәгазьләрен актарып кара син! Бөтенесе ярлы-ябагай баласы да, эш е токымы дәвамы!..

Шул урында телне тыярга кирәк тә бит, булмаган, мин дә кызып китеп зур бер речь сөйләп ташлаганмын.

— Безнең авылда да ярлы-ябагайлар бар иде ул... һәммәсе тоташ эт ялкаулары иде! Аркылыны буйга алып салырга иренгән бәндәләр. Ике бозауга кибәк аера алмаган хөрәсәннәр. Эш башына әнә шулар килде шул. Рәчәй хуҗалыгына шулар баш булды... Илне әнә шулар соңгы чиккә алып бара...

Янымда хуҗа үзе, ул чилем тарта, янымда биш бҗа, пыш-пыш сигарет суыралар... Радж сизгерлеге юк шул миндә, шушы алты борынның кайсысы этлек эшләгәндер, дача вакытын тәмамлап Мәскәүгә кайтуыма ике көн генә үтте, мине дөбердәтеп алып киттеләр һәм Бутыр төрмәсенә илтеп тыктылар. Кызыл чырайлы калын капитан өстәл төя-төя миңа җикеренде:

— Кем идарә итә әле Россия белән? Рәчәйгә кем хуҗа?! Кемнәрнең шәҗәрәләрен тикшерергә кирәк?

* * *

Һич шигем юк ки, бу капитанның да биографиясендә: «ярлы ябагай баласы, тырыш, эшлекле, намуслы коммунист» дип язылгандыр.

Һич шигем юк...

Урысчадан тәрҗемә.

**Әхмәт Тимер**

# БӨЕК ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗНЕҢ БЕРСЕ

Төрки дөньяда гыйльми һәм сәяси төркичелек фикеренең таралышында һәм үсешендә зур роль уйнаган тарих профессоры, Төркия җөмһүриятен кору елларында Ататөрекнең якын хезмәттәшләреннән булган Йосыф Акчура (Акчурауглы, Акчурин) 1876 елның 2 декабрендә (кайбер риваятьләргә караганда, 1872 яки 1879 елда) Сембер (Ульяновск) шәһәрендә туган. Атасы — Хәсән, Хәсәннең атасы — Сөләйман бай булган. Сөләйманның дүрт улы, җиде кызы туып, улларының икенчесенә Хәсән кушканнар.

Зур фабрикант һәм сәүдәгәрләрдән исәпләнгән Сөләйманның Сембер һәм Казан губерналарында байтак милеге була. Аннан улы Хәсәнгә Зөябашында, Сембердә һәм Лаховкада берәр комач фабрикасы мирас ителә.

Хәсән бай ике мәртәбә өйләнә, Йосыфны тапкан икенче хатыны Бибикамәрбану Казан сәүдәгәре Габдерәшит Юныс(ов)ның кызы була. Юныслар Казанның мәшһүр сәүдәгәрләреннән санала. Габдерәшит, Казанда тире иләү фабрикасы корып, әзер малын Кытайга алып барып чәйгә алмаштыра. Хәсән белән Бибикамәрбануның берничә баласы туса да, Йосыфтан калганнары яшьли дөнья куялар.

Хәсән, улы Йосыфка ике яшь тулганда, көтелмәгәндә вафат була. Бу хәл яшь бала белән ананы авыр хәлгә төшерә, аларның Сембердән бөтенләйгә Истанбулга китеп урнашуларына этәргеч бирә. Йосыфка алты яшь тулганда анасы нерв чиреннән җәфалана. Докторлар аңа җылы якта яшәргә киңәш итәләр — бу хәл аларның Төркиягә күчүләрендә аеруча мөһим роль уйный.

Фабрика эшләрен йөртергә саулыгы да, тәҗрибәсе дә җитмәгәнлектән, ярдәмне Юныс гаиләсеннән көтәләр. Булышырга алынган зат, исәп-хисап эшләре белән танышкач, ширкәтнең бурычка батуын ачыклый һәм хәлне көйләгәнче, хуҗаларга «югалып» торырга киңәш бирә. Кымыз эчеп дәвалану, кредиторлардан ерагаю өчен Бибикамәрбану, улы Йосыфны алып, Ставрополь шәһәренә китә. Ләкин монда да тынычлык тапмыйлар — кредиторларның адвокаты артларыннан килеп, күп кенә малларына арест куйдыра һәм саттыра. Моннан соң инде гаилә Төркиягә китү ниятендә Одессага юнәлә.

1883 елның яз айларында Истанбулга килгән Йосыф һәм аның анасы Нуригосмания мәхәлләсендә фатирга урнашалар. Башлангыч уку-язуны Лаховкада имам һәм мөгаллим Габделмән әфәндедән өйрәнгән бала Истанбулда Мәхмүтпаша мәчете янындагы башлангыч мәктәпкә языла. Әмма анасы дәваланыр өчен Бурсаның Чәкиргә кайнар чишмәләренә китәргә мәҗбүр булуы аркасында, Истанбулга әйләнеп кайткан саен Йосыфның торган һәм укыган җир дә гел үзгәреп тора. Диванюлындагы Кара Хафиз башлангыч мәктәбендә белем алганда, шул мәхәлләдә постта торучы, мәйданда хәрби өйрәнүләр уздыручы гаскәриләр малайда бик зур кызыксыну уята — ул өендә дә хәрби уенга һәвәсләнә.

Ниһаять, Йосыфның анасы Аксарай Йосыфпаша мәхәлләсендә зур бер өй сатып ала. Йосыф шундагы башлангыч мәктәптә укуын дәвам итә, аннары шуннан гаскәри рөшдиягә (урта мәктәпкә) керә.

---

Әхмәт Рәшит улы ТИМЕР (1912) — *14 ноябрьдә хәзерге Татарстанның Әлмәт районы Әлмәт авылында туа. 1929 елда Төркиягә күчеп китә. Анкара һәм Берлин университетларында югары белем ала. 240 тан артык фәнни хезмәт авторы, профессор. Анкарада яши.*

Шушы дәвердә Бибикамәрбану Казандагы кардәшләреннән бер телеграмма ала һәм, аннан Ставропольдә малларын саттырган адвокатның Истанбулга киләчәген белгәч, улын алып Измиткә китеп бара. Йосыф берничә ай монда да укып ала. Капитуляция дәверендә Госманлы дәүләте (Төркия) эчендә чит ил консуллыкларының үз судлары да була. Болар Госманлы дәүләтендә яшәгән үз гражданнарын теләгәнчә хөкем итә ала. Урыс консуллыгы да шулай хәрәкәт иткәнлектән, Йосыфның анасы вакытында саклану чараларын күрә, әмма мәсьәлә кабат кызып киткәч, кире Истанбулга кайталар. Тик бу вакыйгалар аның нервысын янә дә бозганлыктан, ул иреннән калган бәхәсле эшләргә катнашудан тәүбә итә.

Мондый кыен хәлләрдә бер таянычка мохтаҗ Бибикамәрбану кияүгә чыгарга карар бирә һәм булачак ире турында улының да фикерен сорый. Бу зат дагыстанлы Госман булып, аны шәех Шамилнең каенанасы димли. Малай каршмаса да, араларына чит кеше керүенә борчыла. Башта мөнәсәбәтләре салкын була, тик соңыннан ул үги атасы белән якыная — үзенә төп дини һәм милли тәрбия бирүченең Госман әфәнде булганлыгын иптәшләренә дә сөйли башлый. Госман әфәнде исә аны үз баласы кебек тәрбияли, аңа һәрчак таяныч була. Хәрбия мәктәбенә керүдә дә ул булыша. Аның дикъкате шул дәрәҗәдә була ки, шәкерт чагында да, соңрак та малай «дагыстанлы Йосыф» рәвешендә танылa. «Казанлы Йосыф Акчура» буларак танылуы исә мөстәкыйль тормышка атылганнан соң гына башлана.

Й. Акчура «Гамәл дәфтәрем» исемле хәтирә китабында анасы һәм үги атасы турында: «Мин шактый үсеп, дәресләрем һәм үз дөньям белән мәшгуль булганлыктан, әнием үзен ялгыз калгандай хис итә иде. Бер яктан, сәламәтлеге какшау, икенче яктан, Рәсәйдәге эшләренең чыгырдан чыгуы үзенә бер терәк, яклаучы булдыру ихтыяҗын барлыкка китерде, ахры. Әниемнең хәлен яхшы белүчеләрнең аңа лаек бер иш эзләүләрен арадагы көрәшүләрдән чамалый идем инде. Яучыларның иң тырышканы Бәдәстән базары сәүдәгәрләреннән берсенең хатыны — казанлы Бәдрия ханым иде»,— дип яза.

«Рөшдиягә кергәннән соң минем аптекарьлыкка кызыгуым да сүнде,— дип дәвам итә ул.— Аның урынына рәссамчылык белән мавыгуым көчәйде. Гашыйк Кәрәм кеби китаплардагы сүрәтләрне сулы буяу белән күчереп ясый идек. Рәсемнәрем күбәйгәч, аларны кешегә күрсәтү өчен бер почмакка «Йосыф бәйәфәнденең рәсем кибете» дигән бер язу язып астым. Мәктәп янында рәсем ясап сатучы Дәрәбостаныйның кибете алдыннан үткәндә-сүткәндә, аның ничек рәсем иҗат итүен кызыксынып карап тора идем».

Й. Акчура, үзе язуына караганда, 1885—1886 уку елында Гаскәри рөшдиягә языла. Беренче курстан икенчегә ул — каптенариус, икенчедән өченчегә сержант булып күчә. Рөшдиягә кергәндә аңа тугыз тулган була. Анда ул дин һәм көнкүреш нигезләрен, Төркия тарихын, дөрес язу кагыйдәләрен, төрки каллиграфияне, икенче сыйныфтан гарәп, фарсы, француз телләрен, рәсем, хисап, география фәннәрен өйрәнә. Бераздан тәртибе белән дә, белеме белән дә укытучыларының хуплавын казана. Йосыф бу хакта, укытучылары, аларның укыту үзенчәлекләре, холык-фигыльләре турында шактый тәфсилләп «Гамәл дәфтәрем» хатирәләрендә искә ала.

Укытучыларының шактый өлеше Йосыфны канәгатьләндерми. Ул монда дини бәхәсләр белән кызыксына. Бервакыт Александр исемле бер грек егете белән алланың өч йөзе турында бәхәскә керә. Бер көнне әлеге егет: «Хак тәгалә кайда?» дип сорый. Үзе күктә дип хисаплый. Йосыф анасыннан ишеткән сүзләрне кабатлый: «Яңа савылган сөттә каймак ни булса, хак тәгалә дә шулдыр». Бу вакытта Йосыф унбердә, Александр унбишләрдә була.

Йосыф Рөшдиядә үзен тәртипле тотса да, өендә шактый ук шаян һәм үзсүзле була.

Үги атасы Хиҗазга киткәндә Истанбулга анасының атасы ягыннан кардәше Мөхәммәтрәхим балалары Фатыйма, Гайшә, Габдулла, хатыны Маһиҗиһан белән күчеп килә. Бибикамәрбануның фабрика эшләрен, аның Истанбулга күчеп китүен нәкъ менә шушы Мөхәммәтрәхим оештырган була. Бибикамәрбану Йосыфка авырлы чагында Фатыйма инде туган була. Хәсән Акчура Габдерәхимгә: «Улым туса, аңа Фатыйманы алырбыз», дигән, имеш. Моны Йосыф яшьтән ишетеп үсә. Ничә елдан соң алар белән күрешү малайны бик сөендерә. Ул хәтта рәсемнәрен дә яңа килүче иптәшләренә бүләк итә.

1889 елның язында Йосыф әнисе белән Казанга сәяхәт итә. Бу сәяхәттә аларга Галатасарай уку йортын яңа тәмамлаган Заһит Шамил дә юлдаш була. Заһит Русия кулына әсир төшкән Кавказ каһарманы Шамилнең оныгы булып, Казанга атасы янына кайта.

Бу сәяхәт Бибикамәрбануның икенче мәртәбә кияүгә чыгып та, аннан галәсенә бер ярдәм булмаганнан соң, 1889 елның язында гына эшкә аша. Туганнары булышлыгында фабрикаларының буталчык эшләре, ниһаять, җайлана һәм моннан соң Истанбулда рәхәт яшәү өчен генә түгел, ватанны кайтып күрү өчен дә мөмкинлекләр ачыла. Монда Йосыфның бабасы үлгәч варислар арасында мал бүлешү, мирас акчасы белән Йосыф атасының бурычларын түләп бетерү дә ярдәм итә.

Русия корабында Одессага, аннан поездда Нижний Новгородка килгәч, алар монда бер сәмәркантлы имамда кунак булалар. Шул имам Казанга телеграмма биргәннән соң, анда кунакларны Заһитның атасы каршы ала, бер көн кунак иткәч кенә, Йосыфларны үз туганнарына илтеп куя. Дачада алар мөфти Солтан Габделгазизнең кече кызы һәм анасы белән бергә ял итәләр.

Бервакыт алар атта Казан буйлап сәйранга чыгалар. Йосыф дилбегәне үзе кага-кага, Маһиҗиһан апасын утыртып йөри. Шунда Маһиҗиһан:

— Истанбул әйбәт әйбәтен, әмма анда болай рәхәтләнеп урам гизә алмыйсың, әйеме? — дип эндәшә.

— Әйе. Мин дә Истанбулга караганда Казанны яратарак бирәм, — ди Йосыф.

Казанда кунактан кунакка, бер күнел ачудан икенчесенә йөри торгач, Истанбул, билгеле инде, күңелсезрәк күренә башлый.

Бервакыт Черекқүл бакчасында йөргәндә җизнәсе:

— Истанбулда шушындый парклар бармы? — дип сорый.

Йосыф урысларның «Истанбул — пычрак дәрьясы бер шәһәр», дип яманлауларына үчләшеп, аның Түбәбашы бакчасының бик ямьле булуын, эчендә тавис һәм попугайлар йөрүен, төрле бүтән кошлар сайравын хозурланып сөйли башлый. Аның Истанбулны юри күпертеп мактавын җизнәсе сизми, билгеле!

Казанда сыйланып, Йосыф тазара, матурлана. Укуны да онытып бетерми — Заһит Шамилдән француз телен, Төркия географиясен, рәсми язуны, бер марҗадан Фатыйма белән бергә урыс телен өйрәнә. Урысчага башта ул ихлас керешми. Дошманын яхшырак танып-белер өчен аның телен дә яхшы үзләштерергә кирәклеген ул соңрак кына төшенә.

Йосыф Казанда театрга да йөри, мәсәлән, Л. Толстойның «Хаҗи Морат» операсын тамаша кыла.

Заһит Шамилнең атасы мөфти хөрмәтенә кунак җыйганда, мәҗлестә яшьләр дә катнаша. Йосыф — фәстән. Урысча белми, татарча да иркен сөйләшә алмаганлыктан, аны «төрек баласы» дип үртиләр. Табында мөфтинең кече кызы белән янәшә утыргач исә, Йосыф уалучан бәлешнең эчен күршесенең затлы ефәк күлмәгенә ялгыш коеп җибәрә, моның өчен бик ояла.

Кымыз эчәргә дип Дәүләкән авылына барганда Уфа кунакханәсендә кич куналар, көндез паркта күңел ачалар.

Йосыф Дәүләкәнгә китапларын да алып килә, ләкин аларны укырга гына туры килми. Монда малай Дим суында балык тота, табигать кочагында ял итә, уйный. Шул дәвердә мөфти ике мәртәбә аларның хәлләрен белешеп китә. Йосыфлар да Диния нәзарәтенә барып киләләр.

Уфадан Нижнийгә баргач, Мәкәрҗә ярминкәсенә тукталалар. Кибетләрне йөреп чыгалар, абзыйлары белән күрешәләр. Шунда Акчуриннар нәселенең байтагын күрәләр, бергәләп спектакль дә тамаша кылалар.

Кечкенә пароходта Касыйм (Ханкирмән) шәһәренә барып, Касыйм татарларына нисбәтләнгән бер мәчетне, ике төрбәне карыйлар. Шәһәрдә татарлар шактый була, тирә-ягындагы авылларның да байтагы татар була. Йосыфлар монда берничә атна якын-тирә авылларны гизәләр. Касыйм татарларының сәүдә итүенә, кунакханәләр тотуына, урысча һәм французча да укуларына гаҗәпләнәләр.

Касыймнан Сембергә һәм Зөябашына килеп мирасны бүлешкәндә, Йосыф үзенә истәлек өчен иске ук белән җәя, кылыч, гөрзи һәм сөңге кебек коралларны гына ала. Бу кораллар Йосыфка үзе укыган төрки дастаннарны хәтерләтә, аны шул әсәрләрдәге каһарманнарга охшарга дәртләндерә.

«Рәсәйгә сәяхәтемнән тәнемә күпме файда тисә, фикеремә дә шулкадәр, бәлки әле күбрәк тә файда алдым, — ди ул соңыннан хатирәләрендә. — Эшләүнең кирәклеген аңладым. Истанбулга кайткач укуда тырыша башлавымда бу тәҗир һәм төшенүнең катнашы булуына шөбһәм юк. Сыйныфка килер-килмәс әүвәл сүземне старшина һәм сержантларның кемнәр икәнлеген сораудан башладым. Шуны ачыклагач, эчемнән каты рәвештә: «Моннан соң старшина үзем булачакмын!» — дип карар кылдым.

Шул көннән аңарда ярышу, беренче булу дәрте уяна. Бәлки Рәсәйгә сәяхәтенең бер елга сузылуы аркасында элекке иптәшләреннән артта калуы да гайрәте уянуына сәбәп булгандыр. Тырышлыгы җимешен дә бирә: ул сыйныфны икенче сержант дәрәҗәсендә тәмамлый.

Хәрбиянең икенче курсында укыганда Йосыф котмәгәндә җәзага тартыла. Шуны узгач, Хәрбиянең икенче назыйры Риза паша аны чакыртып ала да, тырыш курсант булганы өчен генә укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирелүен, ләкин тагын шундыйрак эшләрдә катнашса, киләчәктә мәктәптән, һичшиксез, куылачагын катгый рәвештә кисәтә. Моннан соң Йосыф укуга бигрәк тә күңел бирә. Хәрбияне тәмамлагач ул әүвәл штаб хезмәтенә билгеләнә, аннары, яңадан сорау алынгач, хәрби трибуналга җибәрелә. Монда аны һәм башкаларны — барысы 84 кешене Траблус ягына сөрергә хөкем итәләр. Тоткыннар анда иске ныгытмага ябыла, ләкин озак утыртылмыйлар. Икенче Габделхәмит хәлиф белән «Яшь төрекләр» арасындагы аңлашуның бер матдәсе нигезендә коткарылалар. Йосыфның гаскәри дәрәҗәсе кайтарыла һәм ул штаб кәнсәсендә эшли, бригадада укыта да башлый.

Йосыфның болай эзәрлекләнүенә аның фикерләрен ачыктан-ачык сөйләп йөрүе сәбәп була. Хәлиф яраннары аның хакында да «чит илдәге «Яшь төрекләр» оешмасы белән бәйләнештә эш алып бармыймы икән бу?» дип шөбһәләнә. Әмма Йосыф Госманлы мәмләкәтен Европадагыча демократик яңарган дәүләткә әйләндерү өчен көрәшүче «Яшь төрекләр» белән бәйләнмәгән, ләкин төркиләрнең тарихтагы шанлы роле, аларның бүгенге кызганыч хәле турында уйланучы, әүвәлге дәрәҗәләрен кире кайтару өчен хөррият һәм тәрәккый кирәклеген аңлаучы, шул уйларын яшереп тормаучы бер егет була.

Бу дәвердә төрек матбугатында Нәҗип Асым, Вәләд Чәләби, Бурсалы Таһирларның мәкаләләре һәм бүтән әсәрләре басыла, аларда төркичелек мәсьәләләре күтәрелә. Йосыфның алардан илһам алуы шиксез. И. Гаспралы «Тәрҗеман»ы да Истанбулга килеп җитә. Бу төркичелек төшенчәләренә Урта Азия, Идел буе төркиләре укымышлылары фикерләре дә килеп кушыла. Тарихи ватанына ясаган яңа сәяхәтләре дә кайнар тәэсирләре белән рухын ныгыта һәм төпле нигезгә утырта. Кырымда Бакчасарайга кереп, җизнәсе И. Гаспралы, Казанда татар янарыш хәрәкәте вәкилләре Ш. Мәрҗани, Г. Баруди, К. Насыйрилар белән күрешүләр дә аңа нык йогынты ясый. Абзыйларыннан Ибраһим Акчураның бай китапханәсендә казыну, аның белән бәхәсләшүләр дә аңында якты эз калдыра. Й. Акчура көнбатыш телләре белән бергә иске һәм яңа төрки телләрне дә белә, укый һәм яза торган шәхес була.

Й. Акчураның беренче иҗади хезмәте төркиләрнең ике тармагын бер-берсенә танытуга, госманлыларны (төрекләрне) Ш. Мәрҗани тормышы һәм эшчәнлеге белән таныштыруга багышлана һәм ул «Мусаввар мәгълүмат» гәзитендә (11.II.1897) дөнья күрә. Бу мәкалә 1915 елда нәшер ителгән Мәрҗани мәҗмугасында да басыла. Ләкин К. Насыйри хакындагы мәкаләсе нәшер ителми кала.

1899 елда Йосыф меңбашы Шәүкәт бәй ярдәмендә ике иптәше — Әхмәт Фәрит һәм Зөһте әфәнде белән сөргеннән Туниска качалар һәм, белем алуларын дәвам итәр өчен, Парижга килеп урнашалар. Монда ул беренче очраткан кешеләреннән Шәрәфетдин Мәгъмүмине мактап телгә ала, аның Госманлы дәүләте киләчәге хакындагы фикерләреннән илһамлануы турында ачыктан-ачык белдерә.

Йосыф монда Сәяси белемнәр ирекле мәктәбенә язылып, А. Сорель, Э. Боутми, А. Лерой-Беаулео, Т. Функ-Брентано кебек танылган укытучылардан сабак ала. Сәясәттән тыш, фәлсәфә, социология, тарих һәм филология белән дә якыннан кызыксына һәм Сорбоннаның төштән соңгы дәресләренә дә йөри, Садрый Максудый белән бергә Дуркһайм, Левий-Бруһл, Сайгнобс һ. б. галимнәрнең лекцияләрен тыңлыйлар. Йосыфның көньяк һәм төньяк төркиләре хакында туплаган белеменә һәм тәҗрибәләренә, төрки мәдәният тарихына баглы әсәрләрдән үзләштергәненә Европа фәне дөньясыннан казанганны да кушкач, аның күзаллаулары тагын да киңәя һәм тирәнәя, тагын да анакланa төшә, бу аңа милли хискә (миллияткә) һәм төркичелеккә баглы фикерләрен, уйларын, Париждагы сабаклары тәмамланмас борын ук, тормыш мәйданына чыгарырга, иҗтимагый һәм сәяси эшчәнлектә актив катнаша башларга мөмкинлек бирә.

Парижда белемен күтәреп йөргән чакта Йосыф мондагы «Яшь төрекләр» мөхите белән дә аралаша, шул нигездә беркадәр мәкаләләр дә бастыра. Әхмәт Риза тарафыннан чыгарылган «Шураи өммәт» гәзитендә басылган төрекчә мәкаләләре һәм «Мәшвәрәт» гәзитендә чыккан французча язмасы — шулар җөмләсеннән. Төрекчә мәкаләләре соңыннан аерым җыентык рәвешендә (Истанбул, 1913) дә дөнья күрә. Анда кергән мәкаләләрдә Шәрык тормышы, урыс революциясе һ. б. мәсьәләләр яктыртыла.

Хокук белеме алыр өчен 1902 елда Казаннан Парижга килгән Садрый Максудый, Фатыйх Кәрими хатын тапшыру өчен, Й. Акчураны эзләп таба. Шулай башланган танышлык дуслыкка әйләнә һәм Йосыфның вафатына кадәр дәвам итә.

Студент дәверендә иң мәртәбәле уртак эшләре И. Гаспралының «Тәрҗеман»ына 20 ел тулуны бәйрәм итүгә житәкчелек кылу була. Беркөнне Йосыф жизнәсе Исмәгыйльдән алган хаттан «Тәрҗеман»га тиздән 20 яшь тулачагын белә һәм бу хакта Садрыйга:

— Мәдәни милләтләр моның юбилеен уздырыр иде,— ди.

— Без дә уздырыйк! — ди Садрый.

Бергәләп эшкә керешәләр — җәмәгатьчелекне кузгату өчен бер хат әзерлиләр. Аннары шуны типографиядә күбәйтеп, йөзләп кешегә җибәрәләр, ниятләрен Гаспралыга да хәбәр итәләр.

27 сәхифәлек нәни бу брошюра И. Гаспралы һәм «Тәрҗеман» файдасына шактый эш башкаруга китерә — 1903 елның язында Бакчасарайда күп тарафтан килгән вәкилләр катнашында бер юбилей тантанасы уздырыла.

«Бу тантана Рәсәй төркиләренең әүвәлге милли корылтае төсен алды,— ди соңыннан С. Максудый.— Бу жыелышта төрле губерналардан килгән зыялылар беренче мәртәбә Рәсәй төркиләренә кагылган милли мәсьәләләр — милли мәдәниятне яшәтү һәм царизмның урыслаштыру сәясәтенә каршы көрәш чаралары хакында киңәшергә керештеләр. «Тәрҗеман» юбилее Рәсәй төркиләренең милли уянуы тарихында урын алган күренекле бер вакыйга булды. Кайбер нәни, тыйнак тырышлыктан мөһим нәтиҗәләр туа. Безнең Йосыф бәй белән әүвәлге уртак эшебез дә шундый бер тырышлык булып чыкты: ватаннарыннан еракта яшәгән ике студентның бер хәрәкәтеннән милли корылтай барлыкка килде һәм бу корылтайдан соң Рәсәй төркиләренең миллиятләрен (милли хосусиятләрен, үзенчәлекләрен) саклау юлында оешкан бер сүрәттә көрәш дәвере башланды. Бу беренче корылтайга бер-бер артлы башкалары ялганып китте».

Йосыф 1903 елда Парижда белем алуын тәмамлый һәм «Госманлы императорлыгына нигез салучылар тарихы» исемле бер хезмәт («тәҗрибә») язып, өченче дәрәҗә диплом яклый. Акчура бу хезмәтенең керешендә Госманлы дәүләтенә нигез хезмәте күрсәткән төрки һәм ислам хокук кануннары хакында кыскача белешмә бирә, төп өлешендә исә иске һәм яңа тәртип дип икегә аерылган Госманлы хакимнәре тарихының төп билгеләрен ачыкларга тырыша. Соңгы өлешендә Госманлы императорлыгын таркалудан саклау оешмаларына, көчләренә нинди үзгәреш һәм үсеш файдалы булачагын бәян итә. Бу әсәрнең шул заман сәясәтендә миллият мәсьәләсенә карашны мәйданга чыгару җәһәтеннән зур әһәмияте бар.

Госманлы дәүләте чикләре аңа ябык булганлыктан, Йосыф Париждан туптуры Казанга кайта һәм Акчуралар тамыр җибәргән Зөябашы авылында яши башлый. Бу дәвердә казан татарлары арасында яңарыш хәрәкәте җанлана — күп кенә нәшриятләр ачыла, китаплар басыла. Әмма урыс хөкүмәте татарларга вакытлы матбугат чыгаруда күп киртәләр куя. Шуңлыктан Й. Акчура язган мәкаләләрен Рәсәй һәм Төркия тышындагы басмаларга җибәрергә мәҗбүр була.

Зөябашында яшәгәндә ул 1904 елда Каһирәнең «Төрек» газетендә (№ 24, 25, 26) «Өч тарзы сәясәт» («Өч төрле сәясәт») мәкаләсен бастырып чыгара. Мәкалә соңрак, Г. Камал, Ә. Фәрит тарафыннан бирелгән җаваплар белән берлектә, Каһирәдә (1907), Истанбулда (1911) һәм Анкарада (1976) аерым җыентык рәвешендә дөнья күрә. «Төрек» газетенең баш язучысы Гали Камал «Җавабыбыз» дигән язмасында Йосыф мәкаләсенә салынган фикерләргә, аңлатмаларга җавап бирә. Шулчак Йосыфның Мисырда яшәгән иптәше Әхмәт Фәрит тә, теманы тирәнәйтеп, кайбер фикерләрне куәтләп, кайберләрен кире кагып чыгыш ясый.

Й. Акчураның иң әһәмиятле әсәре булган «Өч тарзы сәясәт»тә төркичелек мәсьәләсе сәяси мәйданга беренче мәртәбә бөтен ачыклыгы белән чыгарыла, Госманлы дәүләтенең барачак һәм барырга тиешле сәяси юлы: госманчылык, исламчылык, төркичелек принципларының уңай һәм тискәре яклары тикшерелә.

Кайбер Көнбатыш авторлары «Өч тарзы сәясәт»нең төркичелек тарихында тоткан урынын бөтен социаль хәрәкәтләр белән чагыштырып: «Бу мәкалә марксистлар өчен Коммунистик манифест ни булса, пантюркистлар өчен шулдыр» (Зареванд. Турция и пантуранизм. Париж, 1930, бит 42), диләр. Америка язучысы Ч. В. Һостлер да: «Бу мәкалә, марксистлар өчен 1848 елгы Коммунистик манифест уйнаган роль кебек, уңышлы булды. Бу җәһәттән Акчураулы, төрки берлек фикерен нигезләүчеләрнең берсе буларак карала» («Туркен унд Совете Франкфурт-Берлин, 1960, бит 176).

1904—1905 елларда башланган революцион хәрәкәт царизм режимын азчылык милләтләрне изү сәясәтен бераз йомшартырга, конституцион идарә кертергә мәҗбүр итте. Рәсәйдәге революция һәм фетнәләргә китергән идарә һәм икътисад кризисының асыл сәбәбе, һич шөбһәсез, урыс-япон сугышы һәм Япониянең Рәсәйне авыр бер җиңелүгә дучар итүе иде.

1894—1895 елларда Япония Кытайны җиңгән һәм Кытай Кореяны, Ляодун ярым утравы белән Порт-Артур лиманын Япониягә бирергә мәҗбүр булган иде. Хәлбуки, Франция һәм Алмания белән сүз берләшкән Рәсәй бу җирләрне үзенә алырга тели иде. Шул максатта ул 1904 елда Япония белән сугыш башлады. Тик коры җирдә дә, диңгездә дә зур җиңүләргә ирешкән Япония гаскәре һәм хәрби флоты һәр яктан дошманыннан өстен икәнлеген күрсәтте.

Рәсәйнең төрле шәһәрләрендә җәелгән болганыш, эш ташлау һәм сәяси митинглар патша хөкүмәтен сугышны беркадәр әүвәлрәк бетерергә мәҗбүр итте. Ниһаять, АКШ арадашлыгында Портсмутта (23.VIII.1905) Япония белән Рәсәй арасында килешү төзелде: Сахалин утравының яртысы, Маньчжурия, Корея, Порт-Артур белән Ляодун ярымутравы да Япониягә тапшырылды.

Рәсәй шундый мөшкел хәлдә калганлыктан, патша сенатка юллаган бер фәрманы (12.XII.1904) белән җыелышлар хөррияте һ. б. кайбер ирекләрне игълан итте. Мондый форсатны зарыгып көтеп алган татарның алдынгы зыялылары Казан шәһәрендә бер җыйналыш (28.1.1905) уздырдылар. Җитмеш кеше катнашкан бу җыелышның максаты хөкүмәткә дини һәм милли таләпләрне белдерү өчен әзерлек күрү һәм шуңа бәйле мәсьәләләрне тикшерү иде. Зөябашыннан Казанга килеп урнашкан Й. Акчура бу җыелышта актив катнаша һәм баш рольне уйнаучыларның берсе була. Фикер алышу нәтиҗәсендә мөселман төрек-татар таләпләрен Рәсәй хөкүмәтенә белдерү өчен дүрт кешелек бер комиссия сайлана һәм аңа рәсми кәгазь әзерләү йөкләнә. Комиссиягә С. Алкин, Г. Апанаев, Ә. Сәйдәшевтан тыш, Й. Акчура да кертелә.

Мөрәҗәгатьнең кереш өлешендә патша хәзрәтләренә яхшатлану чагыла. Төп өлешнең тугыз матдәсендә дини мәсьәләләр күтәрелә. Уфа шәһәрендә эшләгән Мөселман диния нәзарәтенең башына Рәсәй хөкүмәте тәгаенләгән мөфтинең мөселманнар тарафыннан сайлануы таләп ителә. Калган матдәләрдә (пунктларда) гәзит-журнал һәм китаплар басу, аларны иркен тарату, шәхси мәктәп-мәдрәсәләрнең һәр җирдә ачылуы һәм аларның рәсми мәктәпләр белән бер үк хокукка ия булуы, мөселманнарның тиң гражданлыгы танылуы, мөселманнарга Рәсәйнең һәр җирендә күчерелми торган милеккә ия булу һәм ирекле сәүдә итү хокукы бирелү, бу тармактагы чикләүләрнең бетерелүе, җәмгыять тормышында ирекле сайлау һәм синдикатларга катнашу хокукы танылуы кебек үтенечләр һәм таләпләр була. Соңгы матдәдә, югарыда саналган мәсьәләләр буенча яңа кануннар әзерләнсә, мөселманнарның комиссияләр корып, киңәш бирү рәвешендә хөкүмәткә ярдәм итәргә әзер торулары белгертелә.

Й. Акчураның 1904 елда ватанына кайтуы вакытында Рәсәй эчендәге төрки өлкәләрдән аеруча Идел-Уралда милли мәдәниятне үстерү, яңаруны кайгыртучы яшь һәм куәтле көчләр барлыкка килә. Й. Акчураның бу хәрәкәткә ничек катнашуын сүрәтләгәнче, аларның һич югы кайберләрен телгә алырга кирәктер. Рәсәйдә 1906 елның апрелендә Дәүләт Думасы сайланганга кадәр төрек-татар сәяси һәм иҗтимагый хәрәкәтләрендә юл ярып баручыларның берсе, һич шөбһәсез, казый Габдерәшит Ибраһим булды.

1900 елларда Петербургта матбага нигезләп, «Мирьат» исемле бер журнал чыгарган Г. Ибраһим бөтен мөселман илләрен йөреп чыккан һәм японнарны мөселманлаштыру өчен бу мәмләкәткә дә берничә мәртәбә барган иде. 1904 елда Истанбулда яшәгәндә Рәсәй полициясе тарафыннан кулга алынып Одессага китерелсә дә, һәр тарафтан яуган протест һәм матди ярдәмнәр аркасында патша хөкүмәте аны тиздән иреккә чыгарырга һәм кабат Петербургта урнашуына рөхсәт бирергә мәҗбүр була. Габдерәшит Ибраһим 1904 елның соңнарында Эчке эшләр министры С. Мирскийга кереп, мөселман халкы таләпләрен хөкүмәткә рәсми белдерү мөмкинлеген ачыклаганнан соң, Идел-Уралның һәм Көнбатыш Себернең алдынгы вәкилләре белән күрешү өчен сәяхәткә чыга. Казан, Чистай, Бубый, Пермь якларыннан Уфага бара. Монда Диния нәзарәте казыйлары һәм Б. Әхтәмов, К. Тәфкилев, Ш. Сыртлановлар белән фикер алышканнан соң, Троицкига килеп, Вәли бай Яушев һәм Хаҗиәхмәт Рахманкол белән күрешә. Соңрак Кызылҗар шәһәренә бара һәм андагы җыелышларда да фикер алыша. Бу сөйләшүләрнең бер нәтиҗәсе буларак Петербургка мөрәҗәгатьләр ява башлый. Мәсәлән, Х. Рахманкол 1904 елның декабрендә Троицк мөселманнары исеменнән Петербургка килеп һәм Эчке эшләр министрына кереп, таләпләр язылган хатны

калдыра. Кызылъяр мөселманнары да урысча бер үтенеч язып, баш министр Виттегә җибәрәләр. Шунын өстенә Габдерәшит Ибраһимны да үзләренең вәкиле итеп Петербургка юнәлтәләр.

Габдерәшит Ибраһим 1904 елның башында тагын Казанга килә. Монда башта Б. Әхтәмов, Й. Акчура, һ. б. яшьләрдән бер төркем Й. Акчура өендә агымдагы хәлләрне тикшереп, Казанда зур бер җыелыш уздырырга килешәләр. Җыелышны әзерләү Й. Акчурага тапшырыла. Йосыф иртәгәсен Галимҗан Баруди, Әхмәт бай Хөсәенов һ. б. алдынгы фикерле затларны күреп, илле-алтмыш кеше катнашачак мәҗлескә әзерлек эшләрен тәмамлый һәм бу җыелыш Әхмәт бай өендә (28.1.1905) үткәрелә. Алдарак телгә алынган мөрәҗәгать менә шунда кабул ителә һәм Витте исеменә почта аша җибәрелә.

Милли һәм иҗтимагый хәрәкәтләрнең һәммәсенә дә катнашып, дини мәсьәләләрнең куелуына этәргән шәхесләрнең берсе — Муса Ярулла Бигиев (1875—1949) була. Аның янә бер мәртәбәле хезмәте бу киңәшмәләргә бәйле беркетмәләрне, карарларны туплап саклавы һәм хәрәкәтнең тарихын язуы иде. М. Я. Бигиевнең бу җәһәттән иң уңышлы әсәре — «Ислахат әсаслары» («Реформа нигезләре». Петроград, 1915) китабы. Шунда ул 28 гыйнвар мәҗлесе турында: «Җанлы фикер алышулар, карар кабул итүләр юлбашчыларны өметләндерде. Иртәгәсен Рәшит, Йосыф кебек житәкчеләр тупланып, гамәл даирәләрен киңәйттеләр. Петроградта гомум Рәсәй мөселманнары исеменнән бер корылтай уздыру өчен, Кырым, Кавказ, Казагыстан, Төркестан мөселманнарына чакыру җибәрү карарын да кабул иттеләр,— дип яза.— Йосыф әфәнде Акчура мәҗлеснең карарын бәян итеп, мөхтәрәм Исмәгыйль бәк Гаспралы, Галимәрдән бәй Топчыбашов җәнапләренә мәктүп язды һәм март аенда Петербургка килүләрен үтенде».

Җыелуның махсус көне тәгаенләнмәгәнлектән, чакырылган затлар төрле вакытта юлга чыга, шуңлыктан Петербургта гомуми җыйналыш булмый кала. Әмма шул аерым-аерым күрешүләрдә «Бөтен Рәсәй мөселманнары корылтаен» 1905 елның августында Нижний Новгородта үткәрү ниятләнә.

«Рәсәй мөселманнарының беренче корылтае», губерна хакимнәреннән рәсми рөхсәт алынмаганлыктан, бер пароходта су өстендә үткәрелә. Анда төрле төрки өлкәләрдән 120 ләп вәкил катнаша. И. Гаспралы, «Тәрҗеман»ына хөрмәт йөзеннән, рәис буларак сәяси юлбашчылыкны үзенә ала. Г. Топчыбашов һәм Й. Акчура фикер һәм идеология нигезләрен эшлиләр. Моннан алдагы җыелышларда бәхәс ителгән һәм өлешчә әзерлек алып барылган «Мөселманнар өчен сәяси һәм иҗтимагый иттифак (берлек, партия) кирәклеге» мәсьәләсе күрешүнең беренче матдәсен тәшкил итә. Моңа таянып, «Мөселман иттифакы» партиясенең уставы Петербургта (12—23.1.1906. Икенче.) һәм Нижний Новгородта (16—20.VIII.1906. Өченче.) үткәрелгән корылтайларда төзәтмә һәм өстәмәләр белән раслана.

Оешуына һәм эшчәнлегенә Й. Акчура күп көч түккән «Мөселман иттифакы» партиясе 1 һәм 2 Думага сайлауларда уңышлы катнаша һәм төрки депутатлар сайлануга зур йогынты ясый. 1 Дума депутатларының яртысы, 2 Думадагы 34 мөселманның унбише казанлы була. 2 Думаны куып тараткач, мөселман депутатлар саны бик нык кими, төркестанлылар сайлау хокукыннан гомумән мәхрүм ителә. 3 Думага 10 мөселман сайланып, шуларның җидесе казанлы була.

Й. Акчура эшчәнлеген якыннан күзәткән царизм ялчылары, Думага сайлануына комачаулау максатында, аны 1906 елның 8 мартында өенә басып кереп кулга алалар һәм сайлау узганчы 43 көн төрмәдә тоталар. Аның «Тоткынлык хатирәләре» әсәре шушы мөнәсәбәттән языла (Оренбург, 1907; Истанбул, 1914).

«Мөселман иттифакы» Үзәк Идарәсе әгъзалыгына һәм секретарьлыгына сайланган Й. Акчура Казанның Мөхәммәдия мәдрәсәсендә тарих, география, госманлы төрек әдәбияты укытуын да дәвам итә. 1905 елның 29 октябрендә «Казан мөхбире» гәзитен чыгарттыра башлый һәм анда мөхәррир вазыйфасын башкара. Аның «Гыйлем һәм тарих» әсәре Мөхәммәдиядә укыткан тарих дәресләренең бер нәтиҗәсе рәвешендә дөньяга килә (Казан, 1906).

Й. Акчураның 1907—1908 елларда Рәсәйнең төрле тарафларына, Көнбатыш Европага һәм Мисырга сәяхәт итүе, 1909 елда ватанына әйләнеп кайткач, берничә ай Петербургта калуы һәм аннан Берлингә китүе хакында төрле чыганакларда әзме-күпме хәбәр бар. Шул сәяхәтләр нәтиҗәсендә «Вакыт», «Тәрҗеман», «Шура» гәзит-журналларына язган мәкаләләре буенча да аның йөргән юлларын өлешчә күзалларга мөмкин.

Г. Баттал-Таймас «Й. Акчура белән күрешүләрем» истәлегендә: «А) 1905—1908 еллар арасында... мин Каһирәдә булган көннәрдә Й. Акчура да шунда килде,— дип яза.— Шулчак бер шәкерт якташыбыз бүлмәсендә берничә кеше

тупланып, аның белән дусларча әңгәмә корып утырдык. Бу минем Акчура белән беренче мәртәбә күрешүем иде. Парижда белем алган бу чибәр һәм укымышлы якташыбыз бездә шундый әйбәт тәэсир калдырды ки, мин аның хакында «Әл-Мокатдәм» газитендә кыска бер хәбәр дә язып бастырдым. Моннан максат — аны мисырлыларга да таныту, якташларыбыз арасында мондый камил яшьләрнең дә булуын күрсәтеп, бераз горурлану иде. Б) 1908 елның җәй башында «Муса Габдулла» кушаматы астында Рәсәйгә кайткан чагымда Бакчасарайда очрашканда, «Тәрҗеман»ның 25 еллыгын котладык. Й. Акчура да анда иде... Банкетта Акчураның газит хуҗасы мәшһүр Исмәгыйль бәк Гаспралыга мөрәҗәгать итеп, гүзәл һәм эчтәлекле бер нотык сөйләвен, бу нотыгында «Тәрҗеман»ның 25 ел эчендә Рәсәй төркиләренә күрсәткән хезмәтен санап чыгуын бик яхшы хәтерлим. Соңыннан аңлавымча, 1905 ел революциясе коннәрендәге эшчәнлеге өчен патша хөкүмәтенең эзәрлекләвенә очраганнан соң, Акчура анда бер төрле йомык тормыш кичергән икән. Тантана тәмамланганнан соң мин Оренбургка киттем, Акчура исә Бакчасарайда калган иде. Оренбургтан Троицкига килгәч, Төркиядә булган июль түнкәреше хакында ишеттем. Бу түнкәреш нәтиҗәсендә Төркиягә бару мөмкинлеге тугач, Акчураның шул елның октябрендә Истанбулга юл тотуын югарыда әйтеп уздым («Бән бер ышык арыюрдум». Истанбул, 1962. Бит 128—129).

Й. Акчураның «3 июнь монсу вакыйгасы» исемле әсәре, Рәсәйдәге бөтен төрки һәм мөселман хәрәкәтенең рәхимсез дошманы булган шәркыятьче һәм цензор профессор Смирнов тарафыннан «матбугат канунына каршы килә» дип бәяләнеп, прокурорга хәбәр ителә һәм язучыны эзәрлекләү чаралары күрелә. Акчура ул вакытта, докторларның киңәше буенча, Кырымга күчеп килә, Бакчасарайда җизнәсенең «Тәрҗеман» газитендә эшли башлый. Эзәрлекләү повесткасы аны эзләп тапканчы, Төркиядә конституция кабул ителү хәбәре килеп ирешә. Шуннан соң Йосыф, вак-төяк эшләрен тиз генә тәмамлап, 1908 елның октябрендә Истанбулга китеп бара.

Төркиянең конституцион идарәгә күчүе төркичелекнең формалашуына һәм төркиче җәмгыятьләрнең корылуына киң мөмкинлекләр ача. Абсолютизм дәверендә һәртөрле җәмгыятьләр, аеруча миллият нигезендә тәшкиләтләр корырга хөкүмәт асла рөхсәт бирми иде. Шулай да мөселман һәм төрки булмаган гражданнарның миллият нигезенә таянган үзара ярдәмләшү һәм әдәби битлекләр астына яшерелгән байтак җәмгыятьләр барлыкка килгән була.

Төрек теле һәм тарихы буенча алып барылган тикшеренүләрнең бер нәтиҗәсе буларак, унтугызынчы йөз уртасыннан башлап Госманлы дәүләтендә дә «гыйльми төркичелек» хәрәкәте көчәя башлый. Бу тикшеренүләр Госманлы императорлыгыннан тышта — Азия һәм Европаның байтак өлкәләрендә төркиләр яшәвен күрсәтә. Аларның үз тарихы бар, алар да төркичәнең берәр телендә-шивәсендә сөйләшә иде. Төркичелекнең гыйльми тикшерелүендә, табигый ки, сәяси чикләр киртә була алмый, дөньяның төрле тарафында һәм төрле сәяси чикләр эчендә яшәвенә карамастан, төрки кабиләләрнең теле, тарихы, сәнгате үзенә генә хас бер кыйммәт буларак тикшерелә иде. Элек университет яки аның тышындагы фәнни үзәк галимнәре тарафыннан башкарылган мондый эшләр мәгълүм мөхит һәм төркемнәр эчендә генә чикләнеп калса, конституция дәверендә бу темаларны өйрәнү нәтиҗәләрен җәмгыятьләр аша халыкка житкерергә юллар ачылды.

Бу вакытта Й. Акчура берничә айга кабат Рәсәйгә, аннан Алманиягә китүен күрәбез: 1909 елда ул беркадәр вакыт Петербургта кала, фәкать көткән сәяси үсешне күрмәгәч, декабрь аенда Берлиндәге зур татар сәүдәгәрләре белән элемтә урнаштыра. 1910 ел башларында тагын Истанбулга китә. Шушы дәвердә аның «Тәрҗеман» газитендә Петербургка һәм Берлингә кагылышлы мәкаләләре кушамат имза белән басылып чыга. Аларда төрки халыклар язмышы өчен җанаткан Й. Акчураның сәяси эзләнүләре өлешчә чагылып кала.

1908—1912 елларда корылган төреклеккә һәм төркичелеккә бәйләнешле җәмгыятьләрдән «Төрек җәмгыяте түгәрәге» (25.XII.1908), «Төрек йорты җәмгыяте» (18.VIII.1911), «Төрек учагы җәмгыяте» (12.III.1912), «Төрек белем җәмгыяте» (14.III.1913) кебек тәшкиләтләрнең һәрберсендә Й. Акчураны нигез салучылар арасында күрәбез. Ул бу җәмгыятьләрнең һәйәтләренә (комиссияләренә), идарәләренә кереп, барлык оештыру һәм гыйльми тикшеренү эшләрен төпкә җигелеп башкара. Ләкин аның иң күп көче һәм сәләте «Төрек йорты җәмгыяте»н яшәтүгә сарыф ителә. Бу җәмгыятьнең органы булган «Төрек йорты» журналы 1911 елдан 1917 елга кадәр Й. Акчура мөхәррирлегендә чыгарыла.

Й. Акчура 1908 елда Истанбулга килгәч, мәктәп елларындагы сабакташлары Нәҗип Асым белән Вәләд Чәләбине эзләп табып, аларга мәдәни эшләр белән шөгыльләнергә тиешле бер төрки җәмгыять кору уен сөйләп бирә һәм сабакташларына бу эштә юлбашчы булуны тәкъдим итә. Тиздән 14 кеше Мөлкия мәктәбе мөдире Җәлал бәй кабинетында тупланып, «Төрек йорты җәмгыяте» исемендә бер тәшкилат корырга карар бирәләр. Җыйналган укымышлылар арасында мәшһүр язучы һәм мәгърифәтче Әхмәт Мидхәт һәм татар романына нигез салучы Муса Акъегетзадә дә була.

Бу җәмгыятькә чит ил тюркологлары да әгъзалыкка кабул ителә. 1912 елның октябренә кадәр 63 әгъза теркәлә. Алар арасында без шагыйрь Мәхмәт Әмин, Исмәгыйль Гаспралы, әдәбиятчы Фуат Күпрүле һ. б. эшлекләрне күрәбез. Җәмгыять идарәсенең беренче рәисе итеп Фуат Раиф, беренче кятибе (секретаре) итеп Йосыф Акчура сайлана.

Җәмгыятьнең максаты... бөтен төрки кавемнәрнең үткәнен һәм хәзергесен, гамәлләрен, мөхитен өйрәнергә тырышу, ягъни төркиләрнең борынгы тормышын, тарихын, телләрен, халык авыз иҗатын һәм язма әдәбиятын, этнографиясен һәм этнологиясен, иҗтимагый һәм мәдәни хәлләрен, төрки мәмләкәтләрнең борынгы һәм хәзерге географиясен өйрәнү-тикшерү, аны бөтен дөньяга таныту, телебезнең ачык, садә, гүзәл гыйлем теле булу сүрәтендә баюына хезмәт итү, язуын да шуңа баглы тикшерү»,— диелә уставында.

«Төрек йорты» журналын чыгаруга рөхсәт шагыйрь Мәхмәт Әмин исеменнән алына, ул 1911 елның 18 августында теркәлә. Нигез салучы алты кеше арасында Йосыф Акчураны да күрәбез.

Мәхмәт Әмин 1911 елның августында губернатор итеп Эрзурумга җибәрелгәч, журналның хуҗасы һәм мөхәррире вазифасы «Төрек йорты җәмгыяте» рәисе итеп сайланган Й. Акчурага йөкләнә.

Журналның беренче саны 1911 елның ноябрь аенда басыла. 1912 елның октябреннән алып 1913 елның ноябренә кадәр Йосыф Чаталҗа фронтында сугышта йөргәнлектән, журналның 3 һәм 4 томнары вакытлыча Мәхмәт Әмин тарафыннан чыгарыла. Әмма 5 томнан Й. Акчура мөхәррирлекне кабат үз өстенә ала. Фәкать XII томның 12 санын (2.VIII.1917) чыгарганнан соң гына аннан бөтенләй аерыла.

Й. Акчура 1913 елның июлендә Чаталҗа сугышыннан кайткач, Сүриягә һәм Хиҗазга китә һәм дүрт ярым ай дәвам иткән шушы сәяхәте вакытында хаҗ кылу ниятен дә үти.

«Төрек йорты» журналының уставы һәм программасы Й. Акчура тарафыннан әзерләнә һәм кайбер үзгәртүләр белән редколлегиясе тарафыннан кабул ителә. Программаның кайбер матдәләре түбәндәгечә билгеләнә:

1. Журнал төрки кавемнәрнең мөмкин кадәр күбесе тарафыннан укып аңларлык, файда күрерлек бер дәрәҗәдә язылачак; а) теле гади булачак; б) күпчелеккә файдалы темалар яктыртылачак; в) читен, катлаулы мәсьәләләр җинел аңлашылсын өчен тырышылачак.

2. Журнал төркиләргә кулай уртак бер идеал яратуга хезмәт итәчәк.

3. Журналда төркиләрнең үзара танышуларына, икътисадый һәм әхлакый күтәрелүләренә, фәнни мәгълүматлары баюына хезмәт итәчәк темалар төп урынны алачак, сәясәт болардан соң киләчәк.

4. Төркиләрнең үзара танышулары өчен кардәшләр дөньясының һәр тарафында булып узган, аларда шатлык яки кайгы җәелүгә этәргән вакыйгаларга, төрки дөньяның үткәнендә-бүгенгесендә барлыкка килгән фикер агымнарына игътибар биреләчәк һәм кардәшләрнең төрле кавемнәрендә туган әдәбиятны бүтәннәренә танытуга хезмәт кылыначактыр.

5. Журнал Госманлы дәүләте эчке сәясәтен телгә алганда һичбер партия мәнфәгатенә тарафдарлык күрсәтмәячәк, бары гомум төркилекнең сәяси һәм икътисадый мәнфәгатен яклаячактыр. Бер төрки кавем мәнфәгатен яклаганда бүтәннәре арасында каршылыклар чыгарудан сакланып эшләячәк...

6. Журналның сәясәтендә төп кыйбла — төрки дөнья мәнфәгатен яклау.

Алда искәртелгәнчә, Й. Акчура 1908—1912 елларда төрек халкының алдынгы укымышлылары белән берлектә Төркияне, барлык төрки халыкларны өйрәнүче, аларны алга җибәрү өчен көрәшүче күп кенә җәмгыятьләргә нигез салуда, шуларның идарәләренә кереп, уставларын һәм программаларын төзүдә, иҗтимагый һәм мәдәни эшләрен оештыруда юлбашчыларның күренеклесе буларак дәртләнеп катнаша. Ул «Төрек учагы җәмгыяте»нең коручы һәйәтендә — икенче рәис, «Төрек белем җәмгыяте» («Төрек фәннәр академиясе») идарәсе әгъзасы итеп сайлана. Соңгысы алты бүлектән гыйбарәт булып, Й. Акчура

берьюлы икесендә — төркият һәм фәлсәфә-иҗтимагыять шөгъбәләрендә хезмәт итә.

Югарыда саналган тәшкиләтләрнең иң гомерлесе һәм күп файда китергәне — «Төрек учагы». Ул тиз арада Истанбулның иң җанлы, бөтен төрки яшьләр тарафыннан сөелгән бер иҗтимагый-мәдәни оешмага әйләнә. Төрки кавемнәргә милли тәрбия бирү, аларны белемле һәм мәдәниятле итү, икътисадый һәм иҗтимагый яктан алга җибәрү өчен «Төрек учагы» исемле клублар ачыла, аларда лекцияләр укыла, дәресләр бирелә, кичәләр уздырыла, һөнәрләргә өйрәтелә. Төрек учагы мәктәпләр ача, матбугат нәшер итә.

1917 елда «Төрек йорты» «Төрек учагы» белән бергә кушыла. 1920 елда дошман илләр белән вакытлы килешү дәверендә оккупация көчләренең, аеруча инглизләрнең эзәрлекләвенә дучар була: аның мәркәзе басып алынып, архивлары, китапханәсе һәм коллекцияләре талана һәм туздырыла. Шулай да кыйммәтле документларның байтагы фидакарь әгъзаларының өйләрендә яшерелеп коткарыла. Бөтен бу эзәрлекләүләргә карамастан, «Төрек учагы» сүнми-сүрелми, җөмһүрият дәверенә исән-имин килеп җитә.

Й. Акчура бу дәвердә әлеге җәмгыятьләрдә эшләүдән тыш, Хәрбия мәктәбендә, Ваизия мәдрәсәсендә һәм Истанбул дәрелфөнүнендә тарих укыта, яшь буынның дөрес юлда җитешүенә хезмәт итә. Шушы максатта еш-еш лекцияләр укый, болар мәкалә һәм брошюра төсендә басылып та чыгалар. Аның мәкаләләре Париж, Каһирә, Казан, Истанбул, Оренбург, Бакчасарай шәһәрләрендә дистәләгән газит-журналларда дөнья күрә.

Әнә шулай киң колачлы эшчәнлеге дәвам иткәндә, ул 1913 ел тирәсендә берара нindидер аңлашылмаучылык, интрига корбаны булып, Истанбул дәрелфөнүнендә укытудан читләштерелә. Төркиянең яңа хакимнәре арасында аны хөрмәт итүче һәм дус күрүче шәхесләр күп булганлыгын истә тотканда, бу серле хәлне бүген ачыклап бирү шактый кыен. Без бары Йосыф Акчураны яклап Халидә Әдипнең — күренекле язучының Җамал пашага мөрәҗәгать итүен, шуның нәтиҗәсендә Йосыфның Бөекада (утрау) диңгез лицеендә тарих укытучысы вазифасы бирелүен беләбез. Дусларыннан берсе шул утраудагы үзенең вилласында Йосыфка түләүсез торуны тәкъдим иткәч, Акчура Бөекадага ташына.

«Төрек йорты» журналындагы хезмәтен үтәү һәм кайбер җәмгыятьләр эшендә катнашу өчен Йосыфка еш-еш Истанбулга барып кайтырга туры килә. Көнен Истанбулга барып кайту өчен шактый акча туздырырга кирәк була. Укытучылык хезмәт хакы, шуңа анасы өен арендага бирүдән килә торган керемне кушкач та, бу чыгымнарны капларга җитеп бетми. Шундый мохтаҗ чакларда аны хөрмәт иткән иптәшләре, җөмләдән, татар докторы Ләбиб Каран ярдәмгә килә.

«Көннәрдән бер көнне остазны күрергә янә Бөекадага киттем,— ди ул.— Шул кичтә остаз «Иттихад вә тәрәккый» партиясеннән «Иртәгә сәгать унда килүегезне көтәбез» дигән бер телеграмма алган иде. Шул уңайдан Й. Акчура тирән уйга чумды һәм шактый озак чыраен сытып утырды. Билгесез хәбәр килсә, ул әүвәл аның начар якларын күзаллый һәм сәгатьләрчә шул хакта баш вата иде. Шушы партиягә кабулланмау ачысын кичергәнлектән, хәзер шуннан серле чакыру алгач, ул моны һич тә әйбәткә юрамады. Төне буе йокыга китә алмый җәфаланды, әллә кемнәргә хатлар язды. Бу чакыруның ахыры начар бетсә, ул утрауга әйләнеп кайтмаса, бер иш китапларын нишләтергә кирәклеген аңлатып, миңа гозерләрен әйтте. Күп кенә яшерен язулары тутырылган бер сандыгын тулаем миңа тапшырды... Фәкать, шөкерләр ки, миңа ул үтенгәннәрне эшләргә туры килмәде. Әлеге чакыру Әнвәр пашаның Йосыф Акчурага әһәмиятле бер сәяси вазыйфа бирүе уңаеннан җибәрелгән, имеш».

Й. Акчура Бөекадада яшәгәндә дә Рәсәйдәге милләтләрнең хәле һәм андагы төрки өлкәләрнең киләчәге турында иптәшләре, фикердәшләре белән киңәшеп тора, «Рәсәйдәге мөселман төрек-татар халыкларының хокукларын яклау комитеты» («Төрек-татар һәйәте») коруда катнаша. Бу эшләр шул заманның Төркия дәүләт эшлеклеләре тарафыннан да хуплана һәм Дөнья сугышы вакытында хәрби хәрәкәтләр белән бергә сәяси тырышлыклар кую да муафыйк булачагы аңлашыла, Й. Акчура Бөекададан чынлыкта шушы максат белән чакыртып алына. Җитәкчесе ул булачак бер комиссиянең әүвәл союздаш һәм дус дәүләтләр Алмания, Австрия, Мажарстан (Венгрия) һәм Болгарстанга китүе һәм соңра 1916 елның июнендә Швейцариядә тупланачак «Милләтләр конференциясе»нә катнашуы хуп күрелә.

Комиссия Европага киткәнче, кызыксынучы якларга тәкъдим итү өчен 1915 елның җәй айларында алманча ике документ әзерләнә. Аларның беренчесен

Й. Акчура яза, искәрмә рәвешендә әзерләнгән икенче документ комиссиянең калган әгъзалары тарафыннан төзелә.

«Рәсәйдәге мөселман төрек-татарларның бүгенге хәле һәм эшчәнлекләре» дигән 12 битле беренче документның эчтәлеге түбәндәгечә була: 1) Халык саны. 2) Халык артуы. 3) Иҗтимагый сыйныфлар. 4) Икътисадый эшчәнлек. 5) Мәгариф системасы һәм реформалар. 6) Әдәбият. 7) Урыслар изүе. 8) Цензура. 9) Халыкның сәяси хәле. 10) Төрек-татарларның теләкләре. Бу язмада Рәсәйдәге төрки кавемнәр (халыклар) алты бүлемдә тикшерелә: а) Татар-башкортлар — 7 миллион; б) Кыргыз-казакълар — 6 миллион; в) Төркестанлылар — 6 миллион; г) Төрекмәннәр — 1 миллион; е) Кавказ төркиләре — 3 миллион; ж) Кырымлылар — 0,5 миллион. Барысы — 23,3 миллион. Беренче документның басылган җире һәм тарихы күрсәтелмәсә дә, икенче документ белән бергә тәкъдим ителүеннән, аның да шул ук заманда Будапештта нәшер ителүе ихтимал.

«Рәсәйдәге мөселман төрек-татар халыкларының оештыру комитеты истәлек язуы» дип аталган икенче документ Будапештта 1915 елда «Нестер Ллойд-Геселшафт» матбагасында, 1916 елда исә «Ди велт дес исламс» журналында (IV. № 1—2, бит 33—43) басылып чыга. Бу меморандум 1916 елда Швейцариядә алманча һәм французча да дөнья күрә. Документны Й. Акчура, Г. Хөсәензадә, М. Ә. Чәләбизадә, М. Бәйҗаннар төзи.

Бу документта Рәсәйдәге төрки халыклар алты өлкә хәлендә тикшерелеп, сугышның ихтимал нәтиҗәсенә күрә, һәрберсенә хөррият һәм бәйсезлек бирелү таләп ителә. Бу документларда борынгы төрки ханлыклардан Кырым, Казан, Бохара, Хива шикелле, боларның яңадан тергезелүе хакында сүз алып барыла. Ул замандагы хәлгә күрә, тактик караштан моны табигый санарга кирәк, чөнки Төркия дә, союздаш илләр дә ул елларда император һәм корольләр тарафыннан идарә ителә иде.

Бу документларны Рәсәйдәге төрле халыкларның һәм өлкәләрнең хокукларын таныту һәм яклату өчен бары дус һәм союздаш дәүләтләргә генә түгел, тарафсыз (нейтраль) мәмләкәтләргә һәм, хәтта, дошман илләргә дә тапшыру күздә тотыла. Чөнки Рәсәйгә союздаш булган Англия, Франция һәм Италия милләтләрнең саклануын, аларның хокукларын яклануын һәм милли бәйсезлекләре тәэмин ителүен бу сугышның максаты итеп игълан итәләр.

Бу ике документның 1915 елның җәй айларында әзерләнеп, Будапештта бастырылганнан соң, комиссиянең сәяхәтеннән элек Австриягә һәм Алманиягә җибәрелүе һәм кызыксынучы якларга таратылуы аңлашыла. Й. Акчура җитәкчелегендәге һәйәт 1915 елның декабре башларында Кавказ, Төркестан, Кырым һәм Идел-Урал җирләрендә яшәүче төркиләрнең һәм мөселманнарның басып алынган хокукларын кайтару өчен, Софиядән башлап Будапештта, Венада рәсми һәм рәсми булмаган күп кенә югары дәрәҗәле эшлеклеләр белән очраша — комиссия һәр җирдә әйбәт каршы алына. Ул Австрия һәм Мажарстан хөкүмәтенең рәсми даирәләренә бер проект тәкъдим итеп, төркиләрне Рәсәй изүеннән коткаруны союздашлар белән бергә битараф дәүләтләр җәмәгатьчелегеннән дә таләп итәләр.

Й. Акчура һәм аның хезмәттәшләре 1915 елның 8 декабрендә Венада Австрия премьер-министры Сторгк һәм Тышкы эшләр министры Форгах тарафыннан кабул ителәләр һәм кунаклар хуҗаларга алда телгә алынган ике документны тапшыралар. Бу күрешү хакында телеграмма Копенгаген аша көне белән Петербургка барып җитә!

Аннары һәйәт Будапештка юнәлә, 12 декабрьдә монда премьер-министр Тисза, парламент рәисләреннән Андраси белән күрешеп, әлеге документларны тапшыралар. Шәркыятьче галим Месзарошның ярдәме белән, «Күлүгий-һалугий» журналында Рәсәй әсирлегендәге төркиләрнең теләкләрен гәүдәләндергән бер мәкалә һәм урыс кул астындагы җирләрдә корылуы тәкъдим ителгән дәүләтләрне күрсәткән бер карта да басыла.

Й. Акчура Мажар Фәннәр Академиясе залында Рәсәйдәге мөселман төрек-татарларның бүгенге хәлләре һәм теләкләре турында бер лекция укый. Һәйәт әгъзалары Будапештта төрле банкетларда Мажарстанның бүтән күп кенә күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре белән танышалар. Мондый кабул итүләрдә катнашулар сугышчы илләрнең матбугатында чагылыш таба.

Төркия хөкүмәте тырышлыгы белән җирлек әзерләнеп куелганлыктан, төрек-татар һәйәте Берлиндә дә әйбәт каршылана. Башта Тышкы эшләр министры Пагу, аның урынбасары Циммерман, сәясәт һәм гыйльми мөхитендәге, матбугат дөньясындагы рәсми һәм гайре рәсми бүтән затлар белән күрешеп, Рәсәйдәге мөселман төрек-татарларның хәлен ачыкларга, аларның киләчәге хакындагы

фикер һәм проектларын танытуга ирешәләр. Бу хәрәкәт һәм бәйләнешләр алман матбугатында да киң яктыртыла.

1916 елның 12 гыйнварында төрек-татар һәйәте хөрмәтенә Берлиндәге «Кунстлерһаус»та «Дюйтш-Азиатише геселшафт» тарафыннан бер җыйналыш уздырыла һәм анда Й. Акчура Рәсәй төркиләре хакында чыгыш ясый. Нотыгына нигез итеп алдарак таныштырылган ике документны ала. Аның чыгышын профессор Мартин Һартман төрекчәдән алманчага тәрҗемә итеп тора. Нотык зур игътибар бәлән тыңлана. Әлеге ике документ инде алдан ук алман матбугатында басылып чыккан була. Нотыкчыга сораулар бирелә. Лекция һәм Й. Акчура хакында алман матбугатында шактый хәбәр дөнья күрә.

Төрек-татар һәйәте кайту уңаенда Софиядә Болгарстан премьер-министры Радославов, парламент депутатлары, профессор Шишманов һ. б. укымышлылар тарафыннан кабул ителә, монда да хуҗаларга әлеге документлар тапшырыла.

Й. Акчура җитәкчелегендәге һәйәт 1916 елның июнь аенда Лозаннда туплаunionачак Милләтләр Берлеге (Лигасы) өченче конференциясендә катнашу өчен Швейцариягә китә. Бу юлы һәйәткә Казан татарларыннан Габдерәшит Ибраһим, үзбәк, казакъ, комык, чиркәс, әзербайҗан, дагыстанлылардан да вәкилләр кертелгән була.

Беренче Дөнья сугышы башларында союздашлар тарафыннан Парижда корылган Милләтләр Берлеге сәяси бер оешма булып, аеруча күп милләтле Австрия-Мажарстан һәм Госманлы империяларлыгына каршы юнәлтелгән таркату эшенең төп үзәге иде. 23 милләт нигезләгән бу Берлеккә соңрак «Рәсәй изелгән милләтләре берлеге» вәкилләре дә катнаша һәм шулай аның бер әгъзасына әверелгән «Төрек-татар һәйәте» дә керә. Милләтләр Берлеге утырышларында Франция, Англия һәм Италиянең союздашы булган Рәсәйгә каршы кискен һөҗүмнәр ясалганлыктан, нәтиҗәдә бу Берлек союздашларның үзләренә каршы эшли торган бер оешма хәленә керә.

1916 елның маенда Й. Акчура җитәкләгән төрек-татар һәйәте тарафыннан АКШ президенты Вильсонга «Рәсәйдәге изелгән милләтләрнең шикаятьләрен игътибарга алуын, аларны яклавын» таләп итеп бер телеграмма сугыла. Ул: «Безгә ярдәмгә килегез һәм безне юкка чыгудан саклагыз!» сүзләре белән тәмамлана. Бу мөрәҗәгать «Рәсәйнең изелгән милләтләр берлеге»нә берләшкән урыстан башка бөтен халыкларның шикаять һәм теләкләрен эченә алган зур документ фин, литва, латыш, поляк, украин һәм грузиннарның да катнашы белән 21 вәкил тарафыннан имзалана.

Шундый ук эчтәлектәге телеграммалар Англия, Франция, Италия һ. б. дәүләтләргә дә юлланып, «Рәсәй мөселманнарының танылуы» мөрәҗәгатендә дә була. Аннан элек 1916 елның 9 маенда Габдерәшит Ибраһим Стокһольмнан президент Вильсонга бер телеграмма җибәрә, шуннан аның Швециядә сәяси эшләр йөртүе һәм соңыннан Швейцариягә килеп һәйәткә кушылуы аңлашыла.

Милләтләр Берлегенең өченче конгрессы 1916 елның 27-29 июнендә Лозаннда туплана. Бу корылтайда төрек-татар һәйәте уртак бер мөрәҗәгать белән чыгыш ясамый, аның әгъзалары кавем-кабиләсе буенча төркемләнеп, аерым-аерым таләпләр куялар. Мәсәлән, «Татар, чагатай һәм кыргыз-казакъ өлкәләре меморандумы» исемендә бер брошюра конгресс барышында француз телендә Лозаннда бастырыла.

Й. Акчура 1916 елның июлендә Цюрихка китеп, Сиефельднең арадашлыгында, Ленин белән күрешә һәм аңардан Рәсәйдә революция уңыш казанган тәкъдирдә милләтләр мәсьәләсендә большевиклар тоткан юл нинди булачагын белергә тырыша, аңа үз мөрәҗәгатен дә бирә. З. В. Туганның бәян итүенә караганда, Ленин Йосыф Акчурага: «Без хакимияткә килсәк, Сез теләгән хокук артыгы белән тормышка ашырылачак», ди.

Й. Акчура 1917 елның җәй ахырларында «Госманлы Кызыл ай җәмгыяте» вәкиле буларак Скандинавиягә җибәрелә. Госманлы дәүләте Рәсәйдәге 60-70 мең дип фараз ителгән әсирләренә, анда урыс патшасының тәхеттән ваз кичүеннән һәм Вакытлы хөкүмәт корылуыннан соң, ярдәм оештырырга алына. Сугыш аркасында турыдан-туры мөнәсәбәтләр киселгән булганлыктан, дошман илендәге Госманлы гражданнары мәнфәгатен яклау эше Испания илчелегенә тапшырылса да, бу эш тиешенчә йөртелми.

Бу дәвердә, Рәсәй белән әсирләр алмашу эшен җайга салуга бәйле Копенгагенда уздырылган конференциягә Төркия хөкүмәте тарафыннан бер һәйәт җибәрелә, Й. Акчура да шуның белән бергә юлга чыга. Аңа бирелгән күрсәтмә буенча, Кызыл ай вәкиллегенең, шул исәптән, Й. Акчураның Скандинавиядәге вазыйфасы түбәндәгечә була: 1) Рәсәйдә булган госманлы хәрби әсирләре белән

хәбәрләшеп, аларның саннарын, кайда урнашуларын мөмкин кадәр төгәл белү, сәламәтлекләренә, ихтыяҗларына бәйле мәгълүматлар туплау. 2) Бу әсирләр белән гаиләләре арасында хәбәрләшүне көйләү. 3) Швеция һәм Дания Кызыл хачлары белән мөнәсәбәткә кереп, алар арадашлыгында Рәсәйдәге госманлы әсирләренә акча ярдәме, бүләкләр, китаплар һ. б. җибәрү. 4) Скандинавия юлы белән ватанга кайтучы әсирләрне каршылап, аларга иганә һәм бүләкләр өләшү.

Й. Акчура «Госманлы Кызыл ай җәмгыяте» вәкиле буларак Копенгагендагы әсирләр алмашу конференциясенә катнашканнан соң, Швециягә килә һәм бу конференциянең бер нәтиҗәсе буларак, Финляндия, Швеция һәм Алмания буйлап Төркиягә кайту өчен Рәсәйдән китә башлаган әсирләр кәрваннарын каршылап, һәрберсенә акча һәм бүләкләр өләшә.

1918 елның гыйнвары башларында Стокһольмдә чакта Й. Акчура Кызыл ай мәркәзеннән «Рәсәйгә китәчәк Госманлы миссиясе составына Кызыл ай вәкиле буларак катнашыгыз» дигән әмер-телеграмма ала һәм Берлиндә әлеге һәйәткә кушыла.

Й. Акчураның Рәсәйдә узган 14 айга якын вакытның яртысы Петербург белән Мәскәүдә, яртысы Идел-Урал буе шәһәрләрендә һәм авылларында уза. Петербургта һәм Мәскәүдә әсирләр алмаштыру шартларын яхшырту турында сөйләшүләрдә катнаша, Скандинавиядә башлаган эшен дәвам итеп, әсирләр хакында мәгълүматлар җыя, аларга булышырга керешә. Аеруча Рәсәйдәге мөселман-төрки халыклары арасында госманлы әсирләренә ярдәм мәсьәләсен мәйданга чыгарып, аларның игътибарын шуңа тартуга гайрәт күрсәтә.

1918 елның 3 мартында Госманлы һәйәте белән берлектә Й. Акчура катнашында Брест-Литовск килешүенә кул куелып, Рәсәй белән Алмания һәм аның союздашлары арасында солых төзелгәннән соң, илчелек комиссияләре дә Мәскәүгә килә башлый, әсирләрне ватаннарына кайтаруга күбрәк игътибар бирелә. Әмма бу эш гражданнар сугышы башлану нәтиҗәсендә, Идел-Уралда һәм Себердә зур кыенлык белән генә бара. Шунлыктан Й. Акчура 28 июльдә Казанга килә, монда 15 көн торгач, Сембер һәм Самара аша Уфага бара. Сугышучы якларның әле берсе, әле икенчесе тарафында хәвефләр кичереп, һәр җирдә төрек әсирләрен эзли, Швеция, Алмания, Австро-Мажарстан комиссияләре белән хезмәттәшлектә, аларны кайтару чараларын күрә.

Шул вазыйфаларын үтәгәндә, ул җирле милли юлбашчылар белән дә күрешә, 1904—1908 елларда бергә-бергә эшләгән эшләрнең дәвамын һәм нәтиҗәсен шул төбәкләрдә күреп ачыкларга тырыша. Аның Казаннан китүеннән соң узган ун ел эчендә Рәсәйдәге төрки өлкәләрдә күп кенә уңай үзгәрешләр, алга китешләр булса да, Дөнья сугышы тудырган тетрәнүләр алар хәятенә дә тискәре тәэсирен ясамый калмый.

Беренче Дөнья сугышы нәтиҗәсендә Рәсәй империяторлыгы җимерелгәч, бу дәүләт эчендәге урыс булмаган милләтләрнең язмышларын үзләре теләгәнчә хәл кылу мөмкинлеге туа. Фәкать бу мөмкинлек географик һәм бүтән шартлар аркасында һәр милләт өчен бердәй булмый. Көнбатыш Европага күрше булган финнәр, эстоннар, латышлар, литовлар һәм поляклар Рәсәйдән бөтенләй аерылып, бәйсезлек ала. Аларның моңа ирешүендә мәдәни казанышлары гына түгел, Дөнья сугышы барышында алман гаскәрләре кулы астында калулары да зур роль уйный. Украиннар, белоруслар һәм башка милләтләр бу җәһәттән кыенрак шартларга эләгә.

1905—1906, 1916 елларда чакырылган корылтайларда төрле милли һәм дини мәсьәләләрне тикшергән Рәсәй мөселманнары, 1917 елның 1-11 майларында Мәскәүдә бөтен тарафлардан килгән 800 вәкил катнашында «Бөтен Рәсәй мөселманнары гомум корылтае»н уздыралар. Анда Рәсәйнең киләчәк дәүләт төзелеше дә тикшерелә, вәкилләр «федералист» һәм «унитарист» дигән ике төркемгә аерыла. Бөтен мөселманнар өчен 30 кешелек Милли Шура сайлана, аның эченнән эш йөртү өчен 12 кешелек бер даими комиссия төзелә.

1917 елның 21—31 июлендә Казанда: 1) Гомум Рәсәй мөселманнары корылтае. 2) Мөселман руханилары корылтае. 3) Гомум Рәсәй мөселман Хәрби Шурасы тарафыннан чакырылган Гаскәри корылтай уздырыла. Бу өч Корылтай әгъзаларының 22 июльдә шәһәр театрындагы уртак утырышында Садрый Максудыйның рапорты тыңлангannan соң, «Эчке Рәсәй һәм Себер мөселманнарының Милли-Мәдәни Мохтарияте» игълан ителә һәм аның җиде кешелек идарәсе сайлана. «Эчке Рәсәй һәм Себер татарларының Милләт Мәҗлесе»н туплау йөкләнгән бу идарә эш урынын Казаннан Уфага күчерә. Күренә ки, Казан корылтайлары «Гомум Рәсәй мөселманнары» исемендә уздырылса да, моннан соңгылары шуның дәвамы төсендә үткәрелсә дә, Төркестан, Кавказ һәм Кырым

кебек өлкәләрнең вәкилләре Рәсәйдә гражданнар сугышы башлануы аркасында актив катнаша алмагач, Казан корылтайлары чынлыкта Идел-Урал буе төркиләрен генә колачлый.

Казан корылтайлары карары буенча, «Эчке Рәсәй һәм Себер төрек-татарлары Милләт Мәҗлесе» 1917 елның 30 ноябрендә Уфада эшли башлый. 52 көнлек утырышы дәверендә Мәҗлес Милли-Мәдәни Мохтариятнең төп канунын кабул итә, Милли Идарә белән бүтән кануннарны чыгара һәм милли үзидарәләрнең чикләрен билгели. Моннан тыш, Г. Шәрәф әзерләгән «Идел-Урал» проектын да тикшереп, «Идел-Урал штаты» кору максат ителүе хакында карар чыгара һәм бу мәсьәләрне өйрәнү өчен Казан шәһәрендә эшләячәк бер «Тупраклы автономия комиссиясе» сайлый.

120 депутаттан Уфада корылган Милләт Мәҗлесе әлеге мохтарият комиссиясе урынына Мәгариф, Малия (финанс), Диния нәзарәтләреннән гыйбарәт бер Милли Идарә сайлый. Һәр нәзарәт биш кешедән гыйбарәт булып, эчләреннән берсе рәисителә. 1918 елның гыйнвары ахырында Мәҗлес эшен тәмамлагач, Милли Идарә вазыйфасын үтәргә тотына.

Гражданнар сугышы нәтиҗәсендә Идел-Урал вакытлыча большевиклар кулына кергәч, алар башта Милли Идарәгә кагылмый. 1918 елның 3 мартында Брест-Литовск килешүе имзалангач, Казандагы һәм Уфадагы төрек-татар милли оешмаларына һөҗүмнәр башлана. Милли Идарәнең өч нәзарәтеннән шулвакыт Мөселман мәркәз диния нәзарәте генә урынында калдырыла. Милли Идарә рәисе Садрый Максудый Мәскәүгә барып эшне җайларга омтылса да, уңай нәтиҗәгә ирешмәгәч, Рәсәйне ташлап, Финляндиягә сыенырга мәҗбүр була.

1918 елның җәендә Казан һәм Уфа аклар кулында калгач, Уфада Кече Милли Идарә эшли башлый. Соңрак Милли Идарә Кызылҗар (Петропавловск) шәһәренә күченә. Монда Кече Милләт Мәҗлесе тупланып, Париж конференциясенә Эчке Рәсәй һәм Себер төрек-татарларыннан милли һәм сәяси теләкләрен белдерү өчен вәкилләр сайлау уздырыла. Язучы Гаяз Исхакый вәкил итеп Уфа Милләт Мәҗлесендә сайлана. Сайланган икенче әгъза Фуат Туктаров була. Бу ике затка Парижда Милли Идарә башлыгы Садрый Максудый белән берлектә җаваплы бурычларны үтәү тапшырыла.

1919 елның җәендә Кызыл Гаскәр тагын алга киткәнлектән, Милли Идарә тәмам таркала. 1920 елның кышында Себернең күпчелек өлеше кызыллар кулына күчкәнлектән, Совет идарәсенә каршы милләтчеләр моннан да чыгып китәргә мәҗбүр була.

Й. Акчура бу вакыйгаларның бер өлешен үз күзе белән күрә. Уфада Зәки Вәлиди белән очраша, Габдулла Баттал, Галимҗан Баруди һ. б. белән әңгәмәләр кора.

Әсирләргә булышырга акчасы беткәнлектән, Й. Акчура 1919 елның февралендә Петербургтан Стокһольмгә китеп бара. Шушы юлда — Хельсинкидә һәм Стокһольмдә ул Милли Идарә башлыгы Садрый Максудый белән күрешә һәм төрки дөньяда канат җәйгән өметсез хәл турында ачынып фикер алыша.

Й. Акчура юл уңаенда Копенгагенга тукталып, төрки Орхын язмаларын укый алган мәшһүр телче профессор Вилһельм Томсенны (1842-1927) эзләп таба һәм аңа төрки телләрне тикшерүдәге бөек хезмәтләре өчен хөрмәтен белдереп, рәхмәтләрен әйтеп чыга.

23 майда Берлин банкында акча эшләре хакында хисап биргәннән соң, Й. Акчура Һамбург аша әсирләрнең бер өлеше белән «Гөлҗамал» пароходында Истанбулга кайтып китә.

Алмания, Австро-Мажарстан, Госманлы империяторлыгы һәм Болгарстан патшалыгыннан гыйбарәт бердәмлек дәүләтләре баштагы өч ел ярымда сугышта шактый уңышларга ирешә һәм Брест-Литовск килешүе белән Рәсәйне сафтан чыгаралар. Әмма сугышка Антанта ягыннан АКШ кушылу бердәмлек дәүләтләренең хәлен үзгәртә — алар бәрәм-бәрәм җиңелүләрен танырга мәҗбүр була. Севр килешүе (10.VIII.1920) Госманлы дәүләтен дә кыен хәлгә куя. Җиңелү элегрәк башлана, билгеле. Антанта хәрби диңгез флоты 1918 елның 13 ноябрендә Истанбулга керә, 1919 елның маенда исә Измир шәһәре греклар тарафыннан басып алына. Вакытлы килешүгә кул куелгач, Антанта дәүләтләре Төркиянең үзәк өлешен тәшкил иткән Анадулыны да үзара ярыша-ярыша басып алырга тырыша башлый.

Мондый хәвефле шартларда ватанпәрвәр төрекләр булдыксыз хәлифнең һәм аның аксөякләренең капитуляция сәясәтенә каршы чыга — илбасарларга каршы көрәшү өчен вилаятләрдә төрле тәшкилатләр коралар. 1919 елның маенда Самсунга килгән Мостафа Кәмал паша шул таркау көчләрне бергә туплап, милли-

азатлык көрәшен аякка бастыра. Төрки халыкларның үсеше өчен сәләтен һәм көчен кызганмаган Й. Акчура да, әлбәттә, милли азатлык көрәшенә кушыла. Инглизләр аны 1919 елда кулга алып, төрмәгә ябып куя. Аннан котылгач, 1920 елда Шәүкәт бәй кызы Сәлма туташка өйләнә һәм шагыйрь Мәхмәт Әмин белән берлектә Анадолыга юл тота. Милли азатлык көрәшендә актив катнашуы аны бераздан Җөмһүрият халык партиясе сафларына алып килә, Бөек Милләт Мәҗлесенә сайлата. Заманында «Иттихад вә тәрәкъкый» партиясенә кермәве, «Яшь төрекләр» дәверендә үз юлыннан гына атлавы, урыс революциясе чорында хәтәр мажараларга тарымавы — әмма һәрвакыт төрки халыклар файдасына эзлекле хезмәт итүе белән ул Мостафа Кәмалнең игътибарын казана, якыннан аңлашуларына сәбәп була. Төркия Җөмһүриятенә нигез салган, төрек халкын милли афәттән — бәйсезлеген югалтудан саклап калган Мостафа Кәмал Ататөрек бәйсез фикерләргә ия Йосыф Акчурага югары бәя бирә һәм мәдәният, тышкы сәясәт мәсьәләләрендә аның киңәшләренә дә таяна.

Й. Акчура хатыны белән Анкарага килгәч, Мәгариф вәкиллегенең язу һәм тәрҗемә комиссиясе әгъзасы, аның башлыгы була. Аннары инглизләргә каршы көрәштә фронтта штабчы офицер вазыйфаларын башкара. 1922 елда Тышкы эшләр министрлыгының шәркыя эшләре гомум мөдирлегендә киңәшче вазыйфасына билгеләнә. Шушы дәвердә ачлык хөкем сөргән Идел буеннан Диния нәзарәте исеменнән Г. Бубый, Ф. Бубый, М. Ф. Тугай һ. б. йөзендәге бер вәкиллекнең Анкарага килүе уңаеннан, Й. Акчура милләттәшләрен М. Кәмал паша белән очраштыра. Бәйсезлек сугышының ин мөшкел көннәре булуга карамастан, Мостафа Кәмал ачлык кичерүче Идел буена гаскәри запасыннан йөз мең консерв, өч мең капчык он җибәрергә әмер бирә. Ачыгучыларга булышу өчен Кызыл ай җәмгыяте дә үз өлешен куша.

Мостафа Кәмалнең хуплавы буенча, Й. Акчура Милләт Мәҗлесенә депутат итеп Истанбулдан сайлана. Икенче юлы аны Карс вилаяте халкы парламентта үз вәкиле итә — Акчура вафат булганда да шуларның депутаты була. Җөмһүрият дәверендә Йосыф укытучылык эшен Анкарадагы Иректе халык дәресләре курсында (1921—1922) башлый, аннары Анкарада ачылган Хокук мәктәбендә тарихтан сабак бирә. Анкараның тау климатына ияләшә алмаганлыктан, ул 1934 елда хәзерге заман сәяси тарихы профессоры булып Истанбул университетына күчә.

Яңа дәвердә яшәргә сәләтле Төркияне аякка бастыручылар, Ататөрек башлаган көрәшне куәтләүчеләр арасында Й. Акчура да була. Төркияне икътисадый һәм мәдәни яктан Европа илләре дәрәҗәсендә күрергә теләве, шуның өчен җиң сызганып хезмәт итүе күз алдында.

Й. Акчураның күпкырлы гыйльми эшчәнлегендә тарих аерым урын тота. Тарихчы галим һәм тарих укытучысы вазыйфаларын ул берьюлы башкара һәм тарихтан алына торган гыйбрәтләр хакында фикерләрен күпләргә ирешерлек итеп әйтеп калдыра. «Бу сөйләгәннәремнән аңлашыладыр ки,— ди ул,— тарих абстракт бер фән түгел. Тарих тормыш өчен, милләтләрнең, халыкларның барлыкларын саклауга, куәтләрен үстерүгә хезмәт итә».

«Тарих — милли культураның нигезе,— ди Акчура.— Шул ук вакытта тарих милләтләрнең җиһандагы урыны һәм шәрәфләрен тәгаенли: тарихка баглы бер кавем җир йөзендә тормыш һәм бәхет хакының дәлилләрен галәмгә күрсәтә: тарих агышында теге яки бу милләт киләчәгенең якты һәм исәпсез-хисапсыз юлларын ача».

Й. Акчура 1911 елда: «Без үзебезгә, кавемебезгә, кабиләбезгә ятлар кидергән күзлектән карыйбыз. Әгәр төрки халыкларны, аларның үткәнен булганча күрергә теләсәк, ятлар кидергән күзлекне салып атып, вакыйгаларга үз төрки күзләребез белән карарга тиешбез, ягъни бабаларыбыз калдырган әсәр һәм документларны үзебез тикшереп, аңа хөкем, бәя бирү өчен эшләвебез хаҗәт»,— ди.

Нәкъ менә шушы галимнең Мостафа Кәмал белән берлектә 1931 елда «Төрек тарих тикшеренүләре җәмгыяте»нә («Төрек тарих корымы») нигез салуы табигый. Й. Акчура бу җәмгыятьнең башлыгы итеп сайлана һәм Ататөрекнең хуплавы белән 1932 елда «Беренче Төрек тарих корылтае»на җитәкчелек итә.

Й. Акчура тел өлкәсендә чамасыз пуристлыкка, үз нигезенә кискен кайтуга каршы иде. «Тел үз үсеш кануннарына баглы яшәгән бер барлыктыр»,— ди ул. И. Гаспралының «Тәрҗеман» гәзите арадашлыгы белән барлыкка китерергә тырышкан «Госманлычаның гадиләштерелгән бер формасы булган гомуми язу төрки теле»н хуплый. «Төрек йорты» журналын чыгарган дәвердә ул Җ. Сәхип, Х. Әдип, Ә. Агаоглы, М. Ф. Күпрүле, З. Гүкалып, М. Әмин һ. б. белән берлектә халыкка аңлаешлы гади төрки телдә язуны яклый һәм шуны тормышка да ашыра.

Й. Акчура, укымышлылар белән халык арасындагы мөнәсәбәтләргә бәйле фикерләрен «Халыкка тугры» журналында «Халыкка» исемле язмаларында мәйданга чыгарды. Бу журнал «халыкның эчендә яшәгән, ярдәмчесе сыйфатында аның белән серләшеп, кайгыларын уртаклашкан, сорауларына җавап биргән вәгазьче кебек, укымышлы катламның гаммәгә булышу чарасы булырга тиеш иде». Милли аң һәм тойгыларның укымышлылар һәм хезмәткәрләр башында туплануы гына аз, бу аңның авылларга кадәр барып җитүе кирәк, дип исәпли Й. Акчура.

Аның аеруча 1922 елдан соңгы эшчәнлегендә икътисадый мәсьәләләр әһәмиятле бер урын тота. 1924 елда басылган «Сәясәт һәм икътисад хакында бераз мөрәҗәгать» исемле мәкаләләр җыентыгыннан моны тагын да ачыграк күрергә мөмкин. «Бөек сугышка карата» мәкаләсендә: «Бу алдагы бәрелешләрдән соң төп зур сугыш башланачактыр,— ди ул.— Бу сугыш туп, мылтык белән, Лозаннда булган кебек, сүз һәм каләм белән алып барылмаячак, бу бөек сугышның коралы — урак, чалгы, кельма, җәзбә, сандал, чүкеч, верстак, пар һәм машинадыр. Бу бөек сугыш игенчелек, санагат һәм сәүдә тармагында барлыкка киләчәк. Чынлыкта төрек милләте шушы икътисад мәйданы сугышында уңыш казанса гына, хөр, мөстәкыйль, чәчәк атучы милләтләр арасына керә алачак».

Кешеләрнең һәм шулай ук милләтләрнең үсешендә матди як белән бергә рухый якның да тәэсире булуын, «гамәл-идеал-өмет»не күздә тотып, ул болай ди: «Идеалсызлык һәм шулай ук идеалда тәртипсезлек бер иҗтимагый хәятнең бик хәвефле һәм һәлакәтле хәледер. Бу хәл иҗтимагый хәят көчләрен төрле, хәтта, капма-каршы тарафларга этәрер. Идеалларның югалуы, көчле һәм җинүчән бер идеалның булуына киртәдер».

«Иҗтимагый хәятебез яшәргә теләсә, аның бер сәламәт һәм уңай идеал иясе булуы шарт. Әйе, шулай бер идеаллы булыйк, яшьләребезгә, балаларыбызга ул идеал даирәсендә дөрес, сәламәт бер тәрбия, бер иман бирик; ягъни ул идеалны хәяткә кичерик, тормышка ашырыйк»...

Й. Акчураның милли-сәяси идеаллары «Өч тарзы сәясәт» мәкаләсендә мәйданга чыгарыла. Зур бер госманлы милләтен барлыкка китерү белән шөгыльләнүне ул «бушка бер талчыгудыр» дип кире кага. «Исламчылык» һәм «төркичелек» арасында бер өстенлек күрмәгән шикелле тоелса да, шөкер, ул үз юлын инде күптән сайлаган һәм «төркичелек» фикерен «гамәл-идеал-өмет» рәвешендә кабул иткән иде. Аның бу тоткан юлы дөреслеген соңрак милли бер төрки дәүләт — Төркиянең корылуы белән тарихта да исбатланган булганлыктан, аңа бу үсешнең хәбәрчесе итеп карарга тиешбез.

Й. Акчура исәбенчә, төрки җәмгыятьнең Көнбатыш мәдәнияте белән үрелеп яңаруы нинди дер бер тәҗрибә ясау гына түгел, мәҗбүри, зарури бер хәрәкәт, төркиләр өчен үлем яки яшәү мәсьәләсе иде. Асылда Көнбатышның Көнчыгыш алдындагы һәртөрле әхлакый һәм рухый өстенлеге хакында бәхәсләшү кирәк тә түгел иде. Кайберәүләр Көнбатышның бары техникасын алуны гына кинәш итәләр, фикерләрен файдалануга каршы чыгалар иде. Бу чикләүгә шикләнеп караган Й. Акчура: «Европалылардан юл күпере салуны һәм һавада очу машинасы ясауны өйрәник, әмма европалыларча фикерләү ысулын зинһар өйрәнмик, дигән тәгълиматны акылым һич тә кабул итми»,— ди.

Й. Акчураның тарих, тел, икътисад, милли аң һ. б. мәсьәләләргә карашын тикшерсәк, һәркайсының нигезендә төркичелек һәм төрек милләтчелеге идеалы ятуын күрербез. Җ. С. Кырымлының әйтүенчә, «бөтен төркиләрнең милли хисләре көчәюенә, төркичелек идеалы тууына, мәдәни һәм сәяси тормышта шул идеалларга хезмәт итүгә бәрәү дә Йосыф бәй кадәр йогынты ясамады», дип раслый алабыз. Гыйлем иясе, профессор, гәзитче, вәгазьче, сәяси оештыручы буларак һәр яктан тикшерсәк, аны һәрчак бер юлда күрербез: төрки милләтчелеге. Аның һәр китабын, һәр мәкаләсен, һәр нотыгын анализласак, аның һәрчак бер үк максат өчен бәргәләнүен күрербез: төркичелек. Аңа кайда гына очрамыйк — Парижда мы, Казанда мы, Кырымда мы, Истанбулда мы, Берлиндәме, Лозаннда мы — ул һәрвакыт бер үк кайнарлык, бер үк самимилек, бер үк җитдилек белән бер үк идеяны гамәлгә ашыру өчен тырыша: ул бөтен төрки милләтләрнең милләтчесе була. Казанда эшләгәндә Кырымны, Кавказны, Төркестанны, Төркияне онытмый. 1904 елда «Өч тарзы сәясәт»не Идел буеның Зөябашы авылында язуы, Госманлы дәүләтендә күзәтелгән күренешләрне анда анализларга һәм куәтләргә тырышуы, «Казан мөхбире» гәзитендә Төркияне танытуга хезмәт итүе, Казанның Мөхәммәдия мәдрәсәсендә госманлы төрек әдәбиятын укытуы, 1906 елда Казанда чыккан «Гыйлем вә тарих» әсәрендә тарихка милли идея күзлегеннән, бөтен төркичелек мәнфәгатеннән чыгып кара-

вында ныклыгы һәм, ниһаять, Төркиядә... тормышының ахырына кадәр дәвам иткән эшләре аның бөтен төрки милләтләрнең тугрылыклы һәм самими бөек бер милләтчесе булуын күрсәтергә һәм исбатларга җитәрлектер. Аның бөтен әсәрләре, фикерләре һәм хезмәтләре, бөтен тормышы шуңа дәлил.

Й. Акчура төркилекнең географиясен дөнья тюркологлары кебек колачлаган бер шәкелдә төшенә иде. Аңа дөньяның кай җирендә һәм нинди сәяси чикләр эчендә булса да, зур яки кечкенә һәрбер төрки бердәмлек тикшерү өчен бердәй әһәмиятле иде. «Иҗтимагый яшәгән бер милләт югалткан бәйсезлеген иртәме-соңмы казаначактыр. Бу бөтен сәяси төркилек өчен янадан тормышка кайту булачактыр»,— дип ышана Й. Акчура («Салнамәи сәрвәтефенүн», 1912, бит 196). «Өч тарзы сәясәт»нең бер җирендә ул: «Ләкин төркичелек сәясәте дә, охшаш ислам сәясәте кебек, гомумидер — Төркия чиге белән чикләнмидер»,— ди.

Шуңа таянып кайбер (аеруча, Көнбатыш) авторлар Й. Акчураны «пантөркист», «пантөркизмнең атасы» дип бәялиләр.

Й. Акчураның «пантөркист» дип бәяләнүендә барыннан да элек аның «Өч тарзы сәясәт»тәге кайбер җөмләләре сәбәп була. «Телләре, кабиләләре, гадәтләре һәм, хәтта, күпчелегенең диннәре бер булган, Азия кыйтгасының зур бер өлеше белән Европаның көнчыгыш ягына урнашкан төркиләрнең берләшүендә һәм шулай бүтән зур милләтләр арасында сакланып яши алачак көчле бер милли сәясәт тәшкил итүләрендә һәм шушы зур хәяттә төрки җәмгыятьләрнең иң нык, иң көчәя баручы һәм иң мәдәни булуларында Госманлы дәүләте мөһим роль уйнаячак»,— ди.

«Бүгенге төшенчәмә күрә, бу мәкаләдә мөһим бер анализ кимчелеге бардыр,— ди соңрак автор.— «Төркичелек» сәясәте белән «төркиләрнең берләштерелүе», «ислам сәясәте» белән «ислам берлеге» мәсьәләләре бер-берләре белән бутала. Госманлы дәүләте үз эчендә «төркичелек» һәм «ислам» сәясәте уздырганда, тышкы сәясәтендә дә «пантөркист», «панисламчы» булуының мотлак ихтыяҗы юк» («Төрек йорты», 1928, бит 406).

Дөньяның кай җирендә, нинди сәяси чикләр эчендә һәм географик өлкәләрдә яшәүләренә карамастан, бөтен төрки кавем-кабиләләрне тик бер дәүләт һәм идарә астында берләштерү» төшенчәсе килсә, Й. Акчурага пантөркист дию дөрес булыр иде. Әмма Франчоиз Георгеонның алдарак аталган әсәрендә мисалга китерелгән картада Кырым, Казан, Казагыстан, Төркестан һәм Кавказны аерым-аерым дәүләтләр итеп кору күздә тотыла һәм «Өч тарзы сәясәт»тә алар «төрки берлектә иң күренекле рольне уйнаячак» Госманлы дәүләтенең эченә кертеп сызылмаган. Хәлбуки, бу карта Й. Акчура һәм аның иптәшләре тарафыннан Бердәмлек дәүләтләренең 1916 елда җиңүгә иң нык якынлашкан дәверендә хәзерләнгән. Й. Акчура шул чакта «пантөркист» булмаган икән, аннан соң инде гомумән була алмаган!

Й. Акчура һәрнәрсәдән әүвәл, төрки кавемнәрнең бер-берләрен белүләрен, тануларын һәм сөюләрен тели иде. Төрки дөньяның тарихы, географиясе, археологиясе, этнографисе белән, төрки җәмгыятьнең икътисадый һәм социаль мәсьәләләре белән һәм моның бер нәтиҗәсе буларак, сәяси хәлләре белән дә кызыксына. Ягъни бүгенге төшенчәдә ул бер «төрки мәдәнияте миллиятчесе» иде. Атамаларның аңлашылуында мәйданга чыккан буталчыклык, соңыннан Көнбатыш авторларының «төрки мәдәниятләрне тикшерү»енә дә сәяси төс туглап карарга мөмкинлек биргән кебек, «пантөркизм» карачкысы пәйда булуга китерә.

Төркиядә демократик идарә корылганнан соң, аның тышындагы төрки кавемнәр белән кызыксыну бер мәдәни мәсьәлә буларак гамәлгә куела һәм «тышкы төркиләр» атамасы белән сәясәттән ерак гыйльми өйрәнү эшенә керешелә. Анкарада 1961 елдан бирле эшләп килгән «Төрки мәдәниятләрне өйрәнү институты» — шушы максатта корылган ярым рәсми гыйльми үзәкләрнең берсе.

Й. Акчураның хатыны Сәлма Шәүкәт бәй кызы иде. Шәүкәт бәй Траблуста «Иттихад вә тәрәккый» җәмгыятенең җиденче бүлеген коручы һәм конституция тарафдары иде. Аның дүрт кызы һәм бер улы бар иде.

Й. Акчура гаиләсенең исә ике баласы туа. Кызлары Өлкән (1924) табип, уллары Тугрул (1927—1984) — архитектор, Анкара Урта Көнчыгыш техник университеты профессоры була, инсульттан дөнья куя. Тугрул ике мәртәбә өйләнә, ике никахыннан икешәр баласы кала.

«Йосыф белән уналты ел бергә яшәдек,— ди хатыны Сәлма ханым.— Үзен беренче мәртәбә 1908 елда күрдем. Әмма онытылмас көннәрем шактый соңрак башланды. Ул вакыт Йосыф утрауда, нарат лар күләгәсе астындагы бер нәни өйдә яши иде, мин — укучы, имтихан биреп лицейга керергә әзерләнә идем. Һәр көнне сәгать өчтә, иң эссе вакытта, тарих китабымны тотып, мин аңардан дәрес

алырга керә идем. Өстендә, гадәттәгечә, кургаш төсендәге кием, юка ак күлмәк була иде. Тик чәчләре ул чакта кара иде. Тәбәнәк түшәмле зур бер бүлмәсенең уртасында анасы канвалап чиккән эскәтер ябылган өстәл тора, без шуның янына утырып шөгыльләнә идек. Ике сәгатьтән соң хезмәтче хатын безгә ишегалдында табын әзерли. Самавыр кайный башлагач, Йосыфның да кәефе күтәрелә, урыныннан торып чәй пешергәндә, киләчәктә тагынниләр эшләячәген миңа да сөйли иде. Бер көнне «арыдым» дип нарат кәүсәсенә сөялеп торды. «Картлык килгәч нишләрмен, инде җәренгә кырык тулачак. Вакыт шундый тиз уза, шундый тиз. Эшләгән эшләрем исә әле бик-бик әз», дип кинәт иреннәрен тешләде».

«Аңа иң ошаган нәрсә, шөбһәсез ки, эш иде. Бәлки мин аңа комачаулаганмындыр да. Әмма минем өчен чын яшәү аның белән бергә чакта гына булган икән, уналты ел узып китүен сизмәгәнмен дә...»

«Уртак тормышыбызның иң күбе Кәчиүрәндә узды. Зур бүлмәнең өч ягына буйдан-буйга такта шүрлекләр ясалып, аларда китаплар тезеп куелган. Түрендә миңа бүләк иткән өч басма тора: берсе — шигырьләр җыентыгы, икенчесе — аш-су китабы, өченчесе — бала тәрбияләү турында. Югарыгы киштәдә төрле вак-төяк нәрсәләр: бер сигара тартмасы, греклардан калган бер мылтык, Халидә ханымның бер романы. Иптәшләренең рәсемен диварга ул үз кулы белән асып куйды.

Тагын бер бүлмә — аның эш кабинеты. Диварда Ататөрекнең сары рамлы рәсеме, өстәлендә өч-дүрт сүзлек, карталар, анасыннан калган, фин сөягеннән ясалган каләм, кылыч-хәнҗәр шәкелендәге янә бер каләм, озын бер кайчы, Момсенның бер сыны — болар өстәлдә даими тора торган нәрсәләр. Диварда мәктәп программасы, аның өске ягында шәкертләре белән төшкән фоторәсеме. Бүлмәнең кыл уртасында, очраклы рәвештә онытылган кебек, бер зур чемодан тора... Эчендә гаскәри киемнәре белән аларны кигән замандагы хатирәләре саклана. Бүлмәләрне шушы хәлгә китерү өчен Йосыф иптәшләре белән бер атна тырышты. Бөтен китапларын бергә тезеп куйгач, шулкадәр сөенгән иде! Колаклары кызарган, гадәттәгечә, авызында сигарасы, кәефе шәп. Башын алдына игән, иңнәре җиңелчә калкып тора, куллары кесәдә, аякларында калын ак оекбашлар. Бу тупас киемнәр эчендә йөзе бөтенләй нәни күренә. Һәр китапка аерым-аерым күз салганда карашы нурлана. Безгә торып-торып: «Сак булыгыз, чү, бу китапларга кагылмагыз, кирле, тузанлы, тагын әллә нинди булса, үзем тазартырмын, пакьлармын», ди иде. Тәрәзәгә күзе төшкән саен мине чакырып алып, аннан күренгән тауларга, чәчәкләргә ишарәләп: «Баксана, ерактан нинди матур күренәләр!» дип соклана иде... Кичләрен һәр өйнең утлары сүнәр, һәркем йокыга оер, аның өстәлендәге яшел лампасы исә сүнмәс иде. Төннәрен уянып китеп карасам, ул һаман укып-язып утыра, тирә-ягы китап-кәгазьгә күмелгән, үзе бүздәй агарынган була. Шул эшенә кереп чумса, бераүне дә күрми-ишетми иде...»

1935 елның 11 мартында ул Гүзтәпәдәге өеннән улы Тугрул (8 яшендә) белән Баязит урамындагы Әдәбият факультетына сабак укытырга китә. Кичен пароходта Хәйдәрпашага килгәннән соң, шәһәр тирәсе поездына менгәндә хәле китеп җиргә егыла. Улына кырыйга чигенергә ишарә ясый. Шунда соңгы сулышын ала һәм аннан Хәйдәрпаша шифаханәсенә китерелә.

Җеназа намазы Үскүдарда Шәмси паша мәчетендә укыла, аннары мәет Сиркәҗигә алып килена, монда Истанбул Төрек студентлар берлеге әгъзалары һәм халык тарафыннан каршылана һәм иңгә куеп Солтанмәхмүт мәчетенә, аннан Баязит мәчетенә һәм мәйданына китерелә. Университет капкасы алдында халык катнашы белән зур бер озату тантанасы уздырыла — нотыклар сөйләнә, Истанбул университеты ректоры профессор Җәмил Билсал, профессор Шәмсетдин Гүналтай, профессор Садрый Максудый һ. б. соңгы саубуллашу сүзләрен әйтәләр.

Шуннан соң Й. Акчура гәүдәсе автомобильгә менгерелә һәм меңнәрчә кеше озатуында Әдирнәкапы зиратына алып киленеп дәфен кылына. Ул көнне университетның бөтен факультетларында дәресләр туктатыла һәм Йосыф Акчура вафаты уңаеннан матәм тотыла. Кабере өстенә Казан ханлыгы дәвереннән калган соңгы һәйкәл һәм милли хисләрнең гәүдәләнеше булган Сөембикә манарасының макеты куела.

*Төрекчәдән Т. ӘЙДИ тәрҗемәләде*
*һәм басмага әзерләде.*

# ТУГАН ТУФРАК ҖЫЛЫСЫ



Аны телефоннан сөйләшүләр буенча да нәкъ шулай күз алдына китерә идем. Мәһабәт төз гәүдәле, киң җилкәле, өлкән яшьтә булуына карамастан, җиңел хәрәкәтле, бик ягымлы карашлы икән безнең данлы якташыбыз — армия генералы, хәрби фәннәр докторы, профессор Мәхмүт Әхмәтдин улы Гәрәев. Ул мине үзе билгеләгән вакытта, элеккеге СССР Кораллы Көчләре Генеральный штабының тышкы баскычы төбендә үк, аска төшеп каршы алды. Һәм, иң беренче итеп: «Исәнме, якташ»,— дип елмаеп кулын сузды. «Кайда урнаштың? Тамагың ачыкмадымы?» — дип сорашырга да өлгерде. Минем җавапны да көтеп тормастан, ашханәгә алып китте.

Менә шуннан соң инде аның болын хәтле кабинетында безнең икәүдән-икәү генә әңгәмәбез башланды. Армия генералы М. Гәрәев хәзер яңа эштә икән. Ул бүген Рәсәй Оборона министрлыгында хәрби киңәшче. Ә моңарчы озак еллар дәвамында Кораллы Көчләр Генеральный штабы начальнигы урынбасары булып эшләгән иде. Аның бүгенге эше нинди җаваплы булуы Мәхмүт Әхмәтович белән берничә сәгатьлек әңгәмә вакытында ук аңлашылды. Армия генералының өстәл өсте тулы кәгазьләре — кичектергесез карап чыгуны көтә торган төрле-төрле документлар. Күпсанлы телефоннар анда-санда шалтырап куя. Яисә, папкалар тотып, генераллар һәм адмираллар килеп керә. «Эшем шундый бит, якташ»,— дип куя Мәхмүт Әхмәтович аларны озаткач, әңгәмәбезнең өзелүе өчен гафу үтенгәндәй.

Ул Татарстандагы вакыйгаларга бәйле һәр хәбәрне матбугаттан җентекләп укып бара икән. Республика Югары Советы сессиясенең 1990 ел, 30 августтагы суверенлык турында Декларацияне, соңрак референдум нәтиҗәләрен бик шатланып кабул иткән. «Йә, ничек анда беренче адымнар?» — дип кызыксынды Мәхмүт Әхмәтович. Алдан ук шуны әйтим: безнең әңгәмә саф татар телендә бара. Татарстаннан, татар төбәгеннән гел еракларда яшәп тә (ул үзе Чиләбедә туып үскән), туган телен шулай әйбәт белүе, онытмавы соклангыч. Тормыш иптәше Тамара Ивановнаның рус хатыны булуы да моңа комачауламаган.

Мәхмүт Әхмәтович гаиләсе хәрбиләргә хас булган бер гарнизоннан икенчесенә күченеп йөрүнең бөтен авырлыкларын татыган. Һәм шушындый шартларда да алар искиткеч балалар үстерергә мөмкинлек тапканнар. Уллары Тимур Гәрәев әтисе юлыннан киткән. Хәзер М. В. Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлады. Кызлары Галия, Ташкент дәүләт университетының чит телләр факультетында белем алганнан соң, хәзер шул юнәлештә эшли. Гаиләсе турында сүз чыкса, Мәхмүт Әхмәтович: «Безнең иң зур шатлыгыбыз — ике оныгыбыз, Галиямнең кызлары бар. Шуларга куанып бетә алмыйбыз»,— дип куя. Хәзер армия генералына инде 70 яшь тулып килә. Бу яшьтәге кешенең хисләрен аңлатып торырга кирәкме икән?

— Татар төбәгеннән гел читтә яшәргә туры килсә дә, мин туган телемә хөрмәтне гомерем буе сакладым,— ди Мәхмүт Әхмәтович.— Җае чыккан саен татарча китаплар укырга, очраган һәр татар кешесе белән туган телемдә сөйләшергә тырыштым. Татар милләтеннән булган генераллар һәм адмираллар белән дә гел ана телебездә әңгәмә корырга тырыша идем.

Шунда күңелле генә елмаеп, Мәхмүт Әхмәтович, бер вакыйганы искә төшерде... 1942 елда Мәскәүдәге бер госпитальдә дәваланып чыккач, яшь лейтенант Казанга әнисе белән бертуган Фатыйма апаларына берничә көнгә кунакка кайта (аның әнисе Рәхимә апа — Татарстанның Кама Тамагы районыннан, әтисе Әхмәтдин абый Башкортстанның Чишмә районы, Салих авылыннан). Авыр көннәр була бу. Казан халкы да ачлык, ялангачлык кичерә. Менә шунда бер кибеткә кергәч, ике татар хатынының ызгышуларын күрә бу. Берәү булса, тизрәк борылып чыгып китәр иде. Ә Мәхмүт аларны тыңлап тик басып тора. Туган телдә яңгырагач, ачуланышу сүзләре дә якын тоела аңа. Үзләренә яшь, чибәр офицер карап торганны күргәч, хатыннар ызгыш-талаштан туктыйлар, билгеле. «Ник күзеңне тасрайттың?» — диләр дә, татуланышып, кибеттән чыгып китәләр.

Туган телгә ихтирам дигәннән, тагын бер вакыйга искә төшә. Казанда туып үскән генерал туганыбыз Рафаэль Йосыпов, бер кайтуында, байтак кына татарча китаплар җыйды. «Нигә кирәк ул сиңа?» — дип кызыксындык моннан. «Мине Мәхмүт Әхмәтович, туган телеңне начар беләсең, дип кызартты һәм бик яхшылап өйрәнергә кушты. Бу — приказ, аны үтәргә кирәк»,— диде ул җитди төс белән. Ә бу чакта генерал Рафаэль Йосыпов СССР Кораллы Көчләре Генеральный штабында М. Ә. Гәрәев кул астында эшли иде. Без әлеге приказның ничек «үтәлүен» әйбәт тоеп тордык: генерал-майор-инженер, профессор Рафаэль Йосыповның татарча сөйләшү осталыгы бермә-бер артты. Үзенең туган Казанына кайткан саен ул туган телендә сүз запасын арттыра баруы белән куандырды. Моның өчен без рәхмәтне, иң элек, Мәхмүт Әхмәтовичка әйтәбез.

Менә шушында, бераз артка китеп булса да, редакциягә Менделеевск шәһәрендә яшәүче Касыйм Мөхәммәтша улы Усмановтан алынган хатны искә төшерәсе килә. Ул Белоруссия хәрби округында, Брест шәһәрендәге бер полк штабында, 1949—52 елларда штаб начальнигы подполковник Мәхмүт Әхмәтович Гәрәев белән бергә хезмәт иткән. «Татар егетләре белән саф татарча гына сөйләшүен һаман да онытасым юк. Ул минем күңелемә мәңгегә шулай кереп калды. Аның шуннан соңгы язмышын белмим. Сезнең «Ватаным Татарстан» газетасындагы мәкаләгезне укыгач, куанып бетә алмадым. Югалмаган икән безнең татар егете, дип шатланып куйдым»,— дип яза Касыйм ага.

Күренекле хәрби эшлекле, армия генералы М. Гәрәев турында сөйләгәндә туган тел хакында сүз чыгу очраклы гына түгел. Мәхмүт Әхмәтович телне һәр милләтнең йөзен билгеләүче төп сыйфат, дип саный. Бу хакта кат-кат әйтә. Татар телен саклау өчен, аны аеруча шәһәр җирендә балалар бакчасыннан ук өйрәтә башларга, татар мәктәпләрен күбрәк ачарга, югары һәм махсус урта уку йортларында да туган телдә укырга кирәк, ди ул. Заманында бу хакта, Мәскәүдә очрашып, ул чакта КПСС өлкә комитетының идеология секретаре булып эшләгән С. Г. Батыев белән дә сөйләшкән Мәхмүт Әхмәтович. Ул чакта милли проблеманы күтәргән һәр кешегә «милләтче» дигән ярлык тагыла иде бит. Шуна күрәдер, Салих Гыйлемханович, мәсьәләнең өлгереп җитүен яхшы аңласа да, хәл итү өчен бик авыр икәнлеген әйтә.

Мәхмүт ага татар халкының килеп чыгышы, гомумән, төрки халыкларның тарихы хакында сәгатьләр буе сөйли алыр иде кебек. Аның Чыңгыз хан, Батый хан, Аксак Тимер кебек мәгълүм шәхесләр, Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы турында ифрат күп белүенә сокланасың. Татар халкының килеп чыгышы турында сөйләгәндә Мәхмүт Әхмәтович татар галимнәренең инде билгеле фикер-тәгълиматларын кабатлап кына калмый, «мин болай уйлыйм» дип, һәр очракка карата үз фикерен әйтә. Узган елларда профсоюзларның республика советы органы «Аваз» газетасында татар халкының тарихына карата Мәхмүт Әхмәтовичның зур күләмле һәм кызыклы язмасы басылды. Ул аны күренекле галим, академик Әбрар Кәримуллинның «Татары: этнос и этноним» дигән китабы белән танышканнан соң язды. Хәрби фәннәр докторының шулай фикер йөртә алуы, үз халкы тарихын тирәнтен белүе күпләрне сокландыргандыр. Мин аңа Казанда төрки халыкларның икенче съезды буласы турында әйткәч, Мәхмүт Әхтәмович, шунда кайтырга иде, дип кызыксынды. Татар Иҗтимагый үзәгендә дә, аның бу теләгән исәпкә алып, үзенә чакыру кәгазе җибәрергә уйлаганнар иде. Ләкин көтмәгәндә авырып китүе Мәхмүт Әхмәтовичның планнарын җимерде...

Үзенең Бөтендөнья татарлары конгрессына чакырылуы турында ишеткәч исә, Мәхмүт Әхмәтович: «Бик зур рәхмәт! Бу юлы Казанга ничек булса да кайтырга тырышам»,— диде, куанып...

Ул хәрби-транспорт самолеты трапыннан яшь кенә бер егетне ияртеп төште. «Таныш бул, улым Тимур. Үзебезнең милләт рухы керсен дип алып кайттым әле.

Өйләнмәгән егеткә бирәр татар кызы да табылмасмы шунда...» — диде чал генерал, уеның-чынын бергә кушып.

Мәхмүт Әхмәтович дүрт көн буе Яшьләр үзәге кунакханәсендә яшәде. Әлеге көннәрдә бүлмәсе ишеге бервакытта да бикләнеп тормады. Бирегә дистәләгән язучылар, журналистлар, хәрбиләр килде. Армия генералы аларның һәрберсе белән сөйләшергә, сорауларына җавап бирергә вакыт тапты. Һәр мәсьәләгә карата үз фикерен ачык, төпле итеп әйтә дә белде. Һәркемне гадилеге, тыйнаклыгы, киң белемле булуы белән сокландырды.

Татарлар кайда гына яшәсәләр дә, халкыбызның данлы улы турында ишетеп беләләр икән. Конгресс делегатлары арасында Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында йөргәндә аның кулын кемнәр генә кысмады икән! Мәхмүт Әхмәтович конгресста саф татар телендә кыска гына итеп чыгыш та ясады. Зал шаулатып кул чапты үзенә. Армия генералы шунда ук үзенең күп телләргә тәрҗемә ителгән «М. В. Фрунзе — хәрби теоретик» дигән китабын Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевка бүләк итте.

Ә икенче көнне ул тарихчылар секциясендә, Казан дәүләт университетында чыгыш ясады. Бу секциянең җитәкчесе — тарих фәннәре докторы, профессор И. Таһиров соңыннан: «Мәхмүт Әхмәтович татар халкының тарихы моңарчы бозылып яктыртылуга карата бик борчылып сөйләде. Ул безнең үткәнне дөрес сурәтләгән дәреслекләр булдыруны, әсәрләр язуны бик әһәмиятле бурыч дип санавын әйтте», — диде. Үз халкын өзелеп яраткан кеше генә шундый фикерләр әйтергә мөмкин.

Казан читендәге Каен урманындагы Бауман һәм Идел буе районнары сабантуен карау аны бөтенләй рухландырды. Мәхмүт Әхмәтовичка бигрәк тә атлар чабышы ошады. «Күптән мондый күркәм бәйрәмне күргәнем юк иде. Уннарча елга яшәргәндәй булдым. Безнең халык эшли дә, ял да итә белә шул. Казанга сабантуйлар чорында тагын кайтасы булыр, мөгаен», — диде ул, җилдәй җитез чабышкыларны алкышлап. Сабантуй мәйданыннан чал генерал бик боегып кына китте. Аның адымнарыннан бу рухи бәйрәмне, ямьне һич ташлыйсы килмәгәне сизелә иде...

М. Гәрәевкә армия генералы дигән хәрби дәрәҗә бирелгәч, «Социалистик Татарстан» газетасында «Татарлардан беренче» дигән мәкалә язган идем. Газетаны аның үзенә дә җибәрдем. «Мин татарлардан гына түгел, барлык төрки халыклардан беренче армия генералы», — дип язды миңа җибәргән хатында Мәхмүт Әхмәтович, минем сүзләргә төзәтмә кертеп. Мәскәүгә бу баруда да ул хакта яңадан сүз чыкты. 1950 елда М. В. Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә укыганда, берничә көнгә Казанга кайткач, подполковник М. Гәрәев ТАССР Дәүләт музеенда булган һәм «Фикерләр дәфтәре»нә шактый гына «усал» сүзләр язып калдырган икән. Татар халкының үз тарихына, мәдәниятенә һәм сәнгатенә анда бик аз урын бирелүе турында ачынып язган ул. «Бирегә төп урын Габдулла Тукаебызга, башка күренекле милли шәхесләргә бирелергә тиеш», — дип өстәгән. Һәм үзенең тулы адресын калдырган. (Кызганыч, әлеге «Фикерләр китабы» Берләштерелгән дәүләт музеендагы янгын вакытында юкка чыккан. Аны музей хезмәткәрләре күпме генә эзләсәләр дә таба алмадылар.) Әлеге сүзләрне күрми калганнардыр дип уйлыйсызмы? Күргәннәр... һәм тиешле җиренә җиткергәннәр. Беркөнне Мәхмүт Әхмәтовичны Хәрби академия начальнигы урынбасары чакырып ала да: «Син анда Казанда ниләр эшләдең?» — дип, каты гына сорап куя. Аннары берничә сәгать буе «пешерә» моны.

— Мин үз сүзләремнән, хәрби карьерама нык аяк чалу ихтималын белсәм дә, барыбер баш тартмадым, — дип искә ала Мәхмүт Әхмәтович, горурлык белән.

Татарлардан һәр өлкәдә дә күренекле кешеләр булуга шат якташыбыз. Хәрбиләр дә байтак икән татарлардан. Мәхмүт Әхмәтович моңарчы без ишетмәгән генераллар һәм адмиралларны дистәләп санап чыга. Менә аларның кайберләре: генерал-полковник Рәсим Сөләйман улы Акчурин — һава һөҗүменнән саклану (ПВО) гаскәрләренең зенит-ракета частьлары командующие; авиация генерал-лейтенанты Абрек Идрис улы Әюпов — Хәрби-һава көчләре башкомандующие урынбасары; вице-адмирал, хәрби фәннәр докторы Марс Җамал улы Искәндәров; Советлар Союзы Герое, запастагы генерал-лейтенант Мидхәт Абдулла улы Салихов; Советлар Союзы Герое, отставкадагы контр-адмирал Абдуләхәт Умәр улы Аббасов; генерал-майор-инженер, техник фәннәр докторы, профессор, Россия Фәннәр академиясенең Информатика һәм автоматлаштыру институты директоры Рафаэль Мидхәт улы Юсупов... Шушы исем-фамилияләрне санап чыккач, Мәхмүт Әхмәтович:

— Безгә татар булуыбыз белән горурланырга кирәк. Халкыбыз ил тарихында бервакытта да йөзгә кызыллык китермәде,— дип куйды.

Армия генералы, хәрби фәннәр докторы, профессор М. Ә. Гәрәевнең үзе турында, халкыбызның олы горурлыгы, дип кенә бәяләргә мөмкин. Ул, хәрби эштән тыш, фән белән дә күп шөгыльләнә. Аның тарафыннан күп кенә фәнни хезмәтләр язылган. Шулардан икесе — «Гомуми гаскәр өйрәнүләре» һәм «М. В. Фрунзе — хәрби теоретик» — автор тарафыннан җылы сүзләр язып, үземә бүләк ителүе белән чиксез горурланам. Мәхмүт Әхмәтовичның шактый хезмәтләре чит телләргә дә тәрҗемә ителгән. Күренекле полководец Фрунзе турындагы китабы өчен аңа махсус бүләк бирелгән. Армия генералы М. Ә. Гәрәев күп еллар дәвамында Хәрби энциклопедик сүзлекнең Баш редакция комиссиясе әгъзасы булып тора.

Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр катнашырга туры килә аңа. Фронтта биш тапкыр яралана, ике тапкыр контузия ала. Сугыштагы батырлыклары һәм аннан соңгы чордагы хезмәтләре өчен ул Ленин ордены, дүрт Сугышчан Кызыл Байрак һәм Хезмәт Кызыл Байрагы, Александр Невский, ике беренче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Кызыл Йолдыз ордены, күп медальләр, моннан тыш 15 чит ил орден-медальләре белән бүләкләнгән. Бөек Ватан сугышында катнашуы турында сүз чыккач, Мәхмүт Әхмәтович: «Бик озын тарих инде ул. Сөйли башласаң, озак вакыт кирәк булыр иде. Шунысын гына әйтим. Мин сугышчан юлымны 1941 елның көзендә кече лейтенант дәрәҗәсендә Мәскәү янындагы каты көрәшләрдә башладым. 1945 елның 25 апрелендә исә Көнчыгыш Пруссиядә, фашистларның көчле группировкасын тар-мар иткәч һәм Кенигсбергны алгач, майор чинында тәмамладым»,— диде. Аның гаять зур тыйнаклыгы чагыла бу сүзләрдә. Әйтерсең, каты яраланулар һәм контузияләр дә, айлар буе госпиталь койкаларында ятулар да, блиндаж һәм окопларда туңу-өшүләр дә булмаган. «Күп миллионлаган кешеләр сугыш кырларында, концлагерьларда ятып калды. Алар һәрберсе олы ихтирамга, данлауга лаек. Минем фронтта исән-сау калуым шулар исәбенә булгандыр, бәлки»,— дип тә өстәде чал генерал. Без аның белән сугыш эпизодлары турында икенче очрашканда сөйләшергә сүз куештык. «Ә хәзергә менә бу документларны карый тор»,— дип, ул миңа архивтан алынган бүләкләү кәгазьләрен сузды.

...Яшь офицер Мәхмүт Әхмәтович Гәрәевне төрле елларда сугышчан бүләкләргә тәкъдим итү кәгазьләре болар. Алардан Бөек Ватан сугышы чорының дәһшәтле көннәре, аяусыз сугышлар, совет солдатларының каһарманлыгы күз алдына килеп баса. «Немец-фашист илбасарлары белән көрәштә иптәш Гәрәев батырлык, кыюлык һәм курку белмәү үрнәкләре күрсәтте. Ул шулай ук подразделение белән оста җитәкчелек итүен дә танытты. Тишаково авылы өчен сугышларда аның подразделениесе дошманның тылына үтеп керде. Чолганышта калмас өчен, немецлар ашыгыч рәвештә авылдан чигенә башладылар. Әлеге бәрелештә иптәш Гәрәев подразделениесе 7 немецны әсир итеп алды, 200 ләп фашистны юк итте. Авылдагы ике корал склады, ике автомашина, бер туп та аның кулына төште. Операция вакытында подразделение барлыгы 9 торак пункттан дошманны куып чыгарды.

Скучарево калкулыгына якынлашканда фашистлар зур каршылык күрсәтте. Подразделениегә дошманның траншеяларына үтеп керү бурычы куелды. Ул намус белән үтәлде, сан ягыннан шактый күп булуына карамастан, фашистлар кул сугышында тулысынча тар-мар ителде. Бәрелеш вакытында иптәш Гәрәев яраланды, әмма сугыш кырын ташлап китмәде»,— дип язган майор Титов 1943 елның 3 августында аны Кызыл Йолдыз орденына тәкъдим иткәндә. Мондый эчтәлектәге язмаларны бүләкләү кәгазьләреннән әле күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Алар барысы да татар халкының данлы улы Мәхмүт Әхмәтдин улы Гәрәевнең фронтта кемнәрдер җилкәсе артына яшеренеп йөрмәгәнлеге турында сөйли. Һәрвакыт алда, ут эчендә булган ул.

...Аларны, Берлин өчен әле сугышлар барган бер чорда, хәрби эшелоннарга төяп Ерак Көнчыгышка озаталар. Безнең ир-егетләрне алда милитаристик Япония белән аяусыз көрәшләр көтә. Фашистик Германиянең капитуляциягә кул куюын Мәхмүт Әхмәтович Свердловскида ишетә. «Мин 9 Май көнне Ерак Көнчыгышка баручы хәрби эшелонда дежур идем. Әлеге хәбәрне радиодан ишеткәч, шатлыгымның иге-чиге булмады»,— дип, искә ала армия генералы.

Япония җиңелгәннән соң, аның өчен сугыш беткәндер дип уйлыйсызмы? Ялгышасыз. Ул башта киңәшче сыйфатында Кытай Халык-азатлык армиясе составында була. Яшь генералны 1971 елда Мисырга хәрби киңәшче итеп җибә-

рәләр. 1989—1990 елларда исә ул Әфганстан президентының баш хәрби киңәшчесе булды. Шунда контузия алды.

... Армия генералы Гәрәев мине, каршы алгандагы кебек, Кораллы Көчләр Генеральный штабының тышкы ишегенә кадәр озата чыкты. Без бик җылы саубуллаштык.

Бәхеткә, бу искиткеч кеше белән озак та үтми тагын очрашырга язган икән. Теге очрашудан соң берничә ай вакыт узгач, көзге көннәрнең берсендә, эш урынында телефон шалтырады. Трубканы алуга мин аның тавышын танып алдым: Мәхмүт Әхмәтович Гәрәев! «Ни хәлләр, якташ! Менә хәлеңне белим, дип шалтыратам әле»,— ди бу серле генә итеп. Күңеле бик күтәренке булуы сизелеп тора: шаян сүзләр, мәкальләр кыстырып җибәрә. Тукта, ничек соң әле тавышы янәшәдә басып торган кебек бик ачык, чиста яңгырый? «Сез кайдан шалтыратасыз, Мәхмүт Әхмәтович» — дип сорыйм мин, моның серенә һич төшенеп җитә алмыйча.

— Казанда мин. Сиңа Премьер-министр Мөхәммәт Галләмович Сабиров кабинетыннан шалтыратам,— диде шулчак армия генералы.

Ул беренче минутларда минем аптырап калганны аңлады бугай, тиз генә хәрбиләрчә конкрет «эшкә» дә күчте:

— Әйдә, кайда булса да очрашыйк, сөйләшик. Теләсәгез, минем янга — танк училищесы кунакханәсенә китәбез. Башта синең эш урыныңа барасым килә. Каршы түгелдер бит?

— Рәхим итегез, Мәхмүт Әхмәтович, көтәрбез,— дидем мин, куанып.

Алар Пресса йорты янына берничә «Волга» автомобилендә килеп туктадылар. Ишектән бер төркем генераллар, полковниклар кереп килгәнне күргәч, вахтадагы милиционерлар да башта аптырап калдылар. Аннары кулны фуражка козырегы янына куеп, гаскәриләрчә озатып җибәрделәр үзләрен. Армия генералы Гәрәев үзенең юлдашы — Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылында туып үскән авиация полковнигы Васыйл Шәрипов белән «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясендә ул кичне озаклап утырды. Газетаның баш редакторы, Татарстан Республикасы халык депутаты М. Әһлиуллиннан татар матбугаты турында җентекләп сорашты. Аннары бөтен коллектив белән бергәләп чәй эчте, истәлек өчен фоторәсемгә төште.

Ә икенче көнне без Кама Тамагы районына чыгып киттек. «Иптәш армия генералы, бәлки, кире уйларсыз? Күрәсез бит, яңгыр әнә ничек чиләкләп ява. Хәзер авыл юлларында машина белән батып ятуың да бар»,— диде Казан югары командалык танк училищесы начальнигы генерал-майор Г. А. Тимашов.

— Мине юкка үгетләмәгез, Геннадий Александрович. Әни миңа, туган төбәгемә — Атабай авылына кайтып йөр, борынгы бабаңнар туфрагын онытма, дип васыять әйтеп калдырды. Мин менә шуның өчен дип командировкадан кайтышлый Казанда махсус тукталдым,— диде Мәхмүт ага, бернинди үгет-нәсихәткә урын калдырмыйча.

... Ул, әлеге авыл урамына аяк басканчы, аны читтән шактый гына вакыт ничектер моңсуланып күзәтеп торды. Аннары, башкаларга күрсәтмәскә тырышып, күз яшьләрен сөртеп алды. Борынгы бабалары туфрагын күрү данлы генералның да хисләрен нечкәртеп җибәргән иде. «Әни бу яклар турында гел-гел сагынып сөйләде. Бер чыгып киткәннән соң, үзенә кайтырга гына насыйп булмады. Чит җирләрдә җирләдек үзен»,— диде Мәхмүт Әхмәтович, үзенең хисләре белән серләшкәндәй итеп.

Атабай авылы — Ленин исемендәге колхозның бер бригадасы. Кайчандыр бирендә 150 ләп йорт булган, диләр. Ә хәзер исә алар шактый сирәкләнеп калган. Әле тегендә, әле монда буш нигезләр күренә. Кече авыллар язмышы Атабайны да читләтеп узмаган. Без менә шундый нигезләрнең берсенә килеп туктадык.

— Сезнең бабагыз Гафиятулла йорты менә шушында торган,— дип сөйли колхоз бригадиры Нәриман Госманов.— Авыл картлары аның турында соклanып сөйлиләр иде. Ул Бәки волосте башлыгы булган, халык арасында зур абруй белән файдаланган. Бер генә кешенең үтенечен дә кире кагарга тырышмаган...

Авыл урамы буйлап мәһабәт гәүдәле генерал йөргәнне күреп, Атабай кешеләре аның тирәсенә бик тиз җыелып өлгерде. Үзләренең авылдашлары икәнлеген дә белгәч, аларның һәркайсы җылы итеп Мәхмүт Әхмәтовичның кулын кысарга тырышты. Менә шунда бу як халкының кунакчыллыгы да үзен сизләрде. Һәр гаилә генералны үзенә чәй эчәргә алып керергә теләде. «Баш тартып, ялындырып булмастыр, ахрысы. Фамилиябез дә бер төсле икән. Әйдә, үземнең адашларга керим әле»,— дип, Әмир һәм Сәгадәтбану Гәрәевләр капкасыннан атлады Мәх-

мүт ага. Авыл өендә, чәй табынында ул бөтенләй ачылып китте. Атабай кешеләренең тормыш хәле, көнкүреше турында бик нечкәләп сорашты.

— Әни, безнең авыл белән янәшәдәге тауга менүгә зур урман башлана, дип сөйли иде. Ул хәзер кая киткән соң?— дип тә сорап куйды генерал.

Моңа инде озак еллар узган. Атабайлылар аны әкренләп кырып бетергәннәрдер, иген чәчү өчен басу ясаганнардыр, мөгаен. Менә шунда картларның хәтере бик ярап куйды. «Хәзер дә тау өстендәге басуларның берсен Каенлык, икенчесен Имәнлек басуы дип йөртәләр бит. Әлеге атамалар, мөгаен, шул чорда калгандыр. Әниегез Рәхимә апа шул урманнарны хәтерләгән булгандыр»,— диделәр бабайлар. Әйе, кеше табигатьне саклау турында соңыннан — эш узгач кына уйлый шул.

Менә Атабай кешеләре белән саубуллашыр минутлар да җитте. Тагын җылы итеп кул кысышулар башланды. Колхоз рәисе Зөфәр Гарәфиев: «Мәхмүт аганың кулын авырттырып бетермәгез тагын. Сезнең кебек көрәк, сәнәк тотып эшләгән кеше түгел ул»,— дип кисәтмәсә, генералга йөзләгән кеше — игенче-механизатор белән шундый тәртиптә хушлашырга туры килер иде. Ул үзен озата килүчеләргә бик җылы итеп кулын болгады һәм җиңелчә генә башын иде дә автомобильгә кереп утырды. Авыл читендәге зират турына җиткәч, генерал бераз гына туктап торырга кушты. Аннары машиналар Кама Тамагына юл алды.

... Мәхмүт Әхмәтович Татарстаннан бик җылы хисләр белән китте. Кама Тамагы районы администрациясе башлыгы, халык депутатларының район Советы рәисе Миндел Шәмсетдинов бүләк иткән электр самавырын кабул итеп алганда тагын хисләнде чал генерал.

— Хатыным, балаларым белән чәй кайнатып эчәрбез, туган якны гел сагынып искә алырбыз. Зур рәхмәт, туганнар! — диде ул.

Аның сүзләрендә чын мәгънәсендә сагыш сизелә иде. Туган телендә чипчиста итеп сөйләшә белүе, борынгы җырларыбызны онытмавы, уен-көлкегә хиреслеге белән якташларын сокландырды генерал. Ул Кама Тамагына тагын кайтырга, элемтәне өзмәскә вәгъдә итеп китте. Хәзер, телефоннан сөйләшкән саен: «Татарстанда хәлләр ничек? Минем якташлар — Кама Тамагы эшчәннәре сынатмыймы анда?» — дип сораша Мәхмүт ага. Борынгы бабалары ягы, туфрак җылысы аны үзенә нык тарта. Яшәү мәгънәсе турында уйландыра.

**Нургали БУЛАТОВ.**

# ГАЛИҖӘНАП СҮЗ ОСТАСЫ...

Әмирхан ага Еники!.. Татар әдәбиятында гаять үзенчәлекле, ифрат серле һәм сокланггыч иҗат мәйданын тәшкил итүче олы әдибебезнең өч томлы «Әсәрләр»е дөнья күрү, һичшиксез, игътибарга лаеклы вә бәян ителергә тиешле вакыйга. Сүз дә юк, әдәбият сөючеләр өчен бу күптән көтелгән кадерле бүләк булды. Ләкин бу шатлык хисе аз гына үпкә, күпмедер дәрәҗәдә рәнҗү белән дә өретелгәндәй тоелды. Инде бит Әмирхан агадан күпкә яшьрәк һәм иҗади куәте ягыннан күпкә кайтышрак каләм ияләренең том-том әсәрләре басылып чыкты. Нигәдер бездә гел шулай килә: иҗат кырыннан, талантны этә-төртә, иң әүвәл әрсезлек белән ертлачлык йөгерә. Аһ, Тукай, Тукай! Аптырау катыш бер көрсенгән вакытта тагын Сиңа мөрәҗәгать итәбез: «Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү?..» Калган сүзләрен дәвам итмим. Куркам. Ниндидер тыелган, ярамаган гомер битен ашыгып актару булырдыр кебек...

Ярый, соң булганчы уң булсын дигәндәй. «Әсәрләр»нең дөнья күрүенә шөкеранә итәргә кирәк. Өлкән әдибебезнең әсәрләр тупланмасына укучы күптән зарыккан иде бит инде. Китап киштәсенә нәкъ менә шул нәфислек, затлылык белән үрелгән хикәя һәм повестьлар җыелмасы җитми иде. Әнә шул моң — сагыш белән сугарылган, хисләрне иркәли, җанны сафландыра торган әсәрләр тупланмасын бергә күрәсе килү ихтыяҗы канәгатьләнүгә ничек сөенмисең ди?! Шулай да Әмирхан ага Еникинең «Соңгы китап» исемле әсәре томнарга керми калган икән. Кирәк иде! Ул бит гади автобиографик әсәр генә түгел. Татар халкы тарихының (һәм бик ерак тарихының) бер кисәген эченә алган, катлаулы, болганчык та, шул ук вакытта кабатланмас үзечәлеккә ия 20—30 еллар тормышы, татар мохите, әдәби-мәдәни хәяте турында, сугыш чоры, сугыштан соңгы хәлләр вә бүгенге көн хакында уйланулардан гыйбарәт роман бит ул! Ә. Еникинең күп әсәрләрен аңлау, күңелне кузгаткан күп әдәби моментларның асылына төшенү өчен дә ул китап алыштыргысыз күрсәткеч-белешмә була ала. Юк, шул «Соңгы китап» томнардан читтә калган. Заман зары — кәгазь кытлыгы сылтау булды микән? Ирексездән, К. Сибгатуллинның «Туфан белән сөйләшү» поэмасыннан юллар хәтергә килә:

*Дөньябызны инде кәгазь төргән.*
*Җитә генә, димим,*
*артык та.*
*Бетеп куя, ләкин,*
*Кол Галигә...*
*Кол Галигә кирәк вакытта.*

Заманыбыз Кол Галие булган олуг әдип иҗатына чорның кырыс бизмәне белән якын килергә ярыймы соң инде? Киләчәк буыннар безнең турыда ни уйларлар, ничек бәяләрләр? Мин, гап-гади укучы, гәрчә бер катышым булмаса да, нигәдер Әмирхан ага каршында бер уңайсызлану кичерәм. Соңарган үкенүдән дә аяныч лырак бер нәрсә дә юк бит ул. Ходай үзе ярлыкасын...

Хәер, дөньяның мәшәкать-авырлыгын күп татыган, иҗат диңгезенең татлы да, уртларны яндыра торган ачы да «шәрабен» җитәрлек авыз

иткән Ә. Еники бит әле ул. Шатлыкны да, гаделсезлекне дә олпатларча сабыр, аксакалларга хас тыныч хис-акыл белән каршы ала белгән Әмирхан ага ич ул. Гадәттәгечә, сабыр-салмак кына баш кагып куйгандыр, фәлсәфи бер зирәклек белән күңеленнән генә уйлар уздыргандыр... Шулайдыр...

Гомумән, Әмирхан Еники турында язылган барлык мәкаләләрдә диярлек «моң» сүзен кулланмый калмыйлар. Шәрехләүләр генә үзгә: «якты моң», «моңсулык», «сүзсез моң», «әчке моң»... Болар барысы да әнә шул ил агаларына хас булган олпатлыктан, галилектән, рух бөеклегеннән килә. Алыйк «Әйтелмәгән васыять» повестен, алыйк «Матурлык», «Кем җырлады?», «Тынычлану», «Туган туфрак» хикәяләрен — хисләрне кузгата, бәгырьләрне телгәли торган көче нәрсәдә бу әсәрләрнең? Ничек гади генә сүзләрдән шул рәвешле нәфис, затлы гыйбарә-тезмәләр ясап, гади генә вакыйгадан җаннарны бәргәләндерә торган әсәр иҗат итәргә була? Моны аңлатырга көч җитмәстер, ә бәлки мөмкин дә түгелдер... Ләкин кайбер сәбәпләрен күздән кичерү урынсыз булмас. Иң әүвәл буыннардан күчкән горур бөеклек, каннан килгән, тамырлардан аккан затлылык нәтиҗәсендә туган талант икәнен ачыклау зарур. Әмирхан ага — борынгы, тарихта шактый эз калдырган атаклы Еникеев мирзалар нәселеннән. Үзе әйтмешли, «чабаталы морзалардан». Моңа тукталуымның сәбәбе шунда, без «өлкән туган» идеологиясенә мөкиббән китеп, чабаталы мирзалардан рәхәтләнеп көлдек, мыскыл иттек, кыскасы, ятлар язган тамашада шамакай ролен уйнадык. Киресенчә, тарихның кайсыдыр борылышында христиан диненә күчеп, руслашып киткән татар мирзаларын авыз суларын корыта-корыта ләббәкәйләк рәхәтлеге белән берәмтекләп санадык, чыр-чу килдек. Имеш, фәлән рус язучысында татар каны ага икән... Ул гына да түгел, фәлән урыс патшасы да бездән икән бит әле, әй... И-и, бездәге борча куанычы... Никадәр өтәләнсәк тә аң булыйк: «бездән» чыккан булсалар да — Карамзин да, Тургенев та, йә булмаса Куприн да чыкылдап торган рус әдипләре! Шуңа күрә татар мәдәнияте өчен югалган язучы-тарихчыларда ничә процент татар барлыгын «чутлап» утыру — мәгънәсезлек. Елыйсы урында мәтәлчек атып сөенәбез, халык фаҗигасеннән вак канәгатьлек эзләп юанабыз.

Ә менә «чабаталы морзалар» — башка... Фаҗигабез дә, горурлыгыбыз да алар. Диннәренә-телләренә тугрылыклы калу, иманнарын сатмау өчен бер мизгел эчендә дәүләт терәге булган хаким сыйныфтан сукбайга, иксез-чиксез биләмә-байлыкларыннан язып чабаталы фәкыйрьгә әверелүне артык күргән кешеләрне милләтнең йөз аклыгы итеп тану бик тә, бик тә урынлы булыр иде. Бу сукыр фанатизм түгел, бу — тән ныклыгыннан битәр, рух бөеклеге, иман сафлыгы, илаһи көч белән аңлатыладыр. Әмирхан ага шулар кабиленнән. Шуңадыр, шул кавемнең дәвамчысы булгангадыр, аның иҗатында көндәлек ыгы-зыгы, бәләкәй борчу-мәшәкатьләргә югарыдан фәлсәфи елмаю, хәсрәт диңгезенең бер тамчыга тупланган ачысын касәгә салып, халкыбыз исәнлегенә тост күтәрү рухы яши. Аһ, Әмирхан ага, шул тарихмы, язмышмы касәсеннән бер генә йотым, бер генә тамчысын бүгенге елгыр һәм шөп галстуклы егетләргә татыттырып карасы иде! Бер генә йотым (тулы савытын ук булдыра алмаслар) каптырсаң да, орден-медаль, титул-премияләр коелыр да, зәгыйфь иҗат дөньялары шәрәләнеп калгач, үзләренә дә оят шифасы йокмас микән? Юктыр шул, юктыр! Ана сөте белән кермәгән, колхоз сөте белән кермидер ул. Файдасыздыр. Аның өчен Әмирхан агага иңдерелгән талантның вә горур-бөеклекнең чеметеме булса да таләп ителәдер. Шуңа да Еники иҗаты татар әдәбияты дөньясында үзгә тармак булып, аерым бер саф чишмәдәй чыңлый бирә. Цивилизация агуыннан, отышлы тема наркоманнары чирүеннән аерылып, чиста суларын тын гына чурлата-чыңлата ага ул чишмә. Баллы ялганнан, «көн кадагына суга» торган әсәрләрдән йончыган бер вакытта кыйбланы югалтмас өчен кирәк тә ул Еники әсәрләре. Аларда әнә шул гасыр газапларын вә сынауларын уздырып та, иманын һәм вөҗданын сатмаган татар халкының җан авазы, өманәте, хыялы яши. Азатлыгын, ирeген, хакимлеген югалткан мирзалар — ил агаларының буыннардан-буыннарга тапшырылган васыяте кайчан тормышка ашырдыр, Еники анысын әле белми, дәресрәге төгәл датасын әйтә алмый, әмма көндәлек

матбугатта басылган мәкаләләрендә әдип Татарстан мөстәкыйльлеген яклап саллы, төпле фикерләр белән чыгучы өлкән әдипләребезнең берсе булды. Әлегә ул (мин аның 60—70 елларда язылган әсәрләрен күздә тотып әйтәм) үзәк өзгеч моң, эчке чакыру белән милләттәшләрен туклык, көндәлек канәгатьлек йокысыннан уятырга тырыша. Акырын гына... Салмак кына... Дүрт гасыр ярым элек югалткан азатлыкның көрәш эстафетасын ышанычлы кулларга тапшыру өчен тәҗрибәле хөкемдар булып кына... Фәрваз Миннуллин әнә шул эчке хис кайнаган халәт турында әйткән дә иде: «Күздән яшь китерә, бәгырьне телгәли аның әсәрләре... Гүяки алар каләмне язу карасына түгел, ә бәлки хискә-моңга-сагышка манып язылганнар». Мин шәҗәрә кылларына кагылу нияте белән түгел, ә затлылык сәбәпләрен аңлау максатыннан уртаклашам бу фикерләрне. Азатлыгыбыз һәм бәхетебез хакына шәһит киткән бабаларыбызның әманәтен безгә җиткерә алган иҗат итеп кабул итәм Еники әсәрләрен. Иә, кайсыбыз, әйтегез, кайсыбыз бүген тамак кайгысы мәшәкатеннән күтәрелә ала? Кайсыбыз, гасырлар буе җыелган сорауларны учына кысып, көн борчуларыннан югары фикер йөртә ала? Нигә соң заман мөгез чыгаруларыннан күңелләре мүкләнергә өлгермәгән кешеләр тора-тора Еники сүзләреннән кыйбла эзли башлыйлар? «Әсәрләр»гә сүз башы язган М. Мәһдиевны тыңлыйк: «Чөнки ул гомер вакланмаган, табигать биргән язучылык сәләтен радиодан бүген ишеткән яңа карарга көйләп әрәм итмәгән, ул тауларга — татар халкының борынгыдан килгән күркәм әдәп-әхлак хәзинәсенә йөз тотып, шул тауларга карап иҗат иткән, шул тауларга карап безнең көндәлек тормышыбыздагы ыгы-зыгы белән исраф үткән мизгелләребезгә сызланган...»

Эчке моң, яшерен ышаныч вә хәвеф әнә шул гасырлар кичкән
олпатлыктан, ил агасы акылыннан саркып чыккан әманәт. Бу аһәң
мәйданнарга чыгып кычкырмый, кальгә диварларына күкрәге белән
ыргылмый, чөнки ул белә: аның максаты халыкны уяту, уйлату, гамьсезлек пәрәвәзе белән уратылган ымсындыргыч халәтеннән арынды-
рып, заман һәм гавам авазын тыңлату... Юк икән, ул тагын сабыр
итәчәк, көтәчәк, кырмыскадай тырышлык-үҗәтлек белән җимерелгән
ил-йортның, хыял-теләкләрнең туздырылган нигез ташларын кабат тәр-
типкә китерәчәк. Әмирхан ага сүзенең кыйммәтен гасырларда аңла-
ячаклар. Без — шул ерак тарихтан килеп, киләчәккә баручы поездда
вакытлы юлаучылар — аңлый алган кадәре фәлсәфәне чордашларга җи-
ткерә алсак икән. Еники моны үзе дә белә, шуңа ул кешенең тәрбиясенә,
гыйлеменә, дөньяга карашына түгел, ә нәкъ менә аның фани дөньялар-
дан бакый дөньяларга күчәчәк җанына, аның күңеленә, хисләренә мөрә-
җәгать итә. Шуңа да аның әсәрләрендә яктылык, гүзәллек, матурлык
белән бергә моң, сагыш, өмет вә ышаныч катыш сугарылган мәңгелек
хакында уйланулар саркып чыга... Без моны гади генә, коры гына итеп
табигать биргән талант дип атыйбыз. Табигать...'Иҗат методы белән
мавыккан татар әдәбияты теориясенә мин дә «өлеш» кертим әле: Ә.
Еники иҗаты табигать һәм мәңгелек фәлсәфәсенә нигезләнгән. Чорлар,
этаплар белән чикләнмәгән, сәяси кысалар белән киртәләнмәгән ул
иҗат.

Ә. Еники прозасын мин Дәрдемәнд шигърияте белән чагыштырыр
идем. Шул ук эчке фәлсәфә, кешелек һәм мәңгелек хакында уйлану-
лар... Сибгат ага Хәким шагыйрь турында шулай язган иде: «Дәрдмәнд
миллион еллар, мәңгелек белән эш итә. Шушы мәңгелек дөнья эчендә
аның үз җире, үз туфрагы, иле-ватаны шигырьләрендә конкрет төс ала.
Дәрдемәнд шигырьне җилгә, яңгырга, суларның агышы, тал-тирәкләр-
нең шавына колак куеп яза шикелле. Төрле өн-авазларны тыңлап яза».
Ә. Еники дә халыкның җанын, моңын, эчке хиссиятен тыңлап, тоеп яза.
Ә йөрәктән чыккан йөрәккә керә дә... Без аңлап бетермәгән әллә нинди
моң-авазлар бар Еники каләмендә. Миңа аның иҗаты нигәдер алтын
көз — әбиләр чуагы белән аваздаш тоела. Табигатьнең искиткеч бер
мизгеле... Матур, җылы, кояшлы. Рәхәт! Ләкин кызгылт-сары иңгән
яфраклардан, кыр буйлап елтыр-елтыр йөгергән пәрәвәз җепләреннән
нииндидер моң тарала, нәрсәдер гел тын гына кисәтеп тора: болар бар да
вакытлы, барсы да узачак... Ә. Еникинең үтә зәвыкълек белән үрелгән
иҗаты һәрдаим кисәтә сыман: дөнья фани, фани... Матурлыкка сусаган-

да, җанга җылы кирәктә мин кулыма Әмирхан ага китапларын алам. Ирексездән, икенче бер олуг әдибебез Гаяз Исхакыйның әлеге табигать халәте турындагы юллары күңелдә яңара: «Бөтен җир тын; бөтен тормыш — бөтен. Бөтен тирә-юнь — тук.

Ләкин бу тынлыкта әллә нинди моңлык бар. Аңлап бетерерлек түгел бер моңлык бар.

Кояшның шул үтә күренә торган яктылыгындамы, кояшның җылысын бөтен дөньяга тигез җиткерер өчен тырышуында, нурын яудыруындамы, әллә шул чиксез тын, ак көндә һаваланып кына агып йөри торган нечкә-нечкә күбәләк җепләрендә, үрмәкүч дилбегәләрендәме, бер бөхилләшү, бер аерылышу, бер кызганышу буявы, бизәге бар.

Бу көннәрне авылда әбиләр атнасы диләр... Бу көннәрнең җылысын карчыклар җылысына, бу көннәрнең матурлыгын карчыклар гүзәллегенә охшатканнар».

Инде Ә. Еникине тыңлыйк: «Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!» Беренче мизгелдә күңелне иркәли, рәхәтләндерә торган якты, матур, нәфис сурәтләр дулкынында тирбәләсең... Ләкин кинәт кенә, җанны сискәндереп атылган йолдыздай, эчке моң сызылып уза. Укучы сизә, бөтен барлыгы белән тоя: нидер кителә, нидер булачак. Әнә шул яшерен кыңгырау йөрәкләргә аваз салып, нәрсәдәндер, моңлы-сагышлы вакыйгадандырмы, әллә олы фаҗигадәндерме, хәбәр бирә. Уян, уйлан, уяу бул, дип искәртә.

«Әсәрләр»нең беренче томына кергән повестьлар күбрәк әдипнең иҗади тәҗрибәсе нигезендә туган әсәрләр булып, заман сулышын, чор борчуларын укучыга китереп җиткергән, әдәбиятта өр-яңа проблемалар күтәргән иҗат үрнәкләре булып кабул ителәләр. Иң беренче нәүбәттә алар, югарыда әйтелгәнчә, гамьле, уйлы күңелләргә адресландылар. Томда «Уяну» («Рәхмәт, иптәшләр!»), «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Рәшә» повестьлары урын алган. Дөрес, алар сюжет-композиция ягыннан да, идея үзенчәлеге ягыннан да бер-берсеннән аерылалар. «Уяну» («Рәхмәт, иптәшләр!») повесте сугыштан соңгы авыл тормышына багышланган. Канлы гарасаттан соң тыныч тормышка ихлас күңелдән сөенү хисе, заманнар да, яшәүләр дә яхшырачак дигән матур, тыйнак хыяллар тәэсирендә туган повесть иде ул. Бүгенге күзлектән караганда әсәрдә тормышны да, кешеләрне дә бераз идеаллаштырылган төсмерләргә манып-манып алу бар. Хәер, Әмирхан ага соңрак аны үзе дә ирония катыш «үтә современный» әсәр дип атаган иде. Повесть беренче чиратта язучыга әдәбият мәйданында ныгу, позициясен көчәйтү өчен кирәк булды. Хәлиткеч һөҗүм алдыннан иркен бер сулыш алу кебегрәк иде бу. Моннан соң инде язучы ипле, көйле, югарыдан сызган җайлы юлдан «читкә» каерганнан-каера, рәсми сәясәт «буразнасын боза» башлый. Райком секретареның обывательгә әйләнүен күрсәткән «Саз чәчәге» повесте дөнья күргәч, власть тәнкыйте бер мәлгә исәңгерәп калды. Көтмәгән иде ул моны, уйламаган иде!

Ә менә инде «Рәшә» повесте басылгач, рәсми орган әгъзалары коточкыч чыр-чу куптардылар, көндәлек матбугат битләре аша «гадел социалистик җәмгыятьнең» йөз аклыгын яклап тәнкыйть уты яудырырга керештеләр. Аеруча шул заманың бер философы бик активлык күрсәтте. Әмирхан ага үзе аны нәкъ менә «бер философ» дип кенә телгә ала һәм ул, һичшиксез, хаклы: ә нигә әле үткән заманның нафталинлы идеологиясен кабат бу көнгә казып чыгарырга ди?! Исеме тарихка кереп калсын өчен Эфес шәһәре храмын яндырган Герострат сыманнар татар тәнкыйтендә дә җитәрлек. Бу мәкаләдә генә булса да аның атын Әмирхан ага исеме белән янәшә куймыйм. Вакыт үз хөкемен чыгарды ич инде: Әмирхан ага кайда да, ул философ кайда... (юк, чынлап та кайда?). Ә. Еники совет чынбарлыгын ямьсезләп сурәтләүдә, тормыштан гел кара якларны эзләүдә һәм иҗатының социалистик реализм принципларына туры килмәвендә гаепләнде. «Рәшә»дәге Зәфәр Сабитов безнең

җәмгыять өчен типик түгел дип бәяләнде, тәнкыйтьче: бу бит хакыйкатьне бозу, дип шаулады. Ә заман, тормыш нәрсә күрсәтте? Җәмгыятьнең түр башына оялаган кемсәләрнең караклыгы һәм оятсызлыгы, чиктән ашкан ришвәтчелек, казна талаучылык, коточкыч тамыр җәйгән коррупция күренешләре фаш ителә башлагач, Сабитовның кылганнары гап-гадәти хәл, күрше бакчасыннан кыяр чәлдерү ише генә булды да калды. Ә бит Ә. Еники әнә шул үтә азган социаль чирнең сиптомнарын алдан күрә алган һәм кешелекне уяу булырга чакырып чаң каккан иде бит. Ә тәнкыйтьче яза: «Рәшә» повестендагы вакыйгалар һәм образлар — халык тормышы ташкынының өстә йөзеп йөри торган чүп-чары, ярга ташланып җилгә очачак күбекләре». Сүз дә юк, шәп «күрәзәчелек»! Шулай да аның бер фикере белән килешми мөмкин түгел: Еники әдәбиятта «үз сызыгын бөгеп килә», ди ул һәм язучыны «принципиаль» кирелектә гаепли.

Иҗатта үз юлын алган, намусын вә вөҗданын маяк итеп баручы әдипне кыйбласыннан яздыру мөмкин түгел инде. Авыр, борчулы, каршылыклы бу юл. Бик зур ихтыяр көче таләп итә торган юл. Аның бар газабын Әмирхан ага гына белә. «Үрмәләп менгәндә генә мин тагын түбәнгә тәгәрәдем бугай...» — дип яза әдип. Бу әлеге тәнкыйть мәкаләренең мәкерле, зәһәр нәтиҗәләре иде. Кем белә, шул «кыйналулар» Ә. Еникинең вакытын, рухи көчен исраф итмәгән булсалар, язучы безне тагын күпме гүзәл хикәя-повестьлары белән сөендергән булыр иде әле.

«Әсәрләр»нең икенче томын ачып җибәрүче «Әйтелмәгән васыять» повесте Ә. Еники иҗатында гына түгел, ә бөтен татар әдәбиятындагы иң гүзәл әсәрләрдән саналырга хаклы. Бүген, кисәк кенә саташулы авыр йокыдан уянып, исәңгери-аптырый тирә-юнебезгә карап: «без нишләдек», «безгә нәрсә булды» дигән газаплы сорауларга җавап эзләгән бер вакытта, Әмирхан ага чирек гасыр элек үк бүгенгебезне күргән һәм кисәткән булган икән инде. Буыннарны ялгап торучы борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне, әхлак кануннарын, яшәеш кагыйдәләрен санга сукмау тәзәтеп булмастай фаҗигаләргә китерергә мөмкин. Акъәби һәм аның үтә заманча балалары арасындагы мөнәсәбәттә язучы шул идеяне уздыра. Цивилизация театрында «современный» рольләрне бик тырышып башкарудан роботларга, манкортларга әверелеп баручы ул һәм кызлар әниләренең җанын аңлый алмыйлар, дөресрәге, аңларга теләмиләр. Машиналар сатып алырга хәлләреннән килеп тә, аталарының каберенә таш куйдырырга да җай тапмаган балалардан нинди миһербанлык, шәфкатьлелек, изгелек көтәргә мөмкин ди? Акъәбинең туган туфрак, нигез хакындагы уйлары, буыннардан буыннарга тапшырылырга тиешле мөкатдәс сүзләре — соңгы васыяте таш күңелләргә бәрелеп чәлпәрәмә килә. Ә. Еники кисәтә: сак булыгыз, әхлакый тәшенчәләрне җимереп-сытып узучы каты буын килә. Әмма үлем түшәгендә яткан Акъәби рухы белән, иман-ышанычы белән көчле. Чөнки ул әнә шул халык җанына, үзенең Юлкотлы туфрагына таяна, шулардан җан вә иман ныклыгы ала. Бу очракта Акъәби васыяте һәрберебезгә төбәлгән һәм ул һәрберебезне сискәндерергә тиеш: «Онытмагыз!»

Әмирхан ага беркайчан да шау-шулы иҗади кампанияләрдә катнашмады, отышлы темалар белән мавыкмады, һәртөрле вак чыр-чулардан өстен вә азат булды. Аның әсәрләре дә нәгърә ормыйлар, уйчан, салмак кына акыл, гамь чәчәләр. «Без дә солдатлар идек» повесте Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына багышланган. Бирендә баталь картиналар юк, һөҗүм, дошман белән йөзгә-йөз килү күренешләре сурәтләнми. Кечкенә генә бер взвод каравыл хезмәте үти, сугыш кораллары складын саклый. Ватан азатлыгы окопларда гына түгел, тылда да, Еникилар булган «нестроевой» хезмәттә дә хәл ителде. Казакъ Өметбаев, үзбәк Ишмәмәт, татар Төхфәт, рус Шумиловлар тыныч кына, күзгә артык бәрелеп тормый гына үз бурычларын башкаралар, ипле бер тырышлык белән Җиңү көнен якынайтуда өлешләрен кертәләр. Әмирхан ага аерууча бер җылылык белән шулар турында сөйли. Һәм өмет катыш әйтә: «Онытмагыз, без дә солдатлар идек», — ди.

Өченче томда язучының иң яхшы хикәяләре тупланган. Бары дүрт дистә ел элек кенә татар әдәбиятында Ә. Еникинең нәфис, зәвыкъ белән үрелгән, шәфкатьлелек чәчүче, якты сагыш, кайвакытта үзәк өзгеч моң белән сугарылган хикәяләре юк иде бит — хәзер инде моны күз алдына

китерүе дә кыен. Ул хикәяләр аша укучыга тирән һәм нечкә хисләр гаммасы, үзенә бер төрле характердагы кешеләрнең эчке дөньясы ачыла. Уйландыра да, сокландыра да, моңландыра да... Иң әүвәл мин үзем Әмирхан Еникинең «Кем җырлады?» хикәясе белән таныштым бугай. Әсәр күңелгә мәктәп дәреслеге аша килеп керде. Хикәя бик кыска, әмма гаять тетрәндергеч. Ватан сугышы еллары. Кечкенә генә җимерек станциядә ике эшелон очрашып, янәшә туктыйлар. Берсе фронтка китеп бара, икенчесе фронттан тылга яралылар төяп кайта. Вагоннарның берсендә яшь татар лейтенанты үлем белән тартышып, саташып ята. Кинәт егет колагына татарча җыр ишетелә. Каршы эшелонда бер кыз моңаеп җырлый. Егет әсәрләнгән: бу бит аның сөйгәне Таһирә тавышы! Поездлар кузгалып китә. Яралы аңына килми үлә. Ләкин безне тетрәндергәне бу түгел иде (сугыш — сугыш инде, нишләтәсең), иң ачындырганы хикәянең соңгы җөмләсе булды: «Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон ишегенә сөялеп, ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә, чыннан да, бу егетнең сөйгәне Таһирә иде».

Хәтерлим, дәрес буе без хикәя тәэсирендә булдык. «Нигә инде яралы егет үләр алдыннан гына булса да Таһирәсе белән очрашмый икән?» — дип укытучыны да аптыратып, йөдәтеп бетердек. Язучыга да үпкәләдек. Хәзер уйлыйм: Әмирхан ага безнең күңелләрне яулап алып, үзебезгә дә сиздерми генә гаҗәеп серле һәм мавыктыргыч әдәбият дөньясына алып кереп киткән икән. Кайвакытта язучы фаҗигале, драматик хәлләр турында сөйләсә дә, аның әсәрләре һәрвакыт өмет, ышаныч хисе уяталар. «Тауларга карап» хикәясен генә алыйк. Ике сугыш Локман картның улын һәм оныгын һәлак итә. Адәм баласы өчен шуннан да олы кайгы, шуннан да катырак хәсрәт бар микән? Карт өчен дә яшәү мәгънәсе югала, бары тик нәселенең тамырын өзгән дошманга карата чиксез ачу-нәфрәте генә аны бу дөньяда тота. Ләкин кинәттән оныгының баласы барлыгы мәгълүм була, бу исә Локман картка яшәп китәргә терәк, тормышка тотынырга көч бирә. Хикәя тирән фәлсәфи мәгънәгә ия, ул тормышның мәңгелеге, буыннарның өзелмәс чылбыры хакында уйланыларга этәрә. Р. Мостафин «Тауларга карап» хикәясе фикри тирәнлеге, характерларның бирелеше ягыннан кайбер калын романнарга торырлык, дип хаклы билгеләгән иде.

Ә. Еникинең бер үзенчәлеге шунда, ул беркайчан да фикерен көчләп такмый, әсәрләренең идеясе кычкырып тормый, ә эчкә яшерелгән була, образ яки вакыйгалар аркылы укучы аны үзе эзләп таба, җаны белән тоя. Шуңа да аның әсәрләреннән бүген безне борчыган күп сорауларга җавап табарга мөмкин. Әйтик, заман проблемаларының да проблемасы — экология мәсьәләсе. Ул хакта хәзер күп сөйләнелә, роман-повестьлар да дөнья күрә тора. Ә. Еники бу хакта махсус язып чыкмады, әмма тыңлыйк әле: «Ә беләсезме, тургай сайравының сихере нәрсәдә?.. Иң элек, сынаганыгыз бардыр, тургай сайраганда җир өстенә җиңелчә генә уйчан-моңсу бер тынлык җәелә. Әйтерсең, барлык табигать, барлык җан иясе, әдипләр әйткәнчә, сөкүт калып, тәмам мөкиббән китеп, бары аны гына тынлый, аны тыңлап сөенечле, сагышлы, ләззәтле бер рәхәткә чума... Икенче сихере шунда ки, тургай сайраганда дөнья ничектер искиткеч җәелеп, киңәеп, актырып киткәндәй була. Әнә шул югарыда кечкенә кошчык талпынган күкнең үзе шикелле үк, җир йөзе дә иксезчиксез булып, гаҗәеп тын, нурлы булып тоела башлый...» Бу инде «табигатьне саклагыз!» дип шөрран кычкырган коры үгет-нәсихәтләрдән күпкә үтемлерәк һәм көчлерәк яңгырый.

Әмирхан Еники һәр нәрсәдә матурлык күрә ала һәм шул гүзәллекне сакларга, якларга чакыра. Бер сүз белән әйткәндә: Әмирхан ага — матурлык мөфтүне. Шуңа да аның геройлары гүзәллеккә сокланучы затлар. Бу җәһәттән, әдип иҗат иткән хатын-кыз образлары аеруча хәтердә нык уелып кала. Алар үтә нәфис, сылу, гүзәл героинялар. Ул гына да түгел, алар әле эчке дөньялары белән дә затлылар, матурлыкка гашыйк, музыкага, сәнгатькә табынучы персонажлар. Мисал өчен, «Рәшә» повестендагы Рәшидә, «Гөләндәм туташ хатирә»сендә Гөләндәм, «Йөрәк сере» әсәрендә Зөһрә шундыйлардан. Эчке матурлыкны Ә. Еники тышкы гүзәллеккә караганда югарырак та куя әле. Бу җәһәттән, әдипнең искиткеч соклану белән укыла торган «Матурлык» исемле хикәясе гыйбрәтле.

... Ике шәкерт җәйге ялга авылларына кайтып баралар. Юл унаеннан алар шәриктәшләре, мәдрәсәнең иң ярлы, әмма гаять горур һәм зирәк Бәдретдин шәкертне дә ияртәләр. Юлда аның өенә дә кереп чыгарга килешәләр. Бәдретдиннәр өенең фәкыйрьлеге шәкертләрнең бер исен китәрсә, рәхимсез чәчәк зәхмәтеннән коточкыч бозылып, ямьсезләнеп калган йөзле әниләрен күргәч, егетләр бер тетрәнү кичерәләр. Хәтта ул хатынның кыяфәте аларда чиркану хисе дә уята. Ләкин Бәдретдин үзе ясаган скрипкада уйный башлагач, кинәт могҗиза туа. Лирик герой әлеге халәтне түбәндәгечә тасвирлый: «... ана үзенең шәкерт улына шундый бер бөгырьгә төшәрлек тирән мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, эреп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы — гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге өнсез караш та, бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас нинди дер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде...» Хикәядә сурәтләнгән шәкерт егет белән әнисе арасындагы эчкерсез, серенә төшенеп булмый торган олы мәхәббәт хисе укучының күңелен дулкынландыра, җанын тетрәндерә торган хиссият дөньясында тибрәлдерә. Һәм ул, әсәр героена кушылып, әнә шул матурлыкны якларга әзер: «Кемгәдер йодрык селкеп, кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!»

Ә. Еники башлыча геройларның эчке дөньясы, аның кичерешләре, әхлакый хәле, психологик халәте белән кызыксына. Иң әүвәл ул кеше күңеленә каты кагылмаска чакыра, кайвакыт бер сүз, уйламаган бер саксыз ишарә шәхес драмасына, хәтта фаҗигасенә китерергә мөмкинлеген әйтә. Халыкта: «Кеше күңеле — пыяла, саксыз кагылсаң — уала»,— диләр бит. «Бер сүз» яки «Тынычлану» хикәяләрендә әнә шул уйламый әйтелгән бер гыйбарәдән, тупас мөнәсәбәттән туган киеренке хәлләр тасвирлана.

Гомере буе матурлыкка табынган, укучыны да матурлыкка сокланырга өйрәткән Әмирхан ага Еники хакыйкатькә дә тугрылыклы калды. Шуңа да аның әсәрләрендә бар нәрсәгә ышанасың, барысы да табигый, җанлы һәм тормыштагыча. Аларда ясалмалыкның эзе дә юк. Язучының һәр хикәясе, повесте фикерне уята, татлы сызлану булып күңелләрне били, гамьлелеккә өнди. Әдип иҗатының үзәгендә тормышка, кешеләргә ышаныч ята. Шуңа да аның һәр әсәре күтәреп алына, яратып укыла, уйландыра, газаплапдыра, сокландыра, фикерне уята. Ә. Еники үзенең иҗат кредосын билгеләп болай ди: «Кешеләр гадел, намуслы булсын! — менә нәрсә хакына мин язарга тиеш». Олуг әдибебез Әмирхан ага Еники шушы принципка гомере буе тугрылыклы булды һәм шуңа хезмәт итеп килә.

**Фәрит БӘШИР.**

# УРАЛДА МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ

Миңа Екатеринбург өлкәсендәге татар халкы күп яшәгән шәһәрләрдә татар класслары һәм балалар бакчаларында милли группалар ачу өчен сәяхәттә булырга туры килә. Хәзерге заманда, өлкәдәге шәһәрләрнең берсендә дә милли мәктәп юк, ә сугышка кадәр Свердловскида татар урта мәктәбе һәм педагогик училище булган. Шулай ук Дегтярск шәһәрендә, Красноуральскидә, Югары Түрәдә (Верхняя Тура) татар мәктәпләре булган.

Менә мин Серов шәһәрендә. Андагы 20 нче мәктәп укытучысы, якташым Розалия Сенцованың әйтүе буенча, шәһәрнең тарих музеенда Муса Җәлил турында материаллар булуын белдем. Музейга килдем, барлык стендлары белән танышып чыктым, ләкин Муса Җәлил турында бер нәрсә дә тапмадым. Аптыравымнан музейның фәнни хезмәткәрләре янына кердем. Минем соравыма алар бер җавап та бирә алмадылар. Бары Розалия Габдрахимовнадан телефон аша сорагач кына нинди материал турында сүз барганын аңладылар. Менә минем алдымда «Серовский рабочий» газетасының 1966 ел, 21 июньдә чыккан 121 нче саны. Аның бер бите тулысынча Муса Җәлилнең Надеждинск (хәзерге Серов) шәһәрендә булуына багышланган истәлекләр белән тулы.

Муса Җәлил Надеждинскига 1932 елның сентябрь башларында килгән һәм анда 3—4 көн булган. Бу еллар, билгеле булганча, Муса Җәлилнең Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасында эшләгән вакыты. Ә Надеждинскида 1931 елдан башлап «Эшче» газетасы татар телендә чыгып килгән. Бу елларда аның редакторы булып татар коммунистик университетын тәмамлаган Хөсәен Гайнетдинов эшләгән. Соңрак ул сугышта һәлак була. Мәскәүдәге «Коммунист» газетасы «Эшче» газетасының шефы булган. Һәм алар Надеждинскида ударник эшче хәбәрчеләрнең слетын үткәргәннәр. Анда 300 дән артык кеше катнашкан. «Эшче» газетасының хезмәткәре Б. Сибгатуллин Мусаның редакция эшчеләренә зур ярдәм күрсәтүе турында сөйли. Ул шагыйрьне металлургия заводы белән танышканда озата барган. Автор Муса Җәлилнең конторага кереп тормыйча, туп-туры эшчеләр янына баруын яза. Кунак журналист туктап-туктап эшчеләр белән сөйләшкән. Бигрәк тә беренче бишьеллыкта исеме бөтен илгә яңгыраган горновой Шәрифуллин белән озак сөйләшкән. Ул илдәге йөз дә бер домначы арасындагы ярышта җиңеп чыккан һәм җиңел автомобиль белән бүләкләнгән. Шагыйрьнең домначылар Бикмансуров, Сәгъдиев һәм Гимранов белән сөйләшүен Мөнәвир Бәдретдинов та искә ала.

Муса Җәлил слетта матбугатның хәзерге бурычлары турында доклад ясаган. Тәнәфесләрдә ул күп хәбәрчеләр белән сөйләшкән, аларның эше, тормышы һәм еллары турында сорашкан. Бу очрашуларда Муса үз газетасы өчен дә материал җыйнаган, шәһәрнең төрле почмагында, төрле завод һәм шахталарда булган. Әлеге көннәрдән бераз вакыт үткәннән соң, Муса Мәскәүгә кайткач «Коммунист» газетасының бер саны тулысынча Надеждински завод-шахталарына багышланып чыккан. Надеждинскидагы металлурглар мәдәният сараенда татарларның музыкаль, драматик һәм хор түгәрәкләре эшләп килгән. Алар берләшеп, слет көннәренә «Башмагым» спектаклен әзерләгәннәр. Муса Җәлил спектакльне зур дикъкать белән тыңлаган һәм уенда катнашучы Сибгатуллин аның үзешчән актерларны мактавын искә ала. Алтынчы татар мәктәбенең ана теле укытучысы Нәфисә Вәлиева шагыйрь белән «Эшче» газетасы редакциясендә танышуын яза. Ул үзе дә газетага язып торган, редакциянең чыгаручы секретаре Җәмилә Әхмәтова аның ахирәте булган. Муса Җәлил, аның мәктәптә эшләгәнен белгәч, мәктәп хәлләрен кызыксынып сорашкан.

Нәфисә ханым Муса башлангычы белән бу көннәрдә интернациональ кичә үткәрелүе турында яза. Сибгатуллин ул кичәнең металлурглар культура сараендагы бүлмәдә үткәрелүен искә ала. Кичәдә татарлар, башкортлар, руслар һәм

заводта эшләүче немец белгечләре дә катнашкан. Төрле телдә җырлар һәм төрле халыкның музыкасы яңгыраган.

3—4 көн генә булуына карамастан, биредә Муса күп эшләр башкарып өлгергән. Мин сөекле шагыйребезнең эзләрен Уралда очратуыма бик шатландым. Ләкин, башта әйткәнемчә, 26 ел буенча Муса Җәлил турындагы бу материаллар, музейның экспонатларына әверелмәгәннәр. Розалия ханым 20 нче мәктәптә тәрбия эшләрен оештыручы булып та эшли. Бу мәктәп укучылары Муса Җәлил турында музей материаллары чагылдырылган реферат та язганнар һәм фотоальбом ясаганнар.

Югарыдагы истәлекләр буенча Надеждински шәһәрендә татар мәктәбе дә булган, клубларда татар сәнгате секцияләре эшләгән, татар телендә газета чыккан. Галия ханым Гафарованың әйтүе буенча, шәһәрдә ике мәчет булган. Ә хәзер бу шәһәрдә, Серовта, бары тик ике мәктәп каршында ике якшәмбе мәктәбе генә эшли башлады.

**Фәрид ШӘҢГӘРӘЕВ.**

Екатеринбургтагы татар һәм башкорт мәдәнияте үзәгенең идарә әгъзасы, физика-математика фәннәре кандидаты, сугыш һәм хезмәт ветераны.

* * *

Журналның күптәнге укучысы мин. Бүген сүзем — Татарстанның бәйсезлеге турында. Бу мәсьәләдә Мәскәү даирәләренә бик күп мөрәҗәгать, үтенеч, сорау хатлары, «Руки прочь от Татарстана!» кебек телеграммалар (РСФСР Югары Советына) җибәрдем, хәтта шуларның берсенә — тулы бәйсезлек алу өчен референдум үткәрү кирәклеге турында Ельцинның үзеннән дә (1 сентябрь 1991 ел) җавап алдым, аның күчермәсен Шәймиевка да җибәргән идем.

Боларны Казахстан татар-мәдәни иҗтимагый үзәге исеменнән җибәрдем. Референдум көннәрендә безнең кешеләр Казанда булды, анда бәйсезлеккә каршы көчләрнең кара эшен күреп, белеп кайттылар. Безнең үзәк шундый карар-тәкъдим чыгарды: Мәскәүнең, русларның Татарстан бәйсезлеген булдырмас өчен нинди генә басым ясаулары, төрле куркытулар, өндәмә-плакатлар белән эш итүләре турында (сурәтле документлар белән) рус телендә бер җыентык чыгарырга кирәк. Әшәкелекләрен бөтен дөнья халкы белсен, ул тарихи документ булып калсын. Бу эшне язучылар һәм абруйлы журналыбыз эшли алыр иде.

Сезне, хөрмәтле батыр көрәшчеләребез, референдумда җиңү белән ихлас күңелдән котлап,

**Мөхәммәтдин ГАРИФУЛЛИН,**
РСФСР мәгариф отличнигы,
Бөек Ватан сугышы ветераны.
Алма-Ата шәһәре.

* * *

Кадерле «Казан утлары!»

Сезгә хат язу теләге туды. Моңа сәбәпче — февраль санында басылган «Тарихи катламнар» дип аталган язма. Дөресрәге, «Мораса» атамалы су исеме миемне телеп алгандай булды. Нигәме? Чөнки безнең Әлшәй районы Югары Әверез авылы кешеләре — мишәрләр, дәү әнием (бездә — нәнәй) гел шул Морасаны, Чистай якларын сөйли иде. Кайчандыр шул яктан күчкәннәр, ахры.

Безнең авылда татарча газета-журналлар алдыралар, шул исәптән «Казан утлары»н да. Мин дә алам, сөенеп укыйм. Мәсәлән, Рабит Батулла — минем өчен зур бер... кем диим соң, сүз дә таба алмыйм тиңләргә! — аның «Сөембикә кыйссасы»н укып, әллә күпме әсәрләнеп йөрдем. Нинди яхшы әсәр язган Батулла агай! Менә шундый әсәрләрдән башка ничек яшәрбез — киләчәктә журнал бәясе «безнең кесәгә» үлчәнмәгән булса?

Киләчәктә дә шулай татарча, татарлар турында язсагыз иде, ерактан кан-

кардәшләрегезне берләштереп, аралаштырып, илһамландырып яшәтүче көч булып калсагыз иде. Тукаебыз әйтмешли, «гәрчә анда тумасак та», җаныбыз, рухыбыз синдә, безнең, и татарлар иле Татарстан!

**Әлмира ЗИННУРОВА,**
Башкортстан, Аксеново станциясе,
Ким поселогы.

* * *

Сезнең журналны күп еллар инде алып киләбез. Анда басылган әсәрләр чорыбызның бик күп якларын ача, милли, әдәби һәм хәтта дини дөньяны күзалларга ярдәм итә. Бигрәк тә танылган әдипләребезнең роман-повесть, хикәяләре, шигырь-поэмалары шатландыра безне: Иске Кулатка ягына Казан, татар мохите сулышын китерә. Әйе, чынлап та:

*Казан бит ул гүзәл кала,*
*Йолдыздандыр нур ала?!*
*Яңа уйлар нигезендә*
*Бәйсезлеккә юл сала.*

Амин! — дибез.

**Камил ХӘМЗИН,**
Сембер өлкәсе, Урта Терешка авылы.

* * *

Журналдан Ренат Харис шигырьләрен укып зур сөенеч табам. Татар телен саклап калу — барыбызның да бурычы. Бу юлда сез, Ренат, аеруча үзгә булып күренәсез: халыкчанлык, телегезнең сафлыгы белән дә аерылып торасыз. Бу сәләтне сезгә зур күләмдә файдаланырга кирәк. Заманыбызның үз шагыйре булырга хаклы сез, минемчә.

**Мөхәррир ШӘРИФУЛЛИН,**
Башкортстан, Дүртөйле шәһәре.

* * *

Хөрмәтле «Казан утлары»!

Журналның узган елгы 11 нче санында Тәлгат Галиуллинның «Замана балалары» исемле язмасы чыкты бит. Шул чор «җитәкче»ләренең, әйтик, Табеевның безнең Сарман районындагы «маҗаралары» турында шактый саллы хат юлларымын дип торам... Безнең урмандагы җитәкчеләр күнел ача торган «Ленин шалашы» турында... Әнә шундый кайбер «персональ пенсия»ияләре турында. Урыс матбугатында булса да, татарда алар турында ачыктан-ачык язу әлегә юк диярлек... ә кирәк иде... Менә шуның өчен дә Тәлгат әфәнде Галиуллинга зур рәхмәтлебез!

**Әннүрбик СӨЛӘЙМАНОВ,**
Сарман районы, Игәнәбаш авылы.

* * *

Мин — Әстерхан өлкәсенең Бирюковка дигән урыс авылында яшәүче тарих укытучысы. Журналыгызның 7 нче санында басылган Лена Шагыйрьҗанның «Йөрәк авазы» поэмасыннан «Өченче микрофон» исемле өзекне кат-кат укыйм, күзләремнән туктаусыз яшь ага. Әйтерсең, бу шигъри әсәр минем үз күнелемдә туган хисләрне сөйли... Минем ихтирамым белән олы рәхмәтемне шагыйрәгә җиткерсәгез икән.

Тагын берничә сүз: хәзер безнең төбәктә дә туган телебезгә тартылу башланды. Үзем дә Әстерхан үзәк фәнни китапханәсендә татар телен өйрәнү буенча түгәрәкләр оештырдым һәм без, өч укытучы, 3 группада 13 яшьтән 70 яшькә кадәр 35 кешегә (татарлар, хәтта урыслар да!) дәрес бирдек. Шулардан быел Казан университетының татар факультетына укырга керергә теләк белдерүчеләр дә булды. Аларны Казанда аңлап, ачык каршылаганнардыр дип беләм. Әле бу башы гына... Бергә-бергә яшик!

Зөлхәбирә ИШБИРДИЕВА,
Әстерхан өлкәсе.

* * *

Бу хатым — Кыргызстаннан сәлам булсын. «Казан утлары» килгән көн — уразамның соңгы сәхәре булды. Зур шатлык уты янды өебездә!

Миргазиян Юнысның «Шәфкать кыйбласы» исемле публицистик мәкаләсе бик тә вакытында чыккан. Урыс шовинистларының һәм аларга тәлинкә тотучы маңкортларның табан асларына утлы күмер булып ятачак. Ә безнең ишеләргә — җанга җылылык, зур шатлык, милли азатлык юлын яктырткан маяк булыр ул...

Тәүфикъ Әйди кереш сүз белән чыгарган «Яшерен васыять» тә Петр патшадан алып бүгенгәчә империя сәясәтен күрсәтеп тора. Рәмзи Вәлиев белән Мөхәммәт Мәһдиевнең «Болганчык еллар авазы», Флора Әхмәтованың «Камиллеккә омтылу» кебек мәкаләләре дә халык өчен бик кирәкле язмалар.

Т. ШӘРӘФИЕВ,
Кыргызстанның Токмак шәһәре.

* * *

Журналыбыз — минем иң якын дустым, көтеп алган кадерле кунагым, куанычым, шатлыгым... И, «Казан утлары», 62 ел буена сине укыдым, бөтен кайгы-хәсрәтләремне, авыруларымны онытгыручы син булдың. Күпме әсәрләр, күпме яңа әдип, шагыйрьләр, галимнәр дөнья күрде синдә 70 еллык гомереңдә! Барлык-барлык хезмәткәрләренә дә рәхмәт, димен.

Чын күңелдән, журналны яратып укучы, хезмәт һәм сугыш ветераны, инде сиксәнне ваклаучы апагыз —

Мәдинә ГАЙНЕТДИНОВА,
Казан шәһәре.

* * *

Хәзер миңа 45 яшь. Аркамда Әфган сугышының ярасы, Чернобыль фаҗигасе, сөекләмнең вакытсыз үлеме... Чит җир... Мөһаҗирлек... Ялгызлык. Ирексездән кулыма каләм алдым. Әмма зарланырга түгел, көрәш өчен, хөр яшәү өчен «Казан утлары» — шул юлда маягым!

Ә татар халкына сүзем:

*Аң бул, җәмгыять!*
*Колларны — колга,*
*Иңнәрне — иңгә!*
*...Яшә, хөррият!*

Муса ЗӘКИЕВ,
Ташкент шәһәре.

## ГОМӘР БӘШИРОВ

# КҮҢЕЛЕ ТУЛЫ ҖЫР ИДЕ



Мин бу язмамны халкыбызның сөекле җырчысы, Татарстанның халык артисты хөрмәтле Рәшит Ваһапов истәлегенә багышларга булдым. Моның берничә житди сәбәбе бар. Бердән: музыка дөньясында Р. Ваһаповның әллә нигә бер генә искә алынуы, аның җырларын сирәк ишетүебез, икенче төрле әйткәндә, бу останың иҗатын оныта башлавыбыз күңелне рәнҗетә. Минемчә, Рәшит дәрәҗәсендәге талант ияләре, аларның музыка сәнгатенә керткән мактаулы өлеше хәзерге яшьләргә үрнәк булып хезмәт итәргә тиеш иде. Тагын шунысы да бар: Рәшитнең арабыздан китүенә быел декабрьдә утыз ел тула. Вафаты алдыннан аның иң соңгы берничә көне шифаханәдә минем күз алдымда үтте. Шул сәбәпле бу хакта язмый калырга хакым юк дип саныйм.

Һәрвакыт ачык чырайлы, шат күңелле бу сөйкемле затны фәкать күңелгә ятышлы ягымлы сүзләр белән генә искә аласы иде. Аның тормышы да, җырларындагы кебек, аяз һавалы күңел күтәренкелеге шартларында үткәндер дип уйлыйсы килә. Ләкин тормыш дигәнең алай шома гына тәгәрәми бит, ул бер алдын күрсәтсә, биш артын күрсәтә, диләр. Булачак җырчыбыз Рәшит Түбән Новгород губернасы Актүк авылының имамы Ваһап хәзрәт гаиләсендә 1908 елда туган. Димәк, мәхдүм Рәшитнең балачагы халык арасында зур абруй казанган атасы — мөхтәрәм Ваһап хәзрәт тәрбиясендә узган. Ләкин өлкән буынның башыннан узган шомлы, хәвефле утызынчы еллар бу җырчының да йөрәгенә яра салып калдырган. Ваһап хәзрәт тормышы да, ул еллардагы бик күп дин әһелләренеке кебек, Берия төрмәсендә фаҗига белән тәмамланган. Әйе, ул еллар бөтен татар халкы өстенә зур бәла булып ябырылды, авылларны мәчетсез, муллasыз калдырды. Халыкны имансыз калдыру нияте белән эшләнгән коточкыч афәт иде бу.

Ата кебек газиз җанның гаепсез һәлак булуын улы Рәшит, билгеле, авыр кичергәндер. Ләкин бу хәсрәтне ул эченнән тынырга мәҗбүр булган. Заманы шундый иде. Сәхнәгә кояштай балкып килеп чыккан көләч йөзле бу чибәр кешенең йөрәгендә шундый тирән яра барын кем белгән? Күрәсең, ул хәсрәт әрнүчә моңлы көйләрнең йөрәккә барып кабына торган үкенечле сулышларында гына бәреп чыккандыр. Шундый фаҗигаләр кичергәндә дә төшенкелеккә бирелмәве үзе генә дә Рәшитнең көчле рухлы шәхес булуын раслый.

Рәшитнең туган авылын телгә алганда хәзерге талантлы җырчыбыз Хәйдәр Бигичевнең, танылган музыкант баянчы-импровизатор Рамил Курамшинның һәм Мәскәү консерваториясе профессоры Зәйтүнә Әхтәмованың да шул бәрәкәтле яклардан чыгуын әйтеп узу күңелләргә бик тә хуш килә. Бу як яшьләренең таланты ачылуга матур су буйлары, мул сулы күлләр-чишмәләр, сайрар кошлар

---

Рәсемдә: *җырчылар Дина Сираҗетдинова белән Рәшит Ваһапов. 50 нче еллар ахыры.*

ярдәм иткәндерме, ничектер, әмма шунысы хак: бу тирәләр сәнгатебезгә байтак кына күренекле талантлар бүләк итте. Шөкер, халкыбызның талант чишмәләре торган саен арта бара. Иншалла, боларга шундый ук игелекле башка чишмәләр дә кушылыр.

Рәшит Ваһаповның авылдашы Рифат Фәттахов раславынча, Рәшит яшүсмер чагында ук җырларга һәвәс булган. Авылдашлары кебек үк, ул да «Нурия» дигән җырны аеруча яратып җырлаган. Шулай да ул әле яшьтән үк җырчы булып китмәгән. Башта шул тирә авылларында укытучы булып эшләгән. 1941 елда Мәскәү консерваториясе янындагы татар опера студиясендә укып чыкканнан соң гына Рәшит бөтен гомерен җыр сәнгатенә багышларга булган.

Рәшит Ваһапов музыканың илаһи көченә, аның халыкка игелекле тәэсир итүенең биниһая булуына күңелендә тирән ышаныч һәм ихтирам саклаган. Минемчә, ул чын мәгънәсендә профессионал җырчы була алуына, алай гына да түгел, башкаларга һич тә охшатмыйча, фәкать үзенчә — Рәшитчә генә җырлый алачагына байтак тәҗрибә туплаганнан соң гына ышанып җиткән. Танылган җырчыбыз Җәваһирә ханым Сәлахова сөйләвенә караганда, ул ышаныч анда сугыш елларында авылларда концерт биреп йөргәндә туган. Концерт бригадасының чыгышы авыр эш белән йончыган, фронтлардан кайгылы хәбәрләр алган авыл халкының йөрәгенә ял булган, аның кайгы-хәсрәтен азмы-күпме онытып торырга ярдәм иткән. Җәваһирә ханым ул еллардагы концертларны халыкның кадерле җан азыгы итеп, хуплап каршы алуы, күз яшьләре белән тыңлаулары хакында әле хәзер дә дулкынланып сөйли.

Беркемнең дә кабатламый торган Рәшит Ваһапов үз сәләтенең көченә, үзенең халыкка кирәкле кеше, кадерле зат булуына беренче мәртәбә әнә шул концертларда ышанган. Аның сәләте концерт саен ачыла барган һәм ул, ниһаять, үз стилен тудырган.

Рәшит Ваһаповның иҗатын өйрәнүчеләр, хатын-кызларга багышланган җырларны киң сәнгать дөньясына берьюлы һәм күпләп алып чыгучы нәкъ Рәшит Ваһапов булды, дигән фикерне куәтлиләр. Бу фикергә кушылмыйча мөмкин түгел. Чыннан да, «Рәйхан», «Фирдәвескәй», «Әлфия», «Нурия» h. б. күп кенә мәшһүр җырларны Рәшитнең аеруча бер дәрт һәм күтәренке рух белән җырлавы, күрәсең, очраклы хәл генә булмагандыр. Минемчә, игътибар белән тыңласаң, Рәшит җырларында туган хатын-кызлар образы Йосыф кыйссасындагы Зөләйханың кайнар мәхәббәтен, Сөембикәнең горурлыгын, дастаннарда тасвир ителгән хатын-кызларның гүзәллеген, сөйкемлелеген искә төшерә. Бу һич тә гаҗәп түгел. Чөнки киң карашлы, сизгер күңелле зур артист буларак, Рәшит бу җырларында, минемчә, татар халкының хатын-кызга булган тирән мәхәббәтен, зур ихтирамын гәүдәләндерергә омтылган.

Рәшитнең хатын-кызларга багышланган уннап җыры арасында аның иң яратып җырлаганын — «Әлфия»не искә аласы килә. Минемчә, бу җырны башкарганда сөекле артистыбызның тавышының мөмкинлеге һәм осталыгы бөтен куәтенә ачылып китә. Бу җыр тыңлаучыга биргән эстетик ләззәте җәһәтеннән классик операларның кайбер мәшһүр арияләренә охшый. Әлфиягә өзелеп-өзелеп исеме белән дәшкәндә моң дигән тылсымлы көч җаннарны тетрәтеп уза. Бу гади җыр гына түгел. Юк, шундый моңлы гозере белән үзәкләрне өзеп гашыйк егет сөйгәненә үзе дәшә кебек тоела башлый. Рәшит Ваһаповның бу җыры, кайбер башка иҗат җимешләре кебек үк, кадерле мирас итеп сакланырга тиешле.

Тыңлаучыга эстетик ләззәт бирүдән тыш, бу җырлары белән Рәшит тагын бер изгелек эшләде. Мәгълүм ки, «Татар хатыны ниләр күрми» дигән пьесада хатын-кызларыбыз, иң күркәм сыйфатларыннан мәхрүм булып, бик аяныч хәлгә төшкән бичаралар итеп күрсәтелә. Р. Ваһапов исә җырларында тудырган шушы сөйкемле образлары белән хатын-кызларыбызны әнә шул кимсетүләрдән яклап, һәр җәһәттән дәрәҗәләрен күтәреп чыга.

Хәзерге яшьләрнең күбесе ритмга корылган эстрада такмаклары белән мавыгалар. Аларның мәшһүр җырчыларыбызның бай тәҗрибәләрен читләтеп узулары һич тә мактаулы гамәл түгел, дияр идем мин. Бу аларның иҗат мөмкинлекләрен чикли, халык моңына һич тә бәйләнеше булмаган, тыңлаучының күңел түренә үтә алмаган моңсыз, җансыз ясалма көйләр барлыкка килүгә сәбәпче була. Халыкны үз моңыннан мәхрүм итү — аны теленнән мәхрүм итү белән бер. Музыкада халык моңыннан читләшү халыктан ераклашу дигән сүз ул! Хәлбуки, Р. Ваһапов дәрәҗәсендәге осталарның бай тәҗрибәсе халык моңын тирәнрәк аңларга, аннан җан азыгы алырга, яңа көйләр иҗат итәргә ярдәмче булыр иде.

Р. Ваһапов иҗатына игътибар беләнрәк колак салсаң, бездә эстрада җырларының башлангычы аңа барып тоташа, дигән фикергә киләсең. Мин Рәшитнең

танылган артисткаларыбыз Җәвапирә Сәлахова, Динә Сиражетдинова, Рокыя Бәхтиевалар белән парлап җырлауларын күздә тотам. Бу инде җырны гадәттәгечә башкару гына түгел. Болай кара-каршы җырлауда эстрада элементлары да катнаша иде. Р. Ваһаповның бу җырлары, бигрәк тә Җәвапирә Сәлахова белән «Зөләйха»ны җырлаулары әле хәзергәчә истән чыкмый. Бу ике артистның тавышлары соклангыч дәрәҗәдә пар килүе, тирән моннары, башкару осталыклары, күңелләрне рәхәтләндерүләре сагынып сөйләргә генә калды.

Ни хәл итмәк кирәк, никадәр генә кыен булса да, сөекле артистыбызның соңгы көннәре хакында да сүз әйтмичә булмый.

1962 елның декабре иде бу. Р. Ваһапов шифаханәгә килеп керүгә сүлпән генә дәвам иткән авырулар тормышы җанланып китте. Әле 54 яше дә тулмаган якты чырайлы, шат күңелле чибәр артист тиз арада һәммәбез белән дә аралашып, уртак тел тапты. Хәлләребезне белеште, артистлар тормышыннан кызык вакыйга, йә мәзәкләр сөйләп күңелләребезне күтәрде. Аның яман шеш белән авыруы, артистыбызны хәвеф-хәтәр сагалап торуы ул көннәрдә берәүнең дә башына килми иде әле.

Беркөнне кичкә таба Рәшит мин яткан палатага хәлемне белергә керде. Операциядән соң миңа урыннан кузгалырга рөхсәт итмиләр иде әле. Байтак кына вакыт сөйләшеп уздырдык. Чыгып китәргә дип ишек янына баргач, ул кинәт кире борылды.

— Гомәр абый, берне генә җырлап күрсәтимме әллә? — диде.

Ул вакытта врачлар киткән иде инде. Иптәшем белән без бу тәкъдимне хуплап каршы алдык.

— Палатага гына «сыя аласыңмы соң?» — дидек.

— Тырышырмын, — диде Рәшит.

Ул ишеккә аркасын куеп авыз эченнән генә диярлек җырлап җибәрде.

*Аклы ситсы күлмәгеңнең*
*Якаларын кем уйган?*
*Әй, Рәйхан, исемен кемнәр куйган,*
*Сине күреп кем туйган...*

Җыр уртасындагы «әй-й-й»не сузганда тавышын «йөгәнләп» җиткерә алмады, күрәсең, ишек ачыла төште, аннан күрше палатадагы авыруларның, шәфкать туташының елтыраган күзләре күренде. Җыр тәмамлангач озаклап кул чаптык.

Рәшит шунда да шаяртып алды:

— Юк, «бис»не көтмәгез, анысы булмас! — диде.

Бу аның иң соңгы җыры булыр дип кем уйлаган бит!

Үзенә операция булачагын белгәннән соң да ул төшенкелеккә бирелмәде. Аның хәле мөшкеллеген без операциянең бик озакка сузылуыннан гына абайладык. Кич белән хәлен белергә кергәндә ул инде күзен дә ача алмый иде. Безнең сәламәтлек теләвебезгә сизелер-сизелмәс керфекләрен сирпеп кенә җавап бирде. Сөекле артистыбыз шул төндә үк фани дөньядан китеп тә барды.

Зур талант иясе, күренекле сәнгать әһеле иде Рәшит. Халкыбызның җыр байлыгын арттыруда, онытыла башлаган кадерле җырларыбызны тирән моң белән баетып яңадан халыкка кайтаруда аның хезмәте ифрат зур булды. Ул дистә еллар буенча иң сөекле, иң популяр җырчылардан саналды.

Әйткәнемчә, быел Р. Ваһаповның вафатына 30 ел тулды. Ярый әле, Рәшитнең якташлары, рәхмәт төшкерләре, аның туган авылында музеен ачтылар. Ә башкалар? Казан, филармония, мәдәният министрлыгы Р. Ваһапов истәлеген мәңгеләштерү өчен ниләр эшләде? Гомумән, ни сәбәпле бездә әдәбият-сәнгать әһелләренең кадерен белмиләр? Аларны халык чын күңелдән ихтирам итсә дә, хакимият даирәләрендә нигә һаман да империя заманындагы битарафлык, саңга сукмау, күрмәмешкә салыну яшәп килә? Нигә? Нигә, мәсәлән, шушы көнгә кадәр Казанда Сара Садыйкова, Мәрьям Рахманкулова, Рәшит Ваһапов урамнары юк? Бөтен татар халкының кәгъбәсе булган Казанны нигә аның тарихына, шәһәренә һичбер бәйләнеше булмаган ят исемнәр баскан? Әллә кайдагы Армавир, Даурия һәм башка шундый чит-ят исемнәр башкалабызны кайсы ягы белән бизи?..

Әдәбият-сәнгать әһелләре хакында сүз кузгалгач, бу өлкәдә эшләүчеләрнең тормышлары хәзер ифрат кыенлашуын да әйтергә кирәк. Җитәкче даирәләр бу тармакны игътибарсыз калдырмаска тиешләр иде. Тагын шунысын да әйтергә кирәк, җәмгыятьнең дөнья күләмендә тоткан дәрәҗәсен күпме чуен коюга карап түгел, бәлки фәне, мәгърифәте, әдәбият һәм сәнгате нинди югарылыкта булуга карап бәялиләр.

# САГЫНДЫРА КАЛӘМДӘШ

ЯЗУЧЫ ГАЗИЗ МӨХӘММӘТШИННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Табигать озын гомер насыйп иткән булса, язучы Газиз Мөхәммәтшинга быелның декабрендә 60 яшь тулыр иде. Әмма ул, олы кызганычка вә үкенечкә, кырык яше туларына ун ай калганда, 1972 елның февралендә арабыздан китте. Иҗатында иркен сулыш алып, яңа үрләргә омтылганда туктады аның йөрәге. Шулай да ул кулга алып укырлык, телгә алып сөйләрлек күркәм әсәрләр — сокландыгыч хикәяләр, әйбәт повестьлар, мавыктыргыч роман калдырды.

Газиз Фазлый улы Мөхәммәтшин белән мине Казан дәүләт педагогия институты таныштырды. Мин соңгы курста укый башлаган 1952 елда ул татар теле һәм әдәбияты бүлегенең беренче курс студенты булды.

Тәүге күрешүебез хәтердә калмаган. Газиз ай-һайламый гына, бик тыныч танышып китүчән егет иде. Педагогия институтына аны Минзәлә педучилищесында уку китергәндер дип уйлыйм, югыйсә аның мәгариф өлкәсендә түгел, әдәбият мәйданында эшләячәге югары уку йортына килүенең беренче айларында ук сизелә иде. Ул шигырьләр, хикәяләр язды, аларны әдәбият-иҗат түгәрәгендә укый. Энҗе Гыйрфанова, Хисам Камалов, Илдар Юзеев, Суфиян Сафуанов, Ләбиб Айтуганов, Суфиян Поварисов кебек каләмдәшләренең хөкеменә куя иде.

Мин аның «Алтын тешле Хикмәт» дигән хикәясен кульъязмада килеш укыганын бик яхшы хәтерлим.

— Син минем якташның портретын язгансың бит, агай-эне,— дидем Газизгә. Ул, гадәтенчә, хәйлә катыш көлде дә:

— Һе... Танадыңмыни? — дип куйды.

— Танымаска! Мин аны ничә елдан бирле беләм бит инде.— (Бу кеше укытучылар институтын бетереп, мәктәптә эшли иде. Стационарда укып, пединститут тәмамларга карар кылды да, Газизләр группасына килеп керде. Соңрак фәннәр кандидаты булды, хәзер Кырымда яши, диләр).

Хикәя — фотосурәт түгел. Газиз Мөхәммәтшин, әйтергә теләгән фикерне калку итәр өчен, өстәмә детальләр дә тапкан иде.

Институттан соң аспирантурада укып, мин Буага эшкә киттем. Ике ел Төмән өлкәсендә укытып, Казанга кайтып төпләнгән Газиз, «Чаян» журналы хәбәрчесе буларак, бу районга ике мәртәбә генә килде. Икенче сәяхәте вакытында без аның белән икәүләп журналга шикәр заводы төзелешеннән язма эшләдек.

1959 ел азагында мин янә Казанга килеп яши башладым. Озак еллар Газиз Мөхәммәтшин белән күрше йортларда гомер иттек. Дуслар идек, дияргә хакым бар дип беләм.

1960 ел Газиз өчен бик сөенечле булды. Аның беренче китабы — «Сер итеп кенә» дигән хикәяләр җыентыгы дөнья күрде. Әлеге җыентыкка кергән хикәяләр миңа һәммәсе дә бик таныш иделәр инде. Геройлар китапка чынбарлыкның үзеннән килеп кергәннәр. Дөрес, «Соңгы намазлык» хикәясендә кирәксезгә кызарып, динчеләрне сүгү, «нәкъ алласыз кешеләр — коммунистлар китерде бәхетне» дип шөрран яру бар. Бу — заманга ясак иде. Газиз генә түгел, бик күбебез мондый «мөгезләр»не чыгаргалый тордык. Иҗади бәхетенә, Газиз Мөхәммәтшинда әлеге әсәр бердәнбер очрак дияргә була. Тормыш дөреслегенә хилаф кылмаучы,

яшәешне нечкәләп күзәтә белүче, үзенең фикер иләгеннән үткәзгәнне кәгазьгә оста төшерүче язучы иде ул.

Газиз өлкәннәр өчен дә, балаларга дип тә бер дәрәҗәдә уңышлы язды. 1961 елда ул «Яз башы» дип атаган хикәяләр җыентыгын чыгарды. Әлеге китап, «Сер итеп кенә»нең очраклы тупланма булмавын раслап, мөһер басып куйды. 1963 елда исә Татарстан китап нәшрияты Газизнең «Без әле җирдә яшибез» повестен һәм аның янына кушып, «Ун бәпкә», «Мәк», «Бал чүлмәге», «Рәхимнең төше», «Автобустагы исем», «Ярык тояклы куян» хикәяләрен нәшер итте. Шушы хәл автор өчен яңа бер имтиханның уңышлы тапшырылуы иде. Юмор — гаҗәп тансык нәрсә, ул бездә күп түгел. Юмористик әсәр иҗат итү яисә хикәя-повестьны юмор белән сугару теләсә кем кулыннан килми. Газиз Мөхәммәтшин моны бик оста булдыра иде. Шулай да үзеннән бер вакытта да канәгать булмады ул, казанганнарына тәнкыйть белән карады.

Газиз өлкәннәр өчен повесть язарга бик җилкенә, әмма каләм алдымы — хикәя иҗат итеп куя иде. Шул рәвешле, аның «Йолдызлар астында» (1964), «Кояш кызы», «Торналар киткәндә» (1966), «Язгы кичтә» (1968) җыентыклары дөнья күрә торды. «Без әле җирдә яшибез» повесте өч кат басылды. Ике мәртәбәсе үзенең вафатыннан соң. Язучының мирасын укучыга тәкъдим итүдә каләмдәше Аяз Гыйләҗевнең тырышлыгын әйтү урынлы булыр.

«Иөрәктәге эзләр» романы (1967—1969) язучының иҗади хәзинәсендә аерым урын алып тора. Аны мәгълүм кимәлдә автобиографик әсәр диярге дә мөмкин. Аның баш персонажы язмышында яшь педагог Газизнең тормышына тәңгәл килгән манзаралар да бар. Шул ук вакытта романның баш каһарманы — Мөхәммәтшин гына түгел. Ул — гомумиләштерелгән образ, әдәби кануннарга нигезләнеп, авторның уй-хыял-



*1962 елда төшерелгән бу фоторәсемдә «Татарстан яшьләре» газете редакциясе каршындагы әдәби берләшмә әгъзаларының остаз-шагыйрь Сибгат ага Хәким һәм шул вакыттагы «Ялкын» журналының җаваплы мөхәррире язучы Газиз Мөхәммәтшин белән очрашу вакыты сурәтләнгән. (Беренче рәттә, уңда — Газиз Мөхәммәтшин).*

*Бу рәсемдә алтмышынчы елларда әдәбиятка килүчеләрдән Ренат Харис, Шамил Рәкыйпов, Ринат Рәхимов, Шамил Маннапов, Булат Сөләйманов, Тәүфикъ Камалиев, Хәниф Хәснуллин, Фарсель Зыятдинов һ. б. ның исемнәре бүгенге укучыларыбызга яхшы таныш инде. Аларның күбесе, төрле жанрларда уңышлы иҗат итеп, әдәбиятта үз урыннарын таптылар.*

ларын да үстереп иҗат ителгән җыйналма персонаж. Автор үзенең геройлары яшәеше аша мәңгелек теманы — мәхәббәт хәлләрен сөйли. Алай гына да түгел, автор яшәү мәгънәсе турында тирән уйлана, әхлак проблемаларын кузгата.

Заманында «Йөрәктәге эзләр» романы төрле фикерләр уятты. Өлкән буыннан кайберәүләр әсәрне өнәп бетермәде һәм яшьләрне теләсә ничек тәнкыйтьләп ташларга була, дигән караштан чыгып, Газиз Мөхәммәтшинга шактый дорфа кагылучылар да табылды. Тупаслыкны Газиз авыр кичерде, эчтән тынды. Ул шыншырга, сыктарга-сыкрарга яратмый иде.

Гомеренең соңгы елында Г. Мөхәммәтшинның «Саумы сез, аккошлар!» дигән җыйнак кына лирик повесте укучыларга иреште. Шушы әсәр — аның аккош җыры, әдәбият сөючеләр һәм каләмдәшләре белән хушлашуы булды күрәсең.

Газиз Мөхәммәтшин каләмен драма жанрында сынап карады. Ул берничә пьеса язды. «Тынгысыз төн» комедиясе хәзерге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында уйналды, уңыш казанды, тамашачыларның алкышын яулады.

Газиз Фазлый улы Мөхәммәтшинның кыска тормыш һәм иҗат юлы хакында сөйләгәндә, аның журналист эшчәнлеге турында да искә алу мөһим. «Чаян» журналында әдәби хезмәткәр булганнан соң ул «Татарстан яшьләре» газетасе редакциясендә пропаганда-әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире вазифаларын үтәде.

Хәтердә болай калган.

Матбугат йорты коридорында очраштык.

— Ни хәлләр, Газиз? Ниләр майтарып йөрисең? — дим.

— Эшсезлектән аптырап, — ди бу, үзе елмая. — «Чаян»нан киттем. Җибәрделәр дип әйтимме?.. Кыскасы, бүгеннән анда эшләмим.

— Кая барырга ниятлисең?

— Уйлаган юк әле.

— Әйдә безгә, «Татарстан яшьләре»нә, бүлек мөдире булып.

— Ничегрәк була соң әле бу?

— Иртәгәдән бүлекне кабул итәсең, бүген комсомол өлкә комитетына барып киләбез. Килештекме?

— Их-ма, киттек! — диде ул, үзенә бик үк хас булмаган житезлек белән.

Берничә ай гына эшләде Газиз яшьләр газетасендә, аны «Ялкын» журналының редакторы итеп алдылар. Аннары, 1963 елдан 1965 елның маена кадәр, ул «Казан утлары»ның баш мөхәррире булды. Шуннан соң аның профессиональ язучылык чоры башланды.

1972 елның февраль башында ул санаторийда ял итеп кайтты. Кәефе мена дигән иде. Байтак сөйләшеп тордык. Шунда әйтте ул:

— Әнкәй авырып тора икән. Авылга, Яңа Бикчәнтәйгә кайтып килми ярамый, — диде.

Китте. Туган районы Минзәләгә китте. Атна уздымы-юкмы, Язучылар берлегеннән шалтыратып, фаҗигале хәбәр ирештерделәр: «Газиз Мөхәммәтшин вафат!..»

Ул көннәрдән бирле егерме елдан артык гомер узды инде, ләкин Газиз Мөхәммәтшинның үз образы күңелдә тоныкланмый. Бик сагындыра каләмдәш. Талантлы һәм кешелекле дустым сагындыра. Әсәрләрен кабат-кабат алып уку җанның сусынын баса, рәхәт бирә, ләззәт, ямь өсти. Бу инде каләмдәшнең янәбездә рухан яшәве.

**Барлас КАМАЛОВ.**

## Әхмәт Ерикәйнең тууына 90 ел

Шагыйрь Әхмәт Ерикәй (Әхмәт Фазыл улы Ерикеев) 1902 елның 16 декабрендә Башкортстанның Дуван районы, Өлкенде авылында туган. Яшьтән үк эшләп үсә: көтү көтә, байларга ялланып, әтисе белән бергә Злотоуст, Түбән Уфалы шәһәрләрендә көнлекче булып хезмәт итә; шул ук вакытта авыл мәктәбендә укый һәм үзлегеннән рус телен дә өйрәнә. Октябрь революциясеннән соң — волость ревкомында писарь булып эшли, һәм аның башкарма комитетында секретарь була; комсомол, партия органнарында хезмәт итә; шул ук елларда «Юксыллар сүзе» (Злотоуст) газетасында беренче шигырьләрен бастыра. 1927 елдан башлап, Әхмәт Ерикәй — Мәскәүдә; ул — журналистика институты студенты, «Эшче» газетасының җаваплы секретаре, «Ударниклар» журналын һәм Мәскәү пролетар язучылары берлеген (МААП) оештыручыларның берсе, Гослитиздатның СССР халыклары әдәбияты секторы мөдире, Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера театры студиясе ачылгач, М. Җәлил белән берлектә либреттолар язуны оештыручы һ. б. Сугышка кадәрге елларда аның үзенең дә күп җырлары халыкта киң яңгыраш таба: «Көккүк» (Солтан Габәши музыкасы), «Бибисара» (С. Сәйдәшев көе), «Комсомолка Гөлсара», «Яшь егетләр, яшь кызлар» һ. б.

Ватан сугышы елларында шагыйрь фронт газетасында хезмәт итә. 1945—50 елларда ул — Татарстан Язучылар берлеге идарәсе председателе. Ике тапкыр СССР Югары Советы депутаты булып (1946—1950 елларда) сайлана; Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнә. Ә. Ерикәй 1967 елның 15 сентябрендә Мәскәүдә вафат булды.

Иң беренче китабы «Ташлы дулкыннар» (1930 елда дөнья күрә); аннары татар, рус һәм башка телләрдә аның 60 ка якын китабы, шул исәптән берничә тапкыр «Сайланма әсәрләре»е дөнья күрде. Иҗатының төп өлеше — лирика һәм җырлар. Җыр өлкәсендә шагыйрьнең уңышлары — бәхәссез. Бүген дә композиторларыбыз әледән-әле аның шигырьләренә мөрәҗәгать итәләр: мәсәлән, «Яшьлегемә кире кайтыр идем», «Идел буе каеннары», «Төннәр буе йоклый алмый ятам» кебек җырлар соңгы елларда яңгыраш алды. Аның сүзләренә барлыгы 300 дән артык җыр язылган. 1982 елда дөнья күргән «Ике йөз җыр» китабы шагыйрьнең бу өлкәдәге хезмәтләрен шактый тулы чагылдыра. Егерменче гасырның бөтен каршылыкларын туплаган, тоталитар системаның үзе дә аңламастан корбаны булган күп әдипләрнеке кебек, Ә. Ерикәй иҗаты да — халкыбызның мәдәни дөньясының шул чордагы типик бер көзгесе.

Әмма, бөтен ялгышлары белән, кеше китсә дә, алдаусыз, ихлас йөрәктән булса — җыры, халыкчан сүзе кала. Әйе, җырлар кала...

Татар шигъриятенә һәм музыка дөньясына үзенчәлекле җырлар бүләк иткән шагыйрь Мостафа Ногман (Мостафа Ногман улы Ногманов) 1912 елның 22 декабрендә Татарстанның Арча районы Кызыл Яр авылында туган. 1931 елда ул Казан педагогия техникумын тәмамлый, Татарстан һәм Таҗикстан мәктәпләрендә балалар укыта. 1937—41 елларда Дүшәмбе педагогия институтында укый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947—51 елларда Мәскәү Көнчыгышны өйрәнү институтында укып, фарсы, төрек телләре буенча белгечлек ала, аннан Казанда аспирантурада укып, «XVII—XVIII йөзләрдә русча-татарча кулъязма сүзлекләр» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый — бу хезмәт 1969 елда китап булып басылды. 1960—76 елларда М. Ногман — университетта фарсы һәм борынгы татар теле укытучысы. Ул 1976 елның 4 сентябрендә Казанда вафат булды.

1944 елда беренче китабы дөнья күрә. Аннары унга якын шигырь, поэма («Кокушкино таңнары» һ. б.), тәрҗемә (Н. Хикмәт шигырьләре) китаплары басылып чыкты. Әмма иҗатының иң калку өлеше — җырлар. Җитмешкә якын җыр тексты калдырган шагыйрь исеме бүген дә радиодан һәм концерт-кичәләрдә еш яңгырый. Бигрәк тә Р. Яхин белән берлектә иҗат иткән җырлар («Оныта алмыйм»), «Күзләрем гел сине эзлиләр», «Бөдрә таллар», «Ак җилкән», «Салагыш болыннары», «Азин полклары» һ. б.) халыкта киң таралды. С. Садыйкова белән язган «Актаныш таңнары», «Арча кичләре», «Сөн буйлары бөдрә урман», Ф. Әхмәтов көй язган «Таң йолдызы» да — бу өлкәдә шагыйрьне таныткан җырлардан. Рус телендә «Грозовое лето» кебек (Детгиз, 1963) тәрҗемә китаплары да бар.

# 1992 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ

Татарстан Республикасы Президенты каршында Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды булдыру турында. № 3

«Казан утлары» журналы редакциясе коллективын Татарстан Республикасының мактау грамотасы белән бүләкләү турында. № 8

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1992 елгы Г. Тукай премияләрен бирү турындагы карары. № 6

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Туган як» мәдәни җәмгыятенең Гаяз Исхакый исемендәге премияләр бирү турындагы карары. № 4

### «КАЗАН УТЛАРЫ»НА — 70 ЕЛ

Ахунов Г. Әдәби мәккәбез яшәсен! № 5
Бәширов Г. Кыйбла билгеләгәндә... № 5
Гөрләп үтте безнең бәйрәмнәр *(Тантаналы кичәдән репортаж)* № 9
Еники Ә. Чорлар аша. № 5
Журналыбызны кемнәр житәкләгән? № 5
Ихсанова Л. Артта калган көннәр истәлеге. № 5
Котлаулар. №№ 5, 9
Мөхәммәдиев Р. Милли академиябез. № 5
Нәҗми Н. Әдәбият илчесе. № 5
Фәйзуллин Р. «Казан утлары» — безнең юл. № 5
Хәбибуллин М. Без тарихта эзлебез. № 5

### ОЛУГ ЮБИЛЕЙГА — ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ

Афзал Г. Алтын Урда. *Шигырь.* № 5
Зөлкарнәй Л. Бичура. *Шигырь.* № 5
Зөлфәт. Ялгыз сандугач. *Шигырь.* № 5
Измайлова Н. «Хор» дигән сүз бездә юк бугай. *Шигырь.* № 5
Морат Г. Җан сурәте. *Шигырь.* № 5
Низамиев Р. Бүген! *Шигырь.* № 5
Нәҗми Н. Шагыйрь итмәскә. *Шигырь.* № 5
Сүлти Р. Егерме ике. *Шигырь.* № 5
Шабаев М. И татар гынам... *Шигырь.* № 5
Юзеев И. Китәрмендер, ахры, бер көнне мин. № 5
Яруллин Ф. Әйтегез, әгәр белсәгез. *Шигырь.* № 5
Әгъләмов М. Иҗат. *Шигырь.* № 5

### БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАРЛАРЫ КОНГРЕССЫ

Бөтендөнья татарлары конгрессы. № 10
Ниятебез пакъ, юлыбыз туры *(Татарстан Республикасы Президенты МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВНЕҢ 1992 елның 19 июнендә Бөтендөнья татарлары конгрессындагы нотыгы).* № 8

### ДРАМАТУРГИЯ

Миңнуллин Т. Илгизәр + Вера. *Драматик хикәя.* № 9
Юзеев И. Ак калфагым төшердем кулдан. *Халык драмасы.* № 12

### ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Вергазов А. Кайту. *Роман.* № 4
Галиев Ә. Авылдашлар. *Роман.* №№ 9, 10
Гомәр Г. Юлбарыс тырнагы. *Маҗаралы чынбарлык.* № 8
Госманов М. Чәчелгән орлыклар. №№ 3, 4
Евгеньева М. Әби патшаның сөяркәләре. № 11
Исхакый Г. Көз. *Повесть.* № 2
Йосыпов С. Әсир истәлекләре. № 3
Кәрами Р. Каргышлы юллар. *Роман.* №№ 1, 2
Мостафин Җ. Шәҗәрә. *Хикәя.* № 12
Мөхәммәдиев Р. Сират күпере. *Роман.* №№ 4, 5, 6
Мөхәммәтҗан Р. Бүре сагышы. *Детектив әсәрдән өзек.* № 3
Низамиев Р. Билгесез кыз сурәте. *Хикәя.* № 3
Рәхим Г. Җәгүр дәдәй дәмәкләре. № 2
Рәхимов Җ. Батырша. *Роман.* №№ 7, 8, 9
Садриев Ф. Таң җиле. *Роман.* №№ 10, 11
Хафизова Р. Аккошлар сере. *Парчалар.* № 8
Хәлим А. Өя аяклы ат. *Повесть* № 6
Шаһимәрдән М. Кеше күңеле — карурман. *Повесть.* № 12
Әйди Т. Йөртә безне язмышлар. *Сәяхәтнамә.* № 11

### ШИГЪРИЯТ

Афзал Г. Күңел яктысы. *Шигырьләр.* № 6
Баянов Ә. Айга ялвару. *Шигырьләр.* № 2
Булгакова Д. Алдылар күңел күлемнән. *Шигырьләр.* № 3

Габдрәхим Ф. Кораб ясый татар. *Шигырьләр.* № 11
Гадел Ә. Татар зираты. *Шигырьләр.* № 11
Гаташ Р. Кышкы урманда йортлар бар. *Шигырьләр.* № 4
Гыйлаҗев И. Йолдызлардан эзлим үземне. *Шигырьләр.* № 7
Гыйззәтуллина Ф. Ирек юлы. *Поэма.* № 6
Дәүләтбаев Ф. Язмыш. *Шигырьләр.* № 2
Зойнашева Г. Яңа җырлар. № 2
Зәйдулла Р. Кичектергән сәфәр. *Шигырьләр.* № 9
Зөлфәт. Матур бабай. *Шигырьләр.* № 8
Иделбикә. Идеалыма. *Шигырьләр.* № 3
Каюмов М. Дүртенче. *Шигырьләр.* № 12
Латыйп К. Иман кәрваны. *Шигырьләр.* № 12
Лерон Л. Болгавыр заман шагыйренә. *Шигырьләр.* № 4
Лерон Л. Багышлаулар бәйләме. *Шигырьләр.* № 5
Мансуров З. Соңгы сәхнәгә бару. *Шигырьләр.* № 1
Маннап Ш. Кышым белән язым күрешкән мәл. *Шигырьләр.* № 3
Морат Г. Ачлык. *Поэма.* № 8
Мостафин К. Яңа шигырьләр. № 11
Мәлияр Н. Карыйм тауга, упкыннарга. *Шигырьләр.* № 6
Мөхәммәтшин Г. Таңнар, каеннар. *Шигырьләр.* № 11
Мөслимова Ф. Корьән арасында сакланган борынгы хат-шигырь. *Шигырьләр.* № 3
Рафаил. Мизгел. *Шигырьләр.* № 10
Рәхмәтулла С. Ага сулар. *Шигырьләр.* № 11
Сибгат К. Акылдан язган рәссамнар күргәзмәсе. *Шигырьләр.* № 2
Төхфи Х. Газәл. *Шигырьләр.* № 2
Харис Р. Боек хәбәр. *Шигырьләр.* № 7
Хәбибулла М. Көн сурәтләре. *Шигырьләр.* № 6
*Хәким З. Изге җир. Шигырьләр.* № 2
Хөсәен М. Моң канатларында. *Шигырьләр.* № 12
Шагыйрьҗан Л. Өченче микрофон. *Поэмадан өзек.* № 7
Шәфи Р. Күтәр башыңны, татар. *Шигырьләр.* № 12
Юзеев И. Килеп сөялдең касыга. *Шигырьләр.* № 4
Яруллин Ф. Һаман да бер үк кыйблам. *Шигырьләр.* № 7
Яхин Ф. Коръәнгә таяну. *Шигырьләр.* № 11
Әхмәтҗанов Роберт. Туу. *Шигырьләр.* № 9
Әхмәтҗанов Рәшит. Колшәриф. *Поэма.* № 1
Әхтәмова Р. Ташлар эзлим Алабугада. *Шигырьләр.* № 2
Әюп Х. Кош славы. *Шигырьләр.* № 3
Әһлия Ф. Җанымны саклап. *Шигырьләр.* № 3

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Вафин М. Табигать минс кабатлый. *Шигырьләр.* № 11
Исмәгыйлева Ф. Сиңа. *Шигырьләр.* № 4
Нәзиров М. Чакматаш. *Шигырьләр.* № 11
Рахман Р. Керфекле тәрәзәләр. *Шигырьләр.* № 10
Яруллин Ф. Таныштыру сүзе. № 3
Әхтәмова Р. Ә син беләсеңме? *Шигырьләр.* № 3

## ӘДӘБИ МИРАС

Балта әкияте. № 8
Вәлиев З. Милли мәдәниятне яклап. № 3
Гасыр башы шигъриятеннән. № 5
Ибраһимов Г. Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? № 3
Йөрәктәге тынгысызлык (*Язучы Газиз Кашаповның туына — 50 ел*). № 8
Каран Л. Сөембикә һәм татар бәйсезлеге. № 8
Шамуков Г. Язучы архивыннан. № 3

## ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Акутагава Р. Чытырманлыкта. *Новелла.* № 10
Амаду Ж. Габриэланың гыйшкы. *Романнан өзек.* № 10
Ницше Ф. Уймак уйлар. № 2
Уймак уйлар. №№ 8, 11
Эйди Т. Тыелган исем һәм иҗат. № 2

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Шабаев М. Таборда — учак янында. № 6.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Булатов Н. Туган туфрак җылысы. № 12
Гайфуллин В. Татар мәктәбе: алда нинләр көтә? № 10
Галиуллин Т. Замана балалары. № 6
Дунай Ф. Иманнар какшаган дәвер. № 2
Еники Ә. Ялганны яклау. № 4
Кашаф-Үзиле. Г. Фаҗига. № 2
Рәхимкулова М., Хәмидуллин Л. Университетлар урнәгендә. № 7
Сибәгат Р. Башкортстан татарлары һәм аларның теле. № 1
Сәлахов И. Кара көннәр. Истәлек. № 8
Тимбикова К. Хәлең ничек, ил кызы? № 3
Хатипов Ф. Язмышыбыз. № 11
Юныс М. Шәфкать кыйбласы. № 1
Әхмәтова Ф. Камиллеккә омтылу. № 1

## ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Юныс М. Мал бүләбезме? № 8
Әхмәтҗанов М. Татар-башкорт дуслыгы. № 5

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Бәширов Ф. Галиҗанап сүз остасы. № 12

Вәлиев Р., Мәһдиев М. Болганчык еллар авазы. № 1
Галимуллин Ф., «Ни өчен?»нәр турында. № 11
Галиуллин Т. Тарихыңны онытсаң — юк киләчәгең... № 11
Заман сулышын тоймасаң... *(Язучы һәм галим Альберт Яхин белән әңгәмә)*. № 9
Кәшфиева Л. Яңарыш һәм сатира. № 7
Нәҗми Н. Гомернең дәвамы. № 1
Поварисов С. Яфраклар коелмасын иде. № 6
Тукайга тугры булып *(Язучы Ф. Баттал белән әңгәмә)*. № 4
Хафизов С. Янача караш кирәк. № 7
Хәйретдинов С. Еракгагы якын матбугат. № 5
Хәсәнов М. Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре. № 1
Әхмәдуллин А. Тарихны яңадан язганда. № 4

## БЕЛОРУС ТАТАРЛАРЫ АВЫЗ ИҖАТЫННАН

Тапкыр егет. Әкият. № 8

## ЮМОР-САТИРА

Сәлимов М. Бигрәк шәп илебез! *Сатирик хикәя.* № 8

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Галимуллин Ф. Үр артында үрләр. № 8
Тимбикова К. Ихлас җан. № 3
Әмирхан Р. Борынгы тамырлар эзеннән. № 1

## ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Мостафин Р., Даутов Р. Репрессияләнгән татар язучылары. № 2—4.

## МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Абдуллин Я. Тәнзыймат һәм Идел-Урал татарлары арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте. № 5
Алишев С. Тарихи баганышлар. № 6
Алишев С. Татар халкының батыр улы. № 7
Апакай С. Сан-Францискода татар җәмгыяте. № 5
Баязитова Ф. Керәшен татарларының йолалары һәм йола җырлары. № 6
Булатов В. Гореф-гадәт, йолаларыбыз. № 8
Вәлиев Ф. Себердә ислам. № 5
Гарипова Ф. Тарихи катламнарыбыз. № 2
Еллар авазы *(Кереш сүз белән)*. № 2
Исхакова С. Рухи хәзинәләребезне саклаучылар. № 6
Кулиев В. Мирза Кәзимбәк һәм татар мәгърифәтчеләре. № 5
Мөхәммәтҗанов Р. Ел фасылларына бәйле йолалар һәм җырлар. № 1
Мәмәт А. Кырым татарлары. № 5
Солтанбеков Б., Шәрәфетдинов Д. Фаҗигале язмыш. № 2
Солтангалиев М. Мин ялгыштыммы? № 2
Шакир С. Очрашулар. № 6
Әмирхан Р. Гали рухлы шәхес. № 6
Әхмәтҗанов М. Сабирҗан акын. № 2

## СҮЗЛӘР ТАРИХЫННАН

Фәттах Н. Башкорт һәм башкырт. № 8

## КАЙТКАН ИСЕМНӘР

Гыйләҗиева Р. Ялкынлы моң. № 5

## ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

Гайнетдинов М. XVII йөздә татар яңарыш хәрәкәте. №№ 7, 8
Әхмәт Тимер. Бөек шәхесләребезнең берсе. № 12

## ТАРИХЫБЫЗ БИТЛӘРЕННӘН

Беренче Петр «Васыятьнамәсе». № 1
Исхакый Г. Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре. № 9
Кәримуллин Ә. Гаяз Исхакыйның Шиһап Мәрҗани турындагы мәкаләсе уңаеннан. № 9
Әйди Т. Яшерен васыять. № 1

## СӘНГАТЬ

Бәширов Г. Күңеле тулы җыр иде. № 12
Вәлиева-Сөләйманова Г. Сынчы Кадим Җәмитов. № 4
Галимуллин Ф. Татар дикторы. № 5
Гобәйдуллин Х. «Нур»да балкыган гомер. № 5
Зәйнашева Г. Сагынулары биниһая. № 8
Илялова И. Үзебезнеке, халыкныкы! № 1

**Укучы сүзе.** №№ 5, 12

## ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

Надир И. Финляндия татарлары. № 2

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Әхмәтҗанов Рәшит. Кешеләрне яклап яшәде. *(Нури Арслановның тууына 80 ел)*. № 9

Арсланов Н. Тотыла. Шигырьләр. № 9
Гали Хуҗиның тууына 80 ел. № 10
Камалов Б. Сагындыра каләмдәш. *(Язучы Газиз Мөхәммәтшинның тууына 60 ел).* № 12
Әхмәт Ерикәйнең тууына 90 ел. № 12
Мостафа Ногманның тууына 80 ел. № 12

## ГЫЙБРӘТЛЕ МӘГЪЛҮМАТЛАР

Күченүләрдә үзгәреш. № 8
Рәсәй империясе тарихыннан. № 8
Тарихыбыз хатирәләре. № 8

## КОТЛЫЙБЫЗ

Айдар Хәлимгә — 50 яшь. № 1
Кадыйр Сибгатка — 50 яшь. № 2
Азат Вергазовка — 60 яшь. № 3
Азат Ганиевка — 50 яшь. № 5
Равил Вәлиевкә — 50 яшь. № 8
Камил Мостафинга — 60 яшь. № 11
Лирон Хәмидуллинга — 60 яшь. № 11

## ЛАТИН ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Дәрдмәнд. Без. *Шигырьләр.* № 10

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Вәлиева-Сөләйманова Г. Наил Лотфулла әсәрләре. № 1
Рәис Гаитов иҗаты. № 2
Вәлиева-Сөләйманова Г. Мәңгелек мәхәббәт образы. № 3
Вәлиева-Сөләйманова Г. Сынчы Кадим Җәмитов. № 4
Татарстан Республикасының Дәүләт гербы. № 5
«Диңгез буенда». *Санкт-Петербург рәссамы Рәшит Дәминов эше.* № 6
«Батырша». *Уфа шәһәре рәссамы Мэлс Вафин эше.* № 7
Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә Каенлыкта *(Казан)* үткәрелгән сабантуй бәйрәме. Мәйданда — татарча көрәш. № 8
Иярләр, албастылар, убырлар. № 9
Вәлиева-Сөләйманова Г. Бабайлар туп тибә. № 10
Вәлиева-Сөләйманова Г. «Ак чилләк бик матур була...» № 11
Вәлиева-Сөләйманова Г. № 12

**Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан.** № 1—12

## ҮЗ КОНСТИТУЦИЯБЕЗ БУЛДЫ!

Татарстан җөмһүриятенең мөстәкыйльлеге айдан-айга, елдан-елга ныгый бара. Әле Югары Советның октябрь ахырында башланып ноябрьнең 6 сында тәгәлләнгән XII сессиясендә үз Конституциябез кабул ителү — безнең мөстәкыйльлегебезне ныгыту юлында иң зур һәм әһәмиятле адымнарның берсе.

Бу Конституция — бәйсез Татарстан мәнфәгатьләрен чагылдырган тарихтагы беренче Конституция. Ул кемнәрнеңдер ихтыяры буенча гына түгел, ә моннан ике ел элек кабул ителгән бәйсезлек турындагы Декларациядә һәм 1992 елның 21 мартындагы референдумда чагылыш тапкан халык ихтыярыннан килеп чыкты.

Төп Законыбыз бәйсез республикабызның барлык халкына: татарларга, урысларга, мариларга, чувашларга, удмуртларга, яһүдләргә һәм башкаларга тигез, гадел хезмәт итәргә алынды.

Сессия шулай ук «6 ноябрь — Татарстан Республикасы Конституциясе көне» — ягъни бәйрәм көн дигән яңа закон да чыгарды.

Ә ноябрь ахырында булып үткән XIII сессия исә яңа Конституцияне гамәлгә кертү турында аерым карар кабул итте.

## ВЕНГРИЯ ҺӘМ ЛИТВА БЕЛӘН КИЛЕШҮ

Бәйсез Татарстан дәүләтебез якындагы һәм ерактагы илләр белән бер-бер артлы килешүләр төзи. Үткән ноябрь аенда гына да Европаның ике иле белән әнә шундый тигез килешүләргә кул куелды. Билгеле булганча, үзләренең урнашу урыннары буенча да, шулай ук экономик һәм башка мөмкинлекләре ягыннан караганда да — болар белән бәйләнеш һәм товар алмашу безнең өчен бик мөһим. Икенче төрле итеп әйткәндә, моны Европага юл салу дияргә мөмкин.

Аннан алдарак кына Президентыбыз М. Шәймиев җитәкчелегендәге делегациянең Төркиягә барып, шулай ук гаять мөһим килешүләр төзеп кайтуын искә төшерсәк — икътисади бәйләнешләрне ныгытуда алга баруыбыз тагын да ачыграк күренер.

## ЛАТИН ХӘРЕФЕНӘ ТАБА

20 ноябрь көнне Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында республикабызның әдипләре, галимнәре һәм, гомумән, күпсанлы мәдәният әһелләре җыйналып, латин графикасына кайту зарурлыгы турында гаять әһәмиятле фикер алышу уздырдылар. Сүз алып сөйләүчеләр арасында әдипләребез Әмирхан ага Еники, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Рабит Батулла, Лена Шагыйрьҗан, Җәүдәт Дәрзаман, Камил Кәримов, ә галимнәрдән Мирфатих Зәкиев, Вахит Хаков, Рүзәл Йосыпов, Әбрар Кәримуллин, Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Хәләф Курбатов һәм башкалар бар иде.

Җыелыш безнең телгә ят булган кириллицадан латин графикасына кайту теләген белдереп бердәм карар чыгарды. Шулай ук, гаять әһәмиятле бу чараны тизрәк гамәлгә ашыра башлау зарурлыгын искәртеп, Президентыбыз М. Шәймиевкә мөрәҗәгать кабул итте.

Галимнәр һәм язучылар тәкъдим иткән бу реформа турында югары дәрәҗәдәге соңгы карарны кабул иткәндә, әлбәттә, үткән хәреф алмаштыруларның гыйбрәтле сабаклары да истән чыгарылмаска тиеш.

## ИСӘНБӘТ ИСЕМЕ МӘҢГЕЛЕК

Әдәбиятыбыз аксакалы Нәкый Исәнбәт күптән түгел безнең арадан китте. Аның бай мирасы безгә һәм киләчәк буыннарга калды.

Шушы көннәрдә Татарстан Президенты М. Шәймиев «Нәкый Исәнбәтнең истәлеген мәңгеләштерү турында» Указ чыгарды. Аның нигезендә Татарстан Министрлар Кабинеты әдибебезнең исемен мәңгеләштерү буенча чаралар күрергә тиеш. Информация һәм матбугат министрлыгына, Фәннәр Академиясенә олуг язучының иҗат мирасын барлау, саклау һәм әсәрләрен бастырып чыгару бурычы йөкләнә.

Әйе, олы әдипнең һәм киң колачлы галимнең чын зурлыгы елдан-ел ныграк ачылачак.

## ИСЛАМ ТАБИБЛАРЫ БЕРЛӘШТЕ

13 ноябрь көнне Казан дәүләт медицина институтының Актлар залында Татарстанның Ислам табиблары берләшмәсен оештыру конференциясе булды. Ул халык сәламәтлеген, шул исәптән, аның рухи сәламәтлеген саклау эшендә ислам табибларын берләштерү, дини шифаханәләр ачу, ислам принципларына туры китереп халыкның медицина культурасын үстерү һәм шуңа охшаш башка максатлардан чыгып үткәрелде.

Конференциягә килгән 59 делегат арасында Казан вәкилләреннән тыш, чит мәмләкәтләрдән килгән табиблар да бар иде. Шулай ук, Татарстан районнарыннан да байтак кеше катнашты.

Бу җыенда чыгыш ясаучылар күп булды. Алар барысы да медицина өлкәсендәге милли традицияләрне яңарту һәм аларны тагын да үстерү кирәклегенә басым ясадылар. Конференциядә Татарстан Ислам табиблары ассоциациясен оештырырга дигән нәтиҗә ясалды.

## ГАТАУЛЛА КАМСКИЙ УҢЫШЛАРЫ

Соңгы елларда АКШта яши башлаган яшь шахматчыбыз Гата Камский турында хәзер бөтен дөнья матбугаты яза. Чыннан да, яңа иҗади мөмкинлекләр ачылгач (ягъни элекке Ленинград шәһәрендә яшәгәндә аларга карата булган көчле басымнан котылгач), бер-бер артлы ул дөнья масштабында байтак зур-зур җиңүләр яулады. Шулардан берсе: ноябрь ахырында Мәскәү шәһәрендә бөек шахматчы А. Алехинның тууына 100 ел тулуга багышланган мемориалда да Г. Камский уңышлы чыгыш ясады һәм икенче урынны алды.

Ярышлар вакытында атаклы шахматчыбыз Татарстан Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин белән дә очрашты. Ә ай ахырында Г. Камский һәм аның әтисе Рөстәм Казанга килделәр. Татарстан Язучылар берлегендә алар белән очрашу булды. Шахмат сөючеләр Гата белән көч тә сынаштылар.

## ЯЗУЧЫ СӘЯХӘТТӘ

Журналыбызның фән бүлеге мөхәррире Тәүфикъ Әйди төрек-татарларның бүгенге хәлен ачыклауга багышлап Румыниянең Күстәнҗә шәһәрендә уздырылган халыкара симпозиумда катнашты һәм чыгыш ясады. Шуннан соң Бухарест шәһәрендә Румыния мәдәният министрлыгының азчылык милләтләр бүлеге һәм татар-төрек телләрендә басыла торган «Карадиңгез» гәзите редакциясе хезмәткәрләре белән очрашты. Ул шулай ук Төркиянең Истанбул шәһәренә кагылып, «Күпрү» журналы, «Заман», «Яңа Азия» гәзитләре редакцияләре эше белән дә танышты.

Татар әдибенең Истанбулга һәм Румыниягә килүе хакында хәбәр иткән «Заман» (13.X, 16.X), «Карадиңгез» гәзитләре бу көннәрдә үз укучыларын татар матбугаты белән таныштырды. «Күпрү» журналы Татарстан турында күләмле интервью әзерләде.

## ӘДӘБИ ФОНД ТА — ҮЗЕБЕЗНЕКЕ!

Татарстан Язучылар Берлегенең Россиядән аерылуына байтак гомер үтте. Ләкин, шуңа да карамастан, иҗатчыларыбыз турында матди яктан кайгыртучы Әдәби фонд әле һаман да Федерация карамагында калып килә иде. Бу хәл, әлбәттә, татар язучыларын һич кенә дә канәгатьләндермәде.

12 ноябрьдә булган җыелышта язучыларыбыз Татарстанның мөстәкыйль Әдәби фондын оештырдылар. Бу көнне шулай ук Әдәби фондның уставы да кабул ителде. Ахырдан яңа идарә сайланды. Анда шагыйрь Рафис Корбан Татарстан Әдәби фондының рәисе итеп тәгаенләнде.

## ШАГЫЙРӘ — ХАЛЫК АЛДЫНДА

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубы үзенең эшен көздән матур гына башлап җибәрде. Анда хәзер атна саен диярлек кызыклы кичәләр үткәрелә.

Ноябрь башында шундый кичәләрнең берсе шагыйрә, халык яраткан күпләгән җырлар авторы, республикабызның Г. Тукай исемендәге бүләге лауреаты Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган иде. Бу кичәдә шагыйрәнең иҗади дуслары: Татарстанның атказанган артисткасы җырчы Флүрә Сөләйманова, композитор Риф Гатауллин, яшь җырчы Рафаил Җаббаров һәм җырчы Шакировлар гаиләсе дә катнашты.

Җыелган кешеләр күңеленә бик тә хуш килгән бу очрашуны шагыйрә Г. Зәйнашева үзе алып барды һәм залдагыларның күп санлы сорауларына җаваплар бирде.

## ГҮЗӘЛ ВАФИНАНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның атказанган артисткасы, биюче Гүзәл Вафинаның бенефисы — иҗат кичәсе булды. Шыгрым тулы зал артистканың төрле-төрле халык биюләрен югары сәнгать дәрәҗәсендә башкаруын карап сокланды, аны алкышларга һәм чәчәк бәйләмнәренә күмде.

Күренекле биючебез иҗат бәйрәменә ул укып чыккан Алабуга педагогия институтыннан, Төмәннән һәм башка төбәкләрдән кунаклар да килгән иде. Алар да артистканы кайнар котладылар, киләчәктә дә зур иҗат уңышлары, сәламәтлек теләделәр.

Бу кичәдә шулай ук халкыбызның яраткан артистлары Илһам Шакиров, Айрат Арсланов, Гөлзада Сафиуллина, Хәмдүнә Тимергалиева, Зөһрә Шәрифуллина, Зөфәр Хәйретдинов, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Татар дәүләт филармониясе, төрле ансамбльләр артистлары, музыкантлар, язучылардан Камил Кәримов, Зөлфәт, артистканың авылдашы Шамил Маннапов һәм башкалар катнашып, чыгыш ясадылар.

— Биюче артистлар иҗатына багышланган беренче бенефис бу. Киләчәктә бу матур традицияне дәвам итәрбез — диде концертны алып баручы Рәшит Сабиров.

## ЯЗУЧЫЛАР БҮЛЕГЕ АЧЫЛДЫ

Янаул шәһәрендә Башкортстан Язучылар берлегенең яңа бүлеге ачылды. Бүлекнең рәисе итеп Фәрит Суфияров, ә җаваплы сәркатибе итеп Финат Шакирҗанов сайландылар.

Бу бүлек Башкортстанда татарлар яши торган шәһәр һәм районнардагы иҗат көчләрен бергә туплауны күздә тота. Аңа «Дуслык» нәшрияты хезмәт күрсәтергә әзер.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткәне өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Хәлим Бәдри улы Җәләловка «Татарстан Республикасының халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде. Шундый ук олы исемне безнең яраткан җырчыбыз Венера Ганиева да алды. Халкыбызның сәхнә йолдызларын югары исем алу белән кайнар котлыйбыз һәм аларга өр-яңа иҗат уңышлары телибез!

# КИЧКЕ ТЫНЛЫК

Сезнең алдыгызда Башкортстанда яшәүче татар рәссамы Рафаэль Кираев ясаган күренеш. Ул үзе Стәрлетамак шәһәрендә 1955 елда туган, бүген дә шунда яши һәм иҗат итә. Рафаэль Йошкар-Олада сәнгать училищесын тәмамлаган, союз күләмендәге һәм чит илләрдә оештырылган күргәзмәләрдә катнашып үзен сәләтле рәссам итеп танытхан кеше. Рафаэль Кираев иҗат иткән бу рәсем узган ел Санкт-Петербургта үткәрелгән Беренче республикаара татар сәнгате «↑АТАРТ» күргәзмәсенә куелган иде, ул Казан тамашачыларына да күрсәтелде.

Гигант промышленность предприятиеләре белән тулган Стәрлетамак шәһәренең иске бер урамы күз алдына килеп баса. Тамаша кылучы рәссамның романтик карашы аша гади бер урамны күзәтә, анда шәһәр ыгы-зыгысыннан бер читтәге почмак күрсәтелгән, ул ниндидер бер сафлык чыганагы кебек, үзенең гадилеге, самимилеге һәм җылылыгы белән кешеләргә рух биреп тора сыман. Табигать һәм урамдагы йортлар, беренче карашка, аерым-аерым кисәкләрдән торган кебек булса да, рәссам аларны яшәеш өлгесе итеп берләштергән, нәтиҗәдә пластик образ килеп туган. Рәссам төсләр гаммасы аша үзенең уйларын, фикерләрен, кичерешләрен бирә алган. Ул үзенчәлекле алымнар белән, артык вакланмыйча гына моңа ирешә алган. Рафаэльнең осталыгында скульпторның таш белән эш иткәндә ошамаган кисәкләрне китеп-китеп алуы чагыла. Рәсемдә икенче дәрәҗәдәге вак детальләрне тапмыйсың, алар урынына декоратив өслектә график төсләүләр зур урын ала һәм ниндидер кискенлек тә тудыра.

Яктылык һәм күләгә, ак һәм кара, алтынсу-сары һәм зәңгәрсу-соры төсләр контрастлык тудыру белән бергә төрле геометрик фигуралар да төзиләр. Пирамида рәвешендәге түбәләр, турыпочмаклык кебек йортлар кискен ритмнар бирәләр. Композицияне шундый юл белән төзү рәсемгә халык сәнгате төсмерләрен кертә. Кираев төсләр аша төрле формалар бирә һәм графика ысулы белән йортларны аерымлап та ала. Йорт каршындагы баганадагы лампадан төшкән яктылык моңа тагын да нур өсти. Тәрәзәдән юлга төшкән алтынсу-сары яктылык үзеннән-үзе рәсемгә тормышчанлык кертә. Туган йортның җылылыгы, тынычлыгы тамашачыга рәссам күзлеге аша якты хисләр алып килә. Рәсем кино экранындагы кебек хисләребезне тоткарлап кына калмый, ул тамашачыны оста белән бергә шатланырга мәҗбүр итә. Бу инде кышкы кичнең болытларда чагылышы да, иске шәһәрнең тыныч тормышын сагыну да һәм аның тыйнак матурлыгы белән соклану да кебек. Һичшиксез, рәссамның үзенең туган җирен яратуына һәм аның матурлыгын тоя белүенә, аңа соклануына ышанасың.

**Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЙЛӘЙМАНОВА.**

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган әдип, Татарстанның Г. Тукай исемендәге бүләге лауреаты Гәрәй Рәхим.

## АВТОРЛАРЫБЫЗ ИГЪТИБАРЫНА!

Журналыбызда басылып чыккан әсәрләр өчен каләмхак (гонорар) күләме шактый арттырылды. Шул нисбәттән авторларга акча күчерү эшендә дә өстәмә кыенлыклар килеп туды. Күп кенә авторлар үзләренең саклык кассалары турындагы мәгълүматларны дөрес һәм төгәл итеп бирә белмиләр. Шунлыктан каләмхак акчаларының барып җитмәү һәм, тагын да кызганычрагы, хәтта югалу очраклары да бар.

Авторларыбызны искәртәбез, саклык кассаларына акча күчертергә теләгән очракта, түбәндәге таләпләрне истә тотып мәгълүматлар бирергә кирәк:

**1. Сезнең акчаларыгыз саклана торган саклык банкының почта индексы күрсәтелгән төгәл адресы.**

**2. Төп банкның тулы һәм төгәл исеме (чөнки хәзер банклар бик күп һәм төрледән-төрле), коды, исәп-хисап номеры.**

**3. Һәм, ниһаять, үзегезнең саклык кенәгәгезнең исәп-хисап номеры белән дөрес язылган исемегез, атагызның исеме (отчество), фамилиягез.**

Кыскасы, бухгалтерлар теле белән әйткәндә, тулы реквизит булу шарт.

Моның өчен авторларыбызга, иренмичә үз банкларына барып, кирәкле барлык мәгълүматларны язып алырга һәм безгә хәбәр итәргә тәкъдим итәбез.

Дөрес һәм төгәл язылган реквизит үрнәген сез журнал тышлыгының икенче битендә бирелгән белдерүдән укып белә аласыз. Анда журнал редакциясенең үз реквизиты күрсәтелгән.

Бәясе 1 сум 80 тиен

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог